ISSN 0206-4189

# казан утлары

1.1996





**ФАТИХ ӘМИРХАН**
**(1886—1926)**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(879)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Т. ГАЛИУЛЛИН. Тәүбә. *Роман* ........ 3
И. ЮЗЕЕВ. Ут эчендәге чәчәк. *Шигырьләр* 78
Ф. ЯРУЛЛИН. Шушы килеш яратыгыз *Шигырьләр* ........ 84
Г. ГАТАУЛЛИН. Дөнья бу. *Шигырьләр* .... 123

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Ф. БӘЙРӘМОВА. Атылган йолдыз. *Драма* ........ 90

ИЛДУС ГЫЙЛӘҖЕВКА 50 ЯШЬ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Болай гына гади күренә ул... ........ 115
И. ГЫЙЛӘҖЕВ. Кемдә гаеп? *Шигырьләр* . 117

ХӘТЕР

Р. БАТУЛЛА. Акчарлакның сагышы *(Үлеменә бер ел тулу уңаеннан шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанга мәрсия)* ........ 127

ОНЫТЫЛГАН ИСЕМНӘР

Б. СОЛТАНБӘКОВ. Әскәр Али улы Шәех-Али ........ 132

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН. Садри Максуди — олуг галим ........ 141

ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Ф. БӘКХАН. Казаннан ........ 151
Укмасый хәтерендә Әмирхан ........ 154
Фатих Әмирхан турында истәлекләр ........ 156
РАВИЛ ӘМИРХАН. Шомлы еллар кайтавазы ........ 167

Ш. МАННАП. Әз-мәз генә мәзәк хәлләр .. 177
Безнең календарь ........ 184
Укучы сүзе ........ 185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12.

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Т. ГАЛИУЛЛИНА «Покаяние»; стихи И. ЮЗЕЕВА, Ф. ЯРУЛЛИНА, Г. ГАТАУЛЛИНА.
«К 95-летию Хади Такташа»: драма Ф. БАЙРАМОВОЙ «Такташ».
«К 50-летию Ильдуса Гилязова»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА «Простым он только кажется...», стихи И. ГИЛЯЗОВА.
«Память»: статья Р. БАТУЛЛЫ «Тоска чайки».
«Забытые имена»: статья Б. СУЛТАНБЕКОВА об изобретателе первых татарских пишущих машинок на основе арабской и латинской графики Аскар Шаех-Али.
«К истории культуры»: статья Я. Абдуллина «Садри Максуди — выдающийся ученый».
«К 110-летию Фатиха Амирхана»: статья Ф. БЭКХАНА «Из Казани»; воспоминания о Ф. Амирхане, статья Р. АМИРХАНА «Эхо трагичных лет».
Забавные рассказы Ш. МАННАПОВА.
«Наш календарь».
«Слово читателя».
«На наших обложках»: «С Новым годом» — фоторепродукция из картины народного художника Татарстана М. Усманова; поэт И. Гилязов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: T. Caliullin's novel «Confession»; the verses of I. Yuziev, Ph. Yarullin, G. Gataullin.
«Commemorating the 95 th anniversary of Khadi Taktash»: Ph. Bayramova's drama «Taktash».
Commemorating the 50 th anniversary of Ildus Gilyazov»; R. Phaizullin's article « He only seems to be simple»; I Gilyazov's verses.
«Memory»: R. Batulla's article «Sea-gull's melancholy».
«Lost Names»: B. Sultanbekov's article is about the in inventor of Tatar type-writer on the basis of Arabic and Roman script Askar Shaekh Ali.
«To the history of culture»: Ya. Abdullin's article «Sadri Maksudi — the eminent scientist».
«Commemorating the 110 th anniversary of Phatikh Amirkhan's: Ph. Amirkhan»s article «From Kazan»; the articles «Amirkhan Is in Ukmasi's Memory»; «Reminisences about Phatikh Amirkhan»; R. Amirkhan's article «Echo of disturbed years'Sh. Mannap's merry stories.
«Our Calendar.»
»Reader's Word».
In our corvers: the reproduction from the picture of Honoured Artist of the Tatarstan Republic M. Usmanov «Happy New Year»; the poet I. Gilyazov.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 2.12.95 ел. Басарга кул куелды 25.01.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 063. Заказ Д-623.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.



## Тәлгат Галиуллин

# ТӘҮБӘ

РОМАН

1

— Сәет!
— Әү, балам.
— Сәет!
— Кем тия? Кайсы миһербансызы рәнҗетә? Әйт үземә, мин аны... Хәзер кызган табага утыртам.
— Яратасыңмы мине?
— Соң! Бу хакта бөтен дөнья белә. «Азатлык»тан әйттеләр,— ди бер саескан.
— Чын-чынлапмы?
— Ну!
— Мин яраткан кебек, өзелепме?
— Комсызланма, Зөлфия, яратканымны болай да беләсең бит инде. Сиңа ни кирәк тагы?
— Күзгедәге сыныбызга карап ант ит, Сәет.
— Коръән тотып әйтә алам, таң кызым.

Иркәләнәсе, кытыгы килгән яшь ханымның «миңа чаклы йоклаган хатыннарыңнан артыграк сөясеңме», «мәңгегә бергә булырга вәгъдә суы эчә аласыңмы» кебек әллә ниткән сорауларны тезәсе килеп, теле кычытса да, үзен вакытында тыеп кала алды. Авыл тәрбиясе алган кешедә чама хисе җиңде. «Артык бәйләнәсең, нарат чәере кебек ябышсаң, куып чыгарырга да күп алмас, талканы коры күренә»,— дип, сүзне икенчегә күчерде. Яратканы сулыш алуыннан, йөрәге тибешеннән үк сизелеп тора ләбаса.

Зөлфия, аккош муеныдай ап-ак ялангач беләкләрен юрган астыннан чыгарып, ике кулы белән киң агач ятакның башына тотынып, рәхәтләнеп киерелде, сузылды, кан күзәнәкләрен уятып җибәрде.

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938)—*әдәби тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор, РФ гуманитар фәннәр академиясе академигы, Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы.*

Бала имезмәгән хатын-кызны бизи торган, өлгергән эре алмадай тыгыз, очлы күкрәкләре иреккә калкып чыкты, ак куян башы кебек йомры җилкәләре ачылды. Ялангач ир ханымның бер күкрәген учына алып, тәнен иркәли, сөя башлады. Шуны гына көткәндәй, Зөлфия буш сүз көрәштерүдән туктады, ирдән иңгән куәткә буйсынып, аның ягына борылды, бит очларына куе алсулык типте, борын яфраклары узыштан кайткан атныкы төсле киңәеп китте, бөтен гәүдәсе җил тараткан йомшак тал мамыгыдай сәгадәт-бәхет эчендә эреде, юкка чыкты, хуҗасына буйсынмас хәлгә килде.

Мәхәббәтнең сихри көче аларны җәннәт упкынына сөйрәде.

Менә инде алар тышкы мохит белән алыш-бирешне өзеп, телефонга якын килмичә, ишекне ачмыйча, үзләре дә беркая чыкмыйча, биш көн, биш төн ирекле зиндан рәхәте кичерәләр.

Янында чалкан яткан тыгыз гәүдәле ирнең үзенә кем тиешле икәнен Зөлфия тәгаен әйтә алмый. Хатынымы, яраткан сөяркәсеме, урамда эләктергән чираттагы юанычымы? Күпме яшәтер ул аны Сталин заманында салынган биек түшәмле, киң тәрәзәле иркен фатирда.

— Без монда медовый атнабызны уздырырбыз. Аннан соң, рәсми өйләнешкәч, ходаның амин дигән вакытына туры килсә, сәяхәткә чыгып китәрбез. Синең туган авылыңамы, чит илгәме, күз күрер,— дигән иде Сәет беренче зөфаф кичендә.

Вакытның шулай аккан судай тиз үтүенә ышанмый иде Зөлфия әлегә чаклы. Санаулы, серле, бәхетле көннәр ишле гаиләнең сандык төбендәге тәгамы кебек тиз сызыла икән шул. Еллар үткән саен язлар җитми, төннәр кими, дип язган икән бер шагыйрь, тикмәгә түгелдер? Үзе дә шуны кичергәндер?

Сәете бүген гадәттәгедән кырысрак күренә. Зөлфия туйдыра башладымы, әллә башка нәрсә, тормыш мәшәкатьләре күңелен тырныймы? Белмәссең. Ирләр йөрәге — төпсез кое, диләр.

Хуҗа тәбәнәк караваттан төште, аякны суырып ала торган калын келәмгә басты. Сәетнең гәүдәсен Зөлфия күз карашы белән сыйпап алды. Киң җилкәсе, туп мәсле өреп тутырылган булмаса да, килешле бүлтәйгән беләге, алга чыгып торган күкрәге, муен тирәсендәге вак җыерчыклары, кырау иңә башлаган коңгырт чәче, барысы да аңа якын һәм газиз икән. Иреннәре янындагы сызыкларның кайнар, тозлы тәмен тойгандай булды.

Зөлфиянең күзләрен елтыратып, ярым яшертен күзәтеп ятуын сизеп, Сәет оялгандай итте, корсагына шап-шап суккалап алды. Якланмыйча түзә алмады.

— Ябыктыргансың абзаңны, таң кызы, болай ук ярамас иде.

Тегесе, шаяртуны үзенчә аңлап, Сәетнең җилкәсенә килеп сыланды. Ә үзе: «Ир-ат мәңгегә шулай бала-чага булып кала торгандыр инде»,— дип уйлап алды.

— Сиңа берәр нәрсә кирәкме, куштан мәчем?

— Көзгегә кара әле, без бер-беребезгә охшаганбыз икән. Иреннәр, ияк, чәчләр дисеңме.

Сәет олы көзгегә күз ташлап, ике арада бернинди тышкы охшашлык тапмаса да, ризалашты, кызның чәчләренә, үтә күренмәле кызгылт колагына өргән булды. Рәхәт иде аңа. Халык менә шундый мизгелләрдә «мәңге сагынмаслык булып карап каласы иде», дип үрсәләнеп җырлагандыр да инде.

— Күзләр дә...

— Юк, матурым, синең күзләр яшел, минеке — корыч соры.

— Минеке күгелҗем-яшел, синеке соры-күгелҗем,— дип үзенекен итте ханым.

— Зөлфиюшка, син дальтоникмы әллә? Дөресен әйт әле, ят кеше юк монда!

— Нәрсә дигән сүз була инде ул? Нечкә үртисең мине?

— Борын-борын заманда Дальтон дигән химик яшәгән. Бик акыллы, хикмәтле бабай булган, кү-ү-п ачышлар ясаган. Шул исәптән төсләрне кушып, яңадан-яңа, синең йөрәгең кебек, чуар бизәкләр, буяулар тапкан. Соңыннан гына ачылган: тормышта ул кызыл төсне сарыдан, яшелне зәңгәрдән аермаган, мин сиңа бүләк иткән күлмәк төсен — шәмәхәне кешегә дә санамаган.

— Нәкъ синең кебек, кырмавык телле булгандыр әле ул үзе.

— Ничек син шундый нәтиҗәгә килдең әле? — дип, кочагына алып, ияген, борынын, озын муенын иркәләде иреннәре белән.

— Минем йөрәгем сиңа нигәдер охшамый.

— Яратуыма чыдый алмыйча гына әйтүем.

— Әйдә, Сәет, беркайчан да әйтешмәскә, бәхәсләшмәскә, бер-беребезне рәнҗетешмәскә сүз куешыйк!

— Кызык булмас! Хәзер мин сөйли торган бер мәзәктәге кешеләр көненә калуыбыз бар. Ир белән хатын аерылышырга килгәннәр, ди. Судья хатыннан сорый икән:

— Сез ни өчен ирегез белән аерылышырга булдыгыз?

— Талашыр сәбәпләр калмады. Яшәүнең кызыгы, мәгънәсе бетте, — дип ярып салган теге...

Шырык-шырык көлештеләр бу сүзләрдән, башлангыч мәктәп балалары кебек ду килделәр.

— Шулай итеп, сайланучым, сезнең тәкъдим беренче укуда парламент аша узмады. Талашу мөмкинлеге көн тәртибеннән алынмады, — диде Сәет, тавышына күп мәгънәлелек салырга тырышып.

Зөлфиянең кыр чәчәкләре кебек сирпелешеп утырган озын керфекләренә, ачык, якты маңгаена иркәләп карады да: «Матурым, миңа вакыт», — диде.

Зөлфия, Сәеткә киенергә бирмичә, сырпалануында булды.

— Сиңа әллә тагын берәр нәрсә кирәкме, тәүфыйклы песием?

Яшь ханым аны үзенчә аңлап: «Юк, юк, тизрәк кайта күр», — дип, яшькелт халатына үрелде. — Ашарга нәрсә пешерим?

— Кыстыбый. Булдыра алырсыңмы?

— Аңлашылды. Тырышып карармын. Барып чыкмаса, бик ачуланмассың, яме?

— Зөлфия, бүген өйдә утыр. Мин сәгать өчләргә кайтып җитәргә тырышырмын. Ишекне берәүгә дә ачма, телефонны алма!

— Сәет җаным, бер сорау бирсәм, ачуланмассыңмы, үпкәләмәссеңме икән?

— Рәхим итегез, ханым! Хет икене.

— Сәет, мин синең турыңда берни белмим.

— Соң, биш көн, биш төн янында шәрә тән яттым ич! Бөтенләй өйрәнмәдеңме мине?

— Юк ла, кая, кем булып эшлисең дип сорамакчы идем.

Сәет куе зәңгәр пинҗәген төймәләү-ычкындыру белән мәшгуль иде. Шөгылен ташлап, сөйгәненә җитди итеп карады. Күзләреннән кайнар кургаш тамгандай булды. Зөлфия җилкәләрендә олы чиләкләре су белән тулы көянтә тойды.

— Мондый сорауларны безнең илдә генә бирәләр. Гарәпләр үзара очрашканда «ничек тирлисең?» дип сорыйлар. Французны сөяркәсенең исәнлеге борчыса, алманлыны акчаны кайсы банкта тоту файдалырак булу уйландыра. Испаннар өчен иң мөһиме — үгезләр сугышы.

Сәет киенә-киенә сөйләнүен дәвам итте:

— Ә инглизнең чәчен нәрсә агарта дисең? Аны кара смокингка тамган ак тап саргайтырга мөмкин. Ә безне кая эшлисең, күпме акча аласың, фатирың зурмы кебек ахырзаман сораулары интектерә. Шылдымы? Ә син, балам, мин чыгып киткәндә фатиханы бирә торган бул. Артык сораулар бе... н үзеңне бимазалама!

Зөлфия... чагына алып өстәде:

— Кеше күп белүдән иртә картая. Ә мин синең мәңге яшь калуыңны телим!

Сәет үзенең йөртүчесен машинаны күрше өй артына куярга өйрәткән иде. Гавамны борчымас өчен. Акрын гына шунда юл алды. Ә күз алдында һаман Зөлфия... Аның белән танышуы маҗаралы романнардагы кебек көтелмәгәнчә һәм шул ук вакытта бик гадәти булды. Язмыш дигәннәре шулдыр инде.

Арты, як-ягы төсле пыялалы машинасында җитди очрашудан кайтып барышы Сәетнең. Шоферын алмаган иде. Асылма күпер астыннан чыгып, акрын гына, автобус тукталышын узды.

Һава рәхәтен тоеп, сәрхүшләнеп йөрергә вакыты булмаган кешеләргә оялчан, тыныч кояш сихәтле тәэсир ясый, кәефне, рухны күтәреп җибәрә.

Көз яхшы килде быел. Җәй буе койган тәмсез яңгырдан соң түнгән әбиләр чуагы, бурычын түләгәндәй, матур, ямьле көннәрне шактый бүләк итте. Иртәдән үк кәефе әгъла иде Сәетнең. Эше гөрләп барып, акча күктән яумаса да, дөнья бетереп зарланырлык нигез дә юк.

Ә менә уйлап бетерәсе, юнәлешен табасы, хәл итәсе мәсьәләләр баштан ашкан. Үзгә җирдә тынычлык табып булмый. Салмак кына җыр агыла. Салават Фәтхетдиновның сөт өсте кебек куе, ягымлы тавышы йөрәкне, җанны тынычландыра. Татар моңы үзенчә шул. Бер халыкны да кабатламый.

Як-якка күз атып йөрергә яратмаса да, өстенә төймәләре каптырылмаган озын плащ кигән, кулына шактый олы сумка тоткан кызга күзе төште. Җилкәсеннән узган коңгырт чәчләрен җил талкый. Як-якка карана, урынында сикеренә, буш кулын күтәрәп-төшереп ала. Каядыр соңга калганы, машина туктатырга ымсынганы күренеп тора. Юлда таныш булмаган кешене утыртмаска, дигән кагыйдәне катгый үтәгән Сәет тормозга басканын шәйләми дә калды. «Ашыкма әле, абзый. Туктале син! Артка бир. Әнә теге кызны утыртабызмы? Бик ашыга мескенкәй каядыр. Нинди кайгы-хәсрәт йөртә икән адәм баласын? Белешик әле».

Гомере буе ялгызы яшәгән авыл карчыгы кебек сөйләнә-сөйләнә, Сәет машинасын артка чигерде. Шул арада эчтән яхшы күрсәткән пыяла аша кызның төз, озын аякларын, тимерче учы киңлегендәге генә кара итәген, ак блузкасын шәйләп өлгерде. Йомры тез башында кояш нурлары сикерешкәндәй булды. Ачның күзе икмәктә, тукның күзе итәктә, диме әле халык мәкале.

Сәет борылып арткы ишекне ачты.

— Теләсәгез, утырыгыз! Каядыр ашыгасыз булса кирәк.

Кызга уйланып торырга вакыт калмаган иде. Әүвәл арыслан тиресе төсле буй-буй сызыклы чүпрәк сумкасын утыргычка куйды, бавын кулыннан ычкындырмыйча, үзе кереп оялады. Шуннан соң гына телгә килде. Тавышы кискенрәк тоелды Сәеткә.

— Зинһар, вокзалга илтеп куегызчы? Соңга калам.

— Кайсысына? Вокзаллар күп.

— Гафу итегез, тимер юлга. Ярты сәгатьтән поезд китә. Бүген башкасы булмый.

Машинасына алга ыргылырга куәт биргәнче, Сәет гәүдәсе белән кызыгына борылды. Кыска гына бер мизгелгә яшел-күгелҗем күгелҗем соры күзләр очрашып, «аралашып» алдылар. Таныш булмаган абзыйга күз тондыруны оятсызлыкка санап, кыз карашын читкә алды.

Назлы көй колагына иңде. Салонда искиткеч пөхтәлек, чисталык. Утыргычларга шәмәхә бәрхеттән тегелгән чехоллар киертелгән.

Сәет кызның ашыгудан, дулкынланудан алсуланган битеннән, ачылган чәчәк кебек матур йөзеннән, килешле борыныннан, озын муеныннан күзен ала алмый интекте. Таныш булмаган, үзеннән шактый яшь кызга уктай кадалуның әхлаксызлык икәнен дә аңлый. Бер мизгелгә үзе белән идарәне югалткандай булды. Аңа мондый чибәр, зифа, пөхтә, каен

жиләгә исләре килеп торган гүзәллекне очратканы, күргәне булмагандай тоелды. Тән күзәнәкләренә җылы, татлы һәм нәфис дулкын йөгерде.

Сүзгә гаярь булса да, таныш булмаган кешеләр белән бераз гына йомыкый иде Сәет. Ә бүген теле ачылып китте.

— Соңга калырга булгач, иртәрәк чыгарга кирәк иде,— дигән булды, алга борыласы килмичә.

— Мин дәрестә идем. Кайтсам, телеграмма ята. Әтинең чире көчәйгән. Шунда ашыгам.

— Сез мәктәптә укыйсызмы әле?

— Нигә алай дисез?

— «Дәрестә идем», дидегез. Дәрес мәктәптә генә була. Институтта лекция, семинар һәм башкалар, белүемчә.

Кызның бик исе китмәде. Җавабы әзер иде.

— Шулай кабул ителгән инде, студентлар арасында. Җиңеллек өчен.

Шунда гына кызый Сәет ягына борылып, уң кулын утыргыч артына куйган «бәйләнчек» абыйга күз салды. Дингез тозы тамчылары төшкән коңгырт чәч, киң маңгай, уртасында сизелер-сизелмәс кенә бөкрәеп киткән борын, озынча бит — барысы да үзенә килешле. Төсе үзгәрүчән күзләренә машинага утыруга игътибар иткән иде.

— Сезне кайсы поезд көтә инде?

— Көтәр сиңа! Егерме минуттан китеп тә барыр. Кукмарага... Ашыкканда вакытында китәләр алар. Иртәрәк килсәң, яртышар сәгатькә соңга калалар.

Юк-бар турында сөйләшеп бара торгач, тоташ пыяладан торган вокзал янына җиткәннәре сизелми дә калды.

— Менә килеп тә җиттек. Озатып куйыйм инде әзрәк. Әтиегез чирле икән,— дип, кайгы-хәсрәтен уртаклашкан булып, озынча буйлы, таза гәүдәле Сәет тар кара итәкле кызга иярде.

«Ай, мин сезгә акча да бирмәдем»,— дип әйтмәкче иде дә, өр-яңа кара көчтүмнән, ап-ак күлмәктән, кара ялтыравык ботинкадан атлаган ир уртасына сүзен әйтергә кыймады. Студентның чыгарып салырлык артык акчасы да булмагандыр, шәт.

Сәет пассажирының билет алганын көтеп торды, яңадан ярты юлга чаклы озата барды.

— Мулла абзый безгә нинди исем кушкан инде?

— Зөлфия. Зуля, диләр кызлар.

— Ә мин Сәет абый булам.— Ни өчендер фамилиясен дә өстәде:— Сакманов.

Кыз житез, елгыр гына, элеккеге фильмнардагы тәрбияле курсисткалар төсле, тезләрен чүккәндәй итте. Иллэм килешле чыкты.

— Очень приятно.

Аякларының матурлыгына сокланган Сәет биленең эчкә тартылып керүенә, күкрәк уртасындагы сызыкның ымсындыргыч тирәнлегенә игътибар итәргә өлгерде. Кыз табигатьнең югары казанышы, кеше иҗат итә алган тәңгәллекнең, илаһи гүзәллекнең үрнәге тоелды. Көндез шәм яндырып эзләсәң дә, таба алмассың мондый тутый кошны. Янында озак басып торуның килешмәвен акылы белән аңлаган, үзен битәрләгән хәлдә, Сәетнең аягы машина ягына атларга теләмәде.

Кулын бирде кыз гади генә итеп.

— Рәхмәт сезгә, ярдәмегез өчен.

— Кайчан әйләнеп кайтасыз Казанга?

— Иртәгә шимбә. Ял көнe. Дүшәмбе кайтам.

— Каршы алыргамы?

Кыз, җавап урынына, матур кулларын изәде дә йөгерә-атлый яшькелт-кара вагонга кереп югалды.

«Волга»сы урынында тора. Алга утырып йөрергә яратмый иде Сәет. Артка кереп сыенды, йөртүчесенә кул бирде.

— Хәлләр иминме, Замир дус?

— Ярыйсы, Сәет Яруллович! Эшкә барабызмы?

— Әйе. «Игелек»кә киттек. Мине югалтып, сагынып беткәннәрдер инде?

— Киресенчәдер. Сез юктан файдаланып, рәхәтләнеп чәй эчеп утыралардыр әле.

— Кызың үсәме?

— Аның башка эше юк. Бармакны авызына алып, тешләргә өйрәнеп килә.

Үзе ифрат канәгать. Елмаю килешми торган каратут, түгәрәк, кырыс йөзе яктырып китә. Армиядә хезмәт иткәндә югалткан тешләрен алыштырган алтын алдавычлары ялтырап ала. Төп шикелле таза. Тормышчан, ышанычлы егет. Аяк ятлау рәвешендә, буй-сынында Сарман ягы токмачын ашап үскәнлеге сизелеп тора.

Дәүләт эшендәге кеше өчен аны йөртүчедән дә якынрак хезмәттәш юктыр. Адәм баласы беренче хатыннан уңмаска мөмкин. Анысы да фаҗига. Соңгы тамчы суыңны тәүге хәләл җефетең каптыруы хәерлерәк, дисәләр дә, ул үзенә насыйп яртысын эзләвен дәвам итә ала, еш кына табып та куя. Бәхетне кибеттән сатып алып булмый шул.

Ә инде җитәкче беренче шоферыннан уңмаса, беркайчан да үзен һәрьяктан канәгатьләндергән йөртүчене таба, аның белән тулы аңлашуга ирешә алмаячак. Барыбер бер ягы китек булачак. Хет шунда асфальтка төшкән кабак кебек шартла, машинаң син ашыкканда барыбер соңга калып килер, бензины беткән булыр, ГАИ туктатыр, йөртүчең аракыны синнән күбрәк эчәр...

Сәет берничә кат өйләнеп, хатыннары белән буталып бетсә дә, Замирдан уңды. Ул аны армиядән кайту уңаена ук үзенә алды, иске «Москвич»ка утыртты, читтән торып укырга кертте. Егет аз сүзле, саран сүзле булса да, әйткәне, гадәттә, мәгънәле, төпле күзәтү сөземтәсе булып чыга. Авыл агайлары акылын, хәйләкәрлеген үзенә сеңдергән.

Машинаны гел алыштырып тордылар, чит ил «кадиллак»ларында да борын чөеп алдылар. Хәзер дә «Роллс-Ройс» маркалысы гаражда хуҗасын көтеп, әзер тора

— Чит илдә ясалганнар йомшак, җайлы. Ну, алар безнең юллар өчен түгел,— дип, хуҗасына үз фикерен сеңдерә торды Замир.— Ватылса, запчасть таба алмый интегәсең. ГАИ да алардан гел әҗер өмет итә. Усал әнчек кебек бәйләнеп кенә тора. Безнең өчен, Сәет Яруллович, иң җайлысы дәүләт номерлы «Волга». Инспектор аңа кандала кебек ябышмый.

Хаклы булып чыкты егет. Үзебезнең илдә эшләнгән соңгы марка «Волга»да рәхәтләнеп йөриләр.

Замир тәкъдим иткән икенче яңалыкны да кабул итте Сәет.

«Игелек» ширкәтендә эшләүче, саналучы егетләренә Сакманов Мәскәүдән кара, коңгырт, соры күн курткаларны үзе алып кайтты. Чит илдә, затлы күннән, ятышлы итеп тегелгән кием яшьләрне дәртләндереп, башкалар арасында абруйларын күтәреп җибәрде. Тезелешеп утырганда, карарга күңелле иде үзләренә.

Бер мәлне күн курткалы кеше Ленинның мылтыклы солдаты абруенда калды. Аңа каршы әйтмиләр, ресторанда урын тоталар, урамда әйләнеп үтәләр. «Тугызлы», «сигезле» машина, Италиядә, Испаниядә, һич югында Төркиядә тегелгән куртка каста, орден, дәрәҗә билгесе булып китте. «Улым, кызым, юл бирә күр, читкә ал, мафия килә»,— ди

торган иде ата-ана, әби-бабай балаларына, курткалыларны күргәч. Ә ул гәвамга әйләнеп тә карамый, машина ачкычы уйната-уйната үтә дә китә.

Икенче билге — муенга тагылган алтын чылбыр. Ул — саф алтыннан һәм мөмкин чаклы юан, эре итеп үрелгән боҗралардан торырга тиеш. Гарәп, төрек, иран алтыны мәртәбәгә саналмый.

Иң имансызлары Согуд Гарәбстаныннан кайтарылган тәсбих йөртә башлады машиналарында. Бернична ел арасында Казанның беркайда да эшләми, укымый торган машиналы яшьләре тулысы белән диярлек күн курткага төренде. Элек коммунистлар фиркасының беренче баскычтагы кешеләре генә киеп, соңрак теләсә-кем юнәтә алгач, абруе төшкән нерпы фуражкасы кебек, күн киемгә хөрмәт бетте. Мода алышынуны күзәтүчән Замир бик тиз сизеп алды.

— Сәет Яруллович, күн куртканы хәзер бөтен шпана кия. Егетләрне ялтыравык сәдәпле кәчтүмнәргә күчерик әле. Фирмабыз да солидный, балалыктан чыкты. Аерылып торыйк башкалардан.

Сәет уйлангандай итте дә, йөртүчесе белән килеште. Ничек үзенең шуңа башы җитмәгән.

— Яхшы фикер, Замир.

Янәдән үзе Мәскәүгә барып, складтан Австралиядә һәм Финляндиядә тегелгән төрле төсле костюмнар алып кайтты. Егетләргә янә җан керде. Шәмәхә йон, сары вилвет, яшел шевиот костюмнар «Игелек»нең дәрәҗәсен-кимәлен күтәреп җибәрде.

Бер караганда гади, беркатлы күренсә дә, җиргә якын кешеләрдәй төпле егет иде Замир. Әүвәл бер заводның тулай торагында яшәп торды. Хуҗасының фатир алып бирергә мөмкинлеге барын сизеп, никах укытып, авылларыннан бер кызны алып кайтты. Анда да, машинада икәү генә йөрүләреннән файдаланып, башкалар төсле мәсьәләне куертмады, киресенчә, «яшь хатын белән тулай торак та сарай булып күренә икән», дигән булды. Хуҗасын бик үтенеп туйга чакырды.

Сәет бераз төшереп алып, күңеле йомшаргач, алдан әзерләнеп куелган өлкәннәрдән берәү, «җитәкчегә хатыннан кала иң якын кеше шофер, хәтта ул күбрәк тә хәбәрдар булырга мөмкин. Замир сезгә бик тугрылыклы, баласы туып, гаиләсе артып, тегендә-монда сугылып йөрмәсен өчен, аның квартира ягын ничектер хәл итәсе иде. Сезнең өчен мәсьәлә түгел инде», дип салпы якка салам кыстырып та куйгач:

— Бер ай эчендә хәл итәрбез, — дип ычкындырды хуҗа кеше.

Вәгъдә бирүе җинел булса да, аны үтәү өчен бер завод директорына Ижауда болан ата торган мылтык юнәтеп, шуны һәдия итәргә туры килде. Замир иплән кенә ике бүлмәле фатирга кереп утырды.

Тормыш өчен иң мөһим үрне алгач, Замир тагын да рәхмәтле булып, бирелеп хезмәт итә башлады. Беркем белән дә артык аралашмый. Эштә аның дусты да, сердәше дә — машинасы. Яхшы гадәткә адәм баласын өйрәтеп кенә булмый икән. Ул тумыштан килә, ата-ана сөте белән керә.

Замир хуҗасының төрле вакытларын, битләре кара янып, иреннәре канга баткан рәвешләрен, сирәк булса да, лаякыл исерек чакларын да күрде, эченнән аһ итсә дә, беркайчан да артыгын кызыксынмады, төпченмәде, сорамаганда киңәшен бирмәде. Сәет Яруллович, кәефе килеп, сөйләүне кирәк тапса, «шулай, әйе шул», «кара син аны» кебек гомуми сүзләр киртәсеннән чыкмады.

Хуҗасына артык бирелгән, машинасына, өстән әмер булмыйча, беркемне дә якын китермәгән, утыртмаган өчен аңа «Мундир» дигән кушамат тактылар. Үзенә әйтергә берәүнең дә, хәтта Шөреп, Гриша кебек башкисәрләрнең дә, шигъри табышларын иясенә җиткерергә йөрәкләре җитмәде.

Сәетнең беренче ярдәмчесе, урынбасары Хәлил Нигъмәтуллин да Замирдан шөлли. Аның белән бәйләнмәскә тырыша.

Машина Сакмановның Ибраһимов проспектында беренче катта, өч бүлмәле квартирага оялаган конторасы янына килеп туктады. Халыкның

көнкүреш, көнитеш мәнфәгатьләрен хәл итү, ярдәм күрсәтү өчен төзелгән, үз өстенә җаваплылыкның бик аз өлешен генә алган «Игелек» исемле арадашчы Оешма шунда урнашкан. Аның әле башка шәһәрләрдә филиаллары, әйбер саклау урыннары, шәһәр читендә сауналы йорты, тагын әллә нәрсәләре бар. Ширкәтнең ни белән шөгыльләнгәнен, нәрсә эшләп чыгарганын, юнәлешен, мәсләген Ходай Тәгалә белән хуҗасы гына белә.

Мәгәр аның генераль директоры Сәет Сакманов, урынбасары Хәлил Нигъмәтуллин, ярдәмчесе Фердинанд Нигъмәтҗанов, бөтен керем-чыгымны, исәп-хисапны үз кулында тотучы, эш хакын түләүче, налог инспекциясенә вакытында акча төшереп торучы Наилә — Нонса Орбакайте үзләренең Оешмалары турында югары фикердә торалар. Сакчы өчен кулын куеп, эш хакын Әхмәдулла бабай һәм алдан күн курткалар киеп йөреп, аннан төрле-төрле костюмнарга төрелгән алты-җиде егет хезмәткәрләр, оешмада эшләгәннәр саналып, акча алучылар исемлеген бизиләр.

Аксыл-сары чәче иртә коелган, уртача буйлы, гәүдәсенә рәхәт тормыш авырлыгы иңгән Хәлил Фирма эшчәнлегенә зыян китермәве белән кадерле. Кушканны төгәл итеп үтәргә тырыша, шуннан чыкмый, ягъни бервакытта да тәртәгә типми, артыгын майтармый. Ул — тынып калган су шикелле акрын. Якын дуслары булмаган кебек, дошманнары да юк иде аның.

Үзенә охшаган сыйфатларыннан берсе — пөхтәлек һәм сөйләшергә ярату. Ул көне буенча, килгән-киткән кеше белән гәпләшеп, телефоннан кирәкле хәбәрләр җыеп, Сәет колагына ирештерә тора.

Әлбәттә, соңгысы Хәлилне урындык җылытып утырган өчен генә урынбасары итеп тотмый. Аларның тормыш юлларында, язмышларында кисешкән урыннар шактый булды. Икесе дә бер үк район бүлегендә, милициядә эшләделәр. Сәет участковый, Хәлил кизүдә утыра. Икесенә дә, төрле сәбәпләр аркасында, тәртип саклау оешмасыннан китеп, халык хуҗалыгына кушылырга туры килде. Сәетнең үз сәбәбе, Габделхәлилнең үз сере бар иде.

Берни әйтеп булмый. Сәетне милициядән озатуны ышандырырлык итеп оештырдылар. Черки борынын тыгарлык урын калмады.

Алдан читләтеп, киная белән соңрак: «Ташла син ул кызыйны, оныт син ул баланы, ата-анасына кирәкмәгән нарасыйның, бәхетсезләр, имансызлар сафын арттырганчы, вакытында үлүе хәерлерәктер», — дип, турыдан-туры ярып та карадылар.

Сәет, күзенә зәгъфрән төшкән кире үгез кебек, үзенекен тәкърарлады:

— Нарасый баласының җанын алган анадан да явыз, җаһил кеше була алмый. Теләсә нинди ерткыч хайван, гомерен фида кылу исәбенә булса да, нәселен саклап кала, — дип әхлак сатты. — Үтерүче җәзасын алырга тиеш. Мин бу эшне барыбер ахырынача җиткерәчәкмен, — дип үҗәтләнде.

— Хуш, син канализация коесында үле бала тапкансың. Аның анасы Фәридә исемле шәфкать туташы дип расларга тырышасың, ә дәлилләрең сыек, юк диярлек. Исбатлавың — коры комнан ишелгән бау, гайбәт дәрәҗәсендәге юралау, — дип, район прокуроры аны түйганчы әрләде. «Ташла син, егетем, бу эш белән булышуыңны, атасы ташлаган беренче бала түгел, соңгысы да булмас», — дип, аталарча киңәш-нәсихәтен бирде.

Эшнең прокурор дәрәҗәсендә каралуы тикмәгә генә түгел иде. Йомшак җиренә маҗараны Сәет үзе эзләп тапты. Милиция әһелләренә ышанмыйча, этләнә торгач, тикшерүне алып баруны прокуратурага тапшыруга ирешә. Дәүләт, фирка оешмаларына рәсми буйсынмаган бу хакимият ыруына азмы-күпме ышанычы бар иде. Әнә бит чит ил картиналарында комиссар белән прокурор теләсә нинди югары кимәлле, дәрәҗәле чиновникны, миллиардерны дер селкетеп, буйсындырып торалар, хәтта төрмәгә илтеп ябарга да күп сорамыйлар.

Дөреслекне расларга булышыр бу хөкем оешмасы, дигән ышанычы Сәетнең акланмады. Эшне җитди итеп алып барып, судка тапшырасы

урынга, участковыйның үзен һәр көнне чакырып ала башладылар. Җавапны ул тотарга тиеш булып чыкты. «Ничек таптың, ник таптың ул үле баланы, тагын берәр кешегә әйтмәдеңме (чит-ят затка серне чишкән булса, үзенә маддә), кинәшмәдеңме?», кебек сорауларны кат-кат биреп башын катыралар.

Дөреслекнең барыбер өстен чыгасына балаларча инанган Сәет соңгы очрашуда да сыртын кабартты, «шырпы»ларын чыгарды.

— Ничек инде дәлилләрем булмасын? Сез нәрсә сөйлисез? Фәридә үзе таныды, шуңа риза булып, имзасын куйды. Кәгазь сезнең кулда.

Өлкән яшьтә булуына карамастан, аксыл чәче бөдрә куелыгын югалтмаган, ак чырайлы, зәңгәрсу күзле прокурор акрын гына кулын күтәрде. Кызма, янәсе, бу синең вилаять түгел. Күз карашы — ылыс энәләренә тиң. Шулар белән чәнчеп-чәнчеп ала.

— Кәгазь, кәгазь... Кәгазьләрдә кеше язмышы. Ә аны ертып атарга, күчереп язарга, үзең теләгәнчә тутырырга, башка зат өчен кул куярга да була.

— Сез нәрсә сөйлисез, иптәш прокурор? Ялгыш юлга кереп барасыз. Фәридәнең үзен чакырыгыз. Үзе раслар!

— Мин дә, егетем, шул хакта уйлап утырам. Кызны китереп була. Ул — бездә.

Сәет кичә Фәридәне эзләп тулай торакка кергән иде. Таба алмады, беркем бернәрсә белми, күршедә яшәгән карт кыз Сәлимәнең булмәсе дә ике йозакка бикле иде. «Димәк, бу эшнең җитдилеген бәяләп, тикшерүне тизләтү нияте белән, кызны кулга алганнар. Хакыйкать барыбер җиңәчәк», — дип сөенеп куйды Сәет. Хакимият оешмаларына, кайтармалы ак якага куе төстәге кызыл галстук бәйләгән прокурорга ышанычы артып куйгандай булды. Аның Фәридәгә нинди дә шәхси үче юк. Мәгәр аның артында кызны җинаять юлына чыгарган, упкынга этәргән ир-ат тора. Ул бит, христианнарның изге Мариясе төсле, балага җилдән узмагандыр. Авылдан килеп, медучилище тәмамлап, республиканың иң олы шифаханәсендә эшли генә башлаган кызны кемдер юлдан яздырган, рәхәтен күргән, аннары ташлаган, сабыена кул салу юлына этәргән. Бала Фәридәгә, бигрәк тә кемсәгәдер кирәкми. Тормыш тәҗрибәсе булмаган, ышанучан кызны, ахыр башка бер җан иясен әрәм иткән, физик юкка чыгару юлына этәргән өчен менә шул билгесез адәмне җәзага тартасы килә. Күсәкнең юан башы барыбер шомырт күзле, кара озын чәчле Фәридәгә эләгәсен дә белә ул. Теге кабахәтне фаш итәсе иде. Һәркем үзенә тиешлесен алыр, дип ышанды Сәет ихластан.

Сергей Александрович Фәридә Мотыйгуллина папкасы өстендә яткан күзлеген кулына алды, уйланып, колакка элә торган бөкре башның сөяк очын авызына капты. Тынычландыра бу алым.

— Кызны китереп була. Ул — бездә. Тик Мотыйгуллина баладан да, менә бу аңлатмадагы имзасыннан да баш тарта!

Корт чаккандай, урындыгыннан сикереп торды Сәет!

— Ничек инде ул баш тарта? Мин бит аның белән кат-кат сөйләштем. Шаһитем дә бар.

Участковыйның хасси бушануына, туарылуына игътибар итмичә, прокурор сорауга сөаль белән җавап бирде:

— Кем ул? Мондый нечкә мәсьәләдә шаһит була аламы икән? Белмим тагын.

— Күршесе — Сәлимә. Аның күрсәтмәләре шул ук папкада.

Прокурор алдында яткан эшне актарган булды, бер кәгазьне кулына алды.

— Тикшереп карамакчы идек. Хатынны таба алмадык. Тулай торактан киткән. Пропискадан да төшкән. Хәзер аның кайсы якка юл тотканын бер үзе генә белә. Алла булса, ул гына белә булыр.

— Соң аны эзләп табып була ич.

— Егетем, килде-китте, тиле-миле шаһитләрне түгел, авыр җинаять кылган бәндәләрне эзләрлек көчебез дә юк. Ул хәтлесе генә сезгә мәгълүмдер, дип уйлыйм.

Сәет йомгакның очы югала баруны, аңа каршы торган көчләрнең өлгеррәк булуын, эшне олыдан алып баруларын сизенде. «Сәлимәне куркытыпмы, түләпме, кемдер юлдан алган. Фәридәне яшьлеге, матурлыгы, пөхтә киенүе, машинада кайтып төшкәләве өчен яратмый иде утырып калган кырык биш яшьлек кыз. Шәхси дошманы дәрәҗәсендә күрә алмый иде җилбәзәкне. Хәзер ул да юк». Сул як калак сәяге асты чәнчешеп куйды, әйтерсең лә, энә белән кадап алдылар.

Ничәмә-ничә районда прокурор булып эшләгән, меңнәрчә катлаулы җинаятьләрне тикшергән, ачкан, дистәләрчә кешеләрне төрмәгә озаткан Сергей Александрович участковыйның тәгаен хаклы булуына, Мотыйгуллинаны кылган явызлыгы өчен судка бирергә, утыртырга кирәклектә һич кенә шикләнми. Ике икең дүрт сыман. Һәммәсе исбатланган, язылган. Сакмановның үҗәтлеген дә аңлый, хуплый, хөкем оешмаларында шундый намуслы кешеләр күбрәк булсынчы иде!

Ләкин тормыш, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр без уйлаганнан катлаулырак шул.

Пычрак сулар коесында табылган үле бала эшенә ул Сакманов теләге, аның язма үтенче буенча алынмады. Атна-ун көн элек аны обкомның хөкем оешмаларын алып баручы бүлеккә чакырдылар. Утны-суны кичкән, тәбәнәк буйлы, очлы борынлы, үткен күзле бүлек мөдире бу мәшәкатьне үз өстенә алуны һәм «дөрес» нәтиҗә ясауны үтенде. Төлкенең дә төлкесе үзе. Өстенә берни алмый.

— Ниндидер Сакманов дигән участковый милиционер үз эше белән шөгыльләнәсе, урам шпаналарын тотасы урынга, канализациядә казынып, яңа туган бала тапкан, ди. Үле булгандыр инде ул. Үзе үтермәсә,— дип кеткелдәп көлеп куйды.— Бала,— алдында яткан кечкенә кәгазьчеккә карап алып,— Фәридә Мотыйгуллинаныкы дип бара, ди ул.

Компетентлы кешеләрнең әйтүенә караганда, минем аларга ышанмаска нигезем һәм хакым юк, кыз, тәртипле, инсафлы... Хаталанган икән... Анысы кемдә булмый. Бирнәле кыз да туйда кирәкмәгән ис чыгарырга мөмкин диләрме әле. Мин бу хикмәтле эшне үз өстеңә алырсың, дип ышанам. Тикшерү ялгыш юлга басмасын өчен, тәҗрибәле юристка тапшырырга куштылар.

Сергей Александрович үзеннән ни-нәрсә таләп ителгәнне аңлады. «Бүлек мөдире үзе шөгыльләнгәч, бу Горькийның Клим Самгины баласы гына түгелдер. Фәридәсе дә, Катюша Маслова кебек, яклаучысыз калмаган бугай. Йөнтәс кул җитәкчелек итә бу эш белән».

Кабинет хуҗасы иренендә туган елмаюын җыерчыклы битенә, борынына, күз төпләренә җәеп, кучүне мәслихәт тапты.

— Сездәй тәҗрибәле хезмәткәрләр бармак белән санарлык. Биредә,— ди ул, алдында яткан кәгазьләр төркеменә ишарә ясап,— сезне иң югары кимәлле юристка, ягъни полковник дәрәҗәсенә Мәскәүгә җибәрүгә әзер документлар ята. Хуҗадан имза алып, мөһер сугып, бу көннәрдә озатырга исәп. Бу эш өчен генә түгел, әлбәттә, кадерле Сергей Александрович. Быел республикага нибары ике урын бирделәр, югары дәрәҗәгә. Татарстан квалификацияле, сәләтле юристларга ифрат бай булуы белән аерылып тора... Теләүчеләр, ялынып, сорап, таләп итеп йөрүче әрсезләр биниһая. Җитәкчелек сезнең кандидатураны хуплады. Тәкъдимне мин керттем.

Сергей Александрович сизеп тора: икенче эш беренчесенең нәтиҗәсеннән үсеп чыгачак. Әлеге «юеш» эшне япмый торып, аны үстерү турындагы кәгазь беркая да китмәячәк, һич югында расланмыйча, кире әйләнеп кайтачак. Пенсиягә чыгар алдыннан бу йолдыз аңа бик тә кирәк иде.

Ул Сакмановны да аңлый. Яшь кешенең үсәсе бар, үзен бик тәртипле, эшчән, таләпчән участковый, диләр. Ләкин бу очракта ул юкка тискәреләнә, юкка киреләнә. Светофорда яшел утның янмаячагын аңламый микәнни, бахыр.

Прокурор эчке телефоннан каядыр шалтыратты.

— Миңа Мотыйгуллинаны кертегез!

Бүлмә хуҗасы кем беләндер башка телефоннан сөйләшеп алган арада Фәридәне алып керделәр. Кабинетта, төп эш өстәле янында, «Т» хәрефе ясап куелган кечкенә өстәл артында Сакмановны күргәч, кыз дерелдәп, калтыранып куйды. Бу очрашуны көтмәгән иде бугай ул. Өстендә өендә кия торган затлы спорт костюмы, аякларында җиңел туфли. Кыз элеккечә матур, гәүдәсе җыйнак, ташып чыгардай зур кара күзләре нарасый, ахыргача ышанучан, алданучан. Күз төпләренә кара сызыклар төшеп, яңаклары тартылган булса да, карасу йөзле, тыгыз тәнле Фәридә Агыйдел камышы төзлеген, сылулыгын бала тапкач та югалтмаган, элеккечә үк чибәр. Бу кабинетта аңа мөнәсәбәтнең хәерхак икәне исенә төште бугай (Сергей Александрович аның белән аталарча, ипләп, йомшак итеп, бераүдән дә куркырга кирәкмәү турында әңгәмә алып барган иде), гәүдәсен турайтты, йөзенә тәкәббер бәйсезлек чыгарып, ияген өскәрәк чөеп куйды.

— Сез танышмы? — диде прокурор, кызга каршы яктан урын тәкъдим иткәч.

— Таныштлар. Безнең участковый Сакманов бу. Аны кем белми, тыгылмаган тишеге юк.

Сәет Фәридәнең күз карашын тотса, хатын элеккечә хатасын таныр, «үз баласын ташлаган ана мөселман дине буенча мәңге тәмуг утында яначак», дип оялткач, элек әйткән сүзләрен кабатлар, ялгышын таныр дип уйлап, кызның йөзенә текәлде.

Сорауны прокурор үзе бирергә ашыкты.

— Гражданка Мотыйгуллина, кәгазьгә куелган имза сезнекеме?

Фәридә туры текәнүгә җавап бирмичә:

— Монда язганнар барысы да ялган. Мине Сакманов «баланың синеке икәнен танымасаң, мин башка статья белән башыңны төрмәдә черетәм, җинаятеңне үзең танысаң, сиңа бераэр ел шартлы срок бирерләр дә, бетте-китте», дип мине куркытты, янады, язарга мәҗбүр итте. Шантаж ясады, — дип, бер тын белән, яттан сөйләгән төсле ярып салды.

Сәет, үз колагына, ишеткәннәренә ышанмыйча, «сез нәрсә сөйлисез, Мотыйгуллина, мин сезне бары оялттым, намусыгызга барып житәргә тырыштым, үз теләгегез белән яздыгыз», — дип аңлатырга тырышып карады.

Кыз аны тыңларга да теләмәде, чәпчеде, тузынды:

— Куркытты, янады, — дип шәрран ярып кычкыра башлады.

Бүлмә хуҗасы, тамашаның астыртын режиссеры, икесен дә тынычланырга чакырды. Кулына ручка алып:

— Сез бу күрсәтмәне үз кулыгыз белән яздыгызмы?

— Әйе.

— Хәзер алардан баш тартасызмы?

— Баш тартам!

— Ни өчен?

— Әйттем ич инде. Участковый Сакманов көчләп, өркетеп танытты, өстемдә торып яздырды. Мин бала тапмадым, тапмаган баланы үтерә дә алмадым. Барысы да ялган, нахак! Аның үзен судка бирергә кирәк.

Сергей Александрович, икегезнең фикерегез дә дөреслекне эзләү юлында минем өчен кирәкле баганалар дигәндәй, йөзенә битарафлык төсмере чыгарып:

— Кайсыгызга ышанырга да белмим. Тагын бер тапкыр кабатлагыз, икегез дә, — дип, кат-кат сөйләткән, тыңлаган, язган булды.

Ә аның катгый карары фирка бүлеге мөдире бүлмәсендә үк кабул ителгән иде инде. Фәридәне бераз тотарга да... аерым камерада, мәсьәләне ябып, чыгарып җибәрергә. Сасытып, буза күтәреп йөрмәсен, дип алдынгы участковый Сакмановны халык хуҗалыгына озатырга. Сәбәбен тапканнар ди бугай инде. Хатыны белән аерылганын, баласын ятим иткәнен яшергән икән. Эштән куар өчен артыгы белән җиткән бу хәл.

Ә инде Сакмановның турыдан-туры җитәкчесе, элекке комсомол хезмәткәре Сәеткә ачыктан-ачык ярып салды:

— Моннан соң да сине милициядә эштә калдыру ыштансыз кешегә эшләпә кидерү, яисә галстук тагу белән бер булыр иде. Совет милициясе хезмәткәре һәр яктан үрнәк-өлге, әхлакый тотнаклы, намуслы кеше булырга тиеш.

Сәетнең йөзе, үлгәннән соң эленә торган рәсемгә охшап калса да, сер бирмәскә тырышты. Ул һаман да, җиһанда явызлар һәм аны яратмаган кешеләр булуга ышанмый иде әле.

Алты елга якын гомерен Сәет хөкем оешмасында эшләүгә әрәм итте. Участковый булып, яратып, җанын-тәнен биреп башкарды үз бурычларын. Хатыны белән аерылышкач, аның бөтен сөенече, шатлыгы үз төбәгендә тәртип урнаштыру булды. Элеккеге хәрбилек, турылык аның карьерасын өзде дә куйды. Үз баласын үтерүче хатынны эзләп тапканы, хөкемгә тартырга тәкъдим иткәне, хәтта шуны үтәү өчен сугышып йөрүе, шул юлда өстә утыручылар белән әчелешле булуы өчен аны яратмадылар — вак «мәсьәләләрдә» тискәрелек күрсәткәне өчен милициядән чыгарып ташладылар. Ул югалып калды. Аны бит тыныч тормышта, гадәти яшәештә көн итүгә бөтенләй әзерләмәгәннәр икән. Ярый әле Хәлил коткарды. Аларның, сиам игезәкләре кебек, аерылгысыз дуслар булып китүенең үз тарихы бар. Өлкән лейтенант Хәлил Нигъмәтуллинны да хокук оешмасыннан үз теләгеннән башка олактырдылар.

Тасма телләргә ышансаң, алар Хәлил хакында мондый гайбәтне ярәтып тараттылар. Янәсе, милициядә эшләвеннән файдаланып, ул ире белән бер кыз үстереп ятучы укытучы ханымны юлдан яздырган. Шул ук мәктәптә завуч булып эшләүче ире, аларны саклап торып, кызык хәлдә каптыруга ирешкән. Бик күп ирләр шикелле, башын җүләргә салып, берни булмагандай аяк киеме туздырып йөрисе урынга, җәнҗал, тавыш күтәрә. Нәтиҗә аның файдасына чыкмый. Хәлил күбрәк охшап куйган булса кирәк (җанлы, җылы итеп, ышандырып сөйли белә), ханым гаиләсен ташлап, карт буйдакка ябышып чыккан. Мөселман тәрбиясе алган ире, бу хурлыкка түзә алмыйча, асылынып үлә.

Гаилә бәхетен җимергән, упкынга этәргән өчен барысы да Хәлилне дәррәү сүксәләр дә, аны хөкемгә тартып булмый, элмәкне муенга ул кидермәгән. «Үз гомеренә нокта кую — һәркемнең шәхси, бу очракта намус эше»,— дип аңлатты Хәлил үзенә килеп бәйләнүчеләргә.

Ул елларда коммунистик әхлак кагыйдәләре гади кешеләргә нисбәттә бик катгый үтәлә иде. Нигъмәтуллинга да җилкәсендәге өч йолдыз белән саубуллашырга туры килә. Аның каравы, хатынлы һәм кызлы булып кала әрсез ир.

Гаделсез хәятне, тәртипсез яшәешне, нурсыз җәмгыятьне каһәрләп, адашкан ялгыз ата каз кебек каңгырып, Болак урамы буйлап атлаганда, милициядән элегрәк куылган Хәлил җиңеннән тотты. Күзләре — ут. Бармаклары балалайка кыллары. Элеккедән дә җанлы, хәрәкәтчән. Әйтерсең лә нәкъ менә Сәетне эзләп чыккан да, шулай тиз очратуына сөенеп бетә алмый.

— Сәлам, Сәет! Хәлләр ничек?

— Аллага шөкер. Эшсезлекнең рәхәтен тоеп яшим. Гарык булганчы асфальт таптыйм.

— Малай, мин дә киттем бит ментовкадан.

— Нишләп? Бик яратып эшли идең бит,— дигән булды Сәет, берни ишетмәгән кешедәй.

— Минем ярату гына аз булды. Мине яратучылар да табылырга тиеш иде. Мәхәббәт взаимно булса гына кадерле, дип ишеткән идем малай чакта. Дөресен әйткәндә, перспективасын тапмадым. Артым белән җир сөрсәм дә, миңа капитаннан артыгын бирмәячәкләр. Үзең беләсең, махсус белемем юк. Арттан төртүче — нема.
— Эшкә урнаштыңмы әле?
Хәлил җавап урынына үзе сорау тондырды.
— Ә син?
— Юк. Киткәндә биргән пособиемне күшәп ятам, сыер кебек.
— Киттек минем янга! Үземә как раз напарник эзләп ятмыш идем.
— Мине кайларга эшкә аласың дип белик инде?
— Ресторанга.
— Анда йөрерлек акчам юк!
— Аракы эчәргә чакырмыйм мин сине. Эшкә.
— Мин андагы ыспай публикага түгел, үзем түзеп ашарлык ризык та пешерә белмим. Миннән нинди пешекче чыксын!
Хәлил, үзен аңламаганга пырдымсызланып, ярып салды:
— Ишек төбендә торырга. Швейцар булып. Чын исеме — вышибала.
— Шаяртма инде. Без синең белән чүплеккә чыгарып ташланган тутыккан калайлар түгел ич. Шөһрәтле вә данлыклы совет милициясе сафында атлаган кешеләр. Оят! Безне шактый кеше таный. Хурлыгын кая куярсың!
Хәлил күтәренке рухлы җөмләләрне дә, Сәетнең фикер сөрешен дә йөрәгенә уздырмады.
— Юкка исең киткән. Атакага барганда, гел беренчеләрне кыралар, ахырдан килгәннәрнең түшләренә тәре тагалар. Без дә, шыпырт кына, шунда ашап ятыйк. Җаваплылыгы юк. Синең йодрык таза. Аннан күз күрер. Әйдә, хәл ит! Тәвәккәлләә! Үзгә эшкә чакырып та тормыйлар әле үзеңне.
«Теге мескен укытучы хатынын да, шулай вәгъдәләр белән үрмәкүчтәй үреп, үзе белән йокларга күндергәндер әле, шайтан», — дип уйлап алды да, бичарадан ни чыра дигәндәй, күнде, ризалашты.
— Швейцарның дәрәҗәсе, абруе сәвит кәмитендә генә төште. Элек ул купшы хәрби киемнән басып торган, кунакларны үрә катып каршы алган. Як-якка, ата каз канаты кебек, салынып төшкән мыекларына сокланып, аңа кайбер янараллар да ирексездән честь биргән. Бу һөнәрнең кыйммәтен кире кайтару буенча социалистик йөкләмәләр алырга тиешбез.
— Ягъни мәсәлән...
— Һәр көнне биш алкашны ишектән исән-имин, әмма типкәләп озатырга, акча түләмичә шылу ягын караган ике әрәмтамакны тотарга, көн аралаш яңа официантка белән йокларга, почмак читендәге өстәлдә кеше хатыны белән посып утырган начальствога үзеңнең аны күргәнеңне, таныганыңны иплән кенә сиздерергә, аннан берәр үтенеч белән барырга һ. б. һ. б.
— Соңгысы батмый, ирләрчә булмый, — дип киреләнгәндәй итә Сәет.
Тыштан юк-барга тел шомартучы балагур күренсә дә, Хәлил үз җаен белә, тиешлене ычкындыра торган кеше түгел иде.
— Каударланма, Сәет, безнең урамга да бәйрәм килер. Чигәләремдәге кан тамырларым, аягымның чәнчи бармагы белән сизеп торам. Килер ул көн!
Әүвәл бик түбән, галифе чалбар киеп йөргән кеше өчен хурлыклы, оят эш күренсә дә, ахыры игелекле, нәтиҗәле булды. Аларның көне көткәннән тизрәк килде.
Сәет белән Хәлилнең ресторан ишек төбен саклауларын гына көтеп торгандай, Горбачев Рәсәй халкының гасырлар дәвамында күнел юанычы, төп нигъмәте булган аракыга каршы уңышсыз һәм нәтиҗәсез көрәш башлап җибәрде, бәяне давыл вакытындагы дулкыннардай сикертте, корабта укшып барган гавамның болай да гарип, зәгыйфь зиһенен коточкыч чиратлар, талоннар белән бутап бетерде.

Җәмгыятьнең байга һәм ярлыга бүленә башлавы хәмер тирәсендәге уйнаштан, миһербансыз сату-алу котырынуы тудырган гаделсезлектән юл алды.

Аракыны эшләп чыгаручылар, озатучылар, арадашчылар һәм инде атучылар күктән иңгән, бушлай килгән акчаны кая куярга, ничекләр уздырырга, кайларга яшерергә белмичә тәмам иза чигеп, котырындылар, шашындылар. Имчәкне авызларында әвәләүчеләр турында әйтәсе дә юк, хәтта Сәет белән Хәлил кебек әрвахларга да, бүрек белән киңәшеп яши башлагач, шактый төшем эләкте. Дөрес, чәчсез башы гамгалы агайның әмере чыккан беренче мәлне акбашларны таныш-белешкә, дус-ишкә рәхмәт өчен, коры мактауга үз бәясенә чыгарып тордылар.

Аңга беренче Хәлил килде.

— Сәет, минем галифе кесәсе тишек икән.

— Ямат! Хатын белән торган буласың түгелме соң?

— Алкашларның рәхмәте өйгә кайтып җиткәнче, көзге чикләвекләрдәй коелып төшеп калганнар. Җитте. Һәр шешәгә такса куябыз.

— Оят инде, малай, әфисәр калдыкларына.

— Язык казык башында. Оятсызлар заманасы килде. Йоклап ятырга ярамый.

Үзе дә шул фикергә төйнәлеп яткан Сәет ризалашты, эшне үз кулына алды. Болай да оят, тегеләй дә уңайсыз. Иң җайсызы — авыз ачып, акчасыз калудыр әле.

Замана демократиясе атасы Горбачев әйтмешли, «процесс пошел». Аракы бушатканда, икесенә берәр ящик алалар да, әүвәл ике, аннан өч, дүрт, кичке уннан соң биш бәягә арттырып сата торган булдылар. Үзләре бу шөгыльгә артык катнашмадылар да. Тиешле кешесе табылды. Атасы Сталин төрмәсендә юкка чыгарылган, кулак малае, кием биреп торучы Әхмәдиша бабай бу гамәлне иләм дә яратып башкара. Кичке якта, бераз төшергән, мәсьәләне ябу өчен ачы сыекча җитми калган ир-ат килеп баса ишек сакчылары янына.

— Егетләр, бер ярты кирәк иде?

Тиз генә хәл итәргә ярамый. Тартасы, сузасы, нервыда уйнап, бәяне күтәрү кыйммәт.

— Юк бит. Соңгысын әле генә бер танышка биреп җибәрдек.

— Официанттан сорап карасагыз? Сезне тыңлый инде ул.

— Әйтеп карадык. Үзендә дә калмаган.

Сүзгә Хәлил кысыла. Әхмәдиша карт ягына ымлап:

— Бабайдан сорап карасак. Кулак калдыгында бар инде ул. Ну, алар халкын беләсең, бәяне бөердән куялар.

Тәкате сусыз кыяр түтәле кебек корыган ир бар булган акчасын чыгарып сала:

— Зинһар, сорагыз инде!

Бу сөйләшүне ак кыска сакалын сыпырып, елмаеп тыңлап торган «кулак калдыгы», акчаны иренеп кенә алып, як-ягына каранган булып, кара халат астына яшеренгән өемнән берне тартып чыгара.

— Соңгысы, больше сорамагыз! Бетмәс монда ач-әрвах, хәерче алкашлар!

Асыл кош тоткандай, комнан зур алтын бөртеге тапкандай канәгать ирне бәҗәсы Уфадан кайтып төшкән, хатынының туган көненә бер тамчы аракы таба алмаган, унөченче ай өчен алынган эш хакын кая куярга белми алҗыган (өйгә кайтарып әрәм итеп булмый ич инде аны), якын дусты галәмнән кайтып төшкән төрле яшьтәге, төрле рәвештәге, тик барысы да Брежнев тәрбиясен алган, аракыга сусаган халык алыштыра. Әхмәдиша карт тагы да кырыслана, «шайтан төкерегенә» бәяне көйсез базардагы төсле арттыра бара. Табышны Сәет бүлә. Ул — гадел. Кем күпме тапкан, шулчаклысы — анык.

Ресторannan күп алып булмый акбашларны. Үз әрәмтамаклары да житкән. Аракы кибетендә эшләүчеләр белән танышып китәләр. Ике якка да, сары гәрәбә балавыздай, файда тама тора.

Ярты ел эчендә Сәет баштанаяк киенде. Израильгә олаккан яһүдтән, иске йорттан, ике бүлмәле менә дигән квартира сатып алды. Хәлил өч бүлмәлегә күчте. Тагын берничә айдан Сәет өлгергән шомырт төсле кара яңа «Жигули» белән йөри башлады.

Бәйләнчек, вакытында чыгып китә белмәгән исерекбашларны кызганмыйча тукмарга өйрәнделәр. Киләчәктә файдасы тиде. Дөрес, үзләренен дә күз төпләре кара янып, иреннәре майсыз кабартмадай күпереп йөргән чаклары булды. Нишлисең, кунак ашы кара-каршы була.

Ресторан житәкчелеге белән мөнәсәбәтләре жайланды. Киләчәктә эшләп, яшәп, таяныч алып китәрлек таныш-белешләр булдырдылар.

Ике кеше белән генә борчаклары пешмәде. Беренчесе белән яшертен күрә алмау, көнчелек көчәнеше соңрак дошманлыкка күчте, ике якка да зур бәла-казалар китерде. Зал администраторы Мансур Мәүлетов өчесен дә, бигрәк тә мөстәкыйль, үз фикерле мент өчен артык укымышлы Сәетне кабул итмәде. Ишек сакчысы белән булышмаса да ярый иде дә... Әмма ул шул чакта ук Сакмановта үзенә житди көндәш күрә. Соңрак Мансур олы даирәләр белән аралаша, ресторанны сатып ала, хөкүмәт малына чыгу юлларын таба. Мәгәр ике тәкә барыбер тар басмада очрашырга тиеш булалар. Киләчәктә.

Дусларга тынгылык бирмәгән икенче кеше, элеккеге хезмәтләре буенча «сыйныфташлары» — капитан Салих Гаяров булып чыкты. Киләчәктә бу адәм белән юллары гел орынып, кисешеп, мәнфәгатьләре якынаеп барасын, дуслар ук булмасалар да, бер-берсенә кирәкле кишер яфраклары булып китәсен белмиләр иде әле алар.

Кичке жиделәрдә килеп керде Салих ресторанга. Тазалыгы форманы төртеп тора.

— Сәлам, егетләр! Сезнең эш объекты миндә. Хөрмәт итегез,— дип, шаярткандай итте. Танышып торуга кадерле вакытын әрәм итмичә, мәсьәләне хәл итү юлына чыкты капитан.

— Бер ярты алып чык әле,— диде тәбәнәгрәк буйлы Хәлилгә. Алып, иплэп кенә кесәсенә шудырды да, тишек кесәгә салырлык рәхмәт тә әйтмичә, көзге караңгылыкка чыгып та югалды.

Алдагы көннәрдә ул үзенә кирәкле шешә саннарын арттыра барды. Янәсе, шулай булган һәм тиеш тә, сезнең бердәнбер хужагыз — мин. «Абзагыз белән дус яшәү сезләр өчен ожмахка керү белән бер»,— дип тә ычкындырды.

Түзде, түзде дә, Сәет чыгырыннан чыкты. Күтәрелеп бәрелде:

— Иптәш, бездә Әндри казнасы юк. Акчаны түли торган булыйк.

Үз шәхесенә нисбәтән мондый илтифатсызлыкны көтмәгән иде Салих. Кызыл-сарылы күзләрен тасырайтып, егетнең өстенә китте. Явыз итеп ысылдап алды:

— Син кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме?

— Беләм. Гадәти бер мент. Көнбатышта, флик, диләр.

— Караңгы эшләрегезне беләм. Мин сезне яклап, саклап килә идем. Болайга киткәч, бетте башыгыз. Муеныгыз гына тырпаеп калыр!

Өстенлеген раслау нияте белән, елмаерга тырышып карады. Барып чыкмады. Үзе дә беркадәр югалып калган иде. Ломга каршы балта чыкты.

— Ычкын моннан яхшы чакта. Без үзебез дә участковыйның наждак алмый торган тиресеннән ясалган малайлар. Тәртибен беләбез дөньяның.

Сәетнең тавышы сүрән, әмма тәэсирле иде. Каяндыр тирәннән, жир астыннан килде. Туачак житәкче көче астан бәреп тора.

Хәлил, ул чыгып киткәч, чын-чынлап туарылды.

— Кара син аны кәнтәйне, ни кыланган була. Үзенә күрә генә түгел. Исебез китә бик урам себеркесенә. Син аны урынына дөрес утырттың. Тик менә капчыгын тотып күрсәтәсе иде үзенә!

Янгынны сүндергәннән соң су күтәреп килүчеләре дә, батырлары да ишәя шул. Шул көннән Салих көймәдәге ике ахирәтне, аларның турылыклы сакчысы — Әхмәдиша картны күралмас булды. Хәер, кинәсе озакка бармады. Ярты бәясенә машина сатып җибәргәч, Гаяров Сәетнең якын киңәшчесе, «түшәме» булып китте.

Егетләргә ресторан бусагасы тормышы белән җылы саубуллашып, үзгә көнитеш юлына чыгу сәгате җиткән иде инде.

### 3

Хәлил, гадәтенчә, эш урынында иде. «Эш урыны» дигәне биек артлы кәнәфидән, берничә урындыктан, сейф белән ике як тартмалы кара өстәлдән торган бүлмә булыр. Хуҗасы аны «коморка» дип йөртә.

Күзлеге урынында. Ул аны салмый диярлек. «Күзлек — кешене маймылдан аерып торучы тамга»,— ди Хәлил, дүрткүзлелек мәҗбүриятенә зыялылык төсмере тамызырга тырышып. Җылы, ипле бүлмәнең йомшак борылмалы урындыгында утыру өчен яратылган диярсең үзен. Милициядә җил, яңгыр, кар бураны астында уздырган, ресторанда көне буена аяк өсте басып торып, тиеннәр санап этләшкән заманалар, иншалла, артта калды. Нигъмәтуллин хәзер дәрәҗәле, абруйлы шәхес. «Игелек» ширкәте генераль директорының урынбасары ул хәзер. Үзенең вазифаларын тәгаен күз алдына китерә алмаса да, телефонга авызын куеп, озак итеп, тәмләп сөйләшүгә тиз өйрәнде Хәлил.

Ул әле иписез, баллы чәйсез күпмедер вакытка түзә ала. Ә менә җәһәннәм читендә утырган танышының тавышын җиткерә торган гасыр казанышыннан башка, гафу итегез, ул яши алмас иде кебек.

Хәзер дә аягы аяк өстендә, «Мальборо» сигареты авызында. Күзләре, коңгырт нурларын бүлмәгә сирпеп, иң рәхәт мизгелләр кичергәндәге төсле ябылып куя. Җирән керфекләре хуҗаның фикерен хуплап, шап-шап итеп ала. Әгәренки, чыбыкның ар ягыннан яманрак хәбәр колакка иңсә, күзләр кара түфлинең очына кадала.

Телефоннан сөйләшкәндә Хәлилне бер генә кешенең бүләргә хакы бар. «Булды, дустым, туктат, мин ашыгам»,— ди Сәет. Трубканың калтыравычларын кулы белән каплый Хәлил.

— Мөһим сөйләшү, абзый. Хәзер.

— Андый сүзне креслода мәрткә китеп алып бармыйлар. Хатын-кыз белән сөйләшәсеңдер әле.

— Аз гына көтегез!

Сәет юри тавышын күтәребрәк дәвам итә:

— Телефон иркә сүз сөйләү, ыңгырашу өчен уйлап табылмаган Попов бабаң тарафыннан. Аның максаты — эшкә ярдәм итү, аралаштыру. Телефоннан матур апалардан өч сорауга гына җавап аласы: кайда, кайчан, күпме?

«Соңрак шалтыратырмын. Шеф килде»,— дип бик үкенеп, гаҗизләнеп, ярдәмче сөйләшүне өзәргә мәҗбүр була. Кечкенә, йөнтәс куллары белән битен уып ала:

— Күпме? — дигәнеңне аңламадым. Күпме вакытка бушый аласың диюеңме? Акчага сөешү — фәхишәлеккә керә. Безгә ул дәрәҗәгә төшәргә ярамый.

Чын-чынлап үпкәләгән булып, чәчсез маңгаен сыйпап ала, авызын турсайта.

— Күпме? дигән сүзне «ничә» мәгънәсендә аңла син! Ничә кило ысланган ит, шампан, ничә розадан торган чәчәкләр бәйләме, ахыр чиктә, ничә ташлы муенса, балдак... аласы бүләккә... Учыңны ачканда, тешеңне кысма.

Хәлилнең елына бер тапкыр сәдака да бирми торган нәкәс саранлыгын белгән Сәет юри иренмичә аңлата. Тузга язмаслык кыйммәтле бүләкләрне тезеп китә. Затлы тун бүләк итүдә туктый.

Ярдәмченең фикерле, уйлаучан, борчылучан кеше булуын, эш белән шөгыльләнүен күрсәтеп аласы килә. Сүзне башка якка бора.

— Мин әле акча ведомостьларын тикшереп утырдым. Беришесенә кул куймадым.

— Ни өчен дип белик инде? Кул тамагасын салу рестораннан исерек ташудан җиңелрәк, дип уйлыйм.

Шактый тупас төрттерүне Хәлил аңламаганга салышты.

— Үле җаннар күп. Бездә эшләмәгән.

— Чичиковка үле җаннар ни өчен кирәк булганын беләсеңме? Алпавытлар, байлар рәтендә йөрү, дәрәҗә алу өчен кирәк булган.

— Ә безгә?

— Налогны азрак түләү. Хезмәт хакын бүлгәннән соң, инспекция ач кигәвендәйябыша торган төшем өлешенең иллә аз калуын күрсәтү өчен... Ә болай, дустым, без барыбыз да үле җаннар. Иртәме, соңмы. Тагын сораулар бармы? Эшкә күчикме?

Ярдәмчесенең кәефе-сихәтләренә янә бер кашык дегет тамызырга булды Сәет:

— Синең башның гаҗәеп бер сыйфаты бар. Шуны хет беләсеңме?

Ихласлы мактау көткән Хәлил кармакка капты.

— Нинди?

— Сирәк-мирәк булса да, эшләп куя. Менә «үле җаннарны» кояш яктысына өстерәп чыгаргансың!

Мондый ук мыскыллауны көтмәгән иде Нигъмәтуллин. Әмма кая барсын, дилбегә кем кулында, атка юнәлешне шул бирә.

Мин-минлеген җиңеп, аягына басып, Сәетнең җилкәсенә, аркасына кагылып алды. Шул киң аркадан, тыгыз муеннан башка үзенең эче буш клиндер, таяксыз нуль икәнен аңларлык кына сиземләү сәләте бар иде аңарда.

— Кайларда шулай югалдың, Сәет? Инде мин чын-чынлап борчыла башладым. Өеңдә телефонны алмыйсың. Әхмәдиша бабай берни белми, Замир, балык кебек, эндәшми. Миңа артык борчылырга ярамый, ике кыз үстерәсе...

Хәлил йомычка юнган арада Сәет, күнегелгән гадәт буенча, җавапның берничәсен зиһене аша үткәрде. «Түбән Камада шин заводында булдым»,— дип алдашып кына котылмакчы иде дә, житди булмас, дөресен әйтергә кирәк, дигән иманга килде. Чирен яшергән — иртә үлгән, диләр.

— Булды инде хәлләр.

— Әллә тагын өйләндеңме?

— Тагын түгел. Оятсыз. Соңгы мәртәбә.

— Йә хода! Мин шулайдыр дип, кофе чүбендә күрәзәлек иткән идем. Рас булды. Чираттагы мавыгуыңмы, шаяруыңмы?

— Бу юлы — житди. Тиздән шаулатып-гөрләтеп килен төшерербез, туй ясарбыз. Синең бер балагыңны балтырга чаклы сызганып куеп, баш кода булып, түшеңне күркә төсле киереп йөрисе көннәрең алда әле.

— Кызны, киленне каян алып кайтабыз? Башкода булып мин кемнәрнең ишеген кагарга тиеш булам инде?

Хәлил Сәетне һаман шаярта, ирештерә, иркә бала кебек бабасының сакалы белән уйный дип белә.

— Кыз инде минем өйдә. Өстеннән биклəп килдем,— диде Сәет.

Баш кода буласы кеше тулы ай төсле түгәрәк, әмма хәрәкәтчән йөзенә, уртасы миңле маңгаена, күзләренә гадәттән тыш гаҗәпләнгән төсмер чыгарып:

— Урамнан тышаулап алып кайттыңмы? Кайларда эшли инде безнең килен? Ничә баласы бар? Гражданнар сугышында катнашмаганмы? Аклар яклымы, кызыллар өчен көрәшкәнме?

«Балалы, ирле хатыннарны юлдан яздыру буенча син белгеч»,— дип авызын томалыйсы килү кытыклавы узса да миеннән, теленә йозак салуны мәгъкульрәк күрде. Үзе дә гөнаһсыз нарасый түгел.

— Студент кыз. Соңгы курска күчкән.

Хәлил эшсезлектән иза чигеп, тарихи әсәрләр белән мавыга, җае чыккан саен, кирәксә-кирәкмәсә дә, белгәнен кыстырып куюу җаен ычкындырмый.

— Безнең борынгы бабаларыбызның атаклы патшасы Атилла бик яшь, чибәр туташка өйләнеп, беренче төндә җан тәслим кылган. Шулай булмасын!

Хатыны үзеннән өлкән булганга, яшьләргә өйләнгән ирләрне өнәми иде Хәлил.

— Шатланма! Мин инде исән калдым. Атилланың урыны оҗмахта булсын. Егетләрчә үлү әмәлен тапкан. Күп лыкылдадык, эшкә күчик! Нинди күңелле хәбәрләр бар?

— Ерактан башлыйм әле мин докладны. Чапай командировкадан кайткач, Петядан: «Бәла-каза булмадымы?» — дип сорый икән. Тегесе: «Болай бар да тәртиптә, тик кара мәче генә янып үлде»,— ди икән.

— Ничек, кая янды?

— Соң ул лапас башында күгәрчен саклап утырганда, астан янгын күтәрелгәнне сизми калган. Түшәм белән бергә янып төшкән.

— Кайсы лапас янды? — дип сорый икән Чапай.

— Атлар сарае.

— Атлар көтүдә идеме?

— Юк, алары да янды. Фурманов йортыннан да, ялгыз теш кебек ыржаеп, морҗа гына калды.

Сәет тыңлаучы табылганга сөенгән Хәлилне бүлдерде. Аның бу мәзәкне шул ук кабарынкы авыздан йөз дә беренче кат ишетүе иде.

— Әйдә, кирәген сөйлә әле. Вакыт юк.

Хәлилгә тизлекне алыштырып торасы юк иде.

— Мәскәүдән Аркадий шалтыратты. Али исемле, Ямашев урамында комок тотучы әзербайҗан артыннан сезгә папирос итеп эшләнгән биш пачка «күчтәнәч» гашиш җибәргән. Без Самарага вәгъдә иткән идек аларны.

— Бик кирәк иде алар,— диде дә Сәет, сагаеп калды. Дуслары төзәтеп булмаслык хата эшләгәннәр бугай. Бу дус, туган халыкның Рәсәйдә яшәүче вәкилләрендә намус, әхлак, бурыч кебек төшенчәләрне акчага һәм марҗага табыну алыштырып бара. Андыйларны халыкның атамасын бозып, азик, азербутлар, дип мыскыллап йөртәләр.

— Соң, алдыгызмы бүләкне?

— Юк. Бөтен хикмәт тә шунда. Али: «Миңа беркем, берни бирмәде»,— дип баш тарткан. Берничә егетне җибәргән идем, тегеләр бик күпләп җыелганнар. Буш кул белән кайттылар. Син ни әйтәсең инде?

Җаваплылыкны үз өстенә алырга яратмый иде Хәлил иптәш. Сәетнең дә бүген күңелсез хәлләр белән вакланасы, ызгышасы, талашасы килми.

— Уйларга вакыт бир! Телефоннан әйтермен,— дип Хәлилнең юеш кулын кысты да, урамга чыкты.

Сирәк килә торган бәхетле көннәрендә юк-бар белән шөгыльләнергә туры килә, шайтан алгыры. Ә күз алдында сагынычлы мизгелләрнең башы — Зөлфия белән кабат очрашу манзарасы тора.

## 4

Булды андый хәл. Сәет бар әрсезлеген теленә төйнәп, «каршы алыргамы?» дип сорый алды, ә тегесе, җавап урынына кулын изәп, яшел вагонга кереп гаип булды. Рөхсәт бирүеме, саубуллашуы булдымы? Чукраклар телен оныта бара инде. Соңгы вакытта баш-аягы

белән эшкә чумган Сәетнең хатын-кыз нәселеннән читләшеп барышы иде. Вакытны күп урлыйлар. Хәзер дә... Сөйләшү бер хәл, ә аны гамәлгә ашыру... Соңгысы кыенрак икән.

Поездны каршы алырга тәгаен төшәсен белгән, башкача булдыра алмасын йөрәге, тән күзәнәкләре белән сизенгән хәлдә дә, Сакманов үзен бик нык битәрләде, әрләде, эттән алып эткә салды. Кыз-кыркын белән буталып, романтик мәхәббәт дулкынына чумып, хуш исле чәчәкләр күтәреп йөри торган вакыты үткән түгелме соң инде сәрхүшнең? Үзе белән чагыштырганда бала гына бит әле. Анын кызы белән бер чама булыр. Йә хода, ник туктаттым машинаны, ник озаттым шул чибәркәйне. Казан каласында беткәнмени шулай поездга сонаручы ялкаулар! Аларны озатып йөрү синең туры вазифаларыңа керми бугай. Сәет туган, дип үзен өйләгә чаклы тәрбияләде. Мәгәр шул ук киемнәренә төренеп (йә танымас), бу юлы да рульгә үзе утырып, сәгать өчкә машинасын кызыл кирпечле вокзал янына илтеп бастырды.

Поезд сәгать дүртләрдә киләсе. Бөтенләй диярлек таныш булмаган кызны каршы алырга букет күтәреп төшү тартәгә сыймый торган нәрсә тоелды. Бәлки, аны егете каршы ала торгандыр. Бармактан яларлык кызның йөри торган кешесе, сөйгәне булмый калмас. Дус-ишләре белән кайтып төшәргә дә мөмкин. Студент халкы гуртым йөрергә ярата.

Зөлфиянең кайтасы вагонын тәгаен белмәгәч, составның башына, бер читкәрәк китеп басты. Янынннан капчыклар, букчалар, төргәкләр тоткан, балалар күтәргән кешеләр ташкыны агыла. Барысы да каударлана, этешә-төртешә, каядыр ашыга.

Күзләрен чекерәйтеп, бик тырышып танырга тырышса да, керфек каккан арада Зөлфия аны узып китеп (бәлки, шаяртуы булгандыр), бер читкә барып басарга өлгергән. Тузанлы, көзге кояш нурлары көлтәсе эчендә тора. Плащ төймәләрен бүген дә каптырмаган. Ак кофтасын, кыска кара итәген төссез яшел йон күлмәккә алыштырган. Танышлык гомерләрендә икенче тапкыр күз карашлары бәрелеште, чакмадан ялкын күтәрелде.

— Килгәнсез икән, рәхмәт инде. Борчылып йөрмәскә иде. Хәзер ашыкмыйм. Соңга да калмыйм,— диде, елмаюын сүндерүне кирәк тапмыйча кыз.

— Исәнмесез, Зөлфия,— дип, анын нәрсә турында лыпылдавын аңлап та җитмичә, Сәет аңарга кулын сузды. Кызның тырнаклары буялган нәфис бармаклар ирнең олы учына кереп югалды. Икесенә дә рәхәт, җылы булып китте.

— Киттекме?

— Ничек кайтабыз?

— Мин машина белән.

Зөлфия, студентлар беркатлылыгы белән, урынында сикеренеп куйды. Сәет аны карашы белән иркәләп алды да, култыклау өчен кулын җайлап куйды. Таныш машинага урнаштылар.

Сакманов Зөлфияне үз янына, алга утыртты. Куркынычсызлык каешын элеп куйганда, ялгышмы, ирексездәнме, алдан уйланылганчамы, кулы кызның күкрәге өстеннән үтте. Сизгер кул аркасы тыгыз ләззәтлекне тойды. Тәне аша рәхәт калтырау дулкыны узды.

Кыз, гәүдәсен арткарак алды, берни булмагандай сорап куйды.

— Каян вакыт таптыгыз нииндидер билгесез бер студент кызны каршы алырга?

— Урамда туп шикелле тәгәрәп ята иде.

Зөлфия аңлап җитмәде, башын итагатьле генә Сәет ягына борды. Зур ачылган күзләрдә сорау билгесе чалкан ята иде.

— Вакытны урамда таптым диюем.

Кыз, яшьләр генә булдыра алганча, рәхәтләнеп, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Сез шаяртырга яратасыз икән.

— Кая юл тотабыз?
— Общагага кайтасы инде.
— Бәлки, берәр җиргә кереп чәйләп, капкалап алырбыз.
— Әни өч көндә пәрәмәч, бәлеш, токмач, тутырган тавыклар белән дыңгычлап тутырды үземне. Суларга да урын калмады.
— Әтиегез ничек?
— Бавыры бик нык авырта. Түзә алмый, стенага менә. Кстати, менә шул дарулар кирәк тиз арада.
Юлны карап барган йөртүче ягына борылып: «Менә шул даруларны табып булмасмы икән?» — диде кыз.
Сәет рецептларны карап тормады. Барыбер берни аңламый. Таныш аптека мөдире нәрсәгә? Укысын, зиһененә алсын, табып бирсен.
— Уйлашып карыйк әле. Даруларны юнәтсәк, бүген кич мин чакырган җиргә барасызмы?
Сәет ирексездән кызарынды. Тупас, тәрбиясез, аның башкисәрләре дәрәҗәсендә чыкты. Зыялы кеше болай әйтер идеме? Кыз акыллырак булып чыкты.
— Дару өчен генә сатылу арзан булыр. Мин болай риза очрашырга,— диде, кыйгач кашларын уйнатып.— Даруларга килсәк, барысын да табу Казанда да мөмкин түгел, диделәр. Мафия кулында ди алар. Менә бу икесе Польшада эшләнгән, ә менә бусын бары Германиядән, валютага гына алалар икән. Аракы эчеп, симез иттән ясалган шашлык ашап, каз боты кимереп, бавырларын, бөерләрен череткән югары нәчәльство өчен генә тоталар икән,— диде әтине караучы врач абый.
— Безнең әти дә шулар рәтенә керәмени? Кызык...
— Тырышты. Колхоз агрономы гына булса да. Элек рәис иде. Эчкән өчен ыргыттылар үзен эшеннән,— дип, берни яшермичә, күптәннән таныш кешесенә сөйләгән кебек, иң нечкә серләрен риясыз чишә барды. Сәеткә тулысынча ышанып, үзе укый торган институт, тулай торак хәлләре турында сөйләде.
Горкада урнашкан аптекага кереп, бер сәгать эчендә Сакманов барлык кирәкле даруларны күтәреп чыкты. Тик берсенә генә алмаш биргәннәр. Сыйфаты хәтта яхшырак та, ди.
Зөлфиянең даруларны сөенә-сөенә бәләкәй сумкасына төявен күрү Сәет өчен бәхетле бер мизгел иде. Кабарынкы иреннәре шатлыктан дымсуланган. Үбәсене китереп, кытыклап, ымсындырып торалар.
— Ничек таптыгыз шул чаклы даруны? Без бит инде аларны өч ай эзлибез. Сез мафия түгелдер бит? Болай бер дә охшамаган кебек күренә...
Зөлфия бөтен гәүдәсе белән борылып, Сәетнең чиста кырынган йөзен алгарак чыгып торган ияген, киң җилкәләрен тәүге кат күргәндәй иңләде. Бу караштa инде кызыксыну гына түгел, башка, җитдирәк тойгы да бар иде кебек. Үзенә карата кыздагы үзгәрешне Сәет тиресе, йөрәге, җаны, бәгыре белән тойды.
Шуннан, Зөлфия әйтмешли, общагага керделәр. Өченче катта яши икән. Көтелмәгән бер хәл булды. Бүлмәсенең йозагына ачкычны тыгуга, кыз янына олы гәүдәле, мыеклы, Сәеттән шактый яшь ир-ат килеп басты. Күрәсең, ул тәрәзә төбендә, караңгыда көтеп торгандыр.
— Зөлфия, бу мин. Сөйләшергә кирәк!
Әллә дулкынланудан, әллә инде кыюлык өчен төшереп килгәнме, тавышы калтырап чыга.
Кыз, мыеклы ирнең киләсен, каршы аласын көткәндәй, югалып, каушап калмады.
— Килгәнсең икән, кер,— диде. Сәеттән килеп сумкасын алды.
— Вакытыгыз булса, көтегез, зинһар. Бик җитди сөйләшү булачак. Мин тиз!
Сәет үзенең шактый кыен хәлдә калуын аңлап, бәяләп җиткермичә, коридорда йөренде. Ике тапкыр чыгу ишеге янына да килде. Ишекне ачарга кулы күтәрелмәде, аягы тышка атлап чыгудан баш тартты.

Әлеге ирнең кем икәнен белмәсә дә, сүзнең ни, нәрсә турында баруында хәбәрдарлыгы булмаса да, бу очрашуның гадәти күрешү, хәл-әхвәл белешү түгел икәнен аңлый. Бәлки, бәреп керергә кирәктер, яңа танышы ярдәмгә мохтаждыр. Сәет ишеккә якынрак килгән мәлдә Зөлфия кискен нотага күчте. Ишек янында ук тора бугай, сүзләре ачык ишетелә, аңлашыла:

— Мин әйтәсен әйттем! Эш узган. Мин кияүгә чыгам. Ирем көтә мине.

Бу сүзләрдән Сәеткә ничектер рәхәт булып китте. Зөлфия фикерен тулысынча кабул итү җитди булмаса да, ул үзенең кирәкле кеше икәнен тойды.

Беренче булып коридорга, уктай атылып, кыз чыкты. Ярга ташланган балык төсле еш-еш сулый. Ишектән өч-дүрт метрда гына тораташ булып катып калган Сәетнең күкрәгенә капланды, таянычы, ышанычы, яклаучысы барлыкка сөенеп, сулкылдап елап җибәрде.

— Мин сине җәһәннәм читеннән эзләп табармын. Нечестно...,— дип кычкырына-кычкырына, кочаклашып торган Сәет белән Зөлфия ягына үтергеч караш ташлап, чыгу ягына юл алды теге мыеклы адәм.

Сәет ирне куып җитәргә талпынган иде, Зөлфия җибәрмәде. Йомшак, нәфис куллары үзенчә шактый көчле иде.

— Кирәкми. Пычранма. Кешесе ул түгел...

Театр сәхнәсендәге күренешме үзгәрткән төсле, Зөлфия тиз арада үзен кулга алды, элеккеге ашау байдан, үлем ходайдан дип яшәгән, кайгыхәсрәтсез чибәр студент кызга әйләнде дә куйды.

Бу күнелсез, пычрак вакыйга Зөлфиянең кунакка барырга биргән вәгъдәсенә өстәмә көч бирде, авыруны аякка бастырган дәва булды. Кичен авылларына кайтырга җыенган кызга даруларны кертеп бирде дә: «Без бала-чага түгел, сүздә торабыз»,— дип, машинага чыгып утырды.

Биш катлы йортның өченчесенә күтәрелделәр. Сәет әүвәл авыр тимер, аннан соң вак такта белән матур итеп сырланган агач ишекне ачып, кызны эчкә үткәргәч, авыл өеннән, таныш-белешләренең «хрущевка» сыннан, тулайның дүрт тимер караваг тезелгән бүлмәсеннән башка нәрсә күрмәгән сала чибәре аһ итте. Мондый могҗизаны ул кинолар буенча гына күз алдына китерә иде.

Сәет алып кергән квартира искиткеч нечкә зәвык белән җиһазланган иде. Беренче бүлмәнең идәненә юеш ком төсендәге, ялангач аякны үзенә суырып торган олы келәм җәелгән. Стеналарга ябыштырылган инглиз каплагычлары көннең вакытына, караучының кәефенә карап, үзгәрә, балалар уенчыгы кебек төрле төсләргә керә.

Бүлмәне тыгыз, ачык соры тукыма белән тышланган, юан аяклары бизәкле агачтан эшләнгән диван, ике тирән кәнәфи, өстенә видик куелган япон телевизоры, каршы якны кара чикләвек агачыннан эшләнгән стенка, сырлы аяклы түгәрәк өстәл бизи.

Икенче бүлмәнең ачык ишегеннән малайларга мәтәлчек атып уйнарга яраралык, иңе-буе бер гәләмәт зур агач караваг күренә. Алгы, арткы өлешләрендә бизәлгән биек алкалары тормаса, аны татарның элеккеге сәкесе дип тә атап булыр иде. Биек, киң тәрәзәләргә тыгыз материалдан тегелгән авыр пәрдә-портьерлар эленгән.

Бусаганы атлап үтүгә хуҗа, озын, көчле кулларын һавадагы бөркет канатларыдай җәеп, бераз купшырак хәрәкәт ясап:

— Зөлфия, сез хуҗа бу йортка. Җаныгыз ни тели, шуны эшләгез, ашагыз, эчегез, тәгәрәтегез, тәгәрәгез...,— дип әйтеп салды.

Кызның куркынып, сагаеп калуын күреп, артистлануында арттырыбрак җибәрүен сизеп, йомшак кына өстәде:

— Үтегез! Миннән куркырга нигез юк.

Юк, ул ялгышкан булып чыкты. Кыз яңа тирәлеккә, үзгә мохиткә күнегә икән.

— Үз аягым белән кердем. Курыксам, монда күтәрелмәгән булыр идем. Кара пыялалы машинада йөргәч, сездән хатын-кыз, чебешләр шикелле чыркылдап, як-якка сибелешергә тиеш дип саныйсызмы? Яисә, киресенчә...

— Һич тә алай дип уйламыйм,— дия алды кызның шулай төпле, тәфсилле җавабыннан үзе каушап, әсәренеп, хәтта оялып калган Сәет.

— Читсенүемне тормыш тәҗрибәм, сезнеке белән чагыштырганда, азрак булуы белән аңлатып була.

Әлеге көрешүгә нык әзерләнеп, матур-матур җөмләләрне, йомры сүзләрне төенләп куйган булса да, Сәет шуларны кыстырырга җай чыгара алмый интекте.

— Сезгә минем кебек ярлы студент белән аралашу кирәкме икән? Әллә ахирәтегез ташлап, үзегезне кая куярга белми аптырашта калган халәтегезгә туры килдемме? Юкса, мине машинагыз белән вокзалга илтеп куеп, каршы алып, дарулар эзләп йөрүегезне нәрсә белән аңлатып була?

Өй хуҗасы әле диванга, әле читтәге челтәрле урындыкка күчеп утырып, үзен битәрли. «Син нәрсә боламык, шул җилкенчәк сиңа төрттерә, сүз җебен үзе теләгәнчә алып бара. Тот та «мин сиңа беренче күрүдә үк, малайларча, юк, башка сүз кирәктер, тилеләрчә гашыйк булдым, өч көн инде йокым, ашым юк»,— дип, ярып сал. Яңагыңа сыласа, кан әйләнешең яхшырыр, азрак акыл керер, теләсә кайсы матур аяклы, кыска итәкле артыннан тыркылдамассың, урам эте кебек».

Мәгәр шул акыллы сүзләрне тезәсе урынга, буш җавап бирде:

— Күптәннән инде берәү белән дә очрашканым юк. Ышансаң икән...

— Бака белән кәлтә теле бер, ди торган иде минем әби. Барыбер дөресен әйтмәссез,— дип җавап кайтарды кыз. Бераз сүзсез торгач, яшел күзләренә күгелҗем төсмер йөгертеп, «ышандык, безләргә барыбер», дигән төслерәк җилкәсен сикертеп куйды да, Зөлфия сүзне бөтенләй башка буразнага күчерде.

Аягын аяк өстенә куйганда, нәфис күлмәгенең итәген тартып куйды кыз. Бер дә арзанлы, уенчы кәнтәйгә охшамаган, дип күңеленә алды хуҗа.

— Юлдан килгән кешенең тамагы тук булса да, чәй эчәсе килүе табигый түгелме икән, хуҗа әфәнде?

Бәйләнчек чебенне үтергәндәй, шап итеп маңгаена суккан булды Сәет.

— Әйдәгез, бергәләп әзерлик әле кичке ашны,— дип ярдәмгә чакырырга җөрьәт итте.

Әзерлек әгъләдән булып чыкты. Нинди генә нигъмәтләр юк иде «Чит илдә эшләнгән» суыткычларда. Икесе дә затлы балык, ысланган ит, тел, тавык ите кебек азык-төлек, сулар, исерткечләр белән дыңгычлап тутырылган. Кечкенә туй уздырырлык тәгам бар иде аларда.

Өстәлне матур итеп бизәделәр. Француз шампаны белән Зөлфиянең туган авылы болынында үскән әрем тәме аңкып торган итальян «Мартини»ен ачып, икесен дә аз-азлап тәмләделәр. Шәраб җылысы канга үтте, башка менде. Хуҗага кыюлыгы, тәвәккәллеге кайтты.

— Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад.

Бер янып ат алдылар,— дигән Дәрдмәнд бабабыз.

— Мин, гариб, мең янып та,

Яндыга саналмадым,— дип тә өстәгән диләр әле.

— Минем сезгә ышанасым килә,— диде кыз, кытай чәшкәсендәге кайнар кофега өреп.— Мең тапкыр янган булсагыз да.

Сәет аклануны кирәк тапмады. Алдында фәрештә утырса да, тормыш юлыңны бәян итү, гөнаһларыңны ярлыкауны үтенү кабул ителмәгән.

— Чынлапмы?

— Мең кат януыгызга! Әйдәгез, эчик, соңгы көрешүебез булмасын.

— Юк, соңгысы булуын телим мин яну-көюемнең, Зөлфия. Анысы сездән тора. Булыгыз минем хуҗабикәм,— дип, бер тын белән әйтеп салды ир күңелендәген.

Кызның озын, матур керфекләре су чәчәкләре кебек ачылып-ябылып алды.

— Тукай абзый «серен белгәч, кызартырлар йөзеңне, «Җүләр» бу дип ачырмаслар күзеңне»,— дип тә өстәгән.

— Әйтәсен әйттем, Зөлфия. Калганы сездән тора. «Җүләр» дип көләрсез генә, бәлки.

Ул, урындыгыннан җиңел күтәрелеп, кыз янына килде, дала көтүчеләре үрнәгендә, идәнгә чүкте. Ияге йомры тез башына килде. Мондый көтелмәгән гадилек, сәрхүшлек Зөлфиягә тәэсирен ясады. Каршылык күрсәтү, үз-үзен тыю көче кими барганны сизде кыз. Илаһи бер тарту көченә ия иде хуҗа. Сәетнең колагына йөрәкнең дәп-дөп итеп ешая барган тибүе килеп җитте. Сулышы кайнарланды. Нәзакатьлек белән уң кулын кызның җилкәсенә салды.

Зөлфиянең әле кулны, башны акрын гына читкә этәрергә, ияк җылысыннан сары май кебек эри башлаган оятсыз тезләрне бушатырга, читкәрәк алып куйгандай итәргә мөмкинлеге бар иде. Боларны башкарырга кодрәте җитмәде. Җилбәзәк иптәш кызларына үрнәк итеп китерелә торган ихтыяр көче коры чыбык кебек шартлап сынды. Әллә инде аны сихерләделәр? Дымлы иреннәре, һавадан очып, Сәет ягына тартылды. Дөньяда иң татлы шәраб чишмәсе шунда икән. Тәкәббер, кыргый горурлыгы, беренче көнне үк аның җәтмәсенә төшсәм, исемем Зөлфия булмасын, дип кат-кат ант итүләре җилдәге бастырыксыз салам кебек очып таралды.

Ирнең кайнар авызы кызның иреннәрен тәмам үзенеке итте, ничектер сәдәпләр арасына сыйган таза куллары ефәктәй арканы иркәләде. Кызның сулышы ешайды, бөтенләй өзелде, ап-ак беләкләре ирнең муенын, чәчләрен иркәли башлады. Дәртле теләк, омтылыш, хис муллыгы аларны суга эләккән йомычкадай бөтереп алды.

Киң ятакка үз аягы белән килдеме, әллә Сәетнең көчле кулларында килеш бүлмә буйлап сәяхәт иттеме, Зөлфия ул хәтлесен хәтерләмә. Егет, зиһенен җуеп башын югалтса да, иреннәре «ризамы?» дигән сүзне кысып чыгара алды. Җавапның нинди булуы икесе өчен дә әһәмиятсез иде. Бу — борынгыдан калган атавистик бер йоланың пыскып алуы гына иде.

Гадәттә, хатын-кыз белән булганнан соң, Сәет үзен физик һәм рухи яктан бушап, төссезләнеп, тәмсезләнеп калгандай сизә иде. Ике арада вакытлыча булса да, үтәли җил, салкынлык уза, читсенү, ятсыну туа. Зөлфия белән якынлыктан соң, ул үзендә мондый хис, ару, талу сизмәде. Шуннан соң да аның кайнар дәрте, теләге сүнмәгән-сүрелмәгән иде. Бу — ниндидер яңа, үзгә бер мөнәсәбәт иде.

Ризык пешерү эшләрен бергәләп, этешә-төртешә, шаярыша-шаярыша башкардылар. «Игелек»нең генераль директоры, нарасый баладай, Зөлфия тирәсендә буталды, әле алдына чыкты, әле артына төште, килешле борыны, чыгынкы яңаклары онга буялып бетте... Ул — дөньяда иң бәхетле кеше иде.

## 5

Машинасына чыгып утыргач, ул ниндидер җавапсыз калган четерекле бер мәсьәләнең үзен теш сызлавы кебек мазалавын сизде. Тукта, нәрсә борчый соң әле аны?.. Ә-ә, шул гашиш төргәкләре икән. Әйе, бу кавем вәкилләре белән аның тәүге бәрелешүе генә түгел. Монысы соңгысы була күрсен.

Уртак дин, тел якынлыгы әзербайҗан халкына хөрмәт уятып, Карабах фаҗигасе өчен җаны үрсәләнсә дә, бу токымның Казанда, башка калаларда кибетләр ачып, сату-алу белән көн күрүче вәкилләре белән Ярулла абзый малаеның бүрәнәләре бүленгән иде. Башыннан узган ике вакыйга тозлы яра булып һаман да йөрәгендә утыра. Беренче тапкыр бу

ыру белән Монголиядән алып кайткан бердәнбер байлыгын — «Волга» машинасын сатканда очрашты.

Хатыны Рушания белән аерылышкач булды бу хәл. «Машинаның ярты бәясе кызым белән миңа тиеш»,— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды элеккеге хәләл җефете. Ике бүлмәле фатирларын Уфага алыштырып китүе генә җитмәгән иде аңа.

Дөресен әйткәндә, Сәетнең машинасын сату хәлләренә Казанда нык-лап, җитди эшкә урнаша алмау, куяр урыны булмау үтерде... Адәм баласын өмет чаткысы яшәтә. Сәет тә «Волга»ны яхшы бәягә озатып, хатынын бәхилләтеп, «Жигули», «Москвич» кебек түбәнрәк затлы, әмма арзанрак базарлы машина алып куярмын, дип үзен тынычландырды. Сиксәненче еллар уртасында машинага кытлык бетеп, Ижауда ясалганнарын соцрак түләүле бурычка ук сата башлаганнар иде.

Машинасын җибәрү турында уйлап та өлгермәде, маклерлар үзен мәш килеп сырып алды. Кара мыеклы, алтын тешле, шома, елгыр Кавказ егетләре аеруча әрсезлек күрсәтте. Ул заманда чит ил «арабалары» безнең илгә бик сирәк үтеп керә һәм Горькийда ясалган җиңел автомобильнең абруе коточкыч зур иде. Алары да шәхси кулларда, санаулы. Кавказ халкы ГАЗ-24 маркалы машинага хуҗа булу турында хыяллана, бәхетле мизгелләрен төшләрендә күрә, аны кулга төшерү өчен теләсә нинди алдау-елдауга, хәрәмгә бара. Затлы малны мөмкин чаклы арзанрак түләп кулга төшерү юлында мыеклылар шайтан белән дус булырга, тәмугка кереп чыгарга да риза.

Сәетне әзербайҗанлылар чорнап алды.

— Без — мөселманнар. Бер халык дисәк тә ярый. Татарлар безләргә якын, кан кардәшләр. Машинаң кяферләргә әрәм булганчы, мөселман өммәтенә хезмәт итсен,— кебегрәк арзанлы кәлимәләрне тәкърарлап, артыннан бүре көтүедәй өерелешеп йөрделәр.

Телләре шәрыкъ нигъмәтләре кебек баллы, дустанә, һәр кичне тулай торакта пәйда булып, җиләк-җимеш, төрледән-төрле шәраблар күтәреп киләләр. Сәетне күкләргә чөеп мактыйлар, мәңгелек дуслык шәрифләренә чиләкләп ант суы эчәләр.

Дөньяның ачысын-төчесен шактый тәмләгән булса да, фикерләвендә, кешеләр белән мөнәсәбәтендә күпмедер балалыгы да сакланып калган Сәет бу сүзләрне чынга алды, ышанды.

Абуҗәмил исемле тәбәнәк буйлы, әле мыек та үстерергә өлгермәгән, Казан төзүчеләр институтында укучы егет белән дуслашып ук киттеләр. Аңа да машина кирәк икән. Әтисе дә килеп җиткән. Сакмнов әле нибары унбиш мең юл үткән әр-яңа «Волга»сын шуларга сатырга карар кылды.

Экскурсия бүлегендә көнлекче булып йөрүче Сәетне Каспий буе төлкесе үтереп мактарга тотынды:

— Син, энем, төскә-биткә, буйга-сынга шундый чок гүзәл кеше, бездә яшәсәң, минем кулда булса, сине премьер-министр итеп куяр идем...

Максаты мәгълүм: бәяне төшерү, «Волга»ны тизрәк алып китү. Үнсигез меңгә килештеләр. Мәгәречен утырып эчтеләр. Кәмит шуннан башланып китте: машина белән ГАИга, нотариуска йөргән арада ике көпчәк бер-бер артлы тишелеп чыкты.

— Сәетхан, син безне ерак юлга запаскасыз чыгарып җибәрмәссең инде,— диде ата кеше, гөнаһсыз күзләрен сатучыга текәп.

Әлбәттә инде, Сәет шәһәр буйлап йөреп, таныш-белешләреннән бурычка, үзе түләп көпчәкләр юнәтеп, булышты яңа факирларына. Камераларны тегеләр үзләре махсус тишкән булып чыкты. Ярты сәгать эчендә, тәк торганда, ике көпчәкнең бик тырышканда да, һава чыгара алмавын уйлап җиткерергә Сәетнең мөмкинлеге юк иде.

Мөселман кардәшләр хуҗаны гомумән акчасыз да, машинасыз да калдыру юлын сынап карадылар. Совет әфисәре вакытында сизеп алды. Сату-алу кәгазьләрен әмәлләп бетергәч, тегеләрдән алдым, Сәеттән бирдем, дип соңгы журналга кул куясы калды.

— Тамганы салыйк та, кунакханәгә кайтыйк, анда иркенләп санап, акчаны тапшырырбыз,— дигән тәкъдим кертте булачак инженер-төзүче.
Сатып алучыларның дистәгә якын туганнары, танышлары җыелып өлгергәннәр. Шаулашып торалар. «Тегеләр күбәү. Без үз җиребездә, кирәк чакта гел азчылык»,— дип, үзе өчен житди ачыш ясады Сәет. Ярый әле, акылы житеп, тулай торактан үзе белән бер таза егетне алган иде.
— Акчаны санап бирегез,— диде Сәет.
— Кулыңны куй, энем,— дип, Сәетне Әзербайҗанга Министрлар Советы рәисе итеп куярга җыенган абзый сүзгә кушылды.— Акча тулысы белән иртәгә генә килеп житәчәк. Уникe меңен алып тор. Кәгазьләрнең эшен бүген тәмамлыйк, кат-кат килеп йөрмәскә вакыт сарыф итеп.
— Шулай дөрес булыр. Без бит төркиләр, мөселманнар. Бер-беребезне алдашып торырбызмы?— дип шаулаштылар арка терәге итеп чакырылган Казан азиклары.
Сәет, үзен төп башына утыртырга чамалауларын аңлап, ярсыды, дулады.
— Болай булгач, мин машинаны сатмыйм. Мине алдарга җыенасызмы?
— Юк ла, син ничек алай уйлый аласың! Без — чын күңелдән. Без бит төркиләр, мөселманнар... Намуслы халык.
Көпчәкне кирегә әйләндереп булмый иде инде. Кәгазьләр теркәлгән, казнага керә торган керем түләнгән. Көньяк кунаклары барыбер 800 сум акчаны кысып калдылар.
— Энем, соңгы акчабыз, бензинга житми. Карбюратор да начар эшли. Кайтуга телеграф белән җибәрәм. Мин — өлкән кеше. Сине шуның өчен алдап, тәмугка керәсем юк,— дип, абзый ипиләр тотып вәгъдәсен бирде.
Нәтиҗә нинди, дисез инде. Шул ук. Акча килмәде. Сәет хат язып карады, җавапка кәгазь табылмады. Шул вакыйгадан соң күңелендә тулы бер халыкка карата ышанмаучанлык төере калды йөрәгендә. Бер очрактан чыгып кына аерым милләткә мөнәсәбәтеңне билгеләргә ярамаганны да аңлый Сәет. Үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, халык исеменә кара тамга төшерүче мескен, азгын, сатлык бәндәләр һәр кавемдә бар.
Әзербайҗаннарның «чит илләрдә» көн күрүче вәкилләре белән икенче очрашуы да үзара җылылыкны, ышанычны арттырмады.
Тормышның вак-төяк сәүдә, алыш-биреш, сату-алу белән шөгыльләнгән, кеше рәтенә кереп кенә барган чорында булды бу хәл. Фердинанд, Гриша белән Мәскәүдән шактый әйбер сатып алдылар. Казанга кайтышлары иде.
Узып баручы поездга өчесенә дүрт билет алып, бер купега кереп урнаштылар. Соңыннан ачыкланды: составның барча проводниклары азиклар икән. Бер мәлне илдә вагон караучыларга кытлык булып алды. Кавказ халкы «ярдәм» кулын сузды. Кочләүләр, талаулар, үтерешләр башлангач кына алардан баш тарттылар. Кузгалырга иртә иде әле. Үткен күзле, елгыр Фердинанд барча озатып йөрүчеләрнең алар кайтасы вагон башына җыелышып, ашыга-ашыга, берсен-берсе бүлә-бүлә серләшүләрен, киңәшүләрен шәйләп ала. «Гадәти фикер алышу түгел бу, эмоцияләре бугазларына менгән»,— диде мишәр егете.— Сак булыйк, Сәет Яруллович, нәрсәдер мәтәштерәләр бу мыеклылар. Безгә каршы, дим.
Вакыйгалар өермәсе озак көттермәде. Вагон хуҗасы купега килеп тә керде.
— Күпме түлисез алып кайткан өчен?
— Барысы да түләнгән. Менә билетлар, багаж квитанциясе,— диде Сәет.
— Бу хәтле йөкне алып кайтырга махсус рөхсәт кирәк! Безгә өлеш чыгарырга туры килер!— дип, ниятләрен турыдан ярып салды.

Ярты яшьлеген юлда үткәргән Фердинанд «ризалаш, килеш, ватыл, сытыл, соңрак күз күрер»,— дигән мәгънәдә Сәетнең аягына басты, чабуыннан тартты.

— Ярый, ярый, күпме сорыйсыз, шул чаклы бирербез, кузгалып кына китик, аркадаш,— диде Сакманов, мөмкин чаклы тыныч һәм дустанә булырга тырышып.

Алынган хәбәрне кыстырып, киңәш-табышны дәвам иттерергә китте арадашчы.

— Биредә калырга ярамый. Юлда болар товарыбызны алып, үзебезне суеп үтереп, вагоннан бәрәчәкләр,— диде шул ук Фердинанд.

— Вагонда бездән башка кеше дә юк. Ычкынырга кирәк моннан баш сау чакта,— дип өстәде арада иң яше Гриша.

— Кеше күп булса ни файда? Ябык банкадагы үрмәкүчләр төсле, хәзер һәркем үзен генә кайгырта,— дип өстәде Сәет, бу хәлдән чыгу юлы турында уйлап.

Хуҗасы кыен хәлләргә юлыкканда, баш мие өстәмә мөмкинлекләрен ачып җибәрә. Әллә ничәнче буын компьютерларың бер якта торсын. Боларга акча тәкъдим итәргә, малның, әйтик, яртысын бирергә мөмкин. Алар шуның белән канәгать калып, безгә тынгылык бирерләрме? Юктыр, күзләре яклаучысыз сарыклар сараена эләккән ач бүренекедәй ялтырый. Аларга кан кирәк.

— Хәзер ук товарны алып, вагоннан төшәргә кирәк,— дигән тавыш икесенең бер фикергә килүенә инандырды.

Тегеләр югары дәрәҗәдә сөйләшүләр алып барган мәлдә, күз ачып йомганчы, капчыкларын, тартмаларын, чемоданнарын, чанталарын аска төшереп, икенче тимер юл тасмасына ук күчереп өлгерделәр. Аларның малы кем өчендер өстәмә табыш булса, Сәет белән аның егетләренең киләчәге, тормышы, яшәеше шул төенчекләрдә иде. Сәетнең ресторан чорында тупланган, булган акчалары шунда кергән.

Тегеләр хәйләне сизеп алдылар. Чи ит исе борыннарын кытыклаган ерткыч җанварлар кебек, үзе кулга килеп кергән байлыкны кулдан ычкындырмас өчен теләсә нәрсәгә әзер мыеклы, ыржыктай таза егетләр җиргә сикерешеп төштеләр. Җидене санады Сәет. Тыштан бер-берсенә охшау сәбәпле, күп күренәләр. Ачудан тартышкан йөзләренә карап булмый, күзләр камаша. Берсенең кулында балта. Үзара елышып, җилкәләрен тоеп, якынлаштылар. Афәт чыкканда балаларын гәүдәләре белән каплаган аналар кебек, егетләр җирдә яткан әйберләреннән алгарак чыгып бастылар.

— Гриша, газ балоныңны ал, минем култык астыннан чыгарсың! Фердинанд, кастет белән минем сул якка бас! Стойканы алдык!

Каршыга килеп бастылар мөселман кардәшләр. Балтасын җилкәгә салганы:

— Качасызмы! Түләмичә! — дип явыз итеп җикеренде.

— Без башка поезд белән кайтырга булдык,— диде Сәет тыныч калырга тырышып.

— Товарның яртысын калдырыгыз! — дип боерды балта тотканы. Күрәсең, анысы йә бригадир, йә узаман булгандыр.

— Егетләр, без татарлар, мөселманнар. Калдырыгыз безне тынычта. Без сезгә тимибез, сез...

— Карале син аны, «без сезгә тимибез», имеш. Оятсыз!

— Сак булыгыз, без Казаннан!

Сүзнең сере бар иде. Казан төркемнәре Мәскәүдә иң усал, үткен, явыз саналган чор иде бу. Соңрак аларны кырып бетерделәр. Тик үзәк матбугат кына «Казан феномены» дигән уйдырма тирәсендә шактый вакыт әтәч кычкыртты.

Кулга зая мал төшерү хыялы белән әсәренгән азикларны туктатырлык көч юк иде инде хәятта. Өлкәннәре балтаны өскә күтәрде, башкалары кабан дуңгызлары кебек тыгыз рәткә басып, һөҗүмгә әзерләнде.

Өлгерә алмый калдылар. Кыска, тыгыз гәүдәле, йомран кебек житез Гриша, кулларын каратэ алымы белән сугышчан позага күтәргән Сәетнең култык астыннан чыгып, әүвәл «вожакның», аннан башкаларының күзләренә, битләренә газ сиптерде. Шул мизгелдә үк тегеләрнең күзләреннән яшь бәреп чыкты, төчкерә, йөткерә башладылар. Чигенергә дигән әмерне дә көтмәстән, берни аңламыйча, абына-сөртенә, кычкырабакыра вагоннарына йөгерделәр, бер-берсен төрткәли-төрткәли маймыллар төсле үрмәләп менеп киттеләр. Куа килүдән куркыпмы, башка сәбәп беләнме, ишекне бикләп үк куйдылар.

— Гришаның газы бик тәмле дир, бикләнеп иснилэр,— дип авызын ерды Фердинанд, аслы-өсле килгән тешләрен яшереп торуны кирәк тапмыйча.

— Буш балонынны еракка ташла, Григорий. Әйберләрне тегендәрәк күчерик.

Ун-унбиш минуттан яннарына милиционер килеп басты.

— Лейтенанд Дроздов! Сез проводникларга каршы газлы баллон куллангансыз!

— Тентегез,— диде Сәет гади генә итеп.

Лейтенент тикшергән булды да, честь биреп китеп барды.

— Сволочьлар,— дип җиргә төкерде Фердинанд,— жалоба биреп тә өлгергәннәр.

— Гриша, рәхмәт сиңа. Булдырдың!

Менә шул ике хәл-әхвәлдән соң, Сәет туган илләрен авыр көннәрдә ташлап, читтә рәхәт тормыш даулап йөрүче әзербайҗанлыларны өнәп бетерми. Менә хәзер дә, атап җибәрелгән гашишны кысып калырга маташалар.

Сәет шул ике вакыйганы башыннан уздырган арада Төньяк калавылында урнашкан төп резиденциягә килеп җиттеләр. Сулы елгадан олы чокырлары гына калган, тыкырыкка урнашкан, биек коймалы, урыс капкалы, ике катлы йорт тыштан бик кечкенә, тыйнак күренә. Хуҗаның машинасы килеп туктауга, Әхмәдиша бабай килеп чыкты. Махсус көтеп торган, диярсең.

— Сәлам, абзый! Сөякләр сызламыймы?

— Ярыйсы. Сызлар да инде, яшь гел өскә үрмәли.

— Гриша белән Мисхәтне монда чыгар әле.

— Була ул,— дип кереп тә китте.

Тегеләре дә, алдан кисәтелгәндәй, урында, теләсә нинди әмерне үтәргә әзер торалар. Хуҗаның югалып торуыннан файдаланып, йомшарып алырга да мөмкинлек бар иде. Егетләр аяжыганга охшамыйлар. Күз төпләре дә чиста. Кан басымын артык күтәрмәгәннәр.

— Утырыгыз әле машинага.

Тегеләр артка кереп оялаган арада, Замир алгы утыргычны бушатты. Шундый тәртип.

— Егетләр, Хәлил дәдәгез сезгә әйткәндер, теге Али турысында. Барып тагын бер кат җитди итеп, артык шауламыйча гына гәпләшегез. Гриша, син бу юлы газ балонынны алма,— диде көлеп.— Без намуслы партнерлар белән эш итәргә өйрәнгән. Күчтәнәчләрне кайтармасалар, җитди итеп сөйләшергә туры килер. Шылдымы?

Кибетен яхшы белгән егетләргә Алины эзләп табу читен булмады. Чакырып чыгардылар.

— Гашишны алырга килдек,— диде Гриша гади бер нәрсә турында гына сүз каткан кебек.

— Чыгарып бир тиз генә, безнең вакыт юк,— дип өстәде Мисхәт.

— Ул миндә юк.

— Синең арттан җибәргән кеше үзе Казанга килде. Теләсәң, үзен алып киләм. Күзенә карап алдаша алырсынмы?

Али ялган капкынны сизми калды. Шуның белән тотылды.

— Поездда урладылар. Исерек идем.

Гриша зәңгәрсу күзләрен, туң балыкныкы шикелле, бер ноктада туктатты, маңгай сырларын өскә меңгерде, гәүдәсен тартылган җәя хәленә китерде.

— Барыбер рәхәтен күрмәссең! Исән чакта чыгарып бир!

Али да пычрак суда юган, юеш каражимеш күзләрен тәгәрәтеп, йөзенә хәсрәт тавы чыгарып, алдашуына үзе ышанырлык итеп, яклауны тавышыннан табып, төкерекләрен чәчә-чәчә кычкыра, кулларын вертолет канатлары кебек селки башлады. Комоктан, машинадан азиклар килеп бөялде. Мисхәт Гришаның җиңеннән тартты: «Хуҗа «ипләп» кенә сөйләшергә кушты, ычкыныйк».

Сәет егетләре абруйны төшермәслек итеп, ашыкмыйча гына, яшереп куелган машиналарына юл алдылар. Вакытлыча чигенү иде бу.

Телефоннан хуҗалары белән киңәштеләр.

— Күзәтү куегыз. Җаен табып, маен табып, кечтеки генә теракт оештыру мәслихәт булыр. Аннан соң күз күрер.

Шаярып, туарылып алырга рөхсәт кенә бир. Хыяллары шешәдән ычкынган гыйфритнекеннән һич кайтыш эшләми. «Жигули» машинасын УАЗикка алыштырып, җайлы бер урынга басып, кибеткә товар китергән вакытны саклап тордылар. Оста сунарчылардай хис иттеләр үзләрен. Ашыкмадылар. Менә чакмага басар вакыт килде.

Ваклап сату кибете янына аксыл төстәге «Жигули» туктады. Ике арткы ишекне ачып, коробкалар ташый башладылар.

— Газ бир,— диде Гриша.

Мисхәт тимер машинаны зур тизлектә юлга чыгарды. «Жигули»га якын ук килеп, ачык ишекне, янын сыдырып, җиргә куелган шешәләрне, азык-төлекне изеп үтеп китте. Галәмәт олы чыр-чу, тавыш купты. Артына бөтенләй үзгә номерлар тагылган машина икенче урамга кереп югалды.

Егетләр исән-имин кайтып, кылган гамәлләре турында бәян иткәч, Сәет әрләгән булды үзләрен:

— Вак хулиганлык белән шөгыльләнәсез! Безнең ширкәтнең исеме «Игелек». Шуны онытмагыз.

Үзе канәгать.

— Ике көн көтәбез! Әфисәр бармакларын кайтарып бирмәсә, минем белән киңәшеп тә тормыйча, менә шул адрес белән минем дус прораб Василий Яковлевич янына барыгыз. Сез аны беләсез. Менә шул записканы бирегез. Ул көпчәккә көйләнгән олы кранын бирер.

Пырдымсызрак Мисхәт сорап куйды:

— Безгә андый зур кран нәрсәгә?

— Ашыкканның авызы токмачка пешкән, ди татарин. Вәт шул. Али комогын, иртәнге дүрттә, кран белән күтәреп, башка урынга күчереп куюны үтенде. Әле генә шалтыратты...

Гриша, шаяртуны аңлап, йөзен сөенечле елмаю белән бизәде. Кызык, чын эш бу ичмасам, машина ишеген сыдырып йөрү түгел.

— Шуннан соң «азик» ниндирәк көйгә биер икән, күрербез,— дип дәвам итте Сәет.— Туган шәһәребездә үзебез хуҗа булырга тиешбез. Бакуга барып, үз тәртибебезне урнаштырып йөрмибез бит.

Башка сыймастай хыялый күренгән ният гамәлгә шактый җиңел ашты.

Таң атып килә. Гамьсез кала йоклавын белә. Ике олы урам чатында кукраеп утырган тимер кибет янына бик эшлекле кыяфәт белән кран килеп туктый. Хуҗаларына охшаган, кылыч борынлы, кара мыеклы егет биек кран башыннан җиңел генә түшәмгә сикерә, олы тимер кайчы белән ут, телефон, сигнализация булуы мөмкин, асылынып торган бауларны шырт-шырт кисә һәм киоскны тимер ыргакларга эләктерә дә җиргә җиңел генә сикереп төшә. Үзе үк «вера», «майна», «аска төшер», «өскә ал», дип җитәкчелек итеп тора.

Ничәмә тонналап бетон, таш, балчык күтәрергә күнеккән кран өчен бәләкәй кибетне ун метрга читкә алып кую пилмән, бәлеш, шашлык, пылау кебек җитди ризыклар алдыннан кәбестә салатын капкалап алу кебек кенә бер шөгыль иде. Кран тимер җепләрен өскә тарта, аста нәрсәдер шытырдый, чатнап өзелә, коела, әмма зур тартма теләр-теләмәс кенә җирдән аерыла, селкенеп торгач, иртәнге салкынча һава буйлап йөзеп китә һәм шып итеп яңа урынга төшеп утыра. Ике арада сибелгән, чәчелгән нигъмәтләре белән Кытайдан Урта Азиягә сузылган атаклы ефәк юлын хәтерләтеп тора. Байлык, иркенлек.

Сирәк узып баручылар да, берничә йөз метр читтәрәк торучы ГАИ әһеле дә берни шәйләми калалар. Күгендә-түшәгендә чалкан яткан, ваклап сатучыларның кыланышына өйрәнгән айның да исе китми. Бер сәгатьтән «ефәк юлы» өлгер, елгыр кешеләр белән тула. Юлны «чистарту» башлана.

Шул хәлләрдән соң Али, калган әйберләрен саткалап, туган ягына юл ала. Гриша сүзенә ышансаң, аның «җан дусты», үзе теләп, Карабах өчен сугышучы армиягә язылган, ди.

## 6

Хәзерге иң абруйлы ширкәтләрнең берсе — «Игелек» җиңел генә аякка басмады.

Яңартып кору дип аталган үтәли җилләр исә башлагач, халыкка үзенчә уйларга, эшләргә аз гына ирек бирелгәч, аның чос вәкилләре сату-алу, социалистик малны кычкыртып талау, кооператив, уртак, чикләнгән җаваплылык, бердәмлек, АО, МММ кебек оешмалар төзи башладылар.

Ресторанда шактый акча туплап, анда хезмәтне дәвам иттерүнең инде мәгънәсе калмагач, өч дус — Сәет, Хәлил һәм Әхмәдиша карт киләчәкләре турында уйлана башладылар.

— Әйдәгез, вак-төяк мебель ясаучы бер мастерской ачып җибәрик! Аннан күз күрер! — диде Сәет.

Ризалаштылар. Укучылары азая, бүлмәләре артып кала башлаган бер училищены күз уңына алды, директорына якынаю әмәлен тапты Сакманов һәм шунда урындык, өстәл, тумбочка, агач кәрәк кебек, үзләре әйтмешли, шурум-бурум ясау буенча цех әмәлләп җибәрделәр. Ремонт эшләреннән дә йөз чөермәделәр.

Гайса исемле алтын куллы остасы да табылды. Ул, училище укучыларын кызыксындырып, эшкә тартты. Гриша, Мисхәт-Миша кебек, участковый булып эшләгәндә танышкан, ресторан тирәсендә сырпаланып йөргән яшьләрне җыеп алды Сәет үз тирәсенә. Күбесе тәэминатчылар, әзер малны тиешле җиргә озатучылар, машина йөртүчеләр булып урнаштылар. Акрынлап «кара» эшкә дә өйрәнә башладылар.

Халык алар ясаган китап шүрлекләрен, кием элгечләрен, бакчага кирәкле вак-төяк җиһазны ябырылып ала. Беренче елны уңай сальдо белән тәмамладылар. Оныгына кечкенә урындык күтәреп кайтканда, кәшимир яулыклы татар карчыгының: «Улларым, игелекле эш башкарасыз, Ходай Тәгалә тазалык бирсен»,— дигән кәлимәсеннән оешмага исем таптылар — «Игелек».

Мәгәр мебель цехының чәчәк ату чоры озакка бармады. Чабышчы ат кебек ыргылып алга томырылганда, тупас көчләр казып куйган чокгылга эләкте Сәетнең оешмасы.

Әүвәл төрле яклап налоглар белән китереп кыстылар. Табышның яртысыннан артыгын бугаздан буып алды хөкүмәт. Төзелеш әйберләренә, ягулыкка, утка бәяләр арту нәтиҗәсендә, урындык ясап сату файдасыз, зарарлы, чыгымлы була башлады.

Сәет тешен шыгырдатып булса да түзде, цехны, егетләрен сакларга тырышты. Шәхси акчасы, алган кредитлары исәбенәбулса да, эшләп чыгаруны киметмәскә тырышты. Шактый чалшайган мантыйк баганасына ул терәү эзләде. «Дәүләт үз кулы белән нәрсәдер ясаучыны якларга тиеш. Булганны җыеп, ашап бетереп, бер-береңә сатып кына яшәп булмый. Чыганаклар да мәңгелек түгел. Ничәмә еллар тыелып яткан Андрей Платоновның «Чевенгур» романында да сүз бит нәкъ шул хакта бара. Тарих тәҗрибәсен исәпкә алмабыз микәнни? Майланмаган арба белән ерак китеп булмасын аңларлык кына акыллы башлар юк микәнни олы Рәсәйдә?»

Сәет әле һаман да үзенең эшенә ябышып, бөлеп, ахыр штанын сатканчы Казан халкын затлы кләйле урындыкка утырту турында хыялланып йөрер иде, бәлки, «ярдәм» читтән килде.

Төзү материаллары әзерләү хәстәрен күреп, урман хуҗалыгына киткән иде ул көнне. Кайтса, унике кешедән торган коллектив мәктәп янында урамда, кайсы скәмиядә, кайсы җирдә утыра. Иртәдән кәефе юк иде, сул күзенең керфеге тартышты, тикмәгә булмаган икән.

Замир машинаны сүндереп өлгергәнче, эшчеләре янына йөгереп килде. Өстендә кара чалбар, якасы ябык соры свитер.

— Нишләп урамдап утырасыз, егетләр? Мине шулай зурлап каршы аласызмы?

Авызларына су капкандай, басып торалар. Янә Сәеткә сүзне ялгап китәргә туры килде.

— Иртәгә такта килеп җитәчәк. Бер айга җитәрлек! Яшибез әле.

— Кирәк булмас инде,— диде өлкән оста Гайса агай акрын гына.

— Шпана станокларга чаклы ватып чыгып китте. Күрмисеңмени, йөзләребез кара янганны. Каты орыш булды. Сталинград яны сугышлары бер якта торсын!

Сәет, урман сакчыларын сыйлап, агач кисүчеләрне майлап йөргәндә, аның дөньяга карашын, киләчәген текә үзгәртеп куйган вакыйга булган икән шул.

...Көндезге сәгать уникеләрдә мастерской ишеге төбенә дүрт җиңел машина килеп төртелә. Алардан күн курткалы унлап егет төшеп, читлегеннән ычкынган ерткычлар төсле, эчкә бәреп керәләр. Бухгалтер Нонса-Наилә Орбакайтега баллоннан агулы газ төчкертеп, өстәлдә яткан ачкычлар белән сейфны ачып, бар акчаны кырып-себереп алалар. Берни аңламыйча, буш кул белән йөгереп килгән эшчеләрне күн курткалылар кастет, тимер ыргак, монтировка һәм газлы уенчыклар белән каршы алалар. Дөрес, баскынчыларга да шактый эләгә. Сәет егетләре газдан вакытлыча сукыраеп, йөткереп-төчкереп яткан арада бик үк кунакчыл булмаган кабул итүне охшатмаган юлбасарлар, сырт йоннарын кабартып, тәмам азынып, станокларны, җиһазларны, әзер мебельне ватып, сындырып бетерәләр. Ялт итеп торган чиста, матур мастерской кызганыч хәлдә кала. Ахырзаман зилзиләсе сыйпап үткән диярсең бина эчен. Граната, мина-мазар шартлау гына бу хәлгә китерә алмас иде бинаны.

Сәетнең өйдә юк вакытын туры китерүләрен әйт әле. Хәлил дә эштә булмаган. Аның уйлануына, сүзсез сөаленә җавап биргәндәй, Гайса ага йодрыкка йомарланган кулына йөткерә-йөткерә, мәсьәләгә ачыклык кертте.

— Бәддога ул дәҗҗалларга! Тик, Сәет, ачулансаң ачулан, ну аларны чакыручы мин.

Барысы да, «әллә башына тимер-мазар эләгеп, абзый ычкынганмы», дигәнрәк уй белән йөзләрен аның ягына бордылар. Вакыйга тагын да кызыклырак юнәлеш алырга мөмкин иде.

— Күн курткалыларның берсе, күрәсең, өлкәннәредер, кичә төштән соң керде мастерскойга. Минем янга килеп:

— Начальнигыгыз кая?— дип сорады.

— Кичке якта гына була,— дип җавап бирдем.

— Иртәгә биредә булырмы икән? Мин сезгә бик файдалы заказ бирмәкче идем.

— Сәет Ярулловичны берсе көнгә генә күрергә мөмкин. Иртәгә районга китә,— дип ярып салдым. Эшебезне мактаган, салпы якка салам кыстырган булып, шактый озак карап йөрде, тәре. «Без дә шундыйрак нәрсә оештырырга уйлыйбыз»,— дип чыгып китте. Араларында иде ул мәртәт. Аеруча тырышып ватты җиһазларны.

Аңлашыла. Сәетнең өйдә, эштә булмавы кирәк булган аларга.

— Милициягә хәбәр итмәдегезме?

— Монда телефонны өзгәннәр. Директор бүлмәсенә менеп, хәбәр иттем,— диде берсе.

— Соң, килмәделәрме?

— Килделәр. Мәктәпкә җитәрәк ике йөз метр кала туктап, башкисәрләр машиналарына төялеп китеп, тузан басылганны көтеп тордылар. Бездән допрос алдылар. Янәсе, ни өчен сигнализация куелмаган, саклау турында хөкем оешмалары белән түләүле килешү төзелмәгән һ. б. Кыскасы, безгә бик каты шелтә биреп, эт итеп әрләп, бөтен гаепне үзебезгә сылап, сезгә иртәгә сәгать унга майор Гаяров янына килергә кушып, шундый ук тузан калдырып олактылар.

Сәет тавышсыз-тынсыз, эчендәге каһәрен, нәләтен, ярсуын, билгеле һәм билгесез көчләргә нәфрәтен тышка чыгармаска тырышып, озак карап торды хәрабә хәленә китерелгән остаханәләренә. Шулчакны кызганмыйча, варварларча ватканнар, җимергәннәр. Ир уртасы кешенең җылыйсылары килде, тамагына ачы төер утырды. Һәр станок аңа нарасый баласыдай якын иде. Һәрберсен каяндыр эзләп, табып, искерәкләрен сипләп, үзе алып кайткан. Күбесе эшкә яраксыз хәлгә китерелгән.

Шактый акча тамган явызлар кулына. «Хезмәт хакын бүген кич үзем таратырмын, эшчеләремне шатландырырмын бер»,— дип хыялланган иде. Бу ниятен ачы хакыйкать күсәк белән сабан туйда ватылган чүлмәк кебек чәлпәрәмә китерде. Мая өчен сукыр тиенен дә калдырмаганнар. Бу зәхмәтне кемдер оештырган. Тар маңгайлы малайлар үтәүчеләр генә булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килде Сәет. Хәерлегә булсын Хәмдиянең никахы, дип астан бәреп торган ачу хисен дагаларга тырышса да, кыен иде аңа. Бу көн, искә төшкән саен, тәнне чемердәтә торган явыз хатирә булып калды. Гарипләндерелгән остаханә тирән җәрәхәт, мәрхәмәтсезлек, рәхимсезлек, явызлык тамгасы булып яшәде күңелендә.

Сәет Замирны кибеткә җибәрде. Ул алып килгән аракыны, ипи, колбаса, сыр кебек капкалау әйберләрен исән калган өстәлгә туратты.

— Хәтер кичәсен башлыйбыз,— диде төксе тавыш белән.— Урыны оҗмахта булсын, фашистларның кул-аяклары сызласын.

Стакан икенче түгәрәккә чыккач, Сәет берәүгә дә текәлеп карамыйча, сорау бирде:

— Цехны аякка бастырудан мәгънә бармы? Кем нинди фикердә? Хәзер аның язмышын, үзебезнең киләчәкне дә хәл итәбез.

Газиз кешеләрен күмү көнедәй, үле тынлык урнашты. Сүз башларга курыктылар. Җаваплылыгы зур иде.

— Сәет Яруллович,— диде Гриша,— без бу училище белән исәп-хисапны өзик. Аренда өчен акча түләп ятканчы. Бу шпаналар тагын килергә мөмкин. Яхшырак сакланган әйберләрне Әхмәдиша бабай йортына күчерик. Анда урын җитәрлек. Бу подоноклар безнең яңа адресны белергә тиеш түгелләр.

Ризалашты Сәет бу акыллы киңәш белән.

— Гайса абый, син нинди фикердә?

— Энем, ачуланма,— диде йөнтәс кенә оста.— Мин артык сиңа эшкә чыга алмыйм. Карт көнемдә карчыкның токмачы урынына хайваннар йодрыгын ашыйсым килми.

— Ярый, Гайса агай. Тиешле акчаңны соңрак бирермен.

— Син миңа берни тиеш түгел. Кирәк булсам, чакырырсың. Мондый шартларда мин эшли алмыйм.

Сәет соңгы сүзен әйтте. Ташка кадак какты:

— Берничә атнага аерылышып, таралышып торабыз. Очрашу — Төньяк кала авылында. Теләгәннәр — шунда килер. Булачак, туачак яшәешебезне тәгаен күз алдына китерә алмыйм. Мин — әүлия түгел. Әмма бер нәрсә көн кебек ачык: элеккечә яшәп булмый. Без үзебезне үләксәгә өйрәнгән шакаллардан ашатып, шулардан куркып яши алмыйбыз. Фиргавеннәр безне әйләнеп үтә, еректан сәлам бирә торган булырлар. Күбегезгә һөнәрен алыштырырга, киңәйтергә, яңартырга туры килер дип уйлыйм. Риза булмаганнар ирекле. Тиешле зарплатыгызны үзегез биреп җибәргәнсез! Минем әлегә башка акчам юк. Рәнҗештән булмасын,— дип, сүзен шактый кырыс тонда тәмамлады Сәет.

Аның үзе өчен бу вакыйга тормыш чылбырының бер буыны белән хушлашу көнен якынайтты.

Икенче көнне ул Салих Гаяров янына барды. Майор кырында шактый утырды. Әүвәл уртак нокта таба алмыйча өч нарат арасында адашып йөрделәр. Әүвәл ул милицияне эшсезлектә, гамьсезлектә, күн курткалылардан куркуда гаепләп, сүзне зурдан башларга уйлаган иде дә, теленә хуҗа була алды. Үзе дә милициядә матавыкланган кеше буларак, гаепнең аерым бер хөкем хезмәткәрендә түгел икәнлекне дөрес бәяләп, аралашу җаен сайлады. Электән таныш булулары да ярдәм итте.

— Сәет Яруллович, мин сезгә «эш» ачарга мәҗбүрмен,— дип, рәсми башлаган иде сүзне майор үзе дә.— Сәет дус, без бергә, ярдәм итешеп, гел көрешеп яшәргә тиешбез,— дип тәмамлады фикерен.

## 7

Сәет хәзер инде рухы белән җитлеккән, кыю, теләсә нинди кыен шартларда югалып калмый торган, үзен һәм якыннарын яклауга сәләтле шәхес иде. Бер шөгыльдән дә куркып калмавы, замана чалымнарын сиземләве аны упкыннарны әйләнеп үтәргә, кайгы-хәсрәтне уздыра белүгә өйрәтте.

Дөньяви яктан шактый хәбәрдар кеше иде ул. Чит телләрне белмәсә дә, татар, урыс телләрен су кебек эчә. Мангул җирендә хезмәт иткәндә, гомерен башкалар төсле, аракы белән бил алышуга гына әрәм итмичә, фәлсәфи, тарихи китапларны шактый укый, нәфис әдәбият белән дуслаша. Романтик рухлы, тәвәккәл кешеләр язмышын үзәккә алган әсәрләрне ярата. Шигырьне дә кабул итә. Тузанлы, томанлы пыскып яшәешне җене сөйми, кабул итми.

Рухи әзерлеге аңа әлеге хәл-әхвәлләрне артык авыр фаҗига итеп кабул күрмәскә «киңәш» бирде, яшәешнең яңа мөмкинлекләрен барлау, ачыклау, эзләнү юлына этәрде.

Сәет барча исәп-хисап, алыш-биреш кәгазьләрен алып, саннар белән мәш килде. Сызды, бозды, нәтиҗәне җаны, йөрәге белән кабул итә алмый интекте. Ел ярым эшләп, агач остаханәсеннән аның кесәсенә бер тиен акча кермәгән. Коммунистлар мөгаллиме, сакаллы Маркс әйтмешли, башлангыч капитал керемне йота барып, әйләнешкә берни өстәмәгән һәм беренчел халәтенә кайтып төшкән: акча — капитал — акча — хәерчелек. Акча да юк, капитал да тю-тю! Күпме гомер, вакыт, акыл, ихтыяр җегәре әрәм булган, «сөткә киткән». Үзен олы океанда бер ялгызы калган балыкчы халәтендә сизгән көннәре дә булды. Бармакларын чәченә батырып озак уйланды Сәет. Байлыкка, акчага артык мөкиббән китмәсә дә, таза, хәлле яшәешне кешенең акыл сәләтен күрсәтүче билге дип саный иде ул. Исенә бер хикәят килеп төште.

Ике ковбой ат өстендә баралар икән. Юлда нәҗес өеме ята.

Берсе сорап куя:

— Син шул нәҗесне ашый алыр идеңме?
— Нигә ашамаска, түләүчесе табылса.
— Менә сиңа 500 доллар.
Икенче ковбой нәҗесне ашап, акчаны кесәсенә салып куя.
Бераз баргач, шундый ук чүмәләгә юлыгалар.
Икенче ковбой беренчесенә:
— Менә сиңа 500 доллар, аша шуны,— ди.
Тегесе ашап куя.
Бераздан беренче ковбой исенә, аңына килеп:
— Син ничек уйлыйсың: без бушлай нәҗес ашап барабыз түгелме?
Сәет үзен шул юлаучылар кебегрәк хис итте. Ә менә агачтан эшләнгән җиһазларны, Әхмәдиша бабай әйтмешли, уптым сатып алып ваклап озату, үзең ясап акчага алыштыруга караганда, күпкә файдалырак икән. Үзләре юнган көрәк белән тамак туймаган, ә ширкәтне финнар ясаган урындык, немецлар җибәргән диван, төрек кардәшләр кәнәфие тоткан икән.
Мебель ясау үзәген юкка чыгарып, исән калган җиһазларны, сатылмаган әзер нәрсәләрне яңа урынга күчергән көннәрдә Сәет үзенең һәм аңа ышанган, бирелгән егетләренең киләчәге турында баш ватты. Кул көченә һәм гаделлеккә инанган алымның хәерчелеккә алып килгәнен ул аңлады. Аз бирмә — угры булыр, күп бирмә — әрсез булыр, дигән халык. Алыш-биреш, сату-алу шөгыленнән башка яшәп, егетләрне саклап калып булмас, дигән ныклы иманга килде ул. Салих та: «Урындык, өстәл ясап көн итеп булмас, зуррак эшкә алын»,— дигән иде. Милиция әһеле шулай дип торганда...
Нәрсәдән башларга? Кемгә сугылырга? Янәдән аракы сату дәрәҗәсенә төшеп булмый бит инде. Үз заводыңны ачсаң гына. Анысы өчен дә бик күп сәмән, ясалма патент, сыйфат билгесен сугарга җайланмалар кирәк...
Шунда хәрби-сәяси училищеда бергә укыган, Донецк егете исенә төште. Ул, хәрби белемеңә әлләни өмет багламыйча, политехник институт тәмамлаган һәм КамАЗга килеп урнашкан. Бөтен җитәкчелек Мәскәү белән Украинадан булгач, аңа тормышта үзен табу, карьера ясау шактый җиңел була; тиз арада олы заводның генераль директорының коммерция буенча урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелә.
— Кирәк булсам, кил, ярдәм итәрмен,— дигән иде Казанда очраклы күрешкәндә сабакташы Зильберштейн.
Аның янына сугылып кайтсаң? Ятып калганчы, атып кал. Теләнеп йөрүне, бүрек салып, баш иеп соранyны нәселдән килгән горурлыгы өнәмәсә дә, борылышта олавы ишелгән Сакмановның башка хуты калмаган иде. Горурлыгын сындыру алымын да тапты: «Ресторан бусагасын саклаучы, вышибала тиресендә булган кешегә нәрсә дә килешә. Ну, Родион, ярдәм итмәдени, дөнья җимереләме шуннан, аның караvы Чаллыны, шунда яшәгән туган-тумачаңны күреп кайтырсың, солдафон иптәш»,— дип үзенә бик нык басым ясады, мин-минлеген акылына буйсындырды.
Күктән ишелеп яз шавы төшеп килгән, юлларга шарлавыклар тулы хуҗа булган аяз көннәрнең берсендә Замир белән тәвәккәлләп чыгып китте Сәет шәрикташе янына.
КамАЗ заводы татар халкына берни бирмәсә дә, шактый әрсезләрнең тамагын туйдырды, карьера ясарга булышты. Аның җитәкчелеге, совет бюрократиясенең иң югары казанышларын үзләштереп, үзен бик эре, тәкәббер тота, әмма кесәсенә файдалы һәр ниятен гамәлгә ашыра килә.
Сәет танышының сәркатибына үзенең кем икәнен әйтмичә генә, «шәхси мәсьәлә белән» дип шылт кына кереп китмәкче иде дә, барып чыкмады. Әле «Сакманов, Казаннан» дигәч тә, «что за мудак», дип, исенә төшерә алмыйча интеккән. Сабакташ килеп кергәч, йөзе яхшы якка үзгәрә, кочаклап ала.

— Ба, безнең отличник, Саша Сакманов, син икәнсең. Кайсы Казан тинтәге борчып йөри дисәм, үзебезнең кеше икән. Утыр. Маша! Чәй керт, мәй керт. Дөньяда бергә укыган кешедән якын зат юк, була да алмый. Хәлләрең ничек? Ябыгып киткәнсең диимме? Агаргансыңмы? Әллә сөяркәң ташладымы? Исең китмәсен, яңасын юнәтербез. Ошатсаң, минем Машаны ал да кит. Бажайлар булырбыз, хет.

Сәет бу төр җитәкчеләрнең хәйләсен белә: төп шөгыльгә җиткәнче, киеренкелекне төшерү һәм үтенечнең күләмен киметү, яисә аркадан сыйпап, тәк кенә озату.

Куян каны кебек куе, кайнар чәй белән шул ук төстәге «Белый аист» коньягын капкалап, Сәет үз хәл-әхвәле турында бәян итте, сүзен: «Ярдәм сорап килдем, гафу ит»,— дип төгәлләде.

Сөйләшү, аңлату сәләте шактый үскән булса да, Ярулла улы кайберәүләр кебек, тигез җирдә тирән фәлсәфәгә кереп, әйләнә-тирәдә йөрүне кирәк тапмады. Хәленең мөшкеллеген аңлатып, турыдан ярып салды. Шундый урында утырган кеше сабакташының сагынып-саргаеп кына килмәвен болай да аңлагандыр инде.

Көньяк-көнбатышка багып катып калган күзләренә караганда, хуҗа Сәетне җитди кабул итми, яисә бөтенләй тыңламый, дигән фикер калырга мөмкин иде. Нәтиҗә көтелмәгәнчә булды. Олы гәүдәле, аксыл йөзле, соры бөдрә чәчләре учма-уч көлтә төсле ике чыгынтылы калку маңгаена төшкән Донецк «мишәре», Сакмановның агач ясаучы ширкәтен тар-мар итү турындагы хикәясен тыңлагач, тыела алмыйча көләргә тотынды. Тычканга үлем, мәчегә көлке, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер.

— Булган акчаны алып, җиһазларны ватып, җимереп киткәннәр дисең, алайса. Кызык. Бар да заманча. Конкуренцияме, конкурсмы, хулиганлыкмы...

Бергә хәрби мәктәптә укыган дустының аның фаҗигасен җитди кабул итмәвен Сәет аңлап бетерми, рәнҗи, авызын ерып утыруын да өнәми, мәгәр түзә, чөнки ул гозер белән килгән. Ана нәрсә дигән әле: «...түзәр-гә кирәк, балам».

— Шул сволочьлар күпме малны әрәм иттеләр,— диде бөтен ачуын-ачынуын шул җөмләгә салып Сәет.

Бу хәтлесе генә аз тоелды: «Заразалар»,— дип тә өстәде.

— Нишләп шулай тупас? Матуррак сөйләш, Саша, син бит хәрбисәяси әфисәр, шайтан алгыры! Бөтен малың бер КамАЗ бәясе дер әле?

— Хикмәт анда гына мени, Родион. Тыгыз ыштанлы бу малайлар үтәүчеләр генә. Аларны нинди дер үзәк, явыз көч юнәлткән, һәрхәлдә, фатихасын биргән. Эшләп чыгаруга, производство үсешенә каршы аңлы рәвештә олы сәясәт алып барыла. Бу бит илне таркату, халыкны бөлдерү дигән сүз. Көнбатыштан кайткан нәрсәләр исәбенә күпме яшәп була? Бу бит коллыкка төшүнең, кабалага эләгүнең иң туры юлы...

— Бик тирәнгә кереп киттең, дускай. Йөрәк әрнүеңне кемгәдер җиткерәсең килгәнне аңлыйм. Дөресен әйткәндә бездә дә шул ук хәл.— Эре, тигез тешләрен ялтыратып алып, өстәде:— һәркем, синең шикелле, үз җаен карый. Һәм дөрес эшли.

Бу кинаяле төрттерүне дә Сәет чәй катыш йотып җибәрергә мәҗбүр булды. Башкача мөмкинлеге юк. Тимер ыргак кабыргадан эләктергән...

Эре сөякле булса да, бүлмә хуҗасы җанлы, хәрәкәтчән. Авызы капкынны хәтерләтә, аскы ияге алга чыгып тора. Гәүдәсенең матурлыгы турында кайгыртканы сизелә. Тыгыз симезлеге дә килешә үзенә.

Сабакташы көлеп туйды да, япон чәшкәләренә янә чәй, уймак хәтле генә бәллүр рюмкаларга коньяк коя-коя, сорап куйды:

— Ничә КамАЗ кирәк сиңа?

— Соң, ике-өч булса...

Родион Сергеевич, яхшы ат кебек башын артка чөеп, тагын рәхәтләнеп көлде. Җилкәсенә сугып куйды. Сәет, шап-шоп бәреп, майлы кулларын җиңгә сөртеп сөйләшүчеләрне яратмый. Үзе теләп шундый изгелек эшләгән кешене анысы өчен дә гафу итте. Рәнҗемәде.

— Син искечә фикерлисең, Саша. Ике КамАЗ өчен кем инде мине борчып йөри. Башың һаман хәерчелектән чыкмаячак.
— Ничәне бирә аласың?
— Кырыкны ал!
— Кырык КамАЗ алыргамы? Андый акчаны каян табам, ди мин.
— Кредит алырга кирәк!
— Миңа кем бирсен аны!
— Саша, бала-чага булма, минем синең белән балагурланып утырырга вакытым юк. Акча юнәт! КамАЗларны куып китеп, ярты елга яшереп куй. Саклый алсаң, син алты айдан йөз егерме КамАЗлы булачаксың. Иртәгә сәгать икегә хат белән кил. Фикерләрең ышандырырлык булсын. Көчле дәлилләр кирәк.
КамАЗдан машиналар сатып алуның җиңел шөгыль булмавын аңлый иде Сакманов. Ул үзе дә тәртип ярата. Студент чагында ук матур язуы, һәр хәрефне тырышып чыгаруы һәм тиешле дәлилләрне төзеп куя белүе белән аерылып торды. Аңардан менә дигән аппарат кешесе чыгар иде. Вакытында күреп алмаганнар.
Родион аны үзләренең кунакханәләренә урнаштырып калдырды. Сәет төн утырып хат язды. Машиналар безләргә балалар, картлар йортларына, шифаханәләргә арзан бәягә, ашыгыч ярдәм күрсәтү өчен кирәк, дигән фикерне үткәрергә тырышты. Шуннан ары китә алмады. Арзанга алып, кыйммәткә ычкындыру өчен ләзим алар безләргә, дип язып булмый ич.
Табигый ки, сабакташына мәктүб ошамады.
— Мине ышандырмый рәсми язмаң,— диде.— Әле бит мин имза алырга югары нәчәльствога керергә, тәэминатчы сорыкортларны ышандырырга тиешмен. Хатта берәү дә каршы килә алмаслык инандыру көче булырга тиеш. Мондый фикерне уздыр. Сөекле Татарстаныбызга Үзәктән төшерелгән лимиттән башка машиналар белән ярдәм итеп булмый. Ә без, аның җирен таптаган, ипиен ашаган оешма буларак, аңа ярдәм итәргә тиешбез. Машиналарны, рәсми рәвештә, турыдан-туры җибәрсәң, тавыш чыгачак. Димәк, без җирле хөкүмәткә шәхси сату-алу оешмалары аша гына, анда да нindидер житешсезлеге булган, кондициягә житмәгәннәрен,— бүлмә хуҗасы капкын иреннәренә хәйләле кинә чыгарып, күрсәткеч бармагын күтәреп,— арзан бәягә генә сата алабыз.
Менә шул фикерләрне түкми-чәчми кәгазьгә төшер!
Сакманов тагын сырлады, янә сызды. Бу юлы хат төзәтмәләр белән кабул ителде. Родион «болытлар янында утыручылар» катына менеп, аңа имзалар салдырды, аннан бүлмәсенә җаваплы кешеләрне җыйды. Өлкән яшьтәге тәэминатчыга текәлеп сүзен башлады:
— Безне мөхтәрәм Мөнәвәр Абрарович Татарстанга ярдәм итмисез, дип тәнкыйтьли торган иде. Җае чыкты. Кырык КамАЗ бирәбез. Каршылар бармы?.. Юк. Бу иптәш «Игелек» исемле фирма директоры. Акчасын күчерүгә, аңа атна саен бишәр КамАЗ бирерсез. Йөртүчеләрен үзе тапсын. Шуның белән... Ә сез калыгыз, бер минутка,— диде кискен ишарә белән Сакмановка.
Сәет үзен ни өчен калдырганын чамалый. Ашның әле шулпасы гына булды, боткасына барып житмәделәр... Кеше нинди генә югары дәрәҗә биләмәсен, асылында балалык сыйфатларын саклый. Таза, мәһабәт гәүдәле, миллионнар белән эш итүче Родин Сергеевич та мактанып куюдан, абруена асыл ташлар сибеп үтүдән тыела алмады.
— Ну, ничек, барысын да бармак тирәли йөртеп чыктыкмы? Алпартлар дөрес куелдымы?
Әлбәттә, Сәет канәгать, күңеле җиденче күктә, фәрештәләр белән аяк бөкләп чәй эчә.
— Мәңге онытмам изгелегеңне! Миннән ни сорала?
— Синнән артыгын алмам. Өч данәсеннән килгән табышны миңа бирерсең. Кулга. Монысы да үземә түгел, дип, бармагы белән түртеп күрсәтте.

Мәгәр әле шуннан соң да КамАЗларны, бигрәк тә үз бушаткыч итеп җайлаганнарын, алу җиңел булмады. Табага гел май тамызып торырга туры килде. Әмма Сәет кулдагы асыл кошны ычкындыра торганнардан түгел иде. Тиз арада КамАЗда үз кеше булып китте.

Ашыкмаганда да хәрәкәтләре җитез, йөзендә кисәтүле, кинаяле елмаю. Акыллы соры күгелҗем күзләре һәрвакыт уяу. Үзен гәвам дәрәҗәсенә төшерергә тырышып, гадиләштерү сукмагына төшми, тавышын күтәрми, шактый еллар хәрби оешмаларда эшләсә дә, әдәби киртәдән чыккан сүзләрне кулланмаска тырыша.

Бүгенге шөгыльне иртәге көнгә сылап калдыруны аңламый. Акыл, зиһен көче тормыш хәзер куйган мәсьәләләрне хәл итү белән мәшгуль. Туасы көннең үзе белән яңа мәшәкатьләр ияртеп киләсен ул белеп эш итә. Шул сыйфатлары аңа «КамАЗ операциясен» уңышлы башкарып чыгарга ярдәм итте. Машиналарны арзан бәясенә алыр өчен дә акча юнәтәсе бар иде бит әле.

Сәет Чаллы, Казан буйлап, дөнья бетереп, танышларын барлады, койрыгын сыртка салып, хөкүмәт дәрәҗәсенә барып җитеп, кредитлар юллады. Аңардагы җир астыннан бәреп торган кайнар ташкындай дәртне, көчне, фәрманны, ышанычны авызлыклый, туктата алырлык көч юк иде дөньяда.

Чирмешәнгә, ул малай чакта авылларында агроном булып эшләп киткән колхоз рәисенә барып чыкты. Аңа машиналарны, бәя күтәрелгәнче куеп торырга ышанычлы урын кирәк иде. «Абсолют» аракысын тәмләгәч, бөдрә аксыл чәчле, маңгае өсне сайламыйча, як-якка, чигә юнәлешенә үскән, татардан бигрәк, мукшы, ар кавеменә ошаган колхоз хуҗасы үз шартларын куйды. Заманча фикерле торган кеше булып чыкты Сөләйман абзый.

— Алты ай әрәмәлектә тотарга мин разый,— диде. Халыкка «хәрби часть урнашты», дияргә була дигән гоманны хуплады.

— Башковито. Ниндидер хәрби билгеләр, эмблемалар, флажоклар тагасы булыр. Малайлар кызыксынса, дим. Саклауны тулысынча үз өстемә ала алмыйм. Үз егетләрең дә булсын, биредә яшәсеннәр.

Тыныш билгеләренә урын калдырып, өстәде: «ике КамАЗны миңа, алган бәяңә сатарсың».

Кыз сорап килгән кешедәй, Сәетнең калым бирүдән баш тартырга хуты юк иде. Машиналарны алты ай зинданда тотып, янә алучы табасы, бер өлешен Кытай чигенә, иң затлыларын Брест, Чоп тирәсенә куасы була.

Сәетне күп очракта табигатьтән килгән көче, тазалыгы һәм чир исемле әкәм-төкәмне белмәве коткарып кала. Берәр җире авыртса да, ул хастасын яшерү ягын карый. Янәсе, чүп-чар белән вакыт уздырырга ярыймы соң. Чирләп, дәваланып яту — хатын-кызга гына килешә торган иркәләнү, кылану.

Табигать биргән тазалыгы аңа куркыныч, Дамокл кылычы кебек, баш очында асылынып торганда да, КамАЗлар белән башлаган тарихи шөгыльне уңышлы башкарып чыгарга мөмкинлек бирде. Егетләрнең кайсы хәрби, беришесен милиционер киеменә төреп, самосваллар куарга алып китте. Урман аланында сакларга калдырды. Барысы да киләчәк исәбенә, хезмәт хакын бөтенләй диярлек алмыйча эшләделәр. Шунда бернинди өскорма белән җайланмаган, сәясәтне бар дип белмәгән, утка-суга керергә әзер бердәмлек туды. Хәрби тәрбия алган кеше буларак, Сәет оешмада тәртип мәсьәләсен бик каты куйды. Егетләрне үзара артык аралаштырмаска тырышты. Борынгы мәмлүкләр чирүендәге шикелле, һәр берәмлек янындагы кешене, өлкәнрәк бер иптәшне һәм Сәет Ярулловичны гына белергә тиеш иде.

Күгендә өмет йолдызын, төн юлының аргы ягында шәмдәлләр балкышын күргән Сәет яшәреп китте, иҗат кешеләредәй, илһамланып яшәде. КамАЗларның бер өлешен төшемле сатып, аякка баскач, ниһаять, үзе

белән нужа көткән егетләрен җыеп алды. Сөйләшеп алырга, кунак итәргә булды. Билгеләнгән вакытка барысы да килгән. Сәет хәзер үзенең һәм аларның киләчәген тәгаен күзаллый. Офык ачык. Очрашуны мәңге исләрендә калырлык итеп, кыланып, күзгә төтен җибәреп уздырырга булды. КамАЗ җитәкчеләреннән дә күп нәрсәгә өйрәнеп, сабак алып кайтты.

Өстәлгә затлы коньяк, лимон, чикләвек, шоколад куелган. Егетләрнең бит сөякләре ияктән күкрәккә төшеп, ишекле-түрле йөргәнне күрсә дә, шешәне ачарга ашыкмады. Бер актерлы тамаша башланып китте. Арка сөягең нык булганда, җилне кай тарафтан истерсәң дә, үпкәгә зарары тими шул. Сәет шуны белә.

— Егетләр! Болай... Заманалар авыр. Бер-беребезнең чабуына, нәни балалар төсле, тотынып атлаганда гына исән һәм сау калуыбыз бар. Ялгыз агачны кар басар дигәндәй, берәребез калтырана башлап, тәнен каз тиресе капласа — безгә каюк! Аны сындырачаклар. Шуңа күрә алдан кисәтәм, минем белән эшләү иректә. Инде хезмәт итә башладыңмы, ахыргача бергә булу мәҗбүри...

Йомгакның очын югалткандай, уйлы тукталыш ясады.

— Берәрегез чигенә, як-ягына карана башласа, үпкәләштән булмасын! Куркытуым түгел, кисәтеп куюым. Без, тәсбих төймәләре төсле, бер җепкә тезелгән язмышлар. Җеп өзелеп, берсе генә төшеп югалса да, тәсбих изгелеген югалта. Мастерской ачканда, ниятебез изге иде. Эшләргә бирмәделәр. Хәзер үзгә юлга чыгабыз!.. Мин элек хезмәт иткән оешма кешеләре кулына эләкмәү хәерлерәк. Аннан кайтканнарны беләм. Алар бөтенләй башка, рухы ватылган, ихтыяры сындырылган кешеләр. Үзләренә аз-маз охшаганнар да кебек. Әмма... үзгә адәмнәр.

Сәет үзе янына оялаган, куштан Мисхәткә шешәне ачарга кушты. Кue коньякны чәркәләргә үзе койды. Берсен кулына алды. Кояш нурлары уйнаклап торган эчемлекне беренче кат күргәндәй, әйләндереп-тулгандырып карады да, дәвам итте:

— Әйе, без яңа, авыр юлга чыгабыз. Барыгызга шөгыль дә, хезмәт хакы да булыр. Үзебезнең «эшне» ачабыз. Урлау, урлашу, талау, көчләү, урамда сугышу — эшлексезләр гамәле. Мине ярты бәягә сатмаслык зиһенегез булса, өстегездә күн куртка булыр, джинсы чалбар кигән артыгыз затлы машинада утырыр. Матди һәм рухи яктан бәясез шәхесләр итеп сизәргә тиешсез үзегезне. Без — җитди ширкәт әгъзалары. Исемебез шул ук калачак. Тостым мондый булыр. Безнең акыллы башларны өч юха елан сагалап тора: аракы, хатын-кыз һәм нәфес. Өчесе дә, яралы хайван артыннан килгән ач бүреләр төсле, артыбыздан калмый. Ир-егетне харап итәр өчен берсе дә баштин ашкан. Саклап тотучыбыз берәү генә — акыл. Ә акыл дигән бабабыз сакалын селкетеп баш шәрифләрендә утыра. Соңгысының иминлегенә бушатып куйыйк, егетләр!

Дөнья адәм баласын туктаусыз сыный, сират күперен гел алдында тота. Сәет, очрашудан кайтып, өстен алыштырырга да өлгермәде, телефон чылтырады. Кичке телефоннан яхшы хәбәр көтмә.

Чирмешәннән, колхоз рәисе Сөләйман эзли икән. Хәл-әхвәл белешүне кирәк тапмыйча, күңелсез хәбәрен бәян итте:

— Эшләр хөрти, Сәет. Кемдер КамАЗлар турында милициягә хәбәр иткән. Начальнигы Насыйров килеп, карап китте. Бик пырдымсыз адәм. Районда берәүне дә тыңламый. Килеп җит...

Күңеле тыныч булмаганда, эшкә кулы ятмый иде. Замирны эзләп табып, төнлә юлга чыгып китте. Колхоз рәисен нәрәт бирергә барганда, урамда очратты. Сөләйманның кәефе начар, сөмсере коелган, балтасын коега төшергәнмени.

— Юкка сезнең белән бәйләндем. Абруемны төшереп. Пенсиягә ике ел калган.

— Паника өчен нигез юк. Минем кәгазьләр тәртиптә, — дип, үзенең йөрәген кара мәче тырнаса да, колхоз хуҗасын тынычландырырга тырышты Сакманов.

— «Син мафия белән связался! Сколько дали на лапу?» — дип кычкыра миңа.— «Партия заманы булса, мин сине нишләтергә белер идем»,— ди.

— Хәзер аның янына барам. Уртак тел табарбыз, дип ышанам.

Сөләйман аның җиңеннән тотты, кәҗәләр ялый торган эре тоз төсендәге сыек-зәңгәрсу күзләрен өскә күтәрде. Аларда үкенү, сәерсенү, ялвару төсмерләрен укыды Сәет.

— Энем, мине бутама. Ул почти белмәде, диң.

— Мондый эштә «почти» була алмый, Сөләйман агай. Белмәде дисәм, сиңа «борын төбеңдә мафиянең ниләр кыланганын күрмичә йоклап яткансың», диярләр. Бу очракта эшеңнән алганнарын көт тә тор. Югары пенсияңнән колак кагасың.

— Минем рөхсәт белән куйдылар дисәм?

Билгеле бер карарга килгән Сәетнең кәефе яхшыра барды.

— Ялгышкансың, абзыкай, диярләр дә, аркаңа козырь тузы, шелтә чәпәрләр. Бетте-китте. Ә шелтә СПИД түгел... Аның белән озак яшәп була.

— Шаяртма әле. Юлда төшереп килмәгәнсеңдер ич?

— Нигә юктан фаҗига ясарга?

— Ничек инде юктан? Урман аланында дистәләгән КамАЗ, бер районны сатып алырлык байлык ятсын да, ә син пошынма, юкка исең китмәсен, имеш.

— Урланган машиналар түгел. Законный алынганнар. Чуаш агай-эне әйтмешли, такументлары пар.

— Нишләргә дә белмим,— дип, пошынуын дәвам итте колхоз рәисе, күзге пычракны изеп.

— Әгәр акчамы, берәр машинамы тәкъдим итсәк?

Сөләйман кигәвен тешләгәндәй сискәнеп китте. Болай да аксыл чырае яңа акшарлаган мич төсенә керде.

— Ни в коем случае? Ришвәт тәкъдим иттеләр, дип утыртып та куяр.

— Берни алмыймы? Берәүдән дә?

— Бик честный булып кыланган була. Хыялы — Казанга, зуррак урынга күчеп китү.

— Иртәрәк киткән булса соң.

— Безнең башка җитсә, точно үстерерләр үзен.

— Баш бит әле ул, Сөләйман ага, сөяктән генә тормый. Аның эчендә ми дигәне дә бар. Җавабыбызны уйлап барыйк.

— Нервничать иткәндә, минем баш начар кайната. Хәзер дә бер рәтле фикер килми.

Сәетнең тыныч йөзенә карап, шаяртуын бәяләп, үзенең гаебе әллә ни афәтле түгеллеген чамалап, колхоз рәисе дә үз халәтенә кайта башлады. Шулай да үз мәнфәгате үзәктә иде.

— Энем, без КамАЗларны куеп тору хакында үзара килешү ясап куйыйк әле.

— Соң түгелме?

— Без аны задним числом тондырабыз.

Шундый кәгазьне язып, кул тамгаларын салып, мөһерне суктылар. Сәет колхоз кассасына күпмедер акча керткән булды.

Колхоз рәисенең милиция бүлеге мөдире янына бик барасы килмәсә дә, Сәет аны калдырмады, юлда мәсьәләне чишү алымнарын өйрәтте.

— Хуш! Безнең арада договор төзелде. Сине бер бәладән коткардык. «Ни өчен кабул иттең?»,— дип сораса, ә милиционер мондый сөальне бирми калмас, «Миңа Совминнан, фәлән зам. исеменнән звонок булды, «кондициягә җитмәгән кырык КамАЗ куеп торырлар сезгә, алыгыз, яз җиткәч, без аларны бик арзан бәягә колхоз-совхозларга таратабыз»,— дип әйтте... «Кем шалтыратты?» дисә? Бу сорауны ул әбәзәтельни бирәчәк, «хәтерле алмадым. Әллә Абызгельдин, әллә Тәхәутдинов шунда...», дип [illegible]! «Район хуҗаларын кисәттеңме?»,— дип сораса, ул мәсьәләнең

бу ягы белән мәжбүри рәвештә кызыксыначак, чөнки ул милиционер, аның Казанга таясы килә, бер дә авызыңны тажрайтмыйча, сездән күчеп киткән берәр нәчәльникнең исем-фамилиясен әйт, янсә, бездә хәзер демократия, юк-бар белән борчып тормадым», дип бәр.

Сәетнең юравы раска килде. Тыгыз тәнле, кытыршы йөзле, үҗәт күзле майор Сәетнең кәгазьләрен җентекләп тикшергәч, Сөләйманга нәкъ шул сорауларны бирде һәм әзер җавапларны алды.

— Совмин карарын үтим мин,— диде Сакманов үзен бәйсез тотып.

— Сезнең дәрәҗәгә төшеп тордыларммы?— дип белешүне кирәк тапты йөнтәс кашлы майор.

— Өс.ән яхшырак күренә.

Күңеленә хуш, карьерасы өчен файдалы мәгълүмат ала алмады милиция бүлеге начальнигы. Әмма Сәетне яратмас булды. Беренче очрашуда туа алмаган җылылык Казанда күрә алмауга, ачыктан-ачык дошманлыкка күчте.

Канына тоз сибеп торса да, Җәүдәт Габдуллович әллә ни майтара алмады. Тегеләй итте, болай борып карады мәсьәләне, әмма Сакмановка каршы «эш» ача алмады. Мәгәр аның ачы нәфрәтен тиз генә сүндерә алмавы, кара кайрак ташын Сәеткә каршы юнәлтәсе көн кебек ачык иде. Мондый калҗалы сөякне кем инде җиңел генә кулдан ычкындырсын. Бу вакыйганы зурга җибәреп, куертып, бер ата жуликны кояш яктысына тартып чыгарып, погонда тагын бер «йолдыз» арттырырга мөмкинлек бар иде.

Чирканчык асылын ачуны көттерми мәкер. Чирмешәндә булып кайтканнан соң, атна-ун көн уздымы икән, Зильберштейн Сакмановның өенә шалтыратты.

— Сәлам, Саша! Телефоның тыңланмыйммы?

— Кем белсен инде! Мин андый зур шишка түгел лә.

— Зато шишканың иң олысына лаек булырга мөмкинлегең бар.

Шарлавык ярып көлә. Аңа нәрсә? Йомгакның төенле башы аңарда.

— Минем баш сөяге артыннан бер майор җибәргәнсең. Һич сорамаган идем мондый игелекне.

— Гафу ит, Родион. Мин ул эт җан КамАЗга ук барып җитәр дип уйламаган идем.

— Алданрак исәпләргә кирәк иде шул.

— Нинди мәгънәдә?

— Бөтен машинаңны бер җиргә туплау кирәк булмагандыр. Юкка чыгару өчен бер бомба, йә бер өрми тешли торган сыңар мент җитә.

— Республика буйлап таратсаң, җыеп алуы кыенрак булыр, дип уйланылгандыр инде,— диде Сәет кыюсыз гына.

— Бәлки...

— Соң, нәрсә белән бетте?

— Нәрсә белән бетәсен әйтә алмыйм, әмма берничә сәгать кабул итү бүлмәсендә тотуым хак булды. Секретарь кереп әйтте: «Чирмешән районыннан майор Насыров көтә». Мин: «Бу йолдыз Саша калдырган юеш эз буенча килгәндер»,— дип чамаладым. Кәгазьләрне рәтләргә куштым, бүлмәдә утыручыларны чыгармый тордым. Приемныйдан үзем чыгып алган булдым. Янәсе, гафу итегез, бездә производство, эш күп, сулыш алырга вакыт юк.

— Мин урланган КамАЗлар буенча,— ди.— Рухи гарип, мокыт кеше икәнлеге битенә уелган.

— Хуш! Сез аларны каян таптыгыз?— дим.— Чирмешән буенда, урман аланында,— дип җавап бирә синең дустың. Мин мәсьәләнең нәрсә турында барганлыгын чамалыйм. Тиешле кәгазьләрне китерттем һәм үзем һөҗүмгә күчтем.

— Ни өчен милиция җитәкчеләре республика мәнфәгатьләренә каршы астыртын эш алып баралар? Мин бу хакта Министрлыгызга хәбәр итәм,— дим. Трубкага ябышкан булам. Коелып төште. Шадраларына тир бәреп чыкты. Күзе тоныкланды.

— Ничек инде ул алай? Мин каракларны, хөкүмәт исәбенә баеп ятучыларны фаш итәм,— ди теге.

— Без — икмәген ашап, кара җирен таптап яткан өчен Татарстан халкына өстәмә ярдәм итәргә җай таптык. Сез шуңа шатланасы, ярдәм итәсе урынга, аяк чаласыз, эш ачып, тилереп йөрисез. Мин сезнең тәртибегез турында Совминга, башка тиешле кешеләргә хәбәр итәчәкмен. Чын каракларны эзләгез,— дидем. Майор, аңына килеп, нидер әйтмәкче, карышмакчы иде дә, мин кулны суздым аңа:

— Хушыгыз. Танышлыкка бик шат, дидем һәм, беләсеңме, нәрсә өстәдем... Юк, гомергә башыңа китерә алмаячаксың. Әйдәгез, татарлар, бер-берегезне күбрәк утыртыгыз. Безгә яшәргә җиңелрәк булыр,— дидем.

Кызарынды, бүртенде. Честь биреп, чыгып китте. Саша, саграк бул. Майор сине тынычлыкта калдырмаска охшый. КамАЗларыңны тарата башла.

Ярты ел үтте дә китте. КамАЗларны берәм-берәм ил читенә озата башладылар. Һәркайсы үз бәясен җиде-сигез тапкырга артыграк кайтарды.

Сәет үзе дә, егетләре дә «Игелек»нең игелеген күрә башладылар. Ләкин икенче кыенлык туды. Тыныч, иркен, иректе яшәешне сагынып сөйләргә генә калды.

## 8

Тормыш юлының ресторанга бәйле чорында Сәет үзенә бер ышанычлы һәм файдалы кеше тапты. Ул — кием биреп торучы Әхмәдиша карт иде. Күпне күргән, лаеш шулпасын берничә гомергә житәрлек чөмергән, күпләр өчен инде бабай булса да, саф күзле, акыллы һәм алдан күрүчән агай булып чыкты.

Бераз бөкрәя төшкән, әмма ифрат таза гәүдәле Әхмәдиша — Сталин «мәрхәмәте» корбаны — илленче еллар ахырында Казанга кайтып егылган һәм Төньяк калавылында йорт сала башлаган. Барлы-юклы хәзинәсе төзелешкә кереп беткән. Карт эшкә керергә мәҗбүр булган. Иртәнге якта карчыгы Хәерниса белән тәзүче хезмәтен башкара, кичке якта кыска, ак сакалын кием-салым биреп торырга алып килә.

Балалары үсеп, һәркайсы үз көннәрен күрергә төрле төбәкләргә таралышып беткәннәр. Аталар-балалар мөнәсәбәтенә ул бик тормышчан карый.

— Балага таянган көн, таң атмаган төн ул. Мин үлгәч, малымны бүлешергә кайтып җитәрләр. Йортлы-җирле Хәерниса апагыз да берәрсенә кирәк булыр әле.

«Игелек» дип аталган оешманы төзеп, эшен юлга салып җибәргәч, Сәет шәһәр читендә, кешеләрнең күзләренә бәрелеп тормастай бер почмакта, ныклы, ышанычлы база — нигез булдырырга кирәк дигән карарга килә. Контора — вакытлы, училище — үзенеке түгел.

Шунда ул Әхмәдиша абзыйны, аның күркәм, илаһи урынга урнашкан йортын, тирә-ягындагы буш урыннарны исенә төшерде. Болай да тыныч җиргә оялаган бакча артында корыган елга. Яры артык текә түгел, чокыр-чакырлары гамәлгә яраклык, вак куаклыкларны кисеп ату әллә ни кыен булмас. Күңеленә килгән уй-ниятен гамәлгә ашырмыйча, ярты юлда тукталып-төртелеп кала торган шәхес түгел иде Сәет. Хәлиткеч орыш алдыннан урынны, тирә-якны нечкәләп өйрәнгән хәрби төсле, Әхмәдиша бабайның йорт тирәсен, күрше-күләнен ныклап, тәфсилләп тикшерде, суның тирәнлегенә, газ кертү мөмкинлегенә чаклы исәпкә алды һәм җиң сызганып эшкә керешә.

Сәет шул хакта сүз каткач, йорт салу мәшәкатьләреннән иза чиккән, кәгазьләрдә аны хуҗаларның берсе итеп калдыруны һәм шәһәрдә бер

бүлмәле квартира алып бирүне шарт итеп куеп, саф күзле карт ризалашты. Буйсынучан тынычлык турында хыялланган Әхмәдиша морадына иреште. Теләсә кайсы олы затның мөстәкыйльлеге, азатлыгы өлешчә һәм якынча булуны аңлый иде ул.

— Сәет — баш, син койрык,— дип сыртына төртүчеләргә аның җавабы әзер иде.

— Хәзер минем олылап, динебез кушканча күмәрдәй кешем бар. Карт кеше өчен шуннан да зур сөенеч юк.

Ярты ел эчендә Әхмәдишаның хибарасы янында, яр буенда, ике каты җир астында калдырылган, өсте шулай ук ике кимәлле, саунасы, бассейны, ял, эш бүлмәләре белән менә дигән өй калкып чыкты! Чокырчакырларны, әрәмәлекләрне, елга урынын кертеп, йорт тирәсе биек тимер бетон белән әйләндереп алынды. Эчтән корылманы чәнечкеле тимер чыбык, ике явыз немец овчаркасы саклый.

Читтән караганда, Әхмәдиша бабай бу мөлкәткә тулы хуҗа. Килгәнкиткәнгә капканы ача, яба, тиешлесен өйгә алып керә. Карты: «Әй, син, чәеңне куй»,— дисә, озын, киң җиңле күлмәген җилфердәтеп, Хәерниса апа самавырын түргә чыгарып утырта.

Җәен Әхмәдиша абзый яшелчәсен, җиләк-җимешен үстерә, кышын үзләре ясаган тимер кыршаулы агач көрәк белән кар көри. Бабай тормышыннан канәгать. Аңардан йортны, өйне пөхтә итеп тоту, саклау һәм кирәкмәгән җирдә авызны ачып, аңкауны күрсәтмичә, эндәшми кала белү генә үтенеп сорала.

Сәетне борчып торган тагын бер гамәли эше калды. Аларның йортына терәлеп, сылап салынган кечкенә генә өй тора. Җире шактый зур. Машиналарга шыпырт кына килеп керү өчен урын ифрат җайлы. Шактый олы яшьтәге хохол карчыгы берүзе интегә икән анда. Ире үлгән. Әбине шәһәргә күчереп, йортын сүтеп атып, аның җирен дә кушсаң, илләм зур мәйданчык хасил булачак лабаса.

Әби белән сөйләшүне Сәет теле белән тегермән тартырга яраткан, эшсезлектән интегеп утырган Хәлилгә тапшырып, зур хата эшләде, чак кына катлаулы низагъ китереп чыгармады. Сәет аңа теге чактагы ярдәме өчен рәхмәтле һәм, аңардан оешмага файда килмәсә дә, егетләр әйтмешли, Сорыкорт-краснобайны урынбасары итеп тотты, министрлар төшендә күрмәгән хезмәт хакы түләде. Корсак җибәреп, аяк астына яңа дулкыннар өстәгән Хәлил кешеләр белән гади итеп сөйләшә белүне оныткан булып чыкты.

Әби белән иплән кенә, тыныч кына аңлашып, шәһәрдә бөтен шартлары килгән бер бүлмәле фатир тәкъдим итеп, күчерешү шөгыльләрен үз җилкәләренә алып кына, хәл итәсе иде дә мәсьәләне, Сәетнең урынбасары башка юл сайлый. Йорттагы кечек этне һау-һаулатып, әби янына килеп керә:

— Исән-сау яшәп буламы, әби?

— Рәхмәт, улым. Кем дип белим?

— Мин — горсоветтан!

Ярым сукыр әбигә ул чорда теләсә кемгә өләшенгән «КамАЗ автомобиль заводын төзүче батырга» дигән җете кызыл тышлы таныклыкны чыгарып күрсәтә. Аптырап, югалып калган карчыкка мәсьәләнең асылын ныклап бирә:

— Бу урында уналты катлы өй салыначак. Сезнең йорт сноскага эләгә.

— Беренче ишетүем,— ди әби ишекле-түрле йөренеп.

— Бу хакта карар яңа кабул ителде.

— Мине кая куясыз? Мыеклы грузин кебек, салкын якларга озатырсызмы?

— Юк, әби,— ди Хәлил җилле генә,— сиңа Казанның иң матур урыныннан фатир бирәбез. Кайнар, салкын суың, газың — барысы да өеңдә булыр.

— Мин риза,— ди әбекәй, яулыгы белән киңәш-табыш иткәннән соң. Ничек инде мондый солидный кешенең ипле, матур итеп биргән вәгъдәсенә ышанмыйсың!

Мәгәр һәр кешедә әллә ничә «мин» утыра. Шикләнү, шөбһә, ышанасы килеп тә ышанмау, кычытса да алданудан өркү, форсатны ычкындырудан курку — һәркемнең башыннан уза торган тойгылар. Буыннар алышына, өлкәннәр китә тора, ә хисләр, хафаланулар, өркү-сөенечләр, берни булмагандай, яши бирә. Язгы күкрәүләр, көзге пычраклар кебек күчә килә.

Үз файдасына килгәндә исә, адәм баласының — шыгырдавык сиртмәдә чалкан ятса да, Газраилның чәнчи бармагын күргәндә дә — башы барыбер, сәгать теле кебек, үз ягына әйләнә.

Ялгыз әби дә гадәти кеше. Горсовет дигәннәре илләм бай оешма. Нигә аның тәкъдименә каршы килергә. Җирдән дә кадерле нәрсә юк, диләр дөньяда. Аны җиңел генә ычкындырырга ярыймы соң?

Кызыл кенәгәле адәми зат бусаганы азат итүгә, ышанычлы күршеләре белән киңәшеп, Житомирдагы кызын, Одессадагы оныгын чакыртып телеграмма бирә. Юк, горсоветның карарын шик астына кую өчен түгел. Совет хакимияте чорында тәрбияләнгән психология үзенекен итә. Сине талыйлар, син дә авызыңны ачып калма. Йолкы, чум, эләктер! Урла, әмма тотылма!

Кыскасы, украинлы әби хөкүмәттән күбрәк каерып калу хаҗәтен күрә башлый. Бер-ике атна эчендә Казанда яшәмәгән биш кешенең паспортында Төньяк калавылының фәлән урамында, фәлән йортында язылган дигән тамгалар сугыла.

Хәлил бер бүлмәле фатирга рөхсәтне култык астына кыстырып килгәндә, әби аны тулы әзерлек белән каршы ала. Алдына бер өем паспорт чыгарып куя.

— Улым, минем гаиләм зур, миңа өч бүлмәле һәм тагын берле квартира кирәк булыр. Алма, груша, карлыган, кура җиләге һәм башка агачларның бәясен санаган кәгазьне дә алыгыз,— дип, түгәрәк кенә сумманы тоттыра.

Артыгына башы җитми, Сәеткә йөгереп килә. Хәлне аңлата.

— Ну и булдыргансың, егетем! — дип башын тотып утыра тегесе.

Явызлыкка каршы үз этлеге табыла. Әби белән аңлашуны «эттән» башлыйлар. Яңа эшкә алынган башкисәрне, тулы инструктаж биреп, карчык белән югары дәрәҗәдәге сөйләшүләрне дәвам иттерү өчен кертеп җибәрәләр. Кичке эңгердә машина, тузан туздырып, тормозларны шыгырдатып килеп туктый. Йортка керә. Эт тилерә-тилерә өрә. Әби йөгереп чыга. Егетнең йөзендә — кара капрон. Олы омон плащы эченнән кыска мылтыгын чыгара да, этнең авызына пах-пах. Маэмай чинап аркасына ята. Көпшәне әбигә юнәлтеп, бармак яный да, шул ук тизлек белән гаип була.

Икенче көнне башка машина белән үзгә егет килеп, шул ук мылтык белән карчыкның ике тавыгын атып чыгып китә. «Без милициядән, әби. Исән чакта ычкын моннан!»,— ди.

Кичен әбинең колак төбендә, Әхмәдиша бабай бакчасында, тирән чокыр казый башлыйлар. Әллә анда эшләүче егет махсус шулай мәтәштердеме, әллә тәҗрибәсе җитмәдеме, әмма экскаватор тулы тавышка төчкерә, ишәк, дөя авазлары чыгара. Әби тарафларына озатылган мазут сасысына көчек барыбер тончыгып дөмеккән булыр иде. Тавыклар турында әйтәсе дә юк.

Җир өстендәге һәрнәрсәнең кеше күзенә чагылып, көнчелек хисе тудырганын исәпкә алып, Сәет төп байлыкны, склад-гаражны, спорт мәйданчыгын җир астына урнаштырырга булды. Шул ният белән аска төшеп барулары иде. Үҗәт карчыкны кысрыклап чыгару максатын да яшермәделәр игелекле күршеләре.

Әби янәдән киңәшкә балаларын чакыртып ала. Аның моң-зарын тыңлап, якыннары «мафия белән бәйләнмәскә» киңәш бирәләр. Карчыкны олылап, зурлап шәһәргә күчереп куялар.

Ул заманда кооператив дип аталган түләүле фатир сатып алу кыен эш түгел иде. Шул мәлдә Фердинанд, Гриша, Мисхәт, Наилә кебек тугрылыклы хезмәткәрләренә, Әхмәдиша картка МЖК кебек оешмалардан, олы завод-фабрикалардан бурычка, әҗәткә алган булып, дөресе, ришвәт биреп, шактый квартира юнәтеп калды Сәет. Хуҗасын көтеп торганнары да бар.

Әхмәдиша картның йорты «Игелек»нең үзәгенә әйләнде. Шунда эшләр бүлешенә, исәп-хисаплар ясала, дошманнар белән араны өзү планнары корыла.

Хуҗа бабай һәрвакыт игътибар үзәгендә. Божраның эчендә, «сослуживецлары» янына утырып, гәп кору, дөресе, тыңлаучы булудан файдаланып калу — аның яраткан кәсебе. Сөйләшүләре ике юнәлештә бара, гадәттә: сәясәт һәм... хатын-кыз.

— Безнең авызны Горбачев ачты, балалар. Аңа чаклы җиде кат йозакта иде безнең тавыш. Ул рөхсәт бирмәсә, Фәүзия Бәйрамован да, Марат Мөлекевең дә, Фәндәс Сәфиуллинның да парларын юрган астында гына чыгарып ятырлар иде. Рәхмәт яусын аңа.

— Кыланышларының файдасы татарыңа әллә ни тәтемәде,— дип өсти Фердинанд шикелле укыганрагы.

— Татар юаш, басынкы, кайгылы халык. Аңа азатлык тиз генә килмәс. Вакыт кирәк,— ди карт төлке.

— Ни өчен, бабай?

Хәзер инде ул үз җаен җөпли:

— Утызынчы елларда хәлле, таза нәселләрне җыеп, юкка чыгармасалар, хәзер халыкны алып баручы кешеләр күбрәк булыр иде.— Татар ул эшчән халык,— дип дәвам итә Әхмәдиша карт.— Тартыр, тартып барыр, дигән сүздән алынган аның исеме. Татарның ялкавы дәрвиш, ач-әрвах булган. Хәзер дә шулай... Эш ятраткны, иренмәгәне хәзер дә авызын имчәктә тота.

Аның кабатларга ярата торган сүзләре һәркемгә мәгълүм:

— Кош — канаты, агач — тамыры, кеше дуслары белән көчле. Дус бар, дус-иш бар. Алар икесе ике нәрсә. Аера белергә кирәк. Чын дус күп булмый.

— Синең дусларың бармы соң? — дип сорау тондыра Мисхәт-Миша.

— Соң аның дусты Хәерниса түти инде,— дип җавап кайтара икенчесе.

Хәерниса апа, сугыш беткән елны кыш чыккан сыер төсле ябык булуына карамастан, җитез һәм булган карчык. Ул өй буйлап йомгактай тәгәрәп йөри, һәр эшкә җитешә.

Гел авыр хезмәт белән шөгыльләнү аркасында катып калган бармаклары белән кыска сакалын сыпырып, үз-үзенә генә елмаеп куя йорт идарәчесе.

— Хәерниса түтиегезгә тимәгез. Ул — алла билгеләгән үз бурычын үтәде. Шәүләм булып артымнан йөрде, кирәк булса, аягымны юды, тырнагымны кисте. Үзем дә аны рәнҗетмәдем. Минем дуслар үлепләр бетте инде, егетләр.

— Ә без кемнәр? — ди бер әрсезе.

Әхмәдиша бабай сорау бирүчегә, шук балага караган кебек күз сирпи дә:

— Сез сослуживислар, утызынчы елларча әйтсәк, сыйныфташлар. Чын дусларның күбесе инде җир астында. Урыннары оҗмах түрендә булсын, теге дөньяда да тәмуг утларын күрсәтмәсен, бер көнлек дөньяда татыганы да җитәрлек булды.

Колхозга кермәгән өчен барлык мал-мөлкәтләрен талап, Магнитогорскига озатуларын, анда ачлы-туклы яшәп, эчәргә суы да булмыйча, сазлыкта җыелган мүкле сыекчаны кулланырга мәҗбүр ителеп, бик күпләрнең шунда әллә нинди яман чирләрдән, шешләрдән кырылулары турында бик теләп сөйләр иде дә абзый, яшьләрнең тыңлыйсылары килми.

— Елаулардан ни файда!
— Булган, беткән. Үткән эшкә салават...
— Заманасы шундый булган ла...
— Үзләрен яклый белмәгән бабайлар. Күтәрелергә иде.
Шулай да кышкы озын кичләрдә, егетләр «планерка»га җыелганда, хуҗа чакыруны көтеп утырганда, барыбер ул яраткан ике сорау килеп чыга.
Берсе: сез ничек исән калдыгыз?
Икенчесе: бармагыңдагы алтын балдакның серен сөйлә әле, бабай.
Әхмәдиша карт, имансызлардан куркып, куштанланып елмайса да, юеш борынлы малайларны кешегә санамый. Кем беләндер барыбер аралашасы, эчен бушатасы килә адәм баласының.
— Әһем... әһем... Башкалар агулы үләнгә юлыккан сарык бәтиләре кебек кырылып ятканда, әни безнең алтыбызны да саклап кала алды. Авылның җете кызыл коммунистлары (хәзер күбесенең нәселләре чередә, исәннәре дә шунда юл тотсын) безне авылдан сөргәндә, тентеп, рәтлеюньле әйберләрне, азык-төлекне алып калдылар. Биш кило он, ике чиләк бәрәңге, бераз ярма бирделәр дә, шуның белән вәссәлам, теләсәң ничек туйдыр тамагыңны! Чәй, шикәр, бал ише нәрсәләрне ярлы-ябага, ата хөрәсәннәр ташып бетерде... Безнең өйдә чәйгә караш изге иде. Әти, аңа хәтле бабакай, каян туры килсә шуннан, затлы чәй ташыганнар. Афәтне алданрак сизенгәндәй, әнием чәйне чүпрәк-чапрак арасына яшергән, биленә чорнаган. Саз суының микробларын үтерә барганмы, әллә аның башка шифалы, сихәтле көче булганмы, әйтә алмыйм. Чәй, сезнең бәхеткә, Әхмәдиша абзагызны саклап калган.
Аның бу вакыйга-хәлләр турында озын-озак итеп, тәмләп сөйлисе килсә дә, кыскарак юлны сайларга туры килә, яшьләр тыңлый белмиләр, каядыр ашыгалар. Усал кигәвен тешләгән ат шикелле, пырдымсызланалар.
Сул кулының күрсәткеч бармагында тирән бер эз бар. Анда яшь тире аксыл-кызгылт булып үскән, балдак төсле тора.
— Сез әйткән, мәңге салынмый торган алтын балдакны мин урак урганда таптым. Унбер-унике яшь тирәсе булгандыр миңа. Кул астына керә башладым. Әни урак белән эш итәргә өйрәтә. Кызып-кызып бодайны урып ятканда, учма белән бергә бармакны үләктереп ташламыйммы алланың бирмеш көнендә! Үз күзем белән күреп торам: ярты бармагым җирдә. Майлы табага эләккән тере балыктай сикерә. «Әти, бармакны кистем!»,— дип акырып җибәрдем. Көлтә бәйләп ята иде. Йөгереп килеп җирдән бармакны алды да, балчык белән канны туктатып, тегесен ялгап, дегет сылап, соры чүпрәк белән каты кысып бәйләп куйды. «Бер-ике көн өскә күтәреп йөр»,— диде.
Ни хода рәхмәте булгандыр, ялганды бармак. Алтын балдак эзе мәңгелек ядкяр булып калды, бахыр.
Әхмәдиша картны тормыш күп нәрсәгә, күргән-белгәннән нәтиҗә ясарга, кечкенә генә тоелган вакыйгада олы мәгънә табарга өйрәткән.
— Адәм меңнәрчә еллар дәвамында бары зобанилык кыла. Ата-бабалардан килгән рухи хәзинәсе кими, хәерчелеккә төшә бара. Бүген дә ул явызлык юлыннан атлый. Хәзерге аракы эчүне, заяга кеше үтерүне, фахишлекне алып карагыз? Кылануның иге-чиге юк, бала атаны, кече олыны санга сукмый.
Философ-бабайның мондый сүзләре яшьләргә кызык түгел. Бер колакларыннан керә, икенчесеннән чыга тора. Аның кешеләрдә күркәм холык, ихласлык, пакьлек күрү теләге сүнми-сүрелми барыбер.
Әхмәдиша абзый Бәдретдинов яхшы машинада сәйран чигеп йөрүдән башканы белмәгән тыгыз ыштанлы егетләрне өнәп бетерми кебек. Ачуланырга җае чыгып тора.
— Гаурәтегез белән масаеп йөрмәгез әле монда. Андый нәрсә эттә дә бар. Ишәкнекен әйтмим дә.

Икенче берсе житдирәк сорау тартып чыгара:

— Әхмәдиша агай, ни өчен безнең заманда ирләр күпләп, яшьли үлә?

Уйланып торгандай итә карт, аннары әйтә:

— Җыен тиле-миле кулына корал тоттырдылар. Бер-берегезне чебен урынына кырасыз.

Тегесе җавапны кабул итми.

— Үз үлеме белән үлгәннәр дә житәрлек. Зиратка барып карагыз. Гел яшьләр ята.

Монысын карт күпмедер күләмдә үзенә кабул итә. Сөргеннәрне сөреп чыккан, һаман яши, янәсе.

— Һаман үзегезнекен куасыз!

— Нәрсә дигән сүз? Ничек аңларга?

— Чиратсыз кересез!

Сабан туйларын күп күргән бабайны «сыртка» салып булмый. Юморы кара булса да, аңа үпкәләп булмый. Күзләре яшьле.

— Артыгын урламагыз! Нәфесне тыя белү адәм баласының ихтыярын, башка җан ияләреннән үзгәлеген күрсәтүче төп ызан ул, балакайларым. Адәм малына кызыгу — үле күлдә балык сөзү ул,— дип тә өсти карт.— Бушка килгән хәрам сыйны тамагыңа алма!

Арадан берсе генә картны: «Сандугачны сайрарга өйрәтмиләр»,— дип бүлдерде.

Бабайның сөйләнүләрен тыңлый-тыңлый, аңа ике кушамат тактылар: «Коры куык» һәм «Буш чиләк». Ә аның исе китми, сакалы да селкенми.

— Егетләр, бер-берегезне яратмасагыз да, хөрмәт итеп яшәгез, ачу тотып, үзегезне-үзегез җимермәгез, ешрак елмаегыз. Әйдәгез, шәфкатьлерәк, ачык чырайлырак, сабыррак булырга тырышыйк.

Ә үзенең хәсрәтсез, нарасый күзләрендә һәрвакыт яшь һәм моң.

Егетләрнең кәефле вакытларыннан файда күреп калырга ашыга:

— Ягез әле, Хуҗабыз килеп житкәнче, менә бу мебельне машинага төяп куйыйк әле, алтыннарым!

Ачыктан-ачык сөйләшүдән соң берәү дә баш тартырга җөрьәт итми. Ул бандитларга болай гына эш кушып кара син. Утырган жирендә ятып калырсың!

## 9

Гөнаһлы гәүдәсен кая куярга, кемгә барып сыенырга белми, чит-ят тулай торакларда кунып йөргән көннәрнең берсендә, Сәнгат атлы бер егет Нәриман урамында бергә үскән Гришаны очратты. Икесе дә танымаслык булып үзгәргәннәр. Сәнгат сабакташын кылган кебек аксыл чәчләре һәм үзе төсле үк кыска, тыгыз гәүдәсе буенча гына чамалады.

Исәнләшеп, бер тирәдә яшәгән таныш-белешләрен барлагач, табигый ки, сөйләшер сүзләре тәмамланды. Бик оста сүгенүе, тәмәке төтенен ике-өч түгәрәк ясап чыгара белүе буенча Гриша урам танышының кай тирәләрдән кайтуын чамалады.

«Безгә берничә башкисәр, чая, кыю егетләр кирәк булыр, карыштырыгыз»,— дигән иде Сәет Яруллович. Нәкъ шул кеше бугай Сәнгат. Төп шикелле таза. Яшәр урыны юк. Сүзне озынга сузмыйча, Гриша, шефыннан телефон аша рөхсәт алды да, егетне үз машинасына утыртып, Төньяк калавылына, Әхмәдиша абзыйларга алып китте.

Танышын машинада калдырып, Гриша әүвәл өйгә үзе генә кереп китте. Аның югалуы көткән кешегә шактый озак тоелды. «Минем турыда ләтчә саталар булыр, нинди эш тәкъдим итәрләр икән, мин бит параша түгә беләм дә, кабырга сапый алам, иякнең, корсакның кайсы җиренә суксаң, нинди «файда» буласын чамалыйм. Бу һөнәргә аларда ихтыяж булса? Аңа шундыйрак эш тәкъдим иткәннәр иде. Барып чыкмады.

Кимендә машинасы, газ пистолеты булганнарны гына алалар икән. Сәнгатнең өстендәге киеменнән, күкрәк йонынан башка байлыгы юк. Машина тагын... Көтү озакка киткәч, йөрәге тартышып, күңеле бимазаланып куйды. Әйтерсең лә аны тикшерүче бүлмәсенә яисә төрмә башлыгы янына алып керүгә әзерлиләр.

Тулган айдай балкып, Гриша атылып чыкты.

— Эчкә керәбез. Хуҗага — Паханга охшарга тырыш. Эшкә кабул итсә, авызың балда-майда йөзәр, кайгы-хәсрәт белмәссең. Каршы әйтмә! Үзсүзлеләрне яратмый. Боламык икән, дип тә уйламасын. Җае чыкса, сүгенеп күрсәт...

Авыр капканы ачып, эчкә үткәргәндә, колагына пышылдап калды:

— Рекомендация минеке. Беркайчан да онытма.

Көн эссе булса да, башына түгәрәк, җылы мескен бүрек кигән карт егетне уздырып, капканы келәгә утыртты да, көрәк хәтле кулы белән өйгә ишарә ясады. Шунда уз диюе булгандыр инде.

Сәнгат шыгырдап торган нарат тактасыннан ясалган, буялмаган баскычтан менде, салкын чолан аша кабинетсыман ифрат зур бүлмәгә үтте. Кыл уртасында көзге төсле ялтыравык, шома өсле өстәл тора. Ике яклап күн тышлы, юан аяклы авыр урындыклар тезелгән, башында — арты биек, әйләнә торган йомшак кәнәфи. Шундыйны ул кайчандыр төрмә нәчәльниге кабинетында күргән иде.

Бүлмәдәге башка җиһазларны күңеленә сеңдерә алмый калды. Уң яктан калын агач ишек ачылды, бүлмәгә хуҗаларча җитез атлап, урта яшьләрдәге ир килеп керде. Соры җинел костюмы озын, матур гәүдәсенә сыланып тора. Гыйнвар кары кебек ап-ак күлмәк, төсле ефәк галстук, кара күзлек — һәммәсе килешле. Ул акрын гына Сәнгаткә якынлашты, туктап аны күзәтте. Егетнең гәүдәсе аша рентген нурлары уздырдылар диярсең. Сәнгатнең басынкы, тыгыз гәүдәсен, кыска күлмәк җиңен төртеп торган мускулларын ошатты бугай. «Пахан» дигәннәре шул микәнни? Исемен дә әйтмәде Гриша тәре, ничек эндәшергә белмәссең, дип уйлап өлгерде Сәнгат.

Кергән кеше кискен хәрәкәт белән кара күзлеген кулына алды. Үзенә караганда яшьрәк күзләре егетне өйрәнүне дәвам итте.

«Йөзе зыялы күренә шайтанның. Нәселле, күрәсең. Тик ходай ишәкнең холкын белеп, мөгез бирмәгән, ә моңа буйны кызганган», — дигән фикергә килде егетнең тәрҗемәи һәм кәлҗемәи хәленнән азмы-күпме хәбәрдар Сакманов.

— Кара син аны, бездә кунак бар икән. Әйтмиләр дә... — дигән булды.

Янәсе, бүлмәдә чит затның пәйда булуы аның өчен яңалык, ачыш. Гриша бер сәгатькә якын югалып тормаган да араларында Сәнгат турында ләм-мим сүз булмаган, егетнең биографиясен сөйләтмәгән, холкын, фигылен тәфсилләтмәгән...

Аягындагы нечкә борынлы кара түфлиләр хуҗаны бүлмә уртасында тораташтай катып калган Сәнгат янына алып килделәр. Гадәти генә итеп кулын бирде, аннары сынагандай, каты итеп кысты.

— Кем дип белик инде? Ни йомыш китерде салкын Төньяк поселогына чибәр егетне?

Сүзгә маһирлыгы чамалы Сәнгат мондый итагатьле, ягымлы, мөлаем мөрәҗәгатьтән бөтенләй югалып калды.

— Йомыш дип... Мине Гриша алып килде. Нәрсәгә икәнен аңлатмады.

— Ниләр вәгъдә итте инде Григорий?

— Әйдә минем белән, үзеңне Пах...

Пахан белән таныштырам дип әйтмәкче иде. Болай эндәшүнең килешеп бетмәсен аңлап, телен тешләде. Сыртына милициянең резин таягы килеп сылангандай булып китте.

— Ах, Гриша, болтун, кычыткан чыпчыгы. Миңа кушамат та тапкан. Нишлисең, картлар үгетли, яшьләр шаярта. Мулла абзый кушкан исемем — Сәет. Сәет Сакманов. Мәрхүм әтием Ярулла исемле иде. Нинди һөнәрләрең бар, Сәнгат туган,— дип, сөйләшүен дәвам итте, егетне аңларга тырышты.

«Сугышчы булып туган. Башы кечкенә, бәдәне аякларына караганда озынрак (мондый гәүдәгә табигать тиле көч бирә), җилкәләре киң, йодрыклары йомры. Затсыз тәмәкедән саргайган тешләре генә артык эре. Елмаюы өметсез. Төрмәдә иманын алганнар. Сиңа, абзыкай, нәкъ шундый чарасыз һәм дуамал кеше кирәк түгелме соң?»

Сәетнең үзен исеме белән эндәшүе, туган дип атавы егетнең талымсыз, наз, кадер-хөрмәт күрмәгән йөрәгенә эретелгән шәм җылысы булып ягты. Аның туганнары юк, үзенең нәсел-нәсәбен дә белми.

— Һөнәр дип... Гриша саткандыр. Мин зонадан кайткан кеше.

— Безгә бит столяр, балта остасы, һич югында әзер нәрсәләрне машинада таратып йөрүче кирәк,— дип дәвам итте сүзен Сәет, үз ялганын елмаюы белән хуплап.

— Төрмәдә өйрәттеләр инде аз-маз, төрлесеннән,— диде Сәнгат, киная белән. Гриша бит аңа мәсьәләне башкачарак аңлаткан, «Паханга оста сунарчылар кирәк», дигән иде.

— Әхмәдиша абый өенең аскы катында мебель ясый торган мәйданыбыз бар. Шкафлар, урындыклар, өстәлләр ясыйбыз. Риза булсаң, син дә шунда эшләрсең.

— Соң, согласен инде. Минем торыр урыным да, эшем дә юк.

Хуҗа җавап катмыйча, дивар буендагы шкафны ачты, шуннан бер уенчык алып Сәнгаткә сузды.

— Шуны кысып кара әле. Көч үлчәгече бу...

— Вата яздың! — диде Сәет, егетнең кулларындагы көчкә вәйран калып.

— Самбо алымнарын беләсеңме?

— Күзаллавым бар. Сугыша беләм. Төрмәдә шуннан башка исән калып булмый,— диде егет самими беркатлылык белән.

— Хәзер аска, спортзалга төшәбез.

Әхмәдиша бабайның тыштан кечкенә генә күренгән ике катлы өенең астында нәрсә генә юк икән! Затлы агачтан ясалган төрледән-төрле мебель төялгән складны, ике чит ил машинасы торган гаражны узып, спорт белән шөгыльләнү өчен бөтен шартлар тудырылган, заманча җиһазлар белән бизәлгән, көндезге ут лампалары гөжләп торган олы бүлмәгә алып керде хуҗа Сәнгатне. Аскы сәдәфе генә төймәләнергә җайланган пиджәген бик иркәләп, яратып чөйгә элеп куйды.

«Безнең әби әйтмешли, рәешкә, чакырулы кунакка барганда гына кия торган костюмы бугай, бигрәк саклый»,— дип уйлап куйды кием-салымның затлысын күрмәгән, шуңар да аны сакларга өйрәнмәгән Сәнгат. Зиндан киеменә, дуңгыз төсле пычракта аунасаң да, берни булмый.

Кинәт хуҗа аның ягына борылды. Йөзе усал, тартылган, күзләрендә җылылык нурының әсәре дә калмаган иде. Тавышына хәтле үзгәргән.

— Хәзер, егетем, саклан, мин сиңа һөҗүм итәм, йоклап торсаң, тукмап ташлыйм. Нәрсәгә сәләтле булуыңны күрсәт әле. Кулыңа балта тотып тырырга ярыймы икән,— дип, күлмәк җиңнәрен өскә күтәрә-күтәрә Сәнгатнең өстенә үк килә башлады.

Соң чиккәчә гаҗәпләнгән, әмма көтелмәгән хәлләргә өйрәнгән егет, боксер торышын кабул итеп, сул кулы белән йөзен каплады. Сәетнең йомры йодрыгы аның беләгенә эләгергә тиеш. Шунда көтелмәгән хәл булды. Сәет уң кулы белән кизәнеп, яшен тизлеге белән читкә сикерде һәм сул йодрыгы белән Сәнгатнең ияк астына тондырды. Оруы бик үк катыдан булмаса да, егет чайкалып алды, күз алдыннан төрмә тәрәзәсеннән вакыт-вакыт күренеп алган йолдызлар үтте. Ияге авыртудан бигрәк, гарьләнүдән ыңгырашып куйды. Үзен-үзе онытып, ирексездән сүгенеп җибәрде.

— Син нәрсә, падло! Мине кыйнар өчен чакырдыңмы? Урка. Күргәнбез синең ише ак күлмәкле кәттәләрне...

Кызу, яшь кан егетнең башына, миенә менде. Күзләренә кызыл төште. «Ни өчен дип әле чәченә кырау төшкән Паханнан кыйнатып торсын ди, тузга язмаганны. Карт арысланның инде тешләре коелырга вакыт җиткән. Эшкә алам, дип шомартып, йодрыгын сынап карарга булганмы? Тапкан бушлай ияк. Соңгы ике елда аңа зонада бармак белән кагылучы булмады. Чөнки үзен куя белде. Эксперимент өчен башка кол эзлә»,— дип, эре тешләрен явыз итеп ырҗайтты Сәнгат.

— Дүндерәм мин сине хәзер. Иманыңны укытам. Үпкәләштән булмасын! Сакчыларың бардыр әле, әйдә чакыр, аларына да өлеш чыгарырмын.

Егет бар җегәрен вә тиле дәрманын, ятим үскән балаларга гына хас үҗәтлеген, нөктәле үпкәсен уң кулына төйнәп алга ыргылды. Нияте— көндәшенең иягенә, битенә, башына тондыру иде. Сәет Сакманов, кулларын өскә күтәреп, аркылыга куеп, кагыйдә кушканча капланып өлгергән иде. Беләккә сугып, кешене үтереп булмый.

Егет күз ачып йомган арада ниятен үзгәртеп, чакма ташны ватардай нык йодрыгын Паханның эченә, бөер тирәсенә батырды. Сугуы шулкадәр көчле иде, Сәнгаткә хәтта кулы корсакны тишеп, эчәкләргә үткәндәй тоелды. Сөяк эләктергән бәхетле эттәй читкә сикерде.

Сәет, ике кулын аска салындырып, бөгелеп төште. Менә-менә ул шап итеп идәнгә аварга тиеш иде.

— Нәрсә, падло, кәнкәясеңме?

Чын-чынлап шатланырга да өлгермәгән Сәнгат ияге астына бергә укмашкан ике йодрыкның килеп сылануын тойды. Астан өскә коточкыч кодрәт белән күтәрелгән дәрман аны өч метрга читкә алып атты.

Егет берничә дәкыйкә вакытка аңын да югалтып алды. Бар җегәрен туплап, зәһәрен уятып, үз-үзеңне саклау көчен хәрәкәткә китереп, мәче елдамлыгы, эт чираклыгы белән сикереп торып, Сәеткә ташланды. Мәгәр дошманына якынлаша алмады, күзләренә, борын тикшекләренә, авызына томан төсле сыекча тулды. Күзе күрмәс, борыны суламас булды. Ул, ихтыярсыздан, битен юан бармаклы куллары белән каплап, аягында көчкә басып калды.

Әллә каян болытлар артыннан ирләр тавышы килде:

— Ал кулыңны битеңнән!

Бәйгене оттырганын, дошманының аңардан көчле булмаса да, хәйләкәррәк, тәҗрибәлерәк икәнен аңлады егет. Төрмә һәм караклар кануны буенча, ул Сәеткә сүзсез буйсынырга, аңа хезмәт итәргә тиеш.

Егетнең битенә башта бер, аннары башка бер сыекчаны сиптерде Пахан. Айнытып, терелтеп җибәрде. Саф һаваның тәмен тойды Сәнгат. Күзләреннән язгы каен суыдай бәреп яткан яшь туктады.

Ә хуҗага әллә Сәнгат бар бүлмәдә, әллә юк, аңа илтифат әсәре дә күрсәтмичә, матур пинжәген киеп, бармаклары белән көзге алдында чәчләрен тәртипкә салып тора.

— Молодчина, егет. Милиция туктатмаса, еракка китәрсең. Бөерсез калдыра яздың.

— Мин аларда булдым инде. Үземнекен бирдем.

— Киттек өскә. Эшкә алам мин сине. Минем сакта булырсың. Синдә тиле көч күп, анысы яхшы. Әмма сугышу техникасы сыек. Мылтыктан, пистолеттан ата, пычак ыргыта беләсеңме?

— Тәҗрибәм бар беркадәр,— диде акрын гына, бүгенге хурлыклы тукмалудан соң үз-үзенә ышанычын югалта барган Сәнгат.

— Аз-маз белән эш кырып булмый. Атнасына өч көн тренер белән самбо, бокс һәм башка алымнарга өйрәнерсең! Ату тәҗрибәләрен хәрби училищеда алырсың.

Сәет кешесен, урынын, вакытын әйтте. Кош теле хәтле генә кәгазь тоттырды кулына. Стенадагы төймәгә басты. Ишек тын гына ачылды. Әхмәдиша картның әүвәл ике кулы, аннан гәүдәсе керде.

— Тыңлыйм, Хуҗам.
— Орбакайте биредәме?
— Әйе, үз бүлмәсендә эшләп утыра Арбакайта ханым.
— Керсен әле!
— Менә бу егетне цехка эшкә алырбыз,— диде, каршы әйтмәслек фәрман тоны белән, яссы, чәлпәк битле, әмма бик заманча киенгән, озын буйлы, күтәренке чәчле хатынга.— Столяр итеп. Хезмәт хакын билгеләгез, хезмәт кенәгәсен ачып җибәрегез. Пенсиягә чыкканда кирәк булыр.
— Минем янга керерсез,— дип, хисапчы ханым чыгып та китте.
Сәнгат берни аңламыйча, уклау йоткан кешедәй, олы өстәл кырында басып тора бирде. Ничек аңларга бу кешене, мылтыктан атарга өйрәтәм, ди, ә үзе балта остасы итеп эшкә ала. Берни майтармаган килеш, күпмедер хезмәт хакы билгели.
— Хәзер сүзнең җитдие булыр, егетем. Миңа эшкә кергән кеше (еш кына ул ялланган сүзен куллана иде) — тулысы белән минем мөлкәт, ягъни миңа сүзсез буйсынган адәм. Бастырып әйтәм. Соңыннан, вакытында кисәтмәдегез дип, кәҗә кычкыртып йөрерлек булмасын. Мин кушканны «баш өсте», дип үтисе. Монысы — беренче шарт. Авызны җиде кат йозакта тоту — икенче таләп. Берсен генә үтәмәү дә җылы булмаган саубуллашуга алып киләчәк. Безнең оешманың ни, нәрсә белән шөгыльләнүе сине картайтырга тиеш түгел. Артыгын белергә тырышу — каядыр, әйтик, мәктәптә укыганда, хатын-кыз белән аралашканда кирәкле шәйдер. Тик бу очракта...
Сәет озын гына тукталыш ясады, каршында басып торган ифрат тыгыз гәүдәле, тар маңгайлы егеткә күз салды да, тавышын ятрылаш киметеп өстәде,— гомерне озайтмый!
— Мин риза барысына да. Күпме түлисез?
— Илдәге уртача хезмәт хакыннан ун тапкыр артыграк алырсың. Шуның өстенә, һәртөрле чыгымнар, машина расходлары бездән булыр.
— Мин риза,— дип кабатлады егет.
— Синең әле сынау срогы узасың, машина йөртү, ату сәләтеңне күрсәтәсең бар.
«Гриша кирәкле егет алып килгән. Бу — ашатсаң, эчертсәң, күн курткага төрсәң, маңкорт төсле, теләсә кемне чәнчеп, атып үтерергә мөмкин. Аңардан коммунистлар хыялланган, җәмгыять файдасына бушлай эшли торган, иҗтимагый продукт тәрбияләп булмас! Җанын суырып алганнар. Беренче сыйныфлы киллер чыгачак егеттән».
— Төрмәдә нинди иде кушаматың? — дигән сорау Сәнгатне айнытып, сискәндереп җибәрде.
— Мине гел күчереп йөрттеләр. Һәркайсында яңача атадылар.
— Шулай да?
— Ну, саескан, алаколак, тимерче, тармаңгай һ. б. Күп булды. Кушаматсыз кеше юк анда.
— Шөреп яисә Шуруп саморез,— дип атаучы булмадымы?
— Булды бугай.
Әлеге кличкасы хакында, салып утырганда, Гришага сер итеп ычкындырган иде. Саткан. Сыртка салган иске дус. Белеп тору кирәк булыр. Утырган бер җиренә үзе артыннан коерыгы төсле ияреп килгән кушаматын онытырга теләгән иде. Юк шул, үткән белән араны җинел генә өзеп булмый, ахры, балта белән кисеп төшерә торган ботак кына түгел икән кеше хәтере.
Сәет нәтиҗә ясады:
— Синең бүгеннән исемең дә, фамилияң дә Шөреп булыр.
Тәрбияви, төрмәдә әйткәнчә, секс-сәгать әле тәмамланмаган икән.
— Төшерергә яратасың. Анысы бер хәл. Анысын барыбыз да булдыра. Ачы күбрәк керсә, холкың бозыла, теләсә кемгә бәйләнә торган гадәтең бар икән. Күкерттәй кабынасың. Яман кешеләр сизсә, үзеңә каршы барулары ихтимал. Саклангanны гына саклармын, дигән ходай тәгалә.

Шөрепнең үзен аклап, аңлатып карарга нияте бар иде дә, Сәет аңа мондый мөмкинлек калдырмады.

— Бәхәсләшә башласаң, минем сүзләрнең дөреслеген генә раслыйсың. Сине һәр тарафтан өйрәнмичә, тикшермичә торып, бирегә чакырмас идем. Дустың Гриша саткан дип, аңа үпкә тотсаң, хаклы булмассың. Минем кешеләр син укыган мәктәптә булдылар. Әбиеңнең танышлары белән сөйләштеләр. Ни өчен сине эшкә алырга булдык, дип сорыйсың килеп телең кычытамы?

— Әйе.

— Холкың авыр, үчле кеше булсаң да, синең берәүне дә сатканың юк. Биш ел гомереңне заяга алган «юеш эш»не тикшерү барышында берничә кешене атаган булсаң, яисә үзеңә карата хакимияттән гуманлы булуны сорасаң, яшьлегенә басым ясап, гафу үтенсәң, сиңа срокны азайткан булырлар иде. Үзеңне ирләрчә тоткансың. Үзеңә ничек кенә кыен булмасын, әйткән сүзеңдә торасың икән. Сиңа тагын бер киңәш, таләп: караклык гадәтләреңне, кулыңның осталыгы белән уйнавыңны, квартира йозагын оста ачуың белән шаккатыруыңны ташла! «Игелек» андый кешеләрне яратмый. Без — җитди оешма. Колагыңа киртләп куй!

Шөрепнең исенә келт итеп төште соңгы көннәрдә булган бер вакыйга. Шулай ук беркайда да эшләми, үти-сүти йөреп, очраклы төшемнәр исәбенә көнен күрүче Альберт исемле танышы очрады. Мәктәп бусагасын бер елга соңрак таптаган иде. Буфетка кереп тамак күнелен күрделәр. Кәеф-сихәтләре бермә-бер күтәрелде. Аерылышасылары килмәү аңлашылса булыр. Беренче очраган трамвайга төялделәр. Тимер әрҗә шактый тулы иде. Халык каядыр ашыга.

— Бер кулына сумка тоткан күзлекле абзыйны күрәсеңме? — диде Альберт.

— Соң, шуннан...

— Синең белән бик тырышып исәнләште. Ә син аңа ноль вниманҗә.

— Шулай тоелгандыр салган баштан.

— Юк, чынлап әйтәм.

— Кешеләргә хәтерем яхшы минем. Күргәнем юк.

— Кызык егет син, Сәнгатик, адәм баласы, олы башын кече итеп, исәнләшә, ә син — әллә кем булып, борын чөерәсең...— диде киная белән Альберт.

— Бәлки, ерак туганымдыр минем,— диде Сәнгат, уенны кабул итеп, тавышына уйчанлык төсмере биреп.— Тикшереп карасы булыр. Кошелегында визиткасы, йә берәр таныклыгы булмый калмас. Син абзыйның уң ягына бас, бик каты итеп бәрел һәм озак кына гафу үтен, тукталышта урта ишектән сикер...

Чыннан да, күзлекле абзыйның ясалма күн тышлы акча янчегендә егетләргә бер-ике ял итәрлек акчасы һәм пенсия кенәгәсе табылды. Чырайга яшь күренсә дә, Сәнгатнең «танышы» өченче ел лаеклы ялда икән. Акчасын бушатып, кәгазьләрен чүплек чиләгенә ыргыттылар. Ул вакыйга турында Шөреп оныткан иде инде.

Альберт та, Гриша шикелле, Паханның агенты, шымчысы микәнни? Читлек эчендә яшәве, ул алтыннан үрелгән булса да, кызыгырлык булмаячак. Күңеленә шөбһә, шикләнү еланы үтте. Бу дөньяда беркемгә дә ышанма, дип өйрәткән иде аны бер камерада утырган Шәкүр карак онысы (һәрхәлдә, ул үзен шулай дип тәкъдим иткән иде). Өстенә баскан.

Сәетнең исә кәкре атып, туры тидерүе генә иде. Шөреп күңеленә төенләп куйды: Пахан хәйләкәр төлке, аның белән сак булырга, итәкне җыеп йөрергә, иң яхшы дустыңа да сереңне ачмаска... Ялгыз эш иткәннәр отачак.

— Минем вакыт чыкты,— диде Сәет.— Сине Гриша көтә.

— Минем яшәргә урыным юк,— диде Шөреп, кыюлыгына шаккатып. «Минем ни эшем бар. Эшкә яллаганга рәхмәт әйт»,— диярга тиеш иде хуҗа. Шул җавап көтелгән дә иде.

— Шулаймыни? Нишләп эндәшми торасың, еламаган бала авызына имчәк каптыру заманасы үтте.

Яхшы итеп кырынган, затлы хушбуй сөрткән чыраена гаҗәпләнү төсмере чыгарып сораган булды Сәет.

Шунда ул Шөрепнең күңеленә мәңгегә сеңеп калган бер адым ясады. Хәрбиләрчә төгәл адымнар белән атлап, уң яктагы шкафны ачты. Кадакта эленеп торган ачкычны алды да Шөрепкә ташлады.

— Менә сиңа торып торырга бер бүлмәле фатир. Адресы биркада уелган. Бер елга контракт белән. Яхшы эшләп китсәң, үзеңнеке булыр. Өйләнсәң, зуррагын бирербез. Машина йөртә беләм, дигән идең.

— Анысын булдырам. Тик минем правам юк.

Хуҗа янәдән шул ук агач шкаф янына китте. Бер тартмадан күн тышлы документ алып, Шөрепкә тоттырды.

— Сиңа йөреп торырга. Үзеңә охшаган. Тик сак бул. Киләсе атнада үз исемеңә язып бирерләр. Кил әле монда.

Аптырап, югалып калган Шөрепнең кыска күлмәк җиңеннән тотып, тәрәзә янына алып килде.

— Яшел «Жигули»не күрәсеңме? Алтынчы марка. Шуның белән йөреп торырсың! Аннан күз күрер. Хәзергә Гриша белән икегезгә бер задание. Ул — белә!

Менә шулай итеп, Шөреп «Игелек» әгъзасы булып китте.

## 10

Сәнгат-Шөрепнең Сәет күңелендә каршылыклы тәэсир калдыруы табигый иде.

Сәнгат дигән сәер, сирәк очрый һәм хуҗасының табигатенә якын да килми торган исемне аны тәрбияләп, багып үстергән әбисе куша. Әти-әнисен ул белми, хәтерләми. Әбисе Зәмзәмиянең бәян итүенә караганда, аны дөньяга китереп ташлаучылар бер-берсенә торырлык пар булганнар. Әнисе бер яшьлек баласын иренә һәм каенанасына ташлап, бер ир кисәгенә ияреп, Урта Азиягә чыгып олаккан. Бишме-алтымы бала табып, һаман да шунда яшәп ята, ди. Нибары ике хаты килгән. Соңгысында, баласын ятим иткән өчен гафу үтенгән һәм «Ирем бик көнче, минс борчымагыз, зинһар, оныта күрегез», — дип тә өстәгән. Табигый ки, аның үтенече кабул ителгән.

Шөрепнең әтисе — Зәмзәмия апаның бердәнбер улы, бик тәкәббер кеше була һәм хатыны адәм хуры итеп, үзен ташлап китүне күтәрә алмыйча, йөрәк ярсуын хәмер ярдәмендә сүндерү юлын сайлый. Булган мал-мөлкәтен сатып эчеп бетергәч, тулай торактагы кечкенә гаиләләр өчен төзелгән бүлмәсен дә ычкындырып, сал куучылар бригадасына языла, шунда гаип була. Зәмзәмия апа улы турында хәбәр-белешмә килеп чыкмасмы дип, төрле оешмаларга язып карася да, эченә җылы керерлек хәбәр ала алмый.

Улының бүлмәсен алган һәм аннан куып чыгарылган адәмнәр, Зәмзәмия ападан акча таләп итеп, теңкәсенә тияләр. Рәте, артык сәмәне булса, төп башына утыртылган ярлы-ябагага улының бурычын түләр иде дә, үзе дә гомере буенча көчкә очын-очка ялгап, тормыш көймәсенең коерыгына гына эләгеп барды.

Ире — хәрби офицер — чем кара күзле, кара чәчле, төз гәүдәле музыкант хатынын ил буйлап үзе белән йөртә дә, сугыш башлангач, ике яшьлек улы белән чибәркәен Казанда, ләхет кебек тар коммуналкада калдырып, фронтка китә. Өч айдан аның батырларча һәлак булуы турында кара кәгазь килә.

Көйле, моңлы җаны, назлау, иркәләү, сөю өчен яратылган тәне белән Зәмзәмия ханым малае белән ундүрт метрлы бүлмәдә гомерен уздыра. Затлы гәүдәгә кызыгучы комсыз ирләр шактый бөтерелә

янында. Тәкъдимнәр күп була. Мәгәр көйче хатын әфисәрдән башка кешене якын җибәрми. Кырында чәбәләнгәннәре арасында рәтле-башлысы күренми. Берсе — исерекбаш булса, икенчесе — алименттан качып йөрүче. Өченчесе — хатын-кыз исәбенә яшәү хастына керешкәне, ярлылыкны күреп, койрыкны сыртка салып, үкчәне күрсәтү ягын карады.

Зәмзәмия ханым, ул нәселгә бөтенләй кул селтәп, җенси дәртен тезгенгә утыртып, бөтен игътибарын, яшьлеген бердәнбер улына бирде. Малай үзе турында югары фикердә үсте. Батыр сугышчы һәм музыкант малае булуын бер мизгелгә дә исеннән чыгармады. Төзүче-инженерлар институтын тәмамлап, проектлар ясаучы оешмада эшли башлады. Өйләнә алмый интекте. Кызлар күп. Берсен дә ошатмый. Инде менә Нурания белән дә берничә ел гына яшәп кала алды. Зәмзәмия апаның күз нурын, йөрәк парәсен ташлады да китте, имансыз. Аерылуларының сәбәбен ана белми калды. Улы хатынның йөрәгенә юл таба алмадымы, үзе турында гына уйлап, араларына салкынлык бозы төшүгә үзе гаепле булдымы, әллә Нураниясе нурсыз, җилбәзәк бер нәмәстәкәй булып чыктымы?

Аңа исә кояшы сүнеп барган көнендә яшь бала белән, тол тормышны тагын бер үтәргә насыйп булган икән. Заманалар үзгәргән, бала тәрбияләү авырлашкан, гаиләләр тормышына урам йогынтысы дигән, әкиятләрдәге аждаһадай явыз төшенчә бәреп кергән. Бу мохит тәртипле, ата-ана белән үскән баланы да үз кануннарына буйсындыра, юлдан яздыра ала икән.

Үз малаен югалткач, бик нык бирешкән Зәмзәмия апаның дөньяга карашы искергән, үзе төсле үк картайган иде. «Миһербанлы бул, итагатьле бул, кешенекенә кагылма, анда барма, моны алма»,— дип кабатлап торып кына күп нәрсәгә өйрәтеп булмый икән баланы. Яшь чагында Сәнгат әтисен, әнисен таптырып тавыш чыгарса, туктаусыз еласа, соңрак алар, баланың шәхси дошманнарына әверелделәр. Өйдә булган рәсемнәрен, хатларын ертып бетерде.

Әбисе белән уртак тел таба алмаган Сәнгат урамда үз урынын, дәрәҗәсен тизрәк тапты. Үсмер бу бозык дөньяда бердәнбер таянычы үз йодрыгы икәнне аңлый. Баш миеннән бигрәк, мускулларын үстерүгә, ныгытуга көчен бирә.

Уңдүрт яшендә милиция вәкилләре белән «көрешә» башлый. Исәпкә алына. Урта мәктәпне тәмамлап, бер ел заводта селкенеп йөргәннән соң, ике төркем арасындагы сугышта катнашып, кулга алына һәм, бер егетне пычак белән чәнчеп үтерүдә гаепләнеп, биш елга ерак юлга озатыла.

Әбисенең каберен дә эзләп таба алмый Сәнгат аннан кайткач. Ул яшәгән ике катлы агач өйне сүтеп, яңа, олы йорт салып куйганнар. Элеккеге таныш-белешләренең күбесе юкка чыккан. Һөнәрләрен алыштырып, өйләнешеп, төрле якларга күченеп беткәннәр. Бердәнбер якын җан иясе — әнисенең адресын эзләп караса да, беренчесенең бәхетенәдер инде, таба алмады. Әнисен изге ният белән, ихластан эзләгәндер, дип уйларга нигез юк иде.

Тормышының иң авыр, күчеш чорын кичергәндә, аны Гриша эзләп тапты, дусларча ярдәм кулын сузды, яхшы кешеләр белән таныштырды. Калганы үзеңнән тора, дип уйлаган иде дә Шөреп, рәхәт хәятнең шырпылары бар икән.

Җиңел машина утыргычына артын урнаштырып, кесәсенә санаусыз диярлек, хәрам акчалар керә башлагач, төрмәнең кысынкы тормышыннан гарык булган Шөреп рәхәткә чыга, тапканын тәкәллефсез генә җилгә очыра башлый. Әйткәнне кабул итми, вакытын ресторан-кабакларда уздыра, теләсә кемне фатирына алып кайта, тезгенсез теләк-ниятләренә ирек бирә.

Мәгәр аңа күбрәк өлкән яшьтәге, тотылган, үзләре муенга сарыла торган уртакул хатыннар белән эш итәргә туры килә. Күбесе кулында баласы калган ирсез кәнтәйләр булып, максатлары — тагын бер кияүгә

чыгып, бәхет сынап карау, һич югында ир-ат акчасына типтереп-яшәп калу.

Шөрепнең юлдан язып баруы Сәетне борчый. Ул аны азгын-тузгын тормыш өчен түгел, башка максатларга әзерли. Аның кыласы батырлыклары әле алда. Билгеле бер карарга килеп ул киңәш-табышка Мисхәт-Мишаны чакыра.

— Олы дәүләт сере булса да, әйт әле? Йөри торган кызың бармы?

— Әйе, шеф. Энҗе-мәрҗән кебек балкып торган, ярәшкән Әлфиям бар.

— Матур сүзләр яратканыңны беләм. Дөресен әйт.

— Рөхсәт вә ярдәм улса, тиздән башлы-күзле улырга исәп.

— Кәләшеңнең дус-ишләре, иптәшләре бармы?

— Тугыз катлы студентлар торагы шыгрым тулы. Егетләр юк диярлек. Барысы да безнеке.

— Син Шөреп кушаматлы, Сәнгат дигән егетне беләсеңме?

— Әхмәдиша абзый йортында бер-ике күрдем. Якыннан танышканым юк.

— Аның белән аралашып алу кирәк булыр сиңа. Кабанның аргы ягындагы татар урамында туып-үскән егет. Ышаныч синдә!

Хуҗаның соңгы сүзе Мисхәтнең күңелен май канаты белән сыпырып алгандай булды.

— Мин егет белән танышып калырга гына тиеш түгелдер, дип уйлыйм.

— Аны рәтлерәк кыз белән таныштырырга, сүз байлыклары сүгенү, гамәлләре шәрап чөмерү һәм карават шыгырдату белән генә чикләнмәгән җәмгыятькә, дөресе, яхшы компаниягә алып керергә иде. Бәлки, берәрсе үзен охшатып куяр. Өйләнергә дә вакыт. Кем белә... Юкса егет тәмам югалып бара.

Мисхәт чынында Шөреп кушаматлы ходабәндә турында күп белә. Аның каты-коты холкыннан, кемнәр белән төннәрен кыскартуыннан да хәбәрдар иде. Аны талибәләр мохитенә алып кереп, кем беләндер таныштыруга атлыгып тормый. Ул тирәлеккә үзе дә илләм авырлык белән эләкте. Исереп, бәйләнеп, сугышып хур итәр. Теленә тилчән үскере нәрсә, абруен үстерәсе килеп, мактанып ташлады Сәет Яруллович каршында. Ни үтмәс пычагыма картаны ачып салырга иде! Бит әле Әлфиясе дә, ЗАГСка киттек дип, муенына Мисхәт исемле элмәкне эләргә ашкынып тормый. «Яшь гомерләр ике килми, беликче кадерләрен»,— дип кенә җибәрә аның тәкъдименә. Хәер, үзе юк дип тә әйтми, иреңенә ике бармагын гына куя.

Сәет Мисхәтнең йөзе өшегән чөгендер кебек тартышуга игътибар итмичә, соравын, үтенечен кабатлады. Шеф кушкач, кая барасың, үтәргә туры килә. Задание бирми башласа... Башыңны кая тыгарсың. Тутый кош түгел үзе дә.

Мисхәт-Мишаның үзен дә эшкә алганда шактый сынады Пахан. Һәр яңа кешене йодрык белән сыйламаса да, Сәет аны һәрьяклап тикшерә, сөйләштерә, шуннан соң гына нидер тәкъдим итә. Аннан соң да күз уңыннан төшерми. Хуҗаның талканы коры.

Әгәренки берәрсе элек хезмәт иткән хуҗасын, житәкчесен әрләсә, яманласа, пычрак сүз әйтсә, андый зат белән арасын мәңгелеккә өзә.

Аның командасына эләгү — сират күперен чыгудан ким түгел, диләр. Тормыш тәҗрибәң булу өстенә, сасы су тәме белән дары исен бутамаска тиешсең. Үзе һәм егетләре өчен, ул уйлап тапмаган булса да, кат-кат сыналган тәртип кертте. Эш белән шәхси тормышны бутамаска. Һәрхәлдә, алар бер-берсенә зыян китермәсен!

Кул астында эшләүчеләрне ул күп нәрсәгә — корал белән эш итүгә, бокс, самбо алымнарына, тавышны куя, үзгәртә белүгә, кешеләр белән мөгамәлә оештыру тәртипләренә өйрәтте. Хезмәттәшләрендә «дөрес яшибез, үзебезнекен ашыйбыз», дигән ышаныч уятырга, рухи таяныч тудырырга тырышты.

Берничә егете бергә туры килсә, сүзне гадәти шаяртудан башлый:

— Җанкөекләрем! Шәриктәшләрем минем! Албастыларым минем! Без — замана таләбе, вакыт чакыруы белән туган балалар! Без — дәвернең уяну авазы. Җәмгыятьне тазартуга, чистартуга үзеннән өлеш кертүчеләр. Без — тычканнар баскан өйне тазартучы санитар мәчеләр.

Шуннан соң йөзенә уйчанлык, хәтта сагыш җиле сирпеп, җитди элдереп китә:

— Без югары әхлак кешеләре булырга, төпле, акыллы, тәртипле булырга тиешбез. Шалапайлык, кылану — безгә батмый.

Аның әхлак, инсафлык турында сөйләнүләре мәхшәр алдыннан тоткан вәгазь кебек яңгыраса да, Сәетнең бу «ачышлары» кармагына эләгүче беркатлы егетләр барыбер табыла торды. Мондый «аңлатмалар» Сәетнең үзе өчен, Ижаудан мылтык алып кайтып сатуын, коры сөтне читкә озатуын, гашиш белән шаяруын, юлына аркылы төшкәннәрне алып ташлавын әхлакый аклау өчен кирәк иде. Авыр, низаглы хәлләрне дә ул шул алым белән көчәнешсез, талчыгусыз уздыра белде.

Аннан килеп, Сәет татарның үз милли мафиясе булырга тиеш дигән иманда яшәде. Мафияле булу, аның уенча, балигълыкның бер күрсәткече.

Университетның тарих факультетын тәмамлап, үзенә киоск алу, мөстәкыйль тормыш юлына басу турында хыялланган романтик рухлы Мисхәт Сәеткә чын күңелдән ышанды, ихластан хезмәт итте.

## 11

Нарасый баладай иркәләнеп, Зөлфия атлас юрган астыннан Сәетнең кулын эзләп тапты. Озынча бармакларыннан җылы, мәрхәмәтле нур бөркелде. Әйтерсең лә баш очындагы электр утын шәмдәлләр алыштырды. Алар арасындагы илаһи якынлыкны сүндерерлек көч юк иде кебек бу гөнаһлы җиһанда.

Ир, нык муенга утыртылган башын борып, ханымның яшь әрекмән яфрагыдай үтәкүренмәле колак очларыннан үбеп алды, ак муенына төште.

— Әллә матурыма берәр нәрсә кирәкме?— дигән булды ир зат. Үзе тавышын ишетмәде. Анасы сөтенең муллыгы рәхәтеннән тончыккан бала кебек иде бу мизгелдә.

— Тик кенә ята алмыйсың инде син,— диде хатын олы, тыгыз, һәрвакытта кайнар тәнгә сарылып. Сүзләре юеш иреннәрен ерып чыга алмагандай тоелса да, ханым аны ишеткән, аңлаган икән. Фәлән йөзенче катка җавабы да әзер.

Сәет сөеклесен янына анадан тума килеш ятарга өйрәтте. Зөлфиягә Исхак абзый белән Рәмзия ханым бүләк иткән табигать күлмәгенә тиңдәш, көндәш булырдай кием-салымны дөньяның иң гаярь остасы да тегә алмас иде. Һәрхәлдә, Сәет шундый фикердә торды, тәненә ихтыяҗ булмаганда да, киң уч төбенә сыярлык кечтеки чүпрәкчек кияргә дә рөхсәт итмәде. Яңа суырткан бал, нәзәкатьле болын чәчәкләре исе аңкып, кытыклап торган, наз тулы гәүдәне куенында яткыруның, шул нигъмәтнең синеке икәнне тоеп ятуның бәхет, саба җиле сөенече, шашкынлы шатлык икәнен Сәет үзе генә белә. Лолита кебек яшь, Наташа Ростова кебек саф, Нәфисәдәй тыгыз тәнле иде аның сөйгәне. Керфекләре тырпайган. Артык майның әсәре дә юк тәнендә.

Дөрес, авыл тәрбиясе алган Зөлфия, кәбестә төсле кат-кат киенеп яткан әнисен күз алдына китереп, табигать тудырган халәттә йоклауга баштарак карышкан булды. Ихтыяры өченче кичтә сынды. Үзенә дә охшады. Яраткан кешең белән шулай гына янәшә ятып була дигән фикергә килде.

Зөлфиянең ир уртасы каршында тормышка әле аяк баскан, берни күрмәгән-белмәгән сабый рәвешендә күренәсе килмәде.

— Мәхәббәткә багышланган китаплар күп укыдым. Берсе дә безнекенә охшамаган,— диде Зөлфия.

— Соң аларны язган адәм үзе кемнедер яраткан микән? Яшь буынны тәрбияләү турында кемнәр китап сырлаган? Крупская, Макаренко кебек үз балалары булмаган кешеләр. Кофе чүбендә үле балык тотып ятканнар.

— Теория, гамәлдән үсеп чыкмаганда, көчлерәк була торгандыр, бәлки?

— Җилдән туган балаларны күз алдында тотасыңмы? Син ул әкияткә ышанма. Җил дигәне — җилбәзәк ир булыр. Христиәннәрнең изге Мариясе белән дә шундыйрак хәл булгандыр әле. Мифлар соңрак туа.

— Юк ла,— диде Зөлфия, ак, нәфис кулын балкытып юрган өстенә чыгарып.

— Жюль Верн бабаң әнә бер тапкыр да океанны күрмәгән, диләр. Дөрес булса, шулай да су асты дөньясы турында ничаклы матур, ышандырырлык итеп язган!

Сәет Зөлфияне тыңлаган булып ятты да көлеп җибәрде.

— Нәрсәсе көлке, аңламадым,— диде хатын, терсәкләренә таянып, башын калкыта төшеп.

— Бер мәзәк искә төште лә!

— Йәле. Калдырыйк дингез могҗизаларын.

— Унбиш яшьлек кыз белән җенси мөнәсәбәтләр турында сөйләшергә ярыймы?— дип сорыйлар икән әрмән радиосында.

— Бу өлкәдә наданлыгыңны бетерәсең килсә, киңәш итәбез,— дип җавап кайтаралар.

— Бу миңа төрттерүеңме, Сәет?

— Юк ла! Хәтергә төште әле менә.

— Көлмә,— диде ханым, тавышына житдилек төсмере салырга тырышып.— Минем дә аз-маз тормыш тәҗрибәм бар. Мактануым түгел. Сизгәнсеңдер, мин бөтенләй үк гөнаһсыз бала түгел идем. Азып-тузып, теләсә кем белән ястык бүлешмәдем. Бер хатам булды. Кияүгә чыгып кала яздым. Иманым коткарды. Кирәк дисәң, сөйләп бирермен, артыгын сорашмасаң, рәхмәтле булырмын. Иске яраны ачып, тоз сибеп утырасы килми.

Сәет, нарасыена сокланып бетә алмыйча, «мондый намуслы сабыйлар да бар икән әле дөньяда», дип тик тыңлап ятты. Кирәкми аның үткәне. Бүген ул аның куенында, аныкы, мәңгегә аныкы булачак! Монголиянең вак комын ашавы, Казан пычрагын җыюы, элеккеге хатыннарының аңламавы өчен җибәрде аңа Тәңре Зөлфияне. Алар гел бергә булачаклар, ул теге дөньяга иртәрәк китсә, ярты байлыгын биреп, үзләрен янәшә күмәргә кушар, теге дөньяда сөеклесен каршы алыр, шунда инде җаннары мәңге аерылмас. Бәлки, әле балалары да булыр. Тәҗрибәсе бар, улларын, кызларын тәрбияли, дөрес юлга бастыра белер иде. Кызын балалар табибына укытыр, дөньяда шуңардан да игелекле белгечлек юк. Улы үз халкының телен йә тарихын өйрәнер, киләчәккә хезмәт итәр, боерган булса.

Шул уйларыннан күңеленең йомшый, дөньяга, гаделсезлеккә карата булган усаллыгы кими баруын сизде Сәет.

Иренең эндәшмичә ятуын Зөлфия үзенчә юрады. Әллә түкми-чәчми, бәйнә-бәйнә барысын да сөйләп бирергәме? Искитмәле хәл түгел. Үзләрендә танцыда танышты Мөнир белән. Прораб булып эшли икән. Йөри торгач, өйләнешергә булдылар. Язылышырга барырга бер атна калгач, баласын күтәреп хатыны килде: «Сенелем, ятимнәр каргышын үзеңә алма, бәхетле була алмассың»,— диде. Дөрес, алар инде күптәннән рәсми аерылышкан булсалар да, Зөлфия Мөнирдән баш тартты. Тәүчеегет җиләкне тәмләп өлгергән иде. Баналь бер тарих. Оят вә хурлык. Нәрсәсен сөйлисең аның. Гомереңдә бер тапкыр булса да хаталанмый калган хатын-кыз юк җир шарында. Баланы кабул иткән кендекче «кыз» дип шом хәбәр салуга, аның ялгышасы инде тәкъдир кенәгәсенә уелган була. Бу яктан Зөлфия генә искәрмә була алмый ич инде.

Татлы хыял дөньясына чумган Сәетнең, матуры уйлаганча, үпкәләргә уенда да юк иде. Мәгәр Сәет тә, Зөлфия дә үзләрен ни-нәрсә көтәсен, гомергә бер бирелә торган сәгадәт мизгелләрнең озакка бармасыннан хәбәрдар түгел иделәр. Үзе үк хезмәт иткән кара шайтан, явыз мәкер аны хәяттә иң якын, иң газиз кешесеннән аерып алырга, канлы сугыш юлына чыгарырга тиеш иде. Тәкъдир китабына шулай язылган.

Ә хәзер аларга рәхәт иде. Зөлфиянең күз карашлары Сәетнең иреннәре янындагы сызыкларга төште. Ул аларның кайнар, беркадәр тозлырак тәмен сизгәндәй, тойгандай булды.

Нәрсә турында уйлый ул? Янында чалкан яткан кешеңнең, сине өзелеп, тилереп яратуын белгән хәлдә дә, миен, зиһенен биләгән уйхыялларын, күңел күзен ахыргача аңлый алмыйсың. Һәркем — серле сандык. Рухи дөньясы — аның бирәү белән дә бүлешми торган шәхси байлыгы. Кешене талап, чишендереп, көчләп, үтереп була. Әмма аның уен бирәү дә буйсындыра алмый.

Зөлфия дә Сәет турында аз уйланмады бу көннәрдә. Кеше сүзеннән дә колакка үзбәк пахтасы кыстырып кына котылып булмый.

Соңрак авылларына кайтып, килде-китте сүзләр сөйләп йөргән якташы Лилия «үз яшьтәшең белән ачлы-туклы, ертык-пыртык булса да, күгәрченнәр кебек гөрләшеп яшәүгә ни җитә», дип йөрәгенә кан коеп матташты. Соңыннан ачыкланды: көнләшү галәмәте булган икән.

Ни генә сөйләсәләр дә, аны Сәеттән аерып алырлык көч юк иде җир йөзендә. Үзе белән бер яшьтәге кеше аның кадерен белеп, матурлыкны яратуын, поэзияне онытылып укуын бәяләр идеме? Ни өчен гаиләләр оешмас борын таркала? Ызгыш, талаш, бер-береңне кимсетү, рәнҗетү, рухи ярлылыктан бигрәк, матди хәерчелектән килеп чыкмыймы? Әтиәниләре, туган-тумачалары белән яисә тулай ториакның тар бүлмәсендә яшәп, яшьләр бер-берсеннән тиз туялар, җенси тарафтан ачылып китә алмыйча, тәҗрибәсезлек аркасында, тиешле тәрбия алмау нәтиҗәсендә, бер-берсенә тулы ләззәтне бирә алмыйлар. Никахта тапмаган рәхәтне читтән эзли башлыйлар берничә елдан соң.

Ире аны үлепләр сөя. «Гүзәлләр бәйгесендә җиңүчеләр синең белән чагыштырганда мунча пәриләре»,— дип такылдавын белә. Бераз арттыра булыр Сәетҗан. Ә шулай да, сүзләре күңеленә сары май булып ята. Тормыш тәҗрибәсе бай, шактый хатын-кызны кулдан үткәргәне сизелеп, күренеп тора. Зато иң соңгысы, иң яратканы Зөлфия сеңелегез булыр...

Сөйгәненең күңеле булсын өчен генә булса да Сәет сорап куярга тиеш иде:

— Синең булачак ирең тулай торакта очраган мыеклы адәм идеме?

— Әйе. Ярый әле бергә кердек. Ишек янында синең торуың миңа ышаныч, таяныч бирде.

Сәет ханым ягына борылды:

— Зөлфия, ул көнне мине әллә ирем диден, әллә кияүгә чыгам, дип әйттең. Шул сүзеңдә каласыңмы?

— Син бәхетле йолдыз астында туган кеше, Сәетҗан.

— Дәлилләрең?

— Теге көнне, әтигә дарулар табып биргән, озаткан, каршы алган өчен рәхмәтле булсам да, фатирга килеп, шунда яшәп калырмын, дип төшемә дә кертмәгән идем. Мондый хәлиткеч адымга әзер түгел идем әле.

— Чынлапмы?

— Икебезгә дә читтән ярдәм килде. Ирем булалмаган адәм үзенең тупас кыланышы, миңа хакы бар кешедәй сөйләшүе белән гәүдәмне, җанымны үзеннән-үзе синең кочакка этәрде.

Сәет үпкәләгәндәй итте:

— Башкача безнең арада мондый кайнар мөнәсәбәтләр булмас идеме?

— Булыр иде, Сәетҗан. Икегезне чагыштыру комсыз алдакчы файдасына булмады. Сине сайладым. Яратам мин сине, Сәетҗан. Тик кешегә чишмә серне!..

## 12

Сәет тиктомалдан, дөньясын оныткканчы эчеп, өтелеп-сүтелеп йөрүне кабул итми. Ресторанда эшләгәндә дә, ул үзен агуланудан саклап кала алды. Вакыты, урыны белән хәмер кабу эш, сәясәт өчен кирәк була.

Фәрештә дә түгел ул. Монголстанда хезмәт иткәндә, эшсезлектән аракыга өйрәнгән тәне, җаны «яңалык» таләп итә башлый. Шайтан суыннан юаныч эзләгән көннәре дә була.

Кул астында эшләүчеләр белән туарылып утыра алмый (күбесе аңардан яшь, дуамал), йөрәкне әрнү, сагыш, шатлык китереп кысканда, икс ак башны, кабымлыклар кыстыра да, Әхмәдиша карт кырына килә. Тормыш юлы әллә ничә романга җитәрлек абзый белән сөйләшеп утыру үзе бер ял, тамаша, үзе бер гомер.

Бавырына артык килешмәсә дә, зарланып алырга яратса да, Әхмәдиша агай үзен түшәме астына алган, олылап килгән Сәет белән тәмләп, дөньясын онытып утыра.

Кәкре юан бармаклары белән Замир серткән төргәкне иркәләп сүтә. Ысланган итне, сырны ипләп кенә кисә, тозлаган кәбестәсен чыгара, дымлы күзләрен кысыбрак чәркәләргә сала. Башлам кәлимәсе бер үк аның:

— Карале, Сәетҗан, гөнаһсыз сабый баланың күз яше кебек үтә күренмәле бит. Ничек эчмисең аны. Карт кешегә ярамаса да, ходай тәгалә үзе ярлыкасын! Әйдә, тотыйк әле.

Чәркә, кәрәк кулларда югалса да, сакал өстендә үзен зарыгып, өмсенеп көтеп торган тупас иреннәрне эзләп таба. Эчеп куйгач, Әхмәдиша карт тып-тын кала, шәрабның тиешле җиргә төшеп җиткәненә ышангач, мәңге моңсу күзләрен Сәеткә күтәрә...— Урынына кереп утырды.

Беренче шешәне хәл кылгач, Әхмәдиша фәлсәфә куертып алырга ярата.

— Мин, Сәетҗан, бер нәрсәгә инандым. Власть дигән көч наданнар кулына эләксә, бик яман хәлләр чыгарга мөмкин икән.

— Соң, андый кешене тотмыйлар. Алып ташлыйлар эшеннән,— дигән була тегесе.

— Юк шул. Кулыңа яман куәт күбрәк кергән саен акыл, белем, иман кебек нәмәстәкәйләрнең кирәге калмый башлый.

— Арттырасың бугай, абзыкай!

Әхмәдиша, фикеренең астына кереп, йөнтәс, кәкре бармагын түшәмгә юнәлтеп, дәвам итә (мондый игелекле тыңлаучы булганда) фикере дә килеп пешә тора...

— Мин, үз тормыш тәҗрибәмнән чыгып, шуңа инандым: власть акылны алыштыра ала. Бик тә уңышлы итеп.

— Заманалар үзгәрә,— дип сүз кыстырды Сәет, үз сүзләренә ышанмыйча, тоныкка кына.

— Син ул хакта оныт, энем, башыңнан ук чыгарып ташла. Заманалар үзгәрә. Кешеләр шул ук кала. Элекке партия түрәләренең берәрсенең ким-хур булганын, фатирсыз калганын күргәнең бармы? Эшлисе килмәсә, досрочно пенсиягә озаталар.

— Үзгәрешләргә ышанмыйсыңмы бөтенләй, бабакай?

— Ышанам,— дип сикереп торырга омтылып карый, барып чыкмагач, янә бармагын өскә күтәреп, өсти:

— Үзгәрешләрне көтеп куркам. Минем ашыйсы ризыгым ашалган, яшисем яшәлгән. Шулай да Жириновскийларның властька килүен теләмим. Балаларым, оныкларым бар. Син бар.

— Мин Монголиядә чыныккан кеше. Бернидән курыкмыйм,— дип әтәчләнсә дә, Сәет аркасы чымырдап киткәнен бабайга сиздермәсә дә, үзеннән яшерә алмый.

— Ә мин, хуҗам, ГУЛАГ дигән тәмугны күргән, шуның казанында кайнаган кеше. Ишеткәнең бармы? Ул чор төрмәләрен ватмаганнар, юкка чыгармаганнар, барысын да ремонтлап, җилләндереп, кыскасы, әзерләп куйганнар, ди. Яңа буынны кочакларына алырга готовый торалар, ди.

Картның сүзенә дәрт бирү өчен, сүнеп торган утка коры йомычка ташлагандай, Сәет үзләрен демократ дип атап йөргән әһелләрнең көчәеп китүен искә төшерүне кирәк тапты.

— Кешегә шатлык, тән, җан тынычлыгы алып килердәй үзгәрешләрнең Рәсәйдә буласына ышанмыйм. Син гәзит, китап укып, тиле-милене карап, алга таба барабыз, дигән ялганга үзеңне ышандырырга тырышасың. Ышанмасаң да. Як-ягыңа аек акыл белән кара! Берни үзгәрмәде, үзгәрмәс тә...

Түрәләр тирә-юньдә нинди котеджлар салып куйды. Мондый мәһабәт домнарны гади карак, чүпрәк-чапрак сатучы сала алмый. Кулында дәүләт байлыгы уйнарга тиеш. Сату-алу эше дә җиңел түгел. Иң яхшысы — хөкүмәт исәбенә яшәү, аның исәбенә төзү. Олы-олы йортларны кем сала? Кемнең шәһәр уртасында яхшы фатиры бар! Гади халык ничек яшәгән булса, шулай чери дә...

— Ник алай бик төшенке, Әхмәдиша абый? Син начар яшисеңме? Әллә Хәернисә апа җылы куенын ачмыймы?— дип шаярткан була Ярулла улы. Тавышы тәмсез, төссез чыкты. Үзе дә рәхәтләнеп көлә алмады.

Әхмәдиша картка рәхмәт яусын, хуҗасының төрттерүен кабул итмичә, үзенекен дәвам итте:

— Бая әйтә башлаганымны очлыйм. Чутлап кара. Элеккеге райком, райисполкомнарның исеме алышынды. Җисеме шул ук калды. Бүлмәләргә керсәң, кәнәфидә шул ук түгәрәк чырайлы, вакытында ашаудан һәм затлы ризыктан килгән чиста, йомшак тәнле, квадрат иякле кешеләрне табарсың. Иман алыштыру берни тормый. Яңа байлар үсеп килә. Ил шалтайтрестлар кулына күчеп бара түгелме?

Җавапны да үзе үк бирә карт:

— Сату-алуда, кеше талауда баеган яңа нәүришләргә мин ышанмыйм.

Артыграк әйтеп ташлаганын аңлап, карт дымлы күзләрен өстәлдәге ипи катысына төшерде.

Сәет исә картның, яңалык ачмаса да, дөресен сөйләвен һәм үз кыюлыгыннан шөлли калуын аңлады. Халәтенә кереп, җиңеннән тартты:

— Әйдәле, салып бетер.

Бу теманы ябарга тәкъдим итеп, юри тупасрак әйтеп куйды:

— Дөрес такылдыйсың, бабакай. Безнең ватык түгел.

Урыс гадәтенә хилафлык кылып, чәкештермичә генә эчеп куйдылар. Капкалап алдылар. Тынлыкны Әхмәдиша өзде:

— Ачуланма, энем. Бухгалтерың... Наилә лиюем, күренми.

— Сагындыңмы әллә? Күз салмагандырсың үзенә? Ничава әле ул.

Карт янә шаян комагыйлыкны кабул итмәде. Ялагайланып, ярарга тырышып хихылдый торган кеше түгел иде.

— Көн дә килеп чыга торганые. Акчагызның күбесен ул бездәге сейфта саклый.

— Чирли бугай ул. Берничә көн инде эшкә чыкмый.

— Сәер хәл. Бик таза, үзен киләчәк өчен саклый белә торган хатынга ни булды икән?

— Нишләп әле ул хатын борчый сине?

— Борчу дип... әйтсәм, синең эшең түгел дип ачуланмассыңмы?

— Юк ла инде! Безнең ресторан утлары яктысында дөрләп кабынган дуслык мәңгелек.

Әхмәдиша аш бүлмәсендә кайнашкан хатынына әмер төшерде:

— Әй, син, бер «чуаш малаен» керт әле. Кайнар ашыңны да бүл!

— Артык эчмик әле, абзыкай. Хәерче мал тапса, ашап үләр, диләр. Үзебезне бетермик әле.

— Мин разый,— диде карт һәм Сәет ягына иелеп, тавышын кыса төшеп дәвам итте:

— Бухгалтерың синнән без ума! Күптәннән сизеп йөрим. Син Зөлфия белән тора башлагач, әллә нишләп китте. Ычкынмасын дим... Йә, берәр төрле этлек эшләмәсен. Хатын-кызның сүндерелмичә калган теләге бик яман була.

Картның сүзләренә илтифат бирмәде Сәет. Аны өендә Зөлфиясе көтә иде.

— Яратсын, миннән рөхсәт. Мина күз төшермә дип, боерык бирә алмыйм ич мин аңа.

Тәҗрибәле аксакалның сүзләрен җитди кабул итмичә, бусагадан кире кагуы белән Сәет хаклы түгел иде.

## 13

Зөлфия Сәетнең фамилиясенә күчте, уң кулына кин, асылташлы балдак киде. Икесенең дә якыннарын, студент халкын чакырып, бөтен шартын китереп, биеп-биеп, «ачы-горько»ларын кычкырып, туй дип аталган йоланы үтәделәр. Кызның әти-әнисенә чакыру җибәргәннәр иде, килмәделәр. Хәбәрләре дә ишетелмәде.

Яшь ханым бик борчылды. Рәсми язылышуларына атна-ункөн узганнан соң, Зөлфия авылларына барып, никах укытып, якташларын сыйлап кайту турында сүз куерта, Сәетне кыса башлады:

— Сине әти, әни белән таныштырасым килә. Минем сигезенчедә укый торган Самат исемле бер шалапай энем дә бар бит әле. Аны да күрерсең.

— Кыш узсын инде, Зөлфиякәй. Язын йә җәен кайту яхшырак булмасмы икән?

— Сузмыйк инде, Сәетҗан. Минем кышкы каникул вакытында әйләнеп килик.

Газета тотып, зәңгәр экранга текәлеп диванда утырган Сәет янына килеп, куштанланып, кытай чәшкәсе кебек йомры тез башларын келәмгә чүкте. Башын иренең итәгенә куйды. Сәет, ирексездән, сөеклесенең җилкәләренә кулын салды, ефәк хал... астында типкән җылы, татлы тән сулышын сизде. Иелеп чәчләренә өрде. Ир-ат халкы назны кабул итеме, мәсьәләне куеп була дигән сүз. Шулай да, Сәетнең күңеле, аягы тартмый иде Кукмара ягына. Авыл халкының холкын, гадәтен, фигылен ул яхшы белә. Кат-кат өйләнгәч, Зөлфиядән егерме бер яшькә өлкән кешене җинел кабул итмәячәк ата-анасы. Үзләре, бәлки, язмыштан узмыш юк дип, кияү балакайны түргә утыртырга риза да булырлар иде. Татар авылларында «кеше нәрсә әйтер», «кеше ничек кабул итәр», «кеше күзенә ничек күренербез» кебек әдәп-әхлак институтының абруе бик зур. Чит адәмгә өрәсе килмәгән этнең берәр якыны сыртына төртсә, ул үзен бөтенләй башкача тота.

Юк, кызның туып-үскән авылын, әти-әнисен, туганнарын күреп, танышып кайтуга һич каршы түгел Сәет. Һәр рәхәт өчен кем исән чакта, кем үлгәч — барыбер түлисе була. Чанага утырып төшсәң, тауга тартып менәргә иренмә!

Тик ул соңрак, бәби күтәреп кайтсак, беркая китә алмаслар, миңа ачык чырай күрсәтмәсәләр дә, оныкларыннан мәкиббән китәрләр, дип фараз кылган иде дә, Зөлфиясе балага узарга ашыкмады. «Диплом алгач, үземне сиңа һәм балаларга багышлыйм. Әмма дәүләт имтиханына корсак салындырып бармыйм инде, яме, Сәетҗан»,— дип, ирен күндергән иде.

Кыз янәдән үтенечен кабатлады:

— Киләсе шимбәдә кайтабыз, дип телеграмма сугыйммы? Әле хат та барып җитәргә мөмкин.

— Алай ук тавыш күтәрмик. Шыпырт кына, тыйнаклык үрнәге күрсәтеп, арткы яктан, тәпи-тәпи генә кайтып төшик,— диде ир кеше, көчле басымга түзә алмыйча.

Зөлфия җиңел сулап куйды. Ул үзенең Сәетен биш бармагы кебек белә: шаярта башладымы, теләсә нинди мәсьәләне уңайга хәл ителгәнгә сана.

— Уйлап таптым. Берсекөнгә педта укучы Лилия авылга китә. Каникуллары иртәрәк башлана. Шуның аша әйтеп җибәрәм. Авылга, Сәет, алдан кисәтмичә, әткәй әйтмешли, бухты-барахты гына кайтып төшәргә ярамый. Әнинең тавыгы тутырылган, чәк-чәкләре ясалган, бәлеше пешкән, күрше авылларда яшәүче туганнарга хәбәр ителгән, мулла бабай укыйсы сүрәләрен кабатлаган булырга тиеш. Үзең ничек дисең әле: өйләнү — сөйләнү түгел. Кияүгә чыгу да шулай ук.

— Татылдарга маһирланып киттең әле син, кара карлыгачым.

— Кем арбасына утырсаң...

— Юк, мин синең хәтле үк булдыра алмыйм.

— Тукта әле, Сәетҗан, мине яңача атадың. Кара карлыгачым. Нәрсә дигән сүз?

— Кара карлыгачның түше ак була. Синеке дә шундый.

— Минем башка җирләрем ак түгелмени?

— Башка җирләреңне кеше күрми. Алары минеке генә. Ярый, әйдә, сагызланма, юкса, йокы бүлмәсенә күтәреп алып китәм. Анда инде мин дөньяны, шул исәптән, киләсе атнада авылга барасыны да онытачакмын!

Иренең нәфесе тиз кызучан икәнен белгән Зөлфия сикереп торды. Читләшкән булды.

— Юк, юк, Сәетҗан, сөйләшеп бетерик, соңыннан, яме...

— Аның нәрсәсен сөйләшәсең тагын,— дигән булды Сәет.— Акча комодта, теләсәң күпме ал, атна буена бүләк-түләген җыйна! Мин үз өстемә эчемлек якларын алам.

Имтиханнарына да исе китмичә (бишенче курска укытучылар артык каныгып тормый), койрыгын сыртка салып, әни-әтисенә, туган-тумачаларына, күрше-күләнгә, чыбык-чабыкка, энесе Самат кебек эбер-чебергә, этенә-бетенә бүләкләр, күчтәнәчләр җыйды Зөлфия. Акчаң булса, теләсә ни сатып алу мөмкинлеге ачылган вакыт килеп җиткән иде. Базарларга барып, кемгәдер ялагайланып, үтенеп-сорап, теләнеп йөрисе түгел. Зөлфиянең бу чаклы акчаны төшендә дә күргәне юк иде. Рәхәтләнеп туздырды. Белсен, татысын әле Кукмара ягы Исхак киявенең юмартлыгын!

Шимбә көн килеп тә җитте. Кышкы юлның төрле чагы булуын исәпкә алып, бер УАЗ һәм кара «Волга» белән юлга чыктылар. Исәпләре караңгы төшкәнче, сәгать өчләргә кайтып җитү. Хәлил, башкода буларак, алга түнде. Зөлфия белән Сәет, бөтен шартын китереп, киенепясанып, артка утырдылар. Икенче машинага Мисхәт-Мишаны, Фердинандны һәм тагын ике таза егетен алды Сәет. Юл һәм туй хәлләрен белеп булмый...

Ерак ара ямьле музыка, шаяру, көлү, мәзәкләр сөйләнү белән сизелми дә калды. Туктап, коньяк ачып, капкалап алгач, юл тагын да ямьләнеп, җиңеләеп китте.

Авылга җитәрәк, нәрсәдер сизенгәндәй, Зөлфиянең йөрәге ешрак лепелди башлады, иреннәре кипте.

— Сәет, су ач әле? Эчәсем килә.

«Боржоми»ны тәмләгәч тә, тынычлана алмады. Әнисенең кайнар мич янында матавыкланып йөрүдән йөзләре алсуланган, битендәге, маңгаендагы, анык шикелле үк, күгелҗем яшькелт күз төпләрендәге ялтыравык тир бөрчекләрен алъяпкыч очына сөртеп, нәрсәнедер исенә төшереп, выжт итеп, чоланга йөгереп чыгуын күз алдына китерде. Елмаю килеп

чыкмады. Әтисе, өйдә эш кушмасыннар дип, йортта, аты янында кайнашкан буладыр әле. Исән калуына, аякка басуына янәшәдә мышнап утыручы киявенә бурычлы икәнен белми әле ул. Әйтергә кирәк булыр. Хөрмәт дигән нәрсә тиктомалдан гына килми ул. Әйткәләп, төрткәләп торсаң да, бик таман була әле.

Туй эскорды авылга кергәндә, җиргә эңгер-меңгер пәрдәсе салынган иде инде. Ике йөздән артык йортлы, мәчетле, таза татар авылы битараф каршы алды аларны.

— Замир, пока турыга бар. Уңга ал. Хәзер үз ягына бор,— дип, Зөлфия юлны күрсәтеп барды.

«Волга» белән УАЗик биек урыс капкалы йорт янына килеп туктады.

— Сигнал бирикме?— диде Замир.

— Кирәкми. Алдан Зөлфия үзе генә керер.

Ни хикмәттер, урам тәрәзәләрендә дә, хәтта көндез дә янып торган капка лампочкасында да ут юк иде. Күршеләрнең өйләре ялт итеп тора. Йөрәге сизенгән икән Зөлфиянең. Баганаларда гөнаһсыз, нарасый утлар яна, ә әнисенең йорты караңгы, кышкы җилле кичтә үзен борчып йөрүчеләргә эт тә исем өчен берничә тапкыр өргәндәй итте дә тынды.

Әнисенең сагыну шәмнәре кызын көтеп янарга тиеш иде. Юк, шомлы караңгылык.

Кечкенә капканы ачып эчкә үтте Зөлфия. Ишектә олы амбар йозагы ырҗаеп тора. Хайваннар сарайда, бикле. Кыз барысын да аңлап, йөгереп чыгып, ачык машинаның арткы утыргычына капланып, үкереп еларга кереште. Ирләр урыннарында калдылар. Урамда кеше заты күренми. Авылны Али баба башкисәрләре суеп чыккан дияр идең, өйләрдә утлар җемелди.

Күрше йорттан бер кеше чыкты. Аягын сөйрәп, машиналар янына юл алган шәүлә күрше корткасы — Зәйнәпбану әби булып чыкты. Кушаматы — сихерче карчык. Берүзе тора. Исәнләште. Тиешле тынлыктан соң, шәхсән үзе гаепле зат сыман сүз башлады:

— Балалар, үпкәләмәгез инде! Әнигез туйга тырышып әзерләнде. Исхак иртә белән пожаркага чыгып киткән иде, шуннан корт чаккан баладай, холыксызланып кайтты. Атын җикте дә, әнигезне, энегезне, җылата-җылата алып чыгып, чанага ташлап, каядыр алып китте. «Минем мафияга әрәм итәрлек кызым юк. Казаннарында теләсә ничек чәнчелеп китсеннәр, тик күзем генә күрмәсен... Бәдбәхетләрне өемдә кабул итеп, туйлар уздырып ятасым юк, диде. Кемдер махсус эчергән үзен. Тавык тизәге салганнар, диярсең. Күптәннән эчкәне юк иде чирләгәч.

— Кая киттеләр?

— Әйтмәде, балалар.

— Зөлфия, әбигә бүләк бир. Сөенеч алган өчен,— дип, сүзгә кысылды Сәет.

Кемдер уңайсызланып китте:

— Исегез китмәсен: яман кеше туйда тунын кире сорар, ди. Минем гаебем юктыр. Туңып тормасыннар, дип чыгып әйтүем. Чәем кайнар. Кереп җылына аласыз,— дип, өенә таба өстерәде аякларын.

Зөлфиядә җаваплылык тойгысы уянып китте. Сәетне, аның дусларын ул бит алып кайтты. Машинадан күлмәклек материал, төрек яулыгы алып, әбине куып җитеп, кулына тоттырды. Әби ифрат куанды. Рәхмәт сүзләрен әйтә-әйтә, үзе шикелле үк искергән капкасына кереп югалды.

Сәет дилбегәне үз кулына алырга кирәклекне тойды. Кыенлык килгәндә баш мие әлегәчә йокымсырап яткан мөмкинлекләрен уята. Сәет белән дә шулай булды. Хатынны битәрләүдән файда юк. Хәрәкәттә — бәрәкәт, дигән Салсал батыр.

— Хәлил, Фердинанд белән мулла абзыйның өенә барасыз, түбәнчелек белән юлчыларга никах укуын үтенәсез. Шул юлны каплап, Зөлфиягә өйләнмичә, кире китә алмыйм ич мин.

Хәзрәтнең мәчеткә терәлеп салынган йортын табуы кыен булмады. Ирләрне өенә уздырып, йомышларын аягүрә тыңлады.

— Без узып баручы мосафирлар,— диде Хәлил.— Бер егет белән бер кызга никах укыйсы иде. Икесе дә риза. Шаһитләр дә бар. Шундый гозер сезгә.

Мулла абзый, вак тигез тешләрен күрсәтеп, кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Сез авыл кешеләрен, дин әһелләрен, театрда мәсхәрәләгәнчә, диваналар, томаналар дип уйлыйсыз инде, кем, мосафир иптәшләр. Исхакның кызына никах укыйсы иде, диген. Артык кызу кеше шул. Мин аңа тузынма, бүрегең белән киңәш, ничек кенә кылансаң да, кызың синеке түгел инде. Заманалар башка. Яраткан кызыңны бөтенләйгә кайтарып, кулына әле бирәр нарасый тоттырып җибәрсәләр, анысын күтәрү авыррак булыр,— дип үгет-нәсихәтемне әйттем.

— Риза булып чыгып киткән иде. Юлда кайтканда, кемдер борыч кыстырган тегеңә. Хатынын көчләп диярлек чанага ташлап, кире якка чыгып киткән. Нәрсә мин лыкылдап утырам соң әле! Үзегезгә мәгълүм.

— Сән, абыстай, чәеңне куй! Алып керегез яшьләрне!

Хәзрәт бөтен шартын китереп, җиренә җиткереп, яшьләрне кавыштырды, тәбрикләде, чәй белән сыйлады. Шактый алдынгы карашлы муллага, абыстайга мул итеп бүләкләр, мәчеткә зур сумма акча калдырып, дустана саубуллашып, кайтыр юлга чыктылар.

— Зөлфия, болай әйбәтрәк тә булды әле. Мулланың үз өендә никах укыту, фатиха алу бик сирәк кешегә эләгә ул,— диде Хәлил.

— Безнең начар яшәргә хакыбыз юк. Гаилә үрнәген күрсәтергә куша безгә китап,— дип, кәефе күтәрелгән Зөлфия рәхәтләнеп тыкылдый башлады. Ата-ана ничаклы гына якын, газиз, изге булмасын, хатын-кызның үз гаиләсе барыбер үзәктә була икән шул.

— Мин тиз генә өйгә сугылыйм әле, Сәет. Ачкычым бар.

Машиналар янәдән биек капка янына килеп туктады. Ап-ак кар аяк астында затлы күннән теккән аяк киеме төсле тавышлар чыгара. Шыгырт-шыгырт. Мәңгелек эшсезлеккә дучар ителгән ай, тиле кеше төсле, көлемсерәп тора. Аның Исхак абзыйга берни әйтмәсен тәгаен белгән Зөлфия, мичтә пешеп, йомшарып җиткән бәлешне клеенкага төреп алып чыга.

— Егетләр, бәлеш әзер. Авылны чыккач, рәхәтләнеп ашыйбыз!

— Зөлфия, кил әле монда. Әйдә, алып кайткан бүләкләрне кертеп калдырыйк. Безгә хаҗәте юк. Әтиең дә, бавырына бер китереп сукса, безнең кирәкне аңлар әле.

Җәһәт кенә төенчекләрне, чанталарны өй эченә кертеп куялар да, утны сүндереп, ишекне, капканы бикләп урамга чыгалар. Шул арада йорт тирәсенә яшьрәк ир-ат, бала-чага җыела. Робинзон Крузоны беренче күргән аборигеннар кебек, якын килмиләр. Көтәләр.

Сәетнең аракысы, капкалар әйберләре, тәмләткечләре барысына да җитәрлек. Алдан, бәлки, боларны кунак итеп, исертеп китәргә, дигән фикер башыннан узса да, вакытында тыелып кала алды. «Ваклану булыр. Исе чыгар»,— дигән нәтиҗәгә килде.

Шактый кызмача авыл егете генә: «Исхак абзый маладис, мафияне кабул итмәде, кызына да бәддогасы төшәр»,— дип тавыш күтәрә башлаган иде, УАЗикта килгән егетләрнең берсе тегенең янына килеп, каты итеп аягына басты, чын күңелдән беләгән кысты, колагына нидер әйтте. Егет тынды. Зөлфиягә күз атып йөргәннәрнең берсе булган икән.

Эскорт авылдан кичке сигезләрдә чыгып китте. Бәлешкә суынырга бирмичә, туктап, утырып ашадылар, яшьләрне законлы никах белән котладылар.

Сәет бу хурлыкны авыр кабул итсә дә, сиздермәскә, гаярь күренергә тырышты. Вакыйганы авыр кичергән кеше Зөлфия булды. Йөзенә сагыш сарысы, күз төпләренә «кара урак» төште.

## 14

«Игелек»нең янарал директоры авылда «туйлап» йөргән йомшак җилле кичтә дә тормыш тукталып тормады. Әҗәле житкәне башка халәткә күчте. Туасы, үзе турында хәбәр биреп, дөньяга сөрән салды.

Иң олы вакыйгаларның берсе — Зөлфия элек яшәгән тулай торак бүлмәсендә булды. Анда атна саен диярлек була торган күңелле мәҗлесләрнең берсе узды. Студент кичәләре белән ярыша алырлык күңелле, риясыз очрашулар буламы икән җир йөзендә? Юктыр, алдан чакырулы әгълә мәҗлесләрең илләм бер якта торсын. Бередәге күңел күрлегән, яшьлек дәртен түләүле мәзәкчеләрең, мактаулы җырчыларың алыштыра алмый.

Паханның үтенече буенча, Мисхәт-Миша Шөреп-Сәнгатне үзе белән иярттe шул кичәгә. Байларча кыланып, аракы, шампан шәрабы, затлы конфетлар алдылар.

Бүлмә ишеген озынча буйлы, тар йөзле кыз ачты. Түбәдән икегә аерылган чәчләре дулкын-дулкын булып як-якка салынган. Фил сөяге төсендәге тиресенә кыйгач кашлары, зур соры күзләре җылылык бөркеп тора. Муеныңдагы алтын чылбырдан башка бернинди бизәнү әйберсе юк.

— Миша, әйдә! Сине көтә-көтә көтек булдык.

Кочаклап, яңагын Мисхәт-Мишаның битенә тидереп алды. Якын дус итү ишарәсе иде бу.

— Үзең генә түгел икән әле.

Бик гади генә итеп буялган бармаклы тар кулын Шөрепнең учына салды:

— Әлфия. Аля дисәң дә ярый. Узыгыз.

— Сәнгат.

Күчтәнәчләрне Әлфиягә тапшырып, аяккиемнәрен салган арада Мисхәт-Миша Шөрепнең колагына: «Әлфия минем кыз, нәфсеңне сузасы булма. Бармак белән кискән ипине ашарга яратканыңны беләм. Әлфия, малай, особый кыз ул. Группа старостасы, бүлмә хуҗасы. Икенче ел йөрибез, аска төшерми. Кызмы, хатынмы, кояшмы, аймы икәнен дә төгаен әйтә алмыйм. Яратам үзен шайтанны»,— дип аңлатма бирүне, кисәтеп куюны кирәк тапты.

Иптәш кызлары арасында Әлфиянең лидерлыгы күренеп тора. Бөеклек, тирән фикерлелек чалымнары да юк кебек үзендә. Нәкъ менә шул гадәтилеге, арпа мыегы кебек өскә бөгелеп торган керфекләре, киң, җыерчыксыз маңгае, кысан күлмәген төртеп торган, өлгергән алма кебек тыгыз күкрәге, еландай биле, озын аяклары хөрмәт уятмый калырлык түгел иде.

Әлфиянең хәрәкәтендә, йөрешендә, тотышында серле яшеренкелек, кысласыманлык бар. Тәненең һәр күзәнәге җырлап, биеп, үзенә тартып, мәхәббәт нурлары бөркеп торгандай тоела. Аны күрү, күзәтү бәхетенә ирешкән теләсә кайсы ирнең йөрәге лепелдәп куюы табигыйдыр.

Кызның төгаен билгеле бер җиргә ашыккан кешедәй, гәүдәсенең өске ягын алгарак авыштырып атлавының болай да туп төсле йомры артына муллык бирүе Мисхәтнең акылын ала.

Буйсына белгән ирнең андый хатын белән тормышта да, ятакта да кайгы-хәсрәтсез яшәячәге күренеп тора. Шуны аңлар өчен акыл иясе булуның һич хаҗәте юк.

— Сез нәрсә анда хатын-кызлардан уздырып пышылдашасыз? Күптән күрешкәнегез юкмы?— дип, күчтәнәчләрне урнаштырып, кунакларга урыннар бушатып өлгергән, умарта кортыдай житез Әлфия егетләр янына очып килеп житте. Нәрсә турында гәп кылганнарын чамалый иде ул.

— Син, Миша, минем янга ояларсың, каршы килмәсәң. Белмәссең сине... Кунак егет караватка, оратор янына утырыр. Әйдә, Регина, сүзеңне дәвам ит.

«Оратор» дигәннәре, чыннан да, нотык тота иде егетләр кергәндә. Торып басты. Әлфиядән буйга кечерәк. Мул күкрәкле, түгәрәк битле, чәчләрен кыска итеп кистергән кыз иде Регина дигәннәре.

— Мин дәвам итәм. Собственно, мин кирәген әйттем бугай. Мәңгелек белән элемтәнең эчке серләренә тукталдым,— диде томса күзләрен стаканга текәп.— Соңгы сүзем үзем турында: мин фәрештә түгел. Ике җитешсезлегем бар...

Мәгънәле тукталыш ясап, өстәл артында утыручыларга каш сирпеп, әйтеп салды:

— Матурлыгым һәм гадилегем!

Нәкъ шул сүзләрне көткәндәй, дәррәү көлеп җибәрделәр. Әйтерсең лә үтә кызган майсыз табага бер уч борчак ташладылар. Шөреп кызның сүзләрендә «монда көләсе» дип әйтерлек мәгънә тапмаса да, иреннәрен кысып кына, мәҗлес кәефенә кушылды. Яшьли тәмәке тартып саргайган эре тешләреннән ояла иде ул. Кешегә күрсәтәсе килми. Тегендә утырганда, «бүре тешләре» аның аянычы, мактанычы булса, тыныч тормышта, кем әйтмешли, бәяләр бөтенләй үзгә икән.

Өстәлдә булган нигъмәтне тәмләделәр. Мәҗлес кызганнан-кыза барды. Шөрепнең кызлар турында күбрәк беләсе килә. Мисхәт белән дә аралашып булмый. Шайтан сөяге. Әлфия аларны аерып утыртты.

— Бу өстәл артында утырган кешеләрне нәрсә якынлаштыра дип уйлыйсыз инде сез?

— Секска — мәхәббәт,— дип кычкырды, чәчләрен әллә ниләр кыландырып, баш түбәсенә өеп, бер өлешен як-якка тырпайтып куйган, кыр чәчәге төсле ялтыравык зәңгәр күзле кыз.

— Наташа, оятсызланма! Биредә безне бөтенләй белмәгән кешеләр бар. Синең шаяртуыңны җитди кабул итүләре мөмкин. Соравыма җавапны үзем биреп карыйм. Һәркемнең дөньяны үз аңлавы бар. Мин, әйтик, мондый кыйммәтле конфет сатып алмас идем. Мин арзанракны табар идем. Аны инде җәлләмичә ашарга була. Бу — дөньяга студент карашы. Хуш, кешенең затлы ризык сатып алырга хуты бар икән, димәк, ул эшли, акча таба. Һәрнәрсәнең төбендә, малайлар, исәнлек ята. Шул шайтан булмаса, өстәлеңдә ник тере килеш кыздырылган дуңгыз баласы ятмасын шунда (Әлфия өстәлнең бушап калган урыннарына ишарә ясады), тәмен аңламаячаксың. Безне, төрле һөнәрле, үзгә-үзгә милләт балаларын, матур тормышка, ягъни комфорт белән яшәүгә омтылыш якынлаштыра. Урыслар «красиво жить не запретишь», диләрме әле? Бу азгынлыкның төбендә, җәмәгать, үз-үзеңә мәхәббәт, эгоизм ята. Шулай бит, Миша? Кешенең табигатенә хас бу нәрсә — начар омтылышмы? Минемчә, юк, һәркем бу фани дөньяда кунак кына.

— Кунак булсаң, тыйнак бул,— дип кыстыруны кирәк тапты Мисхәт. Көләргә үзенә генә туры килде.

— Анысы сезгә карый,— дип, юл уңаенда гына җавап бирде дә сүзен дәвам иттерде Әлфия.

Җитәкче кеше әхлак мәсьәләләренә дә кагылып үтте:

— Теләсә-кайсы хатын-кыз артыннан сөйрәлүче замана Донжуаннарын яратмыйм мин,— диде Әлфия, озын керфекләреннән егетләргә сәлам сирпеп.

Өйрәтергә, киңәш бирергә туган форсатны беркайчан ычкындырмас кызый. Ашамаска, эчмәскә мөмкин, әмма акыллы сүзен әйтми, сафсатасын кайнатмый калмас.

Әлфия тыштан караганда тәртипле, инсафлы, бәхетле гаиләдә үскән балага охшап тора. Чынлыкта, аның Шөреп хәленә төшәргә бөтен мөмкинлеге бар иде. Шундый ук аянычлы, фаҗигале һәм безнең ил өчен гадәти тәварих.

Кыз бала туугa, әти-әнисе тәртәләрен як-якка боралар. Анасы янә тормышка чыга. Яңа хуҗага кеше баласы кирәк түгел. Әбисе белән яшәгән Әлфия, әнисенең хәлен белергә килгәндә, үги ата кызның тыгыз шалкан кебек үсеп килгән күкрәкләрен, нечкә билнең дәвамын, ак маңгаен, язгы тал бөресе кебек йомшак иреннәрен майлы күзе белән ашый, капшый, җаен китереп, кулын тота, утлы күмердәй учын аркасында калдыра, төрле кинаяләр ясый. Анасы азгын дулкынны сизми калмый, гаепне, табигый ки, озын, төз аяклы кызына аудара. Бүрәнәләрен бүлеп куя. Әлфия Зеленодолда яшәүче әбисе белән кала.

Ятимлекнең ни, нәрсә икәнен ул яхшы белә. Кырыс җилләр, ачы бураннар белән көрәшергә өйрәнгән ялгыз үскән агач төсле, Әлфия бары тик үз көченә, үз акылына, үз ихтыярына таяна. Бик иртә мөстәкыйльлек юлына чыга. Һәр нәрсәгә фәлсәфи карарга, көтәргә, көттерергә өйрәнә. Ул — яшьлегенең көчен, чибәрлеген белә. Юкка-барга сатылмыйча, табигать биргән бердәнбер байлыгын, хәзинәсен әрәм-шәрәм итмичә тота да белә.

— Дус булып, матур итеп, тормыш ямен тоеп, тиешлесен алып яши белергә кирәк бу хәятта. Шуның өчен стаканнарны бушатып куярга тәкъдим итәм!— дип сүзен тәмамлады Әлфия.

Студент халкы арасында гына урнаша алган тигезлеккә таянып, сүз сорап тормастан, Наташа аякка басты.

— Әфәнделәр! Акыллы тостлар сөйләргә яратмыйм. Бик тырышсам, бәлки, җиңеп тә чыгар идем. Миннән бер мәзәк... Бер ханым дус хатынына чылтырата:

— Кичәге мәҗлестән бер дә канәгать калмадым әле. Шулчаклы күп эчелгән, үз ирем белән бер ятакка эләккәнмен, дип зарлана.

Акшарланган битенә җыерчыклар чыгарып, дымлы тешләрен күрсәтеп, рәхәтләнеп көлде үзе.

Наташаны күпләр җилбәзәк кыз, күтләк гетера санап йөрсәләр дә, якыннары аның булган, хәйләкәр, үзен алдатмый торган шәхес булуын яхшы беләләр. Ижауның мылтык заводында цех начальнигы әтисеннән Мисхәт белән алар пычрак балык капчыкларында поездда, җиңел машинаның утыргычы астында күпме корал ташуларын үзләре генә белә.

Шуларны бүләк итеп, «Игелек» ничәмә олы түрәне үз җәтмәсенә эләктерде.

Наташаның тышкы чытыклыгына алданып, ансат җиңүгә өмет иткән күпме ир-егет юеш мыегы, чыланган оекбашы белән торып калды.

Мисхәткә дә күн кепкалы кыздан дәрес алырга насыйп булган иде заманында.

Әлфия белән чәбәләнә башлагач, шул ук бүлмәдә яшәүче Наташа белән танышты. Сүз аралый сүз итеп, бер-берсенә кирәкле кешеләр икәнне ачыкладылар. Сакманов күптәннән Ижау корал заводына якынаю юлларын эзли иде. Олы зәңгәр күзле кызның әтисе заманча мылтыклар ясау цехының хуҗасы икән.

— Кыз белән Ижауга бар. Менә сиңа юллык,— дип, кулына барысына да җитәрлек акча тоттырды Сәет Яруллович.

Поездга төялеп, юлга чыгып киттеләр. Ходаның бирмеш кенендә купеда икәү генә туры килделәр. Сирәк була торган хәл. Тәне гарип, зиһене зәгыйфь, яисә тиле-миле аскет революционер булмаган ир-ат мондый мөмкинлекне ычкындырамы соң? Язмыш сине сайлаган икән, хәрәкәт ит! Кызы да әле табадан төшкән кайнар коймак сыман. Май сылап торасы да юк. Иреннәренне, телеңне яндыра-яндыра ботарла гына.

Мисхәт булачак ләззәттән төкерекләрен йота-йота, өстәл әзерләде, стаканнарга коньяк койды. Тезгә-тез терәшеп, көлешә-көлешә ашадылар, эчтеләр. Наташаның җиңел холкы турында ишетеп белә иде егет. Нигә вакытны әрәм итәргә. Әлфия барыбер тирәнгә уздырмый.

— Әлфиягә сөйләмәс булсаң, телеңне теш арасында калдырсаң, мин риза,— дип ярып салмасынмы егет.

Кызның колаклары үрә тора.

— Син нәрсә лыкылдыйсың?

— Теләсәң, аста бергә ятыйк диюем.

— Менә нәрсә, Мисхәт дус: әгәренки, бу хакта тагын бер сүз катсаң, мин беренче тукталышта ук төшеп калам! Яисә син кайтып китәсең!

Егет, хатасын аңлап, кызны тынычландырырга тырышты:

— Мин шаярттым гына, Наташа. Гафу ит.

— Секс белән эшне бутарга ярамый! Якыннан белгән ирләр, бигрәк тә иптәш кызның егете белән йоклаудан да әшәке нәрсә юк.

Иплән кенә чишенде. Ак, матур тәнен күрсәтеп, халатын киде. Әллә Мисхәт бар аңа, әллә юк, исе дә китми. Ижауга җиткәнче, иреннәрен чапылдата-чапылдата йоклап барды.

Мисхәтнең Наташага беренче һәм соңгы тәкъдиме булды бу. Якын дуслар булып калып, бик күп уртак эшләр майтардылар әтисе аша.

Үзен студентлар компаниясендә җайсызрак тоеп утырган Шөреп, өстәл астына сузыбрак куйган уң аягы өстендә җылылык тойды. Куштан песи баласы менеп утырды, диярсең. Шул чаклы рәхәт булып китте егеткә. Нурлы, якты, татлы хис бөтен тәне буйлап йөгерде.

Кем аягы икәнен тәгаен билгеләве кыен. Өстәлгә җәелгән чуар клеенка идәнгә чаклы төшкән. Аяклар буталышып беткән. Регина булырга тиеш, дип гоман кылып, кыймылдарга да куркып утыра бирде Шөреп.

Җырлап карадылар. Татар көйләрен шыңшыдылар, урысныкын тарттылар. Сүзләрен белмәү сәбәпле, бу шөгыль озакка бармады. Староста яңа фәрман төшерде:

— Биибез! Урындыкларны караватка күтәрәбез, өстәлне — тәрәзә кырыена.

Һәр нәрсәне тәртип белән эшләргә өйрәтелгән Шөреп кулын күтәрде:

— Тартып керергә мөмкинме?— Чынында аның Мисхәт белән пышылдашып аласы, киләчәгенә ачыклык кертәсе килә. Йолдызы аталган кызга бәйләнеп, кара янган күз төбе, кабартма ирен, сынган кабырга белән кайтып китүең бар. Бүлешү — бик кирәкле шәйдер бу очракта.

Беренче сорауны Шөреп бирде:

— Кем ул минем янда утырган, олы күкрәкле кыз? Егете бармы?

— Син булырсың,— диде Мисхәт, үзеннән арткан чәчбикәләрен яраннарына өләшкән хан кебек эре генә. Янәсе, ул монда хуҗа кеше, күп нәрсә аның бармак шартлатуыннан тора.— Тик койрыгыңны белеп чәнче. Милиционер кызы. Әтисе зур кеше, диләр. Син чебешне тиз акылга китерер.

— Секска — мәхәббәт, дип кычкырганы, анекдотлар бәргәне?

— Наташамы? Ижевск кызы. Тачанка кушаматлы.

— Ни өчен шундый сәер исем такканнар?

— Сыерга да, ерактан хәбәр биреп торсын дип, кыңгырау тагалар. Тәгаен белмим. Әлфиядән сорарбыз, ул һәммәсен белә, аңардагы хәтер белән аек акылны әйтсәң, малай. Исең, зиһенең китәр,— дип, кызын мактарга кереште.

Шөрепне Әлфиянең акылы борчымый. Шыр тиле булса да, ул аңа эләкмәячәк, колагы тешләнгән, Мисхәт рәхәтен күрсен. Араларында «менә монысы матур түгел», дип әйтерлек кыз юк. Нечкә кашлары сынган. Элек бәйрәм парадына чибәр, таза, буйлы егетләрне махсус сайлап алып, Кызыл мәйданга чыгаралар иде. Боларны кем шулай җыйган? Сәнгатьнең һушын алыр, зиһенен чуалтыр өченме? Барысы да бер группа кызлары, диләр.

— Анысы кемнеке? Нindirәк кыз? Йоклап кайтып булмыймы?

— Янында фраеры утыра. Бүген ул аның белән. Яраткан сүзләре: «Үзем генә йокларга куркам, гәпләмәгез, янымда ир-ат булмаганда, ачык тәрәзә белән булса да йоклыйм».

Шулай кылана гына. Мин янында сырпаланып караган идем дә, барып чыкмады, отшила. Үтә хәйләкәр. Тышында бер, эчендә бөтенләй башка кеше, дөресе, шайтан утыра.

Мисхәт вагондагы хәлне сөйләп тормады. Наташа да Әлфиягә ләм-мим сүз әйтмәде. Телен йозакта тота белә икән. Безнен замана өчен — бу илләм казаныш.

Кызлар бүлмәдә үзләре генә калды. Әлфия, йөзенә сагышлы-уйчан кыяфәт чыгарып, олы дәүләт серен чишкәндәй, кызларның колагына йөзек салды.

— Әй, кызлар, әйтсәм әйтим инде. Сез бит берни белми яшисез!

— Нәрсә, Әлфиякәй? Сереңне ач!

— Юк, ла! Сезгә ышансаң... Кирәкмәгән җирдә ычкындырып ташларсыз.

— Хатын-кыз күп сөйләшсә дә, ир-ар кебек гайбәтче һәм сатлык түгел,— дип ярып салды Регина.

— Ярый алайса, күндем,— дип озын муенын тагы да алгарак сузып, йомгакны чишә башлады Әлфия.

— Дөньяда иң татлы әйбер нәрсә? Белмисез! Бохар кәлвәсе, сез мөкиббән киткән «сникерс» та түгел. Тыныч һәм эчтән дәртле музыка астында яраткан кешеннең куенына кереп, сеңеп, шунда ләйсән кары кебек эреп бетеп, бер кулыңны йөрәге каз бәбкәсе тәнедәй ләпелдәп торган киң күкрәгенә, икенчесен ышанычлы муенына салып, каймаклы авызыңны аның арыш икмәгедәй тупас, кайнар иреннәренә куеп бию ул. Иң югары ләззәт шунда, бик беләсегез килсә!

Йөзе таң шикелле балкый. Фикеренә ышанып, күз алдына китереп сөйләгәне күренә.

Әлфиянең вакыт-вакыт хискә бирелеп, бизәкле сөйләргә яратканын белсәләр дә, һәркемнең күңелендәген ачып биргән бу дөреслектән бермәлгә югалып, тынсыз калдылар. Шуннан инде, чыр-чу килеп, карышкан булдылар.

— Фу, Әлфиюшка, оятсыз!

— Син безне бозасы итәсең.

— Син бит староста. Ә ул элек укытучылардан билгеләнгән группа җитәкчесе, комсорг, профорг, ДОССАФ кебек бик күп оешмалар урынына калган тәрбияче, остаз.

— Син безгә югары әхлак тәртипләре сеңдерергә тиешле кеше. Нәрсә сөйлисең?

Әлфия, өстән аска карап, тегеләрне юри котырта:

— Аңладым мин. Сезләргә пар күгәрченнәрдәй гөрләшеп, үбешеп тору гына охшамый. Киң ятакта тәгәрәшүне өстенрәк күрәсез.

— Фу, оятсыз,— диештеләр кызлар янәдән. Һәркайсының нәкъ Әлфия теленнән төшкәнчә биеп карыйсылары килү сизелеп тора иде.

Шул арада сабаннан кайтып эшлекле кыяфәте белән тәмәкече егетләр бүлмәгә бәялде. Әңгәмә өзелде. Егетләр керүгә, биюләр башланды. Наташа янында утырган җирән чәчле, сипкелле битле, колга егетне үзе чакырды, кулларын муенына, башын күкрәгенә тапшырды.

Әлфия өстәлне рәткә китереп маташа. Тагын бер пар уртада бөтерелә.

Өстәл артында Регина гына калган. Шөреп аның миң төрткелләре белән тулы муенына, ачык җилкәләренә, сәламәт тиреле, тулы яңакларына яратып карады. Тиле мәхәббәт дулкыны бөтен гәүдәсен биләп алды.

Кызның үрелеп, азык-төлек капкалап утыруын хуплап (ашаган малда бәрәкәт бар), үзенчә мактап куйды:

— Миңа аппетитлы яхшы кызлар ошый!

Регинаның өлгергән гөлҗимештәй күзләрендә хәйләкәр чалымнар йөгереп үтте.

— Сезнең кәефне күрер өчен генә ашаган булып утырам инде.

— Рәхмәт! Рәхмәт! Егетегез бардыр инде сезнең?

Гөлҗимеш күзләр төсен үзгәртте. Серен ачасы килмәү сызыклары чыкты калынрак тиреле йөзенә. Җавапсыз калу — тәрбиясезлек булыр иде.

— Минем яшьтә дә егетем булмаса? Дөрес аңлашылмас иде. Шулаймы?

Югалып калганда, учларын бер-берсенә ышкып ала торган гадәте бар иде. Ярдәм итә. Баш яхшырак эшли башлый.

— Шулайдыр да...

— Соң?

Гөлҗимеш күзләрдә сорау билгесе пәйда булды.

— Миңа да бик ошыйсыз?

— Анысы инде, абзыкай, сезнең проблема. Мине бу эшкә бутамагыз.

Шөреп Регинаны биергә чакырды. Шырпылы сөйләшсә дә, ялындырып тормады. Күптәнге танышы төсле, кулларын егетнең җилкәләренә куйды.

— Исемегез Регина бугай.

— Әллә охшамыймы? Үзем сайлап алган исем түгел. Предки так обозвали.

— Исемдәмени эш. Миңа әбием Сәнгат дип кушкан. Әле күптән түгел генә аның «искусство» икәнен белдем.

Сүзләренә колак салып торган бугай, елгыр, чая Әлфия:

— Безнең институтта укырга кирәк сезгә,— дип кыстырды һәм Мисхәт-Мишаны инструктажга читкәрәк алып китте.

— Чыннан да...— дип өстәде Регина.

— Бөтен кеше мулла булса, атка печән кем сала, диләрме әле?

— Бездә мулла әзерләмиләр, элеккеге муллаларыбыз — марксизмленинизм укытучылары да тинтерәш хәлдә калдылар. Сәгатьләр бар, нәрсә укытырга белми интегәләр. Барыбер шул ук саргаеп беткән дәфтәрләрен күтәреп керәләр дәрескә.

— Сез кем булырга әзерләнәсез инде?

— Кызларның буй-сыныннан, нәфислегеннән аңламадыгызмыни?

— Минем өчен табышмак. Мин килгән хөрмәткә бөтен институтның гүзәлләрен җыеп, бер табынга утырткannар, дип фараз кылдым мин.

Регина кабартмадай күперенке иреннәрен, ак тешләрен елтыратып, рәхәтләнеп, башын артка ташлап көлде. Югары Ослан тавының ике ягыдай күкрәге аслы-өсле килеп калтыранды.

— Бик мактанып китмәгез, иптәш Искусство? Без — булачак хореографлар.

— Ул кем була инде, балетта биюче ме, аягын сәхнәдә болай гына тыпырдатучымы?

Регина үпкәләмәде. Тыныч кына аңлатып бирде:

— Юк, без оештыручы, методист, клуб хезмәткәрләре булачакбыз. Кем кая урнаша ала инде. Киң профиль бирәләр безгә.

Мондый ваклыклар Шөрепкә кирәк түгел. Аңламый да.

— Сез бу бүлмәдә яшисезме?

— Юк.

— Ничәнчедә? Дәүләт сере булмаса.

— Мин әти-әнием белән яшим.

— Кай тирәдә?

— Әһәмияте бармы?

— Якташлар түгелме икән, дип кенә соравым иде.

— Озата барсагыз, белерсез,— диде кыз.

Милиционер кызы мәсьәләне җитди, кабыргасы белән куя дип, үзалдына елмаеп куйды Шөреп. Ул кызны акрын гына үзенә тартты, җилкәдәге куллар йомшарды. Регинаның мул күкрәгенә сылангач, егет үзендә чит-як аяк кагылгандагы хисләр өермәсе уянуын, аның тагын да кайнарын тойды. Шик юк, бая аны Регина котырткан, тәкъдимне үзе керткән икән. Әлбәттә, әфисәр кызының явыз шаяртуы гына булмаса.

Түр башында утырган Сания белән Фәрһад, ипле генә саубуллашып, чыгып киттеләр.

— Тиздән алар өйләнешәләр,— диде Әлфия, Мисхәтнең аркасыннан сыйпап.— Без туйга чакырулы. Өйрәнеп, күреп, үрнәк алып торуның зарары тимәс. Чиратка язылыйкмы соң, батырым?

Әлфия җавап көтми. Мәсьәләнең хәл ителеше аның үзеннән торганын аңлый ул.

Наташа фраеры белән чыгып китте. Әлфия белән Мисхәт кунакларны озатырга чыгуга, Сәнгат, зеклар әрсезлеге белән, иреннәрен кызның ялкынсынып, әсәренеп, үзенә тартып торган битенә, авызына батырды. Регина, еш-еш сулап, егетне акрын гына үзеннән аерды. Кызның егетне ошатуы сизелеп тора.

— Мин сезгә ошыйммы?— дип турыдан бәрде Шөреп.

— Сез оятсыз адәм икән.

— Ни өчен?

— Минем фикерне сораганчы, үзегезнекен әйтергә кирәктер. Зыялы кешеләр шулай эшли, дип ишеткән идем.

— Мин бит гади эшче.

— Кайларда хезмәт итәсез, дип белик?

— Мебель цехында. Урындыклар вату буенча мастер.

Гадилеге, әрсезлеге, хәтта үбешә белүе белән кыз күңеленә хуш килде егет.

— Миңа кайтырга вакыт. Өйгә кертмәсләр. Озатырга уйласагыз, киттек.

Үз бәхетенә үзе көнләшеп, уңышына шаклар катып, Шөреп кызга иярде. Регинаның уңай йогынтысы сизелде. Егет күп эчәргә оялды, бераүгә дә бәйләнмәде. Чын зыялыларча сөйләшергә тырышып кайтты, хәтта кызын озата барганда да.

Шөрепне тулысынча үзгәртә алмаса да, яңа мохит, яңа танышлары аңа уңай йогынты ясады.

Рәхмәт төшкере, Мисхәт-Миша аны югары җәмгыять кызлары белән таныштырды. Шөреп Регинага нарат тактасыннан бәреп чыккан сары чәер төсле ябышты.

Шөреп Регина күңеленә һәр тарафтан хуш килде, дип раслау дөреслеккә хилафлык итү булыр иде. Белеме барлы-юклы ун сыйныф; ятим үсүе сәбәпле, тәрбия, итагатьлелек җитеп бетми егеткә. Җенси мәсьәләдә артык әрсез күренә, анысы, ул теләгәнчә генә булсын.

Кыскасы, Регина тиле көчкә ия, кысык, таза гәүдәле Шөрепкә битараф булмаса да, дөньясын онытып, мөкиббән китмәде. Каны артык уйнамады. Шөреп дөресен сөйләп бетермәсә дә, аның кем икәнен ул сизенде. Үзе юкта: «Минем бандитым килергә тиеш хәзер»,— дип тә ычкындыргалады. Егетнең бәйләнүенә каршы килә алмады, хәер, артык карышып та кыланмады. Тынгысыз кызыксынуы җиңде.

Йоклап йөри башлагач та, артык ләззәтен тапмады Шөреп белән якынлыкның. Аның бертөсле шашынуы, онытылып, кычкырып җибәрүе, хайвани хисенең алга чыгуы, озаклап сөяргә, назларга иренүе, үзе турында гына кайгыртуы иркә үскән Регинаның ачуын китерә, саруын кайната. Нишләмәк кирәк, өлешеңә тигән көмешең, вакыт уздырырга, гомер итәргә барыбер кемдер кирәк бит. Адәм баласы ялгызы яшәргә тиеш түгел. Ходай аны шундый итеп яраткан.

Шул ук вакытта Сәнгат вакчыл түгел, акчаның сукыр тиенен барлап утырмый. Аның белән ышанычлы, курыкмыйча йөрисең. Теләсә кемнән яклый ала.

Әти-әнисе булмаса соң, үзләре генә яшәү яшь киленнәрнең изге хыялы түгелме? Аның гади балта остасы булуы да начар түгел. Регина өстенлек итәр, үз кубызына биетер. Тик арбага җигүне ашыкмыйча, җайлап, ипләп эшләргә кирәк булыр. Коты кызу, холкы дуамал, тәртәне ватып-сытып китүе бар.

Кыскасы, ике яшьнең борчаклары пеште, бер-берсенә тәмам ияләшеп, үзләшеп беттеләр. Бер мәлне егет өйләнешү турында сүз катты. Ниятен кыз хуплады. Тик шунда көтелмәгән ике низагъ килеп чыкты. Бәхетләре идәнгә төшкән бәллүр савыт кебек ватыла язды.

Җәйге ялкау кичләрнең берсендә Шөреп Әлфияләр бүлмәсендә, үз бәясен белеп, хуҗаларча аякны аякка куеп, йокымсырап, Регинаны көтеп утырды. Гадәттә, алар шунда очрашалар да, егетнең яшел «Жигули»ена утырып, чыгып китәләр иде.

Әлфия кухняда чәй әзерләп йөри. Шулвакыт бүлмәгә коңгырт-аксыл чәчле, яшел-күгелҗем күзле кыз килеп керде. Өстендәге тонык зәңгәр кыска күлмәге гәүдәсенең матурлыгын, биленең нечкәлеген, аякларының тиешле төзлеген ассызыклап, күрсәтеп, бизәп тора.

Шөреп, күзләрен тутырып, кызга карады да, зиһенен, һушын югалткандай булды. Дөньяда егерме җиде ел яшәп, шундый матур җан иясен күргәне юк иде әле. Үзен бик иркен, хуҗаларча тотып, бүлмәгә узды, гади генә итеп:

— Хәерле кич,— диде. Тагын елмайды, алсу бит очларында тычкан күзе чаклы гына чокырчыклар пәйда булды.

Шөреп, йөрәге леп-леп типкәнне сизеп, телсез-өнсез калды.

— Сез Регинаны көтәсезме? Ишеттем, ишеттем. Иптәш кызым өчен бик шат.

Шөрепнең «бәлки сезне көтә торганмындыр, Регина белән безнең болай гына, эч пошканнан гына», дип ярып саласы килсә дә, берни әйтә алмады, теле әйләнмәде. Бераздан гына исемен атарга кирәклекне аңлады.

Биючеләрдә кабул ителгән гадәт буенча, кыз тезләрен җиңелчә генә чүгеп:

— Зөлфия,— диде. Шүрлектәге китапларын алып сумкасына салды да: «Ярый, исән булыгыз, уңышлар сезгә!»— дип, бүлмәдә тәмле хушбуй исе, исәренгән ирне калдырып, чыгып китте.

Бу фани дөньяда үзенә гашыйк булган бәхетсез ирләр исемлегенә тагын бер бичараның өстәлүеннән хәбәрдар түгел иде Зөлфия. Аңа ни? Тиләләрне чәчеп үстермиләр.

Регинаның тулы күкрәгенә талымсыз башын куеп йоклау бәхетенә ирешкәч тә, Шөреп Зөлфияне миеннән чыгарып ташлый алмый интекте. Билчән кебек ябышты, төшләренә кереп бимазалады, саташтырды, тилертте шайтан кыз. Ник күрде ул аны теге вакытта! Әле генә әнисенең сөтен туйганчы имгән кәҗә бәтие төсле, тулай торакның шыксыз бүлмәсенә сикеренә-сикеренә килеп кермәсә шунда. Аның дөньяда яшәве, һава сулавы, ипи ашавы турында Шөреп белмәгән дә булыр, кирәге юк, поты бер тиен иде. Хыялында ул пот белән ботны бутады. Күңеле булып китте кыска гына мизгелгә.

Шашынып яратып йөргән Регинасы хәзер артык матур күренми, аякның нечкәлеген күкрәкнең муллыгы каплый алмый икән. Аның белән үбешкәндә дә, Зөлфия иреннәренең тәмен, ләззәтен тойгандай булды.

— Нәрсә дип тынып калдың?— диде Регина, тәмәкедән утырган калын тавыш белән.

Тыелган уенда тотылган баладай, Шөреп югалып калып, җилкәләрен биетеп алды. Нәрсә дип җавап бирсен ул. Кибән өстендә яткан этнең кайгысы сөяктә икәнне әйтә алмый ич.

— Нишләптер күңелсез булып китте.— Арзанлы ялганлауга башы җитте:— Әбине искә төшереп, аны сагынып куйдым әле.

Регина усал гына елмаеп алды. Ул әтисеннән күзәтүчәнлеккә, вактөякне хәтердә калдыруга һәм үҗәтлеккә өйрәнгән иде. Аралары күренеп суынмаса да, ефәк кортының читләшү җебен тукып ятканын сизенә иде ул. Сәбәбен дә белә: абзыйның күзе Зөлфиягә төшкән. Тулай торакка, дөресе бүлмәләренә, Шөреп анда утырганда кергәнен белә. Әлфия дә әйтте, үзе дә урамда очратты кызны, чыгып барганда. «Нәүмизләнмә,

бандитым, сиңа тәтеми ул барыбер. Мин дә күбрәк әле сиңа»,— дип әйтмәкче булды. Үзен-үзе кызганып куйды. Тавыш чыгарды.

— Син, хәшәрәт, Зөлфиягә өмсенеп йөрисеңме? Өстерәл артыннан, Квазимода кебек бөкерен чыкканчы. Маңгаеңда җиде йолдыз яндыра алсаң да, ул сиңа карамаячак. Миңа да кирәген юк, үләт!

Шөреп зур авырлык белән араларындагы бозны эретүгә иреште, гафу үтенде, антлар әтте. Һәр хәбәр сунарчы пычагы кебек ике яклы була. Берәү өчен көенеч, икенче бер зат өчен сөенеч булырга мөмкин.

— Зөлфия кияүгә чыккан икән шыпырт кына. Инде күптәннән, ди.

— Чынлапмы? Кемгә?

— Сиңа түгел инде.

— Миңа бик кирәге бар. Чәнчелеп китсен!

Түзә алмады, барыбер соравын кабатлады:

— Кемне сайлады инде синең группадашың тормыш иптәше итеп?

— Сәет исемле бер абзыйны. Мафия башлыгы, ди.

Шөрепнең үкчәсе янды. Колаклары тонды. Гарьлектән тыны кысылды.

Зөлфия белән йоклау түгел, күрешү, үбешү турындагы хыяллары да чәлпәрәмә килде дигән сүз. «Кара син аны Паханны, нинди яшь кызны, гүзәл сынны кулга төшергән бит. Кеше өчен ясак түләп, төрмәләрдә черемәгән шул ул. Баеп яткан! Акча, байлык, һәр нәрсәне хәл итә. Кара «Волга»ны күрүгә, кызларның күзе-башы агуланган балыкныкы төсле миңгерәүләнә».

Зөлфиянең Сәетне чын күңелдән ярата алуына ышанычын меңнән бергә дә чыгармаган Шөреп кызны үзенчә җәлләп куйды. Ихластан иде ул бу мизгелдә. Икенче бер фикер килде башына: «Зөлфияне күреп сөйләшеп карарга. Үзеннән шактый өлкән кеше белән йоклап йөрергә ризалашкач («кияүгә чыкты» диюләре Регина фантазиясеңдер), бәлки, Сәнгаттән да баш тартмас. Зөлфия белән җәһәннәм читенә чыгып китәргә, гомер буена колы булып, чәче белән идән себереп яшәргә, сакчы эт кебек янында ятарга риза. Әлбәттә инде, кочаклашып йоклап туйганнан соң... Хыялый дөнья ләззәтендә йөзде Шөреп. Аяклары, хуҗаларын тыңламыйча, мәдәният институты янына алып килде. Игенне әрәм иткән боз шикелле, күңеленә шом китереп сукты. «Зөлфия урынына Регина килеп чыкса, сине каршы алам, берәрсе белән чуалмыйсыңмы, дип котылып булырмы, мент кызы бик сизгер, хәйләкәр, мәче мыегы бар диярсең үзендә. Пахан сөйрәлчеген үлепләр яратса да, Региңадан колак кагу аның ниятенә керми. Һавадагы торнага ышанып...»

Зөлфияне туры китерү җиңел түгел икәнен дә белә. Расписаниеләрне карап йөри алмый. Бердән, аңламый, икенчедән, курка. Шөрепнең үҗәтлеге үзенә җиткән иде. Барыбер очратты аны. Институт янында түгел, ә тулай тораклан чыгып барганда. Дус кызлары янына кергән иде, күрәсең.

Шөреп ерактан таныды кызны. Сокланып туя алмады. Рәсемнән төшкән, диярсең. Хур кызлары кебек матур. Килешмәгән җире юк. Кайда ясыйлар икән мондый чибәрләрне? Йөрүен кара әле син аның, хан кызы диярсең! Башын горур тота, аркасы туры, гәүдәсе сәхнәдәге биюче һинд кызларыныкы төсле уйнап тора. Сүз катмыйча гына калган булса шунда... Төрмә этлеге җиңде.

— Сәлам, Зөлфия,— диде куып җитеп.

Кыз тавыш килгән якка борылып карады, күз нурын артык әрәм итмәде, танымады. Ирләргә күтәрелеп карарга курка иде ул. Нәрсәдер өмет итеп, бәйләнә башлыйлар. Ә бу әрсезе татарча исеме белән мөрәҗәгать итә. Күргән-белгән кешесе түгел бугай.

— Исәнмесез,— диде дә, баруын дәвам итте.

— Танымадыгыз бугай? Мин...

Егет исемен, кем булуын шартлатып әйтмәкче иде дә, соңгы мизгелдә үзен тыеп кала алды. «Мин Сәнгат — Регинаның егете, сине яратам дип әйтсенме? Шахмат уенының нәтиҗәсе алдан билгеле булачак. Фил белән

фирзәне бутаган өчен аны бәйгедән төшереп калдырачаклар, бәреп чыгарачаклар».

— Мин..., дип тотлыгып торды да бер тын белән әйтеп салды,— озатып куярга рөхсәт сорамакчы идем.

Кыз мондый арзанлы сагызларны күп чәйнәп төкергән бугай. Югалып калмады:

— Рәхмәт инде. Тик минем озатучым бар. Гафу итегез.

— Башка вакытта бер очрашсак?

Зөлфия бәйләнчек ир ягына бик үк җылы булмаган карашын атты. Яшькелт яшен уты Шөрепне үтәли яндырып үтте.

— Әнә теге кара машинаны күрәсезме?

— Күрәм,— диде Шөреп, әле берни дә аңламыйча.

— Анда минем ирем утыра. Мин Сезне таныштыра алам.

Сәнгат куркытылган ат кебек, бөтен көчен аягына төшерде. Шып туктады. Паханның йодрык көчен ул хәтерли. Тозлап-борычлап сүгенәсе, матур артны авыр сүзләргә батырасы килсә дә, югалып калды. «Үкенерсең әле»,— дип кычкырып калудан узмады.

Шөреп чирканчык үчен алу хыялы белән яшәсә дә, каргышы үзенә төште. Хагы: бәхетсезлекләренең башы шул очрашудан тәгәрәп китте...

## 15

Авыл «туе» онытылып та җитмәгән иде әле. Зөлфиянең әнисе Рәмзия ханым Казанга килеп төшмәсенме. Исәбе: араларны ачыклау, кияүне урынына утырту, кызны... Менә бу мәсьәләдә анык карары юк иде әле. Очрашулары болайрак булды.

Ир белән яшь хатынның машинадан төшеп, кулга-кул тотынышып, чырк-шыр көлешеп, өченче катка күтәрелеп барышлары иде. Тышкы ишек төбендә, аларны көтеп булса кирәк, урта яшьләрдәге бер хатын, әрле-бирле йөренеп тора. Кулында теге вакытта Зөлфияне поездга озатк андагы, Сәеткә таныш сумка.

Кызның шатлыктан: «Әни, әни, нихәл, килдеңме?»— дип кычкырып җибәрүенә, сырпаланып куенына керүенә чаклы ук, хатынның нәкъ менә аларга мөнәсәбәте булырга тиешлеген шәйләп алган иде Сәет.

Ишекне ачып, бүлмәгә үткән, чишенгән арада Сәет: «Өенә кертмәсә дә, үзе килгән, максаты ике генә булырга мөмкин: йә килешергә, йә кызны алып китәргә»,— дип фикерләп алды.

Өстеннән курткасын салгач, ананың күп ягы белән Зөлфияне хәтерләтүенә игътибар итте хуҗа. Тик гәүдәсе тулырак, йөрүе салмак, аяклары идәнгә тия.

— Ягез, бер дога кылыйк!

Утырышып, битләрен сыпырган булдылар. Ана кеше йөзенә миһербансыз усаллык, явызлык чыгарырга, тавышына килешмәүчән кырыслык иңдерергә тырышып, «мин монда беркем түгел, вакытлы кеше» дигәндәй, артлы урындыкның кырыена гына гәүдәсен төртеп, башлам кәлимәсен тышка чыгарды.

— Сезне кем диим инде?— диде Сәет ягына бакмыйча гына.

— Әни, Сәет була ул, минем ирем.

— Синнән сорамыйлар. Тик тор!

— Исемемне Зөлфия дөрес әйтте. Сәет Сакманов булам мин, Рәмзия ханым. Ниятебез гомергә бергә булу. Рәсми язылышкан, Зөлфиянең туган авылында мулладан никах укыткан ир белән хатын инде без. Сез бердәнбер кызыгыздан качып киткәннәр дип, без шәригать кануннарын бозмадык.

— Авылда бу сүзне бик кулланмасалар да, ханым дип дөрес әйттегез. Апа, булмаса әби дип башымны катырырсыз дип шикләнеп килгән идем. Безнең яшьләр бер чамадыр әле?

— Юк, әнкәй, син Сәеттән ике яшькә олырак. Ана кырык өч, сиңа кырык биш. Икегез дә бер айда тугансыз. Явыз арысланнар, р...р...р...— дип шәрехләп бирде Зөлфия, әнисен әле һаман шаярта, дип белеп.

Кызының аңлатмаларын колагына да элмичә, Рәмзия үзенекен тукуын белде:

— Минем кызым кебек кенә балалагыгыз да бардыр инде. Качып йөрмәсәгез, алимент та түлисездер. Оятсызның, җәһәннәмгә керсә дә, йөзе кызармас, диләр.

Әнисенең сүзне ваклап-саклап, инәләп-җепләп киеренке төстә алып баруыннан гаҗизләнә башлаган Зөлфия әле бу юлы да җавапны үзе бирергә итте.

— Әнкәй, аның кызына унсигез яшь. Уфада, әнисе, үги әтисе белән көн күрә. Фатиры бар. Институтның икенче курсында укый. Ихтыяҗ булса, киләчәктә дә ярдәмнән ташламабыз. Иеме, Сәет?

— Кеше күзенә күренергә оят,— дип, хатын әле җыерчыклары артык сизелмәгән куллары белән битен каплагандай булды һәм тагын да явызланып өстәде:

— Хәрам мал түгелме бу бала сезгә? Ничек уйлыйсыз?

Сәет, еллар дәвамында чарлаган тышкы битарафлык битлеген саклап, әүвәл шаяртырга көч тапты:

— Берәүгә хәрам килешә, икенчегә хәләл дә килешми, диләрме әле?

— Кызым, син дә тәүфыйксыз, оятсыз бала булып чыктың. Көтмәгән идем.

Бу юлы инде Зөлфия матур куллары белән алсу битен каплап, күгелҗем-яшькелт күзләренең суын тышка саркытты.

Сәет тә түзем тәкате бетеп, өлгергән кабак кебек шартлады. Авылдан, кызның әти-әнисенә ачуы килеп, аларны берниндн әдәп, гадәт тәртәсенә сыймый торган, урта гасырлардагыча кыланышлары өчен гафу итә алмаган Сәетне Рәмзиянең, укытучы булып йөргән кешенең, кызын шулай рәнҗетүе тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Ничек әле сез газиз балагызны малга тиңли аласыз? Минем хатынымны мыскылларга, рәнҗетергә кем хокук биргән сезгә? Мондый тонда сөйләшсәгез, бушатыгыз безнең квартираны! Сез өегезне бикләп качтыгыз, минем дә сезне куып чыгарырга тулы хакым бар. Кунак ашы — кара каршы булырга тиеш.

Педагог әнисенең үзен базар хатыннарыдай тотуыннан гарьләнгән Зөлфиянең ояты битенә чыкты, чигәләрен бәреп чыгардай булып кан басымы күтәрелде, һәрвакыт җылы, дымсу ирennәре агачта эленеп калган көзге яфрактай калтырана башлады.

Шулай да аның яшьлеге көчле, нервылары таушалмаган иде. Дөньялыкта үзе өчен иң кадерле ике кеше арасында ул гына арадашчы була, ике арысланны ул гына килештерә ала ич. Чит илдән гуманитар ярдәм килмәячәк. «Әни бик итагатьле кеше иде, аны әти — кычыткан чыпчыгы — шулай боргычлап, котыртып җибәргән. Тиле».

— Әнкәй, җитте сиңа! Сәет, син дә кызма!

Ана тәмам рольгә кереп беткән, бик теләсә дә, туктала алырлык түгел иде инде.

— Кызым, киен! Әтиең алып кайтырга кушты.— Сәет ягына борылып өстәде:— Әдәпне, кияү димме инде, базарда сатып алып булмый. Аның төбе — яхшы гадәт. Сездә, ничектер, белмим. Безнең якта кызны башкодалар җибәреп, соратып алалар. Ул — теләсә кем урлап китә ала торган колхоз милке түгел. Бердәнбер кызыбыз.

Бүлмәдә үлем тынлыгы урнашты. Кайсыдыр почмакка, киң караваг янсә аксыл тышлы диван төбенә, бөтен бүлмәне үзенә сыйдырып торган көзге астындагы комодка яшерелгән бомба хәзер шартларга, һәммәсен күккә очырырга тиеш иде. Барысы да шуны көтте.

Өлкәннәр яшь кешегә үрнәк күрсәтә алмый интеккәндә, яшь, җитез, таушалмаган акыл ярдәмгә килде. Зөлфия ирен килеп кочты да: «Бар,

матурым, теге бүлмәгә кереп, газеталар караштыр, әни юлдан, арыган, безнең Шәмәрдән поездында радиация көчле»,— дип, Сәетне икенче якка озатты.

Кыз тәрбияви эшне ни рәвешле алып баргандыр, кистереп әйтүе кыен, әмма нәтиҗә озак көттермәде. Ярты сәгатьтән Сәетне ике ханым чәйгә чакырдылар.

Шәһәр һавасының начарлыгы, поездларга бәянең артуы, пешекчеләрнең ипине сатуга чиле-пешле чыгаруы турында фикер алышканнан соң, ана кеше әйтеп куйды:

— Гафу итәрсез инде. Кыздырганда кыза торган гадәтем бар. Тигез гомер итегез. Кызым «миңа башка берәү дә кирәкми», дип торганда мин нишли алам инде.

— Әти кеше белән уртак тел таба алмабыз, ахры. Асылын ачыкламый аш бирмә, атасын белми кыз алма, дигәннәр дә, оныгы тугач, йөгереп килеп җитәр әле, иеме, Зөлфия,— дип кенә өстәп куйды Сәет. Чүмәлә өстенә куелган бастырыкка каршы килүче булмады.

— Әни, тагын берне эч әле. Балына сузыл, җимешен ал,— дип, Зөлфия әнисен кыставын белде.

Ана ял итеп, иркенләп туарылып, өчне кунып китте кияве белән кызында.

Зөлфиядән, «ничек итеп үзеңнән егерме бер яшькә олы, берничә тапкыр өйләнгән, балигъ балалы иргә кияүгә чыктың», дип сорасалар, тәгаен генә җавап бирә алмас иде. Сәет, көчендә булса да, талчыкканлыгы сизелә, җыерчыклар муен, маңгай тирәсендә елгачыкларын сыза башлаганнар.

— Ун елдан ни булыр?— дип сораган иде әнисе.

— Ун елдан аңа илле өч, ә миңа инде утыз ике булыр,— диде кыз.

— Ә егерме елдан соң?

— Ике дистә ел яшисе бармы, юкмы әле, әни. Миңа кырык ике, ә аңа нибары алтмыш өч булыр. Тәрбиядә яшәгән ирләр алтмыш өчтә егетләр төсле керт-керт басып йөриләр. Кырык ике яшьтә бала табарга ярамый хатын-кызга. Картлык ишеккә шакый. Сәет әле мине ташлап, яшьрәккә өйләнеп, аны да туздырырга мөмкин.

Җитди итеп өстәп куйды:

— Әни, яратам мин аны, беләсеңме!

— Яше шут с ним инде. Атаң да миннән сигез яшькә олы. Аны бит мафия, диләр. Казан Мафиясе башлыгы, узаман, диләр. Куркам синең өчен!

Педта укучы Лилия Сәет турында юлбарыс, башкисәр, ике кесәсендә ике мылтык йөртә, Казан урамына танк белән генә чыга, дип, авыл халкына тагын әллә ниләр сөйләп бетергән икән.

— Ул көнләшүдән гайбәт тарату юлына баскан. Сәет аңа «киттек», дип күз кысса, эчке ыштанын кияргә онытып, артыннан чыгып йөгерер иде әле. Әнием, беләсең килсә, мафия хәзер мактау сүзе ул. Булган, житез, елгыр, тормышта үз урынын тапкан кешеләрне, берсе кызыгып, икенчесе көнләшеп, «мафия» дип атый. Ә Сәет мафия түгел. Язылышканчы документын карадым. Чикләнгән җаваплылык белән эшләүче уртак предприятие директоры ул. Мебель эшләп чыгаралар. Сораганнарга шулай аңлат.

Җан дусты Әлфия Сәетне хуплады, иптәш кызының сүз, абруй саклау, дип тилерү юлына басмыйча, ирнең өенә кайтып, бергә яшәп китүләренә дә уңай карады.

— Ялган әхлак. Кешедән оялу татар хатыннарына болай да ачылып китәргә ирек бирми. Әнә Ижау кызы Наташа ир-ат белән йоклап алуга ашау-эчү, тышка чыгу кебек гадәти бер шөгыль итеп кенә карый. Шуңар да ул һәрвакыт шат күңелле. «Икеле» алса да, исе китми. Икенче-өченче кергәндә, барыбер уңай билге куя ич укытучы, ди. Минем үземә дә өлкән ирләр ошыйрак,— диде Әлфия кырт кисеп.

— Ни өчен алай дисең?

— Хатын-кыз тән ягыннан гына түгел, акыл сихәтеннән дә иртәрәк өлгерә. Яшьтәш егетләрнең күбесе боламык булып кала. Аннары сыек. Кызык түгел алар белән. Үз фикерләре юк. Башкаларны, урамны, кешедән отканны кабатлыйлар. Мин сүзләрен бурычка алып сүгенгән егетләрне яратмыйм. Өлкәнрәкләр бу дәрәҗәгә төшми. Сүзләре дә саллы була. Ахыр чиктә,— дип дәвам итте Әлфия сүзен,— тормышны күбрәк белгән кеше йоклаганда өстеңнән төшкән юрганыңны өстеңә ябарга мөмкин. Салкын тимәсен, дип. Ә яшьтәш? Тартып алып, үзен каплаячак!

— Әлфия, үзеңнең элеккеге романнарың турында Мисхәткә сөйләдеңме?

Күңелен тупсага утырту өчен Зөлфиягә акыллы, өлгер дустының фикерен белү бик мөһим иде.

— Мисхәт күлгә җәлпәк ташлар атып карады. Янәсе, минем ирләр белән йоклаганым бармы? Шул юньсезне көтеп торган, ди.

— Соң?

— Мин җавап урынына булган бер хәлне сөйләп бирдем. Өйләнергә җыенган бер егет олы яшьтәге күршесеннән сорый имеш: «Абый, абый, сиңа кияүгә чыкканда, хатының кыз идеме? Әйтә алмыйм шул, энем, ди теге, мин хатынны күрше авылдан алдым». Әрекмән колак Мисхәтем берни аңышмый калыр.

— Ну, син даешь, Әлфия! Нигә шулай аны интектерәсең?

— Нинди мәгънәдә, дустым?

— Үзең белән янәшә салмыйсың?

Әлфия, терекөмештәй җанлы күзләрен елтыратып, гади, аңлаешлы йомгак ясады.

— Өйләнгәч өлгерер. Юкса, күңеленә болай гына ужым сугып йөрү уе керер. Мин аңа кияүгә чыгарга булдым!

Әлфия белән сөйләшү Зөлфиягә көч өстәде, ышаныч бирде. Ул үзенең Сәеттән башка затны шулай ярата алмаячагына инанды.

*Ахыры бар*



Илдар
Юзеев

## УТ ЭЧЕНДӘГЕ ЧӘЧӘК

### Мин нигә гафил булдым?

Комда — ишәк,
Чүлдә — дөя,
Эш аты йә фил булдым.
Адәм булып тусам да мин,
Илемнән гафил булдым.
Илдә — урыс,
Чүлдә — үзбәк,
Йаурупада — фин булдым,
Татар булып тусам да мин,
Телемнән гафил булдым.
Болгарда — гөл,
Рәсәйдә — кол,
Казанда мин көл булдым,
Җиде бабамнар төзегән
Дәүләттән гафил булдым.
Җырда — бөек,
Моңда — боек,
Дастаннарга тиң булдым,
Алыплардан тусам да мин,
Тарихтан гафил булдым.

Әйтерме бер күреп, җиһан:
«Бабаңнарга тиң булдың!»

*1992.*

* * *

Ахры, мин дә сезнең нәселдәндер,
Шуңа бигрәк якын итәмдер.
Көзен өзгәләнәм, саргаямын:
Таш өстендә үскән юкә мин.
Сездән аерса тик аерадыр
Боек йөзем, язгы ютәлем.
Кыршау миңа — өйнең дүрт дивары:
Таш өстендә үскән юкә мин.
Мин бит адәм, нигә бу җанымны
Табигатьтән мәхрүм иткәнмен?..
Башларыннан сыйпыйм, хәлен аңлап
Таш өстендә үскән юкәнең.
Әнкә-табигатьтән аерылган
Ятим бала сыман үтәмен.
Авыр кагылмагыз... Кызганмагыз!
Таш өстендә үскән юкә мин!

*1995.*

* * *

Ычкынырмын акылдан дип,
Уйланудан куркам,
Газапланып йоклап китсәм,
Уянудан куркам.
Соңгы сулышымдыр, бәлки...
Тын алудан куркам,
Вөҗданым керсез булса да,
Сыналудан куркам.
Хәерлегә булмас бу дип,
Куанудан куркам,
Ширпы уты күргәндә дә
Гел янудан куркам.
Мактап тәмам исертүдән —
Сыйланудан куркам,
Нахак сүзләр ишетүдән —
Кыйналудан куркам.
Дөреслектән читкә таба
Юл алудан куркам,
Аклау өчен сәбәп табып,
Юанудан куркам.
Куркуымнан курыкмыйм һич,—
Кыланудан куркам,
Үз юлымнан каерылып,
Югалудан куркам...

*1993.*

* * *

Аңа хәзер берни кирәк түгел,
«Саумы?» диеп бер сүз дәш аңа...

Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.
Өмет өзәргә дә күптән вакыт,
Ярың — янда, үзең — яшь ана.
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.
Очрашулар башка насыйп булмас.
«Бәхил бул...» дип, бер сүз дәш аңа...
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.

*1992.*

## Янган чәчәк

Кара җаннар
Үч йөрттеләр,
Төнлә өйгә
Ут төрттеләр.

Кайда минем
Янар чәчәк,
Күзләремә
Карар чәчәк?

Исә зәһәр
Җилләр генә,
Нигеземдә —
Көлләр генә...

Янган бакча,
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.

Хәлсез башны
Ташка салдым,
Үзем әле —
Исән калдым.

Янган чәчәк,
Көйгән чәчәк,
Мин өзелеп
Сөйгән чәчәк.

Йөзләремдә —
Көл төсеме?
Янган чәчәк
Шәүләсеме?

Янган еллар —
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.

Ут — тышымда,
Ут эчемдә,
Янам — яшим
Ут эчендә.

Янган гомерем —
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк.

Юк, барыбер
Калкырмын мин,
Көл эченнән
Балкырмын мин.

Булсам да мин
Янган чәчәк,
Ут эчендә
Калган чәчәк...

Юк, сулмамын,
Балкырмын мин,
Таш астыннан
Калкырмын мин!

*1993. Март. Займище.*

* * *

Сизәм ич мин: зур кайгың бар
Эчеңдә...

Тышка чыкмый, бик тирәндә
Хисең дә.
Елмайган да, шатланган да
Буласың.
Бүлмәндәге гөлең кебек
Суласың.
Баш имисең, әмма боек
Күзләрең.
Күрәм ич мин кара хәсрәт
Эзләрен.
Шәлъяулыгың каплый боек
Яменне.
Ничек итеп җиңеләйтим
Хәлеңне?
Мин дә андый мәлне аңлау
Яшендә.
Ачыл, бәгырь, серләреңне
Яшермә.
Йөзләреңне шәлең белән
Каплама,
Газабыңны гел үзеңдә
Саклама.
Кил яныма, әйдә болай
Килешик,
Авырлыкны икәү бергә
Бүлешик.
Җаным ачык: кеше хәлен
Тоярлык,
Газабы да, авыр сер дә
Сыярлык...

*1995, сентябрь.*

* * *

*И. Надировка*

Бу тормыш — гаҗәеп җыр сыман —
Күкләргә үрмәләп менәсең,
Моңлы бер җебенә тотынсаң.

Бу тормыш — серле бер әкият —
Сакланса зур өмет-хыялың,
Күммәсә җаныңны вак-төяк.

Бу тормыш — авыр бер табышмак —
Тапмассың җавабын, китәрсең
Гомереңне шуңарга багышлап...

*1995*

* * *

Олы җанлы шагыйрь-әдипләргә
Үз илендә яшәү читен лә.
Тукай кебек яшьли гүргә китә
Йә Исхаки кебек чит илгә.
Хакыйкатьне төшендерә алмый,
Кадер-хөрмәт күрми китәләр.
Исән чакта үзен аңламаган
Халыкны да бөек итәләр.

*1995*

* * *

*Л. И.га*

Кайчак ямансулап,
Бер көрсенеп куям.
Юк, тормыштан түгел,
Үз-үземнән туям.
Кайчак мин үземне
Бик тә ялгыз тоям.
Кешеләрдән түгел,
Үз-үземнән туям.
Кайчак гомеремне
Бик кызыксыз тоям.
Юк, яшәүдән түгел,
Үз-үземнән туям.
Кешеләргә китәм...
Вак хисләрне тыям.
Үз-үземне көчле,
Кирәк итеп тоям.
Тормыш серле, кызык...
Мин дә шунда сыям.
«Әле дә яшим!» диеп,
Бер сөенеп куям.

*1995*

* * *

*Гази Кашшафка*

Мин ышанып серләремне ачкан
Берәү мине саткан.
Әйтте миңа шул чак бер остазым:
«Дусларыңнан саклан!»
Юк, куркак та түгел, кыю-кыю

Бәхәсләрдән качмыйм.
Әмма кайбер серләремне хәтта
Үземә дә ачмыйм...

*1995*

* * *

Авырлыклар тулы бу тормышта
Бер җиңеллек булсын дисеңме...
Бик иркәләп, бик кадерләп әйттең
Назга тансык минем исемне.
Шул сүзеңнән канатландым әле,
Җанда тоям рәхәт җиңеллек.
Бу дөньяда яшәү бик-бик авыр,—
Синең белән яшәү — җиңел бик.
Әйдә әле үпкә, ачуларны,
Хәтер калуларны онытып,
Салкын мәңгелектә югалганчы,
Яшик бер-беребезне җылытып...

*1995*

## Беренче һәм соңгы әйтер сүзем

Бер ялгызым гүя Галәмемдә.
Сүнеп бара инде шәмем дә.
Бер шигырьлек кенә каләмем дә,
Арган-талган инде тәнем дә.
Бер шигырьлек кенә каләмемне
Ай нурына манармын да мин
Сискәндереп таңда уятырмын
Йолдыз булып янармын да мин.
Беренче һәм соңгы әйтер сүзем
Бер шигырьлек кенә каләмдә.
Үзем сүнсәм, мәхәббәтем балкыр:
Дәвамнары аның Галәмдә...

*1995*



# Фәнис Яруллин

## Шушы килеш яратыгыз

Аунап үстем авылымның туфрагында,
Башак җыйдым язын-көзен кырларында.
Ятсам-торсам һаман да шул бер үк нәрсә —
Туйганчы бер ашау иде уйларымда.

Кәлҗемәгә тамак туйса — шатлык иде,
Ипи ашар өчен әле хак юк иде.
Арба тарттым күз яшьләрен ялый-ялый,
Кызлар сөйдем чалбарларны ямый-ямый.

Үлән ашап үселсә дә, шөкер әле
Сарык булып калынмады дөньясында.
Бер булса да очкын булдым учагында,
Бер булса да дулкын булдым елгасында.

Ләкин тормыш барыбер үз эзен салды,
Янган чакта күңелләрдә сөрем калды.
Чайкалсам да елгаларда дулкын булып,
Юып бетерә алмагандыр әле җанны.

Әгәр мине ап-ак диеп уйласагыз,
Ул уйларны күңелләрдән таратыгыз:
Мин заманнан һәм үземнән шәбрәк түгел,
Яратсагыз шушы килеш яратыгыз.

*1995*

## Сине җиңәр өчен мин бар җирдә

Яшьлек әйтте: бу дөньяда берәр
Мине җиңә алыр көч бармы?
Телим икән — таулар күчерәм мин,
Телим икән — чөям ташларны.

Күкрәгемдә ярсу диңгез көче,
Күзләремдә яшен утлары.
Ялларыннан тотып ега алам
Чабып барган җитез толпарны.

Нинди генә эшкә тотынсам да
Җиңеп чыгам, кире чигенмим.
Буйсындырам, җиңәм, ләкин үзем
Һичбервакытта да җиңелмим.

— Тукта, тукта! — дигән аңа картлык,—
Кайнарланма әле ул чаклы.
Күргәнем юк әле минем һичбер
Мәңге җиңәлмәслек бер затны.

Дөнья фани. Ә дөньяда, дустым,
Һәр батырны җиңәр әмәл бар.
Сине җиңәр өчен мин бар җирдә,
Мине җиңәр өчен әҗәл бар.

*1995*

## Игезәкләр

Игезәкләр туды Җиргә,
Икесе дә сау-сәламәт.
Бу гүзәл игезәкләрнең
Берсе — Яз, берсе — Мәхәббәт.

Заман ничек болганмасын,
Туа болар һәрбер елда.
Яз булгач, Мәхәббәт булгач
Димәк, яши әле дөнья.

*1995*

* * *

Матур кызга гашыйк булу савaптыр,
Ашкынулар — йөрәкләрдән җавaптыр.
Кабыналмасаң чибәрләрне күреп тә
Газаптыр ул, ай-һай, авыр газаптыр.

Берүк, Тәңрем, салма мондый газапка,
Ахыргача йөзим әле савапта.
Сөю-гыйшык гөнаһ булса әгәр дә
Мин әзермен моның өчен җавапка.

*1995*

* * *

Күккә ук атсаң
Бер гаепсезнең
Башына төшәр.
Җиргә ут яксаң

Бер гөнаһсызның
Табаны пешәр.

Ук белән Утның
(һәркем беләдер)
Күзе юк аның.
Шуңа күрә дә
Безгә текәлгән
Күзе дөньяның.

*1995*

* * *

Китәсе килә кайвакыт
Еракка, бик еракка —
Тормыш гел шатлыктан торган,
Кайгы-хәсрәтсез якка.

Менәсе килә кайвакыт
Биек-биек үрләргә —
Тормышның түбәнлекләре
Күренмәслек җирләргә.

Югаласы килә кайчак
Эреп алсу таңнарда.
Үтте инде, үтте вакыт
Кабат юллар сайларга.

*1994*

## Ашыгыйк

Актыкны сулышны алганда
Уфтанмас өчен җан ачынып —
Кулларда егәрлек барында
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Күтәрик егылган гөлләрне,
Матурлык калмасын басылып.
Холкыбыз бик сабыр булса да
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Бумасын нәфсебез безгә баш,
Без аңа үзебез баш булыйк.
Яманлык җиңелсен дисәк без,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

Ходайның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.

*1994*

## Шагыйрь бәхете

Кулга кәгазь-каләм алсам
Өстәлә дәрт, арта көчем.
Табыла сүзләр, агыла хисләр,
Кушылып китә иртә-кичем.
Онытыла тормыштагы
Җитешсезлек, рәнҗү-үпкә.
Ак кәгазем — ак канатым
Алып менеп китә күккә.
Ачыла күкнең капкалары,
Исеп куя йолдыз җиле.
Монда күкләр бер болытсыз,
Монда фәрештәләр иле.
Монда кушыла көн белән төн,
Монда кушыла барлык төсләр.
Агыла җиргә йолдыз нуры,
Сузылып кала ап-ак эзләр.
Карап тора Ай һәм Кояш
Сокланып бу хозурлыкка.
Китә шунда җан пакьләнеп,
Дөнья гаме чыга юкка.
Булмаса мондый мизгелләр
Шагыйрь җаны үләр иде.
Сокланучы бетсә әгәр
Йолдызлар да сүнәр иде.

*1994*

## Сандугач тыйнаклыгы

Сандугач сайрый өздереп,
Җыры сарыла җанга.
Карыйм, карыйм — күрә алмыйм,
Кайда соң үзе, кайда?

Керәм урманнар эченә
Күрмәмме диеп аны.
Юк, күралмыйм — кошым китә
Моңга күмеп дөньяны.
Үзен күрсәтүдә түгел,
Җырда аның шатлыгы.
Булсачы кешеләрдә дә
Сандугач тыйнаклыгы.

*1994*

## Анам теле

Татар теле — анам теле,
Иң борынгы бабам теле.

Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.

Ничә гасыр чарлангансың,
Матурайган, яңаргансың.
Халкыбызның күңеленнән
Җыр алгансың, моң алгансың.

Изелгәнсең, тапталгансың,
Пычратсалар — пакьләнгәнсең.
Милләтемнең үлмәс җанын
Син үзеңдә саклагансың.

Сиңа безнең язмыш сыйган,
Син кайгы һәм шатлык теле.
Татарымны татар иткән
Беренче һәм актык теле.

Анам теле — телләр теле,
Милләтемнең бердәнбере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга — без дә тере.

*1995*

* * *

Зур дәрьялар кичтем диеп
Тынычланма, күңелем.
Алда тирән диңгезләр бар,
Калуың бар күмелеп.

Күкләргә менгән чакта да
Шашынма, җан, ул чаклы.
Күккә менеп җитеп булмый,
Күкләр бит җиде катлы.

Мең сынау аша үтсәң дә
Гел бер уй булсын анда:
Әле тормыш сынавының
Иң авырлары алда,
Иң авырлары алда!

*1995*

## Хаҗга барган кебек саваплы

Авырайдым, кайнарлыгым бетте,
Нишләдең соң әле син, йөрәк?
Авылыма кайту миңа хәзер
Хаҗга барудан да читенрәк.

Чакыралар, ә мин уйлап ятам,
Килә алмыйм ныклы карарга.
Машинам да юкса әзер тора
Выжт иттереп чыгып чабарга.

Моңа кадәр юләрлегем йөртте,
Ярдәм итте дөнья урарга.
Яраларга туфрак сибә-сибә
Әзме йөрдем инде юлларда.

Ә хәзер юк, юллар ашкындырмый,
Түшәгемнән килми кубасым.
Җан талпынса, тәнем разбой сала:
«Мине кая алып чыгасың?»

Беләм юкса, беләм, кайту кирәк,
Авыр булса да юл ничаклы.
Туган авылыңа кайту бит ул
Хаҗга бару кебек саваплы.

*1995*

* * *

Кайларда йөртми кешене —
Язмыш дигәнең кызык.
Чыкмас идең авыр юлга,
Тарта җыясы ризык.

Тарта эчәсе суларың,
Тарта сулыйсы һаваң.
Барасың табышлар эзләп
Югалтуларга табан.

Кайда — кадер, кайда — кабер,
Һич белә алмый бәндә.
Шул белмәгәнлек туктаусыз
Куалый: әйдә, әйдә!

Ашкындыра, кызыктыра,
Гүя тылсымлы чәчәк —
Алдап-йолдап, ымсындырып
Йөртә безне Күрәчәк.

*1994*

# ДРАМАТУРГИЯ

## ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ



**Фәүзия Бәйрәмова**

# АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ

Драма 2 бүлектә

(Әсәрдә кулланылган барлык хатлар, тәнкыйть мәкаләләре, шигырьләр үзгәртелмичә алынды.)

Катнашалар:

**Такташ**
**Беренче Гөлчәһрә**
**Ак дус**
**Кара дус**
**Икенче Гөлчәһрә**
**Яшь шагыйрьләр, артистлар, журналистлар, студентлар**

**Вакыйга 1923-1931 елларда Казан шәһәрендә бара.**

## Беренче пәрдә

**1923 ел.**

**Ул заманда шагыйрьләр, артистлар яши торган кунакханәләрнең берсе. Зур бүлмә. Бүлмәдә яшь шагыйрьләр, артистлар, студентлар. Пәрдә ачылганда гөжләшеп нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр. Ак һәм Кара дус бәхәскә катнашмыйлар. Бер читтә шигырь тикшерәләр.**

Яшь артист. Ну, малай, минем сәхнәдә андый хәлне күргән юк иде әле. Ул сәхнә артында янар таулар ут ата, ул сәхнәдә газраиллар, фәрештәләр очып йөри.

Яшь кеше *(бүлдереп)*. Син чамалап сөйлә инде бераз. Очып йөри, имеш. Җырлап, кычкырып тордылар диген.

Яшь артист. Юк идең — дәшмә! Күрмәдең — белмисең! Ә мин әйтәм — очтылар, дим. Ул нәләтләр, ул ялвару... Бу сиңа мич арасында гыйшык-мыйшык... аңлату түгел инде. Бу — Такташ! «Җир у... лары»! Вакыйга күкләрдә бара, җирдә! А... лалар, Адәм балалары... *(Кабил ... укый)*:

Ник мине ул, ник яраткан,
Куймагач юл иркемә?!
Ник минем бәхетемне биргән
Башкаларның иркенә?!

Ант итәм иркем белән, бел!
Әкълимә булыр минем,
Бирмимен мин башкаларга —
Ул минем аллам, динем!

Икенчесе *(чәчрәп торып, Адәм ...ын укый)*.

---

[1] Әсәр Казан татар яшьләре театры тарафыннан 1991 елда сәхнәләштерелде.

Ник тудырдым мин сине?
Аһ ник бала дип асрадым?
Ник сине туган вакыттук
Янган утка атмадым?!
Я ш ь а р т и с т (Кабил булып).
Ник атмадың?!!
И к е н ч е с е *(Адәм булып).*
Көчле утлар, зур тәмуглар
Мәңгелек йортың булыр.
*(Йомшап.)*
Тәүбә ит! Кем сөйләшә ул — куркыныч.
Я ш ь а р т и с т *(Кабил булып).*
Тәүбә!!!
Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!!
Бул тыныч!
Мин табынмыйм ул ходайга,
Ул ходай җәббар, явыз.
Мин табам башка ходай,
Ярдәмчене, бел: ул — кылыч!

Я ш ь к е ш е *(бүлдереп).* Алла, дин, кылыч! Шушы да булдымы революция әсәре?! Соң моннан, чит идеология, буржуалык аңкып тора бит! Кая монда эшчеләр тормышы, кая монда яңалык, кая монда илнең революцион адым белән алга баруы?! Нәрсә, Такташ революциягә каршымени?

Я ш ь а р т и с т. Бу — сәхнә! Шартлылык! Символ! Идея! Аңлыйсыңмы, авыл бәрәңгесе?!

Я ш ь к е ш е. Сәхнә тормышны күрсәтергә тиеш. Сәхнә безнең корыч адымнарны, тирескә баткан аякларны, менә бу мускулларны күрсәтергә тиеш! Сәхнә ул — революция! Дин, мәхәббәт имеш! Кем ул Такташ? Үзе кайсы якта?!

**Каты бәхәс башлана. Шул вакыт сәхнәгә атылып Яшь шагыйрь килеп керә. Кулында — журнал.**

Я ш ь ш а г ы й р ь. Бетергәннәр! Харап иткәннәр! Суйганнар!!!

Я ш ь л ә р. Кемне?

Я ш ь ш а г ы й р ь. Такташны үтергәннәр... *(Башын тотып утыра.)*

**Халык телсез кала.**

Я ш ь а р т и с т *(әкрен генә аның янына килә).* Син нәрсә... Бутыйсыңмы әллә? Әле бүген генә күргән идем бит, исән иде.

Я ш ь ш а г ы й р ь *(журналны суза).* Менә...

**Яшь артист журналны ала. Укый. Эчен тотып көлә башлый.**

Я ш ь а р т и с т. Ха-ха-ха! Бетергәннәр Такташны! Суйганнар! Ну ярып та караганнар! Тел бар безнең татарда! Менә *(укый).*

«Бер мишәр малае төшендә шагыйрь булганын күрде, ди. Күрде дә, ди, йокысыннан зерә дә кинәнеп уянды, ди». Ха-ха-ха! Тукта, «Җир улары» турында да бар монда. *(Укый.)* «Халык та юк иде ди. Үзебез өчен генә уйнамыйк инде, дип, урамнан кем үтеп бара шуны әйдәп, китереп, тамаша иттерделәр, ди». Ха-ха-ха! Менә сиңа Такташ! «Чаян» абзаң үзе пешергән Такташны! *(Укый.)* «Шагыйрь дулап китеп, акны карадан аера алмый — барысын да адәм аңламый торган чеп-чи «алаша» теле белән эт итеп сүккән, ди». Һәм менә мәкаләнең ахыры. *(Укый):*

Тик китә кай чакта кәефең,
Хәкимең булса ишәк.
Бер татарга ят, мәхәббәтсез —
Күсәк һәм килмешәк...

Менә бу мәкалә ичмасам!

**Ак дус килеп, аның кулыннан журналны тартып ала.**

А к д у с. Ә син нәрсә үрле-кырлы сикерәсең? Әле генә Такташны мактап авыз суларыңны корыткан идең бит. Нәрсә бик тиз кайтып төштең?

Я ш ь а р т и с т. Мин нәрсә... Әнә язганнар бит. Кызык итеп язганнар...

А к д у с. Кызык... Нәрсәсе кызык моның. Такташны халык алдында адәм мәсхәрәсе иткәннәр. Соң бит Такташның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйлар!

К а р а д у с *(янына килеп).* Йә, кызма. Бала-чага белән бала-чага булма. *(Журналга күрсәтеп.)* Менә да исең китмәсен. Язган — беткән. Хәзер кемне язмыйлар? Барыбызга да эләгә. Кара, исемен дә тапканнар бит — «Шак-шак шагыйрь булды». Ну, бу «Чаян»ны! Да, катырак әйткәннәр икән шул. *(Укый.)* «Казанга китте дә, ди, үзен бик шәп, эре сатты ди. Казанда сәхнә әсәрләре язу модага кергән чак иде ди. Ул да карт шагыйрьнең нәсахәт юллары буйлап бер «фаҗига» язган ди. Ул нәрсәсен бик шәп, бик шәп дип, сәхнәгә тәкъдим итте ди. Талымсыз татар сәхнәсе алып уйнады ди...»

**Югарыдагы сүзләрне укыганда, Такташ кереп, ишек янагына сөялеп тыңлап тора. Аны беркем дә күрми.**

Т а к т а ш *(алга чыгып, бүлдереп).* Ә Казан аны менә шулай кабул итте ди.

**Яшьләр Такташны чорнап алалар.**

К а р а д у с *(җилкәсенә кулын салып).* Вакланма, Такташ! Яза бирсеннәр! Хәзер шундый заман — ачыктан-ачык әйтү заманы. Яңаны тәэзибез бит, кәбәм! Яңа өчен янабыз.

Т а к т а ш. Мин янмыйммы?! Бөтен уйларымны, хис-тойгыларымны, җанымны кешеләргә өләшәм. Бөтен җылылыгымны аларга бирәм. Шул җан җылысыннан башка, минем бит бернием дә юк. Ә алар әнә миңа «килмешәк» дип кенә кычкыралар.

А к д у с *(икенче ягына басып).* Син, Такташ, алай артык гомумиләштермә инде. Нигә кешеләр, дисең? Халыкның монда ни катнашы бар? Бер адәм кисәге язган шунда.

Я ш ь ш а г ы й р ь. Әйдәгез, егетләр, җыелып, шул мәкаләгә җавап язабыз! Протест язабыз! *(Кара дуска.)* Дус! Чыгар үз газитеңдә шул язманы?

К а р а д у с. Вакланмагыз, дип әйттем бит. Мәкаләгә түгел, шигырь язып җавап бирергә кирәк.

А к д у с. Дөрес, дус! Әйдә, Такташ, укып җибәр әле әр-яңа бер шигыреңне!

Я ш ь л ә р. Укы, Такташ, укы!

Т а к т а ш *(елмаеп).* Йә, тыңлагыз алайса. Тик катырак киткән урыннары булса, бигайбә! Йөрәкнең бик янган вакытында язылган шигырь...

Я ш ь л ә р. Исеме, исеме ничек?

Такташ. «Казан» дип атала. Драмадан бер монолог. *(Чәчләрен артка чөеп, укый башлый.)*

Күзләремә ничек ачык итеп
Кайгы нуры төшкән.
Аларда
Үз-үземә нәфрәт хисе яна.
Оялам да,
Куркамын да хәзер карарга...
Ә кайчандыр алар көн килерен
Хәбәр иткән язгы таңдагы
Кояш нуры кебек якты иде.
Өметле иде;
Хәзер андагы
Ул сихерле нурлар сүнгәннәр.
Ә тагы
Алар шулай итеп янармы?
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңа
Мин, гыйсъянчы, кереп адаштым.
Череп беткән мещан баткагында
Иркен уйларымнан саташтым.
Казан!
Фахиш шәһәр,
Синең урамыңда
Җанга җылы юктан туңам мин,
Череп беткән мещан мунчасында
Көзге чәчәк кебек сулам мин.
Казан!
Шагыйрьләрең бардак җырлый синең,
Әдипләрең эчеп тилергән,
Нэпманнарың чуар дуңгыз кебек
Кеше каны эчеп симергән.
Казан!
Фахиш шәһәр!
Синең урамыңа
Көчле дуслар эзләп килдем мин...
Тик ялгыштым,
Синдә Дон-Кихотлар,
Милләтчеләр туе күрдем мин...
Киләчәктә юкса мине дәме
Шушы ваклык басар, күмәрме?
Күкрәгемдә янган җәһәннәмнәр
Шулай әкрен генә сүнәрме?
Әгәр алай булса,
Ул вакытта...
Үләргә? —
Ачу итеп тормыш чүпләренә
Үз-үземне җиргә күмәргә? —
А, юк!
Әгәр алай итсәм, алар өчен
Бик зур корбан булыр идем мин.
Шул тормышның астын өскә китереп
Җимерергә, тар-мар итәргә!!
Әйе,
Бу тормышны җимерер, ватар өчен
Алар килә,
Ишетәм:
Яшь көчләрнең
Аяк тавышлары ишетелә!

**Бар да кул чабалар.**

Кара дус. Шәп! Молодец, Такташ! Ахыры бигрәк тә яхшы чыккан. Менә каләмеңне кай якка борырга кирәк сиңа! Яңалыкны җырла, яшь көчләрнең аяк тавышларын җырла! Ә башы — буталчык, кирәкмәс нәрсәләр күп.

Ак дус. Ә миңа калса, башта чын Такташ. Газап, эзләнү, көрәш. Ә ахырында пафос күп.

Кара дус. Ә синең үзеңдә юкмы пафос? Кара инде:

Корыч тешләр белән
Тимер кырып,
чәчкә коям,—
Чәчкәләрдән һәйкәл ясап,
Анда кемне бастырам?
Сине...
аны...
моны...
сезне...
Юк!
«барыгызны»
бергә
Эшче исемендә бастырам.

Ак дус. Гениальный шигыр! Безгә пафос белән язсак та килешә. Ә менә Такташка — килешми. Ура! кычкыра башласа, ул ясалмага әйләнә.

Яшь кеше. Такташ, сиңа бер сорау бар иде.

Такташ. Әйт, яшь дус.

Яшь кеше. Нәрсәдән шушы хәтле риза түгел син?

Такташ. Аңламадым.

Яшь кеше. Аңламадыңмы? Менә без, совет яшьләре дә аңламыйбыз шул. Бөтен шигырьләреңдә нәләт, ризасызлык, газап, каргыш. Бәлки син революцияне кабул итмисеңдер?

**Бар да гөжләп алалар. Кинәт тыналар.**

Такташ. Ну, егет... Син әйтеп тә карыйсың. Мин революцияне, ач-ялангач килеш, «Марсельеза» җырлап, Бохара урамнарында каршыладым. Минем атам-анам — Сыркыды авылының ярлы крестьяннары. Кайдан килсен миңа революцияне кабул итмәү? Җырларымнан башка, дөньяда минем бер байлыгым да юк.

Яшь кеше. Алайса, нигә һаман карганасың? Нидән риза түгел син?

Такташ. Үз-үземнән. Бары тик үз-үземнән. Мин шигърияттә тар кысаларга гына сыймыйм. Күңелем белән күкләргә дә менеп китәм, сарайларга да барып керәм. Нәрсә эзләгәнемне үзем дә белмим. Җан дулый.

Кара дус. Ә белергә кирәк, Такташ. Син эзләгәнне революция инде әзерләп бирде. Хәзер шул турыда җырларга кирәк.

Такташ. Менә шуның көен таба алмыйм шул...

Ак дус. Революциягә көй кирәкмени? Революциягә ритм кирәк! Бәр, җимер, янаны төз! Мылтыгың булсын төз! Тра-та-та! Атака! Алга! Искелек — дошман. Үлеме булсын — кылычтан!

**Шулвакыт ишектән бер төркем кызлар килеп керә. Алар — рабфак студенткалары. Алар арасында Беренче Гөлчәһрә дә бар. Ул үзенең чаялыгы белән барысыннан да аерылып тора.**

Беренче Гөлчәһрә. Кем монда шулхәтле әтәчләнә? А, шагыйрьләр! Артистлар! Әйдәгез, кызлар, үтегез, тартынмагыз. Безнең татар шагыйрьләре бераз оялчан булалар, үзләре чакыра белмәсләр.

**Ак дус янарына йөгереп килә. Гөлчәһрәгә нәзакәт белән кулын бирә.**

Ак дус. Ак шагыйрь.

Беренче Гөлчәһрә. Ә мин сезне беләм. Сез футурист бит. «Айга ут төртәм, жирне гөл итәм. Тра-та-та! Атака!» Ха-ха-ха! *(Сөйләшә-сөйләшә бер читкә китәләр.)*

Такташ *(Кара дуска)*. Бу нинди «пәри кызы»?

Кара дус. Бумы? Бу — рабфак студенткасы. Бик көттә кыз. Җитмәгән жире юк. Русчасын, татарчасын, гарәпчәсен су кебек эчә. Казан каласын ду китереп яши.

Такташ. Адәм баласына... кайдан килгән шушы хәтле гүзәллек? Пәри затыннан түгелме икән ул?

Кара дус. Кара, Такташ, ул Казанда күп кешенең башын әйләндерде инде. Сак бул, синең дә башыңа житмәсен.

Такташ. Кайгырма, дус. Минем өчен ул — гүзәллек кенә. Шигърияттән үзе кебек гүзәллек. Йа... булса да булыр икән шундый матурлык...

Беренче Гөлчәһрә. Кызлар, егетләр, әйдәгез, шигырь әйтешле уйныйбыз. Монда килеп, шагыйрьләрдән шигырь дә тыңламасаң! Менә сезнең номерлар. *(Өләшә.)* Безгә атап шигырьләрегезне әзерләгез.

Ак дус. Минем әзер! Шигырь дә әзер, аны — кемгә бирәсен дә беләм. *(Тиз-тиз шигырь яза башлый. Номерын күкрәгенә кадап куя.)*

**Барысы да шигырь язып, шигырьләрен кызларга өләшәләр. Һәрберсенең күкрәгендә — үз номеры. Такташ кына берни язмый. Буш кәгазьне, кеше аша, Гөлчәһрәгә жибәрә. Гөлчәһрә кулында шигырьләр күп.**

Беренче Гөлчәһрә. Йә, егетләр, укыгыз!

Ак дус:

Керден дә —
Үтердең!
Кояш сүнде, ай тотылды, —
Беттем.
Кирәкми дөньясы —
А, гүзәл, —
Аяк астында Шагыйрь үзе!
*(Тезләнә)*.

Беренче Гөлчәһрә. Номерың мендә, чибәр егет!

Ак дус. Йөрәгем дә!

Беренче Гөлчәһрә. Кояш, ай сүнгән, ул йөрәк ялгызы ни эшли алыр соң? Алай да шигырь миңа ошады. Кабул итәм. Икенче номер?

Кара дус. Минем номер. Ул — сезнең кулда.

Беренче Гөлчәһрә. Шигырегезне укы, шагыйрь!

Кара дус.

Яңа заман корып барган чакта
Яңа заман кызы — син тудың.
Илебездә барган үзгәрешләр —
Синең жирдә янган символың!
Бир кулыңны, илнең ал таңы,
Ирекле мәхәббәт Ватаны!

Беренче Гөлчәһрә. Браво, шагыйрь! Солидно! Бераз буталчыграк, пафос зур, ләкин барыбер шәп! Кабул итәм. Өченче номер? Кем? Нигә ак кәгазь? Шагыйрьнең әллә кызлар күргәч язар сүзе онытылганмы?

Такташ. Онытылмаган, гүзәл. Ул шигырь бәгырьгә газаплар белән күптән уелган инде...

*(Укый)*.

Син уйныйсың. Ә мин шундый ардым;
Өзелеп-өзелеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син бер хәят үзен
Уйнап йөргән иллә, яланда.
Толымнарың белән жилләр уйный,
Унга-сулга ташлый туздырып,
Алар бәхетлеләр...
Соң мин, соң мин нигә,
Төннәр бу шунда утырып,
Кул сузарга куркам?!
*(Такташ укыганда, Гөлчәһрә, сихерләнгәндәй, алга таба килә)*.
Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне!
Алар сузылып төшсен алдыңа, —
Шулай килешә сиңа. Су кызыдай
Кил дә хәзер минем алдыма.
Төпсез күзләреңне айга текәп
Утыр; күлдә — шәүләң уйнасын,
Узган-барган кешеләр туктап карап,
«Су кызы» дип сине уйласын!
Аһ, Әминәм! Булмадың ник бер су кызы,
Иркенлектә уйнап йөрүче?
Ник булмадым мин бер урман углы,
Синең дустың — яшь бер көтүче?
Кыймас иде безгә мәкер күзләр
Болай шөбһә белән карарга.

Беренче Гөлчәһрә *(битен каплап)*. Юк! Юк! Кабул итмим! Кабул итмим...

Такташ. Нигә, туташ, шигырь сезгә ошамадымыни?

Беренче Гөлчәһрә. Шигырегез яхшы. Ләкин ул миңа багышланган түгел! Сез аны ниндилер Әминәгә багышлагансыз. Ә миңа укырга батырчылык иттегез.

Такташ. Ниндидер Әминә... Гафу итегез, туташ, бер мизгелгә мин кинәт аны күргәндәй булдым. Әминәм, дип уйладым.

Гөлчәһрә. Мин Әминә түгел!

Такташ. Ә кем соң сез?

Гөлчәһрә. Мин — Гөлчәһрә Хәмзина!

Такташ. Ә мин — шагыйрь Һади Такташ.

Гөлчәһрә. Такташ? Кызлар, ишеттегезме, үзе — Такташ, үзе миңа атап бер юл шигырь яза алмаган! Ха-ха-ха!

Такташ. Мин теләсә ничек шигырь яза алмыйм, туташ.

Гөлчәһрә. Теләсә ничек? Сез ишеттегезме? Ха-ха-ха! *(Кулындагы бөтен шигырьләрен аяк астына чәчә.)* Язарсың, шагыйрь! Менә болар кебек язарсың! Моны сиңа Гөлчәһрә Хәмзина әйтә. Ха-ха-ха! *(Чыгып китә.)*

Такташ. Җен кызы. Валлаһи, җен кызы! Адәм баласы мондый шашкын булмый... Бөтен зиһенемне чуалтты.

Кара дус *(җилкәсенә кулын салып)*. Кара, башыңны әйләндермәсен, Такташ! Җүнле кызга охшамаган ул.

Ак дус *(икенче яктан килеп, Такташның җилкәсенә кулын сала)*. Калдыр ул кызны, Такташ. Сиңа бөтенләй тиң түгел ул. Берегез — ут, берегез — су...

Такташ.

Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма,
Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа.

Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың да
Ник яшерендең, төренеп таң нурларына?
Их, дуслар! (Аларны кочаклап ала.) Яшисе килеп китте бит әле, яшисе!

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Такташның кунакханәдәге үз бүлмәсе. Такташ ялгыз.**

Такташ. Ничек язарга? Нәрсә турында язарга? Күкрәгемдә — янар таулар ялкыны. Ләкин дөньяга минем бу ут-ялкыннарым кирәкми. Дөньяга таш-тимер турында җырлар кирәк. Мин алар теләгәнчә яза алмыйм! Газеталар минем хакта тәнкыйть мәкаләләре белән тулган. Һәр шигырем штыклар белән каршы алына. Йөрәк каныма манчып язган «Җир уллары» байкотка очрады. Бер фикерсез, кызыл, шома сүзләрдән генә торган шигырьләрне ура! кычкырып каршы алалар. Минем дә үзгәрүемне, башкалар кебек яза башлавымны көтәләр. Ә мин яза алмыйм! Яза алмыйм! *(Өстәленә каплана.)*

**Бүлмәгә әкрен генә Беренче Гөлчәһрә керә. Арттан килеп, Такташның күзләрен куллары белән каплый.**

Такташ *(баса)*. Кем син, йортыма рөхсәтсез килеп кергән юлаучы?

**Гөлчәһрә дәшми.**

Син кешеме, пәри затыннанмы? Нинди максат белән минем күзләремне капладың? Бу дөньяны миннән мәңгегә каплавыңмы, пәри кызы?

Беренче Гөлчәһрә. Мин синнән шигырь алырга килдем, шагыйрь *(каршына утыра)*.

Такташ. Шигырь юк, пәри кызы. Күңелемдәге шигырь орлыкларын җил-давыллар туздырган...

Гөлчәһрә. Син бигрәк сәер кеше икәнсең, шагыйрь! Яңалары юк икән, искеләрен укы. Сине бит бүгенге көндә татарның иң яхшы шагыйре диләр.

Такташ. Шулай диләрмени? Безнең мәртәбәле газета-журналларыбыз шулай язмыйдыр бит?

Гөлчәһрә. Нигә миңа газета-журналлар фикере? Халык шулай сөйли, яшьләр, студентлар шулай әйтә.

Такташ. Менә бит, бер җылы сүздән дә күңелләр күтәрелеп китте бит әле. Бер карасаң, күп тә кирәкми адәм баласына. Ниндирәк шигырь укыйм икән мин сезгә, Гөлчәһрә туташ?

Гөлчәһрә. Әлбәттә, мәхәббәт турында. Миңа чүкеч җыры кирәкми. Мәхәббәт булсын.

Такташ. Йә, ярый алайса. Тыңлагыз.

Аһ, әгәр мин бер зур рәссам булсам,
Тәрсим итеп ул кыз баланы
Бүләк итәр идем сезгә,
Бүләк итәр идем мин аны.
Җир йөзенең бөек рәссамнары!
Килегез дә миңа сөйләгез!
Аның тузган чәчен буяганда
Нинди буяу белән буйыйм да,
Зәңгәр күзкәйләрен, җаным итеп,
Ничек кенә буяп куйыйм да,
Ничек тәрсим итим мин аны?!

Гөлчәһрә. Житте, туктагыз! Сез һаман үткәннәрдә саташасыз, һаман эзләнәсез. Нәрсә эзлисез сез? Кемне?

Такташ. Белмим. Нәрсә эзләгәнемне, нәрсә көткәнемне белгән көннән, мин шагыйрь булудан туктар идем.

Гөлчәһрә. Кем ул — зәңгәр күзле чибәркәй? Нигә Сезнең шигырьләрдә мин юк?!

Такташ. Сез аның булырына ышанасызмы?

Гөлчәһрә. Ха-ха-ха! Әлбәттә! Чөнки мин — Гөлчәһрә Хәмзина. Пәри кызы, җен кызы, чегән кызы, мишәр кызы! Тик минем күзләрем зәңгәр түгел, яшел! Шигыреңдә бутый күрмә! Ха-ха-ха!

**Ишектә Ак Дус күренә.**

Ак дус. Чегән кызы! Тавышың урамның теге башыннан ишетелә. Син нәрсә монда шагыйрьнең башын әйләндерәсең?

Гөлчәһрә. Әйләндерерсең аның башын?! Син әле аны белмисең. Таш ул синең шагыйрең. Так-таш! Таш! Ха-ха-ха!

Такташ. Дөньяда ташларны эретерлек көч тә бар, Гөлчәһрә туташ! Во! Ту-таш! Таш! Таш. Ха-ха-ха! *(Көләләр.)*

Ак дус. Кая, Такташ, синдә капкаларга һәрвакыт бирәр нәрсә була торган иде. Гөрләтеп бер чәй эчеп алыйк әле, булмаса?

Такташ. Ипи-чәй бар, егетләр. Кичә генә Заһидлардан 2 кадак чәй алып торган идем. Утыр, Гөлчәһрә, туташ, фәкыйрь табынымның түрендә бул.

Ак дус. Ә минем — күңелемнең түрендә, Гөлчәһрә туташ!

Такташ. Кара син аны, Такташның чәен эчеп, ярын да кочмакчы.

Гөлчәһрә. Во! Ишеттегезме?! Ярын, диде. Мин күңелемә салып куйдым, шагыйрь!

Такташ. Ай, канатларым! Ай, дуслары́м... Бер караганда, менә күп тә кирәк түгел адәм баласына. Менә шундый көзге салкын кичтә җылы куыш, бер кисәк ипи... Җылы караш.

Ак дус. Нәрсә, янар таулар кирәкмимени инде хәзер, Такташ? Күкләргә дә менәсең килмимени?

Такташ. Күкләр ерак... А впрочем, нәрсә теләгәнемне мин үзем дә белмим әле. Йөрәк уйный, йөрәк ярсый. Анда давыл тынмаган әле, егетләр!

Гөлчәһрә. Син картайгач та шулай давыллы булырсыңмы икән, Такташ?

Такташ. Юк, Гөлчәһрә, мин картайгач тыныч кына, ягымлы гына бер карт булырмын. Тезем тулы оныкларым булыр. Бу авырлыклар, ачлы-туклы тормыш артта калыр... Дөньяның бәхеттән мөлдерәп торган чаклары булыр әле, егетләр!

Ак дус. Күңелләр нечкәреп китте. Әйдә, үзебезнең бер мишәр көен сузыйк әле, Такташ дус.

Гөлчәһрә. Мин дә кушылам! Мин дә мишәр кызы бит!

**Такташ моңлы тавыш белән «Аючылар» җырын башлый. Аңа башкалар да кушыла.**

**Аючылар, баручылар,**
**Кайтыгыз үз ил генәмә,**
**Үз илемә, үз җиремә,**
**Карыйм күзем туйганчы,**
**Елыйм яшем беткәнче...**

**Такташ. Бу — безнең Сыркыды көе...**

**Ак дус. Бездә дә җырлыйлар аны.**

**Гөлчәһрә. Мин дә әтидән ишеттем. Көрәнле көе, дип җырлый иде.**

**Такташ. Халыкныкы инде алайса...**

**Ак дус. Карагыз әле! Җырлаганнан соң, бер аяк та язып аласы килеп китте. Әйдәгез, киногa?! Америка турында шәп фильм бара икән.**

Гөлчәһрә *(сөенеп)*. Әйе шул! Әйдәгез! Мин дә ишеткән идем. Керергә акча гына булмады.

Ак дус. Акча ягы миндә дә бераз такыррак икән такырын. Карале, Такташ, син бу көннәрдә гәзиттән гонорар алдың бугай?

Такташ. Мә, дус! Ни бары — шушы. Бераз булса да, әниләргә җибәрдем. Калганын — мә, алыгыз. *(Акча бирә.)*

Ак дус. Соң, үзең бармыйсыңмыни?

Такташ. «Чаян» өчен язасы мәкаләм бар. Өйгә алып кайтып эшләмәсәң, редакциядә генә бетми. Иртәгә өлгертәсе.

Гөлчәһрә. Нәрсә, алай да була! Бүгенге заманда бары тик Такташ кына шулай эшли ала.

Такташ. Ничек, Гөлчәһрә?

Гөлчәһрә. Акча бирә-бирә, янына килгән кызны башка белән чыгарып җибәрә. Киттек, Ак Дус!

Ак дус. Без киттек, Такташ! Яз мәкаләләреңне! Яз шигырьләреңне! Бүген кич янымда Гөлчәһрә туташ утырганда, миңа берни кирәкми!

**Китәләр.**

Такташ. Менә, дивана. Тәрәзәгә килеп кунган чыпчыкны шулай очыр инде! Җыенып үзем дә барсам, нәрсә була иде инде? Черт белсен, әллә нинди арыганлык шунда. Вакыты-вакыты белән әллә нинди күңел төшенкелеге. Язам — язганым ярамый! Аннан яза алмас хәлгә килем. Ә мин — шагыйрь! Мин язарга тиеш. Мин бит язганда гына яшим. Ни өчен мин кемнәргәдер яраклашып яшәргә тиеш?! Ни өчен?!

**Кара дус керә.**

Такташ. А, дус! Мине аңлый, акыллы киңәш бирә алырлык бердәнбер дус! Утыр! Өемнең түрендә бул.

Кара дус. Төсең киткән, Такташ. Бик күп эшлисең ахры.

Такташ *(Идәндәге кәгазьләрне күрсәтеп)*. Әнә! Аяк асты тулган. Аяк астында аунарлык кына шигырьләр туа хәзер миндә.

Кара дус. Үзеңне алай төшермә, Такташ! Вакланма! Син — зур шагыйрь. Кара, шуны сорамакчы идем. Теге чикерткә моннан чыгып бара идеме әллә ул?

Такташ. Кемне әйтәсең?

Кара дус. Рабфак Гөлчирәсе. Кара аны, Такташ. Бу тирәгә бик иялендермә син аны. Күзләре урынында түгел аның.

Такташ. Юк инде, алай ук түгел инде. Ул артык кыю, чая кыз. Болай, күңеле яхшыга охшаган аның. Ну үткенлек бар инде. Ут!

Кара дус. Безнең футурист шагыйрьгә чат ябышкан. Култыклашканнар, сырышканнар, башны-башка терәгәннәр. Мине күрмичә дә үтеп киттеләр.

Такташ *(күңелсез генә)*. Салкын бит. Гөлчирәнең өстендә бик җиңел иде. Шуңа күрә безнең дуска сыенгандыр.

Кара дус. Алай да, мин сине кисәтәм. Ялгыша күрмә. Үзеңне дә, иҗатыңны да харап итәрсең.

Такташ. Иҗат... Иҗат болай да кыл өстендә.

Кара дус. Син нәрсә Гали Рәхимнәр сүзен сөйлисең? Алар әнә анда синең хакта күрәзәчелек итеп яталар, имеш, «атылган йолдыз булып, үз утында үзе янып югалмагае!» Туктале, кая әле журналы. *(«Безнең юл» журналын чыгара.)* Менә нәрсә ди бит, контр. Синең турыда әйтә. Тыңла. *(Укый.)* «...Көчле каләм белән мәңгелекнең тимер ишекләрен ватырмын, ди торгач, ул үзе шул тимер ишекләргә бәрелеп, канатлары сынып, кире җиргә төшеп сүнмәгәе иде», — ди. Кара, ничек оста карылдый. Тыңла, тагы нәрсә ди. *(Укый.)* «...Әмма бу көченең татар әдәбияты мәйданыннан югалуы чынлап та тәэсирле бер хәл булыр иде: чөнки бу яшь шагыйрьдә безнең татар шагыйрьләренең күбесендә булмаган бер ялкын белән бергә гаҗәп нәзек шигърият һәм әдәби зәвык булганы күзгә бәрелә» *(Журналны ташлый.)* Контр. Сине үзенең буржуазия сазлыгына сөйри бит. «Нечкә зәвык, гаҗәеп шигърият!» Хәзер ут, кан заманы! Тимер заманы! Яңаны төзибез. Нечкәреп торып булмый. Өзелеп китүебез бар.

Такташ. Синеке дә дөрес, дус. Аларда да хаклык бар. Шигърияттә, иң беренче, хис кирәк. Ә впрочем, ике арада буталып калдым мин. Элеккечә дә язарга ярамый, яңалыкны да әле җаным, күңелем аша үткәрә алмыйм. Мин кабул итеп бетермәгән нәрсәләр күп. Туктап калдым.

Кара дус. Туктап калма! Беренче эш итеп, менә шушы вак буржуа җырчыларына каршы җавап яз! Бетереп яз үзләрен. Сөйрәмәсеннәр сине мещан баткагына. Үз гәзитемдә чыгарам, яз гына!

Такташ. Алай да ярамас. Революциянең теге ягыннан килгән тәнкыйтьчеләр әдәбиятны бик яхшы беләләр. Дөнья әдәбиятын! Алар арасында бик фикерлеләре дә бар. Безнең бит ни мәдрәсә, ни югары уку йорты. Аларга каршы чыгарга түгел, алардан өйрәнергә кирәк.

Кара дус. Димәк, аларга каршы чыга алмыйсың, ә безгә каршы чыгасың? Тагы бер-ике менә шушындый төче мәкалә, син, билләһи, дип әйтәм, безгә каршы, Советка каршы кулына кылыч аласы кеше икәнсең.

Такташ. Син нәрсә?! Минем ничек язуым, эзләнүем, юл таба алмавым — минем шәхси эшем! При чем монда Совет власте? Соң мин сезнең барыгызга караганда да җаным белән партияле, коммунист. Ләкин иҗат белән син аны бутама!

Кара дус. Илгә хәзер синең эзләнүләрең, җен-пәриләрең кирәкми! Илгә синең

шагыйрь буларак юл ярып, әйдәп баруың кирәк. Әсин аңа просто әзерлексез икәнсең. Ничек ялгышканмын мин синдә!!

Такташ. Соң, нишлим соң, дустым?! Нишлим!!!

Кара дус. Яз. Безгә, илгә нәрсә кирәк, шуны яз. Куеп тор хисләреңне, шашуларыңны. Андый шигырьләр заманы үтте инде. Яз менә шундый бер шигырь... синең коммунистлыгың, җаның шунда күренерлек булсын. Иртәгә әдәби кичәдә укырсың. Юк икән — бигайбә. Син безгә юлдаш түгел. *(Китә.)*

Такташ *(ялгызы)*. Язам! Язам мин андый шигырьне! Төне буе язам, йөрәгемне яндырып, шуның яктысында язам. Үткәннәрдән, зәңгәр күзле беркатлы яшьлегемнән соңгы шигыремне язам...

**Сәхнә караңгылана.**

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Мәдәният йорты. Бередә әдәбият кичәсе булачак. Зал хәзергә буш. Беренче Гөлчәһрә керә.**

Беренче Гөлчәһрә. Кайда утырыйм икән? Артка барып, бөтенләй күрмәмешкә салышып утырсам? Күрмәмешкә салынсаң, күрмәс. Шул булыр. Бик исе китәр. Әсин бөтен кызлар алдында сүз бирдең, имеш. Такташны үзенә карата. Гөлчәһрә башың белән адәм көлкесенә калырсың аннары. *(Алга үтә.)* Юк, алга утырам. Күзенә кереп утырам. Буталсын, саташсын, сүзен онытсын! Ялгышып, «Гөлчәһрә!» дип кушып җибәрсен. *(Көлә)*. Во була аннары! *(Сәхнәгә йөгереп менә дә, җырлый башлый.)*

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан тамалар?!
*(Биеп әйләнә.)*

**Залга Кара дус керә дә, сокланып ишерә алмыйча, Гөлчәһрәгә карап тора.**

Кара дус. Браво, Гөлчәһрә туташ! Инде мин шигырь тыңламаска да риза. Гүзәллегегез каршында тагы бер кат башымны иям. *(Килеп, кулын үбә.)*

Гөлчәһрә. А, житди шагыйрь! Шигырь укырга килдеңме, тыңларгамы?

Кара дус. Сез сер тота беләсезме, Гөлчәһрә туташ? *(Як-ягына каранып, уфтанып.)* Мин бүген берәүнең шигърияте белән мәңгегә хушлашырга килдем.

Гөлчәһрә. Сез... кемне күздә тотасыз?

Кара Дус. Кемне күздә тотканны бик яхшы беләсез, Гөлчәһрә туташ. Мин аны кызганам. Бетте шагыйрь. Язар сүзе бетте. Сайрак булган, коры шапырыну булган икән ул.

Гөлчәһрә. Сез... аннан көнләшкәнгә шулай әйтәсез. Чөнки ул сезнең барыгызга караганда да талантлырак. Шуңа яратмыйсыз.

Кара Дус. Әсин яратасыңмы? Кызык өчен, үзеңә карату өчен генә йөрисең бит. Һәм дөрес эшлисең. Сиңа тиң түгел ул.

Гөлчәһрә. Ул — шагыйрь! Такташ!

Кара Дус. Әсин — дөньяның иң гүзәл кызы. *(Кулларыннан алып.)* Җүләр була күрмә, мавыгып китмә. Бу гүзәллекне аңлый аламы соң ул? Сыркыдының чабатачы Хәйрук ул Гөлчәһрә! Мин сине яратам! Мин сине дөньяның алиһәсе итәчәкмен. Син матурлык өчен генә яратылган. Ач шагыйрь хатыны булу өчен түгел. Алда мине зур урыннар, дәрәҗә көтә... Гөлчәһрә...

Гөлчәһрә. Китегез, зинһар! Кешеләр килер вакыт җитте. Кемне уйлаганымны, нәрсә теләгәнемне мин үзем дә белмим. Тик хәзергә китегез миннән.

Кара Дус. Вәгъдә?!

Гөлчәһрә. Ашыктырмагыз. Мин бүген шигырь тыңларга килдем.

Кара Дус. Ха-ха-ха! Шигырь булмаячак! Шигырьгә пародия, елау, мескенләнү генә булачак.

**Ашыгып, Ак Дус керә.**

Ак Дус. Такташ күренмиме әле? Халык арасында сүз таралган — Такташ яңа шигырен укыячак икән. Күптән язганы юк иде, ни әйтер икән Такташ?

Кара Дус. Тыңлап карарбыз.

Ак Дус. Гөлчәһрә, бәгърем, кил утыр әле яныма! Такташны тыңлаудан да бигрәк, синең белән янәшә утырыр өчен килдем.

Гөлчәһрә. Әмин Такташны тыңлар өчен килдем!

Ак Дус. Нинди чебен тешләде сине? Алайса, үзем яныңа барып утырам. Такташны бергәләп тыңларбыз.

**Залга яшьләр белән бергә Такташ керә. Ул агарынып киткән. Бер читкә барып баса.**

Яшь шагыйрь. Утырыштыгызмы? Хәзер сүзне символист шагыйрь Һади Такташка бирәбез.

**Такташ сәхнәгә менә.**

Такташ. Хәзер мин сезгә символизм буенча язылмаган нәрсә укыйм. Аны школларга аеру минем эшем түгел, бәлки әдәбият тикшерүчеләр эше. Мин бары «такташист» кына. Мин сезгә бүген төнлә язган соңгы шигыремне укыйм. *(Укый.)*

### Такташ үлде

Көчле кояш күптән баткан инде,
Караңгылык баскан җир өстен,—
Ә ул һаман утын якмый, тик утыра.
Бәлки... кем белсен,
Аның көчле кулы бик күп еллар
Шулай эшли-эшли талгач та,
Күкрәгендә хәят нурларыннан
Соңгы нуры сүнеп калгач та,
Аның иркен күңле тынар өчен
Караңгылык тели торгандыр?
Бәлки шулайдыр да,
Бәлки...
Өстәлендә аның бер хат тора —
Карт анасы язган;
Хатында
Шундый юллар:
...Хәләл сөтен имезеп, төннәр буе
Йокламыйча сине саклаган,
Авырганда үлем кочагына

Үзен атып, сине яклаган
Ул кем иде?
Соңгы сынык нанын сиңа биреп,
Ач калса да, «балам» диюче,
Бөтен дөнья синнән качканда да
Бер ялгызы калып сөюче
Ул кем иде?
Син ач килеш читтә йөргән чакта,
Синең өчен
Елый-елый күзсез калучы,
Синең бәхетең өчен җир өстендә
Төмуг газапларын алучы
Ул кем иде?..
— Мескен әнкәң!
Ул әле дә өзелеп сагна сине,
Ә син?..
Әткәң,
Ул әле дә шулай сөренә-сөренә,
Таяк тоткан килеш, урамда
Туктап ютәлли дә:
«Мин әле дә сезнең өчен
Салкын буранда
Һаман йөрим»,— ди ул.
Аның күләгәсе һаман йөри,
Һаман, һаман да...
Бер ул гына түгел,
Бире бик күп алар;
Ач, ялангач килеш яланда
Тик йөриләр...
Тик йөриләр...
«Син кайт, балам!
Син кайт безнең янга,
Әвәлгедәй сине сөярбез,
Балам, иркәм, бәгърем, диярбез!
Син кайт, балам!»
Төн үтә дә,
Ир, әнге җил аңа җавап яза:
— Улың үлде.
Сагнып хатлар язма, бәхетсез карт,
Зәңгәр күзле улың исменә;
Ул юк инде...
Сагнып хатлар көтмә, изге карчык!
Көзге төндә
Тәрәзә төбендә,
Тәрәзәңне кагып:
— Аңардан! — дип,
Хат китермәс хәзер беркем дә.
Төштә күреп аны уянгач та,
Рәсмен кулыңа алып син аның,
Таң җилләре аша
Елый-елый
Көтмә инде аның сәламен!
Ул юк инде,
Ата
Синең өчен
Ул юк инде.
Ана!
Синең өчен,
Сезнең өчен үлде мәңгегә...
Иске тормыш!
Синең кырларыңда
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет —
Ул юк инде...
Иске тормыш!
Синең «гөл бакча»ңда,
Сөренә-сөренә ачтан интегеп,
Хәят эзләп йөргән уйчан егет —
Ул юк инде...
Гаиләң тар синең аның өчен,
Йортың — төрмә,
Ишекләре корыч-тимердән.
Балаларың — исерек,
Нәслең — черегән!
Барысы тилергән!..
Нәфрәт итеп «синең гаиләңә»,
Барлык матурлык дип белгән нәрсәңә,
Нәфрәт итеп сиңа!
Ул ант итә Казан урамында,
Ул ант итә мещан базында,
Ул ант итә сезнең арагызда.
Әй, сез, калдык нэпман уллары!
Базар корольләре!
Шарлатаннар!
Череп беткән сыра кортлары!
Сез табынган алтын-көмешләрне
Тәңре итеп үзенә алалмый;
Сез аунаган пычрак баткаклыкта
Үзе өчен урын табылмый;
Ишетәсезме!
Сезгә кабак дусты,
Җырчы малай булып калалмый!
Күрәшчеләр!
Сезнең арагызга яшь бер егет килә,
Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да,
Атасы да,
Анасы да,
Сөйгән яры да...

**Яшьләр гөрләп кул чаба башлыйлар. Кайсылары сызгыра. Кем «Браво!», «Бис!» дип, кем «Долой!» дип кычкыра. «Чит идеология!», «Буржуазия исе килә! дигән тавышлар да яңгырый. Такташ башын иеп басып тора.**

**Ак Дус сәхнәгә атылып менеп, Такташны кочып ала.**

Ак Дус. Чын шигырь бу, Такташ! Тик һичбер нәрсәсе юк дип дөрес әйтмәгәнсең. Без бар бит! Шулаймы, яшьләр?!

**Астан гөжләп җавап бирәләр.**

— Кая безнең өченче дустыбыз? Мен бирегә, котла Такташны! Син теләгән шигырьне язган!

**Астан: «Китте ул!», «Китте» дигән тавышлар ишетелә. Яшьләр дә әкренләп таралып бетә. Сәхнәгә Беренче Гөлчәһрә күтәрелә.**

Гөлчәһрә. Рәхмәт, Һади абый. Мин сезне бүген үзем өчен өр-яңадан ачтым.

Такташ. Рәхмәт, сеңлем! Синең аңлавың минем өчен бик тә, бик тә мөһим. *(Кулларыннан ала.)*

Ак Дус. Такташ үлде. Такташ терелде! Димәк, яшибез! Их, йөрәк яна! Молодец, Такташ дус! Җиңдең! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Гөлчәһрә. Нәрсә булган аңа?

Такташ. Шагыйрь кеше бит... Бер яңа, бер сүнә. Ә дөресрәге, сиңа гашыйк бугай ул, Гөлчәһрә.

Гөлчәһрә *(назланып.)* Миңа? Ә минем зәңгәр күзле уйчан егет белән сөйләшәсем килә. Минем аны терелтәсем килә. *(Йөгереп чыга башлый.)*

Такташ *(кулларыннан алып.)* Син терелттең инде аны, Гөлчәһрә! *(Йөгереп чыгып китәләр.)*

**Әкрен генә «Урман кызы»ның мелодиясе яңгырый.**

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**«Урман кызы» мелодиясе дәвам итә. Такташ бүлмәсе. Такташ ялгызы.**

Такташ. Нигә өченче көн инде иң якын дустым дәшми? Илгә янача җырлаулар кирәк, диде, бөтенесен үзгәртергә өндәде. Төн утырып шигырь яздым. Аның фикерен көттем. Ә ул бер сүз әйтми чыгып китте. Димәк, ул минем шигыремне кабул итмәде. Әлбәттә. Үз юлыннан, үз кыйблasыннан чигенгән кешене, үз-үзен үтергән Такташны кем кабул итсен?! Кеше әйткән саен үзгәргән шагыйрьне... Башкалар әле сәхнәгә менеп котлаган була бит. Ничек оста уйныйлар... Ә ул — дәшми... Ник килми ул?

**Ишектә Ак Дус күренә.**

А, син...

Ак Дус. Ә син башканы көттеңме?

Такташ. Әйе, башканы көттем.

Ак Дус. Такташ! Бик җитди сүзем бар иде сиңа, дустым.

Такташ. Мәхәббәт турындадыр инде. Синең шуннан да «җитди» мажараң булмас.

Ак Дус. Бу юлы мажара гына түгел шул. Чын мәхәббәт. Калдыр син аны, Такташ! Мәхәббәт өчен син артык җитди, авыр кеше. Гөлчәһрә синең шагыйрьлегенә генә кызыга.

Такташ. Син дә шагыйрь бит.

Ак Дус. Минем шигырьләрем хатын-кыз өчен түгел! Яңа тормыш, тимер чыңы, көрәш кыры...

Такташ. Менә шулар белән яшә инде алайса. Яңа тормышта нәрсәгә сиңа мәхәббәт?

Ак Дус. Такташ! Син акыллы, син талантлы, син даһи! Нигә барысы да бер кешегә?! Калдыр миңа Гөлчәһрәне? Валлаһи, яратам бит мин ул җен кызын!

Такташ. Соң син миңа ничә тапкыр шулай кереп, ничә тапкыр мәхәббәтең турында сөйләдең бит! Бер айга да бармый бит ул синең яратуларың!

Ак Дус. Юк! Бу юлы — мәңгелек! Ул бит җен! Ул бит сихерче! Шуның яшел күзләре йокларга да, язарга да ирек бирми. Яшәргә ирек бирми! Сиңа нәрсәгә ул кыз, йә?! Ул бит синең идеалың түгел.

Такташ. Белмим... Кем икәнен белмим... Мин синең кебек башымны югалтмадым, дус. Ләкин ул кыз янымда булганда, дөнья яктырак тоела миңа. Караңгылык чигенә. Просто рәхәт. Яшисе килә.

Ак Дус. Димәк, син серьезно?

Такташ *(көлеп.)* Белмим, дидем бит. Мин ул турыда уйламыйм әле. Башка нәрсәгә эчем поша.

Ак Дус. Дусның эндәшмәвенәме?

Такташ. Әйе. Ә син кайдан беләсең?

Ак Дус. Соң, ул миңа да эндәшми. Теге шигырь кичәсеннән соң кисәк кенә шулай булды.

Такташ. Димәк, ул минем шигырьне кабул итмәгән! Минем яңу, өзгәләнүләремне аңламаган! Димәк, ул шигырьдә берни дә юк!

Ак Дус. Юк, Такташ, ашыкма. Шигырең бик җитди. Аның ни дәрәҗәдә җитдиләген әле бүген генә аңлап та бетереп булмыйдыр. Барыбыз да яшьләр, янабыз, эзләнәбез, язабыз... Синең бу шигыреңдә кемгәдер рәнҗеш тә, газап та, көрәш тә бар. Әллә нәрсәләр бар. Минем баш кына җитми.

Такташ. Ә нигә ул дәшми соң?! Нигә? Ул бит акыллы, җитди кеше. Миңа аның фикере бик кирәк. Аңлыйсыңмы, дустым, синең түгел, аның фикере кирәк!!

**Ашыгып, Беренче Гөлчәһрә керә, кулында газета.**

А, таң кызы! Син миңа иң авыр вакытларда күренә башладың әле.

Беренче Гөлчәһрә. Мин сезгә күңелсез хәбәр алып килдем. Ул Сезне саткан.

Ак Дус. Кем саткан?

Гөлчәһрә. Син түгел, шагыйрь. Сатлык җан булу өчен син артык гади, уенчак кеше. Менә аның иң якын дусты — ул — җитди шагыйрь саткан.

Такташ. Ул?! Син нәрсә бутыйсың, җен кызы?! Нинди гайбәт белән килдең йортыма?!

Гөлчәһрә. Гайбәт?! Мә, укы алайса. *(Газетаны бирә.)*

Такташ *(укый.)* «Такташизм». «30 ноябрьдә әдәбият түгәрәгенең нәүбәттәге җыелышы булып, берничә кульъязма укылды. Тыңларга килүчеләр гадәттәгечә күп иде. Кичәне бик шома үтте дияргә ярый. Тик «Такташ үлде» исемле черек идеологияле шигырь генә һәрбер коммунистның, комсомолец иптәшләрнең күзенә бәрелде». *(Мәкаләнең ахырын карап.)* Ул! Ул!!! Ул шулай язган! *(Газетаны ташлап, битен каплап утыра.)*

Ак Дус. Менә ни өчен дәшми йөргән икән ул?! Очраганда да башын иеп, читкә карап китә иде бит. Нинди пычрак мөһер суккан! «Черек идеология»... Куркыныч фикер бу... Моның шаукымы әле күп еларга барачак.

Такташ *(башын күтәрми генә.)* Укып бетер.

Ак Дус *(газетаны алып.)* Монда Гайсә турында фәлсәфә саткан. Ә, менә... *(Укый.)* «...дини әкиятләргә ияртелеп язган әсәргә бәлки тукталырга да кирәкми торгандыр. Нинди дер мещаннар мөхитендә үскән, соңыннан зәңгәр күзле яшьлек чакларын сагынган тәти җегетнең («Такташист»ның) 17—21 нче елларда йоклаганы, советлар тәмам ныгыгач кына «нәләт нигъмәтләргә» дигән сүзләргә кагылмыйча мөмкин түгел. Гражданнар сугышының кызу вакытларында психологический үлгәнсең икән — бик яхшы. Күреп карыйк, яңа тормышта нинди яңалыклар күрсәтерсен икән!» Укый алмыйм! Барып бугазыннан аласым килә!

Гөлчәһрә. Егетләр, нәрсә була инде бу? Соң ул Такташның иң якын дусты иде түгелме соң? Такташ, нигә эндәшмисең?

Такташ. Нәрсә әйтим, канатым. Башка кисәк белән орган кебек булды.

Ак Дус. Аркага пычак чәнечкән кебек диген.

Гөлчәһрә *(газетаны карап.)* О, монда бетмәгән бит әле! Иң кәттәләре монда калган әле. *(Укый.)* «... Такташ үлде» шигырe кулак, мулла һәм башка шул ук типтагы икътисади төркемнәрнең җегетләрендә, кы-

зларында булган филантропияле настроениене күрсәтә.» Оһо *(укый.)* «Эшче-крестьян гаммасы революцияне турыдан-туры үзе ясый. Давыллардан соң урынлашкан вакытлы тынлык вакытында Октябрь корабының койрыгына ябышкан иярчен мосафирлар үлеп терелгәч тә житәкчелек эшен кулларына ала алмыйлар. Шуңа күрә 23 нче ел житкәч кенә «мин — иске тормыш өчен үлдем. Яңасы өчен терелдем. Күрәшчеләр, арагызга зәңгәр күзле тәти жегет кирә!» дигән белән «Такташизм» (!) мәсләгенең чынлап та дөрест идеологияле икәнлегенә ышандыруы читен». Бетте. Бетергән.

Такташ. Нигә андый фикергә килгән ул? Мине иң дөрес аңлый торган кеше шул иде бит...

Гөлчәһрә. Иң дөрес аңлый торган? Син ялгышасың, Такташ. Аның синең турында фикере бик үк яхшыдан түгел иде.

Такташ. Син нәрсә беләсең, Гөлчәһрә?! Бу, гомумән, син аңлый торган нәрсәләр түгел.

Гөлчәһрә. Мин аңламый торганмы?! Соң шул кичә алдыннан гына ул миңа әйтеп торды, «Такташ бетте, башка яза алмаячак», дип. Миңа үзенең мәхәббәтен аңлатты!

Такташ. Мәхәббәтен?! *(Уйланып тора да шаркылдап көлә башлый.)* Ха-ха-ха! Ха-ха-ха! Аңладым. Наконец-то, аңладым. Соң ул боларның барысын да көнләшүдән язган. Мине Гөлчәһрәдән көнләп язган! Ә мин, жүләр, әллә нәрсәләр уйлап бетердем.

Ак Дус. Мин дә сине Гөлчәһрәдән көнлим. Ярты сәгать элек кенә мин дә сиңа Гөлчәһрәне яратуымны әйттем. Ләкин менә болай итеп газета битен пычратырга... Сине пычратырга! Юк, бутама, Такташ!

Такташ. Нәрсә бутама? Син гашыйк булсаң соң? Син атна саен гашыйк буласың. Аның гомумән, хатын-кызга тел катып сүз әйткәне юк. Гөлчәһрәгә гашыйк булган... Һәм менә нәтиҗәсе.

Гөлчәһрә. Ай-һай жинел хәл итәсең, шагыйрь! Әллә аның миңа гашыйк булуына сөенәсең дә инде?

Такташ. Мин әдәбиятта, шигърияттә ир-ат дуслыгы арасына хатын-кыз килеп керүне, гомумән, өнәп бетермим. Күп зыян туарга мөмкин аннан. Менә бүгенге факт та шуны сөйли.

Гөлчәһрә. Такташ! Син миннән күпкә өлкән. Ләкин хәзер син нәкъ балаларча фикер йөртәсең. Ул синең шагыйрьлегеңнән көнләшә, талантыңнан көнләшә! Бөтен тормышыңнан көнләшә. Кара көнләшү белән көнләшә. Мин хатын-кыз булып шуны сизенәм, нигә син кирәкмәгәндә шулай киң күңелле соң?! Син бит сукырларча фикер йөртәсең!!

Такташ. Гөлчәһрә! Булды! Син ике шагыйрь арасына кермә. Син миңа бик якын, беләсеңме, әлегә үзем дә аңлата алмыйм, бик, бик якын... Ләкин... кысылма син бу мәсьәләләргә. Аның турында миңа башка начар фикер әйтәсе булма. *(Ак Дуска.)* Бу сиңа да кагыла.

Гөлчәһрә. Аһ, шулаймени?! *(Ак Дуска.)* Киттек, Ак Дус! Аның өчен дөньяда шигърияттән, шигъри дуслыктан башка берни юк. Киттек!

Ак Дус. Мин Такташны бу хәлендә калдырып китә алмыйм. Мин сине аларның барысына караганда да күбрәк яратам, ләкин синең белән китә алмыйм.

Гөлчәһрә. Ха-ха-ха! Шигъри дуслык! Ярар, карарбыз, күпмегә барыр ул дуслыгыгыз. Бер-берегезне тереләй ашап бетерәчәксез бит сез!!! *(Ишеккә бара. Аннан Кара Дус килеп керә.)* А,... килдеңме, шагыйрь? Мине эзләп килдеңме?

Кара дус. Коридордан үтеп барганда, тавышыңны ишеттем. Егетләрнең дә хәлен белеп чыгыйм, дидем. Саулармысыз, егетләр? *(Кулын бирә. Такташ исәнләшә. Ак Дус читкә барып баса.)* Алай икән... Йә, ярый, исәнлегегезне белдем. Киттек, Гөлчәһрә! Урамда беренче кар ява анда. Казан каласын «барабыз»да бер әйләнербез! Рәт бар. Киттек!

Гөлчәһрә. Киттек, шагыйрь! Төн безнеке! Тик башың әйләнмәсен! Атыңнан төшеп кала күрмә! *(Йөгереп чыгып китәләр.)*

Ак Дус. Гөлчәһрә! *(Артыннан бара. Аннан йөгереп тәрәзәгә килә.)* Киттеләр. Әнә атны туктаттылар. Гөлчәһрә аның кочагына ауды... *(Йөзен каплап, читкә борыла. Такташка.)* Сине сатып алган гонорарына, әнә, Гөлчәһрәне шәһәр әйләндерә.

Такташ. Дус, калдыр әле син мине бүген? Ансыз да йөрәгем яна. Калдыр әле... Шигырьләрем көтә.

Ак Дус. Их, син! Ярыңны тартып алалар — шигырь дисең! Дусларың ташлап чыгып китә — шигырь дисең! Дөнья шигырь белән генә бармый бит, тиле даһи! *(Чыгып китә.)*

Такташ *(ялгыз.)* Нишлим соң?! Минем өчен дөнья шигырь белән генә бара. Шигырь белән генә...

**Такташ кәгазьләрен туздырып, шигырь язарга утыра. Аның бөтен тирә-юне гөж килеп яши — бииләр, кочалар, бүлмә буйлап шайтан-фәрештәләр йөри. Күк читендә ялкын телләре сикерешә. Шагыйрь һаман яза. Шул мәхшәрнең һәммәсе арасында Шагыйрь берүзе яза! Таң алдыннан бар да тынычлана. Артта ак карлар ягылы күренә. Шагыйрь, башын өстәлгә куеп, йокыга китә. Ишектән әкрен генә Беренче Гөлчәһрә керә. Такташ янына килеп, алдына тезләнә.**

Такташ *(уянып.)* Таң кызы!.. Ә мин синең киләсеңне белдем. Син миңа шулай таң алдыннан килергә тиеш идең... Таң кызым минем, жен кызым... *(Иркәли.)*

**Кинәт тәрәзәләр ачылып китә дә, салкын жил кереп, Такташның бөтен кәгазьләрен туздырып ташлый. Гөлчәһрә куркып Такташка сыена. Шул давыл, жил өермәсе уртасында икәү басып торалар. Бөтен җирдә кәгазь — Такташ шигырьләре оча.**

Такташ. Бу әле давылларның башы гына, Гөлчәһрә... Башы гына...

Гөлчәһрә. Сынмабызмы соң, Һади?

Такташ. Сынмаска кирәк, канатым. Хәзер без икәү бит.

**Сәхнә бераз караңгыланып ала. Музыка.**

### БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Такташ белән Гөлчәһрә нәкъ шул кыяфәттә басып торалар. Бүлмәдәге үзгәреш — бала кроваты. Кыш. 1926 ел.**

Такташ. Арыдыңмы, Гөлчәһрәм?

Беренче Гөлчәһрә. Салкын булды, ахыры... Бала төне буе йокламады.

Такташ. Азрак ягабыз шул. Бүген үк утын юнәтергә кирәк. Күбрәк яга башла.

Гөлчәһрә. Юк, юк! Кыш көне утын табып булмас. Монысын саклап кына тотарбыз.

Такташ. Күкрәк иммәгәнгә дә борчыладыр инде ул?

Гөлчәһрә. Шулай килеп чыкты бит инде. Ярар, ныграк булып үсәр. Атасына охшаса, нык булыр.

Такташ. Анасына охшаса, тагы да ныграк булыр. Пәри малае кебек булыр.

Гөлчәһрә. Кит инде, бала өстенә әлләниләр әйтмә. Нишләп пәри малае булсын ул минем улым?! Иеме, улым?

Такташ *(арттан килеп.)* Ие, әни, ие...

**Көлешәләр.**
**Ишек ачылып китә. Төргәк тотып, Ак Дус керә.**

Ак Дус. Болар һаман көлешәләр! Ну, егетләр, көнләшәм үзегездән. Көнләшсәм дә, аяк барыбер шушында тарта.

Такташ. Өйләнергә кирәк, дус, өйләнергә кирәк. Өйләнгәч, аяк өй ягына таба тарта башлый.

Ак Дус. Безгә дигән кызларга берәмберәм өйләнеп бетерәсез дә... *(Төргәгеннән букет чыгара.)* Менә, малайны котлап.

Гөлчәһрә. Ай, нинди матур! Ай, бәби гапкач, беренче чәчәкләрем!

Такташ *(уңайсызланып.)* Такыррак чак туры килде шул.

Ак Дус. Өр-яңа пиджагымны закладка салдым. Гөлчәһрә, синем өчен йөрәгемне закладка салырга да риза.

Гөлчәһрә. Син һаман шул тел бистәсе икән әле. Такташны көнләштерерсең. *Чыга.)*

Ак Дус. Юк, миннән көнләшми ул. Минем уйларымның ак икәнен белә бит ул. Мин үзем синнән көнләшәм, Такташ! Валлаһи, көнләшәм. Гөлчәһрәгә өйләндең, инде малай атасы булдың. Казанга килеп, дүрт ел эчендә бит.

Такташ. Син әле монда кайбер нәрсәләрне төшереп калдырдың, дус. Дүрт ел эчендә миңа Казанда нинди исемнәр тактылар? «Такташ — сәяси белемсез. Такташ — чит элемент. Такташ — вак буржуа шагыйре». Менә шулардан арына алмыйм мин хәзер. Нәрсә генә язып карасам да, шул мөһерне сугалар. «Мин контр түгел, халык улы», дип манара башына менеп кычкырсам да ышанмаячаклар.

Ак Дус. Син үзеңне тәнкыйтьләргә яратасың, Такташ! Әйт, татарда «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын кем язды? Син! Татар шигъриятендә беренче булып Ленинга һәйкәл куйдың. Ә «Сыркыды авылы»?

Комсомоллар — яшь ленинчылар алар,
Комсомоллар — искелеккә
Бомбалар!

Гөлчәһрә *(тегө яктан.)* Чү, баланы уятасыз! Ике шагыйрь очрашты. Хыялланалар хәзер.

Такташ. Беләсеңме, дус, ул тема да бераз ялыктыра башлады миңе. Минем өчен шигърият ул — хис, кеше күңеле, аның табыш һәм югалтулары. Хәзер мин, домна миче кебек, металл бирәм! Кешегә ияреп, ура! кычкырам. Сәүдәгәрләрне пыр китереп сүгәм. Комсомолларны мактыйм. Кыскасы, гәҗит материалы. Арыдым.

Ак Дус. Ул «Авыл яшьләре» журналы да бик бетерә ахыры сине. Җыен агрономический мәкаләләрне, хайваннар карау турында син язып ятасың бит.

Такташ. Башыңа төшсә, язарсың, туган. Синең эш рәхәт, койрыгыңны сыртка салып, укып кына йөрисең. Студент!

Ак Дус. Аның каравы синең кебек гаилә рәхәте күрмим. Кара инде син бу куышны! Күгәрчен оясы бит. Ә вообще то, сиңа да бераз укып алырга кирәк, Такташ.

Такташ. Мин теләгәндә, булмады. Ташкенттан Мәскәүгә уку теләге белән килгән идем бит мин. Булмады. Шагыйрьлек басты. Аннан менә — тормыш. Хатын. Бала. Кая уку? Эшләп тә җиткереп булмый. Әле менә ничә ай фатир өчен түләнмәгән. Гөлчәһрәнең өс-башын карарга кирәк. Хатынкыз бит. Аның менә бу юеш танавына да кирәк була башлар... Юк инде, брат, шигырь генә язарбыз инде.

**Ишектә Кара Дус күренә.**

Ак Дус. О, менә тагын бер семьянин. Син нишләп ялгыз әле? Хатының кайда?

Кара дус. Хәзерге хатын-кызны аз беләсең син, дустым. Ул хәзер җәмәгать эшлеклесе. Әллә нинди җыелышларга чаба, чыгыш ясый, укый, яза... Дөрест әйтәмме, Такташ?

Такташ. Нәкъ шул, канатым! Нәкъ. Әле менә безнең Гөлчәһрә дә...

Гөлчәһрә *(кулына таба белән бәрәңге тоткан.)* Тагы Гөлчәһрәнең гайбәтен сатасыңмы? Кара син аларны! Үз генә борылсаң, хатын яманлый башлыйсыз.

Кара дус. Гөлчәһрә ханым! Соң сез рәхәтләнеп яманларга ирек бирәсезмени? Телгә алуга, каршыга килеп чыгасыз бит сез. Менә, улыгыз белән тәбрик итәбез үзегезне. *(Материал бирә.)* Хатын белән бер сәгать сайладык.

Гөлчәһрә *(материалын өстенә куеп карый.)* Ай, җәйгә күлмәк тектерәм! Бөтен Казанда иң модный булачак! *(Кара Дусны үбеп ала.)* Рәхмәт, дустым, җәйгә күлмәкле иттең. Халат белән җәй чыгармын, дип куркып тора идем.

Такташ *(сүрән генә.)* Рәхмәт, дус. Безнең бераз такыррак вакыт шул.

Гөлчәһрә. Әйдә, утырыгыз әле. Бәби чәе эчәбез. Никахсызларның беренче мәҗлесе. Кыздырган бәрәңге!

**Табын янына утырышалар.**

Ак Дус. Ай, Гөлчәһрә, кулларың алтын икән! Мондый бәрәңгене гомер ашаганым юк иде.

Кара Дус. Шәп, шәп, тәмле. Молодец, Гөлчәһрә. Бу бәрәңгене ашагач, Такташ тагын да дәртләнеп яза башлый инде.

Такташ. Язам, егетләр! Менә малай тугач, бер шигырь язып ташладым әле. Үземнең бала чак, шук чаклар искә төште! Халык ничек кабул итәр тагын.

Ак Дус. Такташ, укып җибәр әле шул шигыреңне! Күптән синең шигырь укыганны тыңлаган юк.

Гөлчәһрә. Аңа әйт кенә! Көне буе укырга әзер. Только бик мавыгып китмә, баланы уятырсың.

Такташ. Уянсын! Их, егетләр! Аңламыйсыз әти кешенең хәлләрен!

Гөлчәһрә. Йә, укы инде! Мактануы тәмам. Әйтерсең, ул тапкан малай.

Такташ. Шулай. «Нәни разбойник». *(Укый.)*

Ак Дус. Менә бит, язарга тема таба алмыйм, дисең. Әнә бу юеш танау да сиңа язарга күпме илһам биргән! Әле бу башы гына бит.

Кара Дус. Алай да, бу муллалар, ата казлар белән бик кайнашмаска иде сиңа. Пролетариат әдәбияты өчен вак нәрсәләр алар. Син менә бүгенге яңа тормыш турында җырла.

Такташ *(тирә-ягына күрсәтеп)*. Бүгенге яңа тормыш минем өчен хәзергә менә шушы. Калганын сез язарсыз инде, дуслар. Сез дә шагыйрь бит.

Ак Дус. Әйе шул. Син беркайчан да безгә тегеләй яз, болай яз дип акыл сатмыйсың. Ни өчен һаман без сине өйрәтергә тиеш әле?

Такташ. Киңәш бирергә мөмкин инде анысы. Тем более, берегез — студент, икенчегез — зур урында. Ә мин кем — сәяси белемсез бер шагыйрь. Октябрь корабының койрыгына ябышкан.

Кара Дус. Йә, Такташ, егет чактагыларны искә алып утырма. Күңелемдә тырнак очы хәтле дә кер юк.

Такташ. Ышанам. Кемгә-кемгә, сиңа ышанам мин, дус.

Кара Дус. Авыр заманда яшибез, Такташ. Сиңа теш кайраучылар да күп. 24 нче елгы әдәби судны хәтерлисеңме? Ничек сиңа каршы күтәрелеп чыктылар? Әдәбиятка якын җибәрмәскә, шигырьләреңне бер җирдә дә бастырмаска иде бит исәпләре. Шул вакытта сине кем яклады?

Такташ *(күңелсез генә)*. Рәхмәт инде, дус.

Кара Дус. Әллә хәзер хәл бик җиңел дип беләсеңме? Бөтен газеталар сиңа тәнкыйть белән тулган бит.

Ак Дус. Соң, дус, синдә хәзер власть зур, ул тәнкыйть мәкаләләрен чыгартмый торган итеп эшлә син.

Кара Дус. Такташ — беспартийный. Аның иҗаты аеруча күзәтү астында. Аны яклыйм дип, мин болай да үз өстемә күп нәрсә алам.

Такташ. Рәхмәт инде, дус.

Гөлчәһрә. Йә, ярар, хәзер әнә бик шигырь язып утыра алмас. Шигырь язмагач, тәнкыйте дә булмас.

Ак Дус. Нәрсә, Гөлчәһрә, Такташны үзеңә нянька итеп алмакчы буласыңмы әллә?

Гөлчәһрә. Үз баласы бит, шулаймы, Ади? Берничә елга гына түзәр.

Такташ. Гөлчәһрә, син тагы шул турыда... Мин бу эшкә риза түгел, дип әйттем бит инде. Ничу аны монда кузгатырга.

Гөлчәһрә. Юк, юк, кузгатабыз да, киңәшәбез дә менә. Дусларың ни әйтер?

Кара Дус. Эш нәрсәдә?

Ак Дус. Нәрсә бүлешә алмыйсыз?

Гөлчәһрә. Мин укуымны Мәскәү рабфагында дәвам итәргә уйладым. Аннан — шунда ук университет, юридик факультет.

Ак Дус *(сызгырып җибәрә)*. Менә сиңа мә!.. Ә бала? Ә Такташ?

Гөлчәһрә. Син бигрәк кадимичә фикер йөртәсең. Соң, бала дип, ир дип укуымны ташлый алмыйм бит инде мин. Сез шигырьләрегездә дан җырлаган яңа тормыш менә шушы була инде ул.

Кара Дус. Монда мәсьәлә бик җитди. Бөтен ягын да уйларга кирәк. Беренчедән, балаң бик яшь...

Гөлчәһрә *(аны бүлдереп)*. Әниләр Казанга килде. Алар карап тора ала. Сырлыгыа кайтарып куярга мөмкин. В конце концов, мин аны үзем белән Мәскәүгә дә ала алам! Детдомга биреп торырмын.

Такташ. Гөлчәһрә! Ай-яй... Син үзең бала шул әле. Ай җинел карыйсың... Соң, бала бит ул. Йодрык хәтле беспомощный бер җан. Кая куясың аны?

Ак Дус. Гөлчәһрә, минемчә, син ашыгасың. Яңа тормыш ул шигырьләрдә җырларга гына матур. Ә монда тере җан иясе.

Гөлчәһрә *(кызып)*. Сиңа гаиләле кешеләргә киңәш бирергә иртәрәк әле. Синең башыңда җил уйный, атна саен гашыйк буласың... Киңәш биреп утырган була тагы...

Такташ. Гөлчәһрә! Бу мәсьәләне үзебез генә хәл итәрбез, ярыймы, аппагым? Сиңа борчылырга ярамый, әзлегерсең.

Гөлчәһрә. Миңа бер атнадан китәргә кирәк. Кышкы каникуллар бетә. Укулар башлана. Соңга калырга ярамый.

Такташ. Бер тиен акча юк...

Гөлчәһрә. Киемнәремне сатармын! Менә шул бер тиен булмаганга укыйм да инде мин. Киләчәктә шушы хәерче тормышта яшәмәс өчен!

Такташ. Гөлчәһрә!

Кара Дус. Карале, Такташ, баласын карарга кеше дә булгач, әллә укуын дәвам итсенме соң? Илгә укымышлы хатын-кызлар бик кирәк бит, үзең беләсең.

Такташ. Ә нигә ул минем хатын хисабына булырга тиеш? Минем баланың анасы хисабына?

Гөлчәһрә. Сине вак буржуа дип белеп сүгәләр икән. Кара син аны — «минем хатын»! Бала анасы! Ә социализмны кем төзер?!

**Теге якта бала елый башлый.**

Такташ. Их! Әйтер идем инде... Бар, әнә, социализмның җылап ята.

**Гөлчәһрә чыга.**

Кара Дус. Бик борчылма, Такташ.

Әнә, минеке дә укыган бит. Беләсеңме, яшәргә җайлырак, дус. Любой нәрсәне аның белән киңәшәм. Бөтен законнарны белә.

Такташ. Сезнең бала юк...

Кара Дус. Ничего, балагызга да берни булмас. Үзең барырсың, ул кайтыр... Борчылма.

Ак Дус. Ә мин барыбер җибәрмәс идем! Бәйләп куяр идем! Бикләп куяр идем. Янымда гына утыртыр идем. Их, Такташ... *(Чыгып китә.)*

Кара Дус. Син аңа игътибар итмә. Гөлчәһрәгә һаман гашыйк бит ул. Шуңа өйләнми дә. Нишләтәсең инде, тилене чәчеп үстермиләр бит. Йә, ярый, мин дә кузгалыйм әле. Карчык көтә торгандыр.

Такташ. Парлашып килегез, дус. Гөлчәһрә киткәнче, тагы килеп чыгыгыз... Бәлки кирегә үгетли алырсыз?

Кара Дус. Ярый, кагылырбыз әле. (Китә.)

Такташ *(ялгыз)*. Нәрсә инде бу? Яши генә башладык — инде җимерелүеме? Нигә кешеләрнең кеше кебек тә, минем генә барысы да шулай катлаулы соң? Шигъриятта бөтен йөрәгемне биреп яздым — кычкырып көлделәр, мыскыл иттеләр. Бөтен җаным белән гашыйк булып, тиңсез башымны пәри кызының аяк астына салдым — атлап чыгып китәргә җыена! Әллә мин үзем артык катлаулы яшимме соң? Кеше кебек барысына да төкереп, бер көнлек рәхәт өчен генә яшисеме әллә? Йә план, расчет белән генә? Нәрсә сөйлим мин? Бөтенләй саташтыра мине бу Гөлчәһрә!

**Гөлчәһрә чыга.**

Гөлчәһрә. Чак йокыга китте. Сөт тә бетеп бара. Иртәгә нишләрбез?

Такташ. Син нишлисең? Син Мәскәүдә укырга китеп барасың. Миңа хәл итәргә барысын да.

Гөлчәһрә. Йә инде, син ир-ат бит, юкка җебеп утырма. Бүген үк баланы әниләргә илтеп куярбыз. Ул җаен табар. Бала үстергән кеше.

Такташ. Гөлчәһрә! Китмисеңме әллә, канатым? Син дә булмасаң, җүләрләнәм бит мин монда. Акылымнан шашам бит мин синнән башка.

Гөлчәһрә *(көлеп)*. Шигырь язарсың! Шагыйрь кешегә язу өчен сагыш кирәк, газап кирәк, аерылу кирәк. Менә дигән шигырьләр язарсың.

Такташ. Берне язарсың, икене язарсың. Биш ел бит ул, Гөлчәһрә! Биш ел синсез. Янып, ташка әйләнермен бит мин! Бер-беребезне югалтырбыз без синең белән...

Гөлчәһрә. Юкны юрап утырма әле. Тукта, тукта, тукта! Син мине көнләшәсеңме әллә? Шуңа күрә җибәрәсең килмиме?

Такташ. Үлеп көнләшәм. Яныңнан искән җилдән дә, сөялгән баганаңнан да көнләшәм! Өстеңә кигән күлмәгеңнән дә көнләшәм, ул миңа караганда сиңа күбрәк сарыла! Көнләшәм, Гөлчәһрә. Көнләшүемне дә беләсең, яратуымны да... Китмә, бәгърем. Укып бетер монда гына. Хоть көн саен үзеңне күреп, исәнлегеңне белеп торырмын.

Гөлчәһрә. Юк, Ади, юк. Без монда гомердә дә кеше арасына керә алмыйбыз. Хәзер башка заман. Мәдрәсә белеме белән генә әллә кая барып булмый.

Такташ. Мин — шагыйрь. Аңлыйсыңмы, шагыйрь!

Гөлчәһрә. Син — бүген шагыйрь. Иртәгә кем буласыңны кем белә? Әнә газета битләрендә ничек талыйлар үзеңне. Кругом бит! Вак буржуа да калмый, черек идеология, чит элемент, тагы әллә нәрсәләр. Мин беләм синең ярлы Хәйрук малае, чабаталы даһи икәнеңне, үзең беләсең. Син үз-үзеңне яклый алмыйсың. Менә мин сине яклар өчен укырга тиеш. Мин университетның юридик факультетына да шуның өчен барам.

Такташ. Мине яклар өчен, значит?

Гөлчәһрә. А как же! Сине, үземне, улымны. Икебезнең беребезгә укырга кирәк. Хис белән генә тамак туймый.

Такташ. Гел болай булмас әле, Гөлчәһрә. Менә пьесага утырам, хикәяләр язып карарга да исәп бар. Әгәр китүеңнең сәбәбе шул гына — хәерчелек кенә булса — көн-төн эшлим! Баш күтәрми язам! Китмә генә!

Гөлчәһрә. Их, Ади! Син хәзер дә көнтөн эшлисең бит! Булмый, шигырь язып кына яшәп булмый. Гаилә, бала булгач, бигрәк тә... Әле әти-әниләрең, туганнарың тыелып көтеп тора. Әниләрең хат саен хәлләре авырдан зарланалар.

Такташ. Аларның хәлләре безнекеннән дә авыр шул. Шигырь язып кына рәткә сала торган түгел. Ә впрочем, синең укуыңнан да ярдәм көтмим мин. Йөрәгемдә әллә нинди шом. Сине мәңгегә югалтырмын кебек.

Гөлчәһрә *(каршысына тезләнеп)*. Шашкан даһием минем! Мин бит төшләремдә дә синең тавышыңны ишетеп уянам! Синдәге йомшаклык, синдәге наз, синдәге күңел — бөтен дөньясында юк бит алар! Җүләрем! Яратам! Шашып яратам! Телисеңме, мин сиңа әле ун малай табып бирәм?! Укыйм да, балаларыңа ана да булам — син сабыр гына ит, син бераз көт кенә!

Такташ. Көтәм... Мин гомер буе көтәргә дә риза. Тик... җаныма хыянәт кенә итмә, Гөлчәһрә! Мин синең хыянәтеңне күтәрә алмам.

Гөлчәһрә *(кулларыннан үбеп)*. Беркайчан да, беркайчан да!

**Теге якта бала елый. Гөлчәһрә аны алып чыгып, Такташка тоттыра. Үзе әкрен генә чыгып китә. Такташ баланы көйләп йоклата. Бүлмә караңгылана. Такташ баланы кроватька сала. Караңгыда Такташ һәм бала кроваты гына яктыртыла. Тагы тәрәзәдән җил-давыл бәреп керә. Такташның бөтен бүлмәсен туздыра. Такташ күкрәге белән бала кроватын җилдән саклый. Бүлмәдә кәгазьләр оча. Такташ, зур көч, газап белән кровать-бүлмәне (ягъни, тормышны) югарыга таба этеп алып менә башлый. Җил бераз тынган арада кровать өстенә куеп шигырьләр яза. Идән тагын кәгазьләр белән тула. Тирә-юньдә — шайтан, пәри туе. Зур корсаклы түрәләр, чиновниклар, тук тормышлы кешеләр. Такташ һаман тормышны бер ялгызы**

югарыга таба этә. Чит-читтән тавышлар — «Ижатына крест куярга кирәк!», «Сызып ташларга!», «Вак буржуа!», «Талант!», «Чабаталы даһи!», «Ха-ха-ха!» 1926, 1927, 1928 еллар — ялгыз гаилә тормышы артта кала. Такташ һаман менә дә менә.

*Пәрдә*

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**1929 ел. Казан. Такташ бүлмәсе. Өстәлдә Гөлчәһрә фотосы. Такташ Гөлчәһрәгә хат язып утыра. Эфирда хат тексты:**

«Гөлчәһрә!

Сиңа 15 сум акча җибәрдем. Үзебез бертөрле торабыз. Бала исән. Үземнең настроение бик начар. Ялгызлык, юксыну, әллә нәрсә. Торасың, эшлисең, әллә нәрсә. Ә бит дөньяга яшәр өчен килгәнбез — ә яшәвебез әллә нинди юлсызлык, кызыксызлык белән бара. Аерылып торуның да чиге булырмы икән? Соңгы вакытларда эшләгән дә юк. Эшләргә дәрт тә юк. Эшләвемнең кирәге дә юк. Сине сагынам. Тыныч, поэшмый, әллә нинди сагыну белән сагынам. Соңгы көннәрдә бигрәк ялгыз. Кемне дә күрәсе килми. Сөйләшәсе, шулай ук үземне-үзем дә күрәсе килми. Әллә нәрсә йөрәктә. Сау калам.

**Такташ.**

*4 январь 1929 ел»*

**Ишектә Ак Дус күренә.**

Ак Дус. Әллә йоклыйсың инде, Такташ?

Такташ. Йоклыйм, дустым, җаным йоклый, йөрәгем йоклый. Уятучымны югалттым.

Ак Дус. Син бигрәк хис кешесе, Такташ. Бер генә минут газапланмый, бәргәләнми торган вакытың бармы икән синең?

Такташ. Мин сиңа әйткән идем бит инде — янмасам, газапланмасам, мин шагыйрь түгел, дип. Тик соңгы вакытта тормыш мәшәкатьләре, ваклык күмеп китте. Җанны шул баса.

Ак Дус. Сизелә, Такташ, сизелә. «Югалган матурлык»та да нык сизелә ул.

Такташ. Укып чыктыңмы?!

Ак Дус. Укыдым. Яхшы нәрсә. Но сүзе күп булачак. Хатын-кыздан. Җәмәгать эшлеклесе дип йөргән вакытта, син аны бөтенләй өйгә бикләп куярга өндисең!

Такташ. Аңламагансың! Сүз хатын-кызны йортка бикләү турында бармый, сүз хатын-кыздагы гүзәллекне, аңа табигать биргән сыйфатларны саклап калу турында бара! Әлбәттә, һәрбер укучы, караучы шушылай аңласа, тәнкыйтьтән башың чыкмас.

Ак Дус. Нәкъ шулай аңлаячаклар. Әле сине үз тормышыңны язуда гаепләячәкләр. Кайбер элементларын мин дә шөйләдем.

Такташ. Но монысы инде слишком! Әдәби әсәрдән тагы минем гаилә серләрен эзли башласыннар!

Ак Дус. Мин әйттем, калганын үзең уйла. Син — автор. Син — даһи. Син — Такташ. Мин бер футурист кына.

Такташ. Синең күңелең ак. Син уйлаганыңны әйтәсең. Минем янда соңгы вакытта берне уйлап, икенчене эшләүчеләр күбәйде ахыры. Үземнең янда шигырьләремне мактап чыгып китәләр дә, карыйм — икенче көнне газетада тәнкыйть. Шул «дус»ның берәрсе язган була...

Ак Дус. Бар, андыйлар да бар. Мин үзем дә күп кыйналам. Ләкин мин синең кебек йөрәккә якын алмыйм. Кызык кына.

Такташ. Ныклабрак, бәгыреңә үтәрлек итеп кыйналганың юктыр әле.

Ак Дус. Кем белә?.. Минем бит әле ныклап язганым да юк.

Такташ. Анысы дөрес.

Ак Дус. Такташ, керүемнең сәбәбе башка иде. Мәскәүгә барышым. Гөлчәһрәгә берәр сүзең юкмы?

Такташ. Мәскәүгә барышың?! Нигә?

Ак Дус. Соң, йомыш белән. Нәшрият тирәләренә. Болай, шәхси эшләр дә бар. *(Елмая.)* Йөрәк мәсьәләсендә.

Такташ. Йөрәк? Тукта, ә Гөлчәһрәнең кайда торуын син кайдан беләсең?

Ак Дус. Аны кем белми? Мәскәүгә барган саен күрәбез бит.

Такташ. Ничек?! Син Гөлчәһрәне һәр баруыңда күрәсең? Әйтмәгән иде... Сәер.

Ак Дус. Нәрсәсе сәер инде аның. Ул бит кызлар белән тора. Кызлар бар җирдә мин һәрвакыт хәзер инде! *(Салют бирә.)*

Такташ. Күзләрең гөнаһсыз, дустым. Әллә уйныйсың гынамы? Юктыр, юктыр...

Ак Дус. Кая, бармы сәлам хатың? Китешем югыйсә.

Такташ. Бар, дустым, бар! Үз кулына тапшыр. Тизрәк кайтсын. Кайбер имтиханнарын җәйгә калдырырга да була. Такташ сагынудан җүләрләнә диген... Юк, берни әйтмә. Менә, хатны гына тапшыр.

Ак Дус. Ярар, бер атнадан җавабын алып кайтырмын. Кәт. *(Китә.)*

Такташ *(ялгызы)*. Көтмичә ниш.лисең?.. *(Кульязмаларын кулына ала.)* 18 январьда театрда «Югалган матурлык»ны уйнаячаклар. Соңгы вакытта күңел кушуы буенча язылган бердәнбер әйбер. Казан мещаннары ни әйтерләр икән? Төрле яктан тагы ут ачарлар инде. Әй, кадалып китсеннәр! *(Язарга утыра.)*

**Кара Дус керә.**
**Эфирда Кара Дус уйлары.**

Яза, һаман яза. Нәрсә шул чаклы мәҗбүр итә аны тилереп, котырып язарга? Ярым ач, ташланган, тибелгән. Ә һаман яза. Менә минем язар өчен бөтен шартларым бар — җылы өем, назлы хатыным, өстәл тулы сыем, дорожаль урыным. Ә яза алмыйм. Ул яза, ә мин яза алмыйм! Халык аның өчен үлеп тора, мине эш урыныма карап кына саныйлар. Нәрсә бу?! *(Кычкырып.)* Нәрсә бу?

Такташ *(борылып)*. Ә, иң якын дустым! *(Кочаклап ала.)* Уз, утыр әйдә. Иң ямансу чакларымда әле дә ярый син бар. Эч пошудан үземне кая куярга белмим.

Кара Дус. Мин сиңа сөенечле хәбәр белән килмәдем әле, Такташ. Мин дә үземне кая куярга белмим. Синең өчен, синең гаиләң өчен борчылам...

Такташ. Тагы Гөлчәһрә турындамы? Ни ишеттең?

Кара Дус. Берни дә ишетмәдем. Ишетсәм дә сиңа әйтмәс идем. Барыбер ышанмыйсың. Аның күпме случайларын мин сиңа әйтә килдем, гел гафу итә килдең.

Такташ. Гайбәт иде бит ул! Без Гөлчәһрә белән аңлаштык бит инде.

Кара Дус. Хатын-кызга ышанма син. Мәскәүгә баргач, минем үземә дә күзләрен бик уйнаткан иде ул. Киноларга чакырган булып, кичләрен бакчалардан әйләнеп килик, дип.

Такташ. Син! Син шушыңа чаклы бу хәлләрне миңа әйтмәдеңме?! Син — минем иң якын дустым — шушы эшләргә бардыңмы?! *(Йөзен каплап читкә борыла.)*

Кара Дус. Соң, Такташ, соң, җаным, барсам, сиңа сөйләп торыр идемме? Йөрәгемә түзә алмаганга гына сөйлим. Сине жәлләп. Их, син аңламадың... *(Китә башлый.)*

Такташ. Зинһар, китмә. Калдырма мине ялгызымны. Әйтер сүзең ул түгел бит...

Кара Дус *(кире килеп)*. Ул түгел иде шул. Но синең болай да чыкмаган җаның гына калган. Анысын да әйтсәм, бөтенләй аяктан егыласың.

Такташ. Әйт.

Кара Дус. Безнең Ак Дус Мәскәүгә Гөлчәһрә янына китте.

Такташ. Беләм. Ул миңа әйтте.

Кара Дус. Әйтте?! Барган саен керүен дә әйттеме?

Такташ. Анысын да әйтте. Мин әле Гөлчәһрәгә хат та биреп җибәрдем.

Кара Дус. Их, Такташ, бөтенләй сукырайгансың икән син. Ул бит Мәскәүгә синең хатының белән гыйшык-мыйшык уйнар өчен генә йөри. Хат илтә, имеш. Ах, дустым, дустым, башың бер дә юк икән.

Такташ. Тукта, ничек гыйшык-мыйшык? Ул бит минем дустым, шагыйрь кеше.

Кара Дус. Булса соң! Ул бит Гөлчәһрәне гомере буе яратты. Өйләнми дә бит. Соң, аларның яратышуларын, йөрүләрен ярты Казан, ярты Мәскәү белә бит инде! Син белмәмешкә салынасың.

Такташ. Беттем. Җир йөзләренә чыгарлыгым калмады. Чат саен бармак төртеп миннән көләрләр. Их, Такташ! Харап иттең тиңсез башыңны хатын-кыз белән бәйләп!

Кара Дус. Кайгырма, дустым! Аер да җибәр син аны. Менә дигән кыз табып бирәбез без сиңа.

Такташ. Аны беркем дә алыштыра алмый... Беләсеңме, нәрсә әйтсәләр дә, шушы хәлендә дә... сагынам... яратам... аңа ышанам, кеше сүзенә түгел.

Кара Дус. Бала-чага булма. Бүген Мәскәүгә чыгып кит, бүген эзләренә төшәсең. Күзәтеп йөр. Бер атна йөр, бер ай йөр, барыбер эзләренә төшәрсең. Сүземне тыңла, дурак булма.

Такташ. Шагыйрь кеше өчен болай йөрү — түбәнлек. Болай йөргәнемне белсә, Гөлчәһрә үзе аерылырга гариза язачак. Син әле аны белмисең.

Кара Дус. Язмый! Хатын-кыз язамы соң?! Шулай мыскыллап, теңкәнә тия әле ул синең. Тиенләп акчаңны суырып ятып... Бар тапканыңны шуңа җибәреп ятасың бит. Башыңа кияргә бүрегең дә юк... Кеше арасында синең өчен кызарам...

Такташ. Нишләргә соң? Әллә чынлап та барып кайтыргамы? Юлга акча ягы да такыр. Шушы көннәрдә пьеса да уйналырга тиеш. Хатын-кыз артыннан йөри торган вакытмы соң?!

Кара Дус. Акчасын үзем биреп торам. Мә, күпме кирәк? Бар, йөр, күр.

Такташ. Алайса, болай итәбез. Мин тиз генә театрга барып кайтам. Пьесада үзгәртәсе урыннар бар иде. Эшкә дә кереп чыгарга кирәк. Записка булса да калдырырмын. Син, зинһар, бала янында утырып тор инде. Ул бераз авырыбрак тора иде.

Кара Дус. Ярар, бар, бар, борчылма, утырырмын. Журнал өчен тәмамлыйсы мәкаләм бар иде. Шуны карап чыгармын.

Такташ. Әнә, минем пьесага да күз салып алсаң була. *(Китә.)*

Кара Дус. Йөгерәсеңме? Йөгер-йөгер, тормыш йөгертә ул. Бу сиңа янар таулар, җен кызлары турында шигырь язу гына түгел! Чабаталы даһи! Казанның иң гүзәл кызына нәфсең сузды бит! Үзенең кем икәнен белмичә. Соң, андый гүзәлләрне саклый алырлык нәрсә бар соң синдә?! Нәрсә?! Талант диярсең, бәлки? Талант... Андый гына талант бездә дә бар ул. Үтә кызыл тиз уңа ди. Үз урныңа утыртырлар әле сине, тәти җегет. Кара бу бүлмәдәге салкынлыкны! Башыңа киеп утырмасаң, колагың өшер. *(Бүрегев кия. Кульязманы алып карый.)* Бөтен татар театры, авыз суларын корытып, шушы әйбер турында сөйлимени инде? Да, тел бар инде үзендә... Бар монда хикмәтле нәрсәләр. Әйдә, куелсын әле. Бу инде сиңа тиләләр турында шигырьләр генә түгел, моның өчен *(өскә күрсәтеп)* әнә анда җавап бирергә туры киләчәк. *(Тагын кәгазьләр карый башлый.)*

**Ишектән әкрен генә Гөлчәһрә керә. Башында озын колаклы ак куян бүрек, өстендә кыска тун. Кулында чемодан. Ул килеп, Кара Дусны арттан кочып ала.**

Гөлчәһрә. Үләм! Сагындым! Сагындым... Кулларыңны сагындым, күзләреңне сагындым. Даһием, шашканым, көнчелем, җүләрем. *(Алдына тезләнә.)*

Кара Дус. Йә, хода! Дөньяда шулай итеп тә яратып буламы икәнни?!

Гөлчәһрә *(сискәнеп сикереп тора)*. Син кем?! *(Пистолетын чыгара.)* Ничек монда кердең? Җаныңны җәһәннәмгә очырам бит хәзер!

Кара Дус. Чү, чү, Гөлчәһрә! Бу мин бит, мин. Такташ театрга китте, мин бала карап утырам.

Гөлчәһрә. Син?! *(Кычкырып көлә башлый.)* Атып үтерә яздым бит үзеңне. Такташ дип белеп, ялгыш кочаклап та ташладым ахрысы.

Кара Дус. Гомеремдә андый назны беренче күрдем. Син Такташка гел шулаймы?

Гөлчәһрә. Мин Такташка гел шулай! Мин аны сихерләдем! Мин аны яратам. Мин аны ашап бетерер идем. Менә бер төнгә, бер көнгә күрер өчен кайттым үзләрен. *(Бала янына килә.)* Йоклыйсыңмы, улым? Үсеп киткән. Тагы бер ел укыйсым калды. Аннары бер көнгә дә аерылмас идем үзләреннән!

Кара Дус. Йә, Мәскәү нишли анда, Гөлчәһрә?

Гөлчәһрә. Мәскәү гөрли. Ул лекцияләр, ул театрлар, ул магазиннар! Йә, мин үзгәргәнме? Ябыкмаганмыным?

Кара Дус. Икенче мондый гүзәлне күргәнем юк әле... Минем сине күргәч үк, тәннәрем чымырдый башлый.

Гөлчәһрә. Йә, йә, күп сөйләшмә. Йә, Такташны көнләштерерсең. Минем чабаталы даһием нишләп йөри соң?

Кара Дус. Йөри. Тегеләй язып карый, болай язып карый. Аллалар чоры үтте, этләр, мәчеләр чоры да үтте, хәзер әнә, хатын-кызны сөгеп язмакчы.

Гөлчәһрә. Син гомер буе Такташны яратмадың. Ә Такташ шуны аңламый бит. Үзе ир-ат, нинди шагыйрь! Ә синең кара уйларыңны сизми.

Кара Дус. Кем аркасында, кем аркасында шушы хәлгә килдем мин?! Арада гел син басып тордың! Мин аның шагыйрьлегеннән түгел, ирлегеннән көнләштем! Синең аныкы булуыңнан көнләштем. Гөлчәһрә! *(Кулларын үбә башлый.)* Яратам мин сине! Хатыныма да бөтен дөньясына, сиңа үч итеп кенә өйләндем. Бир миңа назларыңны, назга, җылылыкка сусадым мин... *(Кочаклмакчы була.)*

Гөлчәһрә. Кит! Син нишлисең?! Үз өемдә миңа шундый сүзләр сөйлисең?!

Кара Дус. Башка җирдә дә була! Ризалыгыңны гына бир! Син бит дөнья бәһасе хатын! Риза гына бул! Такташны да бу хәлендә яшәтмәм. Дөньяның патшасы итәрмен. Риза бул...

Гөлчәһрә *(барып утыра)*. Димәк, син миңа шундый нәрсә тәкъдим итәсең? Өемә килеп...

Кара Дус. Мәхәббәт тәкъдим итәм... Сөю-сөелү.

Гөлчәһрә *(сикереп торып)*. Мәхәббәт түгел бу! Син миңа азгынлык тәкъдим итәсең! Урам хатыннары белән генә шулай ачыктан-ачык сөйләшәләр!

Кара Дус. Нәрсә, Мәскәүдә кем туры килсә, шуның белән ярый, ә монда сайланабызмы?

Гөлчәһрә. Нәрсә? *(Пистолетын чыгара.)* Бас шушында, җаныңны җәһәннәмгә җибәрәм хәзер шушы сүзләрең өчен!

Кара Дус. Гөлчәһрә! Мин шаярттым гына. Сынап кына карыйсым килде.

Гөлчәһрә. Бас! Бер, ике...

Кара Дус *(алдына тезләнеп, үрмәләп килә)*. Тукта... Такташ шулай кушты... Сынап кара, диде. Шаярттым гына... Тукта...

**Ишектән Ак Дус кереп, карап тора.**

Ак Дус. Бу нинди комедия тагы?

**Кара Дус сикереп торып, Ак Дусның артына барып баса. Гөлчәһрә бала кровате янына борыла.**

Кара Дус. Әнә! Мәскәүдән бөтенләй котырып кайткан! Тезләнеп ялындым, Такташ белән арагызны бозмагыз дип. *(Ак Дусны читкә тартып, әкрен генә.)* Әле миңа әллә нәрсәләр тәкъдим итте... «Дустымның хатыны белән алай эшли алмыйм», — дип кенә котылдым. Син дә кылларын чиртеп кара әле. Капмасмы... Хи-хи-хи!

Ак Дус *(көлмәк якасыннан алып)*. Мин синең үзеңне каптырам хәзер, кара җан! Менә монысы Такташ өчен! *(Яңагына суга.)* Менә монысы Гөлчәһрә өчен! *(Икенче яңагына суга.)* Бар, хәзер ычкын! Дөньяны сасыт!

Кара Дус *(тешен кысып)*. Ярар... Ярар! Күрербез! Күрсәтербез! *(Чыгып китә.)*

Ак Дус *(Гөлчәһрәнең иңнәреннән сыйпап)*. Елама, Гөлчәһрә! Аның монда башка эзе булмас.

Гөлчәһрә. Соң Такташ барыбер шулар арасында кала бит! Шулар арасында, шулар кулы астында. *(Елап, Ак Дусның күкрәгенә каплана.)* Әллә барысын да ташлап, кайтыйммы икән? Әйт бер сүзеңне, Ак Дус?! Мин хәзер сиңа гына ышанам.

Ак Дус. Ашыкма, Гөлчәһрә. Үзең әйткән идең бит, болар белән көрәшер өчен белем кирәк, дигән идең. Ашыкма, күп калмады... Мин дә Мәскәүгә баргалап йөрермен.

**Ишектән атылып Такташ килеп керә.**

Такташ. Димәк, дөрес... *(Гөлчәһрә сискәнеп башын күтәрә.)*

Гөлчәһрә *(аңа атылып)*. Һади! Һадием!

Такташ. Тукта! Карама миңа алай итеп, карама! *(Йөзен читкә борып, бала кровате янына килеп утыра.)* Менә нәрсә, Гөлчәһрә! Синең турыда монда инде ничә еллар төрле сүз, гайбәт йөри. Мин һаман ышанмый килдем. Инде үз күзләрем белән күрдем! Кит!

Ак Дус. Такташ, туктале, син ни сөйлисең?

Такташ. Икегез дә чыгып китегез! Моннан соң берегез — хатын, икенчегез — дус түгел. Чыгып китегез... *(Бала кровате өстенә каплана.)*

Гөлчәһрә. Һади! Нишләвен бу, Һади?! Мин бер генә төнгә кайттым. Сине, улымны күрермен, дип кенә кайттым. Ни сөйлисең син?!

Такташ. Мин сиңа ышанмыйм! Мин сине яратмыйм! Мин сине күралмыйм! Кит.

Ак Дус. Их, Такташ! Чынлап та, сукыр икәнсең син! Киттек, Гөлчәһрә! Суынсын бераз даһи башы.

Гөлчәһрә. Нишләп синең белән китим мин?! Сез әле Гөлчәһрә Хәмзинаны белмисез! *(Такташка.)* Ут вакытымны күрдең, таш вакытымны да татырсың! *(Пистолетын алып, чыгып китә.)*

Ак Дус. Гөлчәһрә! Үзенә берәр нәрсә эшләмәсен тагы! Гөлчәһрә! (Чыгып йөгерә.)

**Кроватьта бала елаган тавыш ишетелә. Такташ башын күтәрә.**

Такташ. Кемгә ышаныйм?! Кемгә?! Тирә-ягым ялган, гайбәт, каралык, талантсызлык белән тулы. Кем бар шагыйрь хәлен аңларлык? Кем?!

**Караңгылык.**

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**1929 ел, 27 январь. Татар мәдәнияты йорты. Яшь язучылар түгәрәге җыелышында Такташның «Югалган матурлык» пьесасы тикшерелә.**

Такташ *(пьесаның ахырын укый)* «...**Галия.** Газиз... Газиз... Син йоклыйсың? *(Пауза.)* Ул арып йокыга киткән... Газиз, минем хәлем бик авыр. *(Аяк өстендә тора алмый, хәлсез генә җиргә утыра.)* Сөекле дустым, юк, юк, мин синең мине алдавыңа ышанмыйм... Син миңа яхшы ир идең. Син бөтен көчең белән мине югалтмаска тырыштың... Син миңа яхшы иптәш идең. Шуның өчен дә... *(Ютәлли.)* Шуның өчен дә өзелеп яраттым... Син әйт миңа. Мин синга ике сорау белән киләм. Мин үземнең исәнлегемне югалттым. *(Буылып ютәлли.)* Мин үземнең, мин үземнең аналыгымны югалттым... Мин бөтен матурлыгымны югалттым. Әйт, әйт, мин кешелек дөньясы алдында беренче ана булырга тиешле идемме, яки җәмгыять эшчесеме? Син әйт миңа! *(Ул үксеп елый башлый, аның үксүе тыела алмаслык ютәлгә әйләнә. Иреннәре буенча кан елгалары ага. Ул күкрәген тотып җиргә каплана. Скрипка тавышы һаман ишетелә. Газиз тын гына йоклый. Бераздан бүлмә тынлыгы эчендә Галиянең соңгы авыртулы ыңгырашуы ишетелә.)* Пәрдә әкрен генә төшә». Иптәшләр, пьеса тәмам. Сездән чын иҗат кешеләренчә фикер көтәм. Моңа хәтле минем әсәрләремнең идеологиясен тикшереп җанга тияләр иде, бәлки бу юлы әдәби эшләнешенә, образларга игътибар итәрсез. Чөнки бу нәрсәләр минем алга таба үсүем өчен дә бик кирәк.

Яшь артист *(урыныннан)*. Минем Такташка бер соравым бар. «Югалган матурлык» әле 18е көнне генә татар театрында уйналды. Аннан Такташны «Кызыл Татарстан»да бик каты тәнкыйтьләп чыктылар. Шушы тәнкыйтьтән соң да, нигә ул пьесаны безнең алда укырга уйлаган?

Такташ. Чөнки, минем уйлавымча, рецензия очраклы бер кеше тарафыннан язылган. Ул хәтта үзенең фамилиясен дә күрсәтергә курыккан — мәкаләсенең ахырына «Бис» дип кенә куйган. Мәкалә бик бер яклы, тенденциоз характерда язылган. Ул мине сәяси наданлыкта, сукырлыкта гаепли. Соң, җаным, лозунг ыргытып та, шуны утәлде дип, авыз күтәреп йөри икән, ул үзе сәяси надан. Безнең әле күп лозунгларыбыз һавада эленеп тора. Кем сукыр соң монда? Мин — булган кимчелекләрне күреп, әйтеп биргән өченме, яки күреп тә күрмәмешкә салынып йөргән, башкаларны да күрмәскә өйрәтә торган «ялган авторлар» гаеплеме? Каршылыклар күп...

Алып баручы *(кыңгырау шалтыратып)*. Мәсьәләдән читкә кителде. Такташ, пьесаң турында гына сөйлә.

Такташ. Мин шул турыда сөйлим дә. Йә, тагы кемдә нинди фикер бар? Миңа сезнең бүгенге фикерегез бик мөһим. Чөнки мин «Югалган матурлык»ның бу бәя белән генә калуын теләмим.

Яшь шагыйрь. Такташ, син үзең ничек уйлыйсың — хатын-кыз ана булырга тиешме, җәмгыять эшчесеме?

Такташ. Икесе дә. Ләкин җәмгыять эшчесе булу аның ана булуына зыян китерергә тиеш түгел. Начар ана икән, аның яхшы җәмгыять эшчесе булуының кирәге юк.

Урыннан тавышлар. Долой! Буржуй җыры. Ул хатын-кызны өйгә бикләп куярга куша! Аның үзен бикләп куярга кирәк! Ха-ха-ха! Чит элемент!

**Алып баручы кыңгыравын шалтырата.**

Матур кыз. Такташ, сезгә бер сорау. Сезне хатыныгыз ташлап чыгып киткән, диләр. Бу пьесаны да шул ачудан язгансыз, ди. Шул дөресме?

Такташ. Туташ! Гаиләмдәге шәхси эшләрне мин биредә сөйләргә җыенмыйм. Ә пьеса мәсьәләсенә килгәндә, Галия кебек эш белән гаилә арасында бәргәләнеп йөрүче хатыннар — мең вә миллионнар! Мин алар турында яздым. Мин аларның язмышы, киләчәге өчен борчылып яздым. Шул ук вакытта сезнең язмыш өчен дә.

Яшь журналист. Нигә бөтен коммунистлар, комсомоллар сезнең пьесада кире типлар? Сез нәрсә, моның белән безнең политик стройга кизәнәсезме?

Астан тавышлар. Әйе, җавап бирсен! Нигә барысы да кара?! Эчкечеләр дә алдакчылар! Нигә җүнле кешеләрне алмаган?!

Такташ. Җавап бирәм. Әсәрдә җүнле кешеләр дә бар. Ләкин алар менә шушы черек мещаннар сазлыгында берничә генә. Хәзергә әле аларның тавышлары күмелеп китә. Аның өчен башта менә бу сазлыкны чистартырга, баш миләренә ачыклык кертергә кирәк! Коммунистларның коммунист урынында, аналарның ана урынында булуы кирәк!

**Астан сызгырулар, кычкырулар.**

Матур кыз. Такташ, сез «Азат хатын» журналында эшлисез икән. Хатын-кызга карата шушындый черек, мещанский караштa торганда, сез ул журналда эшләргә хаклымы соң? Сез бит коточкыч куркыныч тип!

Астан. Долой! Долой! Эштән куарга! — дигән сүзләр ишетелә.

Алып баручы. Туктатыгыз! Бу Такташка суд түгел! Фикер алышу гына. Калганын башка урында хәл итәрләр. *(Кара Дуска.)* Сезнең берәр фикерегез юкмы?

Кара Дус. Иптәшләр! Бераз гына басылыйк әле. Суыныйк. Уйлыйк. Менә без бүген Такташның пьесасын укып чыктык. Төрле фикерләр ишеттек. Кызып китүчеләр

дә булды. Минем үземә килгәндә, пьеса шактый четрекле мәсьәләләрне күтәрергә тырышкан. Плюслар да, минуслар да бар. Әйе, үсеп килә торган социалистик җәмгыятьтә әле төрле типлар очрый. Әмма шулай булуга карамастан, безнен илебез гөрләп чәчәк ата! Татарстан кырларына техника үтеп керде. Кызыл яулык бәйләгән хатын-кызларыбыз завод-фабрикаларда җырлап тимер кыралар!.

Ак Дус *(астан)*. Син пьеса турында сөйлә! Әллә үзеңне актив җыелышында дип белдеңме?

Кара Дус. Сөйлим! Пьеса турында да сөйлим... Кайда калдым әле? Әйе, илебез гөрләп чәчәк ата!

Иптәшләр! Мин бүгенгесе көннән шагыйрь Такташны, вак буржуа арасыннан чыккан Такташны үз тәрбиямә алам! *(Астан кул чабалар.)* Ул пролетариат шагыйре булырга тиеш. Җитте ана черек тормыш баткагында казынырга! Ул — талантлы шагыйрь! Даһи!!! Ул әле илнең менә дигән җырчысы булачак! Сез шагыйрьне бер дигәндә үтереп ташларга ашыкмагыз, әле аннан җырлатырга кирәк! Бугазына басып, чүкеч тавышы астында җырлатырга кирәк! (Астан кул чабулар). Мин беренче булып, үзем аңа ярдәм кулы сузам.

Ак Дус. Соң синең үзеңә ярдәм кирәк бит! Син көчәнмичә ике юллык шигырь дә яза алмыйсың бит! Әле Такташка ярдәм итмәкче! Тәрбиягә алмакчы! Түрә булганга гына шулай түш киереп сөйлисең бит син...

Кара Дус. Такташ, мин чын күңелдән, бөтен халык алдында әйткән идем бу сүзләремне. Алай булгач, үзеңә кара. Мин синең юлыннан китәм.

Такташ. Дус, тукта! Кабул итәм мин синең сүзләреңне! Ярдәмеңне дә кабул итәм. Арыдым мин... Синең ярдәмең бик кирәк.

Ак Дус *(үтеп барышлый)*. Такташ, башка кыйблага сәҗдә кыласың.

Такташ. Мин сиңа теге көнне соңгы сүземне әйткән идем инде. Ышанмыйм мин сиңа, аңлыйсыңмы, ышанмыйм! Кермә арага, миңа үземчә яшәргә ирек бир. Үземчә яшәргә ирек бирегез миңа! (Чыгып китә.)

Кара Дус. Ишеттеңме? Бу — аяк астында буталып йөрмә, дигән сүз. Талантыңнан көнли ул синең.

Ак Дус. Шаһитлар күп, концерт күрсәтер идем инде мин сиңа... *(Чыгып китә.)*

**Яшьләр дә таралып бетә.**

Яшь журналист. Сез мактап сөйли башлагач, башта бик гаҗәпләнгән идем...

Кара Дус. Тс-с-с! Күп сөйләшмә. Шулай кирәк. Мәкаләң башта сөйләшенгәнчә булсын. Тозлап-борычлап.

Яшь журналист. Үрле-кырлы сикертәбез Сыркыды мишәрен! Ник Казанга килгәненә үкенерлек булсын!

Кара Дус. Талантыңны кызганма. Эшеннән алдырырлык булсын. Эшеннән чыкса, икенче көнне үк шартлап сына ул. Казанда калмаслык итәбез без аны.

Яшь журналист. Ә нигә сез тәрбия, ярдәм дип маташкан булдыгыз соң?

Кара Дус. Анысы син аңларлык нәрсә түгел... Мин әле аның шагыйрь буларак та таркалып, үз иҗатын үзе бетерүен телим! Менә үзе теләмәгән, үзе яратмаган нәрсәләр турында язып карасын әле ул! Күрербез аннары, даһилыгы нишләр! Миңа ышануы кирәк аның! Һәм минемчә язуы кирәк!

Яшь журналист. Ну баш сездә! Юкка гына шундый урында утырмыйсыз шул.

Кара Дус. Син дә утырырсың! Мәкаләңне генә яз! Кара аны, үзем күзәтеп торам, озакка сузма.

Яшь журналист. Чыгармасалар? Аны яратучы, яклаучылар да күп бит.

Кара Дус. Син яз гына. Чыгару — минем эш.

Яшь журналист. Язам! Такташ ник туганына үзе үкенерлек итеп язам!

**Караңгылык.**

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Такташ бүлмәсе. Такташ Гөлчәһрәгә хат яза. Хатның эфирдагы тексты.**

«Гөлчәһрә!

Теге вакыттагыдан соң гаилә тормышы, бигрәк тә синең белән тормыш, матур тормыш төзүгә бөтенләй дәрт бетте. Аңлыйсыңмы? Бөтенләй, бөтен нәрсә безразлично булып китте. Икебез өчен дә күңелле бер нәрсә тудыруга яки эшләүгә ышаныч та сүнде, дәрт тә бетте. Казандагы бүгенге минем эш мәйданым талантсыз кешеләр белән тулы. Алар бөтен пычраклыклары белән минем юлыма киртә салырга телиләр. Минем әдәби гомеремне Есенин дарына илтеп терәргә телиләр.

...Миңа каршы кешеләр үзләренең тулары белән революция әдәбиятына бәхетсезлек китергән кешеләр. Партия, сукыр рәвештә, кызыл, җансыз, алдаучы сүзләренә карап, аларны яклый. Ул кызыл, җансыз, алдаучы хамелеоннарны, яки тупас, талантсыз иҗат итүче типларны еллар кумәр. Минем алдаусыз хисләрем һаман, һаман шулай калыр. Менә шуның өчен бөтен тупас бәйләнүләрне күтәрергә тырышам. Киләсе югары еллар мине яклар...»

**Кара Дус керә.**

Кара Дус. Хатлар язабызмы? Йә, йә, яшермә, барыбер күрәм бит! Һаман шуңа хат язасың. Нәрсәсе белән сихерләгәндер үзеңне, шаккатам.

Такташ. Башка язар кешем булмаганга язам... Инерция буенча, туктала алмыйча йөгерәм.

Кара Дус. Шигырь язганың да күренми.

Такташ. Язам! Алай да күңелнең ачылып-ачылып киткән вакытлары була. Менә, тыңла! Шәп, якты шигырь яздым. *(Укый.)*

Урам ташларына карлар ява,<br>Кар томалый чана юлларын,<br>Кардан шуа-шуа Алсу килә,<br>Җиң эченә тыккан кулларын...<br>Җилгә каршы бөдрә сулышлары<br>Туңып бөдрә чәчен ак ясый...<br>Юл буена аны тирги-тирги,<br>Сүгнә-сүгнә кайта Газзәсе:<br>— «Алсу, тукта инде, акыллым,

Абау,
Тагы карга батырдың!» —
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
— «Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!»
Үзе — килсә, карга батыра.
Салкын карга басып Алсу килә:
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Кара Дус *(туктатып)*. Булды. Аңлашыла. Тагын үз хатыныың турында. Синең башка язар нәрсәң калмады бугай инде.

Такташ. Дөрес әйтәсең, авыр, дустым. Кайвакытта очраклы нәрсәләр турында шигырь язам. Пьесалар белән дә әнә нәрсә килеп чыкты. Прозага күчеп карыйм. Роман яза башладым.

Кара Дус. Роман?! Нәрсә турында?

Такташ. Анда барысы да булачак. Үткән көннәр дә, киләчәк тә. «Таң җиле» дип атала. Кешенең үз-үзен, үз кыйбласын эзләве турында.

Кара Дус. Табамы соң?

Такташ. Һичшиксез, табачак! Кыйбланы тапмасаң, яшәүдән мәгънә дә юк.

Кара Дус. Безнең кыйбла — илнең алга баруы.

Такташ. Ярый, ул сүзләреңне монда калдырып тор әле.

Кара Дус. Такташ, үпкәләмә, сине вак буржуа дип белеп сүккәннәр бит теге вакытта. Гел кирегә сукалап утырасың бит. Менә газетага да синең турында бик куркыныч итеп язганнар. Кара, һаман мин яклап кала алмам сине.

Такташ. Тагы? *(Газетаны ала.)* «Югалган матурлык» турында? *(Укый.)* «Татар әдәбиятында чит идеология. Кызылга төрелгән чит фикерләр турында». *(Газетаны читкә ташлый.)* Тәмам буржуй ясадылар миннән! Редакторларын әйтер идем. Соң бу бит судка бирелә торган нәрсә! Тоталар да миннән чит идеология эзлиләр. Ә мин — шагыйрь, бары татар шагыйре! Ә алар, тоталар да, миннән чит идеология эзлиләр.

Кара Дус. Үзең гаепле. Син генә илдәге проблеманы күрәсең дә, без күрмибез. Без дә күрәбез. Дәшмибез. Шулай яхшырак.

Такташ. Кем өчен?! Сезнең үзегез өчен яхшыракмы? Әй! *(Кул селти.)* Тагы тирәнгә керәбез. *(Газетаны алып карый.)* Кара, теге яшь журналист малай язган. Әйтәм теге көнне политический сораулар биреп утырган иде. Ул үзе кемнеңдер йомышчысына охшаган. Да, политик яктан суктырган бу, мишәрлектә генә гаепләмәгән.

Кара Дус. Син нәтиҗәсен укы, нәтиҗәсен.

Такташ. Так, нәтиҗә. *(Укый.)*

1. «Югалган матурлык» хәзерге көндә активланып, каты көрәш алып бара торган вак буржуазия, кулак идеологиясенең татар матур әдәбиятына керүен күрсәтә. «Югалган матурлык» — шуның документы.

2. Электән дә идеология ягында тотанаксыз булган Такташ хәзер ачыктан-ачык чит идеология лагерена тәгәри.

3. Безгә матур әдәбиятка һәм аны дыручыларга нык күз салырга кирәк.

Юк, бу аның үз кулы, үз фикере і Ул малайның андый нәтиҗәгә килерлек башы юк. Моның артында кемдер тора

Кара Дус. Ул чагында бигрәк т чар. Димәк, сиңа каршы зур бер кампания күтәрелеп килә.

Такташ. Ул 23 нче елдан бирле кү релә инде. Мин ул кампаниянең исемен н да кемнәр торуын да беләм.

Кара Дус. Кемнәр?

Такташ. Талантсызлар! Талантсы рга һәрвакыт талантларны юкка чыгары торырга кирәк. Талантлар янәшәсендә а рның талантсызлыклары ачык күренә би

Кара Дус. Йә, ташла әле вак ф сәфәңне. Әнә, Мәскәү газетасында да сине сүгеп язганнар!

Такташ. «Эшче»дәме?

Кара Дус. «Эшче»дә шул. Сине яңа тормышны бозып күрсәтүдә гаеплиләр, әсәреңнең художество ягыннан түбән булуын әйтәләр. Сәхнәдән алуны таләп итәләр! Сине ленинизмга ревизия ясауда гаеплиләр.

Такташ *(сызгырып)*. Менә кая барып җиттеләр! Да, бу инде җитди гаепләү.

Кара Дус. Менә нәрсә, Такташ. Бүген югарыда сүз булды. Сине эшеңнән алырга җыеналар...

Такташ. Нәрсә, журналданмы?

Кара Дус. «Югалган матурлык»тан соң сиңа хатын-кыз журналында эшләү турында уйларга да ярамый. Бу юлы мин сине яклый алмам кебек. «Ялчы» гәзите дә сине судка бирергә йөри икән.

Такташ *(уйланып)*. Мине яклау кирәкми, дустым... Монда яклаудан узып бара инде. Менә эш мәсьәләсе генә... Бала бар бит, кулда бер тиен акча юк... Их, шагыйрь, шагыйрь...

Кара Дус. Алай бик борчылма, Такташ, без исән бит әле. Эшчеләр арасына чыгып китәрсең, яңа тормышны өйрәнерсең. Яңача язарга кирәк сиңа, бөтенләй яңача! Соң, бер ай эчендә миллионерга әйләнәсең бит безнеңчә язсаң! Макта, ура! Кычкыр, ышан, ышандыр. Сип кызыл сүзләрне! Сиңа нәрсә тора ул?! Их, үз кадереңне үзең белмисең! Язып ятасың шунда җыен черек нәрсә!

Такташ. Тукта! Башка илһам килде!

Һәр заманның үзенең чире була,
Һәрбер чирнең була докторы;
Һәр дәвернең була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры!..)
Һәр хәзрәтнең була фидиясе,
Һәрбер җинаятьнең — статьясы,
Һәрбер судның була судьясы.
Һәр бакчаның чүбе булган кебек,
Йолкып ташлый торган кул була;
Килеп кергән ишек күп вакытта
Сөрелеп чыгу өчен юл була...

Кара Дус. Буталчык! Кемне мактыйсың, кемне сүгәсең — һични аңлашылмый. Маташма, тагы контр табарлар.

Такташ. Нәрсә языйм соң, нәрс языйм?!

Кара Дус. Әнә, ташлап киткән хаты ныңа хат яз. Йөрәкне бастыру өчен ярый у

Такташ. Ха-ха-ха! Дөрес әйттең, дус! Баш исән бит әле, жан исән. Йә, хуш, калдыр мине Гөлчәһрәм белән.

Кара Дус. Вот, дивана. Юк, һични алмый сине... Үлем дә алмас сине... *(Читкә.)* Каян көч ала? *(Китә.)*

Такташ *(Гөлчәһрәнең фотосын алып)*. Йә, Гөлчәһрә, тагы ялгыз калдым. Ишеттеңме, мине эштән чыгаралар, судка бирергә йөриләр, әсәрләремне басмыйлар, контр, дип язалар, тагы әллә нәрсәләр! Тик бер нәрсәдән туктата алмаслар, ишетәсеңме, Гөлчәһрә, жен кызы?! Язудан туктата алмаслар. Язуымнан туктата алмаслар! Кулларым исән, баш исән, жан исән, иманым исән! Утыр, Такташ, яз шигырь-поэмаларыңны! Үзеңчә яз! Дөресен яз!..

**Утыра. Яза башлый. Тирә-ягы тагы кәгазь белән тула. Караңгылык.**

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**1929 елның көзе. Бакча. Яланбаш, кулына таяк тоткан Такташ үтеп китә. Ялгызы эскәмиягә барып утыра да нидер укый башлый. Бер төркем егетләр, кызлар керә.**

Бер кыз. Кызлар, үләм, әнә шагыйрь Такташ утыра!

Егет. Такташ шул! Их, егетләр, дөньяда тагы шундый шагыйрь бармы икән?

Уйчан кыз. Урысларда Маяковский бар. Ул да Такташ кебегрәк яза.

Матур кыз. Такташ аның кебек яза диген! Ә дөресен әйткәндә, Такташның язганнары бик томанлы, идеологиясе черек.

Егет. Син, чибәр кыз, әдәби түгәрәкләргә еш йөрисең ахыры. Гел алар сүзен сөйлисең. Такташны дөрес аңлар өчен аның шигырьләрен укырга кирәк, аның турындагы тәнкыйть мәкаләләрен түгел.

Уйчан кыз. Ул тәнкыйтьчеләр бер дә кемнең кем икәнен чамаламыйлар микәнни?

Егет. Чамалыйлар!.. Просто үзләрен акыллырак күрсәтәселәре килә. Янәсе, нинди шагыйрьне тетеп салалар. Бушбугазлар!

Матур кыз. Карагыз әле, кызлар, аны хатыны ташлап киткән ди. Хи-хи-хи! Шундый матур шагыйрьне! Мескен!

Уйчан кыз. Сиңа шул гайбәт кенә булсын! Шагыйрь, артистлар турында бер гайбәтне дә калдырмыйсың инде! Үзе ишегер дип тормый.

Матур кыз. Әйдә исәнләшкән булып, янынннан гына үтеп китик әле?

Егет. Шулай иткән, ди. Болай да Такташның башына житә яздыгыз. Сезнең заттан үзебез саклыйбыз аны хәзер. Марш бу тирәдән!

**Чыгып китәләр. Уйчан кыз гына кала.**

Уйчан кыз. Ә минем, нигәдер, барып аның хәлен беләсем килә! Шул хәтле кызганам мин аны! Аның күзләре бигрәк сагышлы, көлгәндә дә сагышлы. Йә, ходаем, бу якка карый... Йә, тагы әллә ни уйлар. *(Чыга башлый.)* Юк, барыбер исәнләшәм, янынннан узам. *(Такташ янына килә.)* Исәнмесез, Такташ абый!

Такташ *(башын күтәрми генә)*. Исәнме, сеңелем...

Уйчан кыз. Башын да күтәреп карамады! *(Чыгып йөгерә.)*

Такташ *(ялгызы)*. Яшьләр! Кәләләр... Каядыр йөгерәләр. Хыялланалар, нидер көтәләр. Минем хәзер бар көткәнем — Гөлчәһрәдән дөресен язган бер хат. Алты хатыма бер жавап юк. Барысының да бетүеме бу? Хәбәрләр дөрес булып чыктымы? Янына барып кына кайтыр идем — бер тиен акча юк. Менә ярты ел инде эшсез йөрим. Муеннан бурычым... Баганага сәлам биргән чаклар була. Сына башлавың шушымы икәнни, Такташ?!

**Кара Дус керә.**

Кара Дус. Такташ! Сөенче! Эш булды сиңа!

Такташ. Чынлапмы, дустым?! Кайда?

Кара Дус. 15 нче октябрьдән «Чаян»да эшли башлыйсың!

Такташ. Аһ, дустым! *(Кочаклап ала.)* Син мине бик авыр хәлләрдән коткардың! Эш бар — димәк, барысы да булачак! Акчасы да, фатиры да, ризыгы да, утыны да! Менә бит бәхет!

Кара Дус. Тегендә үзем сөйләштем. Булды, житте, шагыйрь акылга утырды, дидем. Аның дальнейший нәрсә язарына үзем жавап бирәм, дидем. Ну син дә мине подводить итмисең!

Такташ. Булды. Бу алты ай эшсез, бер тиен акчасыз йөрү минем соңгы шашкын уйларымны бәреп чыгарды. Язам! Хәзер ни кирәк — шуны язам. Эшчеләр арасына китәм, шахтерлар тормышын өйрәнәм. Только болай йөрергә генә язмасын.

Кара Дус. Шулай, Такташ, шулай. Шул кызудан тагы бер хәл итәсе мәсьәлә бар. Безнең теге футурист шагыйрь белән синең араң ничек?

Такташ. Теге вакытта бераз әләгешеп алган идек. Соңгы вакытта күргән юк. Татуланасы булыр, болай үпкәләшеп йөрү ирләр эше түгел.

Кара Дус. Ашыкма! Ул бит күзәтү астында!

Такташ. Кит аннан?! Газеталарда шаулаганнар иде шул. Мин чираттагы гайбәт, дип кенә карадым.

Кара Дус. Эшләр бик житди, Такташ. Укыгансыңдыр, алты кеше нинди дер яшерен политик оешма төзегәннәр. «Жидегән» дип атала. Безнең футурист та таулар арасында. Башкортстан белән ике арада. Эш Солтангалиевләргә барып тартела. Оешмада жиде кеше булырга тиеш, ди. Жиденчесенә синнән шикләнәләр.

Такташ. Миннән?! Соң миндә политика кайгысы булдымыни соңгы вакытта?! Контр дип печать суктыгыз да, токи контр ясыйсыз бит миннән! Төрмәгә утыртып куясыгыз гына калды инде.

Кара Дус. Син кызма әле. Без сине тиз генә бирмәбез. Ну теге дустан публично халык алдында ваз кичәргә туры килер сиңа.

Такташ. Юк, мине бутама. Мин аның контр икәненә ышанмыйм! Ышанмыйм!

Кара Дус. Ышанырсың! Алар белән

бергә үзеңне дә утыртып куйсалар, ышанырсың! Эш мәсьәләсен дә кире уйларга туры килер. Сине яклыйм дип, үземнең утырыр хәлем юк. *(Китә башлый.)*

Такташ. Тукта... ник гел шушындый хәлгә куясың син мине, дустым? Сез бит миңа икегез дә бик якын. Нигә мин әйтергә тиеш аңа соңгы сүзне?! Нигә?!

Кара Дус. Үзеңне яклар өчен. Гомер буе синең өчен үз күкрәгемне куймам! Бүген монда шигъри митинг була. Үз сүзеңне шунда әйтерсең.

Такташ. Уйларга ирек бир.

Кара Дус. Уйла, Такташ! Алар — ил дошманнары, Илне, халыкны сатарга җыенучылар. Андыйларга карата икеләнеп торырга да кирәкми. Туган атаң булса да төртеп күрсәтә торган вакыт.

Такташ. Син хаклы. Үз борчуларыңа күмелеп, мин тормыштан артта калганмын ахры. Илдәге сыйнфый көрәшне күздән ычкындырганмын. Мин бүген үз сүземне әйтергә тиеш! *(Яза башлый.)*

**Бакчага яшьләр җыела башлый. Уйчан кыз да алар арасында.**

Уйчан кыз. Һаман яза. Иелгән дә, һаман яза. Нәрсәләр яза икән ул? Ничек арымый икән? Сары чәчләреннән бер генә сыйпарга иде шуның...

**Ак Дус керә.**

Ак Дус. Такташ!

**Такташ сискәнеп сикереп тора.**

Мин сине дөнья бетереп эзләп йөрим. Миңа синең ярдәмең бик кирәк, Такташ!

**Бер-берләренә таба килә башлыйлар. Кара Дус ашыгып араларына керә.**

Кара Дус. Такташка кагылма! Сезнең кебекләр бәйләнеп йөреп, Такташ ничә ел кеше арасына керә алмый. Сүгеләә. «Контр» исеме алды. Җитте! Ул синең юлдан бара торган кеше түгел. Кит, комачау итмә!

Ак Дус. Татарга толмач кирәкми. Ну, бутыйсың дөньяны! Йә, бүген мине төрмәгә утыртырсың, иртәгә — аны! Берүзең калырсың әдәбият мәйданында! Шуңа омтыласыңмы?!

Кара Дус. Шантаж! Эш башындагы кешегә яла ягу! Такташ, шаһитым булырсың, ул бу сүзләре өчен дә җавап бирәчәк.

**Такташ башын иеп басып тора.**

Ак Дус. Их, Такташ, кайчаннан бирле үз фикереңне әйтми башладың син?

Такташ. Әйтермен... Барысын да әйтермен... Калдырыгыз мине! *(Читкә китә. Язуын дәвам итә.)*

**Бакча яшьләр белән тула. Алып баручы ачык эстрада сәхнәсенә менә.**

Алып баручы. Иптәшләр! Политик митингыбызны башлыйбыз. Ил кискен көрәш көннәре кичерә. Авылларда кулаклар баш калкытып чыга, шәһәрләрдә төрле яшерен политик оешмалар ачыла. Ул оешмаларның максаты — илебезнең политик нигезен какшату. Без аларга отпор бирергә тиеш! Арабыздан себереп түгәргә!

Кызганычка каршы, илдәге контр политик оешмалар эчендә татар шагыйрьләре барлыгы беленде. Аларга шигъри протест сүзен шагыйрь Һади Такташ әйтсен!

**Кул чабулар.**

**Такташ сәхнәгә менә. Ак Дуска карап, «Син дошманым минем» шигырен укый.**

## Син дошманым минем

Очраганда хәзер синең белән
Исәнләшмәм,—
Үпкәләүдән түгел бу минем,
Һич юк...
Газетада исмең күрдем синең,
Үткән көрәш юлың карадым,
Укып чыктым Үзәк комиссиянең
Синең хакта булган карарын.
Ә беләсең,
Шул ук газетада
Бер хәбәр бар,
Кыска гына итеп язылган:
Бер авылда яшь бер комсомолның
Канлы тәне кырда табылган...
Укыгансыңдыр...
Ул эшне мин синең кулың белән
Эшләнгән эш диеп карадым;
Һәркөн булып торган шундый
корбаннарны
Синең корбаннардан санадым.
Чөнки,
Син, хамелеон, төсең алыштырып,
Безнең арабызда калгансың;
Кулакларны яклап һәр эшеңдә
Җимерү юлын алып баргансың.
Без көрәштә булган һәр уңышны
Йөрәк каны биреп алганда,
Мең авырлык белән, ял итмичә,
Соңгы җиңүләргә барганда,—
Син кулыңны биреп, оялмыйча
Солтангалиевтәй этләргә,
Көрәшкәнсең,
Һәрбер адымыңда
Таяк тыгып безнең эшләргә.
Без бүгеннән дошман!
Дуслыгымны саклар өчен
Йөрәгемдә бер хис тапмадым;
Бел!
Бүгеннән соң
Син һәм синең кебекләргә
Пуля саклап йөри башладым.

**«Җимерү юлын алып баргансың»,— дигәндә, Ак Дус битен каплый. Такташ укып бетерә. Кул чабулар. Сәхнәдән төшә. Кара Дус килеп, кулын кыса, кочаклап ала.**

Кара Дус. Молодец, Такташ! Күрсәттең кем икәнеңне! Шәп әйттең, безнеңчә әйттең.

Ак Дус *(Такташ янына килеп)*. Их, Такташ! Мин сине акыллырак дип уйлаган идем. Менә болар уйлап чыгарган уйдырма бит ул оешма дигәннәре! Шуны аңларга башың җитмәде. Хуш, Такташ! Менә хәзер син минем өчен чынлап та юк инде. Үлдең. *(Китә.)*

Кара Дус. Тараллык, жегетләр! Булдырдыгыз, молодцы! Без киттек, Такташ! Иртәгә бер әйләнерсең әле. Сиңа яңа заказ булыр. *(Китәләр. Бер читтә уйчан кыз гына кала).*

Такташ *(башын тотып, эскәмиягә барып утыра).* Иртәгә яңа заказ булыр... Яңа заказ... Ә миңа инде барыбер. Кая, бирегез заказларны, тагы кемне суярга, юк итәргә?! Сатарга! Ха-ха-ха! *(Утыргыч култыксасына таянып, әллә елый, әллә көлә.)* Такташ заказ белән шигырь яза! Такташ заказ белән дусларын юк итә...

Уйчан кыз *(йөгереп килеп).* Такташ абый, сезнең хәлегез начармы әллә? Бөтенләй агаргансыз, калтырыйсыз? *(Читкә.)* Әллә елый да инде?..

Такташ *(бераз утыргач).* Син кем, сеңелем?

Уйчан кыз. Гөлчәһрә.

Такташ *(сикереп торып).* Гөлчәһрә?! Син — Гөлчәһрә?! Дөньяда башка исем юкмы соң әллә, сеңелем?!

Икенче Гөчәһрә. Белмим, Такташ абый.

Такташ. Ә син мине кайдан беләсең?

Икенче Гөчәһрә. Сезне бөтен кеше белә бит. Мин Сезнең һәр шигырегезне, һәр мәкаләгезне укып барам.

Такташ. Ошыймы соң?

Икенче Гөчәһрә. Ошый. Тик...

Такташ. Нәрсә, сеңелем, әйтеп бетер.

Икенче Гөчәһрә. Тик... Өзгәләнү күп сезнең шигырьләрдә. Нигәдер, кызганам мин сезне... Юатасым, яклыйсым килә.

Такташ. Рәхмәт, сеңелем. Үзеңчә дөрес аңлагансың.

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый! Сезне хатыныгыз ташлап киткән, диләр. Шагыйрь кешене шулай ташлап китеп буламыни?

Такташ. Юк сүз ул, сеңелем, Мәскәүдә укый ул. Ә впрочем, белмим. Үзем дә берни белмим. Адаштым мин соңгы вакытларда...

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый, мин сезгә берәр ничек ярдәм итә алмыйммы соң?

Такташ. Син? Рәхмәт, сеңелем! Мин үзем дә белмим әле миңа нинди ярдәм кирәген. Рәхмәт. *(Китә.)*

Икенче Гөлчәһрә. Нинди кеше! Ә шуның башы иелгән! Күзләре гел моң гына. Ничекләр ярдәм итәргә сиңа, шагыйрь абыем? Бер генә бәхетле көнең өчен гомеремне дә жәлләмәс идем. Син генә бәхетле бул идең...

**Караңгылык.**

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

**1930 елның язы. Такташ бүлмәсе. Такташ ялгыз.**

Такташ. Менә бу — минем тема булырга тиеш. Җитте, Такташ! Ничә еллар адашып йөрдең, ничә еллар бәргәләндең. Әйтер сүзең һаман әйтелмәде. Син соңгы вакытта кемнәрдер кушканга гына яза башладың. Ә менә монысы — үз сүзең. Бу шигырең үлемсез булачак, Такташ! *(Укый.)*

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын...
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исемем сезгә җитмәс — онытылыр...
Теләкләрем минем сезнең чорда,
Сезнең кырда чәчәк атачак.
Җансыз гәүдәм шушы теләкләргә
Азык булып җирдә ятачак...

Их, менә бу шигырь ичмасам! Шушы рухта дәвам итәчәкмен. Бу минем киләчәккә атап язылган хатларым булыр. Аһ, шигырьләр белән генә яшәсәң иде! Менә бу тормыш ваклыклары, аллау, хыянәтләр булмаса иде... *(Өстәлдәге хатларын ала.)* Менә болар барысы да синең турыда, Гөлчәһрә... Кемнәр генә, нәрсә генә язып җибәрмиләр! Ир кешегә ничек авыр икәнен белсәң иде боларны ишетүе! Аңласаң иде... *(Хат язарга утыра. Эфирда хат тексты).*

«Гөлчәһрә!

Мин сиңа ике озын хат җибәрдем. бәлки синең рухыңның төшкән вакытында ул хатларны җибәрмәү яхшырак булган булыр иде... Ләкин һәр очраган кеше синең хакта кабахәт нәрсәләр сөйли һәм бөтен уйларымны чуалтып, синең алар теленә яңадан-яңа хәбәрләр бирүең мине ул хатны язарга мәҗбүр итте.

Мин бу соңгы хатым белән сине ачыктан-ачык сөйләшергә чакырырга телим.

Мин синең ирең булып саналып килдем. Бит, бер нәрсәнең дөрес булуына ышанган вакытта гына гакыллы бер карарга килергә мөмкин. Шөбһә-шик дәрәҗәсе кешеләрнең дә аякларын бәйли. Бер төрле адым атларга комачаулый. Мин сине биш ел яраттым. Биш ел иң якын иптәшең булуым исеменә, синнән ачык булуыңны, мине томанлы, газаплы шөбһәләрдән коткаруыңны сорыйм... Ачык сөйләүнең беренче минуты гына авыр булыр. Ә соңыннан мин бер төрле карарга килә алырмын. Бәлки безнең гаиләнең корылышын, аерылып торуларны күзгә алып, сине гафу итәрмен. Синең белән тормышны дәвам иттерергә көчем җитәр. Бит мин консерватор түгел. Инде аерылырга дип карар итсәм дә, син ирегеңне чикләүче иреңнән генә котылырсың. Ант итәм, сиңа авыр булырлык бер генә эш тә, бер генә хәрәкәт тә ясамам.

Тормышыбызның шулай булуы синең өчен дә матурлык хәзерләми. Син университетны бетергәндә бу мәгънәдә тагын да ачыграк була аласың. Син әле икенче гаилә корып та бәхетле була алырсың. Ә минем турыда уйлама. Минем бу мәсьәләне хәл итәргә салкын канлылык җитә...» *(Озак кына битен каплап утыра.)* Нәрсә язам мин? Бу бит инде барысы да бетте, дигән сүз... Барысы да бетте... Киләчәккә беренче хатны язган көнне үткәннәргә соңгы хатымны язам... Дөрес язаммы? белмим... Белмим...

**Ишек шакыйлар.**

Керегез, ишек бикле түгел.

**Икенче Гөлчәһрә керә.**

Ә, сеңелем! Уз әйдә, утыр. Нинди җилләр ташлады үзеңне ялгыз шагыйрь йортына?

Икенче Гөлчәһрә. Бүген иптәшләрегезне очраткан идем. Авырып тора, диделәр. Үзегез дә күренмәдегез.

Такташ. Да, авырулар ешаеп китте шул соңгы вакытта. Узган ел да шушы вакытта баш белән клиникада яткан идем, быел да туры килер ахыры. Баш сызлый, чыдарлык түгел...

Икенче Гөлчәһрә. Күп эшлисез, Такташ абый. «Чаян»да гел сезнең язмалар, журналда романыгыз басылып ята...

Такташ. Шигырьләр генә юк. Сизәсеңме, Гөлчәһрә, шигырьләр юк. Шагыйрьлек бетте.

Икенче Гөлчәһрә. Алай димәгез, Такташ абый. Сез әле әллә нәрсәләр язачаксыз! Әлегә сез арыган...

Такташ. Анысы да бар инде. Их, сеңелем, бер кара-каршы утырып чәй эчәр идек,— өстәлдә берни юк...

Икенче Гөлчәһрә. Борчылмагыз, Такташ абый! Мин барысын да алып килдем. Авылдан әни килгән иде — нәрсә генә юк монда *(өстәлгә бушата)*.

Такташ. Ай-яй-яй! Көн саен килсен иде ул әни, әйеме, Гөлчәһрә?

**Көлешәләр. Гөлчәһрә чәй әзерли. Такташ сокланып карап тора.**

Икенче Гөлчәһрә. Утырыгыз, Такташ абый.

Такташ. А, юк, сеңелем! Син минем кунагым — түремдә бул.

**Кара-каршы утырып, чәй эчәләр.**

Такташ. Нинди хозурлык! Нинди саф тынычлык! Йә, хода! Гомер буе шулай гына яшә идең...

Икенче Гөлчәһрә. Такташ абый, хатыныгыз кайтмыймы соң әле?

Такташ. Ул... кайтмас инде, сеңелем. Шулай тоела. Ә алай да, белмим әле... Берни белмим.

**Кара Дус килеп керә.**

Кара Дус. Әһә! Менә Такташ! Менә мулла песие! Ай, Такташ! Кара син аны, хатыны югында Казанның икенче бер гүзәле белән кара-каршы чәй эчеп утыра бит! Ха-ха-ха!

**Гөлчәһрә, уңайсызланып, чыгарга бара.**

Такташ. Тукта, сеңелем. Табынны алай ташлап китмиләр. Шагыйрь абыең шаярта гына ул.

Кара Дус. Әлбәттә, шаярттым гына. Такташка да бер бәйрәм кирәк бит инде... Такташ! Эш белән килгәнием. Сине киләсе җәйгә Донбасс якларына җибәрәбез. Шахтерлар тормышыннан яңа әсәрләр алып кайтырга! Күрсәт әле үзеңнең кемлегеңне, кайсы якта икәнеңне.

Такташ. Сез һаман шикләнәсезмени әле? Инде сезнең заказ буенча гына язам бит! Ура! Кычкырып язам.

Күп заводлар безнең күптән инде
Планнарны тутырып ташлады,
Алгы өчен эшли башлады!
Кызыл байрак алып җиңеп чыккан
Эшче полклар һаман арталар,
Артып тора кызыл такталар.

Йә, шигырьме бу? Мин — Такташ — шуны язам! Син мактый-мактый бастың. Йә, сеңелем, әйбәт шигырьме бу?

Икенче Гөлчәһрә. Мин шигырьне бик үк аңлап бетермим...

Такташ. Аңлыйсың... Яхшысын тиз аңлыйсың. Ә монысын мине кызганганга гына әйтмисең.

Кара Дус. Йә, беттеме? Кызып алмасаң, Такташ булмый калырсың. Соң, башкача яза алмагач, шунысына риза буласың инде.

Такташ. А, юк... Күмеп куярга ашыкмагыз әле! Язам! Яздым! Менә тыңла:

Сез бу хатны минем укыганда,
Авыр еллар үткән булырлар;
Җирдә коммунизм булган булыр,
Безнең дәвер халкы онытылыр...
Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз,—
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз.
Без — үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Көрәшендә
Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз;
Без яңа җир,
Яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз...

Кара Дус *(бүлдереп)*. Юк! Юк!! Юк!!! Мондый шигырь булмый. Болай дәвам итсәң, тагы провалга очраячаксың... Юк, юк, мондый шигырь булмый.

Такташ. Нинди була соң? Мин сине аңламый башладым, дус. Кешеләр өчен сөенә белмисең син. Их, Ак Дус булса! Аңлар иде ул минем бу шигырьне...

Кара Дус. Юк ул салам сыйрак! Бетте. Төрмәдә утыра. Син неужели үзеңне кемнәр алып калганын хәтерләмисең?

Такташ. Хәтерлим... Син аны онытырга ирек бирәсеңме соң?..

Кара Дус. Менә, ит яхшылык, көт явызлык шушы була инде ул. Мин тагы сине сөендерергә дип килдем...

Такташ. Йә, дус, үпкәләмә. Соңгы вакытта кәеф китеп тора, шуңа гына ул...

Кара Дус. Хәзер кәефеңне күтәрәм, алайса. Киләсе елга синең әсәрләреңнең тулы җыентыгын чыгара башлыйбыз. Беренче томга әйберләреңне әзерлә.

Такташ. Дустым! *(Кочаклап ала.)* Син бит мине коткарасың! Бурычларымнан да, ачлы-туклы яшәүдән дә... барысын да әзерлим, барысын да...

Кара Дус. Барысын да әзерлә. Тик кечкенә генә бер кереш сүзең кирәк булачак.

Такташ. Язабыз! Зурысын да, кечкенәсен дә язабыз, дус! Их, син булмасаң, нишләр идем мин?!

Кара Дус. Үзең беләсең, соңгы вакытта сиңа теш кайраучылар күп. Шуңа күрә кереш сүзне бик чамалап язарга кирәк. Без анда уйлаштык — син беренче чор шигырьләреңнән публично ваз кичәргә тиеш.

Такташ. Тукта, ничек була соң әле ул? Үзең чыгарырга, дисең, үзең — ваз кичәргә?.. Ваз кичәрлек булгач, чыгармаска гына кирәк аларны.

Кара Дус. Чыгарырга кирәк. Гыйбрәт өчен. Сабак өчен.

Такташ. Әһә, шагыйрь Такташ кем иде — кем булды? Аңлашыла башлады...

Кара Дус. Аңлашылса, шул. Башта үзеннең вак буржуа шагыйре икәнеңне әйтәсең, ничә еллар черек идеология белән ижат иткәнеңне әйтәсең. Аннан ничек итеп безнең сине тәрбияләвебезне әйтәсең. Әйе, гажәпләнмә, без, тәрбияләп, сине шагыйрь иттек. Һәм син шуны халыкка әйтергә тиеш.

Такташ. Юк, мин риза түгел! Мин беркайчан да вак буржуа булмадым! Минем идеологиям, иманым дөрес иде. Минем беренче чор шигырьләрем — иң яхшы шигырьләрем! Аларда мин — Шагыйрь, ә болар-да...

Кара Дус. Мин сиңа файда булсын өчен әйткән идем. Үзенә мөнәсәбәтне беләсең. Заманның нинди икәнен дә беләсең. Үзең чамаларга тиеш идең. Анда синең исемне иштергә дә теләмиләр. Кермәгән ишегем калмады. Сиңа ышаныч юк, Такташ.

Такташ. Ә нигә юк? Уйлый белгән өченме? Ә нигә миңа гына шундый шартлар? Берегезне дә болай газапламыйлар бит! Нигә миндә генә шушындый кыенлыклар, каршылыклар?! Нигә, сеңелем?!

Икенче Гөлчәһрә. Чөнки сез талантлы, Такташ абый. Сезне талантыгыз өчен яратмыйлар.

Такташ. Сеңелем... Күзләрең акыллы синең. Сакларга иде сине... *(Кара Дуска.)* Мин уйлармын, дус, уйлармын...

**Ишектә Беренче Гөлчәһрә күренә.**

Беренче Гөлчәһрә. Каршы алучы да юк! Астан күпме кычкырдым, тәрәзәгә таш аттым! Ну, Такташ! Син хатларың белән бирәсең минем кирәкне! Җавабын бирергә үзем кайттым! *(Кочагына ташлана.)*

Такташ *(читкә этәреп)*. Ашыкма, Гөлчәһрә, кешеләр бар.

Беренче Гөлчәһрә. Шулаймыни?! Исәнмесез һәм сау булыгыз! Мине чабаталы даһием белән калдырыгыз.

Такташ. Гөлчәһрә, әдәпсезләнмә. Болар минем иң якын дусларым.

Беренче Гөлчәһрә. Аһ, шулаймени?! *(Кара Дуска.)* Монысын күптән беләм. Курыкма, курыкма, бу юлы пистолетым юк. Алай да, Такташ аңламаган икән әле сине... *(Икенче Гөлчәһрәгә.)* Ә син кем буласың, чибәр кыз?

Икенче Гөлчәһрә. Гөлчәһрә.

Беренче Гөлчәһрә. Гөлчәһрә?! Мин дә Гөлчәһрә бит! Аһ бу Такташның зәвыгы! Хатлар аша мине тиргәп яткан була тагы.

Такташ. Гөлчәһрә, ул турыда сөйләшмибез.

Беренче Гөлчәһрә. Ә нигә сөйләшмәскә? Безнең турыда инде бөтен дөнья әллә ниләр сөйли... Мин сине алырга кайттым, Такташ.

Такташ. Алырга?! Кайда?!

Беренче Гөлчәһрә. Мин университетны тәмамладым бит, Такташ жаным! Бүгенге көннән мин — югары белемле юрист! Менә диплом! Кайсы якка китсәк тә — дөнья безнеке! Бергә китәбез! Телисеңме, Кырымга, Кавказга, Урта Азиягә?! Тик Казан гына түгел!

Кара Дус *(мыскыллап)*. Бар, бар, Такташ, прокурор хатыны булып яшәрсең. Шигырь язып тамак туйдырмассың.

Икенче Гөлчәһрә. Китмәгез, Такташ абый!

Такташ. Җитте. Юк сүз сөйләмә, Гөлчәһрә. Мин — татар шагыйре, ир кеше. Синең арттан китә алмыйм. Тем более, Казаннан. Син моны яхшы аңларга тиеш идең.

Беренче Гөлчәһрә. Нишлик соң?! Тагы шушылар янында яши башлыйкмы? Бөтен тормышыбызны агулаячак бит алар! Күрәлмыйм мин аларны.

Кара Дус. Намусың чиста булса, иштмәс идең!

Беренче Гөлчәһрә. Син! Кара жан! Кызганыч, пистолет юк. Ике дә уйламый, маңгаена пуля утыртыр идем. Һади! Син миңа шушы бәндәдән шундый сүзләр әйттереп торасыңмы?

**Такташ дәшми.**

Ник эндәшмисең?!

**Такташ дәшми.**

Син дә миңа ышанмыйсыңмы? Ник эндәшмисең, Һади?! Ярар, син килмәсәң, мин китәм. Мин синең бу ачулы дөньяңда кала алмыйм. *(Әйберләрен җыя башлый. Икенче Гөлчәһрәгә.)* Чибәр кыз! Кил әле бире! *(Гөлчәһрә килә.)* Син Такташны яратасыңмы? *(Гөлчәһрә дәшми.)* Уңайсызланма, әйт. Миңа бу мөһим.

Икенче Гөлчәһрә *(пышылдап)*. Яратам...

Беренче Гөлчәһрә. Бик яратасыңмы?

Икенче Гөлчәһрә. Бик...

Беренче Гөлчәһрә. Ләкин барыбер минем кебек яратмыйсың!!! Ләкин минем аның каршында ышанычым югалды! Мин горур, Такташ! Мин синең шикләнүләреңне күтәрә алмыйм. Аягыма егылганда гына кичерермен мин сине.

Икенче Гөлчәһрә. Такташ аякка егыла торган кеше түгел.

Беренче Гөлчәһрә. Нәрсә дидең?! Син... син шактый дөрес аңлагансың аны. Бәхетле ит үзен! Хуш, Такташ!

Икенче Гөлчәһрә. Китмәгез! Мин китәм, сез калыгыз.

Беренче Гөлчәһрә. Бәхетенә аркылы төшмә, сеңелем! Такташны сакла! *(Чыгарга бара.)*

Такташ. Гөлчәһрә, тукта әле! Ашыкма! (Омтыла.)

Кара Дус *(Такташның кулыннан тота)*. Ир бул! Җебемә! Киткән хатын артыннан чапмыйлар.

Беренче Гөлчәһрә. Дөрес, Кара шагыйрь! Тот Такташны! Тотынырга янында башка кешесе калмады аның. *(Китә.)*

Кара Дус. Менә шәп булды! Котылдың Борчылма, Такташ. Донбасска жибәрәбез үзеңне! Пролетариат турында язарсың! Төкер бу мещан хатынына.

Такташ. Кирәкми, дус... Берни әйтмә... Әллә нәрсә сынды... Җимерелде...

Кара Дус. Ярый, ярый, мин киттем. Әйтәсен әйттем. *(Китә.)*

Икенче Гөлчәһрә. Әллә ничек килеп чыкты... Без монда булмасак, бәлки хатыныгыз китмәс тә иде... Аңлашып идегез...

Такташ. Китәр иде, сеңелем... Син аны белмисең... бәлки ул инде миннән күптән киткән булгандыр...

Икенче Гөлчәһрә. Мин дә китим инде, Такташ абый...

Такташ. Бераз гына утыр әле, сеңелем... Син дә китсәң, бу дөньяда бөтенләй ялгыз калам бит мин. Бераз гына утыр әле.

**Янәшә утырып калалар.**
**Караңгылык.**

## СОҢГЫ КҮРЕНЕШ

**Бүлмә бераз яктыра. 1931 ел. Декабрь. Такташ баш күтәрми язып утыра. Икенче Гөлчәһрә әкрен генә керен-чыгып йөри. Менә ул теге яктан яшь бала күтәреп чыга, аны кроватька сала. Кинәт тәрәзәдән җил-давыл бәреп керә дә, Такташның бөтен язганнарын туздырып ташлый. Яшь бала елап җибәрә. Такташ бар көченә гаилә-кроватын югарыга этеп алып менә башлый. Туктап, сулыш алган вакытларда, тезенә кәгазен куеп, яза. Язган берен давыл очыра бара. Инде Такташ тормышының түбәсенә менеп җиттем, дигәндә генә, кинәт башын тотып егыла. Моңарчы куркып бер читтә торган Икенче Гөлчәһрә йөгереп янына бара.**

Икенче Гөлчәһрә. Һади, бәгърем, нишләдең?!

Такташ *(торырга итеп)*. Менеп җитеп булмады, канатым... Менеп җитеп булмады... *(Егыла.)*

Икенче Гөлчәһрә. Һади!!! Ярдәм итегез, Һади үлә! Ярдәм итегез!

**Ишектә Кара Дус күренә.**

Кара Дус. Нәрсә булды?

Икенче Гөлчәһрә. Һади үлә... Башын тотып егылды.

Кара Дус. Үлә?! *(Такташ янына килә башлый.)*

Икенче Гөлчәһрә. Тик, зинһар, борчый күрмәгез. Бәхәсләшә күрмәгез. Башы бит... Мин врачка барып киләм. *(Китә.)*

Кара Дус. Ниһаять. Сынды. Такташ үлә... Ничә еллар минем даныма, талантыма аркылы ятты ул! Халыкның күзен томалады. Менә хәзер карарбыз, халык кемне укыр?! *(Такташ янына килә.)* Нихәл, Такташ? Нигә болай ятасың әле? Килешми сиңа, килешми...

Такташ. Киләчәккә... хатларым язылып бетмәде. Чакыр Ак Дусны, алсын язылып беткәнен...

Кара Дус *(читкә)*. Һаман Ак Дус?! Үлгәндә дә миңа түгел, аңа тапшыра!!! *(Такташка.)* Ак Дустың бөтен Казан буенча синең китапны мыскыллап йөри. «Такташ социализм койрыгына ябышып шагыйрь булмакчы!»,— дип сөйләп йөри.

Такташ. Дөрес мыскыллый. Ул кереш сүз белән мин үз-үземә... соңгы хөкем чыгардым...

Кара Дус. Ну үзең дә арттырып җибәргәнсең инде. Вак буржуа икәнеңне дә әйткәнсең. Черек икәнеңне дә! *(Китапны ала. Укый.)* «Шулай итеп, бу том белән үткәннәргә ишекләрне ябып, социализм экономикасы ачып килгән яңа ишекләр алдына миллионнар белән бергә яна, бөек теләкләр белән килеп басам». Ха-ха-ха! Ятам диген. *(Иелеп.)* Ишек төбендә сузылып ятам, кертмиләр, диген.

Такташ *(аягүрә торып баса)*. Басып торам!!! Киләчәк каршында аягүрә басып торам! *(Чайкалып, өстенә кия башлый.)* Ә син... мине үтердем дип сөенмә... үтерә алмыйсың... Шигырьләрем кала... Такташ дигән исемем кала... Синнән ни кала?! *(Өстенә килә. Кара Дус ишекнең теге ягына чыгып кача да ишекне арты белән тери.)* Үз-үземнән ваз кичтем... Шигырьләремнән ваз кичәргә мәҗбүр булдым... Киләчәктә дөрес аңларлармы? Иң кадерле кешеләремне... саттым... Гөлчәһрә... Гадел дустым... Кайда сез?.. Ачыгыз бу тимер ишекләрне! Ачыгыз...

**Такташ тимер ишеккә барып каплана. Югарыда, ак каеннар арасында, бер ир баланың йөгереп килгәне күренә. Ул — Такташның бала чагы. Менә ул йөгереп килә дә, күкрәге белән зур тимер ишеккә барып бәрелә. Әкрен генә җиргә чүгә башлый. Бу вакытта Такташ та тимер ишек буенча әкрен генә аска шуып төшә. Еракта сабый бала елап җибәрә. Бу — Такташның үлеме...**

**Ишекнең бу ягы.**

**Ашыгып, Ак Дусның килгәне күренә. Ул ишеккә арты белән сөялгән Кара Дус янына килеп җитә. Аны күргәч, Кара Дус ишеккә аркылы баса.**

Ак Дус. Кит юлдан! Такташның хәле авыр дип ишеттем. Мин аны күрергә тиеш.

Кара Дус. Сиңа анда керергә ярамый! Сиңа аның янына юл юк! Син аның дошманы!

Ак Дус. Кем аркасында?! Кит юлдан, кара җан!!! *(Бугазыннан алып, ишектән читкә алып китә.)*

**Ул арада Икенче Гөлчәһрә йөгереп кайта. Ишекнең теге ягына кереп китә. Аның ачыргаланып кычкырып җибәргәне ишетелә. Икенче Гөлчәһрә атылып бу якка чыга. Ике дус та, ашыгып, ишек янына киләләр.**

Икенче Гөлчәһрә. Такташ үлгән... Такташ үлгән... Ишекләрен япкан... Мәңгегә... Барыгызга да... Китегез... Сез генә үтердегез аны... Йөрәгенә басып җырлаттыгыз... Сез генә үтердегез. Саклый алмадым каралыктан... Өлгермәдем...

**Елап, ишек төбенә сыгылып төшә. Ике дус, башларын иеп, икесе ике якка чыгып китәләр.**

*Пәрдә төшә.*

*1985*

# БОЛАЙ ГЫНА ГАДИ КҮРЕНӘ УЛ...

Илдус Гыйләҗевнең шигъри дөньябызда үзен ныклап раслый башлавына да ун еллап вакыт узды инде. Кайчан яза башлавын үзе генә беләдер. Ул хәзер берничә китап авторы: «Җир китабы», «Җилкенү», «Өмет ае», «Серле мәгарә».

Бу кереш сүзне язганда моннан җиде ел элек И. Гыйләҗевкә Язучылар берлеге әгъзалыгына керергә биргән рекомендация-тәкъдим язуыма карап алдым. Анда болай язылган булып чыкты:

«Бездә хәзер шигырь язучылар, дәрәҗәге, техник яктан яңгырашлы, килешле, грамоталы итеп язарга сәләтлеләр байтак. Ләкин алар күп вакыт шигырьне ясый, ә тудырмый. Ә шигырь туарга тиеш! Шигырьне шигырь иткән төп хасиятләрнең берсе — аның табигыйлеге, самимилеге. Илдусның шигырьләре бу яктан әлеге таләпкә бик тә җавап бирә: алар табигый да, самими дә.

...Шушы матур,
мәрхәмәтле җирдә үсеп,
тугайларда, урманнарда
печән чабып, агач кисеп,
терекөмеш төсле якты
чишмәләрдә сулар эчеп,
чуклы чыбыркы шикелле
елгаларны йөзеп кичеп..

язылган шигырьләр алар.

Шагыйрьнең дөньясы, тематик диапазоны турында китаптагы шигырьләрнең исемнәре үк кычкырып әйтеп тора. «Басуларым төсе», «Кара туфрак», «Кеше көчле дә бит...», «Шигырьләрне җиргә язам», «Аермагыз җирдән», «Кадерсезләмәгез икмәкне», «Өмет кирәк авылларга», «Җир китабы», «Язгы басу», «Кош күңеле — туган җирләрдә» һ. б. һәрберебезгә аңлаешлы, күңелгә якын исемнәр. Мондый исемле шигырьләр язу хокукын бераү дә бездән тартып алмаган. Әмма яшәү рәвешебездән чыгып караганда, күбебез өчен мондый исемле шигырьләр язып чыгару бик үк табигый булмас иде. Ә Илдус Гыйләҗевнең исә җир кешесе буларак та, шагыйрь буларак та чын хакы, үз хакы бар. Шагыйрьнең, публицистик рухтагы шигырьләреннән тыш, лирик, интим мәхәббәт шигырьләре дә юк түгел. Әмма алар да барыбер теге яки бу ягы белән шул ук дөньяга — Игенчеләр Иле дөньясына бәйләнгән.»

Әйе, И. Гыйләҗевнең үз темасы, үз стиле, үз укучысы бар, димәк — үз дөньясы бар. Аның шигырьләрен мөкиббән китеп яраткан укучыларны беләм. Алар, нигездә, авыл кешеләре, табигать, җир-су кешеләре. Асылда, без — татар теленд& иҗат итүче каләм ияләре нәкъ шулар өчен язабыз да бит. Чөнки, чыгышыбыз Җирдән, бүгенге хәятебез, яшәү-сулышыбыз Җирдә, киләчәгебез — Җирдә.

Илдус Гыйләҗев — интеллигент кеше. Затлылыгы байтакларга бүлеп бирерлек. 70 елларда университетның татар филологиясен тәмамлаган. Туган ягы — Азнакайга кайтып, төрле җаваплы урыннарда эшләгән. Үз вакытында солдат хезмәтен үтеп офицер булган. Татарстанның халык депутаты итеп сайланган. Әмма без Илдус Гыйләҗевне шагыйрь буларак белгән чор — аның авыл хуҗалыгы рәисе булып эшләгән вакытларга туры килде. Председатель-рәис һәм шагыйрь. Сирәк кулланыла торган сүзтезмә (дөрес, заманында кайберәүләр булды: шагыйрь Ринат Рәхимов, җыр текстлары язучы Марсель Гыймазетдинов...). Фәкать язу эше белән генә шөгыльләнгән кешегә дә әле Шигърият галиҗәнабләре хакына, күп генә житмичә, байтак төн йокыларын да сарыф итәргә туры килә. Ә рәис-шагыйрь кешегә? Иртә таңнан торып нәрәт бир, иртә-кичен җир-басу сулышын тыңлап йөр, яуган яки яумаган янгыр-коры өчен борчыл-көек, гади игенче халыкның йөз төрле гозерен аяк астына салмаска тырыш, өстәгеләргә яки янәшәндәгеләргә, горурлыгыңны саклаган хәлдә, ярап кара... Өстәвенә, «заман кемнең заманы?» дигәндәй, бу заман бит — «кыргый базар» заманы, ярминкәләр заманы, үзгәртеп кору-кормауның шомбай-төрәләре заманы! Әле шәхси тормыш та бар бит: гаилә хәлләре, балалар, ошыклар китергән шатлыклар, борчулар... Мал-туар, бакча-түтәл...

Гомумән, авыл җирендә эш-мәшәкать чиктән ашкан. Шагыйрь беренче китабын тикмәгә генә «Җир китабы» дип атамаган иде шул.

Ни чәчсәң, шуны урырсың, ди халык. Тормышның үзәгенә, гади халык күңеленә никадәр якын булсаң,— язган сүзең дә, көйләгән җырың да шулкадәр тормышчан, халыкчан, яшәүчән буладыр. И. Гыйләҗев шигырьләре — гади, хикмәтле, табигый яңгырашлы. Миңа калса, шагыйрь үзенең күпме һәм нәрсә күтәрә алганын, ягъни — нәрсә турында, ни өчен, кем өчен язганын яхшы белә. Ә инде күтәргәнен, көчле кулы белән тимер чөюче атлет кебек, ул егетләрчә күрсәтә, демонстрацияли дә белә.

Кемдер әйтер: илаһ Шигърият ул, тәрәзәдән сызгырып кына катыңа менә торган кәнизәк түгел, аңа бөтен күңел җылыңны, гомер-вакытыңны багышларга кирәк — шул чак кына, бәлки, үзеңне юлдашы итәр; ә болай, иген-чәч, малтуардан арткан вакыт илһамы — дилетантлык, үзешчәнлек, дияр. Моның белән дә килешмичә булмый. Әмма, табигатьтән шагыйрь булып туып та, шуңа бөтен гомерен багышлый алмаган, дөресрәге язмыш мөмкинлек бирмәгән талант иялəре була. Андыйлар, турыдантуры «старттан-финишка» барганнарга караганда күбрәктер дә әле...

Илдус Гыйләҗев — гомеренең төшлегендә җирдә нык басып торучы ир-ат. Фани дөньялыкта кирәк саналган байтак игелекле гамәлләр кылынган. Аның хәзер тормыш куу хәлләрен — дилетантлыкка калдырып, төп эш итеп иҗатны сайларга да хакы бар.

## Халәт

*Илдус Гыйләҗевкә*

Син миңа, аргансың, диден.
Әйе, мин арган идем.
Дөньяның күзенә карап
бер тынып калган идем.

Үткән еллар баскычына
гүя менеп утырып,
Үткән белән Киләчәкне
тоташтырмакчы булып
уйга тардым.

Кемнәрдер хәтерлиләрдер:
без дә бит янган идек!
Очкынын балачактагы
хыялдан алган идек.

Яшьлек чаклары ялкыны
хәйран күренә иде.
Хаклык белән халык хакы
Йөрәк түрендә иде.

Иман күбрәк булган, ахры,
ачлы-туклы буында.
Девиз иде: сынатмаска
Дөнья сабантуенда!

Безгә ул чак егерме иде...
Хәзер чагыштырам да,
бүгенге яшьләрне күреп
әрнүләр туа җанда.
Бихисап сораулар тулы
билгесезлек тора алда...

Безнең дә өлеш үткәндә —
җиңү-җиңелүләрдә...
Күпме патшалар мәтәлде
безнең гомерләрдә дә!
Сәбәпсезмени чатнаулар
буыннар чылбырында?
Горур тора алдыкмы гел
елларның торгынында?

Көн итү җиңеләйсә дә,
уй-гамьнәр авырайды!
Безнең кулдан исән үткән
факел кемнәрдә калды?
Факелмы ул? Тычкан утын
Балкыш дип йөрмибезме?
Юлдан яздыручыларны
алкышлап йөрмибезме?

Син миңа, аргансың, диден...
Әйе, мин арган идем.
Дөньяның күзенә карап
бер тынып калган идем.
Шактые үткән гомерне
бер барлап алган идем.

Кешенең шундый халәте
табигыйдер дөньяда.
Җиңгән гладиаторлар да
хәлсез бер тынып кала.
Яздым да уйлыйм: синә да
минем хәл таныштыр, дип.
Булмый һәм кирәкми, туган,
язмышны алыштырып!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**



# Илдус Гыйләҗев

## Кемдә гаеп?

Мин бит мондый түгел идем —
Усалландым...
Тешлә дисәм, өзеп алам.
Куяннан да куркак малай
Бүре булып җитте тәмам.

Мин бит мондый түгел идем —
Ялганлашам...
Шома булгач, шуа үтә.
(Остарганнар өскә үрли,
Тәҗрибәсез — Себер китә...)

Мин бит мондый түгел идем —
Борсаланмыйм...
Нигә өсте килми түбән.
Бәхет өчен җитмимени
Бөтен булса шәхси түбәң?

Мин бит мондый түгел идем —
Куркынычтыр...
Усал сорау булгач телдә.
Кеше булу иде теләк,
Ник үзгәрдем, гаеп кемдә?

## Болакта

Асфальт ватып җирне бораулыйлар —
Ни бар анда? Нинди катламнар?
Аска төшеп юллар төзү өчен,
Барсын белү кирәк атламлап.

Чама белән әйтеп биреп була
Бу тирәдә ниләр ятканын —
Татар сөягедер катлы-катлы,
Бөтеннәре, турап атканы.

Балчыгы да кызыл төстәрәктер,
Ул кадәр кан агып бетәрме?
Бу турлардан, метро залларыннан,
Тыныч кына ничек үтәрмен?!

Асфальт ватып, җирне тикшерәләр,
Казан уртасында, Болакта.
Ташка тигән борау тавышыдай,
Тарих ыңгыраша колакта...

## Рәхмәт, халкым!

Горурлыгым шактый арта төште,
Баргач быел Болгар иленә.
Рәхмәт, халкым! Яуда кулга төшсә,
Тимәгәнсең колның диненә.

Чиркәү сүтеп мәчет кормагансың,
Көлмәгәнсең айны үптереп.
Аңлагансың — күңел кол булалмый!
Үзгәралмый тәүбә китереп.

Богауларны өзеп чәлпәрәмә,
Очып китәргә ул сәләтле.
Буйсынуны белмәс халык рухы
Мәңгелектер шушы сәбәпле.

Кире кайтып яңа буыннарга,
Ул ирекә әйдәп торачак.
Гасырларны үтеп, киләчәктә
Үз дәвамын эзләп табачак!

Шушы хакыйкатьне аңлагансың,
Киресенчә булса... каргарлар.
Булдыралмас идем мин дә бүген
Кешеләргә туры карарга...

## Күрешәм ике куллап

Кинә саклый торган халыклар бар,
Тарих белә андый хәлләрне.
Уң кулын ул суза күрешергә,
Сул кулында тота хәнҗәрен.
Бабаларым күрше-күлән белән
Соңгы кабымлыгын бүлешкән;
Шикләнергә урын калдырмаган,
Ике кулы белән күрешкән.
Бар дөньяга үрнәк ул гадәтне
Һичвакытта ташлау килешмәс.
Эчкерсезлек нуры сибеп яшәр,
Сыңар куллап татар күрешмәс...
Күрешмәс!

## Бар да исәптә

Чит-читләре көйгән байрак төсле,
Татарстан, Синең харита.

Безгә килеп җиткән нәни кисәк...
Янып, теткәләнеп тарихта.
Олы җәймә кебек вакытлары
Булган. Утлар аңа төрткәннәр.
Кечерәйгәч, комсыз бер дәүләтнең
Кульяулыгы итеп йөрткәннәр.
Башъяулыгы бит ул, ашъяулыгы!..
Зур милләтнең күңел бизәге!
Янган байрак кәлләрен дә җыеп
Үлчәр әле тарих бизмәне...

## Мүкләкләр илендә

Кәеф-сафа корып яши торгач,
Кимеп куйса казна акчалары;
Бәрәкәтле Казан якларына
Килеп чыга Мәскәү патшалары.
— Ничек болар? Тиеш ясакларын
Вакытында түләп баралармы?
Бик тә сөзгәк иде бабалары...
Үзгәрмәде микән балалары?
Ә балалар күптән... мүкләк сыер,
Мөгез урыннары яндырылган.
Карашыңнан куркып, дер калтырап
Тора торган итеп калдырылган.
Кирәк дисәң, илтеп бирәчәкләр
Үзен, кызын, улын, туганнарын.
Агызалар алып байлыкларның
Җир астында хәтта булганнарын.
Тынычланып китә «атакайлар»:
— Килер җире иркен мөлкәтләрнең!
...Исәнлеген бирсен илен сатып
Көн күрүче өркәк мүкләкләрнең...

## Көнләшерлек булган

Ары чапкан, бире чапкан,
Өчкә алган, бишкә саткан.
Күмер баткан, алтын тапкан,
Дүртәр-бишәр хатын тоткан.
Иле булган, дене булган,
Горур саны, даны булган.
Безнең белән чагыштырсаң,
Ким дигәндә даһи булган!
Кызыккан да... әтрәк-әләм
Килеп тулган төрле яктан.
Дошманга ни... әле үзем
Шул Татардан көнләп ятам...

## Көтү чиратьı

Томан мендәренә башын салып
Йоклап ята таулар арасы.

Мал көтәргә чират житте безгә,
Чыклар ярып шунда барасы.
Тургайлары сайрап каршы алыр,
Суырлары кабар сыбызгы;
Йомраннары басып карап калыр
Кай төбәккә барасыбызны.
Кояш чыгар, талгын җил кузгалыр,
Томан мендәр эреп таралыр;
«Әби чәче» китәр дулкынланып,
Төшеп калган төсле тарагы.
Керт-керт итеп маллар утлый башлар,
Сискәнерләр каты сөйләшсәң;
Вакыт туктап калган кебек булыр,
Тау башына менеп чүмәшсәң.
Онытылыр дөнья мәшәкате,
Телефоннар дәшмәс чырылдап.
Мәңге канәгать була белмәгән
Түрәләре йөрмәс ырылдап.
Сәхрәләрне чыгып күрә алмый
Күпме гомер безнең жәл үтә.
Тизрәк житсен иде шушы чират,
Тән арса да, җаның ял итә...

## Үзгәрер ул

Елама син, чиста намус,
Чәбәләнмә, гарьчел вөҗдан.
Оятсызлар әйтсәләр дә:
— Сезнең абруй,— диеп,— тузган.

Хафаланма, керсез хыял,
Өзгәләнмә, нечкә бәгырь.
Бәргәләнмә, юка күңел,
Ватылырсың, син бит — бәллүр.

Белеп торам, Сездән башка
Кеше рухы черер, азар.
Сез бит ваклап сатылмыйсыз...
Таралыр бу кыргый базар!

* * *

Бәхетлерәк микән әллә
Бу дөньядан киткәннәр,
Сират күперләрен узып
Гадел хөкем үткәннәр?

Шулай уйлап куям кайчак
Күңелгә шом кергәндә.
...Мескеннәрнең иман сатып
Җан саклавын күргәндә...

## Гафу итмәс

Катнаш никах арта барган саен
Урыс «бажай» үрчи, шәбәя.
Бездә генә бетә, юкка чыга
Гасырлардан килгән шәҗәрә.
«Насыйп эше»,— диеп әйтсәләр дә,
Нә табигый, сына тәһарәт.
Дөньялыкта тату яшәсәң дә,
Икеңә бит ике зиярат.
Кем фатиха бирә белә торып?
Уртак юл бит сына, өзелә.
...Ни оятың җитеп күренерсең,
Көне җиткәч, Тәңре күзенә...

## Чибәрләр язмышы

Синең чибәрлегең, бүлеп булса,
Җитмеш кызга таман булырлык.
Падишаһлар килеп башын ияр
Керфек сирпеп бирсәң боерык.

Синдәйләрнең яшьлек-дәрәҗәле,
Тәкъдим күпкә башың әйләнер.
Ишегеңнән куып чыгарганнар
Тәрәзәңнән кереп бәйләнер.
Җитмеш кыздан калыр... ялгыз хатын,
Рәхим-шәфкать көтмә ир-аттан.
Таралырлар... Якын килә алмый
Өзгәләнер чынлап яраткан.

Үкенерсең соңгы чиктә генә
Бәхетеңне күрми киткәнгә.
Чибәрләрнең күзе төс аермый,
Сөйлим, сеңлем, баштан үткәнгә.

* * *

Лачын кебек кыю чагым
Үткән инде, үткән.
«Кош-корт» күрсәм чаяланып
Томырылмыйм күптән.
«Җиләк» чүпләп йөргән еллар
Киткән инде киткән.
Җиләк тәме йогып калган
Иреннәрем кипкән.
Сызланма, җан! Бер гомергә
Җиткән инде җиткән.
Бар булганын кабул кылсын,
Шуны сорыйм Күктән...

## Син...

Кичә генә кызыл идең,
Бүген инде яшелсең.
Хамелеон кәлтә сыман
Гел үзгәреп яшисең.
Шәмаилләр сатып алдың,
Кигән булдың түбәтәй.
Эчтәлеген белмәсәң дә,
Иренең дога тибрәтә.
Тәхет саклап, вөждан таплау
Синдәйләргә үз нәрсә.
...Тәре дә тагарсың әле
Заманалар үзгәрсә...

## Хак шулай

Актүбәнең аккош төсле,
Ак күлмәкле чибәре,
Хәлсезләнгән уйларыма
Канат куеп җибәрде.
— Борчылма син, абый,— диде,—
Кайтуыңны күтәрмен.
Синдә әле сөю дәрте
Күп елларга җитәрлек.
Оныттым да уйларымны,
Кушылдым ул көлгәнгә.
...Ялган сүз дә ышандыра,
Ышанасың килгәндә...

## Сирәк бәхет

Буй булса да, акыл шәрифләрең,
Биләүнеке әле, биләүнеке.
Үсмер чакның татлы бер өмете —
Берәүнеке генә булу,
Берәүнеке!
Тормыш итү — шул ук сират кичү,
Гамәл-кануннары — бүренеке.
Сирәк бәхет икән яши алу
Берәүнеке генә булып,
Берәүнеке...
Картлык килә — уйланулар чоры...
Тоярлар да рухи бердәмлекне,
Фәрештәләр йөртер иңнәреңдә —
Берәүнеке генә булсаң,
Бе-рәү-не-ке!..

# ШИГЪРИЯТ



## Гайсә Гатауллин[1]

### ДӨНЬЯ БУ...

* * *

Инде утларыннан алса,
Суга салган дөнья бу.
Чәчкәләре белән алдап
Тартып алган дөнья бу.

Елап булмый, елатса да
Үзе дә бит ничә сүнеп,
Ничә янган дөнья бу!
Үзе дә бит, ах, үзе дә:
«Ни булыр киләчәгем?» — дип
Уйга калган дөнья бу...

* * *

Менә тагын
        бөтен яклардан берьюлы
Җилләр исте.
Бакчамдагы өмет чәчкәләрен
Парә-парә кисте.
Калдым басып бер ялгызым
Кара җир уртасында.

---

[1] Гайсә ГАТАУЛЛИН — *1948 елда туган; балалар өчен «Этнең койрыгы нигә кәкре?», «Тавыш иле һәм батыр черки» кебек шигырь һәм «Очар кошлар кебек» һ. б. проза китаплары авторы, 1995 елдан Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы. Лирик шигырьләре белән журналыбызда беренче тапкыр катнаша.*

Кая барсам, кая китсәм —
Дүрт ягым да кыйбла...

...Бөтен дусларым ерактан
«Нишләр, йә?» — дип карап тора.

* * *

Чалт аяз — ява яңгырлар,
Җирдә кыш — сайрый былбыллар,
Карлар ява җирдән күккә,
Үргә таба ага сулар...

Көлеп барам — ияргәннәр
Төрле-төрле авыр уйлар...
Шатлыкларым күпкә мәллә
Әрнеп туа гел күңелдә
Моңлы җырлар?..

* * *

Якынлашкан саен
Матурлыкка
Һәр адымны бик сакланып атла:
Ярты юлда егылып калучылар
Таш атарга, йә аяк чалырга
әзер торыр сиңа
һәр минутта.

## Коры елда

Ут белән су тигезлеге югалды,
Дөньяларны эссе җилләр урады,
Кипкән яшьләр белән гөлләр елады:
«Бир миңа, күк, бер йотым су?» — диеп.

Ярылды Җир, кипте күлләр, көйде үлән,
Шатлык качты кешеләрнең йөзләреннән.
Тик сабыйлар уйный тузан чөеп:
«Яңгыр ява, яңгыр ява!» — диеп...

* * *

Тоташ шатлык булмагандай
Тоташ кайгылар да булмас.
Сандугач та кунган саен
Бер үк гөлләренә кунмас.

Берчак килеп бозлар яуса —
Берчак килер ләйсән яңгыр.

Бар да узар, барысы да
Сагынып сөйләргә калыр...

* * *

Гомер юлын үткән чакта
Ниләр узмас бу баштан,—
Шатлыклар бер очы белән
Кайгыларга тоташкан.

Гомер юлын үткән чакта
Ниләр узмас бу баштан!
Дуслар дошман булмас, дисәм —
Дус та була икән дошман...

### Уен

Кемнәргәдер өеп бирә,
Укаларга төреп кенә.
Кемнәргәдер сөзеп бирә
Энә очына элеп кенә...

Көн килә дә, энә очына
Элеп биргәнен дә ала,
Укаларга төреп-төреп
Өеп биргәне дә кала.

Шул уеннан дөнья кызык таба...

* * *

Кайчагында матур бер сүз
Матур кабыгын сала.
Сала да, тигәнәк булып
Җанга килеп кадала...

* * *

Инде соңгы сүзләр әйтелде...
Давылдан соң дулкын тынар да,
Яңгырдан соң кояш чыгар да
Салават күпере буйлатып
Син кайтып килерсең шикелле...

* * *

Гөлбакчага килсәм —
Капкалары ябык.

Йөрим менә
Сары камыл эчләрендә
Эзләр салып...

## Тылсым яки әкияттән бер өзек

Бер талпынды — тавык булды,
Бер тайпылды — чыпчык булды,
Бер сибелде — тары булып
Тәгәрәп китте җирдән.

Бер талпынды — лачын булды,
Бер селкенде — дуңгыз булды...
Тагын кеше булыйм дисә —
Тылсымның көче югалды...




# АКЧАРЛАКНЫҢ САГЫШЫ

## (ҮЛЕМЕНӘ БЕР ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН ШАГЫЙРЬ РӘШИТ ӘХМӘТҖАНГА МӘРСИЯ)

*Сез китмәгез, акчарлаклар,*
*Акчарлаклар...*

Рәшит Әхмәтҗан.



Күпме шагыйрь һәм әдип — олугъ исемнәр, зур бүләкләр алалмыйча китте бу фани дөньядан! Лаек килеш — алмыйча киттеләр. Үпкәләгән сыман, хәтта рәнҗегәндәй дөньядан күчте алар! Күпме лаек исәннәр хәзер дә шул халәттә, үпкәләгән шикелле, кемгәдер рәнҗегәндәй — бүләксез, орденсыз иҗат итә. Ләкин шунысы бар: лаек мәрхүмнәр дә, лаек исәннәр дә чынлыкта үпкәләмидер, рәнҗемидер — андыйларның максаты бүләк-медаль түгел. Әмма алар өчен җан атучылар, шигырь сөючеләр үпкәдә, рәнҗештә. Әлеге шагыйрьләр исә гасырларда укып ятларлык әсәрләр калдыра да, җылауга тиң сагышлы елмаеп, вафат була.

Риваятьләр каһарманы кеби батыр ир, олугъ әдип Салих ага Батталның кытыршы гомере, фаҗигале әҗәле тетрәндермиме йөрәкләрне! Назга-сөюгә саран булды аңа язмыш, бик тә саран булды: тәкъдир аңа яхшылыкны мыскыллап-мыскаллап, җәзасын исә олылап-олаулап, мул бирде...

Нишләп шулай була икән ул дөнья: талантлы булса, тормыш җаен белми, бүләкләр артыннан чапмый, «җәмгыятебезнең каймагы» булганнар йортыннан фатир дауламый; эше аз, акчасы күп булган җылы эзләми — ул иҗат итә, нәфис сәнгать ярата, гүзәл шигърият бинасын кора һәм шул бинаны корганда торыр өчен үзенә дә иркен бина төзүне онытып җибәрә.

Бар коеп куйган шагыйрьләр. Алар химаяга, игътибарга мохтаҗ. Андыйларның тормыш-көнкүреш эшләрен кемдер кайгыртырга тиеш. Кемдер... Бай химаячеме, хөкүмәтме, халыкмы? Нишләрсең, әгәр бай кеше сәнгатьтән хәбәрсез булса, хөкүмәттә сәнгать аңламаган кешеләр утырса, халкың үзе ярдәмгә мохтаҗ булса?!

Без әнә шул, үз мәнфәгатьләрен алга сөрә алмаган чын талантларга өстәнрәк багабыз; вакыт-вакыт, ихтыярый-ихтыярсыз рәнҗеткәлибез дә. Без өс-башы өф-өф ителгән, шома битле, сакал-мыек үстермәгән, гел ак якага муенчак тагып, кеше алдында хәмер эчмәгән, төз йөрешле һәм тәти сөйләшүчеләрне күбрәк үстерәбез. Дөрес, тәтиләрне үстерергә кирәк, ләкин ярдәмгә-химаяга мохтаҗ талантларны да читкә какмаска иде... Олы исемнәрне, рәсми игътибарны киемгә карап кына түгел, иҗатка, бары тик иҗатка карап кына өләшер вакытлар да җитәр, иншаллаһ! Бирелде бит Тукай бүләге Семен Липкинга, Шәрәфигә, Әлфия

ханымга, Мөдәррискә, Фәнискә — соңрак булса да, бирелде! Ун елга гына соңара шул татар! Ун-егерме еллар моннан элек алар моңа лаек түгел идемени?!

Өс-башы өф-өф ителгән кешенең таланты да булса, бу бер камиллек булыр иде дә... Талантлы кешенең өс-башы өф-өф ителгән булса, шәп булыр иде дә... Кайчак табигать икесенең берсен генә бирә шул.

Бәс, талант микъдарын дөрес үлчәп, рәсми бүләк бирер өчен бер генә бизмән кала: әдәбият-сәнгать кануннары. Моның өчен әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең нык үскән булуы һәм исем-бүләк өләшүчеләрнең югары дәрәҗәдә мәгълүматлы булуы шарт. Әмма... Шартлар көтә-көтә гомер үтә. Иҗат кешесе шартына-мартына бакмастан, иҗат итә.

Иҗат, сәнгать, әдәбият — ул могъҗизалар иле, серләр яшерелгән сандык, мажаралар аланы. Сәнгатьченең иҗат остаханәсе сихрилек, серлелек белән тулган була.

Анна Ахматовадан сораганнар:

— Твардовский иҗатына мөнәсәбәтегез ничек? — дигәннәр.

Шагыйрә әйткән:

— Твардовский, әлбәттә, яхшы шагыйрь, ләкин анда сер юк! — дигән.

Анна Ахматованың бу сүзе әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүчеләргә шәмаил урынына язып, диварга элердәй тирән мәгънәгә ия.

Без дә бит әдәбияттан, сәнгатьтән могъҗиза, сер көтәбез түгелме? Көткән нәрсәбезне китапта тапсак, без бәхетле. Тапмасак — әсәрнең кыйммәте бетә.

Татар шигъриятендә ачылмаган серләр бик күп. Ул серләрне ачып, бер куаначак, шул могъҗизаны халыкка җиткереп ике кат бәхетле буласы тәнкыйтьчеләрне көтә «Шигърият» дигән серләр сандыгы.

Серлелек, тел төбе, киная, ишарә, төрттереп, читләтеп әйтү, могъҗизалы мажаралар татар әдәбиятында күп исемнәрне мәңгеләштерде: Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый, Кандалый, Имәни, Акмулла, Дәрдемәнд, Рәми, Тукай, Такташ, Туфан.

Алардан соң әдәбиятта сугыш темасы «тәхет» яулады. Шигырьгә яңа буын вәкилләре килеп керде: Илдар Юзи, Шәүкәт Гали, Рәшит Гәрәй, Хисам Камал, Әхсән Баяннар... Ике буын арасында күпер булып Әнвәр Давыд, Зәки Нури, Гали Хуҗи килде... Бу күпернең субай баганалары булып Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Сибгат Хәкимнәр аягурә басты...

Хәрби лирикадан соң шигърият дигән дәрьяда тынлык, салмаклык, җилсезлек чоры башланды. Шигырь көймәсенең җилкәне шәлперәйде. Көймә уңай җил көтеп, чарасыз гына сәясәт дулкыннары каккан якка әкрен генә тирбәлә калды. Әнә шундый чарасыз тынлыкта Роберт Әхмәтҗан җилләп-давыллап, җилкәннәрне өреп кабартты, бер үзе галәм бушлыгын тутырды. Роберттан соң тагын тынлык. Һәм татар шигыренә күпләп яшь шагыйрьләр ургып, бәреп керде: Рәшит, Равил, Рәдиф, Рөстәм, Гәргәри, Харис, Зөлфәт, Мөдәррис, Разил, Зиннур, Фәннурләр — бар да серле шагыйрьләр...

Коммунистик хакимият чорында, ачык фикер әйтергә мөмкин булмаган чакта бу шагыйрьләр серле кинаяләр, ишарәләр артына олуг фикер яшерәләр иде. Зиһниятле укучыга ул — ачыш, хәбәрсезгә ул гап-гади сүз тезмәләре иде. Астарлы сүз, яшерен фикер төрелгән шигырьләр бөек бер шигърият хасил итте.

Символлар, кинаяләр белән артык мавыгу хәтта табышмак кеби шигырьләр язарга этәрде һәм кинаяләр-ишарәләр шагыйрьнең бары тик үзенә генә аңлашыла торган табышмакка да әверелгән очраклары булды. Әмма, ни генә булмасын, бу эзләнүләр матур нәтиҗә дә бирде. Шигырь күпкүзәнәклегә әверелде, «ура, ватанпәрвәрлек»тән ераклашты.

Менә шушы бөек калкыныш чорында аталган шагыйрьләр исемлегенең иң башында Рәшит Әхмәтҗан тора. Ул — боларның барыннан да алда беренче шигырь китабын бастырып чыгарган шагыйрь.

Фикер шигыре белән хис шигыре арасында беренче күперне дә ул — Рәшит Әхмәтҗан салды.

Рәшитнең хиссият, моң, сагыш, рәнҗү, җирсү белән тулган бәгырендә яралган шигъри җәүһәрләр иң башта йөрәккә, хискә, соңра зиһенгә, фикергә бәрә иде. Аның шигыре — музыка. Музыка зиһен, акыл падишасы түгел, музыка — хиссият падишасы!

Рәшит Әхмәтҗан — серле шагыйрь. Ошбу серне бәгъре тибрәнүгә сәләтле кеше генә тоя ала, ача ала. Фикер аша ачылмый Рәшит шигыре эчендәге сер; хис, күңел күзе белән генә ачыла ул сер. Шул түгелме нәфисәи сәнгать! Аның шигъре нечкә кылларга тияр-тимәс кагыла, кагыла да — җылата, җылата да — уйлата. Шулай итеп, Рәшит хис аша укучы күңеленә олы фикер сала. Чөнки Рәшитнең

бәгырендә яралган хис (ватан, милләт, йола, әче тәкъдир) укучы күңелендәге аваздаш хисне уята. Рәшитнең күңеле сихри хис нурланышы бирә башлый, бу нурланышны кабул итәрдәй икенче бер калеб — бәгырь булырга тиеш, ул бәгырь, ул калеб укучыныкы, шигырь сөюченеке. Мөкәммәл бер аңлашу, ике яклы элемтә-бәйләнеш барлыкка килә. Син күңелең белән шагыйрьнең ни әйтергә җыенганын сизә башлыйсың, аны аңлый башлыйсың. Бу хисләр ватанпәрвәрлек, милли каһарманлык хисләре икән. Күңелеңнең иң нәзикъ кылларын тибрәтерлек итеп язган кешедә илаһият тарафыннан бирелгән куәт барын аңлыйсың. Рәшитнең каһарман йөрәкле адәм икәнен тоясың. Кече күңелле, олы йөрәкле «Рәшит Әхмәтҗан шигыре» дигән серле дөнья ачыла.

Бу шигырьләр шагыйрь вафатыннан соң аеруча хисле, моңлы вә мәгънәле яңгырый.

«...көләргәме, еларгамы, әллә күзне мәңгелеккә йомаргамы?», дип язды шагыйрь үләр алдыннан.

«ишәяләр шундый бичаралар, ничә үлдем... һаман үч алалар.»

Үткән эш үткән, кире кайтмас Рәшит Әхмәтҗан. Үкен син, хет, үл, җыла. Ләкин аның шигырьләре — үлемсез. Бүгенге җыламсырап лаф ору соңга калган үкенү түгел, исән калган Рәшитләр, Әхмәтҗаннар, Рөстәмнәр, Зөлфәтләрнең кадерен белик, диеп әйтүем иде.

Эх, бу җирне күпме таптады —
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

Рәшит гомере буе олугъ бәйрәм көтеп яшәде, менә шушы иң беренче язган шигыреннән алып вафатына кадәр бәйрәм көтте. Кыңгыраулы атларда бәйрәмне айкап йөрде ул шигырьләрендә. Ул күңеле, күрәше, хыялы белән халкына ничәмә-ничә тапкыр бәйрәмнәр яулады, ирек алып килде.

Рәшитнең иҗаты акчарлак кеби парлак, аның акчарлагы болытларга, күкләргә, биеклеккә хуҗа булды.

Аның иҗат җәүһәрләре гаҗәеп бер уңдырышлы мохиттә шомарды, ялтырады. Үзе кебек талант иядәре белән бер Казанда кайнау да, башлангыч иҗатында аңа эләккән дусларча тәнкыйть тә, киңәшләр дә, соңгы елларда гына килгән шөһрәт тә аның каләмен чарлады, чыныктырды; яшәгән саен Рәшитнең күңеле нечкәрә-йомшый барды, күңел йомшара барган саен, аның шигырьләре югарырак үрли иде.

Рәсми даирәләр алдынгы тәти исемлеккә кергән шагыйрьләр-әдипләр турында гына мәдхия, тәнкыйть мәкаләләре язып, «курсовойлар, дипломныйлар» һәм диссертацияләр якларга алынган тәнкыйтьчеләр, әдәбият-сәнгать белгечләре, а-ау, сез кайларда йөрисез! Кайда сез ачкан яңа талантлар, кайда сез үстергән шәхесләр, сез яңача шәрехләгән әсәрләр? Нигә Рәшит Әхмәтҗан кебек сирәк туа торган талантларны алданрак сиземләмибез, күрмибез, үз вакытында аларны тәкъдир итмибез?

Утызынчы еллардагы тәнкыйтьнең төп максаты талантларны ачу түгел, ябу, бетерү иде. Аннан соңгы еллардагы тәнкыйть рәсми «обойма»га кергәннәрне мактау илә мәшгуль булды кебек. Соңгы вакытта тәнкыйть ни эшли? Классиклар белән әвәрә килә. Классика да кирәк шәйдер, әмма әдәби мохит өчен яңа исемнәр дә, яңа шәрехләр дә бик әһәмиятле нәрсә.

Күңел әдәбият белеме өлкәсендә яңа ачышлар көтә. Яңа исемнәр тирәсендәге эзләнүләрне тели күңел. Иске исемнәр янында моңарчы күренмәгән яңалык, ачыш; мәшһүр турында яңа фикер, яңа шәрех сагына күңел.

Горур җаннар үлми — һәлак була!
Бөркет мине күзли — мин китәм:
«Бу да, балам кебек, горурлыктан
Һәлак булыр, ахры», ди микән.

Рәшит Әхмәтҗан иҗатындагы серләрне ачу киләчәк буын тәнкыйтьчеләренең җилкәсенә төшә. Бер аның иҗаты гына түгел: Равил Фәйзулла, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Рәзил Вәли, Зиннур Насыйбулла, Зиннур Мансур, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Лена Шагыйрьҗан, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рөстәм Сүлти һәм башка бик күпләрнең иҗатын баштанаяк өйрәнеп, тел төбен, кинаяишарәләрен, астарлы сүзләренең серенә төшенергә, хиссият аша килгән серле фикерне, фикер аша туган хиссиятне шәрехләп бирү яңа тәнкыйтьченең иҗат мәйданы булыр.

Бар шагыйрьләр — олуг талант ияләре. Ләкин алар үзләре исән чакта үз иҗатларына үзләре комачау итә, андыйлар үз иҗатына авыр йөк-балласт кеби. Алар, гадәттә, тәти кием кими, алар — тортмә холыклы, кызмача йөри, шуның аркасында аның иҗаты да рәсми даирәләр каршында пар канат белән очып, югары күтәрелә алмый. Кинәт шәхес вафат була: олуг иҗат артык йөктән, үзен бар итүче кешедән арына һәм биеккә күтәрелә. Рәсми тәнкыйть тә аңа карата фикерен үзгәртә: шагыйрь даһилар рәтенә куела.

Бар шагыйрьләр — алар үз талантларыннан өстәрәк тора, андыйлар өрлеккә ятып, яхшы-чыдам бау белән үз иҗатларын күтәреп-тотып тора. Шәхес вафат итүгә яки өрлектән төшүгә үк, бау кулдан ычкына, иҗат йөге аска төшеп китә.

Бар сәләт ияләре: алар шулкадәр нәтиҗәле иҗат итә ки, ул шагыйрьнең җилкәсенә авыр иҗат йөге җыела, шөһрәт, иҗат бәхете артканнан-арта бара. Шушы талант иясенә шушы талант йөген күтәреп йөрер өчен ныклы тез буыны, рухи үҗәтлек бирелмәгән була. Чәндер аяклар, зәгыйфь буыннар, нечкә муен чыдый алмый, шәхесне үз таланты үзен сытып үтерә: күпме сәләт ияләре сәрхүш булды, янды, үлмичә һәлак булды.

Уйна, көл туган җиремдә,
Гашыйк ит бөтенесен.

Каләмдәшләре арасында иң шаяны, җор сүзлесе ул иде — Рәшит Әхмәтҗан.

Берзаман Рәшитнең чәче агара башлады. Буятмады ул ак чәчләрен. Чәч буятып яшәрергә тырышучылардан ул көлә иде. Чәч агару — ул картаю галәмәте түгел, агарган чәчне кынага буяп йөрү — картаю билгесе.

Чәче коела башлауга, кайбер җегетләр ян-яктагы чәчен озын итеп үстереп, шәрәләнгән баш түбәсен каплап, аркылы яткызып, сулап-майлап йөртәләр. Рәшит пеләшен капламады. Башлык астына яшерергә дә азапланмады. Ясалма чәч тә кимәде. «Алла биргән, Алла алган», диеп калган чәчен да ялт итеп кырдырып йөрде. Шаяртучылар, үртәүчеләргә дә исе китмәде.

— Мөдәррис белән Равилгә теләктәшлек йөзеннән чәчемне юри кырдырдым,— дип көлә иде үзе.

Бу да үзенә күрә бер батырлык.

Чәч коелу ул картлык галәмәте түгел, пеләшеңне яшерергә тырышу картлык килгәнне аңлата.

Рәхәт көлә иде ул Рәшит, һәр нәрсәдән кызык табар иде, мәрхүм, шаярырга оста булды.

Ул ризыкның кадерен белә иде; ул тәмләп ашый, ашамлыкны һәрвакыт бәрәкәтле итеп тота, янга калдыра, соңгысын ашап бетерми, башкалар өчен, мохтаҗраклар өчен саклый һәм соңгысын мохтаҗ кешегә чыгарып бирә. Ул тәмәкене дә тәмләп, бәрәкәтле итеп тарта иде.

Кысанлык аны төнге каравылда торырга мәҗбүр итте; ул балалар бакчасын саклый иде. Торыр урыны булмагач, үзе дә шул бакчаның чарлагында яшәде. Бу чарлак «Дум калхуз» гына түгел, килгән-киткән Казан кешеләре дә шунда җылы куыш таба, бу чарлак шагыйрьләр, сәнгатьчеләрнең иҗат йорты да иде. Түбәсе булмаганнар, вокзалда куныл йөрүче шагыйрь-шогарә, хатыны куып чыгарган бичара ирләр дә, юлы төшкән «командированныйлар» да Рәшиткә килеп сыена, чарлагы тар булса да, күңеле киң — барыбыз да сыя идек.

— Рәшит кебек олы җанлы, киң күңелле дуслар сирәк була,— дип сөйли Әзһәр Хөсәен.— Казанга килгәч тә минем торыр урыным юк иде. Рәшит мине үз чарлагына сыендырды. Мин шунда торып театрда администратор булып эшли башладым. Аннан Курчак театры һәм Камал театры директоры булып киттем. Рәшиткә чиксез хөрмәтем, рәхмәтем...

Әзһәр кебекләр хет Рәшит эшләгән яхшылыкларга рәхмәт укый. Рәшит урын, тәгам биргән кайбер бәндәләр, соңра Рәшиттән көлеп, аны кимсетергә тырышып, иҗатын да күрмәмешкә салышып йөрде. Андыйларга Рәшит эчтән генә бик рәнҗи кебек иде. Ләкин яңадан шул кеше килсә, барыбер аңа урын, ризык бирә иде. Нечкә күңелле иде, мәрхүм, кечкенә генә игътибарга да шатлана; рәнҗетсәләр, күз яше белән җылый иде.

Ул — шагыйрь, бары тик шагыйрь! Жанрларда ул чәчелмәде. Саф шагыйрь килеш иҗат итте.

Әмма без аны аңламадык. Зарланса — көлдек. Кызык сөйләсә дә — көлдек. Без хәтта аның искиткеч нәфис каләмле, гаять олы талант иясе икәнен дә аңлап бетермәдек шикелле. Юкса, ул әдәбиятка күбебездән алдан килде, олы иҗат калдырып, күбебездән алда бәхилләште.

Шагыйрьләр арасында иң сагышлысы, иң моңлысы, иң күп жирсегәне ул иде — Рәшит Әхмәтҗан.

Вафатына атна кала гәжур (гәзитә-журнал нәшрияты) каридурында очраштык. Мин каядыр ашыга идем. Аның күзе дымлы, йөзе бик тә борчулы иде. Ул мине читкәрәк алып:

— Ашыксаң да, әз генә янымда тор! — диде.

— Ни булды? — дип сораганымны да көтмичә:

— Үләм бит, Батулла,— диде дә жылый башлады.— Гомерем әз калды.

Салганнан шулай хисләнгәнме дисәм, юк. Рәшит ап-аек иде. Еш шаяруы белән бергә, ул еш зарлана торган кеше иде. Шуңа күрә, без — дуслары — аның аһ-зарына ияләнгән, игътибар итми идек.

— Үтәр әле,— дидем.

— Үтми, үтәрлек түгел,— дип Рәшит сабый баладай үкси.

— Ни булды соң? — дим.

— Дөньягыз суык, җанга җылы юк! — диде шагыйрь. Мин эшем белән китеп бардым, Рәшит күз яшьләрен бүтәннәргә күрсәтмәскә тырышып, лифт белән тәрәзә арасында калды.

— Син дә мине аңламадың! — дигәне һаман колакта яңгырый.

Аның тавышы диңгезсез калган акчарлак авазына охшаш иде.

Бер атнадан соң Равил Фәйзулланың:

— Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан вафат! — дигәне дөньяны тетрәтте.

Ни булды? Шигырьдән шигырьгә үсә килә иде, поэма арты поэма яза иде. Шөһрәт тә килеп житте үзенә: «Исхакый» бүләген бертавыштан аңа, иҗатына бирделәр. Осталык биеклегенә житкән, тәҗрибәсе, иҗат бәрәкәте мул: яз да яз! Шул чакта гына аның эчендә нниндидер кылы өзелде. Кем өзде аның бу кылын? Йөрәк ни өчен тибүдән ваз кичте? Юрый-юрый үзенә-үзе әҗәл чакыру идеме бу? Тукай әйтмешли: тәдрижи үзен-үзе үтерергә уйлаган идеме ул? Әллә олы талантының рухи буналышы (кризисы) идеме бу мизгелләр? Каян сизгән, ничек сизгән ул тиздән үләсен?

...Энесе Илдусны чакыртып, бераз сөйләшеп утыргач, шагыйрь ятарга тели, ята да — җан да бирә.

Сер. Иҗаты тулы сихри сер аның. Әҗәле дә сер булып калыр. Гадәти булмаган талантның гадәти булмаган вафатыдыр бу үлем. Үзенең олы талантка ия икәнен белеп тә, аның шул талантын күрмәмешкә салышканнары аны еллар буе борчыды, рәнжетте сыман... Бәлки әнә шул еллар буе җыелган сагышрәнжеш аның гомерен кыскарткандыр? Төрле гоманнар кормыйча, кире чыкмас фаразлар урманына кермичә генә, бөтен җавапларны Рәшит Әхмәтҗанның олы иҗатыннан, сихри-серле шигырьләреннән эзләргә кирәктер.

...Татар шигърияте көрәшче, каһарман шагыйрьләр иҗатыннан тәшкил.

Рәшит Әхмәтҗан исә — шигырьләре белән дә, азатлык өчен ачык көрәштә дә шәхси үрнәк күрсәткән милли каһарманыбыздыр!

Олугъ куәгә ия булып та, дөньяда тиешлесен үз вакытында алалмыйча вафат иткән шагыйрьләрне, сәнгатьчеләрне Илаһ изге көрәштә — Җиһад сугышта — Газаватта һәлак булган шәһидләр кеби, турыдан-туры үз хозурына кабул итә торгандыр, мотлак. Алар, бу шәхесләр, кенем өчен дип түгел, денем өчен дип яши, иҗат итә һәм фани дөньядан дәрел бәкага — мәңгелек йортка күчә.

Гүрең нур булсын, урыныңны Җәннәттән әйләсен, Рәшит кардәш!

Бу мәкалә-мәрсия Корбан бәйрәменә каршы таңда язылды. Акчарлаклар тәрәз каршыннан очып-очып уза... Шулар мәҗбүр итте мине кинәт каләмгә тотынырга.


...Акчарлаклар Рәшит Әхмәтҗан тавышы илә кычкырдылар...

**Рабит БАТУЛЛА Мөхлис угълы.**

9*.

# ӘСКӘР АЛИ УЛЫ ШӘЕХ-АЛИ

(1885–1968)



*Әскәр Шәех-Али гомеренең соңгы көннәрендә.*

Борынгы Рим философы Сенека, кешеләр язмышы турында уйланып, үзләре исән чагында ук үлгән саналырлык адәмнәр булган кебек, үзләре үлгәннән соң да башкалар күңелендә яшәүче үлемсез шәхесләр була, дигән.

Бу фикер безнең мәкалә героена да туры киләдер шикелле. Әмма ләкин хәзерге буын аның хакында бер нәрсә дә белми диярлек. Әйе, Әскәр Али улы Шәех-Алиның исемен оныттыру өчен заман шактый тырышкан.

Бервакыт мин үзем белгән бер тарихчыдан: «Аның исеме сиңа танышмы?» — дип сораган идем, ул, уйлап та тормыйча: «Ә, Явыз Иванга Казанны яулап алырга булышкан хыянәтче ханны әйтәсеңме?» — дип ярып салды.

Әскәр Шәех-Алинең тормыш юлы белән танышкан укучылар аны, исемнәре аваздаш булган өчен генә, әле уналтынчы гасырда ук яшәгән сатлыкжан Шаһгали хан белән бутамастыр дип беләм. Алар арасында бернинди уртаклык та юк.

Патша самодержавиесенең нигезләрен какшату өчен күп көч куйган, алмашка исә тоталитар җәмгыять кенә алып, бихисап корбаннар бирергә дучар ителгән зыялыларыбызның үткәне Әскәр Шәех-Алинең язмышында да ачык чагыла.

1917 елның күпне вәгъдә иткән демократик язы белән башланган кискен борылышлар Рәсәй һәм аның халыклары язмышында нинди роль уйнаганы хакында әле күп буыннар дәвамында бәхәсләр булыр. Монысы — тарихи-фәлсәфи мәсьәләләрнең берсе. Ә без исә бәхетле киләчәк өмет итеп егерменче гасырга аяк баскан буынның драматик язмышын үз җилкәсендә татыган шәхес турында сөйләргә җыенабыз.

Әскәр Али улы Шәех-Али үзенең чыгышы белән Россиянең Европа җирлегендә яшәүче мөселман зыялыларының гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклаган хәлдә, унтугызынчы гасырда урыс җәмәгатьчелегенең сизелерлек бер катламы булып әверелгән өлешенә барып тоташа. Элгәрерәк гасырларда үз тамырларын бары тик фамилияләрендә генә саклап калган, асылда исә урыс дворяннары арасында эреп-йотылып юкка чыккан һәм үз халкы, үз этносы белән барлык бәйләнешләрен югалткан милли элитар катламнан нык аерылып тора бу зыялылар.

Әскәрнең әтисе Али Шәех-Али үзе кумык, Кавказ сугышында җиңелгән имам Шамилнең уллары белән бергә әсир ителеп, Петербургка китерелгән мөселман егетләренең берсе була. Пайтәхеттә ул бик төпле хәрби белем ала. Аның хәрби хезмәте казак гаскәрләрендә үтә. Оренбур казакларының 6 нчы полкы командиры буларак, ул 1877 елгы урыс-төрек сугышында катнаша. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен патша Александр II указы нигезендә өч орден белән бүләкләнә. Генерал-майор дәрәҗәсенә ирешеп, отставкага чыкканнан соң, гомерен Петербургта үткәрә.

Али Шәех-Алинең хатыны, Әскәрнең әнисе Гөлсем Тәфкилева Бөкәй урдасы хакиме Җиһангир ханның торыны-оныкчасы була. Борынгы нәселле әлеге татар ыруының туган-тумачалары арасында танылган татар фамилияләрен — Алкиннар, Еникеевлар, Әхмеровлар, Терегуловларны да очратабыз.

Әтисе Әскәрне дә хәрби кеше итеп күрергә хыялланса да, улы пайтәхет университетын сайлый. Әти кешегә үз юлыннан китеп дәрәҗәле-абруйлы кавалергард булган олы улы Җиһангиргә карап юанырга гына кала.

Тикшерену-төпчену, һәр нәрсәнең асылына төшәргә теләп кызыксыну сәләте Әскәрдә бик иртә уяна. Бала чагында уенчыкларын сүтеп-җыеп, ватып-төзәтеп үсә-үсә, егет булып җитешкәч төрле приборлар-машиналар белән мавыгып китә, кем әйтмешли, аңа тәмам «тимер җене» кагыла. Әнә шул мавыгу аның киләчәк язмышын, бөтен гомер юлын билгели. Революция, гражданнар сугышы елларындагы катлаулы-сикәлтәле чорда булсын, соңрак — инде утызынчы елларда Сталин лагерьларының берсендә ачлы-туклы җан асрап яшәгәндә булсын, аны үз һөнәре һәрвакыт үлемнән саклап кала килә. Әмма ачы язмыш аңа барысын да өеп бирә...

Әле гимназиядә укыганда ук Әскәр төгәл фәннәр белән мавыга, бигрәк тә физика белән химияне үз итә ул. Ә гуманитар фәннәргә бик исе китми, аларга яшүсмер малай бәя биреп бетерми һәм бу хәл тиздән алган билгеләрендә дә күренә башлый. Гимназиядә исә тәртипләр шактый каты... Әтисенең дә холкы кырыс... Артта калган фәннәрне репетитор яллап куып җитәргә туры килә. Әскәрнең бәхетенә, репетиторы студент Никола Оттокар рәсем сәнгате, әдәбият, тарих кебек фәннәр буенча энциклопедик тирән белемле кеше була. Соңыннан ул күренекле сәнгать белгече, профессор дәрәҗәләренә ирешә, егерменче еллар башыннан Италия университетларының берсендә укыта. Әскәрнең мавыгуы физика һәм аны тормышта куллану булып калса да, гуманитар фәннәр буенча иркен фикер йөртә алуы, рәсем сәнгатеннән бигрәк тә киң мәгълүматлы булуы белән ул, әлбәттә, Никола Оттокарга бурычлы.

Белгәнебезчә, егерменче гасыр башлары техник прогресс тантана иткән чор була: күктә беренче аэропланнар оча башлый, шәһәрләрдә автомобильләр күренә, урамнарда-йортларда электр лампалары кабына, әле кайчан гына могҗиза саналган телефон исә пайтәхеттәй зур калаларда гадәти күренешкә әверелә. Әскәр гимназиядә укыган елларда физика фәнен укыту нигездә классик кануннар буенча алып барылып, физика законнары тактада язылып кына, немецлар әйтмешли, «крейде физик» — акбур физикасы рәвешендә генә өйрәнелсә дә, техник казанышлар йогынтысы классларга да үтеп керә. Мөстәкыйль тәҗрибәләр үткәрүләр хуплана, техник түгәрәкләр оеша башлый. Әскәрнең дә беренче техник «триумфы» гимназиядә тормышка аша. Гимназия директоры кунакларына, тоныкгаз лампалары белән генә яктыртылган ярым караңгы дивардардан аермалы буларак, электр утларыннан балкып торган якты залны күрсәткәндә, горурланып: «Үз укучыбыз Шәех-Али эше бу!» — дип әйтә торган булган. «Әтисе — кавалерист, ә улы, һичшиксез, инженер булачак» — дип тә өсти икән әле. Ул заманда мондый сүзләр иң зур мактау булып яңгыраган, әлбәттә. Чөнки инженерлар әле бик сирәк, алар гадәттә бай тормышлы, ә инде «инженер» сүзе хәзерге «космонавт» сүзенә аваздаш булгандыр мөгаен.

Әскәр Шәех-Алинең Петербург университетына — физика-математика факультетына укырга керүе бик табигый хәл. Техника белән мавыгуы студентлык елларында тагын да көчәеп киткән егет Форд автомобильләренең берсен «иярләп ала». Бай сабакташлары шоферлар яллап машиналарда элдерткәндә, Әскәр машинасын үзе йөртү генә түгел, бөтен механизмнарын өйрәнеп, кирәксә үзе өзәтә-ремонтлый да башлый.

Беренче бөтендөнья сугышы башлануга, Әскәр Шәех-Али, башка күп студентлар шикелле үк, армиягә алына. Артиллерия училищесы каршындагы офицерлар әзерли торган кыска сроклы курсларда укыганда ул соңрак Распутинны үтерүдә катнашып дөньяга танылган Феликс Юсупов белән бергә утыра.

Офицер дәрәҗәсе алган Әскәр Шәех-Али сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Гражданнар сугышы чорында исә кызылларга кушыла, Көнчыгыш фронтның 5 нче Армиясендә артиллерист була. Ә аннары ул Кызыл Армиянең баш штабына — Артуправлениегә күчерелә.

Иске зыялыларның күбесе өчен революцион үзгәрешләр драматик фаҗигаләр алып килә. Кызыл Армиядә хезмәт иткән офицерлар өчен гарҗданнар сугышы тәмамлангач тормышта юл сайлау мөмкинлекләре бик нык кысыла. Армиядә калу да читерекле, чөнки «патша офицеры» дигән кара тамга һәр җирдә тагылып йөри. Ә менә Әскәр Шәех-Алинең 1921 елда демобилизацияләнгәннән соң берен-

че адымнары чагыштырмача уңышлы була. Аның теләсә нинди техниканы буйсындыра алу сәләте, үз куллары белән иң катлаулы детальләрне дә ясый алуы, слесарь, токарь, югары класслы механик һөнәрләре тормышта тиз генә үз урынын табарга ярдәм итә.

Илдә НЭПның беренче елы бара. Мәскәүдә күптөрле ремонт һәм реставрация мастерскойлары ачыла. Элекке кызыл командирның катлаулы йозаклар, примуслар, арифмометрлар, язу машинкаларыннан алып электр двигательләре, автомобильләргә кадәр теләсә нинди техниканы төзәтә белүе ярап куя. Әскәрне эш белән күмәләр. Теге яки бу әйберне ремонтлаганда-төзәткәндә ул еш кына аның конструкциясенә яңалыклар да кертә, эшләү мөмкинлекләрен яхшырта. Аңа рәхмәт сүзләрен әйтеп бетерә алмыйлар.



*Әскәр Шәех-Али хатыны Суфия ханым белән.*

Мөгаен, Әскәр Шәех-Али Мәскәүдәге Урман техникасы институтында яхшы гына эш хакы алып, катлаулы приборлар төзәтүче механик булып кына да кала алган булыр иде. Ул вакытта аның әйбәт кенә торагы да була. Гаиләсенең — хатыны Суфия ханым (танылган татар мәгърифәтчесе Шахбаз Әхмеров кызы), кызлары Динара белән Гөлнарның да тормышлары җитеш... Әмма талантлы инженерның тәкъдиренә башкачарак тормыш юлы язылган булган, күрәсең...

Әскәр Шәех-Алинең тормышындагы кискен борылыш хакында сөйләр алдыннан революциядән соң илдәге мәдәни тормышнын кайбер вакыйгаларын кыскача искәртеп үтү кирәктер, мөгаен. Большевикларның милли-мәдәни сәясәтен, хәзерге күзлектән чыгып караганда, төрлечә бәяләргә мөмкин. Какшамас «тимер-бетон» стереотип фикерләр, «бердәнбер дөрес» тәгълиматлар чәлпәрәмә килеп коелып төшкән бу заманда бар үткәнебезне — яхшысын да, яманын да — себереп түгәргә омтылучылар еш кына элекке ялганнар урынына яңа ялганнар тараталар, яки ярым-йорты хакыйкатьне расларга тырышалар. Кичәге асыл ленинчылар бүген үз даһиларын «чишендерүдә» ни-нәрсәләр генә кыланмыйлар да, кичәге кайбер елгыр атеистлар дини байлык-хәзинәләребез турында ничек кенә лаф ормыйлар! Ә бит большевикларның халыкны наданлыктан-томаналыктан чыгару өчен көрәштә кабул кылган күп кенә чаралары файдалы иде. «Пролетариат мәдәниятен» өйрәнүдән элек гади тапкырлау таблицасын һәм дөрес язу кагыйдәләрен өйрәнергә, иң гади гигиена шартларын үтәргә чакырулар начар идеме әллә? Илнең мөселманнар яшәгән төбәкләрендә күпкырлы агарту эшләре алып бару да үзенең җимешләрен бирмәде түгел, бирде. Төрле курслар, мәктәпләр... укытучылар һәм укучыларның корылтайлары... Болар барысы бергә культура революциясе дип аталды да инде.

Бу уңайдан яшь милли республикаларда ана телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, милли китапларны күпләп бастыру, газет-журналлар чыгару мәсьәләләре иң үзәк мәсьәләләр булганлыгын искә төшерергә кирәктер. Егерменче еллар башында төрки телле республикаларның күпчелегендә ана теленең дәрәҗәсен үстерү, куллану даирәсен киңәйтү юнәлешендә төрле законнар кабул ителә һәм административ чаралар үткәрелә. Бу чаралар, беренче чиратта, суд эшләрендә, җәмәгать һәм дәүләт оешмаларындагы эш кәгазьләрен йөртүдә, мәктәп һәм башка уку йортларында укыту барышында ана телен куллануны күздә тота. Ул чорда Советлар илендә яшәүче төрки халыкларның барысы да диярлек язуда гарәп графикасын файдалана. Әмма «сәяси офыкта» гарәп язуыннан латин язуына күчү билгеләре шәйләнә башлаган була инде. «Яңалиф»не Шәрекъ өчен янә бер революциягә тиңләп, тырышып-тырышып яклаучыларның таләпләре көннән-көн кискенрәк яңгырый. Шул ук вакытта егерменче еллар башында күп

кенә зыялылар гарәп графикасы, бераз «сиплән-төзәтеп» җибәрсәң, әле культура революциясенә дә хезмәт итә ала, дип исәплиләр. Бу юнәлештә Г. Шәрәф, Н. Хәкимов, Г. Алпаров кебек белгечләр, хәреф-шрифтлар язу остасы Г. Идрисов байтак эш башкаралар. Гарәп графикасын татарча вариантта яңартуны күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы Галимҗан Ибраһимов та яклап чыга. Әмма гарәп алфавитын киң кулланышка кертү юлындагы киртәләрнең берсе булып андый язу машинкаларының юклыгы тора. Күп кенә белгечләр, гарәп алфавитындагы хәрефләрнең язылышы катлаулылыкны, күп төрле вариантлары булуны истә тотып, андый язу машинкасын ясау нигездә мөмкин түгел дип табалар. Дөньяда андый типтагы машинкалар бөтенләй булмый.

Гарәп алфавитына яраклаштырылган язу машинкалары җитештерү эшенә нинди зур әһәмият бирелгәнлеген аңлау өчен бер фактны искә төшереп үтү дә җитә. 1923 елны Г. Ибраһимов РКП(б) Үзәк Комитеты Секретариаты утырышында бу мәсьәләне, хәреф-билгеләрне бердәй унификацияләп, машинка механизмын кирегә кайта торган итеп эшләп хәл итәргә тырышулары турында сөйли. Аны Сталин да тыңлый. Ләкин әлеге тәҗрибә-омтылышлар уңышсызлыкка очрый: танымаслык итеп гадиләштерелгән гарәп хәрефләре машинкада бастырып алган нөсхәләрдә бөтенләй укылмый диярлек.

Аеруча әһәмиятле вакыйгалар турында сөйләгәндә, «тарихи очрашу» дип сөйләү гадәткә кергән. Әскәр Шәех-Алинең әлеге чишелмәс мәсьәлә белән очрашуы бик гади-гадәти килеп чыга: Казаннан Мәскәүгә йомыш белән килгән бер танышы аңа әнә шул киребеткән, буйсынмас машинкада басылган бер нөсхә рәсми кәгазь күрсәтә. Шуннан икәүләшеп бик озак ул кәгазьдә басылган язуны укырга тырышып карыйлар, азаплана-азаплана да текстның утыз-кырык процентын гына сукалап чыга алалар. Әскәрнең танышы, өметсезләнеп башын чайкый да, тең үтмәс кәгазьне ертып ташлый: «Наркоматка бу үтенечне кулдан гына язып илтермен инде...» — ди.

Теләсә нинди механизмның «җанын» бөтен нечкәлекләре белән аңлый ала, башкалар аптырап калганда да оригинал чишелеш таба белә торган Әскәр Шәех-Али өчен мондый машинканы ясап карау кызыктыргыч бер табышмак кебек була. Техника белән өстән-өстән генә таныш булган укучыларыбызга гадиләштереп кенә аңлатып бирергә мәҗбүрбез: әгәр дә латин яки рус хәрефле гадәти язу машинкаларының кареткалары йөреше барлык хәреф-билгеләр өчен дә бер төрле булса, гарәп графикасы нигезендәге машинкалар өчен каретканың төрле тезмәләрдә ким дигәндә дүрт вариантта йөреше кирәк. Гомеренең соңгы елларында язып калдырган истәлекләрендә Әскәр Шәех-Али бу катлаулы мәсьәләне чишү юлларын тәфсилләп шәрехләп бирә. Башта тәҗрибәләр иске модель «Континенталь» язу машинкаларында алып барыла, аннары ул заман өчен иң яңа булган «Ундервунд» машинкаларына күчәләр. Бу техник табышмак Әскәр Шәех-Али тарафыннан искиткеч оста хәл ителә. Тәҗрибә өчен ясалган үрнәк «Ундервунд»та бастырып алынган текст шулкадәр ачык, хәрефләрнең язылышы бернинди бозылуларсыз була ки, аны эксперт белгечләр хәтта кулдан язылган текст дип кабул итәләр.

Әскәр Шәех-Алинең бу уйлап табуы, күренекле ачыш буларак, Халык казанышлары күргәзмәсе каршындагы Ачышлар эше комитеты тарафыннан кабул ителеп, берьюлы ике патент ала: ул безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә теркәлә. Бу ачышны рәсми телдә «Язу машинкасы кареткасының басыла торган хәрефкә тәңгәл китереп хәрәкәтләнү механизмы» дип атыйлар.

Әскәр Шәех-Алинең гарәп графикасы нигезендәге татар язуы өчен машинка уйлап табу хәбәрен Казанда искиткеч яңалык — сенсация дип кабул итәләр. Инженерны, тиешле бөтен шартларны тудырып, яхшы эш хакы вәгъдә итеп, Казанга даими эшкә кодалый башлыйлар. Әскәрнең истәлекләренә караганда, күчәргә карар кылу җиңелдән генә булмый. Мәскәүдә аның яхшы торагы, уңайлы-җайлы тормыш-көнкүреше, алтын кулларын югары бәяләүче клиентлары бар. Аннары кызыктырырлык башка тәкъдимнәр дә булып тора. Әмма үз мөселман халкына булышырга омтылу, төрки халыклар мәдәнияте һәм аның киләчәге алдында үзен бурычлы санау...— бу хис-тойгылар Әскәр Шәех-Али өчен коры сүзләр генә булмый. Гомумән, ул буын зыялыларның яшәү рәвешләрендә, үз-үзләрен тотышларында бурыч һәм намус төшенчәләре зур әһәмияткә ия булып тора. Әскәр Шәех-Али үзенең күченергә риза булуы өчен соңыннан үкенмәдеме икән? Киләчәктә үзен көткән ачы язмышны алдан ук белгән булса, ул бу адымны ясар идеме икән? Без хәзер бу сорауларга тәгәл генә җавап таба алмыйбыз. Ничек кенә булмасын, Әскәр Шәех-Али Казанга — Татарстан башкаласына күченеп килә.




Татар язуы өчен машинкалар эшләп чыгаруның беренче адымнары уңышлы гына башланып китә. Республиканың югары органы булган Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршысында язу машинкалары җитештерә торган мастерской оештырыла. Мастерской өчен бина шәһәрнең үзәгеннән — Чернышевский (хәзерге Ленин) урамыннан бирелә. Уникаль эш җиһазлары — аерым алганда, «Браун» фрезер станогы, кискеч инструментлар, үлчәү приборлары кебек иң кирәкле әйберләрне Әскәр Шәех-Али, төрле предприятие һәм мастерскойлардан җыештырып-табып, Мәскәүдән үк төяп кайта. Үзенә эшкә фикердәшләр туплаганда да ялгышмый ул: беренче булып университеттан М. Николаев, аннары Г. Елизаров, И. Лисенков, Святоносов, Щеглов, Тихонов кебек осталар коллективның үзәгентөшен тәшкил итәләр. Болар үз эшләренең мөнә диган осталары гына түгел, ә эзләнүчән, тынгысыз уйлап табучылар да булалар һәм эш барышында бик күп төрле яңалыклар кертәләр. Бу җәһәттән бигрәк тә Г. Елизаровның тәкъдимнәре бәяләп бетергесез файдалы була. Әлеге мактаулы һәм зур эшнең башында, фикер-идеяләрнең генераторы, сызымнарны тимердә тормышка ашыручы булып, билгеле инде, Әскәр Шәех-Али үзе тора.

Бик кызганыч: күп төрле сәбәпләр, шул исәптән, сәяси сәбәпләр аркасында Әскәр Шәех-Алинең исеме соңыннан онытыла яки сүз уңаеннан гына телгә алынгалый. Ә бит ул Татарстанның талантлы инженерлары арасында беренче урыннарның берсендә торырга лаек шәхес. Һәр яңа эштәге кебек, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы монополистлар Әскәр Шәех-Али алдына да җитди киртәләр коралар. Мәсәлән, Мәскәүдәге кайбер югары урыннарда утыручы түрәләр аерым бер үҗәтлек белән Казанда яңа язу машинкалары җитештерүгә комачаулык ясарга тырышалар. Чөнки алар Ленинград тирәсендәге Лигово шәһәрчегендә урыс хәрефле язу машинкалары җитештерә башлауны планлаштырган булалар. Әле бер машинка ясап карамасалар да, бу эш өчен штатка ике йөзләп конструктор һәм инженер тупланган була инде. Әскәр Шәех-Алигә шулай ук наданлыкка-томаналыкка чумган яки түрәлек тәкәбберлеге белән масаючы Казан бюрократлары да нык кына аяк чалалар. Әмма яңа язу машинкаларын ясау фикере шулкадәр көчле, ә беренче тәҗрибә җимешләре шулкадәр уңышлы килеп чыга ки, Татарстанның сәяси җитәкчеләре, иң беренче чиратта Совнарком Рәисе Х. Габидуллин энтузиастларга эшлекле ярдәм күрсәтә. 1925 елдан башлап гарәп графикасы нигезендәге язу машинкалары эшләп чыгару даими рәвештә арта бара. Башкаладагы һәм Татарстан районнарындагы беренче заказларны үтәгәннән соң, мастерской башка төбәкләрдә яшәүче төрки халыкларның хәреф үзенчәлекләрен дә искә алып эшләнгән язу машинкалары җитештерә башлый. Аерым алганда, андый үтенечләр Урта Азия һәм Төньяк Кавказ республикаларыннан килеп кенә тора. Казанда эшләнә торган язу машинкаларына Кытайдан, Әфганстаннан, Ираннан алынган үтенечләр дә куандыра. 1928 елны татар хәрефләренә көйләү өчен Татарстан хөкүмәте карары белән кырык «Ундервуд» машинкасы сатып алына. Әмма Әскәр Шәех-Али моның белән генә канәгатьләнми, машинкаларны тулысынча Казанда эшләнгән детальләрдән җыю процессын җайга салу өчен тырыша. Һәм бу эш эшләнә дә. Монысы инде бигрәк тә зур казаныш була. Шулай итеп, мастерской чит илләрдән машинкалар кайтарту өчен валюта исраф итүдән котыла. Заказлар арасында Һиндстан, Ливан, Төньяк Африканың мөселман илләреннән — кыскасы, гарәп графикасы кулланыла торган барлык төбәкләрдән диярлек килгән үтенечләр ишәйгәннән ишәя. Монысы инде халыкара танылу дигән сүз була. Ул заманнарда Советлар иле предприятиеләренең бик сирәгенә генә тәти торган күренеш бу. Чит илләргә бездән гадәттә чимал яки ярымфабрикатлар гына чыгарылып килгән бер вакытта Татарстан республикасы әнә шундый төгәл механизмлы, сыйфатлы язу машинкалары чыгаруы белән дан тота. Хәзер республикабызда җитештерелеп, дөньяның барлык кыйтгаларына җибәрелә торган машиналар, приборлар, аппаратлар белән

беркемне дә шаккаттыра алмыйсың, әлбәттә. Әмма 1927 елда мондый хәл сирәк очрый торган гаҗәеп бер күренеш булып кабул ителә. Советлар иле өчен чит илләр белән ярышырлык беренче төгәл механизм Әскәр Шәех-Алинең Казанда җитештерелә торган язу машинкасы булгандыр дип исәпләргә тулы нигез бар.

Ул арада тоталитар режимлы большевиклар илендә вакыйгалар куерганнан куера бара. Алда күрербез: бу хәл-вакыйгалар Әскәр Шәех-Али кебек миллионлаган кешеләрнең язмышларын кискен үзгәртәчәк әле.

Егерменче еллар ахырына таба ил җитәкчеләре арасындагы сәяси көрәшнең гадәти ысуллары үзгәрә башлый. Әлегә кадәр, башкача фикер йөртүчеләрне бик кискен тәнкыйтьләгәндә дә, аларны юк итү юлына басмыйлар иде. Юлбашчыларыбыз, төгәлрәк әйткәндә, Сталин һәм аның фикердәшләре үзләренең кичәге иптәшләрен, ә бүгенге «дошманнарын» тар-мар итәргә тотыналар. Әле «сул» оппозиция кырыла, әле «уңы». Компартиянең революциядән соңгы тарихында беренче буларак, партия Үзәк Комитеты әгъзаларын, хәтта Политбюро әгъзаларын да аяп тормыйча, «себереп түгә» башлыйлар. Сталинның беренче корбаннары — Троцкий, Зиновьев, Каменев, Бухарин, Рыков, Томский... Саный китсәң, алар йөзләр, меңнәр... Ә инде каһәрләнгән утыз җиденче елларда — миллионнар...

Ил өстенә ингән бу афәт милли төбәкләрне дә читләтеп узмый, әлбәттә. Милли республикаларның, бигрәк тә «икенче сортлы» автономияле республикаларның болай да юк дәрәҗәсендәге хокуклары бөтенләй кысылып бетә. Кем әйтмешли, Мәскәү рөхсәтеннән башка кечкенә йомышыңны да үти алмыйсың. Ә инде «милләтче» ярлыгы тагыла-нитә калса, бөтенләй эш харап...

Милли сәясәтнең иң кайнар нокталарыннан берсе мөселманнар яшәгән төбәкләрдә гарәп графикасының язмышы турындагы кискен бәхәсләр була. Бу бәхәс, бер көчәеп-бер тынып дигәндәй, егерменче еллар башыннан бирле дәвам итеп килсә дә, 1927 елга кадәр ВКП(б) Үзәк Комитеты да, урыннардагы партия комитетлары да «яңалиф»не, ягъни төрки халыкларның язуын латин графикасына күчерүне артык ашыктырмыйлар. Бу мәсьәләгә шактый тыныч карыйлар. 1926 елның язында төрки телле галимнәрнең Бакуда үткәрелгән беренче корылтае «яңалиф»кә әкренләп күчүне хуплап карар чыгара, әмма катгый күрсәтмәләр бирүдән тыелып кала. Алай гына да түгел, республикаларның бер өлеше бу чорда әлеге эшне ашыктыруны максат итеп тә куймый, күрәсең. Корылтайга килгән татар делегациясе җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов, мәсәлән, Татарстан республикасының «яңалиф»кә күчүе мәсьәләсе буенча үз өстенә бернинди йөкләмәләр дә алмаска тиешлеге турында партия өлкә комитетының яшерен күрсәтмәсе белән килгән була.

Әмма тиздән хәл кискен үзгәрә. 1927 елның февраль-март айларында «яңалиф»не «төрки халыклар мәдәниятын үстерүдәге иң төп юнәлешләрнең берсе» дип игълан иткән, ә гарәп графикасын «социализмга бару юлындагы реакцион киртә» дип тамгалаган берничә карар кабул ителә. Бу карарлар иң югарыда — Мәскәү Кремлендә «пешереп чыгарылалар». Карарларда, иске алфавит халык арасында дини карашларны саклап калуга хезмәт итә, дип ассызыклап әйтелгән була. «Гарәпчәлек»не эзәрлекләүнең төп сәбәбе шул булгандыр да, бәлки. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты үз карарында, «яңалиф»не гамәлгә кертү — коммунистларның бурычы, аңа каршы чыгу — партиягә каршы эш, дип билгеләп үтә. Тоталитар режим шартларында партиядән чыгарылу — җәмгыятьтән сөрелү, акыл хезмәте белән бәйле һөнәрләрдән читләштерү-тыю икәнен аңлатып торуның кирәге юктыр. Партиядән чыгарылган кеше тормышның иң төпкеленә ыргытыла, аңа партиясезләргә караганда да начаррак мөнәсәбәт була, ул ышанычсыз, аңардан дус-ишләре дә читләшеп бетә... Мөгаен, шуңа күрәдер, әле кичә генә «яңалиф»кә каршы булган бик күп зыялылар бүген инде аерым бер «энтузиазм» белән аны яклап чыгалар.

Әмма... шул вакытта Татарстанда тиңсез бер документ пәйда була. Сталин исеменә, ВКП(б) Үзәк Комитеты инструкторы Пшеничниковка (ул — Татарстан республикасы өстеннән күзәтүче-куратор) һәм Татарстан өлкә комитетының III пленумына юлланган хат була бу. Аңа җәмгысе 82 кеше кул куйган. Алар арасына укытучылар, язучылар, галимнәр, врачлар, агрономнар, рәссамнар, инженерлар, студентлар — кыскасы, татар зыялыларының каймагы була. Болар барысы да партиясезләр. Без бу хатның текстын игълан итеп, аңа кадәр булган кайбер хәл-вакыйгалар турында да язып чыккан идек инде[1]. Хат авторларының

---

[1] «Яшерен архив битләре» дигән китаптан (Казан, 1994) «Татар зыялыларының Сталинга хаты» дигән очеркны карагыз.

*Автор искәрмәсе.*

«яңалиф»не гамәлгә кертүгә каршы килмәүләре, бары тик гарәп графикасын юкка чыгаруда «удар темплар» кирәклегенә шикләнеп караулары, моның татар халкын борынгы мәдәни байлыкларыннан аеруга китерәчәге хакында язганнарын гына искәртеп үтәбез.

Ошбу хатны Сталин үзе укыгандырмы-юкмы, анысы безгә мәгълүм түгел. Партиянең Татарстан өлкә комитеты исә эшне кызу тотып, катгый карар кабул итә. Карарда «моның ише үтенеч белән мөрәҗәгать итү милли-буржуаз элементларның ВКП(б)га каршы юнәлдерелгән (*ассызыклау минеке.*— **Б. С.**) активлыклары үсүне күрсәтүче факт булып тора. Өлкә комитеты бюросына бу үтенеч белән мөрәҗәгать итү фактыннан тиешле нәтиҗәләр ясарга һәм кирәкле иҗтимагый-оештыру, аңлату чаралары үткәрүне йөкләргә» диелгән. Өлкә комитетының әлеге хат авторларына карата «игътибарны» көчәйтү кирәклеге турындагы яшерен күрсәтмәсе ОГПУның җирле бүлекчәсенә дә ирештерелә, билгеле. Хәер, бу хакта искәртеп торуның хаҗәте дә булмый — татар зыялыларының һәр адымы тиешле органнарның игътибар үзәгендә артыгы белән була бит...

Шундый күзәтү астында торучыларның берсе әлеге үтенеч хатына җитмеш сигезенче кеше булып кул куйган: «Шаех-Али А.— зав. маст. по пр-ву тат. пиш. маш.», ягъни татарча язу машинкалары җитештерү мастерское мөдире Әскәр Шәех-Али була.

Хатның төп авторлары кем булганлыгы хакында төрле фараз кылулар бар: Галимҗан Ибраһимов белән Мирсәет Солтангалиевтер дип тә шикләнәләр, башка күренекле кешеләрдер дип тә юрыйлар.

Гомеренең соңгы елларында миңа Бакый ага Урманче белән еш кына очрашып торырга туры килде. Безнең күренекле рәссамыбыз үзе ул хатка илле бишенче кеше булып, «ирекле рәссам Б. Урманче» дип имза салган булган. Сиксәненче елларда бирелгән рәсми белешмә кәгазендә «сиксән ике кеше хаты»ның ВКП(б)га каршы юнәлдерелмәгәнлеге икърар ителә. Бакый ага Урманче хатка кул куючылардан, нахакка гаепләнеп, инде хәзер, санлап булса да, үзенең аклануын исән чагында ишеткән бердәнбер кеше булгандыр, мөгаен. Аның фикеренчә, хатны язучылар Г. Шәрәф белән Х. Исхаков булырга тиешләр. Соңгысы — танылган язучы Гаяз Исхакыйның бертуганы, журналист.

«Тиешле иҗтимагый-оештыру һәм аңлату чаралары» үткәргәннән соң (ул чараларның ничек үткәрелгәнен, буйсынмаганнарга нәрсә янаганын укучы аңлыйдыр, шәт), хатка кул куючыларның барысы да диярлек, телдән һәм язма рәвештә, кылган эшләреннән тәүбә итәләр. Аларның «тәүбәләре» рәсми матбугатта басылып та чыга. Әмма барысының да исем-фамилияләре тиешле оешмаларның «хәтер сандыгына» салынып куела һәм, озак та үтми, күпләп кулга алулар вакытында байтагының гаепләрен тирәнәйтүче дәлил булып санала.

Үзәктәге хакимият тарафыннан хупланган һәм юмарт ярдәм алган «яңалиф» язуы 1928—1929 елларда төрки республикаларда җиңү яулый. «Яңалиф»не гамәлгә кертү өчен оештырылган Баш комитет зур тантаналы шартларда Казанда күчмә утырыш үткәрә. Бу утырышка «Советларның баш латинчысы», Әзәрбайҗан Үзәк Башкарма Комитеты Рәисе Агамалы-Оглы үзе килә. Ул, тантана итеп, «гарәпчелекнең Порт-Артуры булган Казан җиңелде» дип ярып сала. «Баш латинчы» белми әле: тагын бер ун-унике елдан соң «латинчылыкның Порт-Артуры булган Баку да егылачак», төрки республикаларга да урыс графикасы — кириллица үтеп керәчәк...

Латинчалаштыруның гөрләп үсә баруы язу машинкаларын тулысынча яңартуны, латин хәрефле машинкаларны күпләп җитештерүне таләп итә. Әскәр Шәех-Али җитәкчелегендәге кечкенә мастерской «Яңалиф» язу машинкалары җитештерә торган, заманча җиһазландырылган завод итеп үзгәртеп корыла. Ул илдәге барлык төрки телле республикалар һәм шулай ук «латинлаштыру» үткәргән Төркия өчен «Яңалиф» машинкалары эшләп чыгаручы бердәнбер завод була. Үзәкнең тәкъдиме белән заводка Агамалы-Оглы исеме бирелә. Хисаплау һәм бастырып кубәйтә торган техниканы күрсәтә торган иң абруйлы күргәзмәләрдә күпсанлы дипломнар һәм бүләкләр алып килгән «Яңалиф» машинкасының фирма маркасында Агамалы-Оглы исеме кабатланып тора. Исеме аерып аталмаса да, бу машинканы иҗат итүче Әскәр Шәех-Алигә дә мактау сүзләрен кызганмыйлар. Аның талантына баш июченәрнең берсе аны «Кулибин акылы белән Левшаның алтын кулларын берләштергән оста» дип бәяли. Мәгълүм булганча, Кулибин — Рәсәйнең танылган уйлап табучысы, ә Левша исә —

борчаны дагалаучы мифик оста. Мондый бәяләмәләрнең никадәр нигезле булуы хакында бәхәсләшеп тормастан, төгәл техника белән шөгыльләнүче инженерлар арасында Әскәр Шәех-Алинең исеме чынлап та зур хөрт казанганын әйтеп китәргә кирәк.

Әмма ләкин, Әскәр Шәех-Али яңа хыяллар, яңа фикер-идеяләр белән янып яшәгән, янып эшләп йөргән бер мәлдә... 1931 елның 6 маенда аны Татарстан ОГПУы кулга ала. Тентү вакытында аның барлык техник документ кәгазьләрен, проектларын, сызымнарын җыеп алып китәләр.

Илдә тоталитар режимга каршы мөмкин булган «дошманнарны» юк итү буенча чираттагы котырыну башлана. Бу «дошманнар» арасында, билгеле инде, татар зыялыларының күренекле вәкилләре дә була. Казан төрмәсендә бер ел тоткынлыкта яткырганнан соң, Әскәр Шәех-Алигә ОГПУ коллегиясенең карарын игълан итәләр. Үзе белән бер вакытларда кулга алынган башка тоткыннар белән бергә аларны каһәрле-куркыныч 58 нче статья буенча төрле срокларга ябылуга хөкем итәләр. Йөз меңнәрчә кешеләрнең гомерен өзгән, тормышын җимереп ташлаган статья була ул 58 нче статья...

Илдә төзелеш арты гигант төзелешләр күтәрелә, аларны торгызу өчен ни җитәрлек чыганак-байлык, ни квалификацияле белгеч-кадрлар булмый — ил ыңгыраша-көчәнә... Кадрлар мәсьәләсен хәл итүнең төп чарасы булып күпләп кулга алулар кала. ОГПУ промышленность өлкәсендә иң эре оешмаларның,— әгәр дә эреләрдән дә эресе булмаса әле! — берсенә әверелә. Бихисап күп Сталин лагерьларындагы тоткыннар күмер һәм алтын чыгаралар, чит илгә чималл итеп озату өчен урман кисәләр, завод-фабриклар төзиләр, шәһәрләр коралар. Аерым игътибарга лаеклы, һәртөрле делегацияләр килеп-китеп торган, шагыйрьләр-язучылар дан җырлаган, беренче бишьеллыкның «визит карточкасы» хезмәтен үтәгән төзелешләр дә булган. Шундыйларның иң күренеклесе-атаклысы ОГПУ шефы Г. Ягоданың яраткан «җимеше» — Беломорканал төзелеше була. Анда, «чыбыркы һәм прәннек» сәясәтен чиратлаштырып, тоткыннар хезмәтеннән мөмкин кадәр тулырак файдалану ысулларын өйрәнәләр, киң күләмле тәҗрибәләр үткәрәләр. Тоткыннарның хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүгә булган теләк-омтылышларын көчәйтү өчен төрле үсендерү чаралары һәм җиңеллекләр кулланыла. Болар барысы бергә «перековка», ягъни чүкеп яки дагалап яңадан тәрбияләү дип атала. Безнеңчә, «дагалап» дигәне дөресрәк булыр... Бу чорда әле соңыннан Әскәр Шәех-Али гаҗәпләнеп искә төшергән хәл-вакыйгаларга да мөмкинлек табыла. Татарстаннан 600 тоткынны төяп килгән эшелон, үтә дә авыр бер атналык юл үтеп, ниһаять, Беломорканалга килеп җитә... Юлда сакчыларның акыру-бакыруына, суккалау-типкәләвенә күнегеп беткән тоткыннар да, сакчылар да каршы алучыларның мөгамәләсенә гаҗәпләнеп карыйлар. Сакчылар тоткыннарны исемлек буенча тапшырып бетергәннән соң, яңа начальниклар, бередә «зек» сүзе («заключенный» сүзеннән кыскартылып ясалган жаргон) юк, бары тик «каналоармеец»лар гына бар, дип игълан итәләр. Сак та булмаячак, тоткыннар,— әй лә, каналоармеецлар! — үз көн тәртипләрен үзләре җайга салырга тиешләр икән. Төрмә режимы һәм чәнечкеле тимерчыбыклы зона бары тик эшкә чыгудан баш тартучы уголовниклар өчен генә икән. Яхшы эшләүчеләрнең хезмәте аерым исәпкә алып барыла һәм шуның нигезендә аларның тоткынлык сроклары кыскартылачак икән... Ул вакытта әле, әлбәттә, каналны төзеп бетергәннән соң, аны Сталин һәм башка юлбашчылар килеп карап киткәч, күп кенә «корткычлар» һәм «контриклар»ның орденнар белән бүләкләнәчәген, кайбер алдан күрүчәнрәк зирәкләрнең исә, иреккә чыгу хокукыннан баш тартып, төзелешкә ирекле ялланып эшләүчеләр сыйфатында калачагын беркем дә әйтеп бирә алмас иде. Бу хәлләр 1937—1938 елгы иксез-чиксез законсызлыклар котырынган чагында әлеге тоткыннарның кайберләренә гомерләрен саклап калырга да ярдәм итә.

Әүвәлге патша офицеры, аннары кызыл командир, ә хәзер «каналоармеец»ка әверелгән инженер Әскәр Шәех-Алинең ирекгәге эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар белән танышканнан соң, аны Беломорканалның «башкаласы» саналган Медвежьегорск шәһәрчегенә җибәрәләр. Анда бөек төзелешнең төп инженер көчләре тупланган була. Әскәрне күбесенчә кыяташлардан, гранит тау токымнарыннан торган иң авыр Икенче Водораздел дигән районга эшкә билгелиләр. Эш өч сменалы булып, төнлә прожекторлар яктысында алып барыла. Гранит токымнарны ватып, каналның төбен түшәү эшен тәэмин итүне Гидротехник лаборатория инженерларына тапшыралар. Шушы лабораториядә Әскәр Шәех-Али дә эшли башлый. Канал төзелеше, тәртипсезлек һәм хезмәткә төкереп карау белән беррәттән, иҗади-илһамлы фикерләрнең тормышка ашуы, үзләре тудырган кыенлыкларны үзләре үк батырларча җиңеп чыгу чиратлашып килгән гадәти совет төзелешләренең берсе була.

Иҗади фикерлә ия булган кешегә бу төзелеш инженерлык сәләтен күрсәтү өчен менә дигән эш мәйданы да була. Ачышлар дәрәҗәсендәге дистәләрчә рационализаторлык тәкъдимнәре керткән Әскәр Шәех-Али тиз арада каналның инженерлары арасында шактый танылып өлгерә. Ул, электротехника буенча белгеч булмаса да, җирле электр станциясенең, механизмнарны эштән туктатып, шәһәрне караңгыга күмеп, куәтен яртылаш диярлек киметеп, вакыт-вакыт «кәҗәләнүенең» серенә тиз төшенеп тә үзен таныта. Гадәттә бу «кәҗәләнү» лабораториядәге кайбер агрегатларны эшләтеп җибәргәч күзәтелә, юкса ул агрегатларның техник күрсәткечләренә караганда алар шулкадәр зур көчәнеш алырга да тиеш түгел икән. Сернең чишелеше бик гади булып чыга: монтаж эшләре башкарганда берничә турбинаның тоташтыру схемаларын буташтырганнар икән. Мондый эш иректә эшләнгән булса, корткычлык дип тамгаланып, күпләрнең башы китәр иде. Биредә исә, мондый җитешсезлекләрнең сәбәпләрен яхшы беләләр, шуңа күрә гаепләләргә артык каты җәза бирелми, аларның ваемсызлыклары өчен азык паекларын киметү белән генә чикләнеп калалар. Хәер, күп кенә авария-һәлакәтләрнең төп сәбәбе эш нормасын арттырып үтәү турында тизрәк рапорт бирергә ашыгудан килеп чыкканлыгын төзелеш башлыклары да белеп-күреп тора. Канал төзелешендәге тәртипләрнең эпиграфы буларак: «Без туфты и аммонала не построишь тут канала» дигән әйтемнең нәкъ менә биредә тууы да очраклы түгелдер. «Туфта» — тоткыннар жаргонында ялган, алдау, ә инде аммоналның шартлаткыч икәнен укучы, шөт, беләдер. Кызганычка каршы, бу әйтем безнең икътисадыбызның аерылгысыз юлдашы булып озак еллар ияреп йөрде.

Яхшы эшне исәпкә алу системасы һәм шәһәрнең энергетик куәтен коткарып калучы даны Әскәр Шәех-Алигә булыша. Аны 1934 елның җәендә срогыннан элек азат итәләр. Калган утыз дүрт ел гомерендә аңа әле тагын бик күп нәрсәләр күрергә язган була. Яраткан эшенә кайтып эшләү тыела. Казанга кайтып яшәү тыела. Шулай итеп, Әскәр Шәех-Алинең иҗат казанышы — инде ул вакытта яңа бинага күчкән язу машиналары заводы остазсыз, ятим кала.

Сугыш алды елларын, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларны Әскәр Шәех-Али Мәскәү тирәләрендә һәм Алатырь шәһәрендә үткәрә. Яңадан кулга алулар булмаса да, гомере буена аны кырын карашлар эзәрлекләп килә, паспортисткалар һәм участок милиционерлары да аңа карата артык «игътибарлы» кыланалар. Рәхимсез тормыш чынбарлыгы әнә шундый була. Илле сигезенче статья, ирекkә чыксаң да, гомерлек кара тамга икән ул. Бөек Ватан сугышы җиңү белән тәмамлангач, бераз йомшару булмасмы дип көтәләр. Әмма Әскәр Шәех-Алинең «Пишмаш» заводына гади инженер сыйфатында гына булса да эшкә кайтырга омтылышы, әлеге дә баягы, Казанда яшәү тыелган булу сәбәпле, тормышка ашмый кала. Юкса аны заводта яхшы хәтерлиләр, кайтырына өметләнеп көтәләр. Пенсиягә чыкканчы ул Лопатин (хәзерге Волжск шәһәре) поселогындагы бер заводның конструкторлык бюросында эшли. Әскәр Шәех-Али биредә үзе өчен яңа бер өлкәне — агач эшкәртүне механизацияләү эшен үзләштерә. Бу эштә дә аның уйлап табучылык сәләте сизелерлек эз калдыра.

Әскәр Шәех-Али гомере буена бәхетсез булгандыр, диюдән битәр, шулай да мин аны бәхетле дә булгандыр, дип әйтер идем. Кырыс чоры тарафыннан куелган нинди генә авыр сынауларга да карамастан, ул татар халкы мәдәни тормышына сизелерлек өлеш керткән зыялыларның берсе. Аның бәхете башка шартларда, башка тармакларда эшләп үзләрен таныткан кызлары: сугыш елларында ук врач булган менә дигән табип-галим Динара белән инженер-химик Гөлнар тормышында дәвам итәдер, мөгаен. Һәм, ниһаять, әле язмышларын ерак 1910 елда ук бергә бәйләгән хатыны Суфия ханымның гомер буена үзенә турылыклы тормыш юлдашы булып калуы белән дә бәхетле булгандыр ул. Ә кешегә күп кирәкме? Тормышта якты эз калдырып, янып яшәсә, үзенең лаеклы дәвамын балаларында күрсә, исән чакта үзен белгәннәрдән яхшы сүзләр генә ишетсә, фани дөньядан киткәч тә аны яд итүчеләр булып торса — шул җитмиме?

Әйе, нәрсә генә димик, Әскәр Шәех-Али егерменче гасыр мәдәни тарихыбызда күренекле шәхесләрнең берсе булып калыр.

**Булат СОЛТАНБӘКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

**Яхья Абдуллин,**
философия фәннәре докторы

# САДРИ МАКСУДИ — ОЛУГЪ ГАЛИМ



*Олугъ галим Садри Максуди.*

Садри Максуди (1879—1957) — күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, сәясәтчесе, татар милли-азатлык хәрәкәтенең танылган вәкиле һәм аны рухландыручыларның берсе, зур галим, фикер иясе. Бу олы шәхес Казан артындагы Ташсу авылында (хәзерге Биектау районы) Нәҗметдин мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне әтисеннән ала. Аннан Казанга килеп Галләмия мәдрәсәсендә, ә 1897—1901 елларда Казан укытучылар мәктәбендә укый. 1902—06 елларда Парижда, дөньякүләм танылган университетларның берсе — Сорбоннада укый, анда хокук һәм тел гыйлемнәрен өйрәнә.

Яшь белгеч 1906 елны ватанына әйләнеп кайта һәм актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә тартыла, милли хәрәкәтнең күренекле вәкиленә әйләнә, ике мәртәбә Дәүләт Думасына сайлана, депутатлык мандатын төрки халыкларның хокукларын яклауга һәм патша самодержавиесенең колониаль сәясәте асылын ачып салуга файдалана. Февраль революциясеннән соң төрки халыкларның, шул хисаптан үзенең туган халкының азатлыгы өчен көрәш мәйданына ташлана, давыллы 1917 елда узган мөселман корылтайларының эшендә һәм алар кабул иткән документларны хәзерләүдә актив катнаша, 1917 елның азагында җыйналган Милли мәҗлестә милли идарә рәисе итеп сайлана.

1918 елны большевистик хакимият тарафыннан татар милли хәрәкәте бастырылгач, ул чит илгә китәргә мәҗбүр була. Башта Франциядә һәм Германиядә яши, Сорбоннада профессор дәрәҗәсе ала, төрки тарих буенча лекцияләр укый башлый. Төрек революциясеннән соң С. Максуди Төркиягә чакырыла һәм аның 30 елдан артык гомере икенче ватанына әйләнгән шушы илдә уза. Бирегә эшләү елларында ул яңа үсеш юлына баскан Төрек республикасында фәнни эзләнүләрне юлга салу буенча зур эш башкара. Төркиядә хәзер дә эшләп килүче фән учреждениеләренең күбесе С. Максуди катнашында оешкан.

Төркиягә килеп урнашкан С. Максуди төрек революциясе җитәкчесе Кемал Ататөрек белән якынлаша, аның киңәшчеләренең берсенә әйләнеп, ике мәртәбә Төркия парламенты (мәҗлесе) депутаты итеп сайлана. Төркия делегациясе әгъзасы буларак милләтләр лигасы эшендә катнаша. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Аурупа Советы төзелгәч С. Максудига бу совет эшендә дә катнашу насыйп була. 18 ел буена ул Анкара университетының юридик факультеты профессоры вазыйфаларын башкара, ә 1943 елда Истанбул университетына чакырыла һәм шунда фәнни-педагогик эшчәнлеген дәвам иттерә.

Садри Максуди — киң диапазонлы галим, аның хезмәтләрендә фәннең төрле тармаклары үзләренең чагылышын таба. Бездә булган мәгълүматларга караганда аның 17 китабы, ә фәнни җыентыкларда һәм журналларда фәннең төрле тармакларына кагылышлы күпсанлы мәкаләләре дөнья күрә. Беренче чиратта С. Максуди безнең күз алдыбызга хокук фәннәре өлкәсендә зур белгеч булып килеп баса. Моны ул 1917 елны проектын үзе хәзерләгән Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мөхтәриаты турындагы низамнамәдә үк ачык күрсәтә. Бу низамнамәдә Рәсәй төркиләренең хокуклары һәм таләпләре һәр яклап, халыкара хокук кануннарына туры китереп нигезләнә. Парижда барган тынычлык конференциясенә кертелгән Рәсәй төрек-татарларының хокукый хәлен аңлаткан меморандумны хәзерләгәндә дә ул үзенең халыкара хокук нигезләре буенча зур белгеч булуын ачык күрсәтә.

Һәм, ниһаять, аның фәнни хезмәтләре: С. Максуди кулы белән язылган китапларның яртысыннан артыгы һәм фәнни мәкаләләрнең күбесе хокук гыйлеменә карыйлар. Бу хезмәтләрдә беренче чиратта хокук фәненең теоретик нигезләре һәм хокук тарихы мәсьәләләре яктыртыла. Мәсәлән аның «Хокук тарихы дәресләре» (1927), «Хокукның гомуми әсаслары» (1937), «Гомуми хокук тарихы» (1941), «Хокук фәлсәфәсе» (1946), «Теократик дәүләт вә секулярләшкән дәүләт» (1940) исемнәре белән дөнья күргән күләмле монографияләре шундыйлардан.

С. Максудиның бу өлкәдәге фәнни тикшеренүләренең бер әһәмиятле ягы — ул төрки хокукны, аның чыганакларын, үсешен һәм төрки халыкларының яшәешендәге ролен өйрәнү һәм яктырту. 1925 елда ул Төркиядә ачылган хокук мәктәбендә әле моңа кадәр фән буларак һичкайда өйрәнелмәгән төрек хокукы тарихын укыта башлый. 1928 елда аның «Төрек хокукы тарихы», 1947 елда «Төрек тарихы вә хокук» дигән монографияләре дөнья күрә.

Безнең Татарстан җөмһүрияте хәзер дәүләт буларак үзенең мөстәкыйльлеген игълан итте. Мөстәкыйльлекне реаль чынбарлыкка әйләндерү өчен безгә милли яшәешебезнең хокукый нигезләрен һәрьяклап эшкәртергә, законлаштырырга кирәк. Бу, һичшиксез, ныклы фәнни эзләнүләр таләп итә. Бу эзләнүләрдә С. Максудиның хокук фәненә кагылышлы хезмәтләре, беренче чиратта төрки хокук тарихына кагылышлы хезмәтләре мөһим роль уйный алалар. Бу хезмәтләрне безгә хәзерге татар теленә тәрҗемә итеп бастыру турында уйланырга вакыт. Ә хокук фәне өлкәсендә эшләүче галимнәребез, әгәр бу хезмәтләргә кичекмичә игътибар итсәләр, халкыбыз өчен байтак файдалы хокукый тәкъдимнәр кертә алырлар иде.

С. Максуди үзен галим буларак таныткан фәннең икенчесе — тел гыйлеме. Ул 1914 елны үзенең әдәби әсәре «Мәгыйшәт»нең икенче басмасына язылган кереш сүзендә ук милләтнең яшәешендә һәм тәрәккыятендә телнең нинди зур роль уйнавын ачык аңлап фикер йөртүче икәнлеген күрсәтә алды. Соңыннан, Төркиягә барып урнашкач, ул яшь республикада телне, аның үсеш законнарын өйрәнү, төрек телен гадиләштерү һәм гамәлгә кую буенча зур эш башкарды. 1930 елда ул «Төрек теле өчен» исемле китабын бастырып чыгара. 1928 елда «Миллият» газетасы битләрендә аның «Лисан ислахы мәсьәләләре» дигән мәкаләләр тупланмасы дөнья күрә. Ә 1948 елда «Җөмһүрият» газетасында «Тел ислахы вә тел җәмгыяте» исеме белән зур күләмле хезмәте басыла. Бу хезмәтләр Төркиядә тел гыйлеме үсешендә һәм телне халыкчанлаштыруда әһәмиятле роль уйныйлар.

С. Максудиның үзеннән өлеш керткән өченче фәнни юнәлеш — тарих. Париждан Анкарага килгәндә үк ул төркиләрнең тарихи үткәнен өйрәнүне юлга салу һәм тарихны пропагандалау бурычы куя. Шушы максатта ул Тарих академиясен төзү идеясен туктаусыз күтәреп тора. Төркиядә хәзер дә яши торган «Тарих җәмгыяте» — С. Максудиның шушы тырышлыгы нәтиҗәсе. Максуди үзе дә тарих буенча фәндә яңа сүз булып яңгыраган хезмәтләр бастырып чыгара. Аның тарихка кагылышлы хезмәтләре арасында беренче чиратта «Төрек тарихының чыганаклары» тупланмасында чыккан «Искетлар-сакалар» (1933), «Урта Азия төрек дәүләтләре» (1934), һәм инде телгә алынган «Төрек тарихы вә хокук» (1947) исемле китаплары игътибарга лаек. Ул шулай ук фәнни җыентыкларда һәм журналларда уйгурлар, тогуз угызлар тарихына һәм Орхон язмаларын анализлауга кагылышлы тирән эчтәлекле мәкаләләр дә бастыра. Төркиядә тарих фәненең формалашуы һәм үсешендә шулай ук аның тарих фәненең теоретик нигезләрен яктырткан мәкаләләре дә үзләренең рольләрен уйнадылар.

Һәм [illegible] Садри Максуди тирән фикер йөртүче фәйләсүф-мөтәфәккир дә (философ-мыслитель) иде. Фәлсәфи фикерләүче буларак, С. Максудиның игътибарын үзәгендә кеше һәм кешелек җәмгыяте яшәешенең нигезлә һәм аларның үсеш тенденцияләре мәсьәләсе тора. Аерым алганда аның рухи һәм мәгънәви хәятының үсеш законнарын, инсаннарның куйган максат вә идеалларның җәмгыять үсешендәге ролен, Аурупа мәдәниятының киләчәген яктырткан хезмәтләре бар. С. Максуди яшәгән чор зур катаклизмнар, каршылыклы тенденцияләрнең аяусыз көрәше чоры. Шулай да ул кешелек җәмгыятенең, аның мәдәниятының үсешенә ышаныч белән карый. Бу ышаныч, С. Максудига хас оптимизм рухы, аның «Аурупа мәдәниятының киләчәге» һәм «Мәдәният җимешләре һәм культура байлыклары юкка чыкмас» дигән хезмәтләрендә үзенең ачык чагылышын тапты.

Мөтәфәккир буларак С. Максуди мирасын үзәк урынны ул яшәгән заман проблемалары алып тора. Ә бу заман үзенең килешмәс каршылыклары белән характерлана. Бер яктан демократик үсеш тенденцияләре яңа үрләр яулый, ә икенче яктан тоталитаризм тенденцияләре тамыр җыя, аерым илләрдә (Россия, Германия) тиран режимнар урнаша. С. Максуди үзенең хезмәтләрендә шушы каршылыклар белән тулган замана куйган проблемаларга җавап эзли, шул хакта фикер йөртә, аларны чишү юлларын табарга тырыша. Аны борчыган мәсьәләләрнең иң мөһиме — демократик үсеш проблемалары. Шуңа бәйле рәвештә ул үзенең хезмәтләрендә демократиянең гыйльми, рухи, хокукый әсаслары, демократиянең хөрриятә, гражданлык хокукларына, шәхси тигезлеккә һәм сәяси фиркаләр эшчәнлегенә мөнәсәбәте мәсьәләләрен яктырта.

С. Максудиның шулай ук фән һәм фәлсәфәнең үзара мөнәсәбәте дә кызыксындыра. Аның «Позитив гыйлемнәр һәм фәлсәфә», «Гыйлем вә хөррият», «Американың берләшкән милләтләрендә фәлсәфи агымнар» дигән хезмәтләре шушы кызыксынуның җимеше булдылар. Мөтәфәккирнең игътибарыннан шулай ук фәлсәфә тарихы, беренче чиратта, төрки фәлсәфә тарихы мәсьәләләре дә читтә калмадылар. Аның «Фарабиның хокук фәлсәфәсе» исемле китабы һәм «Атом фәлсәфәсе тарихы» дигән хезмәте моның ачык дәлиле.

Һәм, ниһаять, аның фәлсәфи уйлануларында үзәк проблемаларның берсе — милләт һәм аның яшәеше мәсьәләләре. «Бөек милли әмәлләр», «Милли идеология һәм чит идеологияләр», «Милләтләрнең хаятында фикер вә идеалларның роле» кебек хезмәтләрендә ул бу проблемага карата тирән уйлап фикер йөртә һәм милләтләрнең яшәеше өчен мөһим булган принципларны һәрьяклап дәлилли. Бу мөһим мәсьәләгә кагылышлы фикерләүләрнең квинтэссенциясен С. Максуди үзенең соңгы монографик хезмәте — «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән китабында бәян итте. Бу фәлсәфи характердагы хезмәт беренче мәртәбә 1955 елда Истанбулда басылып чыга. Ул дөньякүләм танылган зур галимнәрнең хезмәтләренә һәм социологик тикшеренүләргә таянып язылган. Куелган мәсьәләләрне һәрьяклап карау-тикшерү белән бергә, автор тикшерелә торган проблемага кагылышлы төрле теорияләргә, шул хисаптан метафизик, космополитик, марксистик теорияләргә фәлсәфи анализ ясый, ырку (расачылык) теориясенең биологик, социологик һәм психологик теорияләрнең асылын ачып сала. Китап «ырк (раса) мәсьәләсе», «милләт вә миллият», «Миллият мәсьәләсендә фикери агымнар», «Тарихта миллият тойгысы» һәм «Заманыбызда миллиятчелек» дигән бүлекләрдән тора. Аларда милләт вә миллият мәсьәләләренә кагылышлы бәхәсле проблемалар тикшерелә, каралган мәсьәләләр буенча тирән фәлсәфи һәм социологик анализ бирелә. Әсәр боларның һәркайсының һәрьяклы теоретик дәлилләнгән чишелеше белән характерлы.

С. Максудиның әйтелгән хезмәтендә каралган мөһим мәсьәләләр арасында милләт һәм аның асылына, миллият тойгысына һәм милләтчелеккә кагылышлы фикерләре аерым игътибарга лаек. Шуңа күрә бу мәкаләдә әлеге мәсьәләләр тирәсендә тәфсиллерәк итеп сүз йөртү мәгъкүл күрелде.

**Милләт һәм аның асылы.** Милләтне һәм милли мөнәсәбәтләрне аңлауда безгә берничә дистә еллар буена Сталинның милләтләрне юкка чыгаруга юнәлдерелгән өйрәнмәләре тагылып килгенде. Сталин үлгәннән соң милләткә карата ул биргән төшенчәне атлап үтәргә омтылышлар ясалды, милләт проблемасына төрле яктан килергә тырышулар да күзәтелде. Әмма бу төшенчә марксизмның асылыннан чыга иде, шуңа күрә дә әйтелгән тырышулар нәтиҗәсез тәмамланды. Әле хәзер дә, хәтта милләтне кайгыртып эш итүче авторлар да, милләткә кагылышлы Сталин өйрәтмәләреннән арынып җитә алмыйлар. Бу мөһим һәм кирәкле адымны атлау өчен милли мөнәсәбәтләрне яктыртуда марксизм тәэсиренә бирешмәгән авторларның хезмәтләре белән танышу мөһим роль уйнаячак. С. Максудиның әйтелгән хезмәте шундыйлардан.

Сталин милләтне, билгеле булганча, социал-иктисади мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсендә туган нинди дә тарихи берлеккә кайтарып калдыра һәм теге яки бу милләтне хасыйль итүче халыкны, этносны бөтенләй читләтеп үтә. С. Максуди хезмәтендә исә милләт турында сүз барганда алгы планга нәкъ менә халык, кавем, этнос килеп баса. Аның өчен милләт билгеле бер кавем, ягъни этник берәмлек тәшкил итүче халык үсешенең югары баскычы. Бу мәсьәләне тикшергәндә ул кавем-милләт төшенчәсе куллана. «Кавем-милләт исемен,— дип яза ул үзенең хезмәтендә,— без ыруг, кабиләләрнең бер дәүләт эчендә берләшүе нәтиҗәсендә туган этник бердәмлек рәвешендә күз алдыбызга китерәбез». Кавем һәм милләт тәгъбирләре арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап С. Максуди милләтнең нинди дә бер кавемнең үсеп җитүен күрсәтүче фактор икәнлегенә басым ясап үтә. «Тарихи вә сәяси үсеш нәтиҗәсендә формалашуы тәмамланган һәр кавем,— дип яза ул,— милләттер».

Ахырда автор «Кавем-милләт билгеле бер өлкәдә (территориядә) яшәгән, этнологик яктан бер тамырдан чыккан оймак вә кабиләләрнең иң куәтлесе җитәкчелегендә дәүләт булып берләшүе нәтиҗәсендә туган, бер телдә сөйләшүче, бер үк гореф-гадәтләр тотучы, бер үк дингә инанучы, үзенә хас милли характеры булган, бер-беренә теләктәшлектә торучы вә охшаш кешеләрнең зур төркемедер», дигән нәтиҗәгә килә. Күренүенчә кавем-милләт төшенчәсе бер яктан милләтнең асылын, аның ни-нәрсә икәнлеген, ә икенче яктан тамырларын, килеп чыгышы ачып сала.

С. Максуди үзенең китабында кавем-милләт төшенчәсенә һәрьяклап анализ ясый, милләтләрнең формалашу һәм яшәеше шартларына җентекләп тукталa. Җыеп кына әйткәндә бу шарт түбәндәгеләргә кайтып калалар:

1. Милләтне тәшкил иткән индивидларның (фәрдләрнең) бер дәүләт эчендә яшәве; 2. Халык (нәфус); 3. Географик урын (территория); 4. Бәйсезлек; 5. Тел берлеге; 6. Гореф-гадәтләр берлеге; 7. Гомуми дини инанулар; 8. Милли характер; 9. Милләтнең күпчелегенең бер ырыктан, ягъни бер этник тамырдан булуы.

Бу шартның җәмгысы милләт формалашуының нигезендә яталар, аның йөзен билгелиләр һәм милләт төшенчәсен ачык күзалларга мөмкинлек бирәләр. Милләтнең болай аңлау безгә дистәләгән еллар буе тукып киленгән милләт төшенчәсе басымыннан котылырга ярдәм итә. Инде әйтеп үткәнчә, С. Максуди өчен милләт билгеле бер халык, кавем, этнос. Милләт була алсын өчен ул сан ягыннан билгеле бер күләмдә, үзен саклый алырлык күләмдә, булырга тиеш. Шуның өстенә милләт булып оешучы халык массасы бер ырктан, ягъни бер этник тамырдан чыккан булырга тиеш. Ә «раса» төшенчәсе безнең әдәбиятта башлыча, кеше төркемнәренең бер-береннән тышкы кыяфәтләре (чәче һәм тән төсе, баш төзелеше, күзләре, буйлары һ. б.) ягыннан аерылуларының чагылышы рәвешендәрәк аңлатылып киленде. Бу — мәсьәләнең антрополик ягы. С. Максуди да үзенең китабында раса төшенчәсенә бу җәһәттән тирән анализ ясый. Шуның белән бергә ул раса төшенчәсенә этнологик яктан да бик тирән анализ бирә. Милләт мәсьәләсен тикшергәндә автор «ырк» төшенчәсен нәкъ менә шушы этнологик мәгънәдә, ягъни кеше төркемнәренең этник тамырлары һәм нәсел-нәсәбе ягыннан куллана. «Ырк,— дип яза ул,— билгеле бер нәсел үзлегенең чагылышыдыр». Милләтләрнең формалашуында менә шушы мәгънәдә кулланылган ыркның роле бәхәссез. Милләтләр гадәттә теге яки бу дәүләт эчендә күпчелекне тәшкил иткән ырктан (кавемнән, нәселдән, кабиләләр төркеменнән) укмашалар.

Милли мөнәсәбәтләр урнашуда Сталин теориясендә хәлиткеч рольне икътисади мөнәсәбәтләр уйный. С. Максуди фикеренчә дә инсаният тормышында икътисади факторның роле мөһим булуы бәхәссез. Шул ук вакыт, дип хисаплый ул, кешелек җәмгыятенең яшәешендә икътисади фактордан башка да бик күп матди вә рухи факторлар бар. Шундый мөһим факторларның берсе — дәүләт. С. Максуди фикеренчә, милләтләрнең формалашуында хәлиткеч рольне дәүләт уйный да. Милләтнең барлыкка килүендә, дип саный ул, милләтне тәшкил итүче массаларның озак заманнар буе бер дәүләт, бер үк хокукый кагыйдәләргә буйсынып яшәве кирәк. Милләтләрнең оешып яшәве һәркайда билгеле бер дәүләт эчендә бара. Ә дәүләт исә — индивидлар мәҗбүри рәвештә буйсынырга тиешле хокукый тәртипләр урнаштырылу дигән сүз. Шушы хокукый тәртипләр теге яки бу дәүләт рамкаларында яшәгән массаларның бер милләт булып формалашуында хәлиткеч роль уйныйлар да.

Милләтнең формалашуы һәм яшәешенең мөһим шартларыннан берсе тел берлеге. Кешелек җәмгыятенең кабилә дәверендә ыруг вә оймакларның аралашу чаралары әле камил түгел. Мондый беренчел телләрдә сүзләр аз, грамматика башлангыч чорны кичерә; аның кагыйдәләре камил түгелләр. Шулай да бу

заманда һәр оймакның инде аерым теле бар. Төрле оймакларга кергән кешеләр исә элек бер-берсен аңламыйлар. Уртак тел фәкать озак вакытлар дәвамында бер дәүләт эчендә яшәү, аралашу, бер үк нәрсә күп мәртәбәләр кабатлану нәтиҗәсе буларак барлыкка килә.

«Һәр милләтнен,— дип яза автор,— аралашу теле белән рухи халәте арасында ныклы бәйләнеш бар. Чөнки аңлашуның нигезендә яткан тел берлеге — милләт булуының иң мөһим өлешен тәшкил итә. Тарихтан күренгәнчә, кайда да булса, нинди дә булса бер милләт оешса, шунда ук билгеле бер милли тел дә күзәтелә. Кайда да булса зур бер массаны эченә алган уртак тел барлыкка килсә, шунда билгеле бер милләт вә шул милләткә бәйлелек тойгысы белән яшәгән кешеләр дә булыр. Һәр милли телгә бәйләнешле рух та булыр... Милләтләрнең милли телләренең яшәве милләт яшәвенең иң әһәмиятле чарасы...» С. Максудиның бу искәрмәсе безнең милләт буларак киләчәгебез мәсьәләсендә каттый бер кисәтү буларак яңгырый. Әгәр халкыбызның милли теле аны чолгап алган бүгенге богаулардан кыю рәвештә арындырылмаса, безнең милләт буларак киләчәгебез шикле.

Озак вакытлар буе бер дәүләт эчендә яшәү, шулай ук, кавем — милләтләргә хас бердәм гореф-гадәтләр укмашуга да, милли характер һәм уртак милли рух барлыкка килүгә дә алып бара. Ә милли рух, милли характер һәм милли гореф-гадәтләр милләт яшәешенең мөһим күрсәткечләре.

Күренүенчә, марксизмнан аермалы буларак, С. Максуди концепциясендә милләт барлыкка килүнең хәлиткеч шарты капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килүе түгел, ә милләт булып оешуга тартылган массаларның озак заманнар буе бер дәүләт булып яшәүләре. Шушы дәүләт рамкаларында кабиләләр милләт булып оеша, милли тел барлыкка килә, бердәм милли гореф-гадәтләр формалаша, милли характер чарлана һәм милли рух туа. Шушы дәүләт рамкаларында, әлбәттә, социаль-икътисади мөнәсәбәтләр дә формалаша һәм үсә.



*Садри Максуди үзенең җәмәгате белән*

Милләтнең яшәешен болай аңлату аны «бары тарихи күренеш кенә» дигән аңлатмалар тырнагыннан арынырга мөмкинлек бирә. Кавем-милләтләр тарихның билгеле бер этабы белән генә бәйләнмәгәннәр. Алар инде бик борынгы дәверләрдә үк яшиләр һәм аларның формалашуы беренчел дәүләтләргә туры килә. Ә дәүләтнең барлыкка килүе исә сыйныфлар барлыкка килүенә бәйләнмәгән һәм аны бары сыйнфый сүз коралы гына дип аңлату урынсыз. Дәүләт ул борынгы гореф-гадәтләр урынына индивидлар мәҗбүри рәвештә буйсынырга тиешле хокукый тәртипләр урнаштырылу дигән сүз. Мондый тәртипләр исә кабиләчелектән чыгу дәверендә урнаша. Димәк дәүләтнең яшәве, шуның белән бергә милләтнең дә формалашуы бик борынгы, тарихка кадәрге дәверләргә барып тоташа. Милләтләрнең формалашуы инде беренчел дәүләтләрдә үк күзәтелә. Китапта кельт, герман, славян, төрек ыруглары турында сүз кузгатыла. С. Максуди аларны бик борынгы дәүләтләр эчендә аерым милләт тәшкил иткән массаларның таркалган өлешләре дип саный.

Милләт формалашуның һәм аның яшәешенең мөһим шартларыннан берсе — өлкә берлеге, ягъни ул урнашкан географик урын. Кавем-милләтләр һәркайчан билгеле бер урында укмашалар һәм яшиләр. Әмма бу гомуми кагыйдәгә сыймаган очраклар да күзәтелә. Яһүд милләтенең, мәсәлән, гасырлар буе үзенең милли туфрагы да, дәүләте дә булмады. Ул бөтен дөньяга таралган хәлдә, төрле дәүләтләрдә бер милләт буларак яшәде. Шул ук вакыт яһүдләр милләт булып формалашкан чакта, Давыт һәм Сөләйман исемле хөкемдарлар заманында, аларның дәүләтләре дә, милли туфраклары да бар иде. Яһүдләр дөньяның төрле почмакларына инде милләт булып формалашканнан соң таралдылар. Бу анализга йомгак ясап, С. Максуди «Фор-

малашуы тәмамланган милләтнең миллияте өзлексез һәм ул киләчәктә дә милләт буларак саклана ала» дип күрсәтеп үтә. Димәк, дәүләтчелек, территория берлеге милләтнең формалашуы өчен хәлиткеч шарт булсалар да, инде формалашуы тәмамланган көчле рухлы милләт аларны югалткан тәкъдирдә дә үзен саклый ала.

Бу күрсәтмә безнең милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер йөрткәндә дә гаять зур әһәмияткә ия. Безнең бабайлар да ерак үткән дәверләрдә Болгар дәүләте рамкаларында кавем-милләт булып формалашалар, дип әйтергә тулы нигез бар. М. Зәкиевнең тикшеренүләре күрсәткәнчә, бу кавем-милләтнең нигез ташлары Биарм дәүләте яшәгән чорларда ук салына. Алтын Урда чорында ул катлаулы үсеш дәвере кичерә. Ә Казан ханлыгында яңадан үз җирлегендә үсүен дәвам итә. Урыс хакимиятенә буйсындырылгач ул коточкыч җәбер-золымнар татый, таркала. Хәзер татар Европа һәм Азиянең киң мәйданнарында таралып яши, төрле мәмләкәтләрдә урнашкан социал-икътисади, хокукый һәм сәяси тәртипләргә буйсынырга мәҗбүр. Шулай да, татар кайда гына булса да, шөкер, үзенең татарлыгын югалтмый, бөтен күңелен вә тойгыларын асыл ватанына бәйләп яши. Бу безнең кайчандыр бик борынгы заманнарда милләт булып формалаша алуыбыз һәм шул вакыттан килгән милли тойгыны күңелләребездә саклавыбыз нәтиҗәсе.

Милләт формалашуның һәм яшәешенең тагын бер үзенчәлеге — дини инанулар. Инде әйтеп кителгәнчә, кешелек тарихында динсез бер милләт тә юк. Шулай да, милләтләрнең яшәешендә милли телнең барлыкка килүе белән дини инанулар барлыкка килү арасында аерма да күзәтелә. Милләтләрнең милли теле — бер милли казаныш һәм ул милләт белән бергә барлыкка килә. Дини инанулар исә — милли түгелләр. Аларның асылы, инсанның вә галәмнең барлыкка килүе һәм кешеләрнең җирдә башкарырга тиешле гамәлләре турындагы инануларның, ягъни диннәрнең, бер милләттән икенче милләткә күчкәне дә бар. Милли дине, ягъни үз милләте эчендә генә таралган дине булган милләтләр сирәктер. Әмма милли булса да, башка милләттән алынган булса да, дин милләтнең бер күрсәткече. Француз милләтенең барлыкка килүендә католик дине, бүгенге төрек милләтенең барлыкка килүендә исламият мөһим бер фактор булдылар.

Шул ук вакыт, С. Максуди искәрмә рәвешендә теге яки бу милләтнең булуы өчен дин берлеге зарури түгелдер, дип тә күрсәтеп үтә. Бу уңайдан мисал рәвешендә шул ук французларны китерә. Милләтләре буенча алар, әлбәттә, французлар, әмма аларның бер өлеше католиклар, ә бер өлеше протестантлар. Әмма бу каршылык француз милләтенең нигезенә зыян итми. Чөнки протестантлык француз милләте оешканнан соң барлыкка килгән. Шуңа охшашлы хәл безнең үзебезгә дә хас. Безнең милләтебез исламиятка инанучы бер милләт буларак барлыкка килә. Болгар дәүләте чорында ук инде без ислам тарафдарлары булып формалашабыз. Исламга тугрылыкны безнең милләтебез Алтын Урда чорында да, Казан ханлыгы чорында да саклый. Хәзер безнең арада керәшеннәр бар. Бу катлам соңгы гасырлар күренеше, илебез урыс дәүләтенә буйсындырылгач хакимият тарафыннан үткәрелгән урыслаштыру сәясәте җимеше.

Һәм, ниһаять, милләтләр оешуның һәм үзләренең бөтенлекләрен саклый алуның тагы бер мөһим шарты — аларның бәйсезлеге, мөстәкыйль яши алулары. Милләт бәйсезлеген югалтса, аның бөтенлегенә дә зарар килә, ахыр чиктә инкыйразына да илтүе мөмкин. Безнең кебек мөстәкыйльлеген югалткан бер милләт өчен милләт яшәешенең бу факторы кисәтү буларак яңгырый. Моннан 440 елдан артык элек милли бәйсезлегебезне югалту безне милләт буларак зур югалтуларга китерде. Әгәр киләчәктә дә үз язмышыбызны үз кулыбызга алмасак һәм «империя арбасына тагылган дегет чиләге» хәлендә кала бирсәк, милләт буларак безнең хәлебез бик мөшкел булачак.

Кавемнең милләт дәрәҗәсенә ирешү һәм милләт буларак яшәү шартлары һәм гамәлләрен шулай һәр яклап анализлап чыкканнан соң, С. Максуди милләт төшенчәсенә яңадан әйләнеп кайта. «Милләт,— дип яза ул,— үткәрелгән анализга йомгак ясап,— ерак үткәндә, күп очракта тарихтан элгәре дәвердә ук билгеле бер урында дәүләт корып, шушы дәүләт эчендә озак вакытлар мөстәкыйль булып яшәп, үз составына кергән өлешләре каршылыклы тәэсирләр тойган хәлдә бер-берсе белән аралашып, бердәм гореф-гадәтләргә тугрылыклы булып бер телдә сөйләшүче индивидлар вә гаиләләрдән оешкан бәшәри массадыр».

Кавем-милләтләрнең барлыкка килүе, яшәеше, аларның йөзен билгеләүче факторларны С. Максуди шулай характерлый һәм аларны хакыйкый милләтләр дип атый. Кавем-милләтләр, ягъни хакыйкый милләтләр белән бер рәттән, аның

фикеренчә, кешелек җәмгыятендә тарихи милләтләр дә очрый. Хакыйкый милләтләр (кавем-милләтләр) белән тарихи милләтләр бер-берсеннән үзләрен барлыкка китергән сәбәпләр, милли бәйләнеш нигезендә яткан факторлар һәм үзләренең состав өлешләре белән аерылалар. Бер нәселдән булган ыруг вә кабиләләрнең бер кавем-милләт булып оешуы нигезендә ихтыяри омтылыш ята, алар үз мәнфәгатьләрен яклау өчен үз ихтыярлары белән берләшәләр һәм бу ихтыяри омтылыш кавем-милләтләрнең формалашуына китерә. Тарихи милләтләр исә көч куллану, хаким төркемнәрнең башка кавемнәрдән булган төркемнәрне көч ярдәмендә буйсындыруы һәм йотуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Кавем-милләтләрдә кешеләр бер-берсе белән этник җепләр белән бәйләнгәннәр. Ә тарихи милләтләрдә аларны бер-берсенә бәйләүче фактор — көч. Кавем-милләтләр бер-берсенә якын торган оймак вә кабиләләрдән укмашалар. Тарихи милләтләргә исә мондый бер төрлелек зарури түгел. Алар составына хакимлек итүче кавем — милләт тарафыннан буйсындырылган төрле кавем-милләтләр керүе мөмкин.

Тарихи милләтләрнең мисалы итеп С. Максуди римләннәрне китерә. Бу милләт, дип күрсәтеп үтә ул, римлән булмаган һәм ул телдә сөйләшмәгән күп кенә кавем вә милләтләрне буйсындыру нәтиҗәсендә барлыкка килде. Тарихи милләтләр башлыча империяләргә хас күренеш. Аларның барлыкка килүе вә яшәве, чыннан да, билгеле бер тарихи шартлар белән бәйле.

Соңгы вакытта матбугат битләрендә милләт мәсьәләсен этник асылыннан аерып, тарихи милләтләргә хас төшенчәләргә таянып аңлатырга омтылып күзәтелә. Менә Казандагы «Согласие» төркеменең теоретигы В. Беляевнең бу мәсьәләгә кагылышлы фикере: «В мире с XVIII века,— дип яза ул,— нацией называется не этнос (татары, русские, баски), а все население (согражданство)» («Советская Татария», 1992, 28 май). Мондый фәлсәфә бары империячел сәясәтнең, милләтләрне өстенлек итүче бер милләткә буйсындыру, аның казанында эретеп бетерүгә булган омтылышның чагылышы. В. Беляев теориясен милли мөнәсәбәтләрнең нигезе итеп алынган тәкъдирдә, Россия Федерациясендә, мәсәлән, татар да, чуаш та, башкорт та юк һәм була да алмый. Монда бары бер Россия милләте генә, россияннар гына яши.

Тарихи милләтләр кешелекнең нормаль үсешеннән тайпылыш буларак күзәтелә. Кешелекнең нормаль үсеш процессы исә кавем-милләтләр формалашуга китерә. Болар — хакыйкый милләтләр. Алар ыруг, оймак, кабиләләрнең үсеше процессында барлыкка килә һәм кавем-милләт буларак яши.

**Милләт тойгысы.** Милләтнең яшәешендә һәм көрәш мәйданында үзен саклый алуында, үзенең бөтенлеген тәэмин итүдә, дип хисаплый С. Максуди, миллият тойгысы хәлиткеч роль уйный. «Милләтләрнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүче, башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклаучы,— дип ассызыклый ул,— нәкъ менә шушы куәтле тойгыдыр, ягъни милли хисләр». Бу тойгының чыганагы, аның фикеренчә, ыруг, кабилә вә кавемнәрнең ерак үткәненә барып тоташа һәм ул аларны тәшкил иткән индивидлар арасында кеше рухына хас булган иҗтимагый омтылыш басымы астында барлыкка килә. Кеше тумышыннан ук үзе бәйләнгән төркем, кабилә, кавем яки милләт рухына багланган була. Чөнки аның хәяттагы урыны әйтелгән инсани төркемнең хәятына бәйләнгән. Бу төркем эчендә урнашкан теләктәшлек һәм бердәмлек атмосферасы аның иҗтимагый омтылыш вә һәвәслекләре ачылуга мөмкинлек, мәхәббәт, бер-береңә ышаныч вә тынычлыкны саклый алырдай бер мохит тудыра. Шушы нигездә миллият тойгысы барлыкка килә дә. «Шулай итеп,— дип яза С. Максуди,— миллият тойгысының чыганагы вә үзәк беренчел җәмгыятьләрдә дә», мәдәни җәмгыятьләрдә дә, аерым очракларда хәтта хайваннар дөньясында да күзәтелгән шушы гомуми социологик күренештер, ягъни индивидларның үзләренә хас тойгылары нәтиҗәсендә туган бер-береңә бәйлелек хиседер».

Бу тойгының эчтәлеген ачып автор алга таба «миллият тойгысы индивидларның үз милләтләренең үткәненә, киләчәгенә, теленә, мәдәниятына, өлкә вә туфрагына карата туган карашларының тирәнәюе, нәселдән нәселгә күчүе белән бәйләнгән рухи бер халәттер», дип күрсәтеп үтә. Шуның өстенә бу рухи милләтне тәшкил итүче бөтен индивидларны колачлаганлыктан, шәхси булудан бигрәк, коллектив бер тойгы рәвешендә яши.

Индивидларда милләткә бәйлелек хисенең, миллият тойгысының тууы, көчәюе, тирәнәюе вә бөтен милләт эчендә таралуы, дип хисаплый С. Максуди, милләтнең формалашып мәйданга килүенең психологик нәтиҗәләреннән берсе. Бу тойгы нәселчәнлек кануннары нигезендә милләт эчендә туктаусыз куәтләнә бара. Һәм милләтнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүдә, аны башка

милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклауда хәлиткеч роль уйный. Нииндидер сәбәпләр аркасында шәхесләрне милләт итеп берләштерә торган бу җепнең өзелүе — булган милләтне әкренләп юк итә.

Миллият тойгысы беренче чиратта теге яки бу милләткә караган кешеләрнең үзләренең милли тарихларына, миллиятнең үткәндәге уңышларына яки бәхетсезлекләренә мөкатдәс бер нәрсә итеп караулары рәвешендә күзгә ташлана. Миллиятче инсан милләтнең тарихта ялтыраган дәверләрен, уңыш китергән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алса, караңгылык чорлары, бәхетсезлек вә газап кичергән заманнар исә анда кайгы хисе уята. Милләтләрнең үз үткәннәренә бәйләнгәнлеклары, аларның үз милли мәдәниятләренә, телләренә, диннәренә, милли аннарына, милләтнең олы затларына вә каһарманнарына хөрмәт рәвешендә күренә.

Шулай да миллият тойгысы фәкать милләтнең үткәндәге язмышына бәйле рәвештә генә күзәтелми. Ул индивидларның милләтнең киләчәге күз алдына тотып кылган гамәлләрендә һәм фикерләрендә дә үзенең чагылышын таба. Миллият тойгысының болай киләчәккә булган юнәлеше сәяси яктан мөстәкыйль булган милләтләрдә киләчәктә дә мөстәкыйль булып яшәү теләгендә, ә бәйсезлекләрен югалткан милләтләрдә исә бәйсезлекне яңадан торгызуга булган эшгамәлләрендә үзенең чагылышын таба. Бу ике халәттә булган милләт тә, дип саный С. Максуди үз ватанында үз телендә сөйләшеп, үз гореф-гадәтләренә таянып яшәүгә, мәдәният вә цивилизация җәһәтеннән алга бару теләге вә карашын даими үстерү өмидендә булырлар. Миллият тойгысының ачылуы, үсүе вә камиллеккә ирешүе шушы киләчәккә омтылган теләк вә максат аркасындадыр.

Димәк безнең дә киләчәктә милләт булып яши һәм үсә алуыбыз бездәге миллият тойгысының камилләшә, үткенләнә һәм үсә баруы белән турыдан-туры бәйләнгән. Без бары үзебезнең үткәнебездән сабак алып, милләтебезнең ихтыяҗларын тоеп, аның киләчәген кайгыртып һәм бөтен сәләтебезне шушы киләчәкне күз алдында тотып эш итсәк кенә милләтебезнең башка халыклар белән бер сафта алга баруына ирешә алачакбыз.

**Милләтчелек мәсьәләсе.** Милли тойгы белән бәйле рәвештә С. Максуди милләтчелек турында да сүз алып бара. Соңгы берничә дистә ел дәвамында безнең әдәбиятта хакимлек итүче коммунистик идеология басымы астында милләтчелеккә (С. Максуди аны «миллиятчелек» дип атый) кара мөһер сугып киленде. Ул шовинизм белән тәңгәлләштерелде һәм антигуманистик характерда булган бер идеологик юнәлеш рәвешендә тасвирланды. С. Максуди фикеренчә, миллиятчелек шовинизм кебек идеологик юнәлешләрдән ерак тора. Ул милләтнең яшәешеннән туган гадәти бер күренеш, милли тойгының гамәли чагылышы. «Милләтләрнең яшәүгә омтылышы вә ихтыяры,— дип яза С. Максуди,— «миллият тойгысы» яки «миллиятчелек» дип атала.» Милләтчелекнең мөһим принципларыннан берсе, үз милләтең һәм аның киләчәге өчен тырышу, бу юлда фидакарьлек күрсәтү, милләтеңнең үз җирлегендә вә үз инсаннарына таянып калкып чыгуы өчен көрәш алып бару.

Милләтчелек башка милләтләрне буйсындыру яки җәберләүне һич кенә дә күз алдында тотмый. Аның асылы бары үз милләтеңнең кайгысын, аның киләчәген кайгырту, аның теле, мәдәнияте турында уйлап эш итү, аның киләчәге өчен тырышлык күрсәтү, үз милләтеңнең киләчәктә дә милләт буларак яшәешен тәэмин итү, аны башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклау. «Милләтче инсан,— дип басым ясый автор,— үз милләтенең тарихта ялтыраган дәверләрен, уңыш китергән заманнарын горурлык вә зур канәгатьләнү хисе белән искә алыр. Караңгылык чорлары, бәхетсезлек вә газап кичергән заманнар исә анда кайгы уятыр». Миллиятче инсан, С. Максуди фикеренчә, бетмәс төкәнмәс мәгънәви байлыкларга ия булган рухи камил һәм бәхетле бер инсандыр. Ә милли хистән вә милли изгелектән мәхрүм калган инсан исә, рухи яктан фәкыйрь бер мескендер.

Милләтчелекнең нигезендә кайбер авторлар раслаганча, башка милләтләрне буйсындыруга һәм җәберләүгә юнәлдерелгән шовинистик омтылыш ятмый. Киресенчә, дип яза С. Максуди, миллиятчелек хисе милли җәбер-золымга каршы протест рәвешендә үсә вә ныгый. Теге яки бу милләт тарихта ни кадәр еш кайгы вә газаплы дәверләр кичергән булса, башка милләтләрнең һөҗүменә, золымына вә изүенә никадәр күп дучар ителсә, шул нисбәттә ук аның уллары вә кызлары үз милләтенә бәйләнгән булырлар, шул нисбәттә үк миллиятче дә булырлар. Милләтләрнең тарихта кичергән фәлакәтләре, алар өстенә төшкән җәбер, золым вә хаксызлыклар, аларның үз бәйсезлекләре өчен алып барган көрәшләре вә фидакарьлекләре милли хисләре үсүгә этәргеч вазыйфасын үтәгәннәр.

Бу факторларны С. Максуди милли хисне куәтләндергән «бөек гамәлләр» дип атый һәм мисал рәвешендә полякларны һәм яһүдләрне китерә. Бу ике милләт поляк һәм яһүд булган өчен генә гасырлар буе күп җәбер вә золымнар татыдылар. Бу үз чиратында аларның милли хисләрен чарлады. һәм нәтиҗәдә поляклар белән яһүдләр хәзерге дөньяда иң миллиятче милләтләрдән саналалар.

Милләтчелекнең иҗтимагый-сәяси йөзен ачып С. Максуди аның хөррият, демократия һәм либерализм идеяләре белән нык бәйләнгәнлеген, анда тәгассыблык яки чикләнгәнлекнең әсәре дә булмавын басым ясап күрсәтеп үтә. «Бүгенге миллиятче,— ди ул сүзен йомгаклап,— милли намус вә абруй, милли дәрәҗә вә милли мәнфәгатьләр мәсьәләсендә гадәттән тыш нәзакәтле булу белән бергә, шовинизмнан ерак торган, әмма шул ук вакыт рациональ, төпле һәм аек акылга нигезләнгән милли хискә бирелгән инсандыр». Ул социаль һәм психологик әсасларга таянып эш итә, кеше канын тикшерү белән дә шөгыльләнми, баш сөягенең шәкеле белән дә кызыксынмый. Бүгенге милләтчелекнең төп нигезе — билгеле бер милләткә бәйлелек хисе. Шул ук вакыт ул нинди дер өстен милләт идеясен дә, милләт эчендә ниндидер өстен шәхес яки төркем (сыйныф) булуы идеясен дә кире кага. Ул милләтләрнең һәр җирдә тигезлектә һәм килешеп яши алуларына инана.

Миллият хисе тууны XIX гасырга бәйләп карау ул бары: Аурупадагы бәйлелектә булган бәгъзи милләтләрдә миллият хисенең шушы гасырда яңадан җанлануын гомумән миллият хисенең килүе дип санау нәтиҗәсе генә. Ә хакыйкатьтә инде борынгы дәвердән үк кешелек тарихының асыл нигезе миллият хисе белән бәйләнгән. Миллият хисенең, милләтчелекнең милләтләрнең үзләре кебек үк бик борынгы булуын С. Максуди тарихтан бик күп мисаллар китереп дәлилли. Менә аларның кайберләре: Миладидан 17 гасыр элек Мисырга бәреп кергән Һиксос кавеме белән Фива фиргавеннәренең озакка сузылган көрәше мисырлыларда миллият хисе көчәюнең ачык мисалы иде. Яки менә Месопотамиядә миладидан 40 гасыр элек яшәгән туран кавемнәреннән булган шумерлар белән семит кавемнәреннән саналган акадларның бертуктаусыз көрәше. Бу очракта да әйтелгән аяусыз көрәшне рухландырып торучы миллиятчелек хисе булды. Троя сугышларының да, безнең эрага кадәр V гасырдагы юнаннар белән иранлылар арасындагы бәрелешләрнең дә, Рим-Карфаген сугышларының да нигезендә милли каршылыклар ятты һәм аларның этәргеч көче миллиятчелек хисе булды. Урта гасырлардан чыкканда 100 еллык сугыш вакытында французларның да, инглизләрнең дә яу кырында күрсәткән фидакарьлекләре милли хиснең нинди көчкә ия икәнлеген ачык күрсәтте.

Димәк, милли хис, милләтчелек тарихта милләтләрнең үз-үзләрен саклауларында хәлиткеч роль уйнады. Әмма инсаниятнең яшәешендә аның роле моның белән генә чикләнми. Аерым шәхесләр өчен дә, милләтләр өчен дә милләтчелек хаятилек галәмәте дә, яшәүгә сәләт галәмәте дә, тарихи үсеш галәмәте дә. «Миллият тойгысы, миллиятчелек,— дип яза автор,— яшәү сәләтен саклый торган, милләтләрнең рухларын тулыландырып торучы бер хис булганы кебек, тарихи вакыйгаларга да юнәлеш бирә торган бер башлангыч». Ул милләтләрнең тормышында бөек роль уйнаучы зур тәэсирле вә динамик бер мәгънәви куәттер. «Милли аң, миллиятчелек милләтләр өчен иң тәэсирле үсеш вә камилләшү гамәле..., тәрәккъыят гамәле, хаятилек гамәле вә гарантиясе».

Совет хакимияте ныгыгач, милләт мәнфәгатьләрен яклап эш иткән татар интеллигенциясенең башка вәкилләре кебек үк, Садри Максудиның хезмәтләрен уку-өйрәнү түгел, хәтта исемен дә телгә алырга ярамады. Аның милләт кайгысын кайгыртып Дәүләт думасында сөйләгән кайнар нотыклары һәм ялкынлы мәкаләләре басылган гәзит-журналлар ябык архивларның яшерен фондларында бикләнеп тотылды, ә чит илләрдәге эшчәнлеге һәм анда язылган хезмәтләре тимер пәрдә аша үтеп илгә керә алмады.

С. Максуди иҗатының кыйммәтле җимешләре, аларда бәян ителгән фикерләр, халкыбызның милләт буларак яши алуы өчен барган көрәштә ул керткән өлеш — безнең олы әһәмияткә ия булган милли мирасыбыз. Хәзер, милли мөстәкыйльлегебез өчен яңа көрәш җәелү шартларында, бу мирас халкыбызның хәтерендә яңадан кабынырга һәм аның күңел түрендә үзенең лаеклы урынын алырга тиеш. Бу милли аңны уятуда, кардәшләребезне милли бәйсезлек өчен көрәш туплауда үзенең мөһим ролен уйный алачак. Максатка ирешүдә, милли бәйсезлеккә баруда эзлеклелек саклау өчен без милли кыйблабызны ачык күрсәтердәй идеологиягә мохтаҗбыз. Садри Максуди мирасы бу идеологиянең эчтәлеген һәм аның юнәлешен билгеләүдә мөһим чыганак була ала.

# ӘРНҮЛӘРЕ ДӘ ЯКТЫ



Әдипләрне мин Ходайдан бирелгән сәләтләренә карап аерудан тыш, үзем өчен генә ике зур груһка бүлеп карыйм: берәүләр үз иҗатын яшәүгә ярдәм чарасы итеп көн итә, икенчеләре исә — яшәү рәвешенә әверелдерә. Кайсы төре өстенрәктер, кайсы отышсызрактыр, бу очракта сүз ул хакта түгел: чөнки беренчеләр әдәби шедеврлар тудырып, икенчеләренең уртакул әсәрләр белән генә дә канәгатьләнүе бик мөмкин ләбаса. Бу — сәләт-талант эше. Әмма, иманым камил, беренче төркемгә керүчеләр үз иҗатларына яшәү рәвеше, дип карасалар, әдәбиятыбызга керткән өлешләре чагыштырыргысыз зуррак булыр иде. Шуңа күрә, мин үзем шәхсән икенчеләрдән көнләшәм — иҗат ләззәтен андыйлар күчлерәк тоя. Ләкин, ул вакытта, авырлыкларны да кыенрак кичерә алар: дөньяның бөтен яме — иҗатларында ич!

Фаяз Дунай дигән намны ишетүгә, күз алдына шундук икенче груһ язучылары килеп баса: әдәбияттан башка яшәүне үлемгә тиң санаучыларның иңиң үҗәтлесе ул, дисәк тә ялгышмабыздыр, мөгаен. Әсәрләре белән бергә сөенә-шатлана, әсәрләре белән бергә яна-көя. Шунлыктан ул кайчак хәтта үз хыялында тудырган каһарманнарын тормыштагы реаль кешеләрдән аерып карый да алмый кебек. Бәхете дә, кайгысы да бергә аралашкан. Тик бер үзгәлеге бар: аның иҗат бәхете сагышлы, иҗат кайгысы — якты нурлы. Шушы үзенчәлеге аны уңыштан башы әйләнүдән һәм уңышсызлыктан абынып, сөрлегүдән коткарып килә. Ни аяныч, иҗади уңышлары да, ялгышлары да аның үзеннән генә торса иде! Фикеремне ачыклар өчен бер генә гыйбрәтле мисал китереп үтим. Шигырьләр-поэмалар, хикәяләр-нәсерләр иҗат итә-итә борынын берничә тапкыр канаткан тынгысыз җанлы Фаяз Дунай 1970 (!) елда «Сөюнең сынаулары бар» дигән драма «язып ташлый». Театр әһелләре аны ачык йөз белән каршы алалар: берьюлы ике татар театры — Әлмәт һәм Минзәлә театрлары җиң сызганып ул әсәрне сәхнәләштерергә керешә һәм...

— Антипартийный нәмәрсә язгансың! Син КамАЗ төзелүен яз. Язмыйсың икән — пеняй на себя...

Фаяз Дунай пьесасында Сталин-Ежов-Вышинский-Берияләрне начар яктан телгә алган — «антипартийныйлыгы» шул икән. Икенче мәртәбә «авызын пешергән» әсәре белән драматургны 1985 елда талпындырып куялар: драматургларның Казанда үткәрелгән Бөтенсоюз семинарында була ул хәл. Мәскәүдән, Ленинградтан килгән «киң маңгайлы олпат» тәнкыйтьчеләр һәм драматурглар Фаяз Дунайның пьесасын күкләргә чөеп, үтереп мактыйлар. Качалов театрының ул вакыттагы баш режиссеры (кунаклар мактамаса, ул әсәргә борылып та карамас иде, әлбәттә!) шундук, үзем куям, дип пьесаны алып китә һәм... «эш» шундук өлкә комитетында кабат «аталарча кайгырту» белән төгәлләнә:

— Ул режиссерның кыйбласы юк! Без аның үзен эшеннән куарга торабыз. Уңай герой турында яз. Ә синең героең — төрмәдә утырып чыккан карак! КамАЗда син язарлык яхшы эшчеләр беткәнмени?!

Шулай да, Фаяз Дунайның «әрнүләре» дә якты: ул беркайчан үзенең иҗат язмышыннан зарланмас, рәнҗеттеләр, дип шикаять белән йөрмәс, һаман әдәбият дөньясында бөтен җанын-сәләтен биреп кайнашыр.

Шатлыклы уңышлар сиңа, каләмдәшебез!

**Ризван Хәмид.**

# ФАТИХ ӘМИРХАН ИҖАТЫНЫҢ БЕР ЯФРАГЫ



*Фатих Әмирхан. 1904 ел.*

1905 ел инкыйлабы җиңелеп, кара реакция еллары башлангач, эзәрлекләүләрдән качып кабат Төркиягә киткән Йосыф Акчура анда 1909 елдан башлап «Төрек йорды» дигән журнал чыгара башлый. Журнал битләрендә, сирәк-мирәк булса да Рәсәйдә яшәүче татар әдипләре язмалары да күренгәли. Әйтик, журналның 1912 елдагы 7 санында «Казаннан» дигән хәбәр урнаштырылган. Язма «Ф. Бәкхан» дигән имза-псевдоним белән тамгаланган. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, «бу мәкаләнең авторы кем булуы мөмкин соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Мантыйкый фикер йөртә башласаң, моңа «ачкычны» бик тиз табарга була. Әмирхан исеменең «әмир» өлеше гарәп сүзе булып, төрекчәгә ул «бик», «бәк» мәгънәсендә тәрҗемә ителә. Шул рәвешле, «Ф. Бәкхан»ның Фатих Әмирхан булуы гади тәрҗемә итү юлы белән дә аңлашыла. Әдипнең читтә адашып калган бу мәкаләсе аның фикер йөртү эволюциясен күзаллау ягыннан да кызыклы бер чыганак булып тора. Билгеле ки, мәкалә, төрек укучыларының ихтыяҗларын һәм мөмкинлекләрен истә тотып, берникадәр редакцияләнгән, ягъни төрекләштерелгән.

Ә без исә, үз чиратыбызда, татар укучысына аңлашылсын өчен, мәкаләдәге кайбер төрек сүзләренең татарча аңлатмасын да бирүне кирәк таптык. Әйткәнебезчә, мондый «чистарту» эшләре аерым сүзләр дәрәҗәсендә генә алып барылды, ә җөмлә төзелеше һәм стиль төп нөсхәдәгечә калдырылды.

Инде мәкаләнең эчтәлегенә бер күз салыйк. Дөньяны кайтадан бүлешү өчен, Италия империалистларының Төркия биләмәләренә (Ливиягә) һөҗүме (1911 ел) — Урыс-Япон сугышы кебек үк, Беренче бөтендөнья сугышының тәүге гереләре. Идел буенда ачлык һәм аның төбәк икътисадына тәэсире... Татар җәмагатьчелегендә тәрәккый хәрәкәте алга баруын исбатлау рәвешендә, Казандагы «Шәрекъ клубы» эшчәнлегендәге яңалыклар... Шул чор татар революцион демократларын борчыган, дулкынландырган мәсьәләләр... Моны шундый эзлекле һәм нигезле рәвештә, шул хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган Ф. Әмирхан гына яктырта ала. Бу яктан караганда да, мәкалә — Ф. Әмирханныкы булуында шик

калдырмый. «Телеграф» стилендә, җыйнак кына итеп кайбер хәбәрләрне, яңалыкларны ерактагы фикердәшләргә җиткерү, фикер алышу рәвешендә язылган бик тә гади һәм гадәти мәкалә. Бер үк вакытта, ул — Ф. Әмирхан иҗаты югарылыгындагы тирән эчтәлекле, зур идеаллы, идеяле, эчке көрәш пафосы белән сугарылган язма. Автор үзенең яшьлек, көрәш идеалларына турылыклы булып калган. Бүгенгәчә татар матбугатында чыкмаган бу материалның җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим ителүе әдип мирасын барлау ягыннан да зур әһәмияткә ия.

**Мәсьгут ГАЙНЕТДИН,**
филология фәннәре кандидаты.

## Ф. Бәкхан

# КАЗАННАН

Бөтен урта Русия төрекләре яшәешенең үзәге урынындагы Казан Госманлы — Итальян сугышыннан бик мөтәэссир [1] вә мөтәһәйиҗ [2] улды. Тышкы күренешләренә караганда, урыслашкан дип уйларлык яшьләребездән алып көндәлек мәгыйшәттән [3] башка һичбер нәрсә турында пошынмас кебек күренгән гади сыйныф, арбачыларга [4] кадәр, һәр җан иясе мөтәссыйл [5] мөхарабәдән [6] бәхәс итмәктә. Бу мәсьәләдә бәхәсләшәләр, хәтта ызгышларга барып җитәләр. Казанлыларның җөмләсенең кальбендә хакны таптаган итальяннарга каршы тирән бер хис, нәфрәт бар.

Күп еллардан бирле Русия төрекләрен иң күп уйландырган бер мәсьәлә бар: ул — милли мәктәп вә мәдрәсәләр мәсьәләсе. Хөкүмәтнең соң заманнарда сайлаган сәясәте нәтиҗәсендә (бу мәсьәлә) безнең өчен гадәттән тыш нәзакәт вә әһәмият кәсеп итүенә дә карамастан, Траблис (Триполи — **М. Г.**) — Гареп мөхарәбәсе бер мөтдәткә [7] ул мәсьәләне бөтенләй онытты: мәктәп-мәдрәсәләребез ябылулары, имам вә мөгаллимнәребез кулга алынулары, ул сугыш башлану белән хәтерне ребездән чыкты, исебезгә төшмәс булды.

Бераз югарыда, Госманлы — Итальян сугышы бәхәсләре кайчак ызгышларгача барып җитә дигән идем. Берничә көн әүвәл Казанда шуйлә [8] бер вакыйга улып кичте. Бер авыл агае Казанга килә. Чәйханәләрнең берсендә икенче бер авыл агае (моның алдында) бер рус белән шул сугыш турында сүз кузгата. Русның бәгъзе [9] лафлары безнең авыл агаена госманлы төрекләрен тәхкыйрь[10] кеби күренә. Авыл агае тик торганда әлеге руска салып җибәрә. Бәрәкәт булсын, шундук полицай килеп җитеп, ул-бу булмастан кала, боларны килештерә. Бу хадисәдән[11], төптән уйласаң шул нәрсә аңлашыла: бу авыл агае үзе яки якыннары хакында болай тиз кызуланмас, кизәнмәс иде бит...

---

[1] М ө т ә э с с и р — тәэссирле.
[2] М ө т ә һ ә й е ж — хисле.
[3] М ә г ы й ш ә т — көнкүреш.
[4] А р б а ч ы — барабыз (извозчик).
[5] М ө т ә с с ы й л — тоташ.
[6] М ө х а р а б ә — сугыш.
[7] М ө т д ә т — ара.
[8] Ш у й л ә — шундый.
[9] Б ә г ъ з е — кайбер.
[10] Т ә х к ы й р ь — хурлау.
[11] Х а д и с ә — вакыйга.

Шәркый Русияне баскан дәһшәтле ачлык быел Казан төрекләренең сәүдәләренә шактый кәсад[1] бирде. Вә бондан бөтен хәятемез мөтәэссир улды. Шуның белән бергә, көчәя барган ачлык мәдәни хәятебезне торгынлыкка юлыктырды. Әмма хәрәкәтебез, агыр, фәкать әмин[2] адымнар илә дәвам итмәктә. Мәсәлән, күңелгә бик кечкенә кебек күренсә дә, игътибар итәрлек ике вакыйга зикергә шаяттер[3]. Моннан биш ел әүвәл Казан төрекләренең тәэсис итдекләре[4] «Шәрекъ клубы» бу сәнә яңа әсасларга[5] истинад итмәк[6] үзрә ислах улынды[7]. Шимдидән[8] соңра клубымызның үзенә мәхсус бер театросы вә һәйәте[9] улачактыр. Бу көнә дикен клубта ялгыз, гыйльми конференцияләр бирелеюр, музыка кичәләре тәртип улыныюрдә. Инде үз сәнгатьчеләре тарафыннан театро да уйналачактыр. Икенче, тагын да әһәмиятлерәк булган вакыйга «Шәрекъ клубы» низамнамәсенең[10] әгъзага гаид[11] мәддәсенең тәгъдиледер[12]. Иске низамнамәдә тик ирләр клубка әгъза итеп языла иделәр. Яңа низамнамә мөҗибенчә[13], хатыннар да «Шәрекъ клубы» әгъзасы була алачак.

Соң көннәрдә Шимал төрекләре матбугат галәменә Казан төрекчәсенең сарыф[14] вә нәхүенә[15] даир[16] ике әсәр чыкты. Безнең белдекемезгә күрә, шимдигә кадәр тәртип вә тәэлиф[17] улынмыш төркичә сарыф вә нәхү китаплары йә франкларны (ауропалыларны — М. Г.) тәкълидтән[18] гыйбарәт. Бонлар телебез тәдкыйк улынып[19] телемездән чыгарылмыш кагыйдәләрне ихтива итмәсләр[20], бонларның тәкъсиматы[21] телемезнең табигатенә назарән япылмамыштыр[22]. Хасыйл, төрекчәнең мәүҗуд[23] кавагыйд[24] китаплары төрек теленең духыннан озакта калырлар. Хәтта төрекләрнең иң мөтәрәккыйсы[25] булган госманлыларның рәсми мәктәпләрендә укытылмакта булынган сарыф вә нәхүләр шундый тәкълид юллы вөҗүдкә китерелмештер. Бу исә төрек лисаненең[26] истикъбале[27] өчен биек бер зарардыр. Интишарыны[28] әүвәл гарз итдекем[29] ике әсәр бу гомуми косурдан[30] гаридыр[31], лисанемезнең әсаслы[32] тәфтиш вә тәдкыйкы[33] нәтиҗәсе уларак каләмгә алынмыштыр.

Ике-өч атна мөкатдәм Уфа «Мәдрәсәи Галия руханияъ»-се мөдәррисләреннән Зыя әл-Кәмали әфәнде «Коръән Кәрим»нең шимал төрекчәсенә тәрҗемә итмәгә башладыкыны Казан вә Оренбур мөселман җәридәләре[34] илә игълан итте. Бу

---

[1] Кәсад — тоткарлык.
[2] Әмин — имин.
[3] Зикергә шаяттер — игътибарга лаеклыдыр.
[4] Тәэсис итдекләре — оештырган.
[5] Әсас — нигез.
[6] Истинад итмәк — кору, юнәлдерү.
[7] Үзрә ислах улынды — юнәлешендә яңартылды.
[8] Шимдидән — моннан.
[9] Һәйәт — комитет.
[10] Низамнамә — устав.
[11] Гаид — каралы.
[12] Тәгъдиледер — гаделлеккә китерелүедер.
[13] Мөҗибенчә — буенча.
[14] Сарыф — морфология.
[15] Нәхү — синтаксис.
[16] Даир — караган.
[17] Тәртип вә тәэлиф — төзелгән һәм язылган.
[18] Тәкълид — кабатлау.
[19] Тәдкыйк улынып — тикшерелеп.
[20] Ихтива итмәсләр — тупламаслар.
[21] Тәкъсиматы — төркемләүләре.
[22] Назарән япылмамыштыр — эшләнмәгәндер.
[23] Мәүҗуд — бар булган.
[24] Кавагыйд — кагыйдәләр.
[25] Мөтәрәккый — алга киткән.
[26] Лисан — тел.
[27] Истикъбал — киләчәк.
[28] Интишарыны — нәшер ителүен.
[29] Гарз идекем — әйткән.
[30] Косур — кимчелек.
[31] Гаридыр — азаттыр.
[32] Әсаслы — төпле.
[33] Тәфтиш вә тәдкыйкы — өйрәнелүе.
[34] Җәридә — газитә.

игълам бер кыйсем[1] руханиларымыз арасында газыйм[2] һәйаҗан[3] тудырды. Һәйаҗанга килмеш руханилар «Оренбур мәхкәмәи шәргыя» («Дини идарә — **М. Г.**) мөфтисе Мөхәмәтьяр мирза Солтановка мөрәҗәгать итәрәк, Кәлам кадим (Мәңгелек Коръән — М. Г.) тәрҗемәсенең интишаренә[4] мохалифәт[5] вә мөманәгатене[6] риҗә[7] вә таләб итмешләрдер. Бән Казан имамнарыннан бәгъзеләрене күреп, бу бабта фикерләрен сорадым. Тәрәккыйпәрвар имамнар, әсасән, Коръән Кәримнең тәрҗемәсендә бер шәргый[8] манигъ[9] күрмәюрләр исә дә, лисанемезнең хәзерге хәлен вә биек вә вәбалле[10] тәшәббесне[11] яклый алмыйлар, шуңа күрә, телемезнең эшләнеп мөкәммәлләшмәсенә кадәр, тыелуны лазыйм күрәләр.

Казанның мөнәүвәр[12] яшьләре арасында яңа бер фикер мәйдан алмакта: балаларга мәхсус бәйрәмнәр булдырырга. Ригайә[13] вә хөрмәт итдекемез бәйрәмнәрдә үсмерләребез хәят вә мәгыйшәтләрен тәнәввегъ иттерәрәк[14], бераз истирахәт[15], бераз тәсалла[16], бераз шатырәт[17] була белеюрләрсә дә, сабыйларыбыз яшьләренә вә рухларына мөнасиб бер года, бер әкләнҗә[18] татылмаюрлар. Бу җәһәтлә, безнең кошчыкларыбыз сабый дәверләрен суык вә коры кичереюрләр. Әмма безгә күрше һәм аралашып яшәгән милләтләр — руслар, алманнар балалары өчен мөнасиб бәйрәмнәр оештыралар, моңа зур әһәмият бирәләр. Мәсәлән, Гайсә пәйгамбәрнең тудыгы көн болар арасында инде балалар бәйрәменә әйләнеп киткән кебидер. Күршеләребез белән мөнәсәбәттә булынганнарыбыз рус вә алман балаларының Гайсә туган көн җиткәнен нә кадәр дәрт вә иштияк илә көткәннәрен, үтеп киткәннән соңра ничә айлар хәтерләрендә саклауларын күреп беләбез. Һәм үз-үзләренә шундый сорау куялар: «Гаҗәба, безнең балаларыбыз да, рухан, мондый бәйрәмнәргә мохтаҗ түгелмедерләр? Мондый бәйрәмнәрнең тәрбиягә тәэсирләрен без ни белән алыштыра алабыз соң?

Менә шул иҗтимагый вә тәрбияви мәсьәләләр алдында калган «Шәрыкъ клубы» киләчәк мәүледеннәби (Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган көне — **М. Г.**) бәйрәмендә бер балалар кичәсе оештырырга карар бирде. Әгәр муаффәкыятьле[19] кичәрсә, һәр сәнә тәкърер итәрәк тәгъмименә[20] тырышмакчылар.

*Казан, 3 канун сани, гыйнвар, 1912.*

# УКМАСЫЙ ХӘТЕРЕНДӘ ӘМИРХАН

Татарның классик әдибе Фатих Әмирханның тууына быел 110 ел. Әдип хакында күп язылган, күп сөйләнгән, исеме дә, иҗаты да мәдәниятебез тарихыннан аерылгысыз. Шуңа да карамастан, тәрҗемәи хәленең аерым

[1] Кыйсем — өлеш.
[2] Газыйм — олы.
[3] Һәйаҗан — борчылу.
[4] Интишаренә — басылып таратылуына.
[5] Мохалифәт — каршылык.
[6] Мөманәгетене — тыюны.
[7] Риҗә — теләү.
[8] Шәргый — шәригать кушканча.
[9] Манигъ — тыю.
[10] Вәбалле — хәвефле.
[11] Тәшәббес — тәвәккәллек.
[12] Мөнәүвәр — мәгърифәтле.
[13] Ригайә — кабул иткән.
[14] Тәнәввегъ иттерәрәк — төрләндереп.
[15] Истирахәт — ял итү, рәхәт кичү.
[16] Тәсалла — юаныч.
[17] Шатырәт — житезлек.
[18] Бер года, бер әкләнҗә — болыннарда күңел ачулар.
[19] Муаффәкыятьле — уңышлы.
[20] Тәгъмименә — һәр җиргә кертүгә.

хасиятләре [illegible] укучыга һаман да тулысынча билгеле түгел әле. «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» китабын (1986) төзүчеләрнең берсе, аның иҗатын, биографиясен өйрәнүчеләрдән буларак, без монда аеруча басым ясауны тиеш табабыз. Эш шунда ки, мәгълүм тәгълимат кысаларында гамәл кылырга дучар ителгән авторлар әдип биографиясенә, иҗатына кагылышлы истәлекләрне теге елларда йә кыскартырга, йә фильтрларга, йә аннан да яманрагы, бөтенләй төшереп калдырырга мәҗбүр булдылар. Атап кителгән хезмәткә кертелгән 33 язманың да абсолют күпчелеге төрлечә редакцияләнде, шомартылды, тиешле-мәҗбүри калыпка туры килмәгән урыннары сызып ташланды. Әлбәттә, күбесе котылгысыз кабатлаулардан арыну хакына эшләнде боларның. Ләкин идеологик яктан «кытыршырак» Р. Алуши, И. Биккулов, Ж. Вәлиди, М. Бәдәйли һәм аеруча Ф. Әмирхан II истәлекләре бигрәк тә рәнҗетелде, аяусыз «эшкәртү»ләргә, ыспайлауга юлыкты. Шуның нәтиҗәсендә классик әдип тормышының байтак үзенчәлекле, каршылыклы яклары, кем әйтмешли, кадрның тышында калды.

Төрле «соображениеләр» аркасында Г. Толымбайский, Ф. Бурнаш, М. Сафин кебекләрнең истәлекләренә, гомумән, урын бирелмәде. Башка замандашларының язмаларына принципиаль яңалык өстәмәсәләр дә, ул чор җәмәгатьчелек фикерен чагылдыру җәһәтеннән үзләренчә игътибарга лаек иде алар. Шулай да иң зур каза Миргазиз Укмасый (1884—1947) истәлекләрен инкяр итүдә чагылды булса кирәк. Турысын әйтик, моңарчы «Атаклы кешеләр тормышыннан» дигән сериягә нисбәтле китаплар, «Хатирәләр», «Истәлекләр» калыбында яңгыраш тапкан хезмәтләр теге яки бу шәхесне йөз фаиз (процент) диярлек уңай җәһәттән генә сурәтләп килде. Аларның берсендә дә «атаклы шәхес»нең «кире» якларын тасвирлау түгел, аңа аз гына күләгә төшерүче мизгелләргә дә урын бирелмәде. Хәзер дә шул ысулдан ваз кичү бик күзәтелми. Хәлбуки, мондый «кершәнләү» изгеләр тормышын (урысча — «житие святых») сурәтләүне хәтерләтә һәм һичкайчан хакыйкатьне ачуга хезмәт итмәде һәм итми.

М. Укмасыйның Ф. Әмирхан турындагы истәлекләре бу җәһәттән аерым бер урын били. Алар шагыйрь тарафыннан 1940 елның 10 мартында Казанның Бишбалта Бистәсендә язылган. Гарәп имлясында стандарт булмаган ундүрт озынча бит тәшкил иткән әлеге язма Татарстан Фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивында саклана (16-ф., 2-тасв., 46-эш, 1—14 б.). Автор имзасын Миргазиз Укмасый — «Зәбиров» дип куйган.

Баштан ук шуны искәртергә кирәк, Укмасый үзенең истәлекләрен тоталитар хакимиятьнең иң кара, хәтәр-аяусыз дәверендә иҗат иткән. Бу тынчу чорда, беренчедән, милләтпәрвәр затлардан карачкы ясау, аларны сыйнфый яктан «фаш итү», «чын йөзләрен» ачып салу шаукымы канат җәйсә, икенчедән, «буржуаз» әһелләрне дөмбәсләп, алардан йөз чөереп, үз тиреңне саклап калу «ихтыяҗы» урләр яулый. Укмасый да, чирканыч чынбарлык алдында гаҗиз калып, мәдрәсәдәше, каләмдәше Фатихны «тук», өсте-башы житеш мулла баласы, буржуаз язучы булганы өчен нык кына тешли, үзенең ябагай чыгышын алга сөрә, Әмирханны морзаларга каләм әрәм итүеннән баш тартып, хезмәт ияләре хакына («Гайфетдиннәр өчен») язарга өнди, замандашының иҗатына уңышсыз елларда ук «дөрес» сыйнфый юнәлеш бирергә омтылганын исенә төшерә. Тәкъдирнең ирониясе белән, диикме, Укмасыйның Әмирханга тискәре дип биргән кайбер бәяләре хәзерге көндә әдипкә мәдхия булыбрак яңгырый. Укмасыйның үз «күге» дә бу дәверләрдә тәгаен аяз булмагандыр. «Буржуаз» әдип Ф. Әмирханның тетмәсен тетү йола төсен алган чорда (Ф. С. Казанлы, Г. Толымбайский әсәрләрен, Ф. Әмирхан II хатирәләрен генә искә алыйк), Укмасыйга да бу эшкә үзеннән өлеш кертүдән башка чара калмаган булса кирәк. Әмма классик әдип иҗатын бәяләүдә тиздән уңай тенденция дә үзен сиздерә башлый. Безнең уебызча, истәлекләр Ф. Әмирханның «Сайланма әсәрләр»ен басмага әзерләү барышында (1941 елда нәшер ителә) Хәй Хисмәтуллинның үтенече, йә булмаса махсус заказы белән язылган.

Инде аңлашылганча, Укмасый үзенең истәлекләрендә Ф. Әмирханны күкләргә чөйми, шәхесенә мәдхия җырламый, байтак кына мәсьәләләрдә аңа да, атасы Зариф муллага да кырын караш сирпеп уза. Мәдәни тарихыбызда мондый төр хатирәләр бар һәм аларга күз йому һич тә гадел булмас. Башкитмәле имәнеч заманда «сыйнфый яктан ят» әдипне нигездә каралту максатында язылсалар да, истәлекләр Ф. Әмирханның калку фигура булуын инкяр итмиләр. Ул гына да түгел, бу елларда яшь Фатихның үткенлеге, шәкертләр хәрәкәте җитәкчесе, матбугат эшлеклесе, күренекле әдип булуы, Тукай белән тыгыз хезмәттәшлеге, шагыйрьгә шифалы йогынтысы шактый анык күзаллана, Әмирханның киң карашлы зыялы булуы, урыс әдәбияты белән дә танышып-

кызыксынып баруы чагылыш таба. Иҗади яссылыкта үзен Фатихка каршы куебрак караса да, Укмасыйның үз вөҗданына хыянәт итәргә ашкынмавы сизелеп тора. Аерым урыннарда фактик хаталар, хронологик тайпылышлар, субъектив-тенденциоз фикерләүләр (Рәшид казыйны түбәнсетү, үзен социал-демократларга нисбәт итү, Х. Ямашев абруена сыенырга омтылыш шундыйлардан) очраса да, истәлекләрнең кыйммәтле яклары байтак. Аларда башка хатирәләрдә очрамаган кызыклы эпизодлар, XX йөз башы мәдәниятенә, әдәбият үсешенә, аерым шәхесләргә кагылышлы «таушалмаган» күзәтүләр теркәлгән.

Истәлекләрдә гади укучы гына түгел, тикшеренүчеләр дә барып «төртелерлек» урыннар байтак. Шунлыктан текстка искәрмәләр бирү тиеш табылды. Мондый төр язмаларны басмага әзерләгәндә моңарчы хөкем сөргән кыскарту, шомарту, ялтырату кебек гайре тарихи принциплардан ваз кичеп, без хатирәләрнең бер тәгъбирен генә түгел, сыңар хәрефен дә үзгәртмәдек (хәер, артык күплекләре сәбәпле, саннарның байтагын сүз белән бирергә туры килде). Текстологик эш шуннан гыйбарәт булды: гарәпчә имля кириллицага күчерелде, житешмәгән сүз яки хәрефләр квадрат җәяләр эчендә бирелде, тыныш билгеләре бүгенге кагыйдәләргә буйсындырылды, тоташ урыннар абзацларга аерылды, артык озын, чуалчыграк җөмләләрне ике-өч кисәккә бүлү кулай табылды. Авторның стиле, сүз сөреше, фикерләү алымнары, аерым очракларда орфографиясе («имнәү», «хәрәмнәү» һ. б.) шул килеш сакланды, искәрмәләре текст эчендә үз исеме белән күрсәтелде. Төзүче-шәрехләүче буларак, үзебезнең искәрмәләрне текст тышына чыгаруны, кайбер сүзләрне тәрҗемәдә бирүне мәгъкуль күрдек.

Ышанабыз ки, төрле архив фондларында, шәхси кулларда үзенең эшкәртелүен, актив әйләнешкә кертелүен әле һаман да зар-интизар булып көтеп яткан һәр истәлеккә шундый «тулылык калыбы» белән (әлбәттә, искәрмәләр белән) килә торган булсак, без үзебезнең мәшһүр шәхесләребез, мәдәни мирасыбыз, гомумән, милли тарихыбыз хакында тагын да төплерәк, колачлырак мәгълүмат хасил итәчәкбез.

**Равил ӘМИРХАН.**
5 ноябрь 1995 ел.

# ФАТИХ ӘМИРХАН ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Ачык әйтә алмыйм: «мәдрәсәи Мөхәммәдия»гә 1897 нче елда укырга килдем, шул вакыт Фатих Әмирхан рөшди сыйныфында бер ел миннән алда бара иде. Бу вакыттагы рөшди сыйныфы «Мөхәммәдия»нең хәзерге бинасы күршесендә булмыйча, капка асты юк, ул урын буш, йорт салынмаган, хәзерге капкадан кергәч тә уң якта, Йосыф мулла мәдрәсәсеннән эчтәрәк кечкенә генә бер катлы йорт иде[1]. Шул чагында Ф. Әмирхан, капкадан кергәч уң яктагы бер катлы таш йортта, мин килгәндә беренче яки икенче рөшдидә укый торган шәкерт булып, без мәдрәсәдә куныш торып укысак та, ул алай булмыйча, иртә белән Ф[атыйх] һәм И[браһим] Әмирханнарны бик матур кара ат белән өстенә калын толып кигән кучер мәктәпкә китереп куя торган иде.

Аларның кулларында сумкалар, өс-башлары шәһәрчә матур киенгән. Без, бала булу сыйфаты белән, Казан мулласының балалары дип аларга сокланып карап тора идек. Алар төшке аш вакытында ләвәшләр, сумсалар ашыйлар, без авылдан килеп, озак вакыт уку сәбәпле, күгәрә төшкән икмәк ашыйбыз, жылы аш күп вакытта юк. Болар жимертеп кич белән тагын кучер белән өйгә кайтып китәләр, жылы, тәмле аш, иртә ана чырае күрәләр, йомшак урында йоклыйлар, теләгән вакытларында мунча, ашарга теләсәләр, кәләвә, төсле кәгазь, карандаш — барысы да болар кулында иркеле дип, мин үзем шәхси боларга кызыга идем.

Икесенең дә төс-бит бик матур, килештереп тегелгән киемнәр, житмәсә, алар төрле модага алмашынып торалар. Син бер камзолга яки бер чалбарга мохтаж, алар аны төрле фасонга алмаштырганга, безнең күк ярлы авыл шәкертенә бу бик зур алдынгылык, бәхет күк тоела иде. Һәм утырачак та күк тоелмый торган матур, утыра торган урыны киң, асты тар, бик юка табанлы матур чана белән, кара атның өстендә «көмешләр» тезгән шләя, җинел камыт, нечкә тубылгы дуга, тар каештан эшләнгән, «көмешләр» тезелгән җүгән, аның тезгенен икегә аерып, дуганың ике ягына тарттырып куелган тасма дилбегә. [Кучер] шул ат белән мәдрәсә алдына тукталган да, Әмирхановларны көтә. Алар, дәресләрен бетерүгә, ашыкмый гына икәүләп урамга чыгалар, без, авыз суыбызны кортып, аларны карап торабыз. Ямщик алар утыра торган яктан чана алдына япкан тирене ачып, аларны утырта һәм алларына тагын теге тире юрганны ябып, тасма дилбегә белән атка чиртә дә, алар шул вакыт күздән юк булалар.

Менә мин, аякта агач башмак, авылдан яңа килгән малай, боларга карап сокланам, әле үзем Казанның рәтен белмим, «Мөхәммәдия»дә Кәрим хәлфә кул астында нәхү кыйсме, тәҗвид, бәдәэлмәгариф, матур язу, Коръән дигән нәрсәләрне укып йөри торган бер малай, бу көнгә кадәр мин язуны, дөрест булмаса да, танып беләм. Әмирханнарның зурлыгына, Казан йортларының зурлыгына, мәчетләрнең зурлыгына, анда җәелгән яшел сукнола [р]га, «зур» кешеләргә исем китә. Ләкин мине, авылдан килгән малай дип, теләсә кем кыерсыта, мин өч юл чатында үскән каен күк, теләсә кем... (бер сүзе танылмый.— **Р. Ә.**) миңа суга. Безнең мәдрәсәдә ул вакыт электр юк иде, бервакыт Ф. Әмирханнар укый торган бүлмәгә барып кердем, электр чыбыгы үткән һәм лампасы куелган, ләкин ут кына җанмый. Моны да эшләткән кеше Фатих Әмирхан иде, мин моңар да зур таңлану белән карап тордым.

Минем Яңа Бистәдә җизнәләрем бар икән, атам килгәч, аларга алып барды. Аның исеме Вәли Сәйдәшев булып, Әхмәд байда конторда эшли торган бер түбән (текстта шулай.— **Р. Ә.**) язучы иде. Мин шуннан соң бу җизнигә һәр атнакич бара торган булдым, чөнки аларда аш ашап кайта торган идем. Шуның белән бергә монын мунча алачыгы күк бер кибете яки өй алдысы булып, анда күмәч, күмер, утын, варенье, кәгазь һәм конфет булып, бөтен суммасы ул вакыт хисабы белән 30 сумнан артмаган товар булып, шунда авылда кузна уйнап үскән Хәсиб Төхфәтуллин дигән, миннән берәр яшь өстен күршебез малае, минем иске дустым, жалуньясыз приказчик булып торганга, ул миңа туйганчы ашарга күмәч бирә һәм «Шау күмер» дигән пекарня тотучылардан аның белән күмәч алып кайта торган идек. Мин һәр атнакич көнне туйганчы күмәч ашый торган идем.



*Фатих Әмирханның Кабан күле буена сәйранга чыккан вакыты. Дилбегәне тотучы үсмер — Мәгъсүм булырга тиеш. 1909—1910 еллар тирәсе.*

Менә шулай Яңа Бистәгә килеп йөргәндә Ф. Әмирханнарның йортларын да[2], аталарын да белдем. Алар Вәли җизниләрнең нәкъ күршеләре Зариф мулла балалары икән. Аларның капкалары хәзерге вагон йөри торган урамда, беренче мәчеткә[3] каршы кыйгач, наискосок салынган булып, ләкин йортлары капкадан байтак эчтә, ишек алды түрендә, ишек алдына аркылы салынган иде. Мин аннары аталарын да күрдем. Ул урта буйлы, җуан, калын матур тавышлы, бер дә пошынмый торган, киеменә ут төртсәң дә, ашыкмый торган бер кеше иде. Ләкин Яңа Бистә халкы аны башка сыйфаты белән түгел, тавышы матур дип җараталар иде. Мин аның җомгасында күп вакыт була торган идем. Чөнки син шәкерт, дип Вәли җизни алып бара торган иде. Аның вәгазь сөйләгәнен мин бер дә белмим. Мәчеттән чыккач, Вәли җизни: «Шәпме безнең мулла» — дип сорый торган иде. Мин, шәплеген-фәләнен белмичә, җавап булганга, «шәп» дип җавап бирә торган идем. «Шәп шул, тамагы бик матур бит аның»,— ди торган иде.

Сүз җае килгәндә, урынсыз булса да, язып узыйм, бу урынга икенче җизнәм Садыйк Сивиргузин хуҗа булгач, ул Вәли җизнигә караганда яшькә сазаган һәм дөньяның бик нык әчеләрен татыган кеше булып, шул ук Зариф мулладан аз гына, бер-ике яшьләр түбән булганга, аның бик күп интимный эшләрен миңа сөйләгәне бар. Бервакыт, ди, Мәңгәргә кунакка кайттык, ди. Зариф мулла яшь иде әле, ди, аның сөеп, орынтын тота торган бер кызы бар иде, ди. Пар ат җигеп, мин ат башына утырып, Дегтярный урамнан шул кызны Мәңгәргә җыенга[4] алып кайтып киттек, ди. Трантас артына чыпта белән төреп ике кәрзинкә сыра бәйләдек, ди, ат башысы астына кызыл аракылар тутырдык, ди, әлеге кызга чапан яптырып, авылда аны Зариф хәзрәтнең остабикәсе бу дип таныттык, ди. Мәңгәрнең кемдер бер баенда бер атна гулять итеп, рәхәтләнеп кайттык, ди. Моннан соң да мондый эшләребез күп булды, ләкин мин серле булганга, башка кешеләргә мондый эшләрне белгертмичә, миңа гына белгертә торган иде, дип сөйләгәне, моннан башка вакыйгаларны да сөйләгәне бар булса да, мин монда, төп максат ул булмаганга, аларга тукталмый китәм[5].

Менә шулай итеп мин Фатих Әмирханнарның йортларын да, аталарын да белдем. Ул, шәһәр малае, уку эшенә миннән алдан тотынганга, ул миннән бер-ике сыйныф югары барадыр иде. Хәтеремдә ялгыш калмаса, Вафа Бәхтияровлар[6] белән сыйныфташ, ул безнең белән Бишенче ел революциясеннән бер яки ике ел алдан катнаша башлады, чөнки бу чорларда шәкертләр эчендә яңалык теләү, уку системасыннан ризасызлык, укыла торган программның хәят өчен кирәкле шартларга алып бармаганлыгы аңлашылды. Моның сәбәбе: мәдрәсә галәменә, бердән, «Тәрҗеман» газитәсенең[7] тәэсире булса, икенчедән, төрек газитәләре һәм мәдрәсәгә төрле яктан килеп-китеп, шәкертләрнең эч үзәкләренә катнашып йөрүче. Төркия тәрбиясендә үскән милләтче агитаторлар иде. Шулай ук Бакуда чыга торган «Шәркый рус» газитәсенең[8] дә тәэсирен юк дип әйтеп булмый. Шул чорларда мәдрәсәдә кружоклар оештырылып, ләкин ул кружоклар, үзенчә булса да, сыйныф, «класс» системасында иде. Монда хәлфәләр, мәдрәсәнең «зур» саналган сыйныфлары үзләренә бер кружок төзесәләр, безнең күк түбәнрәк шәкертләр үзебезгә аерым кружок төзегән идек.

Безнең кружок башында яки аның житәкчесе булып Фатих Әмирхан тора иде. Мин хәзер бу кружокның төп программасын әйтә алмыйм, чөнки ул нигезле бер программага таянмаган, бәлки чикле рәвештә мәктәп- мәдрәсәләрне ислах, «милләтне тәрәккъый» иттерү нигезендә иде. Без һәр атнакич бер кружок членнары бергә җыелабыз, җыелу урыныбыз урамга караган мәдрәсәнең уртанчы катында дәресханәдә булып, кружок членнары һәркайсы бу җыелышка бер язма материал белән килергә мәҗбүр иде. Әнә шунда Фатих Әмирхан рәислек итә, бөтен әгъзалар шул җыелышта үзләре хәзерләгән материалны укыйлар, соңра аны язма рәвештә Ф. Әмирханга тапшыралар иде. Безнең бу кружогыбыз өч елларга тартылды булырга кирәк. Шунда укылган һәм язылган материаллар һәркайсы Ф. Әмирхан кулында кала килде, аларны Фатих кайда куйган, мин моңар җавап бирә алмыйм.

Безнең бер җыелышыбызда почетный кеше булып Петербурдан (Ленинградтан) килгән Рәшид казый Ибраһимовның[9] катнашканын беләм. Ул инде безнең өчен «зур акыл иясе» булып хисапланганга, без аның алдында бер сүз әйтергә дә кыймыйча, аның сүзләрен акыллар хәйран булып тыңлыйбыз, ул үзенең сөйләгән «речь»ләрендә мәдрәсәләрнең яраксызлыгын, хәзерге мәдрәсәләр [гә], анда укыла торган мантыйклар урынына физика, математика, ягрофия, төрек һәм татар теле, шуның белән бергә, фәлсәфәсе белән бергә, Коръән тәфсире вә хәдисләр керергә тиеш икәнен сөйли. Без ансыз яшь бу[ы]ннарга милли яктан тәэсир итеп, Европа милләтләренең аң-белем ягыннан күтәрелеп, безнең йокы хәлендә икәне-

безне, «Казан халыклары»н, «Чыңгыз балалары», татарларның бөтен Европаны тетрәтүләре»н, гарәпләрнең ислам галәме саф вакытта шәрекътән гаребкә кадәр үсүләрен, безгә дә шул үткән тарихны яшь буыннар тергезергә тиеш икәнне сөйләп, безне таң калдыра. Без әле ул чорда сәяси белемебез юклык аркасында растлап, бөтен йө[р]әгебез белән шул «адәм»не ихтирам итәбез. Без шунда Чыңгызны да, Чемберленны[10] да, Николай II не дә бар да бер кеше икәнен аңламыйбыз, ул гына да түгел, шул юлда безне агулаучы бер пычракны җан күңелебез белән ихтирам итәбез. Әй, бүгенге сәяси аң булсачы, безнең бу кружокта күп нәрсәләр-күп нәрсәләр укыла иде (текстта ике тапкыр — **Р. Ә.**). Шул материаллар бар да Фатих Әмирханда калып, аларның бу көндә саклану урыннары бардырмы-юкмы, мин анысын белмим, ләкин ул материаллар бик күп булырга тиеш.

Бүгенгедәй хәтеремдә, шушындый кружок 1904 елда күңел ачу җыелышы үткәрде, гыйнвар числоларында булырга тиеш. Мәдрәсәнең капкадан керүгә уң як башында ул вакытта шәкертләр урнашмаган буш бина, «Сахалин» дип йөртелә торган бер почмагы бар иде. Аның «Сахалин» аталуына сәбәп тә мәдрәсәнең иң аргы башы, шуның белән бергә паровой отопление кертелмәгән һәм кеше тормый торган ялгыз бүлмә булганга, шул исем бирелгән иде. Безнен әлеге кичәбез менә шунда булды.

Ул вакыт гармун, скрипка яки башкача уеннар мәдрәсә эченә керә алмыйлар. Без беренче тапкыр күргән симпиньонны[11] (текстта шулай — **Р. Ә.**) Ф. Әмирхан кайдандыр алып кайтып, шул җыелышка китерде. Ул төрле татар көйләрен уйный, без искиткеч рухланабыз, дөньяда моннан да зур «шәп мәҗлес» юктыр төсле представить итәбез, ул ниндидер бер марш уйный, без тезелеп, кулга-кул тотынып, тансыга охшаган бер хәрәкәт белән, ләкин һичбер тәртипкә салынмаган рәвештә шул симпиньон тирәсендә әйләнәбез. Бик фәкыйрь генә үзенчә бер буфет сымак нәрсәсе бар, ул бер дә сату итә алмый, чөнки бер шәкертнең дә акчасы юк.

Шуннан соң кружок әгъзалары үзләре язган нәрсәләр белән выступать итteләр. Болар беткәч, без симпиньонга да гадәтләнгәч, мәҗлеснең төзелгән бер программасы юклык сәбәпле, мәҗлес үз-үзеннән сүрәнләнеп, ахырында күңелдә бер йогынты да ясый алмыйча, таркалды. Ләкин Фатих Әмирханның монда төп теләге: шәкертләрне әдәбия[т] кичәсе, аның төзелеше белән таныштыру иде. Ф. Әмирхан бу кичәдә активный катнашып, симпиньонны үзе борып, төреп һәм танса юлларын да үзе организовать итеп йөрде.

1905 нче ел революциясе шәкертләр арасына әллә ничегрәк килеп керде. Фатих Әмирхан кружокта безне «Марсельеза», «Похоронный марш» һәм башкача революционный җырлар белән таныштырып, без боларны барысын да язып алып һәм аларның русчасын, шулай ук татарчага тәрҗемә ителгәннәрен һәркайсыбыз җырлап йөри башладык. Шул ук кружокта без халык арасында төрле партияләр бар икәнен, кадетлар, социал[ист] — революционерлар, социал-демократлар, максималистлар бар икәнен аңладык.

Аңладык дигәч тә, программалары һәм тоткан юллары белән детально танышып түгел, исемнәре белән таныштык һәм кайсы партиянең кемнәргә, нинди сыйныфларга опираться итүләре белән таныштык. Кадетлар партиясе зур байларга, русның милләтче сыйныфына, помещикларга, социал[ист] — революционерларның крестьяннарга, социал-демократларның завод-фабрикада эшләүче рабочийларга таянганын белдек. Шулай да бу соңгы ике партиянең кайсы дөрест юл белән бара, без кайсын алда күрергә тиеш, моны аера алмый идек. Икесенең дә бара торган юлы, теләге бертөсле күренә иде. Шуңар күрә без үзара обсуждать иткәндә, мин социал-демократия партиясен[12], тегe с[оциалист]-революционер партиясен алга куя, ләкин бер-беребезне җиңәрлек, хаклыкны җарып салырлык икебездә дә көч юк.

Моны Фатих Әмирхан да ачык әйтеп бирә алмый. Бары Хөсәен Ямашев кына моны миңа бик нык доказательстволар белән төшендереп, ул с[оциалист]-революционерларны җыртып салды. Алар ялганлыйлар, крестьянга таянган төсле күренәләр, ләкин крестьян алар өчен бер вакытта да таяныч булачак түгел, крестьян үзе дә катлаулы, аның бер катлавы кадетлар юлына иярепл, икенче катлавы рабочийлар белән кулга-кул тотынып барачак, димәк, эсерларның программалары тыштан караганда изелгән халыкларны коткару төсле булып күренсә [дә], бу күз буяу гына булып, алар шул ук кадетларга барып тоташачаклар, рабочий өчен дә, ярлы крестьян өчен дә алардан он да юк, йон да юк, диде[13].

Мин монда кыска язам, ул миңа бу турыда озак сөйләде һәм төшендерде. Мин шуннан соң эсерларны кызыл күлмәк киеп йөрүдән башкага ярамаган, кайберсе алданган, кайберсе — алдакчы һәм революцияне булдырмаска юл эзләп йөрүче бер партия икәнен яхшы аңладым.

1905—1906 нчы елны булырга кирәк, кружокта Фатих Әмирхан безгә бер значок күрсәтте. Ул көмештән эшләнгән булып, анның төзелеше ук, җәя һәм укның өстендә нечкә ай белән йолдыз ясалган иде. Без бик кызыксынып алып карадык һәм безнең һәркайсыбызга шуны ясатып алып, тагып йөрергә кушты. Без: «Бу нәрсә соң?» — дип сорадык. Җавабында: «Монда «Болгар» нумирәсенә Будапешта профессоры, мадьяр, «мажар» Мәйсуруш (хәзерге язылышы: Мессарош.— **Р. Ә.**) исемле кеше килгән, без мадьярлар белән бер нәсел, аларның знаклары ук, җәя булып, безнең нечкә ай эчендә йолдыз булганга, алар белән без бер нәсел икәнебезгә билге булсын өчен бу галәмәтләр бергә тоташтырылырга тиеш»,— диде. «Соң ул профессор монда нинди теләк белән килгән?» — дип сорадык. «Анның теләге — татар һәм чуаш телен өйрәнеп, җола-гадәтләренә төшенеп, шуларны үз тел вә җола гадәтләре белән чагыштыру»,— диде һәм шундук: «Менә аңар татарның такмак, такмаза, хикәя, табышмаклары белән таныштыручы бер кеше кирәк, атнага ике көн чуаш теле, дүрт көн кич белән татар телен өйрәнү өстендә булачак, һәр дәрескә 50 тиен акча түли, шул эшне кайсыгыз өстенә ала?» — диде.



*Фатих Әмирхан апасы Сәгадәтбануның улы Зәкәрия белән Кырымның «Гастрия» шифаханәсендә. 1925 елның 3 ноябре.*

Хуҗа Бәдигый[14] алды һәм ул Мәйсуруш белән кыш буенча шөгыльләнеп, җәй көне татарлар арасына, җола гадәте өйрәнү өчен татар авылларына чыгып киттеләр. Хуҗа Бәдигый Мәйсурушка өйрәтү өчен кыш буенча шәкертләр арасыннан борынгы җырлар, мәкаль, такмак, такмаза, татар телендә имнәү сүзләре, «кетер-кетер»,— «кытыр-кытыр», «чебер-чебер», «шабыр-шобыр» күк сүзләре арасындагы мәгънә аермаларын бергә обсуждать итеп, җыеп, һәр кич Мәйсурушка илтеп тапшыра һәм шуннан җыелган бөтен материалларны үз кулында да язып калдырып бара иде.

Бу вакытларда бездә рухта зур күтәренкелек, дәрт, энтузиазм кайнап җанып тора, без мәктәп-мәдрәсәләрнең җитешмәгән якларын бик нык тикшерәбез, татар теле өчен кагыйдәләр, сарыфы, нәхүе булырга тиеш икәнен, аңар юллар, кагыйдәләр хәзерлибез, шуларны тикшерәбез, шәрекъ логикасына караган «Исагуҗи», «Шәмсия» күк китапларны җыртып бетереп, тәрәзә аркылы бәрәбез, хәлфәләргә рәтләп буйсынмыйбыз, мантыйк — «логика» дәресләренә беребез дә кермибез.

Көз көне безнең кружокның гына түгел, бәлки бөтен мәдрәсә күләмендә булган шәкертләрнең җыелышлары булды. Анда мәктәп-мәдрәсәләрнең программ һәм укыту юлларының төзелешен, нигезеннән алып үзгәртү кирәк икәнен сөйләдек. Чыгып сөйләүче «оратор»лар бик күп булды, һәркайсы үзенең планын тәкъдим итте. Менә шунда Фатих Әмирхан да чыгып сөйләп, үз речендә ул бу реформаның акчага бәйле булганын, бу реформаны мәдрәсәләргә кертергә һичбер Казан баеның риза булмаячагын, буржуй-байларның моңар начар караячаклар [ын] һәм мәдрәсәләргә биреп бара торган финансовый поддержкаларын өзәчәкләрен, бу реформага без ирешә алу өчен Петербурга вәкил җибәреп, хөкүмәт белән сөйләшергә һәм татар халкыннан җыела торган земский сборның мәгарифкә китә торган процентын татарларның үз мәктәп-мәдрәсәләренә бирелергә тиеш икәнен доказать һәм таләп итәргә тиешбез, диде.

Без[нең] бу шәп акылга исебез китте, вәкил җибәрәбез, Петербур (Ленинград)ка кеше җибәрәбез, кемне сайлыйбыз, бу эшне кем башкарып кайта алыр, дигән обсуждениеләр башланды. Ф. Әмирхан тагын торып, «вәкил җибәрербез,

ләкин аны сайлаганчы аның юл расходлары, ашау, йөрү расходлары бар, элек шуны карарга кирәк»,— диде. Без һәр шәкерттән 50 тиен акча алып, бу чыгымны тәэмин итәргә дигән карарга килдек. Инде вәкил булып бару өчен кандидатлар күрсәтелә башлады. Кайсы әйтә Әкрәмне сайлыйбыз, ди.

— «Бик йомшак, бер авыз рус теле белми, сөйләргә бик ярата, төпле бер сүзе юк, сүз белән сүз арасын ун минут исәпләп тора, күзен йомып, йозрыгын йомып, һәр биш сүзгә бер «миллэт артта», «милләтне тәрәккъый иттерергә кирәк», дип үзе сүзе белән тыңлаучыларны йоклата». Кайсы: «Вәли карины сайлыйк», һәм башкалар.

Бу кандидатлар эчендә Ф. Әмирханның да кандидатурасы алга сөрелеп, соңра бер авыздан Ф. Әмирхан Петербурда югарыда сөйләнгән мәсьәлә белән министр просвещениягә кереп сөйләргә вәкил булып сайланды. Юл расходына безнең һәркайсыбыздан 50 шәр тиен акча җыеп алдылар. Һәм Петербурда министрга керү өчен Фатих Әмирхан своеобразный җөббә тектерде, шуннан соң ул Петербургка барып кайтты[15]. Нишләгән, кергәнме, ни җавап алып кайткан, Дума әгъзалары[16] белән бу турыда сөйләшкәнме. Без берсен дә белмәдек. Ул да сөйләшмәде һәм отчет та бирмәде, бу мәсьәлә шулай тып-тын сүнде һәм билгесез калды[17]. Ләкин шунысы мәгълүм булды, ул Петербурда Шамил[18] белән күрешкән, бусы Мәскәүдә «Тәрбияи әтфаль» журналы чыгарачак икән, Әмирхан шул журналны чыгарышырга һәм анда язышырга, Мәскәүгә барырга вәгъдә биреп кайткан.

Шуннан соң Ф. Әмирхан Мәскәүгә китеп «Тәрбияи әтфаль» журналында эшли башлады[19]. Исеменнән дә күренә, бу журнал балалар тәрбиясе өчен чыгарыла торган бер журнал иде. Ф. Әмирхан анда баргач, бу журналга «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» дигән хикәяне бастырып, аңар үз имзасын куйган иде[20]. Мин Фатихтан бер очраганда: «Бу хикәя үзеңнекеме?» — дип сорадым. «Үземнеке»[21], диде, ләкин мин бу хикәяне моннан биш-алты ел элек Лаеш өязе Күгәрчен авылында булган рус теле мәктәбендә укыган идем. Шундый мәктәпләр өчен Радлов[22] та «Белек» исемендә бер уку китабы төзеп, бу хикәя аның китабында бар һәм заглавиесен «Шыксыз бәпкә» дип атаган иде[23]. (Бу хикәянең язучысын белсәм дә, хәтеремнән чыгу сәбәпле монда күрсәтә алмадым[24].— Миргазиз Укмасый искәрмәсе). Ләкин аны Ф. Әмирханның үзенә әйтмәдем. Радловның бу уку китабы нәгыз татар теле белән язылган, бер генә дә гарәп яки рус сүзе юк, күләме 200 битләрдән азрак артык булып, татар телендә мәктәп балалары өчен язылган уку китабының иң беренчесе булырга тиеш. Шунлыктан бу китап — «Белек» тарих һәм тел төзелеше ягыннан зур әһәмияткә ия була ала. «Белек» нәгыз татар телендә булу һәм сүз төзелешләренең матурлыгы ягыннан һәрвакыт үрнәк була алу белән бергә, моны төзү эшендә кемнәр булышкандыр, анысын мин әйтә алмыйм, ләкин моңар Каюм Насыйрилар һәм аннан алдагы язучыларның катнашлары барлыгында бер дә шик юк. Бу китапны Мөхетдин Корбангалиев[25] белә һәм хәтерли торгандыр дип уйлыйм.

Ф. Әмирханның мин жандармнардан да качып йөргәнен хәтерлим. Ул көндезләрдә Яңа Бистәгә аталары йортына кайтканда ал капкадан кермичә, үзенә хас арт юлдан, хәзерге чуен юл киткән яктагы урамнан керәдер иде, ләкин кичләрдә өйгә кунарга кайтмыйча, читтәге танышларында йоклый иде. Һәм Ф. Әмирхан [ның] бер вакытны «Музуров номерасында»[26] торганын да хәтерлим, шунда мин аның номерасына кердем, янында матур гына бер гимназистка бар иде. Ул чыгып киткәч: «Укмасый! Бу маржа кызлары бик матур булалар, ләкин картайгач аларның карчыклары бик ямьсезләнә»,— диде.

Ф. Әмирхан Мәскәүдән авырып, паралич сугу сәбәпле кайтты[27]. Ул авырып ятканда мин хәлен белү өчен йортларына бардым. Үзе карават өстендә, кулында нииндидер бер китап, шуны укып ята.

— Нихәл, Фатих,— дидем.

— Менә, син күргәнчә, авырыйм,— диде.— Дуслар сау вакытта гына тирәҗүнеңдә кайнышлар, авыргач, бар да качып бетәләр,— диде.

Без нәрсәләр сөйләшкәнбез, аны хәтерләмим, ләкин авыруының сәбәбен сорагач, «Мәскәүдә трамвай юлын аркылы чыкканда гына шушылай булдым, ахры, электр тәэсир итте бугай»,— дигән сүзен хәтерлим[28]. Аннан соң ул кул белән хәрәкәткә китерә торган, «үзен үзе йөртергә» резинка тәгәрмәчле бер арба алып, шуның белән урамга чыга һәм шул арбада килеш урамда капкалары янында һәрвакыт йә гәзит яки берәр кенәгә укыганын күрә идем.

«Әл-Ислах» газите рәсми чыга башлагач[29], ул һәр көн аның редакциясенә килә. Фатихны анда ат белән кучерлары китереп, кич белән килепалып китә иде. Мин бервакыт «Әл-Ислах»ка басарга бер шигырь бирдем. Шул шигыремдә «мөлаем керфекләре сыйпап сөйдерә», дигән бер җмләне укыгач, бу сүз удачно чыккан, керпекнең күңелгә каты, сөйкемсез тәэсир итә торганнары да күп була»,— диде. Мин бу газиткә шигырь биргәндә аны бик җентекләп тикшерә, житешсез, җогышсыз урыннарын тәнкыйть итә, төзәтергә куша, кайбер сүзне берсен икенчесе белән генә алмаштырырга туры килгән вакытлар була иде. Аның кулында каләм, миндә юк. «Әйдә, төзәтеп куй инде»,— дигәч,— юк, мин төзәтмим, ул җинаятькә батырчылык итмим. үз кулың белән төзәт, әсәрең — синең балаң, син аны үзең тәрбия итәргә, үзең киендерергә, чишендерергә тиеш»,— ди торган иде[30].

Бервакыт без шулай укып торганда ишектән Г. Тукай килеп керде.

— Нишләп йөрисең,— Тукай? — дидем.

— Ул бала әле, балалар белән кузна уйнап йөри,— диде Ф. Әмирхан. Һәм Тукай кесәсеннән морҗа артына кузналар бушата башлады. «Нишләп син сакалың сәрияйтеп («сәлперәйтеп» булырга тиеш.— **Р. Ә.**) кузна уйнап йөрисең?» дигән сорауга каршы Тукай: «Бала вакытта уйнап булмады, шуның үчен алам»,— диде. Шуннан соң Ф. Әмирхан белән кузна уйнагандагы эффектларны, ничек атуларын, бер малайның хәрәмнәвен, моның ата торган чөененең бик удачный икәнен сөйләргә керешге. Ф. Әмирхан иронически көлеп: «Бик зур эш бетердең инде»,— диде.

Ул вакыт җоласы буенча ураза һәм корбан бәйрәмнәрендә белгән дуст-иш, гаеттән чыккач, өч көнгә кадәр бер-берсенә кунак булып бару, йортка кереп чәй эчеп чыгу гадәте бар иде. Шуңар күрә һәркем кулыннан килгән дәрәҗәдә өстәл һәм анда ашамлык нигъмәтләр хәзерләү гадәте бар. Вә килгән кунакларны каршы алу гадәте бар иде. Галимҗан Баруди[31], «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөдәррисе, күп елларга кадәр шул мәдрәсәдә укыганда бәйрәм кунакларын каршы алу өчен Ф. Әмирханны чакыра. Өч көнгә кадәр ул анда Барудига килгән кунакларны каршы ала һәм сыйлый иде. Чөнки Фатих андый югары катлау арасында булган тәкәллеф, йола-гадәт һәм алар белән сөйләшү җаен белә иде. Шуның белән бергә, безнең күк тартынып, кыюсызланып тормыйча, батыр сөйләшә. Шул сыйфаты өчен аны Баруди мулла күп вакытлар мәҗлес уздырганда үз янында йөртә иде.

Кай елларда икәнен хәтерләмим, «Әл-Ислах» газите рәсми чыга башламас борын подпольно чыгарыла иде[32]. Менә шуның редакциясенә бервакыт жандармнар тарфыннан тентү кереп, анда аның пичәтен, берникадәр кәгазьләрен кулга төшереп, шулар белән бергә Нургали Мамин дигән бер егетне дә кулга алганнар иде[33]. Бу тентүдән берәүгә дә бер зыян булмады, шулай булса да Ф. Әмирхан бу чорларда качыбрак, өйләренә кайтмыйчарак йөрде.

Ф. Әмирхан бер вакытны «О повешенных семи людях» (бу әсәр Леонид Андреевныкы булырга тиеш.— Миргазиз Укмасый искәрмәсе) дигән хикәяне тәрҗемә итеп, аның исемен дә «Асылган йиде кешеләр хикәясе» дип тәрҗемә кылган һәм аны шулай бастырып та чыгарган иде[34]. Шул хикәя чыгуның өченче көнендә мин аның белән Яңа Бистәдә, урамда очраштык, сүз шул хикәя турында барды. Мин хикәянең телен яратканлыгымны сөйләдем, шулай да моны бик ашыгып тәрҗемә кылганын отмечать итеп узгач, исеменең дә ялгыш тәрҗемә ителгәнен әйттем. «Ничек кирәк соң?» — диде. «Татар телендә саны исеменнән соң килә торган исем һәрвакыт күплек булып язылмыйча, берлек булып кына языла һәм сөйләнә»,— дидем. «Монда «йиде» саны үзе күплекне күрсәтә, аннан соң килә торган «кеше» дигән исем, күплек булып язылмыйча, берлек булып кына язылырга тиеш һәм дөрест тәрҗемәсе «Асылган йиде кеше хикәясе» дип кенә тәрҗемә ителергә тиеш иде»,— дигәч, бераз уйлап торды да: «Ах, черт возьми, промахнул»[35],— диде.

Аның «Хәят» дигән әсәре мәйданга чыккач[36], тагын шул ук Яңа Бистәдә обсуждение ясадык. «Ничек, ярattыңмы, Укмасый?» — дип сорады. Мин тартынмый әйттем:

— Фатих,— дидем,— мин ул «Хәят»та булган типларны яратмыйм, алар төче типлар, морзалар, урталыкта калган халыклар типлары, аларның беркемгә дә кирәге юк. Каләмең, шиксез, матур, ләкин әдәбиятка андый типларны кертмәү кирәк иде. Без аларны укымый, болай күреп тә тук, аларга хезмәт, кәгазь әрәм, дигәч.

— Син дә, мин дә ул типларны кертмәсәк, алар «фи нәфсеһи», ягъни чын-чынлап караганда хәятта бар бит, аларны ничек отрицать итәсең,— диде.

— Алар барын бар, ләкин аларның беркем өчен дә кирәге юк, шунар күрә без аларны юк дип белергә тиеш,— дидем.

— Соң менә үзең дә барлыкларын икърар итәсең бит,— диде.

— Мин әйтсәм дә аларны сан дип һәм кеше дип түгел, алар хакында хикәя язсам, аларның шул түбәнлекләре, мин-минлекләре, паразитлыклары турында язар идем, «Хәят»тагы кебек кеше итеп саннап язмас идем, болай язсам, минем күңелем, тойгым кыерсытылган булыр иде,— дидем.

— Син революционный фраза кулланырга телисең, сыйнфый күзлек аркылы карарга әйтәсең,— диде.— Соң Гайфетдинне языйммы инде? — диде.

— Шуны яз, алар чын типлар, кирәкле типлар, синең каләмең матур, шул каләм аркылы чыкканда алардан бик матур һәм ялган булмаган типлар мәйданга чыгачаклар, алар үзләрен синең каләмең аркылы укып, җанга азык табачаклар. Синең «Хәят»ыңны синең морзаларың укымыйлар, безгә дә ул төче, Гайфетдингә бөтенләй җат, шулай булгач, әсәрен укучысыз кала, укысалар да, укучылар нәфрәт белән укыйлар[37],— дидем.

— Син бик тәнкыйтьче булып киткән әле, ну ярар, кирәк ул, аларны да уртага тартырга кирәк,— диде.

— Бу карашың, Фатих, бөтенләй ялгыш. Уртага тартмаска кирәк, тартсалар да, төртеп чыгарырга кирәк,— дидем.— Морза булып азапланма, аларга син дә үз түгел, кеше дә түгел һәм аларга, үзләреннән башка, кеше дә юк, аларны эткәннән — этәргә, кысарга, кысырыкларга кирәк,— дидем. Шулай итеп, мин бу хакта Фатих белән байтак сөйләштем.

— Алай булса, борчылма, менә син әйткән типны язам,— диде.

— Ул кем? — дидем.

— Фәтхулла хәзрәт[38],— диде.

— Ул турыда мин хәзергә бер фикер дә әйтә алмыйм, Фатих,— дидем. Ул һаман мин әйткән Гайфетдин түгел, Фәтхулла хәзрәт,— дидем.

— Ярар, гомер вафа итсә, барын да язарбыз әле, «шагыйрь әфәнде»,— диде. Чөнки Фатих сөйләшкәндә кайвакыт шундый чеметтермәле, өсте баллы, асты әче сүзләр куллана торган иде. «Шагыйрь әфәнде» дигән миңа хитабы шул чеметтермәнең берсе иде. Аның бу чеметтерүенә сәбәп тә мин аның «Хәят»ы белән ризалашып бетә алмавым иде.

Фатихка мин күп вакытларда андый «урталыкта» кебек типларны язмыйча, халык тибы, дөрест типлар язарга кирәклеген әйтә идем. Ләкин Фатих элек сау вакытында җанып торган ялкынлы йөрәк булу белән бергә паралич суккач, яхшук боекты һәм эш көче дә кимеде. Театр кебек гомуми урыннарга барырга уңайсызлана иде. Ләкин уңайсызлануын белдермәскә тырыша иде. Халык белән үз теләгәненчә аралаша алмый, бәлки үз янына килгәннәр белән генә сөйләшә яки газет-журнал кебек вакытлы әдәбият аркылы гына халык хәле, аларның рухлары белән таныша иде. Бу чорлар бик катлаулы һәм үзгәрешле булганга, болай гына танышу Фатихны таныштырып бетерми иде[39].


Фатих сау вакытында көчле оптимист булса, Столыпин чорындагы көчле реакция аңар нык тәэсир итеп, шуның өстенә саусыз булу боеклыгы аны көчле пессимизмга алып бардылар[40]. Фатих яшь, сау чорларында атеистик караштa булу белән бергә соңгы чорларда, шул ук сырхау тәэсире булырга кирәк, дини тойгыларга бирелгән һәм ялгызлыкны ярата иде[41]. Фатих белән күп вакытлар булдым, күп сөйләштем, шулай да аннан бер вакытта да үзенең сырхавыннан зарлану ишетмәдем.

Фатих Чехов һәм Андреев кебек соңгы рус язучыларының әсәрләрен укырга ярата, Максим Горький әсәрләрен сөеп укый торган иде. Рус әдәбиятын да вә аның соңгы шагыйрьләрен дә яратып укый иде. Фатихның псевдонимы «Ташмөхәммәд» булып, мин аның моннан башка псевдонимнарын хәтерләмим[42]. Тукайның өч төрле псевдонимы бар иде («Шүрәле», «Ганкәбут» (үрмәкүч), «Касимский»[43].— Миргазиз Укмасый искәрмәсе). Мин үзем дә өч төрле псевдоним белән яздым, ләкин Фатихта бер генә булырга кирәк.

Фатих миңа бер вакытны үзенең яшь, сау вакытта алдырган фотокарточкасын бүләк итеп, аның сыртына:

«Җисмү зарым хакыда пинһан
уланча эстәрем,
Сурәтем бу рәсем илә калсын
җиһанда ядкяр.

*Шагыйрь Укмасыйга хатирәм».*



*Фатих Әмирханның Л. Н. Толстойга язган хатыннан фрагмент. 1910 ел дип фараз кылына.*

— дип язып куйган иде. Ләкин мин бу карточканы югалттым.

Г. Тукайга мәгънәви рух бирешүдә Фатихның көчле тәэсире һәм хезмәте байтак. Шунлыктан Тукай да Фатихны ярата, аңар бәһа бирә иде. Бигрәк тә Фатих Тукайга төрекчелектән чыгып, татар телендә язарга һәм шул телне баетырга куша, Тукайның саф татар телендә чыккан шигырьләрен төрекчелек тәэсире астында, корама тел белән язылган шигырьләреннән күп матур икәнен сөйли һәм кайвакыт Г. Тукайны үпкәләтә дә иде. Г. Тукайның үпкәсе шуннан гыйбарәт: ул байтак вакытка кадәр сөйләшми йөри яки исәнләшми чыгып китә, шулай да бу үпкә бик озакка таралмый иде. Г. Тукай да, Ф. Әмирхан да Галимҗан Ибраһимовны сөйми гомер иттеләр, «эгоист», «мин-минлекле», «скандалчы» ди торганнар иде.

Ф. Әмирханның мин аттестат зрелостига хәзерләнгәнен хәтерлим. «Заучнотное подготовление к поступление в уневриситит» (урысча язылган, текстта шулай.— **Р. Ә.**). Аның моңар экономический көче җитмәгәнгә һәм атасы Зариф мулла аның бу уен сөймәгәнгә, ул хәзерләнүдә аптырау-читенлектә кала, теләге юридический факультетка керү. Атасы аның бу теләге белән күнми, ул шуннан соң йортны ташлап чыгып, хәзерге Бауман урамының чатында булган, ул вакыт «Музуров нумирәсе» аталган нумирәдә бүлмә алып, шул теләген дәвам иттерә[44].

Аны экономический хәл кыса. Ул анасына кайтып үзенең положениесен сөйли. Ана, хатын булу сыйфаты белән, атага, Зариф муллага тәэсир итә. Зариф мулла соңынтын аның аттестат зрелостига хәзерләнүенә разый булса да, ләкин Фатихка бер тиен ярдәм итмәячәген сөйли. Ана Фатихка ата сүзен сөйли, шуннан соң Фатих өйгә кайта һәм нииндидер бер студент[45], мулла йортына килеп, аны русча укытып, шул юлга хәзерли башлый. Укыткан өчен студентка акча түләргә кирәк. Ф. Әмирхан моны юллау өчен Камчылы ишан улы Әхәт «күршеләре» (куштырнаклар текстта.— **Р. Ә.**) һәм шуның белән бергә тагын биш юлдашын русча укытып, алардан бишәр сум, һәр айга утыз сум акча хәзерли. Шул акчаны әлеге студентка түли.

Мин сәбәбен белмим, никтер соңынтын Ф. Әмирханның бу теләге эшкә ашмый кала. Аның бу хәзерләнү чоры Хөсәен Ямашев белән бер вакытларда булып һәм һәр икесе дә аттестат зрелостига юридический факультетка хәзерләнү чорлары булганга, монда, шиксез, Ямашевның тәэсире булган булырга тиеш[46].

Хәзергедәй хәтеремдә, Ямашев бөтен предметтан «5»кә экзамен бирә, ләкин соңынтын аннан славян, ягъни церковный языктан, «чиркәү теленнән» сынау сорый башлыйлар, ул моңар, татар булу сыйфаты белән хәзерләнмәгәнгә, провалиться итә[47]. Моны профессорлардан үтенү өчен Алабуга мулласы Зәки Хуҗахановы аркылы генерал Занфировка тәэсир иттереп, бу генерал профессорларга мө[р]әҗәгать итә. Профессор генералга әйтә: «Ул сәяси, «ялгыш юлда», син аның артыннан йөрмә, үзең өчен дә яхшы булмас, бу «губернаторның заданиесе», син үзенә чокыр казыма»,— дип җавап бирә. Занфиров һәм мулла моннан соң туктап калалар. Мин белмим, Фатих өчен дә бәлки шундый тоткарлык чыккандыр. Фатих та реакция чорларында бу теләгеннән туктый, сырхау, боек, өметсез хәлдә әдәбият дөньясында эшләп азаплана[48].

Ф. Әмирхан сүзгә оста, шуның белән бергә «вак язучы»ларга иронический карашы көчле булганга, аны пролетариат язучылары хөрмәтләмиләр. Ул да аларга түбән карый. «Акчарлаклар»ны яратмый, тозсыз, эчлеге аз, балык тозлаучы марҗаларны чагылдыра, аларның әдәбият белән һичбер бәйләнешләре һәм алар тормышыннан җанга азык юк, ди[49].

Димәк, Ф. Әмирхан өчен буржуа әдәбиятында гына жанга азык булды, хезмәтчел халык өчен булган әдәбият аның өчен азыксыз, тозсыз, тәссез булып чыга. Ф. Әмирхан, һичшиксез, буржуа әдәбияты яклы, шуларны чагылдыручы вә шул әдәбияттан тәм табучы, үзе дә шул сыйныф белән килешә вә аларга үзен сөйдерә белүче, «түбән сыйныф» язучыларына түбән караучы «олуг табигатьле» язучы иде[50].

Максим Горькийның әсәрләрен яратып укый, ләкин аның сыйныф күрсәтү ягыннан булган характерын яратып түгел, бәлки тел[е]нең простой, төзелешенең матур, әсәренең чыгышлы булу ягыннан ярата иде.

## ИСКӘРМӘЛӘР

1 Хәзерге Г. Тукай урамы, 34 нче йорт.

2 М. Гафури урамы, 35 нче йорт. Хәзер хәрабә хәлендә.

3 М. Гафури урамы, 34 а. Популяр исеме «Иске таш мәчет».

4 Җыен — элекке заманда бер төркем авылларда гадәттә сабан эшләре тәмамлангач үткәрелә торган атналык бәйрәм.

5 Бу сүзләр «сер саклый» торган җизни кешенең фантазиясе булса кирәк. Егерме ике яшеннән имамлык кыла башлаган, абруйлы Хөсәен хәзрәтнең улы Зариф мондый шәригатькә хилаф юлга басып, азып-тузып йөрсә, 47 ел буена муллалык итә алмаган булыр иде.

6 Вафа Бәхтияров (1881—1960) — «Әл-Ислах» гәзитенең рәсми мөхәррире, журналист, укытучы.

7 «Тәрҗеман» (тәрҗемәче) — Бакчасарай шәһәрендә 1883—1918 елларда И. Гаспринский һәм варислары нәшер иткән гомумтөрки телдәге гәзит.

8 Азәрбайҗан телендәге бу гәзит гасыр башында Тифлис шәһәрендә чыга.

9 Рәшид (Габдерәшид) казый Ибраһимов (1853—1944) — милли идеологларның берсе, күренекле җәмәгать эшлеклесе. Укмасый аны «адәм», «безне агулаучы бер пычрак» дип атап, үз-үзен «йолу» чараларын күрә.

10 Чемберлен — Англия тарихында өч мәшһүр Чемберлен билгеле. Биредә сүз инглиз дәүләт эшлеклесе, 1937—1940 елларда премьер министр Невилл Чемберлен (1869—1940) турында бара булса кирәк.

11 Симпиньон — дөрес язылышын да, үзен дә ачыклап булмады, граммофонга охшаш музыка уйнаучы җайланма булса кирәк.

12 1940 ел шартларында Укмасый, әлбәттә, үзенең социал-демократлар партиясенә күңел куюын искәртә, ләкин большевикларгамы, меньшевикларгамы икәнен ачыкламый.

13 Х. Ямашевка сыгыну 1940 елларда гына түгел, 1980 еллар азагынача модада булды.

14 Хуҗа Бәдигый (1887—1940) — атаклы фольклорчы галим, соңыннан Казан дәүләт педагогия институты профессоры.

15 Ф. Әмирхан Петербургка мәгариф министрлыгына керү өчен сайланмый, бәлки бөтен Казан шәкертләре исеменнән Бөтенрусия мөселманнарының II — съездында (1906 елның 13—23 гыйнвары) катнашу өчен вәкил буларак җибәрелә.

16 Бу вакытта Дума әле юк, ул 1906 елның 27 апрелендә генә эшли башлый.

17 Шәкертләр арасында дәрес ташлаулар киң колач алган чорда отчет-фәләннәр бирү әһәмиятсез бер эшкә әйләнеп кала, өстәвенә Фатих полиция эзәрлекләвеннән качып йөри.

18 Заһид Шамил (1868—1920) — мәшһүр шәех Шамилнең оныгы, «Тәрбияи әтфаль» журналының нашире һәм мөхәррире, җәмәгать эшлеклесе.

19 «Тәрбияи әтфаль» 1907 елның гыйнвар-март айларында Мәскәүдә чыга. Биш саны дөнья күрә. Җаваплы сәркәтибе һәм фактик җитәкчесе Ф. Әмирхан.

20 «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» «Тәрбияи әтфаль»нең 1—4 (1 гыйнвар — 15 февраль) саннарында басылган. Анда Ф. Әмирхан имзасы юк, азактан «Андерсеннән тәрҗемә» дип куелган.

21 Хикәяне Ф. Әмирхан тәрҗемә иткән. Ул Г. Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1910), «Күчмә уку китаплары»ның беренче «төб»енә (1921) Фатих Әмирхан имзасы белән кергән.

22 В. В. Радлов (1837—1918) — атаклы тюрколог, академик, байтак еллар Казанда эшләгән.

23 «Белек» исемле уку китабы Радлов тарафыннан 1872 елда Казанда нәшер ителгән.

24 «Шыксыз бәпкә»нең авторы атаклы Дания әкиятчесе Х. К. Андерсен (1805—1875).

25 Мөхетдин Корбангалиев (1873—1941) — күренекле педагог һәм тел галиме.

26 «Музуров номерлары» хәзерге Свердлов урамы, 1 нче йортта урнашкан булган.

27 Ф. Әмирханны паралич Казанда, 1907 елның 15 августында суга. Бу хакта әдипнең Р. Алушига 1907 елның 25 ноябрендә язылган хаты дәлил.

28 Бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Фатихның хәле Казансуда эссе көнне су кергәннән соң кисәктән начарланып китә.

29 Рәсми «Әл-Ислах» 1907 елның 3 октябреннән чыга башлый.

30 «Әл-Ислах» битләрендә М. Укмасыйның үз имзасы белән 1907—1908 елларда «Ялкынлы сулудан», «Хәзрәтләргә», «Тан-болыт», «Чыпчык иттифакы татарларныкыча

икән», «Фиргавен» исемле тезмә әсәрләре басыла. Аларның берсендә дә «мөлаем керфекләре сыйпап сөйдергә» дигән тезмә очрамый.

31 Галимҗан Галиев — Баруди (1857—1921) — «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесе, мәгърифәтче, олуг дин әһеле, мөфти.

32 Гайре рәсми, җилем басма «Әл-Ислах» 1905 елның 29 ноябреннән 1907 елның башларынача чыга. Җитәкчесе Ф. Әмирхан.

33 Маминны 1906 елның 17 мартында кулга алалар. Бер кешелек камерада ул 24 көн утырып чыга.

34 Сүз күренекле урыс язучысы Л. Андреевның (1871—1919) 1908 елда язылган «Рассказ о семи повешенных» хикәясе хакында бара. Ф. Әмирхан аны татарчалаштырып, 1909 елда «Үрнәк» матбагасында бастырып чыгара.

35 Бу фраза урысча әйтелгән булса, «промахнул» — «промахнулся» дип яңгырарга тиеш иде.

36 «Хәят»ның беренче бүлеге 1911 елда басылып чыга.

37 «Хәят»ны нәфрәт белән укулары» турында сүз кузгатып, М. Укмасый «сугыш беткәч, батыр күбәя» дигән әйтемне аклый.

38 Биредә кычкырып торган каршылык, чөнки «Фәтхулла хәзрәт», дүрт кисәкле әсәр буларак, «Хәят»тан алда, 1909—1910 елларда ук басылып чыга.

39 Ф. Әмирхан, аяксыз булса да, күп аяклыларга караганда җәмгыятьтә ешрак була. Ф. Әмирхан II сүзләре белән әйткәндә, «театр-концертларга һәм хосусый лекцияләргә йөрүдә үз ишләреннән күп калышмый». Ул гына да түгел, әдип, гомумән, сәфәр кылырга ярата, коляскасына береккән булса да, берничә мәртәбә Чистайга, Әстерханга, Кырымга, Башкортстанга, Буага, Мәскәүгә барып чыга, бик күп зыялылар, прогресс тарафдарлары белән аралаша.

40 Ф. Әмирханның пессимизмга бирелүе хакында мәгълүматлар юк.

41 Әдипнең дини тойгыларга бирелүе, ягъни Исламга күңел куюы хак, әмма ялгызлыкны яратуы бернинди мисаллар белән дә расланмый. Аерым алганда, Әмирхан янына дуслары еш килеп, алар тәүлекләр буе преферанс уены белән мавыгалар.

42 «Ташмөхәммәд»тән башка Ф. Әмирхан революциягә кадәр «Дамелла», «Хәзрәт», «Зәмзәметдинов», «Т — д», «Ф. Ә.», «Ф.», революциядән соң «Марксит», «М-т» псевдонимнарын һәм, әлбәттә, үзенең тулы исем-фамилиясен куллана.

43 Тукайның псевдонимнары шулай ук дистәдән артык: «Биик усал», «Тәртә башы», «Мәҗнүн», «Гөмберррт», «Гъ.Т.», «Гъ» h. б.

44 «Музуров номерлары»нда әдип 1906 елда торып ала.

45 Бу студентның социал-демократ С. Н. Гассар (1877—1918) булуы мөмкин.

46 Ямашевның тәэсире булганмы-юкмы, анысы билгесез. Бу чорларда бик күп татар яшьләре аттестатка имтихан тотып, университетка керү юлында бәхетен сынап карый. Ф. Әмирхан да 1911 һәм 1912 елларда ике мәртәбә талпыныш ясый. Кодасы Ф. Әмирхан II бу хакта болай дип язган иде: «Ләкин икесендә дә, укучылар теле белән әйткәндә, провалиться итте, дөресрәге, аны провалить иттеләр; чөнки ул заманда рус мәктәпләрендә җитәкчелек ролен уйнаган чиновниклардан күбесенең рустан башка милләт кешеләренә юл бирмәскә тырышканлыклары һәркемгә билгеле, ә Фатыйх кебек танылып килә торган татар язучысына һәм публицистына юл бирмәү бигрәк тә аңлаешлы».

47 Х. Ямашев, мөселман буларак, Казан уку-укыту округы назыйре (попечителе) тарафыннан славян һәм немец теле буенча имтиханнардан азат ителә, гимназия курсын тәмамлавы турында аттестат ала, 1911 елның 18 августында университетның юридик факультетына кабул ителә.

48 Ф. Әмирхан «сырхау, боек, өметсез хәлдә әдәбият дөньясында эшләп азапланмый», бәлки татар әдәбиятын, матбугатын төптән җигелеп тартучылардан була, милли әдәбиятның алтын фондына керерлек әсәрләр иҗат итә.

49 М. Укмасыйның Әмирхан тарафыннан Ш. Камал иҗатына биргән бәясенә төзәтмәләр кертергә кирәк. Шул ук вакытта Ф. Әмирханның Г. Исхакый иҗатына карата югары фикердә торганын К. Тинчуринны нәтиҗәле («плодовитый») язучы итеп таныганын искәртү дә урынлы булыр.

50 Укмасый да, заман шаукымына бирелеп, әдип иҗатын һәм шәхесен берьяклы гына бәяләүдән котыла алмый, шәхсән үзенең дә, «түбән сыйныф» язучысы буларак кимсетелүе өчен, дигәндәй, үпкәсен белдерергә онытмый.

Равил
Әмирхан

# ШОМЛЫ ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

**Равил Госман улы Әмирхан — татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның туганы, ягъни Әмирханнар шәҗәрәсенең бер тармагы. Ул 1946 елның 9 гыйнварында Ульян өлкәсендәге Иске Кулаткы авылында туа. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Тарих фәннәре кандидаты. 1981 елдан — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр. Көндәлек матбугат, төрле җыентыкларда басылган фәнни-популяр язмалары 250 дән артып китә. Быел докторлык диссертациясе якларга җыена.**

**Егерме ел дәвамында халкыбызның күп гасырлык тарихын, аерым алганда, аның азатлык өчен көрәшен, милли матбугатын, мәгарифен, мәдәниятен төрле яклап өйрәнүгә сизелерлек өлеш керткән тарихчы-галимгә гыйнварда 50 яшь тулды. Аны шул уңайдан котлыйбыз, сәламәтлек һәм иҗат шатлыклары телибез.**

**Укучыларыбыз игътибарына Равил Әмирханның яңа язмасын тәкъдим итәбез. Ул — Фатих Әмирханның бертуган энесе, җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Әмирхан турында.**



*Ибраһим Әмирхан. 1915 ел.*

Тарихыбызның 70 еллык тоталитар дәвере сәхифәләрен актарганда әле һаман да бәгырең куырылып, тетрәнеп куясың: нихәтле иҗтиһад, якты омтылыш, игелекле гамәл үсентеләре тамырында көе корытылган, никадәр саф күңелле, эчкерсез, намуслы җаннар җинаятьчеләр өере тарафыннан бер гаепсез корбан ителгән икән! Милли тормышыбыз, үткәнебез кысаларында күзалласак, әлеге чор тагын да шомлырак, чирканычрак булып гәүдәләнә. Тагын кайсы кавемнең затлы, зыялы вәкилләре өстенә берьюлы котсыз-иләмсез гаепләрнең бөтен бер көлтәсе ыргытылды икән? «Милләтче», «солтангалиевче», «сәгыйдуллинчы», «троцкийчы», «җидегәнче», «фәлән илнең шпионы», «халык дошманы»?.. Болары да буш җирлектә шытып чыкмаган — тамырларын шул ук дөмбәсләү максатында иҗат ителгән «басурман», «панисламист», «пантюркист» кебек тәгъбирләргә барып тоташа.

Хәятен тәмуг дәһшәте өткән шундый затларыбыз арасында классик әдибебез

Ф. Әмирханның бертуган энесе, Г. Тукайның дусты, татарның Совет чорындагы тәүге дипломатларыннан берсе, югары дәрәҗәле юрист, җөмһүриятнең хокукый нигезләрен ныгыту эшенә лаеклы өлеш керткән күренекле дәүләт эшлеклесе Ибраһим Әмирхан (1889—1938) да бар. Кылган гамәлләренә генә түгел, исеменә дә ярты гасыр дәвамында богау салынган иде аның. Тәрҗемәи хәле дә, татар халкының, республиканың иҗтимагый-сәяси, мәдәни тормышында уйнаган роле дә әле өйрәнелмәгән диярлек. Бу бигрәк тә Ибраһимның дипломатик яссылыктагы эшчәнлегенә хас. Әмма булган кадәр мәгълүматлар да кече Әмирханның зур, максатчан натура, кабатланмас биографияле шәхес булуын раслый.

Ибраһим Мөхәммәтзариф улы Әмирхан 1889 елның 5 сентябрендә дөньяга килә. Абыйсы Фатихтан дүрт яшькә диярлек кечерәк булса да, аларның балалык һәм үсмер еллары бер-берсеннән аерылгысыз рәвештә диярлек үтә. Үз карамагында берникадәр вакыт укытканнан соң, Зариф мулла кече улын да заманының иң атаклы мәдрәсәләреннән саналган «Мөхәммәдия»гә бирә. 1897 елга караган мәгълүматлар буенча, кыш көннәрендә яхшы киенгән ике бертуганны матур дирбияле кара туры ат зиннәтле чанада «Мөхәммәдия»нең капка төбенә хәтле китереп куя, ә дәресләр беткәч, өйгә алып кайта торган булалар. Ә инде үсә төшкәч, аларның һәр икесе мәдрәсәдә торып укый башлый.

Абыйсы төсле үк, Ибраһим да зирәк, укуга һәвәс, тере һәм аралашучан шәкертләрдән була. Әйтик, аның «мөхәммәдияче»ләрнең яшерен өй спектакльләрендә 1903 елдан ук якыннан катнашуы, ул гына да түгел, аларны оештыруда, сәхнә өчен кирәк-яраклар табышудагы елгырлыгы мәгълүм. «Артистлыгы»да хәйран була моның. Мәсәлән, 14 яшьлек Ибраһим үзенең шәрикләренә Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасын күрсәтүчеләр арасында була. Ул анда тегендимондый гына түгел, ә төп каһарман, ягъни Закир ролен башкара.

Күп нәрсәдә абыйсына иярергә күнеккән, аның фикере белән нык хисаплашкан Ибраһим, заман таләбенә муафыйк рәвештә, урыс телен бик тырышып өйрәнә. Әйтик, 1904 елның җәендә алар, Фатих белән берлектә, ике ай буена Самарада ниндидер курсларда укып кайталар. Шул ук елның көзендә ул, инде Казанда, абыйсыннан күрмәкче, китап-дәфтәр күтәреп, яңадан учительгә йөри башлый. Мөгаен, бу кеше — Фатихка да урысчадан һәм башка сәяси-иҗтимагый «фәннәр»дән дәрес биргән С. Н. Гассар булгандыр.

Абыйсының ялкынлы тарафдары булган Ибраһим, әлбәттә, «Мөхәммәдия»дәге яшерен түгәрәкләрдә, әдәби-музыкаль кичәләрдә, бирөдә чыгарылган сатирик кульязма, җилем басма гәзитләрдә дә катнаша. Ул гайре рәсми «Иттихад» оешмасының да, аның мәгънәви варисы мәшһүр «Әл-Ислах» комитетының да эшлекле әгъзаларыннан санала. 1904, бигрәк тә 1905—1906 елларда аеруча зур куәт алган шәкертләр хәрәкәте «казаны»нда кайный, «Әл-Ислах» үзәк комитеты башлыкларының берсе буларак, милли тормыштагы искелеккә, торгынлыкка каршы көрәш, яңага, европача белемгә йөз белән борылу фикерен алга сөрә.

1905 ел революциясе либеральрәк фасылда калыпланган укучы яшьләр хәрәкәтенә яңа рух өрә. «Мөхәммәдия» шәкертләре, шул мәдрәсә җирлегендә оешкан «Әл-Ислах» комитеты торган саен суллаша, өлешчә эсерлар, башлыча социалдемократлар йогынтысына бирелә. 1905 елның октябрь күтәрелеше көннәрендә Казанда «халык милициясе» оеша. Гомуми саны берничә йөзгә җиткән милиционерлар арасында шәкертләр дә байтак хисаплана. «Әл-Ислах» комитеты әгъзасы, бик хәрәкәтчән һәм өлгер Ибраһим да күнелле (ирекле) сыйфатында шушы милициягә языла. 19—21 октябрьдә, ягъни Казанда революционерларның «Шәһәр коммунасы» хакимлек иткән кыска бер чорында кулларына кызыл тасмалар бәйләп, «инкыйлаби тәртип» саклаучылар, полицияне коралсызландыручылар арасында безнең Ибраһим да активлык күрсәтә. 21 октябрьдәге халык күтәрелеше бастырылгач, башка милиционер белән берлектә Ибраһим Әмирхан да кулга алына. 16 яшьлек үсмерне зинданга әләгүдән Казанның абруйлы мулласы — Зариф хәзрәтнең катышуы гына коткарып кала. Полиция аның өстеннән яшерен күзәтү оештыра.

Инкыйлаб хәрәкәтендә, укучы яшьләр кузгалышында турыдан-туры катнашкан Ибраһим абыйсы Фатихның ярдәмчесе буларак, Казанда үткәрелгән яшерен Бөтенрусия шәкертләр съездларын (1906—1907) оештыручыларның, аларны мәгънәви яктан җитәкләүчеләрнең берсе була. «Әл-Ислах» комитетының башта шул исемдәге җилем басмасы, аннары рәсми гәзите тирәсенә замананың алдынгы карашлы зыялы яшьләре — Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, К. Бәкер, В. Бәхтияров һәм башкалар туплана. Ибраһим Әмирхан, шәкертләр хәрәкәтен җитәкләүчеләрдән буларак, бу даирәнең үз кешесе санала. Әлеге фактны мәгълүм дәрәҗәдә 1908 елның маенда алынган бер күмәк фото да раслый.



*«Әл-ислах» гәзитәсе идарәсе. Сулдан — уңга: Вафа Бәхтияров, Кәбир Бәкер, Фатих Әмирхан, Ибраһим Әмирхан, Габдулла Тукай. 1908 елп.*

Биредә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров, К. Бәкер белән берлектә, бөек шагыйребез белән янәшә терәлеп диярлек утырган Ибраһим да сурәтләнгән. Бу уңайдан шуны искәртү дә урынлы булыр. 30 нчы еллар азагыннан башлап «халыклар атасы» фатихасы белән корбан ителгән шәхесләрнең сурәтләре әүвәлге фотолардан «юылу» гадәте канат җәйде. Шушы принципка нисбәтән, без әле генә сүз алып барган күмәк сурәт тә котсыз рәвештә имгәтелеп, анда гайре табигый халәттә (бушлыкны тутыру уңышсыз) өч шәхес кенә «тырпаеп» калган иде: Ф. Әмирхан, Г. Тукай һәм В. Бәхтияров. Әйтерсең, тарихта атаклы журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе Кәбир Бәкер дә, татарның тәүге дипломатларыннан берсе, дәүләт эшлеклесе Ибраһим Әмирхан да булмаган...

«Столыпин реакциясе еллары» дигән атама алган чорда Ибраһимның хәле шактый тотрыксызлана, төшенкелеккә бирелгән, сүлпән-битараф чаклары еш була. Алдынгы зыялылар тирәсендә кайнаган кеше, төпле генә белемгә ия булса да, ул үз-үзен тиз генә таба алмый, каләм эше дә аны бу чорда артык мавыктырмый. Хәер, соңрак ул кайбер гәзит-журналларда язышкан булырга охшый. Һәрхәлдә, аның татар телендәге беренче хатын-кызлар журналы «Сөембикә»дә «Кызларга бигрәк тә тиеш» дигән мәкаләсенә тап булдык) (1913, № 1). Ибраһим «Әл-Исхак» даирәсенә тартым кайбер яшьләр белән кәеф-сафа корулардан да тайчынмый, «режим»ны да ярыйсы гына бозгалап куя. Бу хәлләр күбрәк аның аттестатка имтиханнар тапшырып, университетка укырга керү хыялы җимерелә баруы белән бәйләнгән булса кирәк. Төпле европача белем алу өчен байтак кына акча кирәк, ә уларын хак мөселман рухында тәрбияләргә тырышкан, алардан дин-диянәт, шәригать «тоткасы» ясауга өметләнгән ата-ана дөньяви, урыс калыбындагы «иләс-миләслек»кә юл куярга ашкынып тормый, димәк, алардан матди ярдәм көтү урынсыз. Яшь мәхдүм, ягъни хәзрәт малае, рухи кризис кичерә.

Нәкъ шул чорда Ибраһимга бәхет дигән нәрсә саран гына булса да елмайгандай итә. Бу вакытларда мөселман-татар дөньясының эре кәсәбәчеләре сәүдәмилек эшләрен кискен көндәшлек шартларында алып барырдай милли кадрларга мохтаҗлык кичерә. Шундый атаклы затларның берсе, Оренбургның мәшһүр миллионеры Әхмәт бай Хөсәенов, аеруча зиһенле шәкертләрне үз хисабына Төркиянең Бәйрүт шәһәрендәге махсус америкаи көллиясенә (колледжына) укырга җибәрә торган була. 1908 елда бу коммерция уку йорты Ибраһимга тәкъдим ителә. Яшь мәхдүм бер мәлгә икеләнеп кала, чөнки алыш-биреш, сәүдәгә бәйләнгән эшчәнлеккә тулысынча битараф ул. Әмма уку йортының тулаем дөньяви, исеменең дә бик ятгыравыклы булуын игътибарга алып, кичәге «ислахчы» ахыр чиктә ризалыгын белдерә. Дөньяви көллия икән, форсаттан файдаланып калырга кирәк. Һәм егет яңадан шәкерт булып китә.



*Шул ук фото. Тоталитар системаның иң дәһшәтле чорында Ибраһим Әмирхан белән Кәбир Бәкер тарихтан әнә шулай «сызып» ташланган.*

Көллиягә эләккәннән соң, Ибраһим зур дәрт, тырышлык белән инглиз, гарәп, төрек телләрен үзләштерә, дөньяви һәм махсус фәннәрдән киң мәгълүмат ала.

19 яшьлек егетнең туганнан туган сеңелләре Фатыйма белән Өммегөлсемгә 1908 елның 30 октябрендә Бәйруттән язган почта открыткасы сакланган.

«Сөекле сеңелләрем Фатыйма, Өммегөлсем! Гаед шәриф мөбарәк булсын. Җизни, Мәрьям апага сәламнәрне почта күтәрә алган кадәр җибәрдем. Бер хат йибәргән идем, алгансыздыр. Хат язсаңыз, шат улырмын. Саг улыңыз, Ибраһим».

Ара-тирә мәхдүм туган якларына, Казанга да кайткалап китә. Бер кайтуының шаһиты шул: ул Мәрьямбану апасына (әтисенең бертуган сеңлесе) һәм Өммегөлсемгә, артына үз кулы белән язып, 1911 елның 22 вә 23 августында ике сурәт бүләк иткән. «Мөхтәрәмә Мәрьям апага ядкяр өчен» бирелгән фотодан затлы озын чапан кигән, башына ак чалма ураган рухани чалымлы егет карап тора. «Сөекле сеңелем Өммегөлсемгә онытмасын өчен вирелмештер», дигән сурәт икенчерәк фасонда. Биредә традицион шәрекъ җиләненә аркылы-торкылы һәм бил тирәли патронташ таккан, өстенә кара чапан бөркәнгән, түбәсенә чүл гарәбенекедәй асылынма баш киеме кигән, кулына ау мылтыгы тоткан ялан тәпиле яугир күзен текәгән.

Ниһаять, 1913 елда көллияне уңышлы тәмам итә бу. Әзерлекле егетне, белемен тагын да арттыру өчен, Америкага җибәрергә карар кылалар. Бу планны тормышка ашыру максатында ул Казанга кайта һәм яңа ерак сәфәргә җыена башлый. Гөнаһ шомлыгына, 1914 елның җәендә Бөтендөнья сугышы кабынып китә. Корылган ниятләр челпәрәмә килә. Ибраһим инде Казанда калырга мәҗбүр. Хәзер аның төп шөгыле шул — татар мәдрәсәләрендә мөгаллимлек кыла. Зур гына белемгә ия мәхдүм яңа эшкә бөтен көчен бирә, шәкертләр укытуда иҗади алымнар куллана, тиз арада шөһрәт казана. Шушы чордан башлап ул тутырган анкеталарның «һөнәре» дигән бүлеменә даими рәвештә «халык укытучысы» гыйбарәсе кереп урнаша.

Ибраһимга инде 25 яшь. Апасы күптән вафат, абыйсы инвалид, димәк, аның гаилә коруы инде бик икеле. Ә төпчеккә башлы-күзле булу өчен берәр киртә бармы соң? Кайдан килсен ди, сау-таза егет ич ул. Менә кәләш эзләү мәшәкате башлана. Булгач-булгач, гөл төсле матур булсын инде ул яшь бикәч, үткән-сүткән артына каерылып карарлык булсын, «ну бу Ибраһим чын җегет икән, асыл кошны аягыннан эләктергән», дисеннәр. Кияү буласы кеше әнисе остазбикә алдына мондыйрак таләп куя:

— Әни, миңа Казанның иң матур кызын димләгез!

Шуннан китә кыз сайлау. Ибраһимга килен буласы кызларны кыл иләктән генә иләмиләр. Казанны, тирә-юньне бетереп, укалы фәрештә эзлиләр болар. Һич табар әмәл юк, егет тегеләрне рәттән яраксызга чыгара, йә булачак кодалар мач килми. Ә бәхет дигәнең шушы Яңа Бистәдә, каршы як урамда

гына йомылып ята икән лабаса. Күршеләре Рәхимҗан Дәминов кызы Нәфисә, чәчрәп торган гүзәл булмаса да, күркәм йөзле, сылу гына туташ — ничек моңарчы күзгә чалынмаган соң?

Яшьләр бер-берсенә ошый. Ата-ана да риза. Никах, туй, кодалашу кебек йолалар үз тәртибе белән гамәлгә ашырыла. Кыскасы, җиһанга яңа Әмирханнар гаиләсе аяк баса. Зариф хәзрәтнең өе хәзер бәләкәйләнебрәк китү сәбәпле (остабикә кыз балалар да укыта), бер катлы йортка уртачарак бүлмә зурлыгында гына икенче кат үстерелә. Кияү белән яшь бикәч шунда яши башлый. Матур гына гомер кичергән яңа гаиләнең тормышы, кызганыч ки, камил булып бетми: бер-бер артлы туган балалары Мөхәммәт тә, Әхмәт тә сабый чакларында ук дөнья куя.

1915 ел. Бөтендөнья сугышының иң кызган чагы. Ул, туймас аждаһа сыман, үзенә яңадан-яңа корбаннар сорый. Инде җирәбә Ибраһимга төшә: кару белмәс татар егете Никки (Николай II) белән Виллинең (кайзер Вильгельм) ерткычы аппетитлары өчен башын утка тыгарга, иксез-чиксез урыс империясенең иминлеген саклап, үзе кебек үк миңгерәүләтелгән герман солдаты белән якага-яка килергә тиеш. Юк, Ибраһимның башына тай типмәгән әле, америкаң көллиясен ул эчен прусс штыгы айкап чыксын өчен тәмамламаган. Һәм егет, «туп ите» булырга кайчан да соң түгел икәнен фәһемләп, ул чордагы башка бик күп рекрутлар кебек үк, соры шинель киюдән тайчанып, бер шәһәрдән икенчесенә күчеп, каңгырып йөри, инглиз теленнән хосусый дәресләр биреп җан асрый. Ләкин язмыштан узмыш юк, дигәндәй, аңа Николай патша мобилизациясеннән котылу насыйп булмый. 1916 елда Казанга ярым яшерен төстә кайтып керү белән «качкын»ны кулга алалар һәм әлләни кырыс чаралар күрмичә, Сарытау вилаятендәге Сердобск шәһәренә, ягъни хәрби частька озаталар.

1916 елның ахыры — 1917 елның башы. Ибраһим Әмирхан 161 нче запас пехота полкының кече әфисәре дәрәҗәсенә «күтәрелә». Ул монда кырыс гаскәр тормышының, хәрби вәзгыятьнең, гаделсезлекнең бөтен әчесен татый. Оста хатиб (оратор), урыс һәм татар телләрен яхшы белгән унтер-әфисәр тиз арада солдатлар алдында абруй казана, хәтта аларның сугышка, хөкүмәткә каршы хәрәкәтләренең җитәкчесе булып китә. Февраль инкыйлабы булып, патшаны төшергәннән соң, солдатлар аңа зур ышаныч күрсәтә, полк комитетына сайлый. Ибраһим, урыс телен начар белүләре сәбәпле, инкыйлаби, сугышка каршы кузгалышка зәгыйфьрәк тартылган татар хәрбиләре арасында аңлату эше алып бара. Тиздән элекке унтер татарларның Сарытау губернасы корылтаена вәкил итеп җибәрелә һәм анда Сарытау өлкәсенең милли идарәсе әгъзасы итеп сайлана. Ибраһим бу идарә составында 1918 елның башына чаклы кала, татар хәрби фиркаләрендә сәяси тәрбия эшләре белән шөгыльләнә.



*Фатих Әмирхан энесе Ибраһим белән. 1915 ел, 14 июль.*

Инкыйлаби рухлы солдат массалары арасында эшләү күп яктан аның киләчәк язмышын да билгели. 1918 елның башында Ибраһим туган шәһәренә кайта, тиздән Казанның 7 нче участогы халык хөкемдары (судьясы) итеп сайлана. Октябрь түнтәрешеннән соң иң хәтәр чор була бу. Учредительное собрание куып таратыла, илдә сәяси вәзгыять кискен үзгәрә, ул да булмый, ата — кызны, ана — улны белмәгән имәнеч, канлы ватандашлар сугышы җәелеп китә. Кыйблалар чуала, киләчәк калын томан пәрдәсе артыннан бөтенләй төсмерләнмәс була. Халык арасында инде шактый гына күзгә күренә башлаган Ибраһим җиде юл чатында кала. Нишләргә? Язмышны нинди мәсләк белән бәйләргә? Хәзрәт малаеның Октябрь гайәсенә (идеяләренә), бигрәк тә аның бөтендөнья пролетариат революциясе хакындагы шигарьләренә мөкиббән китүе шикле. Ләкин кырыс чынбарлык бар бит әле, аның белән дә хисаплашмыйча булмый. Зәйнәп апа Әмирханиянең заманында колагына чалынган мәгълүматлары буенча,

бу болгавыр заманда юл билгеләү мәсьәләсендә Фатих Әмирханның киңәше хәлиткеч көчкә ия булган, имеш.

— Энем, хәзер заман бик чуалчык, дөньяның кая таба барганын чамалау мөхальдер (мөмкин түгелдер). Болай итү мәслихәт булмасмы, син большевик агайлар фиркасенә языласың, ә мин үземнең милли тәрәккъыйпәрвәрлегемә тугрылык саклыйм. Андый-мондый хәл килеп чыкса, бер-беребезгә ярдәм кулы сузу әмәлен табарбыз.

Шулай булгандырмы-юкмы, хәзер тәгаен генә әйтүе кыен, әмма 1918 елның февралендә Ибраһим рәсми төстә большевиклар партиясенә языла. Рекомендацияләрне дә әллә кайдан эзләп йөрисе юк, берсен күршесе, мәдрәсәдәше, хәзер күренекле большивик булып танылган Мәхмүт Дулат-Али бирә... Халык хөкемдары булуы белән генә чикләнмичә, Ибраһим Казан губкомы мөселман бюросында да актив эшчәнлек җәелдерә.

1918 елның җәе. Ватандашлар сугышының бөтен илне тетрәткән чоры. Казан Советка каршы корал күтәргән ак чехлар кулында. Җан кыюларның яңа баскычы инде бу. Ибраһим суеш мәйданына әйләнгән шәһәрне вакытында ташлап чыга алмый, яңа мобилизациягә эләкмәс өчен җизнәсе һәм апасы өендә, Апаковларда качып ята. Ләкин аның эзенә тиз төшәләр. Әүвәлге унтер-офицерне, хәзрәт малаен, инде тагын алмашынган властька хезмәт итәргә күндермәкчеләр. Бер чиктән икенчесенә ташлануны һичкайчан өнәмәгән мәхдүм, билгеле ки, бу эшкә атлыгып тормый. Шул ук вакытта тегеләрнең коммунист халкы белән ничегрәк «мөгамәлә» кылуларын да бик яхшы белә. Аклар, әлбәттә, монык мулла малае, атаклы әдипнең бертуган энесе булуыннан хәбәрдар. Шунлыктан алар Яңа Бистә халкының җыенын оештыралар һәм Ибраһимны, ай-ваена карамыйча, бистәнең мәхәллә комитеты рәисе итеп «сайлап» куялар. «Квартальный» Әмирханны «дружинниклар отряды» төзергә мәҗбүр итәләр. Ибраһим, бистәнең үзендә тәртип саклау дигән сылтау белән, отрядның читкә чыгып, төрле казалар кылуына юл куймаска, үз карамагында туплап тотарга тырыша. Һәрхәлдә дружинниклар халыкның канын коюда катнашмый, чехлар кысрыкланып чыгарылгач та кызыл яу белән чәкәләшми, бәлки шуның ягына чыга.

Фетнә афәтен кичергәннең соңында Ибраһим Әмирхан яңадан үзенең элекке эшенә — халык хөкемдары постына кайта. Җигелеп эшләгәндер, күрәсең, өлгер һәм әзерлекле хезмәткәрне губерна юстиция бүлеге тиздән Казан халык хөкемдарлары советы рәисе урынбасары итеп күтәрә. Абруй дигән нәрсә көннән-көн үсә, исеме дә танылa башлый Ибраһимның. 1919 елда ул — Казан губернасының милләтләр эше буенча бүлек мөдире. Бу инде олы «карьера»га юл ачылу дигән сүз.

Ләкин ватандашлар сугышы дәвам итә әле. Инде көнчыгыштан Себернең «югары идарәсе» Колчак һөҗүм итеп килә. Монда инде ике сөйләшеп торулар юк, «губотдел» мөдирен «үз иреге белән» гаскәргә озаталар. Ни дисәң дә, коммунист бит. 1920 елда И. Әмирхан Совет республикасының Запас армиясе политбүлегендә аз санлы милләтләр секциясе мөдире вазифасын үти. Казан укчы дивизиясе оешу белән, Зариф хәзрәт улы аның политбүлеге башлыгы ярдәмчесе итеп билгеләнә һәм фронтка җибәрелә. Казан укчы дивизиясе Көньяк фронтта таратылуга юлыкканның соңында Ибраһим 51 нче Мәскәү дивизиясенә күчерелә. Монда ул башта Утлы (Огневая) бригадада инструктор-оештыручы, аннары шул дивизиянең политбүлегендә мөселман секциясе мөдире булып хезмәт итә. Аның тәрҗемәи хәленең бер сәхифәсендә Перекопта Врангельгә каршы һөҗүмдә катнашуы (1920) теркәлгән. Бу катнашуның ни рәвешле булганлыгы хакында тәфсилле мәгълүматыбыз юк, алай да Сиваш җәһәннәмен ерып чыгусыз булмагандыр, мөгаен.

Кызыл яу Кырымны «азат» иткәннән соң мәмләкәттә ватандашлар сугышына, нигездә, нокта куела. Инде теттереп социализм нигезләрен генә саласы кала. Әлбәттә, бу эшне әзерлекле белгечләрсез башкарып чыгып булмый. Шушы шартларда америкaн көллиясен тәмам кылган Ибраһимга да лаек шөгыль табыла. 1920 елда ул гаскәрдән чакыртып алына, бер яктан, Симферополь ревкомы әгъзасы, икенче яктан, Симферопольнең дә, өязенең дә халык мәгарифе бүлеге мөдире итеп билгеләнә, шул ук вакытта партиянең Кырым өлкә комитеты мөселман бюросы әгъзасы вазифасын үти. Бу эшләрнең һәркайсы бихисап көч, түземлек, һиммәт һәм өлгерлек сорый. Ару-йончылудан аяктан егылыр дәрәҗәгә житсә дә, йокысызлыктан күз кабаклары шешеп, күзләре кызарып чыкса да, Ибраһимның ял турында уйларга вакыты булмый. Бер сәгатькә түгел, бер минутка да «тугарылырга» ярамый. Заманы һәм «партия дисциплинасы» шуны таләп итә. Җебеп төшәсең икән, беттең, хәрби коммунизм вакытында үгетләүләр, озак сөйләшеп торулар юк.

1920 ел. Июнь. Татарстан автономиясе төзелеп, «чуаш биялә» хәтле генә мәйдан татар халкының дәүләте дип игълан ителә. Аны гамәлгә кую, юлга салу өчен, мәгълүм инде, тәҗрибәле кадрлар кирәк. Партия, совет, хуҗалык, мәдәният эшләрен яңа нигездә алып барырдай белгечләргә бар җирдә дә кытлык сизелә торган заман бу. Билгеле ки, Ибраһимны да онытмыйлар. РКП(б) күрсәтмәсе буенча, И. Әмирхан 1921 елда хәрби хезмәттән бушатыла һәм Татарстан партия өлкә комитеты карамагына җибәрелә. Өлкә комитеты, Ибраһимның тәҗрибәсен һәм риясызлыгын игътибарга алып, аны кассацион трибуналның әгъза-докладчысы сыйфатында юстиция халык комиссариатына (Наркомюст) юллый. Җөмһүриятгә, барлык илдәге төсле үк, яңа икътисади сәясәт (НЭП)хөкем сөрә, шуңа нисбәтән төрле шәкелдәге җинаятьчелек гөрләп чәчәк ата. Билгеле, бу җинаятьчелек сыртларны яңадан кабарткан нэпманнар «казынуы»на гына бәйле булмый, хөкүмәт чыгарган кануннарын бозуда үзе дә кимен куймый. Мулла гаиләсендә миһербанлык рухында тәрбияләнгән намуслы шәхес буларак, Ибраһим ин җавапны, үзе өчен хәтәр мизгелләрдә дә принципиальлек күрсәтергә тырыша, гаделлек сагында торырга омтыла. Һәм шуның бәрабәренә үзенә байтак кына дошманнар әзерли.

Хәлбуки, йогынтылы шәхесләр аның эшен тагын «күреп ала». 1922 елда Ибраһим инде Югары трибунал рәисе ярдәмчесе, ә 1923 елдан — өлкә суды рәисе урынбасары. Заманына күрә зур постлардан хисаплана болар. Ибраһимның җөмһүрият күләмендәге «карьера»сының иң югары ноктасы мөгаен, шулдыр. Һәм ул бу вазифаларын намусы кушканча башкарырга омтыла. Хәер, «партия дисциплинасы» дигән нәрсә аны да аяктан екмый калмагандыр. «Сәяси уяулык» күрсәтергә дә туры килгәндер хөкем әһеленә, югыйсә мулла малайларына караш сагаюлы, «особый».

Аны күреп белгән кешеләрнең хәтерендә Ибраһим образы болайрак гәүдәләнә. Көнкүрештә йомшак мөгамәләле, игътибарлы, тиз аралашучан, киң һәм кече күңелле, үзен вәкарьле (солидно) тота, вакчылланып маташмый, буш сүз сөйләргә, тормышка ашмас вәгъдәләр бирергә яратмый. Киң белеме, табигый зыялылыгы белән эшләгән даирәсендә дә зур абруй казана ул.

Балалар үстерергә насыйп булмаса да, Ибраһим гаиләсе ишле генә була: җәмәгате Нәфисә, кайнанасы Газизә Яушева, абыйсы Фатих, мәрхүмә Сәгадәт апасының кызы Разия, соңрак Разияның энесе Мәхмүт. Өйләнгәнче туганнан туган энесе Гомәр дә яшәп алгалый аларда.

Ул чорларда Казанда яңа торак йортлар салынмый диярлек. Җөмһүрият күләмендә зур гына постлар биләгән Ибраһимны, әлбәттә, фатирсыз калдырмыйлар инде. Ләкин юристыбыз, ни хикмәттер, гел бер йорттан икенчесенә күчеп йөри, күрәсең, яшәү шартлары зур гаилә өчен бик үк уңайлы булмагандыр.

Бу тынгысыз, михнәтле заманда, революциягә кадәр төсле үк, Ибраһимның иң якын киңәшчесе һәм рухи яктан арка таянычы абыйсы Фатих була. Кичләрен алар озак гәп коралар, теге яки бу мәсьәләне һәрьяклап тәфтиш кылалар, берберсе белән килешмәгән чаклары да була, әмма ахыр чиктә һәрвакыт диярлек уртак бер фикергә киләләр.

Кинәт И. Әмирхан язмышында кискен борылыш. Сәләтен, телләр белүен, хезмәтчән сыйфатларын, киң мәгълүматлылыгын һәм тәҗрибәсен күздә тотып, совет хөкүмәте 1924 елда Ибраһимны дипломатик эшкә тарта. Яңа эш урыны итеп Хиҗаз (бераздан Согуд Гарәбстанына керә) билгеләнә. Монда баш консул вазифасын татарның күренекле дипломаты Кәрим Хәким үти. Элегрәк Хәкимов климаты һәм яшәү шартлары Гарәбстанныкыннан күпкә уңайрак булган Персиядә эшләгән була. И. Әмирхан илчелекнең сәркәтибе, тәрҗемәчесе сыйфатында Хиҗазда ике ел буена җиң сызганып эшли, үзенең әзерлекле, төпле белгеч икәнен күрсәтә, кайбер көнбатыш мәмләкәтләренең төрлечә аяк чалуларына карамастан, Хиҗаз, аннары Согуд Гарәбстаны белән Советлар иле арасында хезмәттәшлекне ныгытуга байтак көч куя. Оста әңгәмәче, аралашучан, чит ил дипломатлары белән тиз уртак тел табучан Ибраһим, бер Согуд Гарәбстанында гына ятмый, билгеле. Хатынының язган хатларыннан аңлашылганча, алар дипломатик миссия белән Абиссиния, Италия, Австрия кебек илләргә дә сәфәр кылалар. Кайбер мәгълүматлар буенча, Әмирхан «кызыл паша» Хәкимовның уң кулы була, байтак кына бәхәсле, четерекле мәсьәләләрне җайга салуда күренекле роль уйный. Кызганыч ки, Ибраһимның консуллыкта эшләгән дәверен без әле бик аз беләбез.

Шәхси архивыбызда бер кызыклы гына вәсика (документ) бар. Ул — илченең туганнан туган сеңлесе Фатыймага язган открыткасы. Язмадан күренгәнчә, җаваплы эштә эшләгән җитди илче юмор хисеннән дә мәхрүм булмаган икән. Хат

Хиҗазның үзәк шәһәре Җиддә каласыннан язылган. Текстны тулысынча китерәбез.

«Фатыйма! Син инде Казанда вакытта да безне бөтенләй оныта торган идең. Хәзер белми үк башлагансыңдыр. Мин хаҗи булгач инде, үзең беләсең, ул кешеләрнең догаларын алырга кирәклеге турысында. Менә шуңар күрә, кардәш кеше бит, искә төшерим дип бу мәктүпчекне җибәрәм. Ибраһим. Җиддә, 27 февраль 1925 сәнә».

И. Әмирхан туганнарына бу чорда бер генә хат язмагандыр, дип уйларга кирәк. Калганнары инде эзсез югалган, күрәсең. Ә менә хатыны Нәфисәнең әнисенә, апаларына юллаган открыткалары байтак сакланган. Гәрчә бу язмаларда иренең консуллыктагы эшчәнлеге хакында бер генә сүз булмаса да, яшәеш-көнкүрешләрен, сәяхәтләрен тасвирлау җәһәтеннән шактый кызыклы алар.



*Ибраһим Әмирхан хатыны Нәфисә белән илчелектә хезмәт иткән чорында. 1926 ел.*

1926 ел. Дипломат язмышында безгә төп сәбәпләре әлегә мәгълүм булмаган яңа кискен борылыш. Бәлки бу «буржуаз белгечләр»дән арыну шаукымы белән бәйле булгандыр. Ни дисәң дә, мулла малае эшче-крәстиян вәкиле түгел шул. Ничек булса да булган, Ибраһим хатыны белән ватанына, Казанга кайтып төшә. Иң якын туганы, рухи терәге булган абыйсы инде юк. Ибраһимның бер канаты сынгандай була. Өстәвенә, туган җиренә зур өметләр баглап, якты планнар корып кайткан «хаҗи» үзенә карата мөнәсәбәтнең кире якка таба капыл үзгәрүен тоя. Бу вакытта җөмһүриятнең югары даирәләрендә ниндидер тынчу атмосфера, йомыклык, һәр нәрсәгә шикләнеп карау галәтмәләре өстенлек ала башлаган була. Беркадәр читкә җибәрелгән Ибраһим 1927—28 елларда үзенә хас булмаган вазифага тартыла, авыл хуҗалыгы банкының рәисе урынбасары булып эшли.

Рухына, интеллектына туры килмәгән шөгыль тәҗрибәле белгечне канәгатьләндерми, билгеле. Ул үзен яңадан Наркомюст системасына кайтаруларын сорый. Ниһаять, 1928 елның 8 мартында аны ТАССР Баш суды һәм Наркомюст коллегиясе әгъзасы итеп раслау турында карар кабул ителә. Монда ул 1932 елгача эшли. Элекке илченең намуслылыгы, гаделлеге, үз дигәнендә торучанлыгы кайбер түрәләргә бик үк ошап бетми. Мөстәкыйль участокка чыгару сылтавы белән (янәсе аның белеме һәм тәҗрибәсе зарур) Ибраһимны, вакытлыча дигән булып, шул ук елны промторг идарәсе рәисе итеп билгелиләр. Чыннан да, ике ел дигәндә И. Әмирхан андагы эшне җайга сала һәм яңадан Наркомюст челтәренә әйләнеп кайта. Ләкин озакка түгел. Җитәкчелек тарафыннан төрлечә бәйләнүләрнең, аяк чалуларның яңа дәвере башлана хәзер. Әлбәттә, Ибраһим да характер күрсәтмичә, бәхәсләшмичә калмагандыр. Наркомюстта өйрәнчек түгел ич инде ул, тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек, кешелек горурлыгы да бар. Ләкин Кировның гомерен өзгән 1934 ел элекке мулла малае өчен дә фаҗигале юлның башы була. Ибраһимның «язмышы тәгәрмәче» әкренләп упкынга таба тәгәри башлый.

1935 елда И. Әмирханнан үч алу өчен «уңайлы» форсат туа. Большевистик партия сафларында чираттагы «чистарту» башлана. Хөсетле җаннар әвәләгән әләкләр нигезендә, Бауман райкомы бюросы 1935 елның 18 ноябрендә Ибраһимны партиядән чыгара һәм эшеннән азат итә. Ул заманда (хәер, 80 нче елларның уртасына кадәр дә) фиркадән чыгаруның нинди афәт белән бәйләнгәне хакында озак сөйләп торуның хаҗәте юк. Бу инде синең бетүеңә беренче сигнал, ягъни муеныңа элмәк салыну дигән сүз. Нинди гаепләр ташлана соң И. Әмирханга? Шәхси властеннан явызларча файдаланганмы, «социалистик закончылык»ны бозганмы, берәрсенә нахак бәла якканмы, партия линиясенә каршы чыкканмы,

уңга яисә сулга тайпылганмы ул? Берсе дә түгел. Гөнаһлары бик иске инде аның, ә хәзер бераз пассиврак кына икән. Ягъни: 1) янәсе үзенә партстажны 1918 елның 1 февраленнән «үзләштергән»; 2) 1918 елда ак чехлар вакытында Казанда кораллы дружина оештырган; 3) партия һәм иҗтимагый тормышта пассивлык күрсәтә.

«Җинаятьләр» әлегә баш китәрлек үк түгел кебек. Һәм бу юлында Зариф хәзрәт улына ничектер котылып калырга насыйп була. Бәхетенә, фиркагә кергән вакытында аңа рекомендация биргән кайбер шәхесләр әле исән була (мәсәлән, партконтроль «эш»ләрендә Каюм Саттаровның белешмәсе бар). Тикшерү нәтиҗәсендә шунысы ачыклана: бернинди үзләштерү юк. Ибраһим партиягә 1918 елның 1 февралендә кергән, № 78 партбилет аңа губкомның мөселман бюросы тарафыннан бирелгән, ә райкомда 1919 елда расланган икән. Әлеге «ачыш»ка таянып, партколлегия үзенең 1936 ел, 10 февраль утырышында элекке дипломатны партиядә 1919 елгы стаж белән торгызырга, дигән карар кабул итә. Шунда ук Әмирханның фиркагә кергән чагында үзенең акчехлар чорындагы гамәлләрен яшермәве дә искәртелә. Ибраһимның муенындагы элмәкне вакытлыча бушаткан бу карар партия өлкә комитеты тарафыннан 1936 елның 1 июлендә раслана.

Ләкин Сталин өере җәһәннәменнән котылу исеме инде бер мәртәбә пычратылган кешегә насыйп булмый. Эшеннән бушатылган Ибраһимның тормышында иң соңгы кара дәвер башлана. Ул көч-хәл белән Зеленодольск фанер заводына мескен бер вазифа белән юрисконсульт булып урнаша. Аннан Казанга кайтып йөрүләре үзе бер бәла. Наркомюст коллегиясе әгъзалыгыннан шушы дәрәҗәгә төшерелгән Ибраһимны элек моның күләгәсеннән дә курыккан бәндәләр дә типкәли башлый. Канатлары каерылган кеше өстеннән хәзер төрле органнарга шикаятьләр языла, эшчәнлегенең аерым хасиятләре сабын күбегедәй күпертелеп, яла өстенә яла ягыла. Шушындыйларның берсе — Яңа Бистә «карачкысы», Нәфисәне беренче мәртәбәсендә Хиҗазга алмаганы өчен әледән-әле иренә, Ф. Әмирханга каршы котыртучы, бөтен тирә-юньгә хөсетлеге, явызлыгы белән танылган Хөршид тәтәй була. Тәкъдирнең каһәренә юлыккандыр инде, бу бәндә соңгы елларын тома ялгызлыкта үткәрә, юләрләр йортында җан тәслим кыла. Ибраһимны гаепләү «эш»ләрендә аның өстеннән иң әшәке әләк язган, асылда Әмирханның башын ашаучы тагын ике бәндәнең фамилиясе теркәлгән. Боларның берсе — нәмәгълүм Хәйруллин, икенчесе — ниндидер Зәйнуллин.

Чоры шундый: бу вакытта партаппаратта һәм башка совет-хуҗалык органнарында «халык дошманнары»н мөмкин кадәр күбрәк табу һәм фаш итү уе белән янган кешеләр эшли, яисә аларга бу җәһәттән план җиткерелә. Шуңа нисбәттән, 1937 елның 3 мартында партия өлкә комитеты РКП(б) Бауман райкомы бюросының И. Әмирханны партиядән чыгару турындагы карарын үз көченда калдыра. Ул заман күзлегеннән караганда, бу инде үлем җәзасына хөкем итү белән бер.

НКВД наряды Әмирхан артыннан 23 декабрьнең кара төнендә килеп җитә...

Хәзер инде Ибраһимга берьюлы 1918 елның җәен дә, заманында Солтангалиев белән эшләгән кешеләр илә очрашуларын да (димәк, «солтангалиевче») һәм, иң кәттәсе, Хиҗазда вакытта янәсе Япон разведкасы белән элемтә урнаштыруын да «исенә төшерәләр» (димәк, «шпион»!). Бу «җинаятьләр» пунктлар тәртибендә болайрак калыплана: 1) 1918 елда ак чехлар Казанда вакытта аларга ярдәм күрсәткән; 2) милләтчел солтангалиевчеләр оешмасында катнашкан; 3) Япония файдасына җасуслык кылган.

Бар, 1937 елда үзеңнең гаепсез икәнеңне исбатлап кара син! Ә бит бу пунктларның берсе дә үз чоры шартларында кешене стенага терәү өчен җитә калган. «Халык дошманы» мөһере җуелмаслык итеп сугылган Ибраһимга бернинди дәлилләр, аңлатма язулары, апелляцияләр ярдәм итми. Бар гаепләүләрне кире кага элекке илче, эшне объектив карауларын сорый. Ләкин заманының адәм түзмәслек җәза ысуллары эшкә җигелгәч, ватылмаган-имгәтелмәгән әгъзасы калмагач, сына, җанын рухи өметсезлек били. Инде котылу булып күренгән үлемне тизләтү өчен үзенең чыннан да «милләтче», «солтангалиевче», «япон шпионы», «халык дошманы» булуын «таный»...

1938 елның 3 ноябрендә ТАССР НКВДсы өчлеге Ибраһим Әмирханны атарга хөкем итә. Хөкем карары шул көнне үк җиренә җиткерелә. 48 яшьлек азамат иренең гомере, шулай итеп, нахакка өзелә, ә исеме «халык дошманы» сыйфатында тарихтан сызып ташлана... Мәгаен, гәүдәсе аның, фаҗигале язмышын уртаклашкан бихисап корбаннар белән берлектә, Архангельск зиратына күмелгәндер.

«Халык дошманы» буларак атылган кешенең гаиләсе язмышы, шуннан соңгы изалануларын күз алдына китерү кыен түгел инде. Ирен зинданга илтеп тыгу белән Нәфисәне бик нык җәберлиләр һәм фатирыннан урамга куып чыгаралар. Әлбәттә, эшкә алмый тинтерәтәләр, кая килеп керсә дә, бусагага күрсәтәләр. Анда-монда сугылып, эт типпкәсендә йөргәннән соң, бичара хатын Яңа Бистәгә,

туганнарына кайтып егыла. Анда да кочак җәеп каршы алмыйлар Нәфисәне, чөнки НКВД капшавычларының Кәтиевларга таба да сузылачагын беләләр. Йончыган, кыерсытылган, кеше күзенә күренерлеге калмаган бичараның акылына зыян килә. Үзен дә, туганнарын да азаплый торгач, чит мәмләкәтләрне урап кайткан элекке илче хатыны 1943 елның кышында, 47 яшен дә тутырмастан, дөнья куя.

50 нче елларның азакларына кадәр Ибраһим Әмирхан кебек «халык дошманнары» хакында авыз ачып сүз әйтерге ярамады. «Беренче җепшеклек» дәверендә Бибисәгадәтбану кызы Разия абзасының намуслы исемен кайтару йөзеннән тиешле даирәләргә мөрәҗәгать итә, «эш»не кабат карауларын үтенә. Озак кына йөри торгач, 1958 елда аңа бер кыска белешмә тоттыралар.

Бәй, бернинди җинаятьче түгел икән ич Ибраһим Зарифович, җаны ялгыш кына кыелган, була инде дөньяда андый гына хәлләр! Аннары хәзер, егерме ел вакыт үткәч, искедә казынулар ниемә кирәк!

80 нче еллар башы. Җылы җилләр исә башласа да, «халык дошманы» дигән тәгъбир кулланылыштан нигездә инде төшеп калса да, аклану дигәннең дә төрле дәрәҗәләре бар иде әле. Әйе, диләр иде ул чорда, гражданлык җәһәтеннән абзагыз гаепсез, ләкин бит партия тарафыннан торгызылмаган, димәк, анда нидер бар... Аның хакында язарга, авыз тутырып сөйләргә телисез икән, партиядә торгызу мәсьәләсен күтәрегез, бәлки әле колак та салып куярлар.

«Аклау», торгызу юлында яңа инициативаны минем үземә күрсәтергә туры килде. Бу эшкә хәер-фатиха бирүчеләрнең иң беренчесе Мөнирә апа Сәйдәшева булды. Ибраһим Әмирханның тормыш юлын өйрәнү, эшчәнлеген ачыклаубарлау эшенә ул, гомумән, байтак өлеш кертте. 1984 елның 2 ноябрендә мин, абзамны «партияле буларак аклау» максатында партия контроле комиссиясе исеменә гариза яздым. Берникадәр вакыт узгач, үзебезнең кадрлар бүлеге кабинетында бер мөһим очрашу оештырылды. Минем белән махсус әңгәмә өчен моңарчы бөтенләй мөнәсәбәткә кергәнем булмаган дәүләт иминлеге комитеты вәкиле килде. Ул беренче нәүбәттә Разия Әмирханиянең кем булуы, минем аңа һәм Ибраһимга кем туры килүем, аннары эш кузгатуымның сәбәпләре белән кызыксынды. Боларны шәҗәрә фрагменты төзеп аңлатырга туры килде. Шаһитлардан башка үткәрелгән әңгәмә соңында бик рәсми сөйләшкән комитет вәкиле миңа Ибраһим Әмирханның бернинди дә гаебе булмавын искәртте, аңа яла якканнар, дип аңлатты, бу шәхес хакында теләсә күпме язарга, сөйләргә мөмкин генә түгел, бәлки эшчәнлеген, гомумән, пропагандалау кирәклеге турында өметле фикер әйтте. Тиздән махсус чакыру кәгазе алдым. Шуның нигезендә, 1985 елның 16 гыйнварында, мин реском бинасындагы партконтроль комиссиясенә килдем. Комиссия вәкиле ярым тантаналы, ярым фаҗигале тон белән, абзамның партия стажын 1919 елдан торгызырга карар кылынуы турында хәбәр итте. Нихәтле тыныч-битараф булырга тырышсам да, бугазыма кисәк тыгылган төердән тиз генә арына алмадым. Бичара Ибраһим абый! Синең намуслы исемеңне бөтенләйгә кайтару, һәртөрле идеологик «тышау»лардан азат итү өчен энеңә ярты гасыр үткәннән соң шулай мескенләнеп йөрергә язган икән!

Әйе, фаҗигале тарихыбызның аерым сәхифәләрен барлыйсы, алардан нахакка сызылган мәгърур шәхесләрнең язмышларын ачыклыйсы, тәрҗемәи хәлләрен ныклап өйрәнәсе бар әле безнең.

# ӘЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

**«Әгәр биш-алты кеше бергә җыела икән, шулар арасында бөтәннәрнең күңелен ачардай бер җор кеше, халык әйтмешли, авызы белән кош тотардай берәр «тел бистәсе» булмыйча калмый. Ул элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Билгеле, андый кешенең теленә эләксә, иң гади бер хәлнең, кечкенә генә тормыш мажарасының да күңелле бер мәзәккә әйләнеп китүе тиз...» — «Мең дә бер мәзәк» китабының авторы, аксакал әдибебез Гомәр ага Бәширов әнә шулай язуы белән бик хаклы, әлбәттә. Дөньядагы һәрнәрсә хәрәкәттә булган кебек, мәзәкләр дә заманалар узу белән үзгәрәләр, яңадан-яңа мәзәкләр туа тора. Аларның геройлары — төрле-төрле һөнәр ияләре. Соңгы елларда мәзәк иҗат итүгә һәвәс булган әдәбият һәм сәнгать әһелләре, гомумән, зыялыларыбызның үзләре турында да мәзәкләр еш сөйләнелә, алар турында матбугатта да күренгәләп тора. Бу юнәлештә Батулла, Фәнзаман Баттал, Марсель Гали, Шамил Маннап кебек язучылар аеруча актив эшли.**

**Чыннан да, башка һөнәр ияләре арасындагы кебек үк, әдәбият вә сәнгать әһелләре белән дә мәзәк хәлләр булгалап тора бит. Күп вакыт алар бу хәл-әхвәлләрнең мәзәк язу өчен менә дигән азык булуын сизми дә калалар шикелле. Чөнки бит мәзәк хәлләр аларның яшәү рәвешеннән, җор телле, үткен фикерле чичәнлекләреннән үзеннән-үзе килеп чыга. Шуларны күрә бел дә, тотып ал да яз гына. Андый мәзәкләр теге яки бу шәхеснең күңел төпкелен бер мизгелдә ачып күрсәтә. Караңгы төндә күктә ялтырап алган яшен елдырымы җир өстен яктыртып күрсәткән сыман... Ә кызыклы шәхесләр тормышы турында кемнең генә беләсе килми икән?!**

**Без журналыбызның бу санынан башлап, «Әз-мәз генә мәзәк хәлләр» дигән сәхифә ачып җибәрәбез һәм анда халыктан язып алган яки үзе иҗат иткән мәзәкләре белән әдипләрне, сәнгать әһелләрен, журналистларны, галим-галәмәне, гомумән, җор сүзнең кадерен белүче барлык укучыларыбызны актив катнашырга чакырабыз.**

**Бу сәхифәне ШАМИЛ МАННАПНЫҢ куен дәфтәренә теркәп барган мәзәкләре белән ачып җибәрик әле. Кул-аягы җиңел булсын!**

## Карак дип белгән

Гадәттә, диңгез буйларына ял итеп, тазарып кайту өчен баралар. Ә шагыйрь Мәхмүт Хәсәен Күктүбәдән кайткан саен фәлән килограммга ябыктым әле, артык авырлыгымны калдырып кайттым, дип сөенеп сөйли иде. Махсус ябыгу өчен портфеленә таш тутырып, тауга күтәрелүен әйтә иде. Шуңа микән, язучылар арасында мондый бер мәзәк барлыкка килде.

Имеш, Мәхмүт абый, иртән таш тутырган портфелен күтәргән килеш, Кара диңгез яры буйлап йөгереп йөргәндә, үз артыннан кычкырган тавыш ишетә: «Эй, ворюга! Стой!» — дип акыра-бакыра йонлач күкрәкле бер әзмәвер куып килә икән ләбаса моны! Мәхмүт абыйның коты ботына төшә, аяклары артына тими, сыптыра гына. Шулай куыша-куыша, Күктүбә иҗат йортының капкасына килеп җитә болар. «Ач портфелеңне!» — ди теге йонлач күкрәк боерып. Нишләсен, Мәхмүт абый портфелен ачып, ташларны җиргә бушатырга мәҗбүр була. «Фу, черт!» — ди әзмәвер сүгенеп. — Мин бит сине карак дип белдем. Минем көймәнең моторын салдырып алганнар...»

Бу елны Мәхмүт абый диңгез буеннан сәпсим ябыгып кайткан, имеш.

## «Сәлам-сәлам, коллега!..»

Шактый еллар партия аппаратында эшләп, пенсиягә чыккан берәү Батулла белән очраша.

— Нихәл, әкиятче? — дип сәлам бирә ул язучыны мыскылларга теләп.

Ләкин Батулланың керфеге дә селкенми.

— Ә-ә, сәлам-сәлам, коллега! — ди ул ачык йөз белән.

— Һә,— ди теге, элеккеге түрә,— мин нишләп сиңа коллега булыйм?

— Соң син, гомереӊ буена халыкка җирдә оҗмах төзү турында әкиятеңне сөйләп көн күрдеӊ ләбаса,— ди Батулла һәм өсти: — Хәер, минем әкиятләрнеӊ тормышчанрак булуларын исәпкә алганда, без коллегалар ук түгел икәнбез шул. Бигайбә!

## Тәнкыйтьче мунчасы

Мансур Вәли шәп тәнкыйтьче булу белән бергә, мунча керергә яратуы ягыннан да танылган. Аккош күлендәге мунчаны иӊ еш ягучы ул булыр. Утынын да үзе хәстәрли, себеркесен дә кычыткан кушып бәйли. Мансур үзе чабынып-парланып чыкканнан соң, Аккош күлендәге башка әдипләрне дә мунчага чакыра. Ходайның хикмәте, ул яккан мунчага керергә бик атлыгып тормыйлар.

Нишләп болай икән бу? — дип аптырый Мансур.

Ниһаять, бер көне үзен мунчага чакыргач, шагыйрь Рәдиф Гаташ ачып сала серне:

— Тәнкыйтеӊ белән мунча кертүеӊ җитмәгән, тагын монда да парламакчы буласыӊ безне! Шалишь, тәкъсир! — ди ул...

## Телен күрсәткән...

Язучы Гариф Ахуновның нефтьчеләр каласында яшәп, «кара алтын» табучылар турында роман язып йөргән елларында була бу хәл. Нәшриятка биргән китабына эчке рецензия язуны «Чаян»да эшләүче Габделхәй Сабитовка тапшыралар.

Көннәрдән бер көнне бу ике язучы Казан урамында очраша. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, Габделхәй әйтә Ахуновка:

— Гариф, телеңне күрсәт әле,— ди.

— Ник? — ди Ахунов аптырап.

— Әсәрләреңнән нефть исе аӊкып тора. Телеӊ нефтьле, ахры. Шуӊа тагын бер кат күреп ышанмакчы булам,— ди Габделхәй.

## Потенциаль клиентлар

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенеӊ киӊәйтелгән утырышы бара. Көн тәртибендә: берлеккә яӊа әгъзалар кабул итү. Алар арасында Трофимов дигән керәшен егете дә бар. Ул Казан хастаханәләренеӊ берсендә табиб-психиатр булып эшли икән. Яшерен тавыш бирү тәмамланганнан соӊ, Трофимовка ике кешенеӊ каршы булганлыгы беленә. Моны ишеткәч, Батулла әйтә:

— Кайгырмагыз, Трофимов әфәнде, тиздән ул ике язучы сезнеӊ потенциаль клиентларыгыз булачак! — ди.

## Рәхмәт кемнән тиеш?

«Казан утлары»ның поэзия бүлеге мөдире Рәдиф Гаташ шагыйрь Мөдәррис Әгъләмне коридорда очратып, болай ди:

— Ну, Мөдәррис, журналда чыккан шигырьләреӊне күрдеӊме?

— Күрмәскә, сукыр түгел лә,— ди Мөдәррис, төксе генә.

— Һм... Шәп чыгардык бит, ә?
— Һы, шигырьләре шәп булгачыннан, шәп чыкмый хәле юк.
Рәдифнең бераз кәефе кырылса да, сиздерми:
— Һмм. Тагын әзерлә, яңаларын. Тагын шәпләп бирербез, тәкъсир.
— Һы. Әле боларын биргән өчен дә рәхмәт әйтәсең бар,— ди Мөдәррис һәм юлын дәвам итә.

## Бер лифтка — ике тәкә башы...

Мөдәррис Әгъләм — лифтта. Лифт ишеге әле ябылмаган. Ни өчендер Батулла лифтка керми тора. Мөдәррис аны дәшә:
— Әйдә, Батулла, син генә сыясың әле монда.
Батулла:
— Юк инде, агайне, син сыйган җиргә мин сыймамдыр.
Мөдәррис:
— Шулай шул. Бер лифтка «ике тәкә башы» сыймый ул...

## Кирәген әйткән...

Бервакыт шулай, Сибгат Хәким партия өлкә комитетыннан чыгып килә икән. Ана студент шагыйрьләр очрый.
— Исәнмесез, Сибгат абый. Нихәлләр?
— Яхшы-ы... «Беренче»нең үзе янынннан чыгып килешем әле.
— Кергән-кергән теге... ни... яхшырак итеп, тазарак итеп әйтергә иде, Сибгат абый. Юкса ни бит...
— Әйттем инде кирәген, әйттем...
— Нәрсә дидегез соң?
— Әйттем инде, әйттем. Үзегенә үтәрлек булды.
— Шулай да, нәрсә дип әйттегез икән Сибгат абый? Ә?
— Әйттем инде, әйттем. Һы-ы. «Исәнмесез, Фикрат Әхмәтҗанович!..» — дип әйттем. Тәки татарча исәнләшергә мәҗбүр иттем үзен! Һы...

## Дуслык телендә аңлашу

Әхәт Гаффарның Әлмәт Язучылар берлеге башлыгы булып эшләгән еллары. Кичен өенә кайтып килгәндә бер салмыш адәм юлын кисә моның. Тәмәке сорый. «Юк!» — дип кенә китеп бармакчы була Әхәт, әмма алай ансат кына котылырсың исеректән. «Скряга! Шею сверну!» — дип, русчалатып сүгенә, бала башы кадәр йодрыгын Әхәтнең борын төбендә уйната башлый теге имансыз. Әхәт Гаффар да төшеп калганнардан түгел, күкрәген киерә төшеп, болай ди:
— Нет, брат! Не сможешь, брат! Депутат, брат!
Бу вакыйганың бердәнбер шаһиты Хәйдәр Гайнетдиннең әйтүенә караганда, теге юлбасарның кикриге шундук шиңеп төшә һәм ул шәмаилдән качкан шайтан шикелле, шыпан-шыпан китеп бару җаен карый. (Депутат белән бәйләнешеп, башын бәлага тыкмас бит инде.)

## Эльс Гаделгә ТАССтан хат

Мәшһүр диктор Эльс Гадел бервакыт «Татарстан яшьләре» редакциясендә тәрҗемәче булып эшли. Гәзиткә Мәскәүдән килеп торган ТАСС материалларын тәрҗемәләп биреп бара. Моның өчен, билгеле инде, аз-маз гонорар да тия үзенә.
Беркөнне Эльсның бүлмәдәше Илдус Сафин, кеше-кара күрмәгәндә генә, Мәскәүдән килгән конвертны ача да, ТАСС материалы өстенә машинкада болай дип өсти:
«Товарищ Гаделев! Вы систематически используете наши материалы в вашей газете. За это Вы должны высылать нам часть гонорара». Һәм конвертны әйбәтләп ябыштырып, Эльс өстәленә куя.
Эльс Гадел эшкә килгәч, теге конвертны ача. Язуны кат-кат укый. Йөзе җитди, анда — аптырау галәмәте. Илдус моны күрмәгәнгә салышып, үз эше

белән мәшгуль сыман утыра. Гадел ТАССтан килгән хатны күтәреп, газета мөхәррире Хәлим Гайнуллин янына кереп китә. Бераздан ай шикелле балкып чыга.

— Миңа дигән хатның безнең машинкада басылган булуын ничек абайламадым соң мин-дивана! — ди ул. — Дөрестән дә, ТАСС журналистларына безнең машинка каян килсен? Әллә, Илдус, син ТАССка эшкә күчтеңме?!

## Кама Тамагында мишәрләр бармы?

Туфан Миңнуллин «Казан утлары» журналы редакциясендәге дусларына туган яклары — Кама Тамагына кайтып килүе турында сөйләп тора. Шунда бер мишәр егет сорап куя:

— Ә Кама Тамагында мишәрләр бармы соң?

— Юк.

— Ницек яшисез соң сез мишәрләрсез? Кыендыр бит?

— Кыен, бик кыен,— ди Туфан, мыек астыннан көлеп.— Әмма без акыл алырга Цүпрәләгә барып катябыз.

## Бер куянны тоту өчен

Туфан Миңнуллин троллейбуста бара. Кремль тукталышында контролер килеп керә һәм юлчыларның билетларын тикшерә башлый.

— Бер куянны тоту өчен күпме арысланның кәефен бозалар...— ди Туфан ризасыз тавыш белән.

## Итәк астыннан

Журналист һәм детектив әсәрләр язучы Госман Гомәр районга командировкага бара. Бер авылда аракы алмакчы булып, кибеткә сугыла. Ләкин киштәләр буш. Госман кибетче хатынга әйтә:

— Мин беләм бит, сез башкаларга «итәк астыннан» гына биреп ятасыз. Миңа да бирегез! — ди.

Шуннан сатучы хатын итәген күтәреп, мул гына артына чәбәкли дә:

— Мә соң ал, энем, ал гына, жәл түгел синең өчен дә! — ди икән.

Госман кибеттән ничек атылып чыгып китүен үзе дә сизми кала.

## «Авыр туфрагың җиңел булсын!»

Мәгълүм ки, халыкка дача өчен җирнең юнлесен бирми хөкүмәт. Йә ул элекке карьер булыр, яки сазлык, яисә чокыр-чакыр. Андый җирне алдыңмы инде, гомер буе туфрак ташып чиләнәсең.

Әнә язучыларның «Весна» дип аталган дачалар җиреннән элек кирпеч заводы өчен сары балчык чыгарганнар. Хәзер инде, киресенчә, шундагы үз җиренә һәркем үзе булдыра алганча, балчык-туфрак ташый.

Хәкимҗан Халиков урман туфрагын зур биштәргә тутыра да, аркасына асып алып кайта.

Бер көнне аңа каршы Габделхәй Сабитов очрый.

— Авыр туфрагың җиңел булсын, Хәкимҗан дус! — дип «күәт бирә» ул.

Хәкимҗан маңгаендагы борчак-борчак тирне учы белән сөртә дә, зәңгәр күзләрен хәйләкәр кысып, Габделхәйгә карый:

— Сүзең хак, кордаш. Эшләр болай барса, мондагы күп язучыга синеңчә сәлам бирергә туры килмәгәе...

## Яхъяның теше ничә?

Татарстан китап нәшриятының атаклы мөхәррире Яхъя Халитов эштән еш кына сорап китә торган була. Һәр сораган саен: «Тешемне алдырасым бар иде...» — ди икән.

Бүлек мөдире Фәрваз Миңнуллин да хәйләкәр. Теге сорап киткән саен өстәл календарена бер таяк сызып бара.

Көннәрнең берендә Яхъя Халитов янә керә бүлек мөдиренә:

— Тешемне алдырырга барасым бар иде, китим әле мин?— ди.

Фәрваз Миңнуллин, каш астыннан сөзеп карый да, елмаеп болай ди:

— Яхъя абый, синең ничә тешең бар иде? Инде бит 96 тешеңне суыртып алдырдың. Авызында тагын ничә тешең калды соң?

Усал мөхәррир дә аптырап калмый:

— Халтурщик авторларны тешләргә генә җитәрлек әле!— дип җавап бирә.

## Кыскарткан...

Нияз Акмал «Казан утлары»на үзенең «Күгәрчен сөте» исемле әсәрен тәкъдим итә.

— Бераз озынрак икән,— ди проза бүлеге мөхәррире,— 250 бит чамасы калдырып, кыскартсаң иде.

— Кыскартабыз аны!— дип, Нияз кульязмасын алып китә. Берничә көннән елт итеп янә килеп тә җитә бу.

— Менә кыскарттым, абый,— ди.

Мөхәррир кульязманы актарып карый, бер бите дә кыскартылмаган, элек ничек булса — шулай.

— Кайсы урынын кыскарттың соң моның?— дип сорый ул автордан.

— Соң күрмисеңмени?— ди Нияз.— Фамилиямне кара. Элек «Акмалов» иде, хәзер «Акмал» дип кенә калдырдым. Кыскарттым...

## Шуңа да көнләшкән

Иртән эшкә килгәч, Рәшитнең бер хезмәттәше зарлана:

— Дачама караклар кергән. Электр счетчигын алганнар да үткәргеч чыбыклар очына изолента урап калдырганнар. Янгын чыкмасын дигәннәрдер, күрәсең. Башка әйберләргә тимәгәннәр үзе. Ишек-тәрәзәләрне ватмыйча, форточкадан тыгылып, башта тәрәзәне ачканнар. Шуннан кергәннәр. Чыкканда тәрәзәне әйбәтләп ябып калдырганнар. Каян кергәннәрен дә тикшерә торгач кына абайладым. Шундый тәгәллек һәм саклык белән эш иткәннәр...

Рәшит Әхмәтҗан тыңлап-тыңлап тора да болай дип әйтеп куя:

— Әй, кешенең дачасына да җүнле караклар гына керә ичмасам...

## Яхшы эшләгән...

Баш мөхәррир бүлмәсендә җыелыш бар. Көн тәртибендә подписка мәсьәләсе. Баш мөхәррир журналга яздыру буенча кемнең ничек эшләгәнлеген сораштыра.

— Ә син, Рәшит абзый, ниләр эшләдең?— дип сорый ул, озын нечкә кулларына якты башын салып, йокымсырап утыручы Рәшит Әхмәтҗаннан.

— Ә?! Яхшы эшләдем!— дип, чатнатып җавап бирә Рәшит.— Әле генә Баулыдан командировкадан кайттым.

— Командировкада ниләр эшләдең соң?

— Кулдан килгәннең барысын да эшләдем.

— Ә шулай да, конкрет алганда...— дип, йомшак кына кызыксына баш мөхәррир.

— Яхшы эшләдем. Командировкада мин дүрт көн булдым. Ике көн бардым... аннары... ике көн кайттым... Котчыккыч яхшы эшләдем!

## Көлне кая сибәргә?

Мәрхүм Рәшит Әхмәтҗан ихлас сөйләшергә, арада аз гына зарлангалап алырга да маһир иде.

Бер көнне эшкә килгәч, бүлмәдәше Мансур Вәлигә әчен бушата бу:

— Малай, дачамдагы гөрләп үсеп утырган бәрәңге сабаклары күз алдында диярлек шиңеп төште...

Мансур:
— Медведька дигән зәхмәт анық тамырын кисәдер. Бәрәңгеләреңнең төбенә көл сип син.
Рәшит:
— Жук, аңардан түгел... Күз тигәннән шиңә алар. Әхәт Гаффар күзен акайтып: «У-у, бәрәңгыгыз шәп икән. Һәр төптән бирәр чиляк була икән!» — дип шаккатып узган иде. Торганы шуның зәхмәте тиде...
Мансур:
— Алайса, Гаффарның күзенә көл сип! — дип куя.

## Митинг дип белгән

Милли көрәшче Рәшит Әхмәтҗан, илле яше тулгач, үзенең дус-ишләрен кунакка чакыра. Тост артыннан тостлар әйтелә. Кайнар речьләр тотыла.
Мәҗлеснең иң кызган бер вакытында Рәшит кинәт сикереп тора да кулларын алга сузып:
— Азатлык! Азатлык! Азатлык! — дип кычкырып җибәрә.
— Ни кылануың инде бу, Рәшит? Өендә моның ирегеп кысалар икән дип уйлаулары мөмкин...— ди хатыны борчылып.
— Ә-ә! Мин бит үземне Ирек мәйданында, митингта дип торам! — ди Рәшит.

## Язучылар берлегенә кемне алырга?

Вакыйга Язучылар берлеге коридорында бара. Идарә әгъзалары әле генә колхоз рәисе булып эшләүче берәүне Язучылар берлегенә әгъза итеп алганнар. Берлеккә кабул итү комиссиясе сәркатибе Рәис абый Даутов белән күрешкән Мөдәррис әйтә:
— Союзга бөтен колхоз рәисләрен алып бетердегез бугай инде... Хәзер спонсорларны ала башласагыз да буладыр...
Рәис абый:
— Спонсорларны союзга алу килде-китте язучыны алуга караганда яхшырак ләбаса.
Мөдәррис:
— Ярый ла ул спонсор Дәрдемәнд кебек миллионер да, шәп шагыйрь дә булса...
Рәис абый (көлеп):
— Байлыгы булса, шигырь язуы ниемә хаҗәт аның, хе-хе...

## Сәламенә күрә җавабы

Заманында каләм кыштырдаткан, соңра сату-алу эшенә, ягъни бизнеска керешкән берәү урамда шагыйрь Мөдәррис Әгъләмне очратып, болай ди:
— Ну Мөдәррис, мин сиңа бер йөз доллар бирсәм, адәм рәтенә керер идең инде керүен...
Мөдәррис башын гадәтенчә кыңгырт салып, моңа карый да:
— Ә синнән, агайне, йөз түгел, мең долларың булса да, шагыйрь чыкмаячак! — дип, юлын дәвам итә.

## Ирекле яшәү туйдырамы?

Матбугат йорты коридорында Роберт Әхмәтҗанов белән Мансур Вәли очрашалар.
Мансур:
— Роберт абый, тагын эшкә кердеңме әллә?
Роберт:
— Керергә туры килде, парин. Яңадан «Шәһри Казан»да мин.
Мансур:
— Ирекле яшәү туйдырдымыни?
Роберт:

— Юк шул, парин, ирекле яшәү тамакны туйдыра алмаганга кердем дә инде эшкә...

## «Виолончель булыр идем...»

Әдәбият-сәнгать әһелләре Арча районы хезмәт ияләренең бозауларны салкында кышлату тәҗрибәсен карарга баралар. Көндез хуҗалыкларда булганнан соң, кичен мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә оештырыла.

Менә сәхнәдә, оркестрга кушылып, Миңгол Галиев җырлый:

«Мин гармун булыр идем,
Назлы җыр көйләр идем...»

Оркестрның алгы рәтендә Лариса Маслова, виолончеленең сыңар аягын үзенең йомры, матур бот арасына кыстырган да нәфис куллары белән биленнән кочып кына, кылларын чиертә. Җан сөйгәненең чәчен сыйпап иркәли диярсең. Залның алдагы рәтендә шушы гүзәл күренештән бихуш булып утыручы шагыйрь Рашат Низами Миңголга кушылып әйтеп җибәргәнен сизми дә кала:

«Ә мин исә, Миңгол абый,
Виолончель булыр идем...»

## Кем арбасына утырсаң...

Могътәбәр бер журналда Фәнзаман Батталның фотосурәте белән саллы гына әңгәмәсе басылып чыга. Шушы куаныч уңаеннан берничә егет аның фатирында очрашалар, «өстәл» корып җибәрәләр. Фәнзаманның, билгеле инде, чәе дә, мәе дә җитәрлек була. Гапләшәләр, фикер алышалар, акыл көрәштерәләр.

Тора-бара кунаклар тагын да сүзчәнләнеп, егәрләнеп китә. Һәркайсының сөйлисе килеп кенә тора бит, әттәгенәсе! Әмма ул чакларда тамчы да хәмер капмаучы Фәнзаман, сөйләшү дигәндә теле-телгә йокмыйча, кунакларыннан да уздырып, сүз айгырын һаман үз кулында тота.

Шунда Рашат Низами түзми, саубуллашканда әйтеп куя:

— Син, Фәнзаман абый, бездән дә ныграк «кәефләндең» бугай. Түлке, зинһар, иртәгә баш төзәтә күрмә. Ярыймы?...

— Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың икән ул, җәмәгать,— ди Фәнзаман.

## Бәхет өчен күп кирәкме?

Шагыйрь Рәдиф Гаташның каләмдәшләре белән очрашканда сәлам биргәннән соң: «Бәхетлеме син?» — дип сорап куя торган гадәте бар. Җаваплар төрлечә була, әлбәттә. Әйтик, Рөстәм Мингалим болайрак җавап бирә:

— Шундый шәп, просто түзеп булмаслык. Тик шунысы гына начар: киләчәктә тагын да шәбрәк булачак, диләр...

Мәгъсум абый Хуҗин баш бармагын тырпайта да, кыска гына итеп:

— Әтәч кебек! — дип куя.

Шаһинур Мостафин да әлеге сорауга елмаеп җавап бирә:

— Әйбәт бит, дустым. Гөлләр кебек!

Бер читтәнрәк, әз генә өстәнрәк карап торган Тәүфикъ Әйдинең йөзе җитди:

— Хы, нәрсәсе әйбәт икән? Хезмәт хакын да үз вакытында бирми башладылар.

— Кайгырма, дустым,— ди Шаһинур,— авылда күптән шулай бушка эшлиләр... Әле президент аппаратында эшләүчеләр үзләре дә бер айдан бирле зарплата ала алмыйлар, ди.

Инде Тәүфикъ та елмая:

— Хы! Син шуңа ышандыңмы? Хы-хых! Ай, көлдердең тәки. Син шуңа ышандыңмы?

— Ышанырга кирәк, дустым. Ышана белү — үзе зур бәхет ул,— ди Шаһинур.— Менә мин хәзер сине елмайта алуым белән икеләтә бәхетле.

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

### Гамир Насрый

(1916—1959)

Күренекле драматург Гамир Насрый 1916 елның 3 январенда хәзерге Башкортстанның Кызыл Кама районы Иске Янҗегәет авылында крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белем ала, 1928—31 елларда Казанда туганнары гаиләсендә тәрбияләнә һәм җидееллык мәктәптә укый. Ә 1932 елда туган авылына кайтып башта колхозда хисапчы, аннары район башкарма комитетының авыл хуҗалыгы бүлегендә секретарь һәм район газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Шуннан соң ул Казан театр техникумында укый, Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә фин сугышында катнаша.

1942 елда Гамир Насрый фронтка китә. Ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Сугышның соңгы чорында ул фронт газетасында эшли һәм яза. Сугыштан кайткач, Татарстан радиокомитетында эшли, 1949 елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. 1959 елның 27 декабрендә вафат була.

Гамир Насрый бик яшьли яза башлый. 1932 елда, 16 яшьлек үсмер чагында, аның дүрт пәрдәле пьесасы матбугатта чыга. Ул бигрәк тә кече формалы сәхнә әсәрләрен күп яза һәм үзен үткен телле, тормышчан конфликтлар, көлке ситуацияләр кора белгән драматург итеп таныта. Соңгы елларда Г. Насрый комедия жанрында актив эшли.

Гамир Насрый — кырыкка якын сәхнә әсәре авторы. Көндәлек матбугатта аның сатирик шигырьләре һәм поэмалары, хикәяләре дә басыла иде. Әдип җыр жанрында да эшләде. Гомумән, әдәбиятыбыз хәзинәсенә матур-матур әсәрләр калдырды.

●

## АЛДАГЫ САННАРДА

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

Журналыбызның алдагы саннарында сезне мондый яңа әсәрләр һәм язмалар көтә. Әйтик, проза хәзинәсеннән **Әнәс Галиев**нең «Җимерелгән хыяллар», **Роберт Айзатуллин**ның «Ирекле тоткыннар» романнары, **Рафаэль Сибат**ның «Текә күтәрелеш» дигән документаль повесте, **Рабит Батулла**ның «Американы мин ачтым» дигән сәяхәтнамәсе белән таныша аласыз. Шигърияттән **Гамил Афзал, Равил Фәйзуллин, Әхсән Баянов, Әхмәт Рәшитов, Клара Булатова, Роберт Миңнуллин** шигырьләре дә күңелегезгә хуш килер дип ышанабыз.

**Габдулла Тукайның тууына — 110, Муса Җәлилнең тууына 90 ел** тулу уңаеннан бай һәм кызыклы сәхифәләр биреләчәк.

## УКУЧЫ СҮЗЕ

* * *

Хөрмәтле редакция!

Татар әдәбияты тиздән зур югалту кичерәчәген сизгән кебек, журналыгызның апрель санында өр-яңа язучы Тәбриз Мөбәрәковның «Хәтер аланы» романы белән таныштырып, укучыларыгызны никадәр сөендергәнегезне беләсезме икән?! Ә шуннан соң күп тә үтмәде, халкыбызның яратып укый торган, үзенә генә хас матур телле, олы язучысы һәм галиме Мөхәммәт Мәһдиевне югалттык. Арча төбәге, бигрәк тә Гөберчәк авылы, аерата моңаеп, ятим калган кебек тоелды. Чөнки ул якларның кадерен белеп яшәгән, шуны гомере буе иҗатында чагылдырган, туган авылын иң гүзәл легендага әйләндергән бай табигатьле шәхес тә иде ул. Ә менә Гөберчәкнең күршесендә генә Мөрәле авылыннан чыккан Тәбриз Мөбәрәков үзенең бу әсәре, аннан берсе артыннан берсе «Шәһри Казан» битләрендә дөнья күргән хикәяләре белән («Кәшимир шәл», «Аю белән Аккош мәхәббәте») безне бу зур югалтудан азмы-күпме юаткан кебек булды. «Юк, Арча төбәгендә талантлар чишмәсе саекмасын әле, әдәбиятта тоткан мәшһүр урынын тагы да киңәйтсен әле»,— дигән кебек тоелды. Зур рәхмәт Сезгә!

Әйе, элек-электән иң мөхтәрәм журналыбыз «Казан утлары» тагы бер мәртәбә укучылары алдында изге бурычын гадел, эчкерсез тормышка ашыра барганын күрсәтте. Югыйсә, Т. Мөбәрәков — Казан университетының физика-математика бүлеген тәмамлап, аннан аспирантурада гыйлемен тагын да үстереп, кандидатлык диссертациясен яклап, гомере буе математика өлкәсендә эшләгән галим. Җитмәсә, Татарстанда да түгел, Уфада. Бу өлкәдә аның күпме гыйльми хезмәтләре дөнья күргән! Кем уйлаган аның эчке дөньясында шуның кадәр, моңарчы беркемгә дә билгеле булмаган, әдәби хәзинә яшеренеп ятар дип. Юк, күпкырлы талант әдәби иҗат белән дә шөгыльләнгән икән. Язган, күп язган, шомарган. Тик ни өчендер ул аларны дөньяга чыгармаган. Бәлки, аның сәбәпләре дә булгандыр...

Ә менә Сез, мөхтәрәм редакция әһелләре, аның әле беренче мәртәбә генә мөрәҗәгать итүенә, беркемгә таныш булмаган автор булуына карамастан, үзегезнең саллы журналыгызда урын биреп (урынның да журналның иң түреннән, авторның сурәте белән!) нинди зур изгелек күрсәткәнсез. Аның алдагы иҗатына зур илһам канатлары куйгансыз, дип уйлыйбыз. Сезнең журналыгыз аркылы, яраткан язучыбыз Фәнис Яруллин әйтмешли, **«быел безнең әдәбиятка чишмә кебек бәреп, бер яңа исем килеп керде — ул Тәбриз Мөбәрәков».** («Шәһри Казан», 27/X—95 ел)

Аның безнең күрше генә авылдан булып, үзен бөтен яктан да яхшы белгәнгә күрә, бу — безнең өчен икеләтә шатлык булды.

Әсәрне укып бетергәч, без беравык югалып калдык, ниндидер бик кадерле әйберне җуйгандай булдык, ә үзебез һаман да романдагы күңелләрне тетрәндерә торган вакыйгалар эчендә калдык. «Журналда әсәр кыскартылып бирелә»,— дигән сүзләрне укыгач кына, димәк, әле андагы геройлар белән тагын очрашабыз икән, Алла боерса, дигән өмет белән тынычлана төштек. Һәм, күп тә үтми, авторның кульязмасын табып, әсәрне тулысы белән уку бәхетенә ирештек. Тулы варианты бик күпкә көчле яңгырый. Анда авторның фәлсәфи карашлары, төрле вакыйгаларга бәйләп керткән үзенең җырлары, такмаклары әсәрне тагын да баеткан.

Дөрес, кыскартып бирүнең сәбәпләрен дә аңлыйбыз (журнал варианты). Әмма «Хәтер аланы»н укучыга тулысы белән житкерәсе иде. Аның өчен әсәрнең китап булып басылып чыгуы кирәктер инде. Бәлки әле алга таба бу авторның китапларын күрү дә насыйп булыр.

Соңгы бер чыгышында М. Мәһдиев: «Кабат кайтылып укыла торган әсәр иң яхшы әсәр була, соңгы вакытта андыйлар бик күренми әле»,— дигән иде. Менә «Хәтер аланы» — ничә кабат укысаң да — яратып укыла торган әсәр. Чыннан да, ул китап булып чыкса, татар әдәбиятына отыш кына китерәчәк. Бу роман — тел өйрәнүдә, аны тагы да баетуга хезмәт итәрлек әсәр дип бәяләдек без аны.

Аннан авторның тагын бер кадерле ягы: ул нинди генә тискәре образны бирмәсен, аны бөтенләй карага батырмый, киләчәгенә ниндидер өмет калдыра һәм кайбер геройларның кешелек сыйфатларын югалта баруда шул чордагы җәмгыятьнең вәхши яклары сәбәпче булуны тирән итеп ача белә.

Тагын Т. Мөбәрәковның без укыган өч әсәрендә дә хатын-кызга җылы карашы, аларның эчке дөньясын тирән аңлый белүе безне бик куандырды. Кешеләр язмышында саф мәхәббәтнең нинди көчкә ия булуын укытучы Габдерахман, Фатыйма, Габделхәй һәм Купцовлар гаиләсе аркылы нинди саф, матур итеп бирә. Ярату хисләрен шулкадәр саф, изге итеп тасвирлавы йөрәкләргә май булып ята, рәхмәт төшкере!

Шушындый матур хисләрне без Аяз Гыйлаҗевның (сезнең журналда ук) «Яра»сын укыганда кичергән идек. Ул да, ничә кат укысаң да, йотылып укыла.

Тагы Т. Мөбәрәковның көче шуннан гыйбарәт — ул укучыны, әсәрен укый башлау белән үк, вакыйгалар тыгызлыгы, табигый күренешләрне һәм персонажларының эчке һәм тышкы кыяфәтләрен тасвирлауда кулланылган гаҗәп кызыклы алымнары белән бөтереп алып китә дә, ахырга кадәр үзеннән ычкындырмый. Кайбер урыннарында чыдый алмыйча көлдертә, кайбер урыннарында үзең дә сизми каласың, күзләрең яшь белән мөлдерәп тула. Мәсәлән, «Мәче борын» кушаматы алган Галихуҗаны ул болайрак сурәтли: «Лэбә белән сызылган шикелле түгәрәк йөзнең өчтән бер өлеше калын, кайтарылган иренле зур авызга сарыф ителгән, өчтән бер өлеше зур соргылт-яшел күзләре, калын җирән кашлары астында калган. Ә маңгаена бөтенләй урын җитмәгән. Авыз белән күзләр арасына, борын булырга тиеш җиргә, Ходай Тәгалә төймә кадәр генә бер төерчек чәпәп куйган, бүтәннәренә мулдан җибәргәч, борынга материалы җитми калган, күрәсең».

Менә тагын бер мисал. Тәүфыйкның су буенда Галимәнең ялангач гәүдәсен күреп үзенә дә аңлаешсыз тирән тәэсирләнүен автор болай сурәтли: «13 яше тулып килгән үсмернең балигъ булган кызларның яшерен, ләкин гөнаһсыз гүзәллеген, оят, әмма гыйффәтле матурлыгын үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде». Сөбханалла, бер җөмләдә нинди тирән мәгънә ята!

Әсәрдә еш кына табигать күренешләренең, таулар, чишмәләр, урман-аланнарның гүзәллеген искитәрлек зәвык белән, нәкъ табигатьнең үзенчә тасвирлануы безне таң калдырды. Ә кайбер язучыларның әсәрләрендәге мондый урыннарны төшереп калдырып укыйсың, ул үзенә җәлеп итә алмый, әсәр дә аннан күп нәрсә югалтмый. Ә Тәбризнең бу юлларын кабат-кабат укыйсың, ул эчтәлек белән шулкадәр тыгыз бәйләнеп килә, аның хәтта бер генә сүзен дә төшереп калдырасы килми.

Менә Мирас авылы өстенә бик көтелеп алынган яңгырның куркыныч булып килүе, болытларның төрләре һәм гыйбрәтле күренешләре сине: «Әллә нинди афәтләр генә була күрмәсен инде»,— дип чынлап торып борчуга сала. Баштагы җил давылы, аннан яңгырның башланып китү, көчәю, ниһаять туктау рәвешләре сине ирексездән шул вакыйгалар эчендә калдыра, башта тузанга төрә, аннан чылата башлап җеббөртексез итә. Хәтта әсәр кыш көне укылса да, ул шулай тәэсир итәчәк. Бу инде менә язучының укучысын бер генә минутка да үзеннән ычкындырмыйча тотуының сихри көчедер. Бу әсәр турында никадәр генә язсак та, уртаклашасы фикерләребез бетмәстер...

Тагын бер кабат олы рәхмәтебезне белдереп, сезнең журналны һәрчак яратып укучыларыгыз:

**Әхмәт һәм Гөлчәчәк ГАЛИЕВләр.**
Казан.

## Анатолий Мухачев

«Тимер» акционерлык ширкәте президенты,
Россиянең атказанган төзүчесе

# Авылга «Тимер» дә кирәк!

«Сивяга» акционерлык ширкәте герман-швейцария фирмасы «Бюйлер»дан чит ил җиһазлары кайтарта башлагач, ашыгыч рәвештә завод бинасы төзергә туры килде. Ярдәм сорап Буа махсус күчмә мехколоннасына мөрәҗәгать иттеләр. Һәм оттырмадылар. Монтажчылар берничә атна эчендә модуль металл конструкцияләрдән һәм җылытылган каркас панельләрдән өч катлы бинаны төзеп җиткерделәр, үз вакытында җиһазлар һәм механизмнар урнаштырылырга тиешле ярусларны да әөеп куйдылар. Аларны автоматика һәм электроника белән җиһазладылар. Кулланучылар тиздән карабодай ярмасы һәм үсемлек мае ала башладылар.

Бу «Тимер» акционерлык ширкәте мобиль подразделениеләренең күпсанлы эшчәнлегеннән бер мисал гына. Беренче чиратта безнең заказчылар — авыл эшчәннәре, кыр-басуларда, фермаларда хезмәт итүчеләр. Җиләк-җимеш-яшелчә саклагычлары, күпсанлы максатлы тәгаенләнгән универсал биналар, ашлык саклау складлары, авыл хуҗалыгы техникасы өчен ангарлар, мал асрау биналары — безнең белгечләр боларны проектыннан алып ачкыч тапшырганчы башкаралар. Әгәр Татарстан картасына безнең зоналарны язып чыксаң, шактый куе челтәр хасыйл булыр иде. Чагыштырмача кыска вакыт эчендә Татарстан агрокомплексына утыздан артык җиләк-җимеш, яшелчә саклагычлар, алтмыштан артык суыткыч складлары эшләп тапшырылды. Аларны төзү дәвам итә.

Бер-берсеннән йөзәр чакрым ераклыкта урнашкан бу объектлар ничек төзелә соң?

Бу эшне күппрофилле «Тимер» алып бара. «Татагроспецмонтажпроект» тикшеренү-проектлау институты бөтен кирәкле документларны әзерләп тора. Зәй эксперименталь заводы һәм Столбище модуль металлоконструкцияләр заводы, шулай ук мехколонналарның производство цехлары комплектлау узелларын һәм панельләрне җитештерә. Әлмәт, Буа, Кукмара, Түбән Кама, Байлар Сабасы, Теләче, Алексеевск, Чистайда биналар корыла, җиһазларны монтажлау бара. Һәркайда яхшы автотрассалар, тимер юллар бар, алар эшне арзанайта (чыгымны киметә) һәм җиңеләйтә.

Кыскасы, агрокомплекс заказлары теләсә кайсы вакытта һәм республиканың теләсә кайсы почмагында үтәлә ала. «Тимер» ширкәте белән килешү төзегән заказчылар өстәмә чыгымнардан да котылалар, субподрядчиклар эзләп тә йөрисе юк. Шул ук вакытта эш сыйфаты Европа үлчәмнәренә туры килтереп, югары дәрәҗәдә була. Без алдынгы чит ил фирмаларыннан үрнәк алабыз. Мәсәлән, фин фирмасы «Макрон» җиһазларын тулысы белән алып, без җиңеләйтелгән җылылык панельлары — «сэндвич»лар чыгаруны үзләштердек. Бу — монтажлау эшләрен тизләтә, корылмаларыбыз эстетик яктан да отышлы була. Татарстанга Германия, Финляндия, Венгрия, Италиядән югары сыйфатлы җиһазлар кайта. «Тимер»нең эшләп чыгарган продукциясе белән Төркия, Болгария, Канада, Бөекбритания эшкуарлары (бизнесменнары) да кызыксына.

Әмма зур күләмле суыткычлар, саклагычлар төзесәк тә, гигантомания

белән авырмыйбыз. Хәзер без, мәсәлән, фермер хуҗалыклары төзибез, йортлар, ангарлар, сыер фермалары, теплицалар, гаражлар, мунчалар һ. б. бик күп объектлар корабыз. Кечкенә габаритлы суыткычлар, автофургоннар да җитештерә башладык.

Татарстан авылларын газлаштыру аерым игътибар сорый. 1995 елның икенче яртысында без дә газлаштыруга лицензия алдык. Эшне башлап та җибәрдек. Австралия технологиясе нигезендә тәҗрибә төсендә казаннар ясый башладык. Быел ул казаннар күпләп чыгарылачак. Авыл халкы аларны бик теләп ала. Авылларда да халык газ ягып, бөтен уңайлыклар белән яшәргә тели.

Тораклар төзү проблемасы белән дә «Тимер» шөгыльләнә. Татарстан республикасының җитәкчеләре, безнең күп профельле оешма икәнне истә тотып, безне дә республиканың «Торак йорт» программасына эшләргә тартты. Алдагы елларда иске йортлардан котылу — реаль бурыч. Коттеджлар иң яңа материаллардан иң яңа технология буенча салыначак. Бу максаттан чыгып Австралия эшкуарлары-бизнесменнары белән элемтәгә кердек. Аларның проектлары Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиев тарафыннан да уңай бәя алды.

Авыл юлларында чиләнмәгән кеше юктыр, күпме техника ватыла, күпме азык-төлек әрәм-шәрәм була. Хәзер күп кенә районнарда бу эшкә ныклап тотындылар. Безнең ширкәт тә читтә калмады. Аерым алганда Буа, Теләче, Кукмара спецмехколонналары җиң сызганып эшкә керештеләр. Алар күрше районнарга да ярдәм итәргә торалар.

Базар мөнәсәбәтләре, икътисади элемтәләрнең тулы булмавы, заказчыларның да хәлләре җитеп җитмәве безне яңа юллар эзләргә этәрә. Әмма ләкин нинди генә шартларда да авыл эшчәннәренә тырышып хезмәт итәчәкбез. Авыл халкы яхшы эшләргә, яхшы яшәргә, яхшы ял итәргә хаклы. Безнең «Тимер» маркасы югары торырга тиеш.

Безнең ширкәтебезнең уставы эшчән, коры һәм кыска. «Тимер»нең төп бурычы: игенче-терлекчеләргә нәтиҗәле хезмәт күрсәтү, алар бит безне сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итәләр, ә промышленностька тиешле чимал бирәләр.

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ЛАУРЕАТЛАРГА — ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ

29 декабрьдә Казан Кремлендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев 1995 елда республикабызның Дәүләт бүләгенә лаек булган бер төркем лауреатларга дипломнар һәм күкрәк билгеләре тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында Казан дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы — журналыбызның редколлегия әгъзасы Хатип Миннегулов, Татарстанның травматология-ортопедия фәнни-тикшеренү үзәге директоры — медицина фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Хәйдәр Гаффаров, Арча районы хакимияте башлыгы Вагыйз Минһаҗев һ. б. бар.

## ХАТЫН-КЫЗЛАР КОРЫЛТАЕ

21—22 декабрь көннәрендә башкалабыз Казанда Татарстан хатын-кызлары корылтае үткәрелде. Аңа төрле төбәкләрдән, чит илләрдән дә мәртәбәле кунаклар килгәннәр иде. Корылтайның беренче көнендә делегатлар төрле оешмаларда, предприятиеләрдә булдылар, секцияләргә бүленеп, мөһим мәсьәләләрне тирәнтен өйрәнделәр. Икенче көнне исә Г. Камал театры бинасында корылтайның пленар утырышы булды. Корылтай делегатларын Татарстан Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин котлады. Доклад белән ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары З. Вәлиева чыкты. Фикер алышуларда «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Р. Туфитуллова, Россия хатын-кызлары союзы рәисе А. Федулова, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Чаллы хакимияте башлыгы Р. Алтынбаев, «Теплоконтроль» заводы генераль директоры В. Кулагин һ. б. катнашты.

Корылтайда Татарстан хатын-кызлары оешмасының эш платформасы билгеләнде. Оешманың рәисе итеп З. Вәлиева сайланды.

## ЖУРНАЛ ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ ЧАКЫРА

Инде өченче ел республикабызда, төсле рәсемнәр белән бизәлеп, һәртөрле кызыклы материалларга бай һәм яхшы сыйфатлы «Бизнес в Татарстане» журналы (баш мөхәррире — Хәсән Вәлиәхмәтов) чыгып килә. Рус һәм инглиз телләрендә нәшер ителүче бу басманы Татарстан Республикасының Тышкы икътисади бәйләнешләр министрлыгы белән ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы гамәлгә куйган иде. Журналның 1995 ел азагында чыккан соңгы саны да укучыларнең игътибарын үзенә җәлеп итәрлек итеп эшләнгән. Анда Татарстан Республикасы Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин белән әңгәмә, «Промтранссервис» акционерлык җәмгыяте президенты Шамил Давыдов язмасы, «Вираж» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Рәшид Шәйхетдинов, «Мәгариф» нәшрияты һәм аның директоры — язучы Мөдәррис Вәлиев турында кызыклы материаллар һәм фоторәсемнәр урын алган. Журнал шулай ук башкалабызда ачылган «Арча» сәүдә йортында, «Сельхозтехника» сәүдә үзәгендә генераль директорлар булып эшләүче бертуган Ирек һәм Илдар Хафизовлар, «Идел» агрофирмасы житәкчесе Рафикъ Гыйльметдинов һәм Идел аръягындагы «Подберезье» крестьян хуҗалыклары кооперативлары ассоциациясе рәисе, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Петр Чекмарев кебек кызыклы шәхесләр һәм аларның матур эшләре белән таныштыра, үзара хезмәттәшлеккә чакыра.

Журналда шулай ук рәссам Ильяс Фәйзуллин картиналары күчермәләре, Г. Камал театрында куелган «Идегәй» спектакленнән күренешләр бирелгән.

## ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

6—7 декабрь көннәрендә Биектау районы үзәгендә «Казан арты: тарихы һәм мәдәнияты, аның проблемалары» дигән темага I региональ фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Ул, Биектау районы оешуның 60 еллык юбилеена багышлап, әлеге район хакимияте тарафыннан, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан мәдәният министрлыгы, Иске Казан тарихи-мәдәни һәм табигать музей-тыюлыгы, Идел белән Нократ елгалары арасындагы төбәкнең көньягы — Казан артының мәдәни һәм тарихи һәйкәлләрен өйрәнү, саклау һәм файдалану проблемалары буенча гыйльми совет катнашында оештырылган иде.

## МУЗЕЙ ӘҺЕЛЛӘРЕ КИҢӘШӘ

Башкалабыз Казанда «Югары уку йортларының музейлары. Проблемалар, перспективалар» дигән темага региональ конференция булып узды. Конференцияне Урта Идел төбәгенең югары уку йортлары музейларының фәнни-методик советы, Казан Дәүләт университетының тарих музее, Татарстан Җөмһүриятенең берләштерелгән дәүләт музее оештырды. Урал урман-техника академиясеннән, Мари техник университетыннан, Коми университетыннан һ. б. юга-

ры уку йортларыннан килгән вәкилләр бүгенге көндә музейлар эшендәге мөһим мәсьәләләр турында җентекләп фикер алыштылар, киңәшләштеләр. Аннары, бергәләшеп, Казандагы Е. Баратынский, С. Сәйдәшев, М. Горький музейлары экспонатлары белән таныштылар. Татарстан Республикасының берләштерелгән дәүләт музеендагы «Иске музей» дигән күргәзмәне карадылар.

### УДМУРТИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ III КОРЫЛТАЕ

Ижевскида Удмуртиядә яшәүче татарларның III корылтае булып үтте. Әлеге республиканың Татар иҗтимагый үзәге тарафыннан оештырылган ошбу җыенга Казаннан һәм Чаллыдан да байтак кунаклар чакырылган иде. Корылтай Удмуртиядә гомер итүче 135 меңләп татарның мәнфәгатьләрен чагылдырган карарлар кабул итте.

### МӘКТӘПЛӘРГӘ ИСЕМ КУШЫЛДЫ

Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән, Әтнә районы Комыргуҗа урта мәктәбенә унтугызынчы гасырның танылган мәгърифәтчесе, олуг галим Шиһабетдин Мәрҗани исеме, ә Күлле-Киме урта мәктәбенә Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким исеме бирелде.

## *ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

14 декабрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып узды. Аның барышында Г. Бәшировның — 95, М. Җәлилнең 90 еллык юбилейларын үткәрү, әдәби ел йомгакларына хәзерлек һәм вафат булган кайбер язучыларыбызның исемнәрен мәңгеләштерү, кабер ташларын яңарту мәсьәләләре тикшерелде һәм шуларны тормышка ашыру юнәлешендә тиешле карарлар кабул ителде.

### ТУКАЙ КЛУБЫНДА ТАНТАНА

Танылган язучы-фронтовик Гурий Тавлинга 70 яшь тулуга багышлап, Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында кичә уздырылды. Юбилярны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы А. Гыйләҗев, әдипләрдән Б. Камалов, М. Хуҗин, шагыйрьләрдән Г. Зәйнәшева, С. Гәрәева, М. Әгъләмов, «Мәдәни җомга» газетенең баш мөхәррире З. Мансуров һ. б. котладылар.

Якташлары исеменнән Г. Тавлинны Зәй районы хакимияте башлыгы урынбасары Р. Нәҗипов тәбрикләде, бүләк тапшырды. Танылган җырчылардан Г. Казанцева, Г. Ибушев юбилярга багышлап керәшен халык җырларын башкардылар. Г. Камал театрының күренекле артисты Н. Дунаев юбилярның әсәрләреннән өзекләр укыды.

### РӘШИТ ГӘРӘЙ АТНАЛЫГЫ

Танылган шагыйрь Рәшит Гәрәйнең 65 яшьлек юбилеен Минзәлә һәм Тукай районнарында зурлап, әдәби атналык рәвешендә билгеләп үттеләр. Иң элек аның олы бәйрәме туган авылы Малтабарда уздырылды (Хәзер бу авыл Тукай районына керә). Юбилярны котлау өчен биредәге мәдәният сараена Тукай һәм Минзәлә районнары хакимиятләре башлыклары урынбасарлары Ф. Гыйниятуллина, З. Павлова, Казаннан шагыйрә С. Гәрәева, әдип М. Хәбибуллин, күпсанлы зыялылар, авыл хезмәтчәннәре килгән иде.

Минзәлә шәһәрләре мәктәпләрендә, «Чишмә» бакча-гимназиясендә, педагогия училищесенда, медицина техникумында һәм Дәвек, Кадрәк, Тауасты Байлар авылларында үткән әдәби-музыкаль кичәләрдә дә Рәшит Гәрәйгә зур хөрмәт күрсәтелде.

### ШАГЫЙРӘГӘ — ЧӘЧӘКЛӘР

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, күренекле шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның 50 еллыгына багышлап, шигырь, җыр-моң бәйрәме уздырылды. Юбилярны котларга аңа тормыш бүләк иткән Актаныш районының Пучы авылыннан да, гомеренең шактый зур өлеше узган Әтнә районының Күлле-Киме авылыннан да байтак кунаклар килгән иде. Алар Л. Шагыйрьҗанга кайнар тәбрик сүзләре әйттеләр, истәлекле бүләкләр, чәчәкләр тапшырдылар.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Л. Кустабаева, Г. Камал театрының танылган артисткасы Н. Ихсанова, «Мәдәни җомга» газетенең баш мөхәррире, шагыйрь З. Мансуров һәм башкалар, үзләре эшләгән иҗат коллективлары исеменнән дә котлап, юбилярга иң изге теләкләрен җиткерделәр. Күренекле артистлардан У. Әлмиев, Гөлзадә, И. Биктаһиров, К. Хәйретдинова, Л. Маслова, Д. Закиров һ. б. юбиляр сүзләренә язылган һәм ул яраткан җырларны башкардылар.

### ТУФАН ТУГАН ТУФРАКТА

Татар халкының атаклы шагыйре Х. Туфанның тууына 95 яшь тулган көннәрдә бер төркем язучылар аның туган ягына — Аксубай районының Иске Кармәт авылына килделәр. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, драматург Т. Миңнуллин, шагыйрьләрдән Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, Хәйдәр, әдибә Н. Гыйматдинова олуг язучыбызның музеенда һәм мәчеттә булдылар, укучылар белән очраштылар. Аксубай районы хакимияте башлыгы М. Халитов белән сөйләшүләр барышында Х. Туфан музеен киләчәктә тагын да киңәйтеп, аны мемориаль үзәккә әверелдерү мәсьәләсе дә күтәрелде.

### ШАГЫЙРЬНЕ ИСКӘ АЛУ

«Казан утлары» журналында озак еллар эшләгән каләмдәшебез, Г. Исхакый бүләге лауреаты шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов 1995 елның гыйнвар аенда арабыздан киткән иде. Аның туган ягы Баулы районында 27—29 ноябрьдә әдипне искә алу көннәре булып узды.

Кичәнең иң беренчесе шагыйрьнең туган авылы — Татар Кандызы мәдәният йортында үткәрелде. Язучылардан Айдар Хәлим һәм Рашат Низамиев, Сара Садыйкова исемендәге мәдәни-хәйрия фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов, җырчылардан Габдулла Рәхимкулов һәм Фердинанд Сәлахов, композитор Сафиян Ибраһимов, артист Илдус Әхмәтҗанов, шагыйрьнең тормыш юлдашы Луиза ханым Әхмәтҗанова тамашачылар алдында Рәшит Әхмәтҗанов турындагы истәлекләрен уртаклаштылар. Кичәдә шагыйрь сүзләренә язылган җырлар да яңгырады.

Казаннан килгән кунакларны, сәнгать әһелләрен икенче көнне Баулы районы хакимияте башлыгы Наил Зарипов кабул итте. Кунаклар район музеенда, мәктәп-гимназиядә, сәнгать-музыка мәктәбендә булдылар, чыгыш ясадылар. Очрашуларның йомгаклау өлеше районның М. Җәлил исемендәге мәдәният йортында үткәрелде. Әдәби-музыкаль кичә барышында шагыйрьнең иҗатын пропагандалау, аның истәлек-ядкарен ныгытып калдыру буенча байтак кына эшлекле тәкъдимнәр дә әйтелде.

## *СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНДА*

### КОМПОЗИТОРЛАР КОРЫЛТАЕ

Мәскәүдә Россия Федерациясе композиторларының чираттагы корылтае булып үтте. Аның эшендә Татарстан вәкилләре — танылган композиторларыбыздан Ә. Бакиров, М. Яруллин, Ф. Әхмәтов һәм иҗади берлек рәисе Р. Кәлимуллин да катнашты. «Россия музыкасы киңлекләре» фестивалендә республикабызның иҗат көчләре дә чыгыш ясап, тагын бер мәртәбә үзләренең зур башкару осталыкларын күрсәттеләр.

### КАЗАН КУРЧАКЛАРЫ — ТӨРКИЯДӘ

Казан дәүләт курчак театрының татар группасы артистлары, театрларның Адана шәһәрендә (Төркия) үткәрелгән II Халыкара фестивалендә катнашып, тамашачыларга «Ат өреккән шомлы төн» дигән спектакль күрсәттеләр һәм зур уңыш казандылар. Танылган шагыйрь Зөлфәтнең бу пьесасы Г. Тукайның һәркемгә мәгълүм «Су анасы» исемле тезмә әсәренә нигезләнеп язылган. Спектакльнең музыкасы исә композитор М. Шәмсетдинова тарафыннан иҗат ителгән.

### ТАТАР БИЮЕ АЛТЫНГА ТИҢ

Анкарада үткәрелгән төрки халыклар фестивалендә Казанның Химиклар сараеннан барган «Яшьлек» бию ансамбле өч алтын медальгә лаек булды. Ансамбльнең программасында дистәгә якын татар һәм шулай ук башкорт, урыс биюләре бар иде. Татарстан биючеләре Албания, Болгария, Чехия, Төркия, Кипр кебек илләрнең биючеләре арасында барган иҗади бәйгедә җиңүчеләр дип табылды.

### ГӨЛЗАДӘНЕҢ ХӘЙРИЯ КОНЦЕРТЛАРЫ

Яңа ел алдыннан Татарстанның атказанган артисты, М. Җәлил бүләге лауреаты Гөлзадә Сафиуллина Ватан сугышында катнашкан ветераннар өчен хәйрия концертлары оештырды. Бу тамашада нәфис сүз остасы Айрат Арсланов, язучы Батулла һәм Гөлзадә ханым җитәкли торган «Мирас» җәмгыяте музыкантлары, һәвәскәр артистлар катнашты. Һәр ике концерт та Тинчурин театрында зур уңыш белән узды.

## *КОТЛЫЙБЫЗ, СӨЕНӘБЕЗ!*

### ДӨНЬЯНЫҢ ТАНЫЛГАН ЭШЛЕКЛЕСЕ

«Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Ринат Галиевның биографиясе «Дөньяның танылган биш мең эшлеклесе» дигән тәрҗемәи белешмәнең бишенче басмасына кертелде. Әлеге китап 28 ел дәвамында Американың Биография институты тарафыннан нәшер ителә һәм анда эше, осталыгы һәм кылган гамәлләре белән дөньякүләм танылу алган атаклы шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре яктыртыла.

### ФОЛЬКЛОРЧЫ — ФӘН ДОКТОРЫ

Татарстан Фәннәр академиясендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында танылган фольклор галиме Хуҗиәхмәт Мәхмүтов «Татар фольклорының афористик жанрлары» дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Рәсми оппонентлар А. Алиева (Мәскәү), С. Галин (Уфа), Н. Юзиев (Казан) һәм тикшерүдә катнашучылардан Х. Миңнегулов, А. Китиков (Йошкар-Ола), Ә. Сөләйманов (Уфа), Н. Хисамов, Ф. Солтановлар диссертациягә югары бәя бирделәр, аның татар фольклор фәненә зур өлеш кертүен билгеләп үттеләр.

### БЕРТУГАН НӘҖМЕТДИНОВАЛАР — СПОРТ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

Екатеринбург шәһәренең спорт мәктәбендә нәфис гимнастика өлкәсендә шөһрәт казанган дүрт бертуган Нәҗметдиноваларны хөрмәтләү кичәсе булды. Әлеге татар кызларыннан Лилия, мәсәлән, нәфис гимнастика буенча илдә иң беренче атказанган спорт мастеры. Әлфия — спортның әлеге төре буенча дөнья чемпионы, Роза — күп мәртәбәләр ил беренчелегендә җиңү яулаган гүзәл, хәзер — Россия Федерациясенең атказанган тренеры. Илмира да — спорт остасы... Инде хәзер алмашка кызлары үсеп килә. Бәйрәм кичәсендә дә алар кызлары белән бергәләшеп чыгыш ясадылар.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе — рәссам Рәшит Имашевка, Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов Указы нигезендә, «Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# ЧИКСЕЗ МАНЗАРА — ЧИКСЕЗ КҮҢЕЛ...

Табигатьнең шагыйрьләре бар, тарихның — елъязмачылары. Берәүләре үз талантын мәңгелек гүзәллеккә багышлый, бүтәннәре — дәвергә. Кемнең бәхете ничек бит, меңләгән кешеләр арасыннан берәү ифрат та озак иҗади бәхеткә лаек булып чыга: ул — һәр вакыйганы терки белгән елъязмачы да, чорының көзгесе дә... Юл ахырына житкәндә ул шәхес шагыйрь булырга да, фәйләсуф булырга да өлгерә. Рәссам Мәхмүд Госман улы Госманов — нәкъ менә шундый шәхесләрнең берсе. Иҗади гомере озын аның, нәфис сәнгатькә багышлаган эшләре чиксез. Нәфис сәнгатьнең агымнары күп төрле. Ләкин бу рәссамның сәләте гадәти саналган сәнгать кануннарына, гореф-гадәтләренә генә сыеп бетә алмый. Дәлилләрне сурәтләү, лирика хакында тирәнтен уйланырга, дәвам һәм барысын да үзенә сыйдырган күләм-киңлек хакында җентекләп уйланырга кирәк...

Рәссамның язмышы бүген уйлап чыгарылган серле әкиятләргә, тылсымнарга тартенә. Һәм боларның барысы да рәссамның иҗади иманына барып ялгана. Татарстандагы Кукмара төбәгенең Адай авылында, 1918 елда дөньяга килгән җир сөрүче улы М. Госманов 1938 елда Казанның сынлы сәнгать уку йортын тәмамлап чыккан, шул ук елда солдат итеп алынган, биленә каеш салынган... Сафтагы солдат буларак, мең җәфа күрә-күрә чигенгән, соңыннан Сталинградтан алып Берлингача барып җиткән.

Госмановның фронтта тиз-тиз генә ясап алган рәсемнәреннән сугыш үзе безгә карап тора: хәлдән тайган кешеләр... Күзләренә әрнү-авырту сеңгән җаннар... Куллары махра тәмәкесеннән саргаеп беткән. Әнә, безнең җимерелеп беткән шәһәрләребез... Әнә, аларның без яңадан азат иткәндәге хәле... Дошман дзотларының сукыраеп калган күзләре... Рәссам пумалачыгы бу коточкыч сугыш манзараларын һай күп ясаячак әле. Госманов баталиzмы — сугыш манзаралары — инде сугыш узгач та безне тетрәндерер, төсләр күчеше күкрәп-тетрәп торыр, тыныч чорлар килсә дә мең кояш берьюлы шартлап ярылыр сыман тоелыр.

Рәссам 1950 еллардан башлап Татарстан нефте дөньясын сурәтләргә тотынды. Рәсемнәрдә әр-яңа төсмерләр пәйда булды: күпереп үләп үскән болыннар, Эйфель манарасыдай җиргә каныккан нефть манаралары, «кара алтын» фонтаннары һәм нефть чыгаручы каһарманнар күрене башлады. Рәссам бу темага төрле яктан килеп карады. Ниһаять, зур рәсемнәр иҗат итеде: «Татарстан нефтьчеләренең иртәсе», «Оста М. Гыймазов бригадасы». Бусы — төркемле портрерт. Натура этюдлары да барлыкка килде — Баулы-Әлмәт төбәге манзаралары, тимер-бизәк шикелле нефть манаралары, зур көчәнешле ток чыбыклары эленгән манаралар... Рәссам боларны күпләгән төрле аһәң яңгырашы дәрәҗәсенә житкереп сурәтләгән. «Шишкин ватанында» яки «Яңа Чулман» картиналарына гына күз салыгыз! Рәссам Чулман якларының сәнгатенә кое төбенә төшеп җиткәндәй төшә алган, иң нечкә кан тамырларына кадәр үтеп кергән. Дөнья һәр ноктасына кадәр дөрес, камил. Һәр төс сулкылдап тора. Рәссамның җан дәрте — шунда!

Ул сугышның кара-кызыл төсләрен аңлый, сәнагатчылык манзараларын да күрә («Миңлебай нефть комбинаты», «Оргсинтез»), ил белән бергә һәр чуалыш чорын гизә... һәм, көтмәгәндә генә, үз туган иленең гүзәллекләрен тирәнтен тоя башлый. Сагындырган гүзәллек! Менә ул — Идел, Чулман... Менә ул мин туып-үскән җирнең аяз күге! Менә ул — борынгы бабайлар төзегән йортлар («Казан» дип аталган триптих — өч рәсем бәйләме!) Акыл зирәклеге менә шунда!

Табигать белән Кеше бер үк — Госманов рәссам буларак шушы фикерне раслый. Чынны сурәтләүче рәссам форма белән мавыкмый, ул үзе форма кочагына ташлана, агымына чумып югала... Ул шушы агымны сәнгатьнең бөек көче итеп таный — шәхеснең дөньядан өстенлек, илаһияткә ия булуы нәкъ менә шунда. Гапгади түтәлне сәнгать әсәре итә белгән гаҗәеп табигать белгече ул.

**Карина БУЛЫЧЕВА.**

**Тышлыкның беренче битендә:** Татарстанның халык рәссамы М. Госмановның «Яңа ел белән» картинасыннан фотокүчермә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Илдус Гыйләҗев.

# ТАНЫШ БУЛЫЙК: «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ




Татарстан Республикасы Милли нәшрияты «Мәгариф» — нигезе гасыр башында ук салынган шул исемдә нәшриятның рухи дәвамчысы, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр чыгару үзәге.

Бүген «Мәгариф» — дәреслекләр чыгаручы иң зур нәшриятларның берсе, ул елына йөзләгән исемдә ике миллион данәдән артыграк тираж белән китап чыгара. Дәреслек һәм методик әдәбияттан тыш, балалар бакчасы өчен кулланмалар, татар һәм рус телләрендә сүзлек һәм белешмә әсбаплар, матур бизәкле әдәби китаплар да «Мәгариф» нәшриятында дөнья күрә.

«Мәгариф» нәшрияты татар теле һәм әдәбиятыннан өр-яңа дәреслекләр һәм уку әсбаплары эшләүнең дәүләт программасын тормышка ашыра. Аларның бер өлеше — рус телендә сөйләшүче балалар өчен.

Милли мәктәпләр өчен «Мәгариф» нәшрияты чыгарган рус теле дәреслекләре белгечләр тарафыннан югары бәя алды. Һәр дәреслек үзенең методик кулланмасы һәм сөйләм үстерү ярдәмлеге белән бергә тәкъдим ителә.

Нәшриятның колачын һәм изге ниятләрен 1996 елда гамәлгә ашачак тематик планда да күрергә мөмкин. Иҗат перспективалары ифрат зур, киң. Ул — укучылар өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре, укыту-методик һәм педагогик әдәбият, ул — сүзлекләр, белешмәләр һәм матур әдәбият үрнәкләре. Нәшрият быелгысы елны төрле профильдәге 120 дән артык китап бастырырга җыена. Шуларның 20 ләбе матур әдәбият китабы. Дәрестән тыш уку өчен өстәмә әдәбият — классик мирас һәм бүгенге әдәбият үрнәкләре — «Мәгариф китапханәсе» дигән махсус сериядә чыгачак алар.

Мәскәүнең «Просвещение» нәшрияты белән иҗади хезмәттәшлектә «Мәгариф» Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең укыту татар телендә алып барыла торган мәктәпләре өчен төгәл фәннәр һәм табигать белеменнән дәреслекләрнең тулы җыелмасын чыгара. Соңгы елларда югары уку йортлары өчен татарча дәреслекләр чыгаруда беренче адымнар ясалды.


Тукай замандашлары традициясен дәвам итеп, «Мәгариф» нәшрияты «Балалар күнеле» сериясен яңартып җибәрде. Бу сериядән нәниләр өчен гаҗәеп бизәкләргә төрелеп мавыктыргыч әкиятләр, хикәяләр һәм шигырьләр чыга. Яшь буынны дөнья әдәбияты классикасы белән таныштыру да — нәшриятның мөһим бурычларыннан берсе.

Нәшрият хезмәткәрләре дәреслекләрне кызыклы һәм матур итеп чыгаруда көчләрен дә, вакытларын да кызганмыйлар.

«Мәгариф» нәшрияты белән атаклы галимнәр, танылган язучылар һәм рәссамнар хезмәттәшлек итә.

**«Мәгариф» нәшриятының адресы:**
**Казан, Бауман ур., 19.**
**Телефоннар: 32-49-97; 32-11-90.**

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог